ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

6. 1991



# 1991 ЕЛГЫ ТУКАЙ БҮЛӘГЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ



Ә. Кәримуллин



Г. Зәйнашева



А. Монасыйпов

**Татарстан ССР Министрлар Советы**
**ТССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитеты**
1991 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирү турында карар кабул иттеләр.

Премияләр:

Язучы **Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллинга** — «У истоков татарской книги» (от начала возникновения до 60-х годов XIX века) (Татарстан китап нәшрияты, 1971 ел), «Татарская книга пореформенной России» (Татарстан китап нәшрияты, 1983 ел), «Татарская книга начала XX века» (Татарстан китап нәшрияты, 1974 ел) трилогиясе өчен;

Шагыйрә **Гөлшат Хисам кызы Зәйнашевага** — «Илле җыр» (Татарстан китап нәшрияты, 1988 ел) китабы өчен;

Композитор **Алмаз Закир улы Монасыйповка** — «Муса Җәлил» симфония-поэмасы (1973 ел), «Тукай ритмнарында» вокаль-симфоник поэмасы (1976 ел), «Салих Сәйдәшевка музыкаль бүләк» симфония-поэмасы (1990 ел) өчен бирелде.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1991

6


## *Бу санда*


Татарстан: кичә, бүген, иртәгә. *Түгәрәк өстәл янында галимнәр, язучылар, сәяси эшлеклеләр* . . . 3

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ә. БАЯНОВ. Җәй белән җәй арасы. *Повесть* . . 22
Р. НИЗАМИЕВ. Кар кеше. *Повесть* . . . . 117
Г. ХӘСӘНОВ. Шәфәкъ чыпчыгы. *Парча* . . . 144
М. ӘМИРХАНОВ. Саба җиле. *Хикәя* . . . . 150

ШИГЪРИЯТ

Р. СҮЛТИ. Җырым минем. *Шигырьләр* . . . 107
Ф. ЯХИН. Тормыш, тормыш... *Шигырьләр* . . . 111
Ф. ШӘЕХОВ. Йолдыз булып... *Шигырьләр* . . . 113
Н. САФИНА. Егет җыры. *Шигырьләр* . . . . 115
Х. ИБРАҺИМОВ. Стефани. *Шигырьләр* . . . 141
М. РАЗОВ. Бөре кебек... *Шигырьләр* . . . . 142
Р. АЙМӘТ. «Сукыр тәкә». *Шигырьләр* . . . 143

ПУБЛИЦИСТИКА

Г. РӘХИМ, Б. ХӘСӘНШИН. Сулар һаваң бармы? . . . 158

ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Я. АБДУЛЛИН. Чишелмәгән төеннәр . . . . 163

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. МОРТАЗИН. Шигырьләрдә заман төсмере . . 172
Ф. ӘГЪЗАМОВ. Безгә нинди журналистика кирәк? . . . 175

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

М. ГОСМАНОВ. М. Гафури мирасыннан . . . 179

СӘНГАТЬ

Р. ФӘХРЕТДИНОВ. Хәтер. *(Ф. Вәлиевнең тууына 70 ел)* . . . 182



ТАТАРСТАН ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН



РЕСПУБЛИКАНСКАЯ НАУЧНАЯ БИБ...

*Баш мөхәррир*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘЖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙФИ
*(җаваплы сәркәтип)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш мөхәррир урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек мөхәррире)*
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек мөхәррире)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркәтип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

УКУЧЫ ФИКЕРЕ

Г. ВӘЛИЕВ. Һәр чагыштыру да урынлымы? . . 186

ТӨРЛЕСЕННӘН

Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Борынгы мәхәббәт билгесе . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Котлыйбыз! . . . . . . . . . . . . . . . . 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . . 190
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: повести А. БАЯНОВА «Сколько лет, сколько зим», Р. НИЗАМИЕВА «Снежный человек», рассказы Г. ХАСАНОВА «Дрозд», М. АМИРХАНОВА «Свежий ветерок»; стихи молодых поэтов Р. СУЛЬТИ, Ф. ЯХИНА, Ф. ШАЕХОВА, Н. САФИНОЙ, Х. ИБРАГИМОВА, М. РАЗОВА, Р. АЙМАТ.
«Публицистика»: Татарстан: вчера, сегодня и завтра — за круглым столом ученые, литературоведы, политологи; писатель Г. РАХИМ беседует с директором Волжско-Камского заповедника Б. Хасаншиным об экологических проблемах Татарстана.
«Актуальная проблема»: статья профессора Я. АБДУЛЛИНА «Неразвязанные узлы».
«Литературная критика»: М. МУРТАЗИН. «В стихах дыхание времени»; статья Ф. АГЗАМОВА о проблемах татарской журналистики.
«К истории культуры»: М. УСМАНОВ. «Из литературного наследия М. Гафури».
«Искусство»: статья Р. ФАХРУТДИНОВА «Память» (к 70-летию со дня рождения искусствоведа Ф. Валеева).
Слово читателя.
В номере отмечаются 60-летие Р. Халиуллиной, Г. Сабитова.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Золотой шлем»; известная писательница Лябиба Ихсанова.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Хезмәткәрләр:* Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Г. Хөснетдинова.

Производствога бирелде 11.04.1990 ел. Басарга кул куелды 18.06.1991 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 39943. Заказ И-169. Бәясе 1 сум 50 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1991 ел.

# ТАТАРСТАН: КИЧӘ, БҮГЕН, ИРТӘГӘ

## ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ЯНЫНДА СӨЙЛӘШҮ

*Татарстан Югары Советы сессиясе 1990 елның 30 августында, республикабызны суверен дәүләт дип белдереп, махсус Декларация кабул итте. Хәзер алдыбызда шул Декларациянең асылын тәшкил иткән принципларны тормышка ашыру буенча конкрет бурычлар тора. Шул хакта фикер алышу, киңәшләшү өчен редакциянең түгәрәк өстәле тирәсенә татарның мөхтәрәм әдипләре, галимнәре, дәүләт һәм иҗтимагый оешма җитәкчеләре, мәгариф, сәнгать һәм дин әһелләре җыелды. Әңгәмәне журналның баш мөхәррире, ТССР халык депутаты Равил Фәйзуллин алып барды.*

### Равил Фәйзуллин.

Хөрмәтле иптәшләр!

Әйе, узган елның 30 августында татар галәме елъязмасында тарихка кирәрлек сәхифә язылды, халыклар таныррлык сәяси җиңүгә ирешелде, максат ачыкланды, киләчәккә бару юллары ачыклана төште. Безнең халык күпгасырлык яшәү дәверендә төрле катаклизмнар — җиңелү, югалтулар, афәт-фаҗигалар кичереп, көч-дәрманын шактый ук җуйган булса да, шөкер, иманын, кыйбла-максатын югалтмаган, эчке рухи потенциалын саклаган икән әле! Өмет һәм ышаныч уятты ул август көннәре!

Әмма, мөхтәрәм милләттәшләр, бүгенге көн хакыйкате без теләгән киләчәккә җиңел генә ирешеп булмаячагын һәркөн, һәрдаим искәртеп тора. Декларациядә күрсәтелгән нигез принципларны тормышка ашыру, ягъни Татарстанның мөстәкыйльлеген тәэмин итү процессы гаять зур кыенлыклар аша бара. Сәяси яктан да, икътисади яктан да, рухи-мәдәни яктан да... Халкыбызның мөстәкыйльлек юлындагы хаклы омтылышын, мөкатдәс теләген, изге гамәлен төрлечә бозып күрсәтергә азапланучылар күп. Алар төрле даирәдә бар. Соңгы 9-10 ай эчендә үзәктә дә, кырыйда да, уңда да, сулда да шактый күп күрдек аларны, күп тойдык... Шуңа күрә дә, олы максатка бару юлында ориентирларны дөрес билгеләп, үкенечле ялгышлар ясамас өчен (тарихыбызда алар байтак!), без үткәнне яхшы белергә, бүгенгебезне объектив анализларга, киләчәкне ачык күзалларга тиешбез! Шул хакта бергә киңәш-табыш итәргә җыелдык та.

Тагын шунысы да бар: Татарстан — татар иленең бер өлеше генә. Татар диаспорасы, үзегез беләсез, гаять киң һәм тармаклы. Халкыбыз вәкилләре җирнең кайсы кыйтгасында гына тормасын, аларның күңел күзе Татарстанга төбәлгән. Хәзер безгә игътибар арттыра көчәйде. Моңарчы милләтебезнең төп журналы булып килгән «Казан утлары» тиражының да яртысы чамасы ТССР чикләреннән тышта тарала. Татарстанның киләчәге — читләрдә яшәүче укучыларыбызны да бик кызыксындыра. Тоткан юлыбыз дөрес дип, үз-үзебезне юату бер хәл, ә иманыңны ил-халыкка иңдерә алу — икенче нәрсә. Ахыр чиктә, дөреслек-хакыйкать тә аңлауга-аңлатуга мохтаҗ. Әйдәгез, иптәшләр, ихлас күңелдән чыккан фикерләребезне уртага салып сөйләшик бер!

## Индус Таһиров,

*тарих фәннәре докторы, профессор, КДУның тарих факультеты деканы, ТССРның атказанган фән эшлеклесе, КПССның Татарстан рескомы бюро әгъзасы.*

Иң әүвәл шуны әйтим: республикабыз узган юл, катлаулы тарихыбыз бүгенге омтылышларыбызның җиңүенә куәт өсти. Без үз көрәшебез дәвамында аның данлы сәхифәләренә таянып горур эш итә алабыз.

Мәгълүм ки, хәзер суверенлык өчен көрәшнең икенче, тагын да катлаулырак этабы башланды. Хәрәкәтнең дошманнары яшеренеп тә, ачыктан-ачык та безгә аяк чалмакчы булалар. Кайберәүләр бу максаттан матбугат битләрен файдалана, үзләре язган корамага әллә ничә кешенең имзасын куйдыра. Халыкта, бигрәк тә татар телен белмәүче ватандашлар арасында коткы таратмакчылар. Алар безне көчләп РСФСР составында калдырырга тели.

Декларациябездә, РСФСРга бәйле булмыйбыз, дип белдергән өчен генә безне «сепаратизм» дигән яман хәрәкәттә гаепләмәкчеләр, безгә ил дошманы тамгасы такмакчылар.

Инде, аз гына артка чигенеп, әлеге Декларациянең кабул ителү юлына күз салыйк. Хәтерегездәдер: мөстәкыйльлеккә беренче адымнар халык массаларының «союздашлык» таләп итеп, урамнарга чыгуыннан башланды. Хикмәт нәрсәдә иде соң? Ни өчен халык тулы ирек түгел, ә бары союздаш республика мөмкинлекләрен генә өмет итте?

Чөнки без моңарчы кичергән хәлләрдә, татар өчен, союздаш республикалар тормышы да чиксез хөррият булып күренә иде. Әмма соңгы вакытта, демократия сулышы сизелгәч, үзегез белеп торасыз, күп кенә союздаш республикаларда да канәгатьсезлекләр башланды. Шунда без союздашлыкның да бары хәерчеләр арасындагы, гаделсез бер тигезлек икәнлеген аңладык. Бусы — бер. Икенчедән, Союзга керү — бер халык ихтыярыннан гына килми. Әйтик, сине кабул итәргә теләмәсәләр, ул берлеккә ничек тыкшынмакчы буласың?!

Тулы суверенлык таләбен куярга исә татар халкының нигезле хокукы бар. Азатлык — һәр халыкның табигый хокукы ул. Аны көч белән яулап кына алырга мөмкин.

## Ркаил Зәйдулла,

*шагыйрь, «Идел» журналының бүлек редакторы, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге бүләге иясе.*

Бездән ул хокукны Явыз Иван гаскәрләре тартып алган иде шул инде.

## Индус Таһиров.

Дөрес. Татарлар үзләренең әлеге хокукыннан Казан ханлыгы яулап алынганнан соң мәхрүм ителә. Озак еллардан соң безнең җирдә Октябрь революциясе җиңә. Аның беренче документларыннан саналган «Халыклар хокуклары Декларациясе» Россия халыкларының суверенлыгын таный. Тик бу «тану»ны Сталин чоры сәясәте юкка чыгара. Күргәнегезчә, безнең бүгенге суверенлык әнә шул беренчел баскычларга басу гына әле.

Шулай да житмеш елдан артык вакытта гел буйсынучан гына тормыш алып бара-бара без шактый катлаулы мәсьәләләргә килеп батканбыз. Күп кенә бәхәсле яклар бар: әйтик, татарның үз тимер юлы, су юллары, һава флоты күршеләр карамагына бирелгән. Тел мәсьәләсе дә шактый четерекле. Мин үзем, мәсәлән, әлеге тарихи Декларациябезнең тел турындагы пунктына: «Татарстан республикасы татар һәм рус телләренең дәүләт телләре булып гамәлләшүен гарантияли» дигән сүзләрне кертергә сорадым.

Гомумән, безнең Татарстандагы кайсы вакыйгага гына тукталә башласаң да, кайберәүләр аның РСФСР составында булуын сәбәп итеп, безне чишеп чыкмаслык киртәләр арасында калдырырга тырыша. Әмма, басым ясап әйтергә кирәк, Татарстан республикасының суверенлыкка омтылуын берәү дә, фәнни яктан, яман эш итеп раслый алмаячак. Дөреслек — безнең якта. Һәм моны дәлилләү дә һичнинди кыенлык тудырмый. СССР төзелү тарихына күз салу җитә. Хикмәт шунда ки, СССР үзе РСФСР җирлегендә туа. Шундый бер мәл булып ала: РСФСР, һичнинди махсус

документлар төзеп тормастан, Союз белән тәңгәлләштерелә. Хәтта чит илләр белән элемтәләр төзегәндә дә РСФСР бөтен Союз вазифаларын үз өстенә ала. Илчеләр дә үзгәрми. Кыскасы РСФСР белән СССР икесе бер үк дәүләт рәвешендә кабул ителә. Безнең Татарстан җитәкчеләре, бәхеткә, диик инде, автономия буларак та, килешенү документларын СССР белән генә төзегәннәр. Безнең, РСФСР составына керәбез, дип ирекле төстә солыхлар төзегәнебез юк.

Моны раслау өчен тагын бер мисал бар әле: хәтерегездәдер, моннан берничә дистә еллар элек чуваш, мари кебек халыкларның Россиягә үз теләкләре белән кушылуына 400 ел тулу вакыйгалары билгеләнде. Ул автономияле республика җитәкчеләренә орден-медальләрне бик мул өләштеләр. Бары Татарстан гына, барлык автономияле республикалардан аермалы буларак, телгә дә алынмады. Һәм бу чын дөреслек иде. Чөнки безнең Россиягә ихтыярый кушылганыбыз юк, ә аның составында калуыбыз — өстәге, Мәскәүдәге власть ияләренең әмерен үтәү генә иде ул.

Тагын өстәргә мөмкин. РСФСР әүвәлге үсеш дәверендә автономияле республикаларның союздаш республикаларга үсүен тәэмин итү ролен дә үти. Шул дәвердә аңардан башта автономияле саналган Казахстан, Төркстан, Кыргызстан республикалары союздаш булып аерылып та чыгалар. Без өлгерә алмый калганбыз, заманнар һич көтелмәгән юнәлештә үзгәреп киткән.

## Ркаил Зәйдулла.

Бөтен халыкларны РСФСРга гына туплау уе большевиклардан чыккан ул. Тик тарихта, алар көткәнгә каршы рәвештә, Украина, Белоруссия, Грузия кебек мөстәкыйльлеккә омтылучы республикалар туа. Алар җирләренә дә, телләренә дә үзләре хуҗа булуны алга сөрәләр.

## Рафаэль Хәкимов,

*фәлсәфи фәннәр кандидаты, КПСС рескомының идеология комиссиясе председателе урынбасары, Бөтенсоюз Татар иҗтимагый үзәге идарәсе әгъзасы.*

Телләр мәсьәләсе шулай ук бик тирәнгә китә. Озак еллар буе безнең илдә милләтләрнең кушылу идеологиясе, перспективалы һәм перспективасыз телләр теориясе хакимлек итте. Күп галимнәр «табигый ассимиляцияне» якладылар. Инде мондый заман артта калды кебек. Без хәзер телне милләтләрнең аралашу чарасы гына түгел, ул бөтендөнья кыйммәтләрен саклаучы чара да, дип таныйбыз шикелле.

Бу җәһәттән без — татарларда югалтулар биниһая. Шәһәр яшьләре ана телен белми. Шулай итеп алар милли культурадан да читләште. Татарлар арасында яшәп тә рус мәктәбендә укучы балалар интеллектуаль яктан артта кала. Мәсьәләнең әхлак ягы турында әйтеп торасы да юк: туган телен белмәгән бала, гомумән, тулы кыйммәткә ия түгел.

Кайчак дәүләт теле турындагы проблеманы, Ленинга мөрәҗәгать итеп, кире якка борырга маташалар. Янәсе даһи Ленин дәүләт теле мәсьәләсенә гомумән каршы килгән. Хикмәт шунда ки, Ленин һәр очракта бары тик рус теле турында гына сүз алып барган. Мәсәлән, 1914 елны Ленин, Рус империясе шартларында рус телен дәүләт теле, дип игълан итүнең шовинизм котырынган чорда милли мәктәпләрне кысуга китерүеннән шикләнә. Социалистик революциядән соң исә Ленин милли телләрне саклау өчен законнар җыентыгы булдырырга тәкъдим итә һәм бу тормышка да ашырыла.

Инде килеп, татар телен бездә дәүләт теле дип игълан итү рус һәм башка телләрне чикләүне һич тә күздә тотмый. Бу — телне бетүдән саклап калу, аның дәрәҗәсен күтәрү, аның хокукларын рус теле һәм башка телләр белән тигезләү.

## Индус Таһиров.

Әйе шул. Татар теленә гарантия кирәк. Без аны, рус теле белән рәттән, дәүләт теле итеп таныганбыз икән, инде дәүләт аның саклануын һәм үсешен гарантияләргә тиеш була. Халык киләчәктә үз дәүләтеннән моны таләп итәргә дә хаклы. Бу — аның тарихи 1990 елның 30 август Декларациясендә кабул ителгән хокукы!

## Зиннур Әһлиуллин,

*электрик, Татар иҗтимагый үзәгенең Чаллы бүлеге рәисе.*

Мөхтәрәм галимнәребез, мин сезне тыңлап-тыңлап торам да аптырабрак калам, тарихта тегеләй булган да болай булган — кыскасы, барысы да дөрес булган, тик ул турыда укырлык бер китап та юк. Дәреслекләрнең күбесе ялганга корылган. Безгә тиз арада үз тарихыбыз турында, ничек булган шул килеш басып таратырга кирәк. Югыйсә, яшерен-батырын түгел, безгә кыргыйларга караган кебек карыйлар.

Мин — практик. Мөмкинлек тугач, Татарстанны мөстәкыйль дәүләт итеп күрү теләгеннән без Чаллыда, Казан белән бер вакытта ук диярлек, Иҗтимагый үзәк оештырдык. Безне хәзергә ТИҮнең Чаллы бүлекчәсе, дип йөртәләр. Дөресендә, минемчә, без — үзебез бер зур үзәк. Чөнки күп мәсьәләләрдә Чаллы яшьләре алданрак бара, алар тәвәккәлрәк, фидакарьрәк. Суверенлык мәсьәләсе хәл ителгәндә, дистәләгән яшьләребез, үз хисапларына ял алып, Казанга җыелды. Кем кертсә, шунда кунып, ни бирсәләр, шуны ашап, атна буе Казан мәйданында яттылар.

Оешмабызның төп сыйфаты аның составыннан килә. Бездә эшче яшьләр күп. Аларга, марксистлар әйтмешли, югалтулар берни түгел — кулдагы чылбырлар гына өзелергә мөмкин. Казандагы «Үзәк»тә интеллигенция вәкилләре күп, алар эш югалтудан, абруй төшүдән куркып, алдын-артын карап кына хәрәкәтләнәләр. Хәлиткеч адым ясар чакта куркып калалар. Минем фикеремчә, бары үз мәнфәгатен генә алга сөргән кешеләрдән әллә ни көтеп булмый. Андый көрәшчеләр бервакытта да тулы азатлыкка ирешә алмаячак. Тулы ирек шул юлда шәһит китәргә әзер җаннарга гына тиеш.

## Туфан Миңнуллин,

*драматург, ТССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге, ТССР комсомолының М. Җәлил исемендәге, РСФСРның К. Станиславский исемендәге Дәүләт бүләкләре иясе, СССР халык депутаты.*

Мин Чаллы егетенең бер фикерен аеруча хуплар идем: азатлыкны безгә бирәү дә әзер килеш китереп тоттырырга җыенмый. Мин Мәскәүдә йөреп күпне күрдем. Үз республикабызның суверенлык алуын хуплатып имзалар җыйдым. Бик авыр булды, хәтта төрки республикалар вәкилләре дә безнең РСФСРдан тыш яшәүгә кул чабып тормыйлар. Әйтик, Казахстан җитәкчеләре моны һич тә хупламады. Тагын шуны әйтер идем: безгә бу юлда һич кенә дә кабаланырга ярамый. Иплэп кенә, законнарны нык өйрәнеп, бәйләнергә урын калдырмыйча эшләргә кирәк. Миңа калса, ашыгабыз кебек. Безне шул ук каһәр суккан экстремизмда гаепләүләре бар.

## Зиннур Әһлиуллин.

Минемчә, хәзер яше кырыктан узганнар, гомумән, көрәшкә лаек түгел. Шуңа күрә без, күбрәк, яше кырыкка җитмәгәннәргә йөз тотабыз. Алар милли азатлык өчен гомерләрен дә кызганмый. Өлкәнрәкләр исә куркытылган, аларны кузгатуы кыен. Бәхеткә, безнең Чаллы «Үзәге»ндә яшьләр күп. Шуңа күрә җиңеп чыгуыбызга ышаныч та нык.

Сүз уңаеннан социалистик революциянең җиңүе турында да әйтәсем килә: кызганычка каршы, бу революция, аерым алганда, безнең татар халкы өчен әллә ни бирмәгән. Дөньяның алга киткән илләрендә, күптән инде, базар икътисады хөкем сөрә. Мондый шартлар колониаль системаның таркалуына китерде. Бездә исә, икътисадны санга сукмау аркасында, колониаль системадагы шикелле шартлар сакланып килде.

## Сорау:

Сез, Татарстанга суверенлык сорап, ачлык игълан иттегез, дистә көннәрчә аны җиренә җиткереп үтәдегез. Сәламәтлегегез нык какшады. Үкенмисезме?

## Зиннур Әһлиуллин.

Юк. Үкенмим. Үләргә әзер булмаган кеше ирекка, азатлыкка исәп тотмасын.

## Туфан Миңнуллин.

Без хәзер һәр адымыбызны, илнең кануннарына салып, чамалап атларга тиешбез. Язучыларыбызның РСФСР язучылары съездына катнашмавын да бик теләмичә телгә алдылар. Миңа махсус кеше килде. «Әйдә, ди, РСФСР язучылары исеменнән бергә чыгыш ясыйк!»— ди.

## Ринат Мөхәммәдиев,

*язучы, филология фәннәре кандидаты, ТССР язучылар берлеге рәисе, РСФСР халык депутаты.*

Язучы — милләтнең иң тугрылыклы улы, аның тел сакчысы. Тел булган җирдән милли рух, дин һәм иман да ерак йөрми. Татарстан дәүләт суверенитеты — безнең иң зур казанышыбыз. Узган елның август урталарында Язучылар берлеге идарәсе гадәттән тыш карар кабул итте: Республика иҗат берлекләренең чираттан тыш берләштерелгән Пленумын чакырырга һәм Татарстан Югары Советына мөрәҗәгать кабул итәргә! Бу — иҗат берлекләренең беренче тапкыр «башбаштаклык» күрсәтүе иде. Минем карашымча, әлеге форум тарихи вакыйга булды. Без, җиде иҗат берлеге рәисләре, Югары Совет Рәисе Минтимер ага янына бардык. Ул безнең борчылуны аңлады һәм авыр йөкне үз җилкәсенә алды.

## Минтимер Шәймиев,

*ТССР Югары Советы Рәисе, СССР халык депутаты.*

— Табигый ки, безнең халык хәзер Татарстанны суверен итеп билгеләгән тарихи декларация нигезендә ниләр башкарылуы белән нык кызыксына. Бу уңайдан һәркемнең күңелендә бик күп сораулар бар һәм ул аларга гел яхшы җаваплар гына ишетергә тели. Әмма чынбарлыкка да күз йомарга ярамый. Суверенлык Декларациясе кабул итүчеләр бер без генә түгел. Иң әүвәл халкыбызга да, илнең җитәкче даирәләренә дә үз Декларациябезнең эчтәлеген, алга куелган максатны бәйнә-бәйнә аңлатырга кирәк. Бу җәһәттән матбугатка, шулай ук язучыларыбызга да республикабыз өчен җиң сызганып эшләү — аңлатулар алып бару мөмкинлеге бирелә.

Татарстан җитәкчелеге исә хәлне Мәскәү алдында конкрет төстә тасвирлап, төшендереп бирү белән мәшгуль. Без мәсьәләне, төрле яктан нигезләп, бик җитди иттереп куябыз. Бу юнәлештә мин СССР һәм РСФСР Югары Советы җитәкчеләре белән сөйләштем. Үзебезнең максатны, бурычларны аңлатырга тырыштым. Бәхеткә, бу даирәләрдә безне аңларга теләмәү дигән нәрсә сизелмәде. Хәер, безнең кемгәдер аңлашылмаслык омтылышларыбыз юк бит, бары да ачык: без турыдан-туры Союз килешүен әзерләргә, анда катнашырга һәм кул куярга тиешбез. Без бу эшләрне әйдәп йөрүчеләр арасына Татарстан республикасыннан вәкилләр кертүгә ирештек.

Шунысы да мәгълүм булсын: сүз күбрәк милек турында куера. Әйтеп үтим: Татарстанда турыдан-туры бары Мәскәүгә генә буйсына торган предприятиеләр бик күп, алар безнең предприятиеләрнең 80 процентын тәшкил итә. Киләчәктә бу милек безнеке булырга тиеш. Бүгенге көндә Россиягә караган милек исә 18 процент чамасы. Аның турында без РСФСР җитәкчелеге белән сөйләшеп килешергә тиеш булачакбыз. Бу хакта сүз чыккач, шунысын да ачыклап китәргә кирәктер, мөгаен, без билгеле бер мөмкинлекләр туганчы, РСФСРны исәптән чыгара алмыйбыз.

Татарстанның һәр кешесе бу үзгәртеп коруларның ашык-пошык кына башкарылмаслыгын тирәннән аңласын иде! Сүз бит озак еллар дәвам иткән бәйләнешләрне бөтенләй башка җирлектә — мөстәкыйльлек шартларында яңарту турында бара. Республика җитәкчелегендә, Югары Совет сессияләрендә, Президиумда моңарчы берәү дә үтәмәгән һәм үтәргә мөмкин дә булмаган үзгәртеп коруларга юл ярабыз.

Инде кайбер өлкәләрдә шушы яп-яшь мөстәкыйльлегебезнең матди чишелешләре дә күренә башлады. Әйтик, КамАЗ акционерлык җәмгыятенең 13 процент акцияләре Татарстан хөкүмәте карамагына тапшырыла. Бу — киләчәктә ел саен 14-15 мең «КамАЗ» машинасы турыдан-туры республикага бирелә дигән сүз. Акцияләрнең 25 проценты КамАЗ эшчеләренә, ягъни безнең республика кешеләренә сатылачак. 13 процент акцияләр хәзергә СССР милке сыйфатында кала. Бусы — вакытлыча. Килешү төзелгәндә, бу мәсьәлә яңадан каралачак. Бүген Союзга буйсына торган предприятиеләрнең дә Татарстан карамагына күчүе сәбәпле, киләчәктә КамАЗ акцияләренең 51 процентлары безнең республикада калачак. Калган 41 процентның да язмы-

шы хәл ителеп бетмәгән әле. Аларны акчасы булган һәр предприятиебез сатып алырга мөмкин.

Киләчәктә суверен Татарстанның барлык кереме шул предприятиеләрнең байлыгына, алардан ясак төсендә тотылып калыначак өлешкә бәйле булачак.

Хәзерге вакытта иң бәхәсле мәсьәләләрнең берсе — нефть һәм энергетиканың башка чыганаклары. Үзәк — нефтьне үзендә калдырырга тырыша. Әмма бу юлда да аңлашуларга ирешербез, мөгаен. Үз җирендәге байлыклар өчен бер без генә түгел, башка республикалар да көрәшә. Дөрес, нефть киләчәктә тулаем безгә генә калыр, дип әйтергә иртәрәк. Әмма без Мәскәүдәге һәр сөйләшүне үз файдабызны күздә тотып алып барабыз.

Башкача була да алмый. Безнең халык хәлен яхшыртудан бүтән омтылышыбыз юк. Шуңа күрә мин һәркемнән, бигрәк тә язучылардан, журналны укучылардан да мәсьәләне аңлауларын, башкаларга да аңлатырга тырышуларын сорар идем.

Хәзер без Союз һәм башка республикалар белән эшлекле килешүләргә кул куярга тиешбез. Бу килешүләр ТССР экономикасын алга җибәрерлек булсын иде! Без эшне башкача алып бара алмыйбыз. Үзебезнең Югары Совет сессиясендә кабул иткән Декларациябез безгә бары тик шул юнәлештә генә эш алып барырга кирәклеген кисәтеп тора.

## Азат Зыятдинов,

*Түбән Камадагы «Нефтехим» берләшмәсенең фәнни лаборатория мөдире, техник фәннәр кандидаты, ТИҮнең Түбән Кама бүлекчәсе җитәкчесе, ТССР халык депутаты.*

Үз вакытында, барыбыз бер булып, гигант төзелешләрне хуплый идек. Шулай түгелмени?! Түбән Кама каласын, аның нигезе салынуга сәбәпче булган нефть-химия корылышларын да нинди генә эпитетлар белән мактамадык?! Аның масштаблары, үсеш темплары, дөнья күләмендә дан тоткан продукциясе барыбызны да шатландыра иде. Бүген генә, кырт борылып, барына да кара тамга сугып куярга ашыкмыйк. Мин үзем — оптимист. Түбән Каманың бу биниһая киң колачлы предприятиеләре белән бүген дә горурлансак, һич тә хата булмас.

Сүз дә юк: бу төзелеш безнең тып-тыныч Камабыз буена илнең әллә кай тарафларындагы сукбайларның килеп тулуына сәбәпче булды. Аларның һөнәре юк, милләте безгә ят иде. Икенчедән, берләшмә заводлары төбәкнең саф һавасын бозды, җирләрен киметте. Әмма аның тормышыбызга китергән файдалы якларын да исәпли белергә кирәк. Бу очракта мин матди якны гына күздә тотмыйм. Түбән Кама шәһәре милләтнең шушы төбәгендә яшәүче кешеләренә рухи яктан да байтак нәрсә бирде. Бездә егерме елдан артык инде «Яшьлек» җыр-бию ансамбле иҗат итә. Аның чыгышлары шәһәр халкына — зур бәйрәм. Бусы — бер. Икенчедән, 1965 елны бездә «Кама таңнары» исемле әдәби берләшмә оештырылды. Бу күркәм башлангычны язучы Рахмай Хисмәтуллин әйдәп барды. Әхмәт Гадел, Айдар Хәлим дә ярдәм иттеләр.

Әнә шушы беренче адымнарга нигезләнеп, яңа, шактый тирән эчтәлекле, формасы ягыннан бөтенләй үзгә булган «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсе туды. Ул киң тармаклы, эзләнүчән, шәһәр халкына ифрат бай мәгълүмат бирүчән хәрәкәт булып ныгыды. Аның тәэсире Татарстаннан узып китеп, күрше республикаларга барып җитте. Шул ук вакытта Түбән Кама кешеләре дә әдәбият-сәнгать әһелләренең әллә кай тарафларда яшәүчеләре белән күреп-сөйләшү форсатына ирештеләр.

Бүген күп якларда милли аңны уяту бик тә авыр бер мәсьәләгә әйләнеп калган икән һәм шул ук вакытта безнең төбәктә бу хәл, чагыштырмача, уңайрак чишелеп бара икән, монда, һичшиксез, әнә шул күренешләр — җирле зыялыларның милләт турында һичбер вакытта да онытмавы, җан аямый, үз абруен онытып торып, туган халкына хаклыкны аңлатырга тырышып яшәүләре нәтиҗәсе дияр идем. Еллар буе шушындый рухи эш алып барылганлыктан, бездә Татар иҗтимагый үзәгенең бүлекчәсен булдыру да, чагыштырмача, җиңел булды. Ул рәсми төстә хәтта Казандагыдан да алда туды. 1988 елның декабрендә безнең иҗтимагый үзәгебез бар иде инде. Казан исә оештыру съездын моннан соң ике ай үткәч кенә уздырды.

Инде килеп Түбән Каманы шәһәр иткән төп сәбәп — «Нефтехим» берләшмәсе хәлләренә дә бераз ачыклык кертим. Дөресен әйткәндә, аның Татарстан җирендә корылуына без шулай ук, аек акыл белән, уйлап, уңай бәя бирергә тиешбез. Казаныбыз борын-борыннан атаклы химиклары белән дан тоткан. Русы, татары, яһүде, бер булып, бу серле фәнне баетканнар, берсеннән-берсе кыюрак яңалыклар ачканнар. Әллә ни үсендереп җибәрмәсәләр дә, галимнәр арасында татар балалары да шак-

тый. Гыйлем ага Камайның ачышларына әле булса тулы бәя бирелмәгән. Гаҗәеп бай эзләнүләр алып бара ул, искиткеч файдалы ачышлар ясаган. Андый талантлар тагын да бар, белмибез, эзләнмибез, үстермибез генә.

Түбән Кама берләшмәсе исә яңа фәнни ачышларга, яшь галимнәргә зур юл салды. Мин үзем дә шунда фән кандидаты булдым. Инде менә докторлык диссертациям әзер. «Нефтехим» дистәләрчә галим тәрбияләде. Киләчәктә исә, бигрәк тә яңа шартларны искә алсак, теләге барларга үсү өчен шартлар тагын да зуррак булачак.

«Нефтехим» эшчәнлегенең нинди зур байлык чыганагы икәнлеген аңлату өчен бер генә сан китерәм: аның еллык байлыгы 1 миллиард 200 миллион сумлык. Әгәр Татарстанның суверенлыгын матди яктан да үз кулларыбызга алсак, күрәсезме, Түбән Кама аңа нинди өлеш кертәчәк! Өстәвенә, аның продукциясен теләсә кайсы чит илгә дә сатып була. Ул инде бүген үк дистәләгән илләр белән алыш-биреш итә. Тик, кызганычка каршы, соңгы елларга кадәр бу байлык тулысынча — Үзәк карамагында.

Мин, әлбәттә, бу заводлар тезмәсенең кеше организмына, табигатькә зур зыян салуын да яшерү ягында түгел. Шәһәр халкы агулы газлар тәэсирендә чиргә сабышты, харап булу куркынычы алдында калды. Шунлыктан әлеге зыянны киметү, һавага чыга торган агуларны мөмкин кадәр булдырмаска тырышу безнең беренче бурычка әйләнде.

Кешеләрнең сәламәтлеген ныгыту өчен конкрет эш башладык: башма-баш ярдәмләшү килешүе төзеп, шәһәргә Кытай табиблары чакырылды. Андый кешеләрне кабул итү өчен медсанчасть оештырылды. Хәзер безгә эзлекле рәвештә Кытайдан биш табиб килеп йөри. Алар бик нәтиҗәле ысул белән дәвалыйлар.

Чит илләр белән элемтә башка юнәлештә дә алып барыла. Көнкүреш кирәк-яраклары, автомобильләр кайтартыла. Күргәнегезчә, без бу очракта да шәһәребез халкын, Казанга караганда, иртәрәк тәэмин итә башладык шикелле. Киләчәктә моны тагын да киңәйтеп җибәрергә мөмкинлекләр күренеп тора. Әлеге дә баягы, халыкның гасырлар буе көтеп алган мөстәкыйльлеген генә ныгытырга кирәк булачак.

## Мөхәммәт Сабиров,

*Татарстан республикасының Министрлар Советы рәисе, РСФСР халык депутаты.*

— Мин Түбән Кама вәкиленең сүзләренә ялгап, аны куәтләп берничә аңлатма бирүне кирәк табам.

Республиканың суверенлыгы турында Декларация кабул ителгәннән соң, ни гаҗәп, безгә ифрат күп чит илләр мөрәҗәгать итә башлады. Минем үземә дә, төрле дәрәҗәдәге сөйләшүләрне рәсмиләштерер өчен, Америка Кушма Штатларына һәм Төркиягә барырга туры килде.

Чит илләрдәге бизнесменнарны Татарстанның потенциаль мөмкинлекләре, нефте, нефтехимиясе һәм башка байлыклары, сәүдә итәрлек матди чаралары кызыксындыра. Сүз, әлбәттә, ике якның да файдасын күздә тотып алып барыла. Безнең белән нинди дә булса элемтәләр урнаштырырга алынган илләр, безнең илдәге гомуми кризисны күздә тотып, кайбер ташламаларга да әзер. Бигрәк тә — Төркия. Аларның вәкилләре безгә килгәндә дә, мин Төркиядә булган чакта да Татарстанга зур хөрмәт сизелде. Аңлашыладыр: мондый илләрнең игътибарын тарту өчен Татарстанның һәрьяклап алга киткән дәүләт булуы кирәк.

Әгәр алга сызылган программабыз без уйлаганча үсеш алса, Татарстанның якын киләчәктә халыкара аренага чыгуы бик ихтимал. Без шуны күздә тотып чит илләр белән ныклы элемтә булдырырдай махсус министрлык оештырырга уйлыйбыз. Аерым коллективлар, оешмалар, әйтик, иҗат берлекләре дә чит илдәге коллегалары белән иркенләп делегацияләр алмаша алыр иде.

Төркиянең безгә булган мөнәсәбәте шактый өметле. Казанга беренче булып килгән «Дегерә» фирмасы президенты Дегер Эртург әфәнде ачыктан-ачык:

— Минем визитның төп максаты — Төркия республикасының сәүдә һәм промышленность эшләре министры исеменнән сезнең республиканың Министрлар Советы Рәисе М. Г. Сабировны рәсми визит белән Төркиягә чакыру,— диде.

Һәм үткән елның декабрендә, Төркиягә баргач, мине суверен дәүләт җитәкчеләренә күрсәтелә торган рәсми Беркетмә нигезендә кабул иттеләр.

Визит дәвамында премьер министр урынбасары Шюкрю Юрор һәм мин Төркия Республикасы белән Татарстан арасында сәүдә-икътисади хезмәттәшлекне үстерү буенча үзара аңлашу турындагы документка кул куйдык. Аның нигезендә Татарстан быел ук Төркиягә нефть сатарга тырышачак. Шулай ук «КамАЗ» машиналары, агач, торф кебек нәрсәләр җибәрү мәсьәләсе каралачак.

Аңлатып үтик: нефтьне безгә бирергә әзерләнеп торучылар юк. Шулай да, төрлечә аңлаша башлагач, елга бер миллион тонна нефтьне безнең карамакка тапшырдылар. Имзалар салынган кәгазь — безнең кулда.

Төркия, моннан тыш, безгә промышленность товарлары, азык-төлек бирүне дә арттырырга уйлый. Шушы арада ит, үсемлек мае кәтелә. Ә Төркиядә Татарстанның Сәүдә йорты ачылачак.

Безгә үзара аралашу-аңлашу өчен әзерлекле белгечләр кирәк. Төркия мәсьәләнең бу ягын тулысынча үз өстенә ала. Дегер әфәнде, мәсәлән, шушы беренче очрашуда ук, Казан университетының шәрык телләрен өйрәнүче студентларына 25 мең герман маркасы күләмендә акча калдырды.

Татарстан белән Төркия арасында сәяхәтчеләр алмашуны активлаштыру да күздә тотыла. Гомумән, алда — эшләр күп. Аларны киң колачлап алып бару өчен безгә республикабызның суверенлыгын чын җирлектә тәэмин итү кирәк.

АКШ тан килүчеләр дә бар. Мәсәлән, «Дрессер» фирмасы вице-президенты Кен Аллен әфәнде һәм аларның тагын берничә вәкиле булып китте.

Алар үзләрен кызыксындырган предприятиеләрдә: «Казанкомпрессормаш», «Татнефтебитум», «Татнефть» кебек зур коллективларның җитәкчеләре белән очрашып сөйләштеләр. Уртак эшләр билгеләнде. Бу килешүләрнең нәтиҗәсе буларак бездә берничә елдан соң нефтьне эшкәртү заводы эшли башлаячак. «Татнефть» берләшмәсе исә «Дрессер» фирмасына девон нефтен эшкәртү заводының техник документларын тапшырачак. Бу яңа эшләрнең беркетмәсенә миңа кул куярга туры килде. Мин, бик рәхәтләнеп, хәерле сәгатьтә! дип, бу вазифамны үтәдем.

Ел башында Татарстанга Гонконгның эшкуарлары килде. Алар шулай ук нефть якларында, Алабугада, Менделеев шәһәрендәге химия заводында булдылар. Гонконг белән дә шактый кирәкле һәм файдалы килешүләр төзү күздә тотыла.

Тагын шуны кисәтәсем килә: чит илләр безнең республикадагы халыклар арасындагы дустанә мөнәсәбәтне бик хуплыйлар. Алар өчен дә илнең тыныч хезмәт белән мәшгуль булуы, кешеләрнең тату-дус яшәве хәерлерәк. Шуңа күрә безгә республикабыздагы төрле милләт кешеләренең үзара тату яшәвен бәяли белергә, аны тагын да ныгытырга кирәк.

Инде үзебездәге кайбер эшләргә тукталыйм. Быелның март аеннан башлап без республикадагы пенсионерларга 100 сум акча бирү мөмкинлеге тудырдык. Бу, ил күләмендә — 70 сум гына каралган. Аннары менә Язучылар Берлеге һәм комсомол комитеты тарафыннан чыгарыла торган «Салават күпере» журналына юлны киңәйтә төштек. Журнал моңарчы аена 25 мең данә басыла иде. Ил күләмендә ихтыяҗ ифрат зур. Уйлаштык, киңәштек, санап-санап караштык та балалар өчен чыгарыла торган бу кадерле басманың санын 100 меңгә җиткерергә мөмкинлек таптык.

Шулай ук үзебезнең Фәннәр Академиясен ачу мәсьәләсе дә, әгәр суверенлык турында авыз ачмасак, тиз генә хәл ителмәс иде. Дөрес, моңа ирешү өчен әле хәзер дә күп тырышырга туры киләчәк, әмма җиңеп чыкмаслык каршылыклар күренми инде. Халык әйтмешли, башланган эш — беткән эш.

Халык суверенлыкның безгә киң юллар ачуына шикләнмәсен иде. Шул эшләрнең эчендә кайнаганга, безгә моның әһәмияте бик нык сизелә. Элек бик кечкенә эш өчен дә Мәскәү рөхсәтен ала алмый интегә идек. Хәзер бу юнәлештә нык алга киттек. Киләчәктә, һичшиксез, тагын да җиңелрәк булыр.

## Марсель Сәлимҗанов,

*СССРның халык артисты, ТССРның Г. Тукай исемендәге, РСФСРның К. Станиславский исемендәге Дәүләт бүләкләре иясе, Г. Камал исемендәге театрның баш режиссеры.*

Бердәмлектән, дуслыктан башка, республикалар белән аралашып яшәүдән башка безнең театрның иҗат тормышын күз алдына да китереп булмый. Язучыларыбыз, әнә тоттылар да РСФСР Язучылары берлегеннән чыктылар, съездларына да бармадылар. Алда безнең дә шундый ук чара тора: безгә РСФСР театр эшлеклеләре берлеге съездына катнашмый булмый. Бу бик катлаулы. Матди мәсьәләләр белән бәйләнгән. Беренчедән, РСФСР театр эшлеклеләре берлеге безнең пенсия яшендәге артистларыбызга аларның хезмәт хакы күләмендә пенсия алуын тәэмин итә. Моның әһәмиятен аңлыйсыздыр: бу — театрга яшь талантлар килүгә юл ача.

Икенчедән, театр сәнгате, гомумән, кысалар эчендә бикләнүне кичерә алмый. Моннан берничә ел элек Молдова республикасының 100 еллык тарихы булган театры үзәк белән арасын өзгән иде. Шул уйланмый эшләнгән адым тарихи театрның тәмам сүнеп калуына китерде.

Сорау.

Россия матди ярдәмне язучыларга да күрсәтә иде. Мөстәкыйльлек хакына Татарстан язучылары Россия нәшриятларыннан да, кайбер иҗат йортларыннан да баш тарттылар. Сез бу хакта ни уйлыйсыз?

## Ринат Таҗетдинов,

*ТССРның һәм РСФСРның халык артисты, ТССРның Г. Тукай исемендәге һәм СССРның Дәүләт бүләкләре иясе, Татарстан театр эшлеклеләре берлеге рәисе.*

Аңлагыз әле, җәмәгать! Без бүген үк РСФСРның безгә күрсәткән яхшылыкларыннан баш тартырлык хәлдә түгел. Әгәр без пенсия яшендәге артистларыбызга өстәмә түли алмасак, алар, картлыкларын аямыйча, театрда эшләп йөрергә мәҗбүр булачаклар. Аннары, РСФСР берлеге безгә квартиралар, ял базалары булдыру өчен дә акча бирә. Татарстан хөкүмәтенең исә хәзер үк безгә шул кадәр чыгымнар тотарга мөмкинлеге һич юк. Дистә еллар буе сакланып килгән дуслык-ярдәмләшү җепләрен без алай тиз генә өзеп ташлый алмыйбыз.

Сорау.

Аларның сезгә киләчәктә тагын да күбрәк бирүе ихтимал. Гомер буе кызыгып яшәрсезме? Халык моны ничек кабул итәр? Кайбер митингларда: «Театр милләтне майлы калҗага алыштырды»,— дигән плакатлар да күренә. Киләчәктә нишләрсез?

## Марсель Сәлимҗанов.

Сүз алай чик-чамасыз озак вакытлар турында бармый. Без үз хәлебезне, Татарстан язучыларының тәвәккәл адымнары белән чагыштыра-чагыштыра, аңлатып та күрсәттек инде. РСФСР театр эшлеклеләре берлегенең рәисе Михаил Ульянов безнең хәлне яхшы аңлый. Киләчәктә без Россиянең төрле төбәкләре белән килешүләр төзиячәкбез. Үзегез беләсез: татар халкы күп өлкәләргә таралган, театрның гастрольләрен һәр җирдә көтеп алалар. Без читтәге милләттәшләребез хакына да бүген үк мөнәсәбәтләрне кискенләштермәскә булдык.

## Равил Фәйзуллин.

Мәсьәләгә бер яктан гына караганда, бүгенге көндә «Казан утлары» журналы да матди кыенлыклар кичерә: бәяләр артты, тираж кимеде... Шуны белеп булса кирәк, РСФСР Язучылар берлеге җитәкчелегеннән миңа да шалтыратканнар иде: «Күпме кирәк сезгә?»— диләр. Мондый кайгыртучанлыкның сере әллә ни тирәндә ятмый. Аңлашыла.

Безнең ярдәм сорарга исәп юк. Күрәсең, мөстәкыйльлеккә чыгу юлында күпмедер югалтуларга, корбаннарга бармый мөмкин түгелдер.

## Туфан Миңнуллин.

Иптәшләр, театрның хәле миңа якыннан таныш. Язучылар берлеге белән театр арасына тигезлек билгесе куеп булмый. Ашыкмыйк, алай ярамас.

## Габделбәр Фәйзрахманов,

*тарих фәннәре кандидаты, Татар иҗтимагый үзәгенең рәис-координаторы.*

Мин бу «ашыкмау» сәясәте белән бик үк ризалашып бетә алмыйм. Татар халкы, сабыр итә-итә, буйсынуның аргы ягына барып чыккан инде. Гасыр арты гасыр үткән. Мөстәкыйльлек алырга мөмкин булган ситуацияләр еш кабатланмый. Берничәсендә авыз ачып калганбыз. Инде Горбачев тарафыннан тудырылган бу җайдан да файдалана алмасак, тагын да бичаралыкка төшәчәкбез.

Татар иҗтимагый үзәге бу юлда шактый эшләр башкарды. Халык күреп тора. Алга корылган планнар тагын да катлаулырак. Безгә җәмәгатьчелекнең ярдәме, гомуми уяну, күтәрелеш кирәк. Халык һаман йоклый. Зыялылар да бердәм түгел. Халыкны бердәмлеккә өндисе урында кайбер зыялыларыбыз кирегә тырный башлый.

## Ркаил Зәйдулла.

Заманында Болгар, Казан ханлыгы кебек дәүләтләр тоткан безнең халык бүгенгедәй хокуксызлык белән беркайчан да килешә алмаячак.

Безгә өйрәтүче генә булмаган, яшергәннәр; чынлыкта исә милли дәүләтчелекне кире кайтару өчен көрәш бервакытта да тукталмаган.

## Сәлам Алишев,

*тарих фәннәре докторы.*

Шагыйрь дөресен әйтә. Бу теманың озак еллар өйрәнелми ятуы да хак. Татарларның милли азатлык көрәшен әледән-әле яңартып торуларын мин җентекләп тикшердем. Фәнни хезмәтләремә нигезендә шул күзәтүләр ята. Пугачев явында булсын, Батырша җитәкчелегендәге баш күтәрүләрдә булсын — татарлар көрәшнең үзәгендә кайнаган. Пугачевның таянычлары арасында Бәхтияр Канкаевның булуы турында инде, шөкер, шактый язылды. Гайрәтле Батырша җитәкчелегендәге күтәрелешне дә безгә тиешле югарылыкта яктыртырга кирәк иде.

## Равил Фәйзуллин.

Сәлам ага, сезнең бу сүзегезгә безнең җавап әзер. Үзегез дә күрәсездер: соңгы елларда журнал тарихи темага язылган әсәрләрне шактый мул бастыра. Сандыгыбызда Җ. Рәхимовның «Батырша» романы да бар. Бу күләмле әсәр өйрәнелү стадиясендә. Киләсе елга аны бастырып чыгарырга исәплибез.

## Ркаил Зәйдулла.

Егерменче гасыр башындагы буржуаз мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә туган яңа күтәрелешләр дә бик кызыклы. Бу чорда тарих сәхнәсенә татар капиталистлары да керә. Без аларны җитмеш ел буе тоташ сүгеп кенә килдек. Минемчә, ниһаять, аларның татар мәдәниятенә керткән мактаулы өлешләре турында дөресен әйтергә дә кирәктер инде.

Хәзерге университетларга тиң торырлык мәдрәсәләребез әнә шул каһәрләнгән капиталистлар, татар миллионерлары тарафыннан тәэмин ителеп килгән. Мәсәлән, «Галия» мәдрәсәсен салдыру өчен Садретдин бай Нәзиров — 100 мең, Сәлимгәрәй Җантурин 30 мең сум бирә. Мәгълүм булганча, мәдрәсәне тоту өчен дә урыс хөкүмәте нинди дер чыгым ясарга атлыгып тормаган, барысы да милли фидакарьләрнең ихлас күңелдән күрсәткән ярдәме аркасында үскән. Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсен миллионер Хөсәенов салдыра. Шул ук кеше милләт эшләре өчен ярты миллион акчасын васыять итә, бу акчага шактый татар егетләре Аурупа университетларында укып чыга.

Февраль революциясеннән соң татар дәүләтен булдырырдай җитди адым да ясалган, «Милли мәҗлес» оештырыла, тик Октябрь фетнәсе аны да юкка чыгара. Мин илдә урнаштырылган тотрыклы тоталитар режимны большевизм яки Сталин тудырган тәртипләрдән генә эзләүгә каршы. Моны барыннан да бигрәк күп гасырлар буе барлык милләтләрне үзенә буйсындырып яшәгән урысларның психологиясеннән күрәм мин.

Тулы мөстәкыйльлеккә ирешсә, Татарстанда яшәүче һәркемгә мул тормыш тәэмин ителүе ап-ачык, әмма кайберәүләр (күпчелек очракта — урыслар) моңа каршы. Алар, кулларыннан элекке форсатны ычкындырмау бәрабәренә, ач яшәргә дә, бүгенгедәй хәерче булырга да риза.

Хәзер әле анда, әле монда, аз санлы халыкларны өркетү өчен, хәрби көч кулланулар да ешайды. Балтыйк буе яки Кавказдагы халыкларның үзара сугышуы кемгә кирәк? Бары империя өчен генә кулай бу.

Без, татарлар — тыныч халык. Ләкин нинди дер көчләр монда да гауга чыгарырга, безне башкортлар белән бәрелештерергә тели кебек һәм бу хәл безнең барыбызның да күңелендә тирән борчу тудыра. Бу хакта без, һичшиксез, башкортлар белән бергәләп уйлашырга тиешбез.

Татарстанның киләчәге бездәге милли рухның никадәр нык булуына да бәйле. Грузия республикасы Президенты, шагыйрь Звиад Гамсахурдия болай ди: «...чын бәйсезлеккә таба юл, миңа калса, без инде шактый җуйган милли рухны, милли холыкны, милли горурлыкны кире кайтарудан башлана. Алардан башка бер генә сәяси һәм икътисади мәсьәләне дә хәл итеп булмый».

З. Гамсахурдия бу сүзләрне әйткәндә грузиннарны күздә тота, әммә әлеге хакый-

кать барлык халыкларга да һәм бигрәк тә безгә артык басынкы, үз кадерен үзе белеп җиткермәгән татарларга беренче нәүбәттә кагыла кебек.

## Тәлгат Таҗетдин,

*Шәйхелислам мөфти хәзрәт,*
*СССРның Аурупа кыйсме һәм Себер мөселман-нарының Диния нәзарәте рәисе.*

Мәгълүм ки, безнең мөселман халкының тагын да бер зур байлыгы — Аурупа, Урал, Себердә яшәүче татар-башкортларны, ислам динен тотучы һәркемне берләштерүче Диния нәзарәтебез бар. Ул 1789 елның 17 декабрендә Екатерина 11 нең фәрманы белән оештырыла. Патшабикә бу адымны халыкның азатлык өчен алып барган көрәше сәеземтәсендә ясарга мәҗбүр була.

Ислам тәгълиматында Адәм галәйһиссәлам вә анабыз Хавадан туган һәркем бертигез. Адәмнәр бер-берсеннән кылган изге гамәлләре белән генә өстенлек ала. Шөкер, өлкәнебез Диния нәзарәтенә баглы мөселманнар гасырлар буена күрше-тирәдә яшәүче халыклар белән дус, тату, ихлас, чын, кешеләрчә эчкерсез, уртак Ватанда акыл һәм хикмәт белән яшәргә тырыштылар.

Моңа тарихларыбыз шаһит. Олы гарасатлар, яулар килгәндә, Туган илне яклау булсын, патша золымы чиктән чыккан чакта, хокук вә ирекләрен якларга тырышулар булсын, аларның җөмләсен без тарих сәхифәләрендә күрәбез. Ходага шөкерләр булсын: 1989 елда без Диния нәзарәте төзелүгә — 200 ел һәм бабаларыбызның Ислам динен кабул иткәненә 1100 ел тулуын илебездәге дин кардәшләребез һәм чит илдән килгән кунакларыбыз белән бергәләп, шатланып бәйрәм иттек.

Шөкер, мәчетләребезнең саннары арта, яңа мәхәлләләребез барлыкка килде. Бүгенге көндә 170 шәкертебез Бохара, Чаллы, Уфа, Чистай мәдрәсәләрендә гыйлем нигезләренә төшенә. Бер дистә шәкертебез исә Мәгърип, Җәзаир, Иордания, Төркия илләрендә гыйлем эсти. Меңнәрчә яшьләр мәчетләрдә, төрле түгәрәкләрдә динебезнең нигезләрен өйрәнә.

Хак ки, хәзер кешеләр дин һәм аның әһелләреннән бик күпне өмет итә, бигрәк тә күңелләрне сафландырмакта. Ләкин шуны да әйтеп үтик: дин әһелләре үзләре дә мәрхәмәткә мохтаҗ. Шуны да аңласагыз иде! Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәлам: «...бизешә күрмәгез, бер-берегезне хурлый күрмәгез!»— дип кисәткән. Исламны дуслык, татулыктан башка күз алдына да китереп булмый.

## Габделбәр Фәйзрахманов.

Мөфти хәзрәтнең бик матур сүзләре мине татар-башкорт мәсьәләсе турындагы борчулы уйларга кайтарды. Без соңгы унннарча еллар буена Башкортстанда яшәүче милләттәшләребездән аһ-зарлар ишетә килдек. Миңа анда булырга, «Урал» исемле башкорт милли хәрәкәте җитәкчеләренең бер төркеме белән очрашып, шул хакта бик инсафлы төстә сөйләшергә туры килде. Бик хафаланып кайттым. Юньле сүз ишетмәдем. Җитәкчелекнең өлкән вәкилләре килмәгән иде.

Тарихыбызда гомердә дә күренмәгән бу яман чир тирәнгә китмәгәе дип бик шикләнәбез. Татар иҗтимагый үзәге исә Татарстанда яшәүче башка милләт вәкилләренең хөр яшәве өчен җан аямый. Чувашларга газета чыгарырга йөрибез. Тик шунысы да бар: бу милләт кешеләре бигрәк тә йомылып калган, кузгатуы авыр.

## Туфан Миңнуллин.

Бу мәсьәлә мине дә бик нык борчый. Без ниндидер явыз ниятле бәндәләр ташлаган кармакка эләгәбез кебек. Чөнки безнең халыклар гасырлар буе дус яшәде. Минемчә, берәүнең дә халык исеменнән, ягъни башкорт халкы татар халкын кысрыклый яки, киресенчә, татарлар башкортларга яла яга, кебек зурдан кубып күтәрелгән сүзләргә тулысынча ышанырга хакы юк. Минемчә, ниндидер яман күренешкә тап булабыз икән, аның кем тарафыннан башланып җибәрелүен тикшерергә кирәк.

Дәлилләрсез сүз йөртүе кыен, әмма, миңа калса, бу ике олуг халык арасын махсус бутыйлар кебек. Дөньяларның болганган чагы. Милләтләрнең һәркайсы мөстәкыйльлеккә омтыла. Башкортстанда яшәүче миллионлаган безнең татар халкын кем җәберләргә җөрьәт итсен?! Бу хәл минем башыма сыймый.

Моны дусларча, уртага салып, тикшереп карап анализларга кирәк. Әлеге дә баягы фикеремне кабатларга мәҗбүрмен: ашыгырга, кабаланырга һич тә ярамый. Бу — халыклар язмышы. Уен эш түгел. Бу җәһәттән төрле төбәкләрдә, шул ук

Башкортстанда да чыга башлаган яңа татар газеталары да ярдәм итсен иде. Мин аларны күзәтеп барам. Бик шәп егетләр эшли аларда, афәрин!

## Равил Фәйзуллин.

Без журналда аларның эшчәнлегенә махсус күзәтүләр биреп барачакбыз. Безнең яктан ярдәм шул булыр.

## Абдулла хаҗи Галиулла,

*Казанның «Печән базары» мәчете имам хатибы.*

Анысы шулаен шулай. Әмма без, мөселман халкы, сабыр булырга тиеш. Халыкны халыкка да, динне дингә дә каршы кую һич тә ярамый. Бик катлаулы вә авыр көннәр кичерәбез.

Бүгенге көндә безнең мәчетләр дә зур хафалар кичерә, әмма бирешергә, бигрәк тә артка чигәргә һич уйламыйбыз. Мин үзем әле күптән түгел Казанда яңа торгызылган «Печән базары» мәчетенә имам хатиб булып алындым. Җитешмәүчелекләр бик күп, аннан чыгу юлларын табарга кирәк. Халык әйтмешли, бәхеткә илтә торган кырык юл бар, аның утыз тугызысы ябылса да, берсе һәрвакыт ачык тора. Әнә шуны таба белергә кирәк.

Безнең мәчетләр әле генә шундый авырлык кичерә, алар бит дистә еллар буе рәхим-шәфкать күрмичә, ташландык хәлдә яшәделәр. Киләчәктә без аякка басачакбыз.

Мин беренче тапкыр татар театрларының матди яктан мөшкел хәлен ишеттем. Дөрес, алар, кайсебер спектакльләрендә, хакыйкатькә хилафлык китереп, дингә каршы пропаганда алып баралар. Шуңа да карамастан без, киләчәктә, матди яктан ныгыгач, аларга ярдәм итәчәкбез.

## Марсель Сәлимҗанов.

Абдулла хәзрәт, безнең бервакытта да дингә каршы сәясәт алып барганыбыз юк. Матди кыенлыклар исә, бүгенге көннең базар икътисадына күчүе белән аңлатыла. Безнең тамашачыга сатылган билет театр бинасының чыгымнарын тотуга керә дә бетә. Үз-үзебезне акларга тырышсак, билет бәяләрен арттырырга кирәк. Безнең исә бу юлга басасыбыз килми. Һич кенә дә! Без хәтта һәр спектакльне бушлай күрсәтер идек! Тик... шундый кырыс кысаларга кереп каптык ки, ничек котылырга да белмибез.

## Фәндәс Сафиуллин,

*ТССР Югары Советы Президиумы әгъзасы, сугыш һәм хезмәт ветераннары, инвалидлар һәм шәфкатьлелек комиссиясе рәисе, запастагы полковник.*

Без бу сөйләшүдә әхлак мәсьәләләрен читләтеп үтә алмыйбыз, әлбәттә. Ниятләребез гел яхшылыкта бит. Минем иманым камил: һәр эшнең башында изге ният торырга тиеш. Явызлык белән тормышка ашырылган эшнең ахыры барыбер юньле булып бетми, башка казык булып төшә ул, шуңа күрә мин әлеге зур эшебезнең, ягъни республика суверенлыгын да бары тик бөтен халыкларның ризалыгы белән, иплән кенә тормышка ашыру ягында. Мин үз республикабызны гаҗәеп бер хәлдә күрәсем килә: ул бөтен ваклыклардан өскәрәк күтәрелсән иде дә дөньядагы иң гадел, иң мөкатдәс, иң мәдәниятле, иң матур, иң гадел, иң укымышлы бер төбәк булып, дөнья халыкларына үрнәк бер ил төсен яулап алсын иде!

Бүгенге хәлебез исә мактанырлык түгел. Татарстанда 810 мең пенсионер, 120 мең инвалид. Аларның хәле авыр. Республикадагы татарлар, русларга караганда, азрак укымышлы. Алар бик таркау, милли горурлыклары юк дәрәҗәсендә.

## Мирза Мәхмүтов,

*СССР Педагогия Фәннәре Академиясенең махсус урта мәктәп фәнни-тикшерену институты директоры, академик, «Ватан» җәмгыяте президенты.*

Мин сезнең сүзне бик хуплыйм. Татарлар укымышлылар арасында гына түгел,

хәтта оста эшчеләр арасында да азчылыкны алып тора. Без, хәтта суверенлыкка ирешкән очракта да сәер бер хәлдә калачакбыз: матди яктан да хәерче без, өстәвенә укымышлыларыбыз, осталарыбыз да юк дәрәҗәсендә. Гомумән, мин бу сөйләшүдә өч мәсьәләгә тукталып идем.

Аның беренчесе — республикабыздан, читтә яшәүче татарлар хәле. Алар, бер яктан, безнең ярдәмгә мохтаҗ булса, бүгенге ситуациядә үзләре дә безгә ярдәм итәргә тиешләр. Илнең төрле төбәкләреннән Мәскәүгә ишетелгән тавыш безнең файдага яңгыраячак. Алар хәтта бу юлда «Азатлык» радиостанциясеннән дә файдалана алырлар иде! «Азатлык»ка Мәскәү бик тиз колак сала. Әле безгә Польша белән Румыниядән руханилар килгән иде — аларның һәр сүзе әһәмияткә ия.

## Абдулла хәзрәт.

Безнең мәхәллә чит илдәге кардәшләр белән элемтәне һәрчак барлап тору ягында. Мин, мәсәлән, тиздән, Мәскәүгә барып, андагы мөселман халыкларының илчелекләренә керәчәкмен. Мәчетләребез безгә бик җимерек хәлдә кире кайтарыла. Аларны тәзәтерлек мал-мөлкәт бездә юк. Иншалла, кардәшләр ярдәмнәреннән мәхрүм итмәс. Без — бер аллаһе тәгалә балалары.

Мөхтәрәм академик, сезнең изге эштә дә ярдәм итәргә әзербез. Күп мәчетләребездә сабыйларны тәрбияләү мәктәпләре ачылды: Казанның Мәрҗани мәчетендә, Әҗем мәчетендә якшәмбе мәктәпләре эшли, татар гимназияләренә дә кулдан килгәнчә ярдәм итәбез.

Сүзегезне бүлүем өчен кичерегез, зинһар!

## Мирза Мәхмүтов.

Зарарсыз. Без бит барыбыз да бер максатка ирешү юллары турында сөйләшәбез. Шуңа күрә монда бер-беребезне бүлдерүләр — бик табигый хәл.

Минем әйтәсе килгән сүзне куәтләвегез бик хуп! Безгә хәзер тавышыбызны дөнья күләмендә яңгыратырга вакыт җитте. Кечкенә генә Кырым татарларының Мостафа Җәмилев дигән егетләре, әнә, бөтен галәмгә мәгълүм булды. Аны дөнья галимнәре зурлап телгә алалар.

## Зиннур Әһлиуллин.

Куркакларга азатлык төс түгел. Ирекә омтылган затлар үлемнән курыкмаска тиеш. Без Чаллыда шундый сәясәт алып барабыз. Әмма, хәзрәтләр мине гафу итсен, без дингә артык мөкиббән китү ягында түгел. Дин юлы бездән тагын шәхес культына баш июне таләп итәр кебек.

## Мирза Мәхмүтов.

Безнең алда хәзер бик күп яңа мәсьәләләр туды. Әмма, тормыш хакыйкате шуны раслый ки, матди мөстәкыйльлек булмаганда, һичнинди суверенлык та тормышка ашырыла алмый. Гафил булмыйк! Мин, мәсәлән, театр эшлекләләре берлегенең РСФСР театр эшлекләләре берлегеннән бүген үк чыкмавының сәбәпләрен аңлыйм. Алар үзара мең төрле җепләр белән тоташкан, барын да берьюлы өзеп ташлау кыен, хәтта мөмкин түгел. Бу мәгариф челтәрендә дә шулай. Акча дигән каһәр суккан нәрсә бар. Шул барысына да аяк чала. Безнең тулы матди мөстәкыйльлеккә ирешкәнче әле күпме вакыт үтәр, ә кешеләргә бүген үк яшәү шартлары булдыру кирәк. Нефтебезне безнең кулга бирергә тормыйлар. Зур заводларыбыз — барысы да Мәскәү кулында. Дөрес, бик зур байлыгыбыз бар: җиребез, туган туфрагыбыз! Ул — бинихая зур байлык. Аны әле безнең халык аңлап бетерми. Әйтергә теләгән икенче сүзем дә җиргә бәйле. Шул байлыкны үз кулыбызга алып, аннан килгән байлыкны эшкә җиксәк, без хөр вә мул тормышка ирешер идек. Тик моны әле халыкка аңлата белергә, җирдән файдалану юлларын өйрәнергә кирәк безгә!

Хөрлек тә мөстәкыйльлек дибез. Әмма аның һәр адымы саен акча кирәк. Менә үз академиябезне булдырырга торабыз. Академия тоту дистәләрчә миллион чыгым таләп итә. Бездә әлегә ул юк. Гел шулай Мәскәүдән сорарга кала.

Әйтергә теләгән өченче мәсьәләм — әзерлекле кешеләребез юк. Фәндәс әфәнде бездә укымышлыларның азлыгын күрсәтеп узган иде, ә мин республикада хәтта станокта эшләүче оста һөнәр ияләре арасында да татарның, руска караганда, азрак икәнен әйтергә мәҗбүрмен.

## Равил Фәйзуллин.

Мирза ага, сез ничә еллар инде шул өлкәдә эшлисез, бу хәлне милләт файдасына төзәтә алмадыгызмыни соң?

## Мирза Мәхмүтов.

Безнең институт хәлнең теоретик ягын гына өйрәнә. Күзәтүләрне тиешле инстанцияләргә дә җиткерәбез. Хәлләр әнә шундый: квалификацияле эшчеләр арасында татарлар аз, иң күбе — яһүдләр, аннары — руслар, иң азы — татарлар. Ил буенча завод-фабрикаларда җиһазлар искергән, заманга туры килми, дип, аһ итәләр. Җиһазларның иң шәбе кайтарылса, заводларыбыз бөтенләй туктап калыр кебек, чөнки, эшче көчләребез өйрәтелмәгән, әхлакый наданнар. Хәтта аларны өйрәтердәй укытучыларыбыз да юк. Алары үзләре дә — наданлык чигендә.

Уйлап карасак, әле 30-40 еллар элек кенә дә укытучылар халык арасында күпкә абруйлырак иде. Бу нәрсә аларның материаль кереме белән дә ныгытылган иде. Тора-бара бары да тигезләште, хәерчеләнде. Укытучы үзендә укыган балалар белән бер чиратта сөт алырга, май алырга басып тора, сатучылар белән әрләшә. Кыскасы, ул — кыен хәлдә. Без матди яктан мөстәкыйль ил булсак, мөмкинлекләребез артса, укытучыга зур абруй казанырга юл ачарга тиешбез. Җиребездән дөрес файдалануны, нәкъ менә үз кешеләребезнең алуын һәм аны зур байлык чыганагына әйләндерүне алга сөргәндә, максатка тизрәк ирешербез кебек.

## Әгъдәс Борһанов,

*тарих фәннәре докторы, Мәскәү тарих-архив институты профессоры.*

Җирне кемнәрдер кулына тапшыру, шулай ук предприятиеләрне акционерларга өләшү, мал-мөлкәтне тарату, ягъни приватизация, минем уемча, бик саклык белән үтәлергә тиеш. Бу байлык — илнең бөтен гражданнарыныкы. Бүлешүдә төгәллек сакланырга тиеш. Әгәр хәзер тагын ничек җитте, шулай таратып бетерсәк, болай да бөлгенлеккә төшкән илне тәмам чыгырыннан чыгарачакбыз.

Без, социализм төзибез, гомуми хөрриятә чыгабыз, байлык эчендә йөзәчәкбез, дип, илнең гасырлар буе тупланган малын-байлыгын әрәм-шәрәм итеп, бер мәртәбә нык ялгыштык бит инде. Тагын да хаталансак, анысын бөтенләй дә төзәтеп булмас кебек. Бигрәк тә әзерлекле хуҗалар, осталар, хәтта эшчеләрне өйрәтерлек укытучылар да юк чакта без бу өлкәдә ифрат сак кыланырга тиешбез.

## Абдулла хәзрәт.

Әзерлек булмау безнең мәхәлләләрдә дә сизелә. Хәзер мәчетләребезнең саны арта, әмма аларны тиешле дәрәҗәдә алып барырга укымышлы егетләребез бинихая аз. Дин эшлекләләрен укыту, гомумән, бик авырлык белән алып барылды бит. Шуңа күрә безгә, бердәм төстә, дөнья ирешкән гыйлемгә борылырга, яшьләрне күбрәк укытырга, чит илләргә җибәреп-җибәреп кайтарырга кирәк.

Мәгълүм ки, элек Казаныбыз мәдәният, дин вә нәшрият ягыннан мөселманнарның иң атаклы мәркәзе булган. Мөселман мөгаллимнәре, Төркстанга барып, андагы халыкка аң-белем вә дин серләрен өйрәтеп йөргәннәр. Бүген мактанырлыгыбыз юк, шулай да гел зарланып кына утырырлык та түгел. Алда безнең максатлар билгеләнгән: Казанда дини югары уку йорты булдырырга кирәк. Кайбер ярдәмне, бигрәк тә дәреслекләр мәсьәләсендә чит илдәге мөселман-кардәшләрдән өмет итәбез. Укытучы галимнәрне, тел белгечләрен, бәлки, иншалла, үзебезнең университет әзерләр. Анда гарәп-фарсы телләре кафедрасы ачылса, безнең мәчетләр бер стипендиат тотарга, ел азагында, бик булдыклы бер шәкерткә мең сум күләмендә бүләк бирергә ниятләп торалар.

## Мирза Мәхмүтов.

Дәреслекләрне үзебездә бастыру ягын карарга кирәк, чөнки гарәп илләрендә төзелгән дәреслекләр безнең укучылар һәм студентлар өчен җайлаштырылмаган. Үз тәҗрибәмнән чыгып беләм: мин университетта гарәп теле укыткан идем. Җыеп бардым әлеге гарәп дәреслекләрен — алар бит телне тумышыннан аңлаучы балаларга йөз тотып төзелгәннәр.

## Абдулла хәзрәт.

Безнең нәшрият белән эш алып баруы бик кыен. Аларда план дигән нәрсә бар. Аны берничә ел алдан әзерләп куялар. Әле шул планга кертсәләр дә, китапның дөньяга чыгуын еллар буе көтәргә туры килә.

## Әбрар Кәримуллин,

*филология фәннәре докторы, ТССРның Г. Тукай исемендәге бүләге иясе.*

Сүз бу темага кагылгач, мин татар халкының китап басу дөньясындагы урыны турында тарихи мәгълүмат биреп китүне изге бурычым саныйм.

Китап басу барлыкка килү — кешелек тарихында яңа эраның башлануына, тарих тәгәрмәчен кызулатырга китергән зур ачышларның берсе. Бөтен халыклар бу эшкә берьюлы керешеп китә алмаган. Кайберләре бигрәк тә соңга калып керешәләр икән, моның сәбәпләре ул халыкларның мәдәни, икътисади үсешенең, милли аңының ни дәрәҗәдә булуына бәйләнгән.

Китап басу эшенә керешү өчен түбәндәге факторлар кирәк. Беренчедән, бу халыкның үз графикасы, үз язуы булырга тиеш. Безнең исә язуыбыз IV-V гасырлардан ук билгеле. Борынгы рун язуыбызны IX-X гасырларда гарәп графикасы алыштырган. Димәк, бу фактор бездә мең ярым елдан ук элек булган. Икенчедән, ул халыкта фольклор һәм әдәби традицияләрнең тиешле үсеше һәм кульязма китапларның шактый киң таралуы мәҗбүри. Бу яктан да без моннан мең ел элек әзер булганбыз. Ибн Фадлан язып калдырганча, Болгар дәүләтендә шагыйрьләр, тарихчылар, галимнәр шактый күп яшәгән, кульязма китап шактый киң таралган. Болгар һәм Казан заманнарында кульязма китап язучы хәттатлар булган, китап язу эше аерым һөнәр булып киткән. Казан ханлыгы заманында ук бай китапханәләр, хәтта аерым кешеләрнең өй китапханәләре дә тупланган. Өченчедән, халык арасында укый-яза белүнең шактый киң таралуы уку-укыту мәсьәләләренең алга китүе. Бу яктан да безнең халык житлеккән булган. Болгар чорында ук бездә мәдрәсәләр эшләгән, аларның саны 1917 елга кадәр ун меңнәрдән артып киткән. (Хәзер ярым-йорты татар мәктәпләре саны бер мең тирәсендә генә икәнен искә төшерик).

Китапка булган сорауны үстерүгә китергән башка факторлар да бездә зур булган. Ул — белемгә ихтыяҗ. Чит илләр белән тыгыз мөнәсәбәттә яшәүче бабаларыбыз чит телләрне белергә тырышканнар, үзләре белән мәдәни, икътисади элемтәдәге халыкларның тормышын, культурасын, тарихын, фәнни казанышларын өйрәнгәннәр. Шуңа күрә көнчыгыш халыкларыннан кульязма китаплар алдырганнар, ул телләрнең сүзлекләрен, грамматикаларын әзерләгәннәр, ул халыкларның фәнни, әдәби, фольклор әсәрләрен ташыганнар... Менә шушыңа охшаш сыйфатлар бабаларыбызның китап басу дигән ачыш барлыкка килү белән, бу эшкә тотынырга тырышуларына сәбәп булган. Ләкин патша Россиясендә кол хәлендә яшәгән безнең халыкка китап басарга гасырлар буе рөхсәт бирелми килгән. Инде рөхсәт бирергә мәҗбүр булгач та, аларга басмаханәләр ачарга рөхсәт бирелми, татар нәширләренең заказын бары рус типографияләрендә басу гына рөхсәт ителә, ә аны басу өчен, рус китабы белән чагыштырганда, 10, кайвакытта хәтта 25 мәртәбә артык акча түләткәннәр.

## Ринат Мөхәммәдиев.

Татар китабын чыгару хәзер дә ел саен катлаулана бара. Суверенлык исә бу өлкәдә дә бездән сабырлык таләп итә. Чөнки, тиражлары аз булу сәбәпле татарча китаплар, икътисади яктан, үз-үзләрен акламый. Дәүләттән дотация сорала. Хәзер без РСФСРдан аны көтә алмыйбыз. СССР белән булган элемтәләрне нигытырга кирәк әле. Шул арада үз көчебезгә, Татарстанның үз мөмкинлекләренә таянырга кала. Киләчәктә, әлбәттә, хәл үзгәрер. Татар китабының тарихи үткәне безгә сабыр итәргә көч өсти сыман.

## Әбрар Кәримуллин.

Татар телендә беренче китап 1612 елда Лейпцигта басыла, ләкин әле аны без беренче милли татар китабы дип атый алмыйбыз. Беренче милли татар китабы 1722 елда Әстерханда басыла. Шуннан башлап XIX йөзнең башына хәтле татар китабы Мәскәү һәм Петербургта ара-тирә басылып тора. Аның яңа этабы 1800 елдан, Казанда Азиат типографиясе ачылудан соң башлана. XIX йөздә татар китабын басу белән Казанда 20 дән артык рус типографиясе шөгыльләнә, аннан бик зур керем

алалар. Татарлар бары тик XX гасыр башында гына үзләре басмаханә ачуга ирешә башлыйлар. Шул вакыттан татар китабы басу эшенә Петербург, Оренбург, Әстерхан, Уфа, Тубыл, Уральск, Томск, Стәрлетамак, Семи һәм башка шәһәрләрдә дә керешәләр.

Безнең хисаплаулар буенча, 1917 елның октябренә хәтле 14-15 мең татар китабы басылган. Бу азмы, күпме? Моңа җавап биргәнче бер фактка тукталыйк. 1917 елның октябренә хәтле Россия империясендә яшәүче барлык башка төрки халыклар, барын бергә санаганда, 500-600 китап бастырганнар. Ә без бер үзебез 14-15 мең!

Татар китабы XX йөз башында Россия империясендәге латыш милли китабыннан гына сан ягыннан бераз калышкан, ә тиражы буенча татар китабы бары рус китабыннан гына калышкан, илдә икенче урында торган. Дөньядагы бөтен төрки халыклар арасында татарларның беренче булып китап басу эшенә керешүләре үзе күп нәрсә турында сөйли.

Татар китабы үзенең эчтәлеге белән гаять бай төрле. Елына матур әдәбият әсәрләре генә дә 120-150 шәр исемдә басылып килгән. Туган телебездә инглиз, немец, голланд, испан, итальян һәм башка Европа халыкларының классик язучылары Шиллер, Сервантес, Дидро, Гейне, Твен, Мольер, Франс, Ж. Берн, Шекспир, Андерсен, Сенкевич һ. б. әсәрләре дөнья күргән. Классик көнчыгыш һәм мөселман халыкларының Хәйям, Рудаки, Фәраби, Лотфи, Чәләби, Бакыргани, Ясәви, Намык, Кемал, Мидхәт, Тагор, Мәгари, Ибн Батута һәм башкаларның әсәрләре басылган. Революциягә хәтле 500 дән артык татар кешесенең шигырь, хикәят, драма, повесть, романнары басылып чыккан.

Ел саен йөзгә якын география, тел, әдәбият, тарих, физика, химия, арифметика, геометрия, математика, табигать белеме буенча дәреслекләр чыгып торган. Елына дистәләгән календарьлар, шулар эченнән балалар, әдәби, фәнни календарьлар, өстәл һәм стена-өземтә календарьлары басылган, аларның тиражы хәзерге календарьдан зур. Төрле төгәл, табигать фәннәреннән, фәлсәфә, иҗтимагый фәннәр буенча популяр хезмәтләр белән бергә фәнни монографияләр дөнья күргән.

Революциягә хәтле татар китабы тарихыннан күренгәнчә, бездә халыкның китапка булган сусавын бервакытта да канәгатьләндереп бетерә алмаган. Шуңа күрә безнең бабаларыбыз Төркия һәм гарәп илләреннән өзлексез рәвештә китап ташып торганнар.

## Ринат Мөхәммәдиев.

Әбрар ага, мин сезне тагын бүләм, кичерегез! Мөхәммәт Галләмович әйткән иде инде: миңа да Төркиядә булырга туры килде. Анда безнең сөйләшүләр бик җитди нигездә алып барылды. Киләчәктә безнең язучыларга Төркия басмаханәләреннән файдалану мөмкинлеге туачак. Әсәрләрне тәрҗемә итәргә дә алар бик риза. Әлбәттә, кунак ашы — кара-каршы, безгә үз мөмкинлекләребезне дә арттыру ягын карарга кирәк.

Март аенда узган Татарстан язучылары корылтаенда да китапларыбыз турында сүз күп булды. Белгәнегезчә, без бу корылтайда үз мөстәкыйльлегебез турында зурдан кубып сөйләштек. Устав кабул иттек. Корылтайда СССР Язучылар Берлеге җитәкчелегеннән дә вәкил катнашты. Безгә ярдәм итәргә вәгъдә бирде.

## Әбрар Кәримуллин.

Съездда мин дә булдым. Сезнең Төркиядән алып кайткан хәбәрләрегез белән дә таныштым. Безгә Көнчыгыш илләре белән элемтәне яңартырга кирәк. Элек-электән, әле царизм татар китабын эзәрлекләгән чорларда ук, безнең авторларның әсәрләрен Төркиядә, Мисырда басып чыгарганнар, шуннан күтәреп алып кайтканнар. Шул ук вакытта татар китабы үзе дә мөселман халыклары арасында таралган, аларның мәдәнияте үсешенә йогынты ясаган. Ул халыкларның мөхтәрәм зыялылары зур рәхмәтләр белән татар китабын искә алалар.

Тагын бер мәсьәләне ачыклыйк: безнең бабайлар һәр елны миллионнарча китап баскан икән, димәк, аны укучылар да миллионнар белән исәпләнгән.

Безгә исә революциягә кадәр татар халкы тоташ надан булган дип тукып килделәр, ялганладылар. Мондый карашның чеп-чи ялган булуын татар китабы басуның тарихы, күләме, эчтәлеге бик ачык фаш итә. Татар халкының югары дәрәҗәдә укымышлылыгын раслаучы башка дәлилләр дә күп. Татар мәктәпләре өстеннән күзәтчелек итүче патша чиновнигы М. Пинегин үзенең жандарм управлениясенә язган яшерен хатында, татарларның 80 проценты укый-яза белә, дип хәбәр итә. Татарларны чукындыру буенча эшләп килгән Казан духовная академия ректоры профессор

П. Знаменский үзенең «Казанские татары» дигән китабында (1910) бик ачынып: «Не мудрено, что благодаря своим многочисленным школам и печати, татарское население в настоящее время сплошь все грамотное и с презрением смотрит на страдающий безграмотностью русских»,— дип яза. Царизмның эчке эшләр министрлыгы тарафыннан яшерен рәвештә үткәрелгән тикшеренүләрне эченә алган «Наиболее важные статистические сведения об инородцах Восточной России, Западной Сибири, подверженных влиянию ислама» дигән китапта (1912) Казан татарларында 100 кешегә бер мәктәп, ә православный русларда 1500-3000 кешегә генә бер мәктәп туры килүе турында язылган. Татарларның укый-яза белүе белән кызыксынган чит ил галимнәре татарларның бу яктан алдынгы ил саналучы Австро-Венгрия империясе кешеләреннән өстен торулары турында язып калдырганнар.

Китабыбыз тарихы үзенә күрә халкыбызның укый-яза белүе тарихы, дәрәҗәсе, аның белеменең нинди булуы турында да күп нәрсә сөйли. Кыскасы, карап үтелгән фактлар халкыбызның революциягә хәтле мәдәни үсеше, мәгърифәте, укый-яза белү дәрәҗәсенең югары булуын ачык исбатлый. Кызганычка каршы, бүгенге бердәнбер китап нәшриятыбызның хәле бик авыр. Китап бастырып чыгару ифрат кыен бер эш.

Сорау.

Һәр тарафта гел артка китеш кенә күрәбез икән, бу Бөек Октябрь социалистик революциясен, татар халкы язмышына карата, ничек бәяләргә соң?

Индус Таһиров.

Революциянең иң зур әһәмияте шунда — ул үзенең беренче булган документларында ук Россиянең изелгән халыкларының тигезлеген вә суверенлыгын таный. Нигездә, максатлар изге, тик ленинчыл идеяләрнең кайберләре инде 1918 елларда ук бозыла башлый. Соңра, Сталин чорында милли политиканың төп принциплары да чәлпәрәмә килә.

Сорау.

Бу хакыйкатьләрдән чыгып без Ленин шәхесенә, аның өйрәтмәләренә нинди карашта торырга тиеш булабыз?

Индус Таһиров.

Бер Татарстан язмышына таянып кына сүз алып бару берьяклылыкка китерергә мөмкин. Ник дигәндә, Ленинның алга куйган төп максаты — социалистик революцияне Бөтендөнья күләменә җәелдерү. Шундый зур омтылыш белән канатланганда илнең үзәгендәге милли автономияләр аны әллә ни борчымаган булса кирәк.

Мирза Мәхмүтов.

Шулай да ул аларның киләчәген чамалаган. Безнең Сәетгалиев белән әңгәмәсе вакытында, мәсәлән, Ленин: «Автономияләр әле бик озак яшәячәк»,— дигән фаразны һич тә яшермичә әйтә.

Индус Таһиров.

Ленин шәхесе турындагы бәхәсләр нәрсәдән чыга? Хикмәт шунда: без аңа фәрештәгә караган кебек карадык, һәр фаразын, ул кылган һәр эшне идеаллаштырдык. Әмма адәм баласының берсе дә хаталардан тулысынча котыла алмый.

Фәндәс Сафиуллин.

Монда тагын бер нәрсәне искәрергә кирәктер, мөгаен, җиңүгә ирешкәндә теләсә нинди алым шәп, дип, без гомум кешелектә кабул ителгән иң изге әхлак кагыйдәләрен санга сукмыйча ялгышканбыз. Вәгъдәләр бирелгән, аларны җиренә җиткереп үтәмәгәннәр. Әхлаксызлык исә җәмгыятьне һәлакәткә китерергә мөмкин. Ата — улны, ана кызны белмәгән, башбаштак җәмгыятьтә камил рухлы кеше ничек үсә ала? Без Ленин эшчәнлегендәге бер бик ачык үрнәкне истән чыгармаска тиешбез. Ленин үз тирәсенә ифрат акыллы кадрлар туплаган. Алар һәммәсе көчле рухлы, эшчән, ышанычлы.

## Кояш Тимбикова,

*язучы, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире, ТССРның һәм РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре, ТССР журналистларының Х. Ямашев исемендәге бүләге иясе.*

Минемчә, революциянең җимергеч көчләре үткәндәгенең иң матур сыйфатларын юкка чыгарганда, татар кызы язмышы бигрәк тә тирән тетрәнү кичерә. Без, бүгенге көнгәчә, татар кызын бары социалистик революция генә кеше рәтенә бастырды, дигән ялгыш караштa торабыз. Баксаң, элек-электән ханбикәләребез дә, әдибәләребез дә, мөгалимәләребез дә, сәнгать әһелләребез дә җитәрлек булган. Шулай да «хөррият» вәгъдә итүче революционерларга татар кызы ихластан ышанган. Кан коюлы көрәш юлына баскан: озын толымнарын кистереп, энҗеле калфагын, ак ефәк шәлен салып, башына кызыл йолдызлы беретка, күн фуражка кигән, озын асыл күлмәкне галифэ чалбар алмаштырган. Күркәм сыйфатлары белән гасырлар буе макталып килүче үрнәк кызларыбызның әхлагы тупасланган, бозылган. Бу исә җәмгыятебездәге яман күренешләрнең дә сәбәбе булып тора.

Ни кызганыч, шул гайяр холыклы, көрәшчән рухлы мөселман кызларының кайберләрен соңыннан Сталин төрмәләренә утырталар, гаиләләреннән аерып бетерәләр. Татар кызы узган катлаулы юлда берсеннән-берсе көчле шәхесләр бар: Әминә Мөхетдинова, Заһидә Бурнашева, Гыйззениса Таҗетдинова, Абруй Сайфи, Гөлчирә Гафурова... Гөлчирә апа — татар хатын-кызлары өчен «Азат хатын» журналын чыгаручы әдибә. Ул Һади Такташ белән бергә иҗат итә. Мин 1959 елны, яңадан чыгарыла башлаган «Азат хатын»га эшкә килгәч, лагерьдан кайткан Гөлчирә апа белән очраштым. Ул Ленин-Сталин идеяләренә әле һаман ышана иде. Гаҗәп!

## Рафаэль Хәкимов.

Русьта элек-электән идеология, фән нигезенә таянмыйча, коры ышануларга көйләнгән. Бу — халыкка коллык психологиясен сеңдерү өчен бик кулай. Һәр империя патшаларга, юлбашчыларга, геройларга сукырларча инануны таләп итә, демократия исә үз көчеңә һәм акылыңа гына таянырга чакыра.

## Әгъдәс Борһанов.

Октябрь революциясе шартларында бәхәсле мәсьәләләр шактый. Әйтик, террор мәсьәләсе. Моны Фәндәс әфәнде, үз исеме белән атамаса да, телгә алды. Ачыклабрак китәргә дә мөмкин. Моңа кадәр барлык дәреслекләр, әлбәттә, террорны аклар гына кулланган, дип язды. Чынында исә массакүләм кызыл террор да булган бит. Революция, дөресен әйткәндә, үзе үк террор инде ул. Яңалыкны кабул итәргә теләмәгән кешеләр властеннан да, мал-мөлкәтеннән дә массаларның аяусыз көче тарафыннан колак кактырыла. Моннан тыш террорның таррак мәгънәсе дә бар. Без гражданнар сугышында 13 миллион кешебезне һәлак иттек, аннары — Сталин корбаннары...

Энгельс әсәрләрендә, «асларына җибәргәннәр генә террор куллана», дигән фикер бар. Мин моның белән тулысынча килешәм. Ленин да террорның зарарлы булуын аңлый, тик...

Революциягә, Ленин кебек тарихи зур шәхесләргә объектив бәя бирү өчен безгә барлык архивларны, яшерен документларны ачарга кирәк. Югыйсә, без бүген барыбыз дә әзерлек классындагы сабыйлар хәлендә, чөнки тарих фәне бик нык бәясезләнделәре.

Бәхеткә, бүген, ниһаять, безгә мөмкинлекләр тудырылды — җиң сызганып эшләргә генә кала. Фәндә дөреслеккә ирешү дә, Татарстан республикасы суверенлыгын тормышка ашыру да халыктан бердәм рәвештә тырышу, хезмәт сорый. Без моны бер генә минутка да истән чыгармаска тиешбез.

## Әмир Мәхмүтов,

*шагыйрь, филология фәннәре кандидаты, КДПИ доценты, «Суверенитет» комитетының координацион совет рәисе.*

Билгеле булганча, республикабыздагы Татарстанның мөстәкыйльлеге турында Декларацияне яклау һәм гамәлгә ашыруда булышу ниятеннән «Суверенитет» комитеты оештырылды. Комитет оештыру корылтаен да уздырды һәм ТССР Министрлар Советы безнең бу оешманың уставын рәсми яктан теркәде.

Шунысы да мәгълүм булсын: безнең комитетка гаять дәрәҗәдә көч түгәргә, әле яралгы хәлендәге суверенлыгыбызны саклау өчен, аны ныгытуда алга бару өчен күпләр белән көрәшергә туры килә. Декларациябезне танымаска теләүләр, күрмәмешкә салышып, аңа каршы гамәл кылулар — адым саен. Кайбер депутатлар, КПСС оешмаларының район җитәкчеләре (хәтта!), үз властьларыннан файдаланып, һаман безне «бүленмәс Россия» байрагы астына тартмакчылар.

Безнең комитет мондый һәр очракны тиешле урыннарга барып, гаепле кешеләрен фаш итеп ачыклый, халыкка җиткерә. Тик мөмкинлекләребез гаять чикләнгән. Безгә кичекмәстән үз газетабызны булдыру кирәк. Без аны «Суверенитет» дип атарга һәм рус телендә чыгарырга булдык. Чөнки республикада монарчы басыла торган рус газеталары Татарстанда яшәүче урысларга һәм татарча белмәүче башка милләт халыкларына безнең суверенлык яулавыбызны бозып аңлаталар.

Шөкер, бу эшләрне җәелдерерлек фонд булдыру өчен, ниһаять, үз исәп-хисабыбызны булдырдык («Суверенитет» комитетының агымдагы счеты № 700580 — ТРУ, ЖСБ, МФО 265016). Инде акча күчерергә вәгъдә бирүчеләр дә шактый. Мәсәлән, Татар иҗтимагый үзәге корылтаенда Шәйхелислам мөфти хәзрәт Тәлгат Таҗетдин да шактый зур ярдәм вәгъдә итте. Әле бу җәһәттән файдаланып мин журнал укучыларыбызга да аңлатмакчы булам. Ярдәм итәселәре килсә, ягъни Татарстанның суверенлыгын яклау юлында үз өлешләрен кертәселәре килсә, без аларның күчергән акчасын иң изге эшкә тотарга вәгъдә бирәбез.

## Равил Фәйзуллин.

Күргәнегезчә, иптәшләр, бу хакта бик күп сөйләшергә мөмкин икән. Бүгенге фикер алышулар — республикабызның мөстәкыйльлеккә ясаган адымнарын укучыга да бераз аңлату юлында — беренче талпыныш. Мәсьәлә бик кирәкле, биниһая катлаулы. Тиз генә хәл ителә торган түгел. Татарстан тулы матди мөстәкыйльлеккә ирешсен өчен, әле шактый вакытлар көрәшергә, тырышырга туры киләчәк һәм бу юлда, әлеге аңгәмәләрдән дә аңлашылганча, һәркемгә урын да, мөмкинлек тә җитәрлек. Барыннан да бигрәк, безгә бу көрәштә бердәм булырга, эшләребезне уйлап, максатчан юнәлештә алып барырга кирәк.

Журнал, әлбәттә, бу хакта әзлекле рәвештә язмалар биреп торыр, укучылардан килгән фикерләргә, мәкаләләргә күзәтүләр ясар.

Бүгенге сөйләшүдә катнашкан һәркемгә зур рәхмәт. Сезнең киләчәктә дә журнал эшенә актив катнашуыгызны өмет итеп калабыз. Бу активлык укучыларга да кызыклы булыр. Журналга язылучылар санын да арттырыр, дип ышанабыз. Бүген безнең өчен бусы да бик мөһим. Татар телендә чыга торган басмаларга язылу, һичшиксез, шулай ук Татарстан республикасының суверенлыгын ныгытуга илтә. Укучыларыбыз һәм язмалары белән журнал эшенә катнашучы авторларыбыз бу хакыйкатьне дә исләреннән чыгармасыннар иде!

*Түгәрәк өстәл янында сөйләшүләрне*
**Кояш ТИМБИКОВА** *теркәп барды.*
*Февраль, 1991 ел.*

## Чәчмә әсәрләр

**Әхсән Баянов**

# ҖӘЙ БЕЛӘН ҖӘЙ АРАСЫ

ПОВЕСТЬ

## Беренче бүлек

(Төш)



Малай төш күрде.

Төшендә, шатлыгыннан кыр яңгыратып көлә-көлә, агач атка атланып чапты. Уянып киткәч караса, агач ат каядыр чабып киткән, югалган иде.

Үсмер егет төш күрде.

Төшендә иярле аргамакка атланып дөнья гизде. Аргамак артык дулап чапканлыктан, ул аннан егылып төште. Уянып киткәч караса, чабышкы чынлап та аны ташлап качкан. Ә үсмер егет, буш кулларын сузып, ычкынган тезгенен кабат эләктерергә азаплана...

Ир-егет төш күрде.

Төшендә чибәр кыз белән болын-кырларда йөрде. Кызга чәчәкләр өзеп бүләк итте, аның белән кочаклашып мәхәббәттә аңлашты. Уянып киткәч ни күрсен, ул үзенең юрганын гына каты итеп кочаклаган икән. Мәхәббәт исә каядыр киткән, юкка чыккан иде.

Кеше еллар буе шушы өч төшен оныта алмыйча яшәде. Хәзер дә, картаймыш көнендә дә: «Гомер әллә бары тик юш килгән төш кенәме соң?»— дигән соравына җавап эзли.

Эзли, таба алмый...

## Икенче бүлек

Җир өстенә июнь килде.

Сабыйлар һәм картлар чоры тантана иткәндә, өйдә тыныч кына кем утыра алсын. Әнә бит сине июньнең нәкъ үзе төсле яшел чеби-

---

Әхсән БАЯНОВ (1927) — *шагыйрь, әдип, «Елларга сәяхәт», «Язмыштан узмыш», «Тау ягы повесте»— барлыгы утызлап китап авторы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

ләр, канатланырга ашыккан каз һәм үрдәк бәбкәләре сөенеп каршылый. Кай арада сагынганнар диген!

— Пип-пип! Пип-пип!

— Чирек-чик-чик, чирек-чик-чик!

Ә син, Ильяс агай, гадәтеңчә: «Чиреклэп торасы юк алай, менә бөтенләе белән бирәм»— дигән булып, җим сал, табаларга, ләгәннәргә су өстә, рәхәт чиксеннәр — үзең сәбәпсез шатлыклар тойган шикелле, алар да бәйрәм итсеннәр. Менә шулай. Июнь бик кыска бит ул — кадерен белеп кал. Гомер шикелле, күз ачып йомган арада каядыр китеп тә бара ул. Әле кайчан гына үзең дә яшь-җилкенчәк идең. Хәзер карасаң, ап-ак чәчле, җитмештән узган бабай. Ышанасы гына килми. Һич тә, һич тә килми ышанасы. Ышандырам димәгез дә Ильяс абзагызны. Әйе, кем. Ильяс абзагыз бөтенесен үзе белә. Аның күңеле, җаны картаюга бирешә торган түгел. Шулай булды һәм шулай булып калачак. Моның сәбәбе, бәлки, бәгъзе адәмнәргә билгеле булмаган сере бардыр. Әйе, дөресе шул — абзагыз моны үзе генә белә. Үзе генә белгән истәлекләр, ни сәбәптәндер, нәкъ менә шушы матур җәй көннәрендә, нәкъ кичә булгандай, хәтергә килә. Ильяс абзый әйтерсең ки, бүгенге яшел чирәмгә түгел, ә яшьрәк чактагы җиңел аяклары белән нәзберек хыялларына басып, канатлы кош кебек җилпенә. Һәр адымында яшьлек назын, матурлык йомшаклыгын тоеп атлый. Яшь чирәмне рәнҗетмәслек сак адымнар белән урамга чыга. Чебиләр, бәбкәләр кай арада өйрәнеп җиткән диген, аның артыннан һич калмыйча ияргән көннәре.

— Пип-пип, чирек-чирек!

Кош теле белән әйткәндә: «Сабыр, сабыр, ашыкма, безне дә көт, бергә чыгыйк»— дигән сүзләре инде бу. Болай әйтмәсләр иде, ләкин шуны шәп төшенгән алар — Ильяс бабалары исән булганда, аларга каты җил-яңгыр тимәячәк. Ямь-яшел, йоп-йомшак җил генә сыйпаячак аларның каурыйланып бетмәгән мамыкларын. Менә шулай.

Ильяс абзагыз, аллага шөкер, колакка бик каты түгел, күзләре сизгер килеш. Күктән һәм каен башларыннан аңдыган усал кошкортлардан һич курыкмыйча, шикләнмичә, сөенечләрегезне киметмичә, чирәм буйлап, сибелеп йөрегез. Чемченегез. Рәхәт чигеп калыгыз. Ник дигәндә, җир өстендә — сезнең заман. Ә җәй сезнең күбегез өчен бер генә кабат килә.

Җир өстендә — ямь-яшь июнь.

Нәкъ үзегез төсле, сезгә генә атап килгән төсле.

Дөнья буйлап, яшел җил җилферди. Яшел җил Ильяс картның мамыкка тартым чәчләрен сыйпый. Чәчләрен генә түгел, чал сакалын, битен, җилкәләрен, бөтен гәүдәсен сөя.

Урамга ашыгу сәбәпле, сакалы кыркылмыйча калган икән, хәерсез. Ну, ничава, зыян юк. Бәпкә-чебеш болай да читсенми, таный, ярата. Карт үзе дә аларны күздән ычкындырмый саклый. Бичәсе Бәһрәмия кушканга күрә генә дия күрмәгез — үз теләге һәм чебешләр ирегеннән. Бу — аның һәр язда, һәр җәйдә кабатлана торган һәм, әйтергә кирәк ки, яратып башкара торган шөгыле. Менә шулай.

Ильяс бабагыз урамның икенче ягына чыгып, улы Зәкәрия трактор белән алып кайткан каен өемнәренә менеп утырды. Монысы шулай ук ел саен, җәйгелектә исә көн саен диярлек кабатлана торган фигыле. Менеп утырыр да, кунычлы галушын салып, каен төсле үк ак оеклардан калыр. Кайчак менә бүгенге кебек, анысын да салыр. Мондый кояшлы, матур көнне кием үзлегеннән шуып төшәргә тора. Дөресе шул.

Ильяс бабай, яланаяк хәлдә, түбәтәйле башына яшькелт эшләпәсен кигән килеш һәм улы Зәкәриядән калган көрән пинжәген җилбәгәй җибәреп, үз бәхетенең никадәр зур икәнлеген карарга,

күзәтергә кереште. Кирәге бик сирәк чыга торган, болай рәвеш өчен генә дигәндәй тотып чыккан таягын кош-корт шикләнмәслек итеп кенә читкә ыргытты. Җирдә булган бөтен күренеш ул теләгән тәртипкә килде. Күзне чагылдырырлык зәңгәр күк — кояшлы, тыныч. Таныш кояш аңа каш астыннан гына караган булып, елмаеп куя. Яшә, кояш дус, маладис!

Кояш елмаюын тойган урам рәхәтләнеп ята.

Урам — бер генә яклы. Икенче ягы — урман һәм саз. Анда исән калган ике-өч йорт утыра утыруын. Иллә аларның шушындый якты көннәрдә дә чырайлары ачылмый. Сукыр тәрәзәле өйләргә нур уза алмый. Абзар-кураның салам түбәләре — кара-кучкыл. Капка-коймалар, хуҗаларын көтә-көтә арып ауган. Дөньялар! Кая гына илтеп ташлады икән язмыш ул бәндәләрне?! Эзләгән бәхетләрен таптылар микән? Тапсалар да изге, чын, тыныч бәхет түгелдер. Анысы көн кебек ачык.

Ә бит, монда калганнар да исән әле. Әнә бит, Фәтхелислам иптәш үз атын җиккән дә үз арбасына утырып килә. Үз арбасы, мөстәкыйль тормышы. Башта китеп, аннан сагынып кайтканнардан килешкилбәте һич калышмалы түгел — күк буй төшкән аклы күлмәк, күгелҗем чалбар. Җенеси чалбар диләрме? Анысын улы алып кайткан иде. Әйе, шулай да булсын. Ул җенеси чалбар теләсә кемгә сыймый, зифа гәүдәле булу кирәк икән аны кияр өчен. Фәтхелислам иптәшкә сыйган. Димәк, буй-сын ыспай аның. Калада булса, алтмыштан узган кеше чучка мисалында симереп, мыш-мыш сулап йөрер иде. Ә Фәтхелислам — егет!

Фәтхелислам, арбасыннан төшеп, ике куллап күреште.

— Ни хәл, абзый. Көтеп буламы кошларны?

— Бик шәп хәлләр, Фәтхелислам. Үзеңнеке ничек соң?

— Синең фатиха белән йөреп яту менә.

— Атлы кеше — канатлы кош. Сезгә карап, минем күңел күккә менә. Рәхмәт. Берәүләр машина дип уф органда, саттың алдың менә дигән чаптарны. Атның кадерен белгәч, шулай инде ул. Бик дөрес. Машина никадәр шәп булмасын, тимер бит ул, яратып булмый аны. Ә ат, ә чаптар бөтенләй бүтән чут. Шулаймы, Фәтхелислам?

— Син мин уйлаганны үземнән дә шәбрәк беләсең, абзый.

— Белмәскә теге. Бәләкәй чакта безнең дә бар иде атлар, колыннары белән дүртәү. Үземә аталган тайны суйгач, атна буе елаганым хәтердә. Ашыгып елаган өчен тәкъдир үч алды — гүпчи җәяүлегә калдык. Менә шунда сынды да инде канатларның берсе. Ә син, лесник булгач, аттан өзелмәдең. Хәзер менә тагын дөньяң бөтен.

— Дөнья үзгәрде бит, абзый. Рөхсәт итә башладылар.

— Яхшыга бара. Егерме беренче гасыр әйбәт булыр, мин шуны әйтәм.

— Син әйткәнчә барса, шәп булырые, абзый. Алдагын белгән юк шул.

— Безгә хәтле дөнья әйбәтрәк булган, бездән соңгысы тагын әйбәт булыр. Шулай була күрсен.

— Дәрвишрәк шул син, абзый. Бездән соңгысына куанасың. Гомер буе кеше бәхетенә куанып яшәдең.

— Егерме беренче гасыр әйбәт булыр, Ильяс абзый әйтә торган иде дип сөйләрсез, яме.

— Бергәләп сөйләшергә язсын, абзый.

— Мине дә ияртергә чамалаган өчен рәхмәт. Иллә йөрәк отпускы сорый, нишләргә икән?

— Ашыкмаска куш, рөхсәт бирмә. На, исән булыйк әле.

— Ярый, Фәтхелислам, атың тартсын, арбаң ватылмасын.

Атлы арбаның таудан тирес күпергә келтердәп төшеп китүен кызыгып һәм рәхәтләнеп карап калды Ильяс карт. «Безгә булмады,

узды гомер, буш арбадай шалтырап. Аның каравы яшьләргә килә адәмчә тормыш. Шулай булгач, рәнҗемик. Югарыга карап фикер йөртеп, түбәнгә карап шөкер итик. Егерме беренче гасыр, әйбәт булыр, алла бирсә».

Шулай уйлап, карт баягы таягын кулына алды. Шуңа таянып, янә каен бүрәнәләр өстенә кунаклады. Дөнья матурлыгы белән янә хозурланып, тыныч рәхәтлеккә талды.

Күзе күргән кешегә бүгенгесе дә ярыйсы бит. Әнә, ямь-яшь дөньяны зәп-зәңгәр яктылык балкыткан. Шуны сулап була бит әле. Шуннан да мәхрүм калсаң? Әйе, күп нәрсә кешенең үзеннән дә тора. Ничек исәпләсәң, шулай була ул. Бәхет — ул багана, утыртсаң утыра, аударсаң, ава.

Күк биеклеге — зәңгәр тау. Зәңгәр тау түбәсендә, канатларын чаңгы итеп, тилгән шуа. Шуа-шуа да бер мәлне һава тавыннан аска таба томырыла. «Әх, бәләкәй чакларда без дә шулай оча торган идек тау башыннан»,— дип уйлый карт. Иллә, хәерсез, уйны бүлдереп, күз ачып йомган арада тилгән юкка да чыга. Күк яңадан көтә, мөгаен, көтә, чакыра, җилкендерә. Хәтта карт йөрәк кымырҗып, талпынып куя. Иллә нишләмәк кирәк, бәхетнең чиге бар бит. Аяз көнне яшен суккандай, сискәнеп китә карт. Ни бу, нәрсә бу, дип уйлап өлгергәнче, карт күзләр сизгерлегенең чамалы икәнлеген, карт зиһеннең чамадан артык акрын кыймылдавын исбатлап, нindидер кара-кучкыл нәмәрсә җиргә ялт төште дә нәрсәнедер эләктереп, каен ябалдашлары аркылы очып, юкка да чыкты.

— Ходай орган нәмәрсә, ямаулы карга! Исбулыч!— дип кычкырды бабай һәм, хәл кадәренчә ярсып, каеннарның җәелеп кушылган ябалдашларына таягын тондырды.— Башың беткере, кяфер!

Шул арада капкадан, сул кулы белән биленә таянган, күзләре чагылудан булса кирәк, уң кулын каш өстенә куйган хәлдә, алга таба ким дигәндә ярты метрга кәкерәеп, аксап-туксап Бәһрәмия әби чыкмаса, әле тагын бер хәл иде дә бит, юк, гөнаһ шомлыгы, кортканың күренүе бәлане икеләтә, өчләтә арттырды, көчәйтте. Һич тә көтмәгәндә, кинәт кенә бөтен бер матур дөньяның асты өскә килде.

— Ни булды, ник акырасың?— дип чөрләгән тавыктай чарылдарга кереште кортка.

Итәкләре нәкъ менә чуар тавык канатларыдай тузан өертә иде.

— Ни дип, әнә, ямаулы карга, алды качты аксак чебешне.

— Син үзең ямаулы карга, ачык авыз. Авызыңны карга ояларлык итеп ачып утыргач, нишләп урламасын ди ул. Менә бит ә, күзең тонганмы әллә? Күрәләтә, көпә-көндез бот арасындагы чебешен карга алып очсын инде ә? Чебешне түгел, үзеңне дә алып китәр әле. Адәм гарьлеге, бар икән мондый хикмәт тә. Көзгә хәтле бер чебеш, бер бәбкә калмый икән! Менә күрерсең, мин әйткән ие диярсең. Юньсез, аңгыра, миңгерәү!

— Җитте сиңа, чәпчемә, бер аксак чебештән дөнья бетмәс.

— Бетмәс сиңа! Көзгә хәтле дөньяны кортасың, болай булгач. Авыз ачып күккә карап утыргач. Беләм мин сине, ни сәбәптән хыялга сабышып утыруыңны, бик беләм. Бозык җан!

Шушы мәлдә дөнья, әйтерсең, чынлап та җимерелде. Шул сүзне ишетүе булды, Ильяс картның чәчләре үрә торды. Сынына каткандай, өнсез калды. Шактый вакыт калтырап утырганнан соң гына һушына килеп, кычкырып җибәрде:

— Котырган! Шайтан алыштырган нәмәрсә! Телең коргыры? Кабатла, ни дидең?

— Нәмәкәй, ишетәсең киләмени? Сөяркәң исемен ишетәсең киләме? Бик тә сагындыңмы, исемен генә булса да ишетәсең киләме? Ишетми генә тор әле, яме.

Карт тагын аптырап калды. Таягы җиргә авып төшкәч, шуны

кире бастырып куя алмыйча интекте. Бер дә яман ният белән түгел, тик нәрсә эшләргә белмәгәннән, каушаганлыктан гына иде таяк белән булышуы. Мәгәр ул барыбер яманлыкка тоташты, бичә зиһенендә фикер тудыру булып, фикер тудыру юлы белән кулына таяк тоттыру булып чыкты. Картның үз гомерендә эшләгән иң зур хатасы бәлки шушы булгандыр.

Кортканың артына әйтерсең ут капты. Биленнән гомере буе алынмаган кулы купты да ялт эләктерде таякны. Күтәреп тә алды, тавык тирәсендә бөтерелгән этәч кебегрәк, карты тирәсендә бөтерелергә керешге. Җитмәсә, икенче кулы белән үзенең коелып бетә язган чәч кәмәшен йолкырга, тарткаларга тиеш тапты. Тавышы исә бөтен авылның колагын ярды мөгаен. Күрше-тирә җыйналып, ни әйтергә белмичә карап торды. Мәгәр кортканың аларны күрер хәле юк иде инде. Сөт савытларына су тутырып менгән Фәтхелислам да читтәрәк тукталды. Ишетмәс җиреңнән ишет менә. Гәрчә бөтенесе күптән таныш сүзләр:

— Карт иблис! Беләм мин синең нишләп авыз ачып, аңгыраланып утырганыңны. Диванаңны сагынып утырасың. Дивана сөяркәңне.

Хатын усаллыгыннан коелып төшкән карт:

— Җитәр, кортка, кеше көлдермә, үзеңнең дивана икәнең күренә бит,— диде. Янәсе, тынычландыра.

Чынында ул утка май гына сипте. Карчык картның таягын тартып алды да, бер кизәнде, ике кизәнде, өченчесендә, дүртенчесендә...— әйдәгез, санаудан туктыйк — картының аркасына ук дөпелдәтә башлады:

— Әле мин диванамы? Инде мин диванамы? Булмый торсын, яме. Бөтен Сысысыр белә — синең сөяркәң дивана икәнне. Яшь чагында ук справкысы барые диваналыкка. Әллә кем белән түгел, шул исәр белән чаштың. Менә шул. Менә шул. Шуны уйлап утырдың, авыз ачып, күккә карап. Ала карга да белә кемнең кем икәнен. Әнә бит Зөлхәбирә җиңгәчәйнекенә тимәде, синекен эләктерде. Ямаулы карга, имеш. Ямаулы каргадан да аңгырарак булгач, нишләп урламасын.

Ниһаять, карчыкның сүз капчыгы бушабрак калды бугай, әллә карты әрепләшмәгәнгә, шул төштә тыйлыкты. Кешеләргә күз ташлады. Якын-тирәдәге карчык-корчык яулыклар белән авызларын каплаган, ир затлары авызларын капкадай киереп ачкан иде. Кемнең ни әйтерен белеп булырга кирәк, Бәһрәмия капыл борылды да сул кулы белән янәдан билен сыйпый-сыйпый, уң кулы белән таякка таянган хәлдә, чарылдый-чорылдый, чөрли-чөрли, капкадан кереп китте. Кергән арада зәһәрлеген сибеп калдыра торды:

— Шул тилене уйлый ул, бер дә әллә кемне түгел. Яшь чагында ук бар иде ыспырафкысы диваналыкка. Монысы шуның аркасында үзе дә шашты. Әллә кемне уйлап түгел, шул дивана аркасында котырды. Хыялыйга сабышты. Бөтен Сысысырга билгеле, бөтен Сысысырга!

Авыл кешесе итәгатьле бит, берсе дә кычкырып көлмәде, мыскыл да итмәде. Картны яклап, карчыкны яманларга да керешмәде.

— Дөнья булгач, савыт-саба шалтырамый тормас,— диешеп таралыштылар. Арбага утырганда Фәтхелислам энекәш Ильяс абзыйсына:

— Егет кешегә андый гына гөнаһлар хәләл,— дигән булып күз кысты һәм,— бирешмә, картлач,— дип өстәгәч, дилбегәсен тартты.

Менә бит нинди мәрхәмәтле безнең авыл халкы. Һич тә бит: «Егет кеше хатыннан кыйнатып тормас»,— димәде, бөтенләй икенче төрле итеп әйтте. Чынында егетлекнең чамалы икәнлеге бөтен авылга күптән үк фаш ителгән бит. Акланыр, батыраеп күренер әмәл юк. Шулай бу. Ә менә Фәтхелисламга хатыны түгел, әллә нинди явыз

угырлар да таяк күтәрү димәстән, йодрык та төя алмыйлар. Усал булганга түгел, олпатлыктан, җитдилектән шулай. Ильяс абзыегыз исә, андый ук җитди кеше була алмады. Ихатага кереп, бичәнең котын алып, бөтен йорт-кураны калтыратырга тиешле кеше, авырткан аркасын угалап, сазга баткандай, аякларын кузгата алмыйча, баганадай катты да калды.

Бераздан соң гына, дөнья тынычлангач кына, ихатага кереп качкан кош-кортны яңадан урамга алып чыгарга җөрьәт итмичә, башын игән, кулларын аркасына куйган хәлдә, чишмә буена төшеп китте.

Күңелендә җыйналган әллә нинди рәнҗешле сагыш чишмә суына кушылып китмәсме дигән уй шунда дәште булса кирәк. Шактый җайсыз хәл бит, мондый чакта тамак төбендәге төенне йотып та булмый, күз яше белән дә юып булмый. Әллә кешеләрдән, әллә кояштан, әллә инде үз-үзеңнән оялта. Кояш үзе дә әнә оялды бугай — кашларын җыерып, җимерек каш астыннан карап озатты.

* * *

Кортка өянәгенең инде менә дүрт дистә елдан соң да кузгала торуы сәер тоелса да, утыз яшьтәге кешенең гөнаһы сигезенче дистәне ваклаган көннәренәчә килеп җитмәскә тиеш булса да, моңа Ильяс бабагызның һич бер катнашы юк, дисәк, дөреслеккә бераз хилафлык китергән булыр идек. Һәр чирнең сәбәбе була. Сәбәп бу очракта, тайчанмыйча әйтсәк, Ильяс картның үзенә туп-туры карап тора, гәрчә, җитмештән узган карттан утызга җитәр-җитмәслек яшь кеше гаебен түләтү гадел үк булып бетмәсә дә.

Әйе, булмады түгел, булды хәлләр. Менә инде күпме заманнардан соң да онытылырга чамаламагач, гади ялгышлар дип кенә, кул селтәп кенә котылып буламыни алардан. Тагын да дөресрәк әйкәндә, котылырга исәбендә дә юк Ильяс бабагызның. Киресенчә, «котылу» дигәнең үзе ялгыш сүз. Котылу түгел, бераз вакытка аерылып тору да фаҗига булыр иде кебек. Әйе, кем, дөресе шул. Белеп сизенә бичә, ире еллар буе иңгә иң терәлеп яшәсә дә, аркага арка терәп йокласа да, күңеле белән ул әллә кайда еракта, бик тә, бик тә ерак көннәрдә онытылып калды һәм шул көннәр бәхете белән көн күрде. Хәзер дә шул көннәрдә яшәп ята ул. Нишләмәк кирәк, аңа ходае шулай язган, мөгаен. Әле дә бөтен нәрсә ерак матурлыкларны хәтерләтә. Чишмә таныш һәм бик тә, бик тә кадерле тавышлар китереп челтери, җил җанга якын сүзләрне колак төбендә чыңлата, бөтерелеп җанга керә дә күңелдә тыныч яткан тойгыларны кузгата. Әллә хыял, әллә хатирәләр битләрдән сыйпый, каядыр дәшә, чакыра...

Шул сәбәпле, карт өйгә кайтырга ашыкмый. Әгәр кайтса, Бәһрәмия кортка бер каравы белән үк ул уйларның әсәрен дә калдырмыйча тузгытачак. Чебешенә кул сузган кешегә ташланган тавыктай, канатларын кабартачак. Сүзләрен җыеп бетерә алмассың. Кичкә хәтле бабагыз чишмә һәм елга тирәсендә әйләнер, аннары абзаркурада тегә-бу эш табып вакыт уздырыр, әңгер төшкәч кенә, анда да, түр якка узмыйча, алгы бүлмәдәге диванга утырып ял итәр. Төшкелеккә кайтмас. Ач тамагың — тыныч колагың. Менә шулай. Ерак чишмәгә, елга буена килеп утырсаң, колакларың бераз тынып торачак. Бигрәк тә — җаның.

Туктала-туктала, саескан ояларына һәм кошларга карый-карый тау менде карт. Менеп җитте дә, берничә буын җибәреп, куакланып өлгергән һәм инде менә мең тапкырлар әйтелгәнчә, яшел дәрья булып шаулый башлаган иген басуы буйлата атлап китте. Менә ичмасам сәхрә. Рәхәтләнеп сула кыр иркенлеген, рәхәтләнеп эч

җәйнең яшел гүзәллеген. Нәкъ теге чактагыча!..

— Бытбылдык! Бытбылдык!

Яшь аваз, сөенечле, мең өметле, якты, назлы аваз. Һәм карт шул аваз артыннан, сазлы каенлык белән арыш кыры аша сузылган, тапталып та бетмәгән чирәмле юл буйлап, яшьлегенә, гомерлеккә хәтердә калган бәхетләренә таба атлап китте. Юлның бер чаты кыр эченә, игеннәр арасына йөгерә, икенчесе урманга кереп чума. Өченчесе чишмәле ярга китерә. Аларның һәркайсы бер бәйрәмгә — очрашуга алып барачак иде.

Карт чишмәле ярны сайлады.

Бу ярда кайчандыр йорт-кура булган, кешеләр — риваятьләр буенча әйтсәк, Ильяс бабагызның борынгы бабалары яшәгән. Менә бит, каенлык арасында әле дә вак-вак калкулыклар сибелеп ята. Зыярат урыны. Кешеләр сайлый белгән бит дөньяның иң матур җирен: аста елга. Яр астында — үзән буйлата — зур суга кушылырга ашыгып, чишмә чаба. Яр өстендә — өйләр... булган. Тәрәзәләре мөгаен елгага һәм икенче яклап кыйблага, кояшка карагандыр. Елгага һәм кояшка йөз белән карый белгән әнә Ильяс бабагызның бабалары. Бер дә хәзерге бәндәләр кебек елгага арт белән утырмаганнар, матурлыкның ни икәнен белеп, күреп яшәгәннәр. Менә шулай.

Карт кайчандыр бабаларының өянке, тирәкләр үсеп утырган бакча чигенә, яр буена килеп, аякларын салындырып утырды. Яр астындагы бормалы-бормалы чишмә эзенә, үзәнгә, елганың үзенә карап хозурланды. Алар нәкъ менә шушы төштә мәңгелеккә аерылышканнар иде...

— Рәгыйдә, әй, Рәгыйдә! Син кайда?— Җавап юк...

Ләкин хәтер аерылышу фаҗигасен читләтеп узарга тырыша, урау юл эзли. Җан кичәге өнсезлектән бүгенге терелекне өмет итә — ишетергә, ишетелергә, яңгырарга тели. Мөмкин булмаганны көтә — могҗиза көтә, әйтерсең ки, көздән соң җәй кабат кайта ала. Чынлыкта исә ул җәй инде еракта, бик тә еракта калган. Җәй белән җәй арасында — кырык ел!

Ильяс белән аның сөекле кешесе арасында үлчәнмәгән ераклыклар!

Сынады тормыш, кызганмады, уттан алса, суга салды. Кыяга менгезде дә упкынга ыргытты. Хәзер — яр буенда тукталыш. Инде бер нәрсә дә куркыныч түгел кебек.

Имгәнермен дип курыкмыйм  
Егылып тау башыннан мин.  
Җитәрлек кадәр генә күп  
Кыйналган, ватылганмын.

Инде шушы рәвешле, авылдаш шагыйрьнең сүзләрен тулы хокук белән кабатларга мөмкиндер кебек.

## Өченче бүлек

Аргы ярда — Череккүл, Ильяс картның туган авылы. Әшмән авылына ул җайсыз хатирәләрдән һәм хатынының өянәгеннән качып китү максаты белән күчкән иде. Ләкин язмаган икән ходай. Бу авылга бер генә бөртеге дә төшеп калмыйча иярде бәлаләрнең. Иярде кара сакал, куба алмады. Агаргач та хәл үзгәрмәде.

Ә бит Череккүлдә тормыш шундый матур башланган иде!..

Җәйге һәм көзге тыныч кичләрдә елга аръягында Әшмән егетләренең гармун тавышлары ишетелә. Ильясның егет чагы җил белән килгән тылсымлы чыңнарны рәхәтлектән бөгелеп төшәрлек булып тыңлап тора. Мондый чакта аңа дөньяда бүтән бер нәрсәнең дә

кирәге юк — тавышлар тынганчы баскан төшеннән кузгала алмыйча, тораташ итеп сихерләнгәндәй тора да тора ул.

Череккүл егетләре дә төшеп калганнардан түгел. Гармунчылар, җырчылар монда да бар. Ильяс бигрәк тә аларның култыклашып урам әйләнгәннәрен ярата. Җыр артыннан, гармун артыннан ул бала чактан ук ияреп йөрде. Атаклы җырчылар кебек һава яра алмаса да, авызны бик ачмыйча гына ул да тыйнак тавышы белән кушыла торган була.

Гармунчы алдан бара, әледән-әле, култыклашкан егетләргә борылып, арты белән атлый һәм гармунны күккә чөя-чөя, бөтен авылга, бөтен күңелләргә тыелгысыз дәрт сибә. Аның шул дәртләрен башка егетләр күтәреп ала да, күп мәртәбә, бик тә, бик тә күп тапкырга кабатлап, үлчәнмәгән ераклыкларга озата.

Олырак яшьтәгеләр аларны тәрәзәгә капланып карап кала, кайсылары капка төбендә, утыргычта тыңлап утыра. Яшьрәкләр үзләре иярә тора, җыр дәвам итә. Ә сүзләрнең кайсы кемгә багышланганын тиешлеләр аңлый:

Сикереп суларга төшәрсең,
Янса яшь йөрәкләрең.

Урамны бер-ике тапкыр урагач, авылның матур бер төшендә, ялан җирдә кичке уеннар башлана. Монда инде кызлар да була. Җырга кызлар да кушыла. Күп тә үтми, гармун бию көенә күчә. Менә шушында инде күңелендә җыйналган барлык исәпсез һәм сәбәпсез ашкынуларын хәлдән тайганчы түгә Ильясның яшь чагы. Ә түгәрәккә тезелгәннәр кул чаба-чаба такмаклый:

Әткәңнән сине сорармын,
Әнкәңнән дә сорармын.
Сорап-сорап бирмәсәләр,
Килермен дә урлармын.

Монда син түгәрәк ни җырласа, шуңа кушыласың. Түгәрәк кемне тиеш тапса, шул кыз белән уртага чыгып биегәч һәм азакта култыклашып ике кабат бөтерелгәч, яңадан түгәрәккә чыгып басасың.

Күңел ачу, ял итү рәвеше булу белән бергә, уенның тел белән әйтелми торган серләрәк мәгънәсен дә сизәсең. Әгәр үзең күз төшерергә тиешле тиңеңнең кем икәнен ачыклый алмыйча яки якын килергә куркып йөргән булсаң, авылдашларың кемгә игътибар итәргә, аннары күнегә торырга, һәм... бәлки... бәлки чәчләрне бәйләшә торырга кирәклекне бик оста күрсәтеп бирәләр. Ильяска ике генә өй аркылы яшәгән Бәһрәмия дигән чибәр кызны чыгаралар. Мескен бала, әгәр кулыннан җитәкләп чыгармасалар, уртага кереп басарга һич кыючылык итәсе түгел. Кереп баскач та әле Ильяска аркасы белән борыла, анда да оялып, җиргә генә карап тора. Биергә вакыт җиткәч кенә кинәт үзгәреп, кош шикелле җилпенергә керешә. Ильяс шактый гаҗәпләнеп, сокланып, күз дә алмыйча аның тирәсендә очына. Кыяфәтен генә кара син кызның — елга буенда үскән, кәрҗин үрер өчен яраклы нечкә тал чыбыгы диярсең. Ничәмә ел бер урамда буталып йөргәндә ничек күз төшмәгән диген. Кай арада күзгә күренерлек булып үскән! Карап туймаслык икән ләбаса — ак яулыгын аркасына бөтен киңлеге белән төшереп бәйләгән — әйтерсең ки, аккош канатлары — җилпенепме җилпенә. Яулык астыннан узып, тезләргә җиткән пар толым чайкалыпмы чайкала. Ә чулпылары? Чулпыларымы! Нәкъ менә гармун кыңгыравы шикелле күңелгә бәреләбәрелә челтери. Бөтен нәрсә җиңел бу чакта — суларга күкһава җиңел, җыр, көй җиңел, аякларың, кулларың, бөтен гәүдәң җиңел — күтәр дә, ал да оч үз тормышыңа, үз киңлегеңә! Дөньяның бер генә кимчелеге бар икән, вакыт чикле икән. Җаның күккә очам

дип талпына гына торган бер мизгелдә — кыз белән култыклашып, аның кош булудан бигрәк чын кеше икәнен, беләкләренең шулай ук оялчан, әмма чын тән икәнен тойгач кына, читтәгеләр яңадан кул тотыша. Бу чакта синең яндагы кыздан, исеме белән әйтсәк, Бәһрәмия дигән чибәрдән инде җилләр искән. Чиратың узган — түгәрәктә бүтән пар...

Исеңдә тот — дөнья бу!

Дөрес, исендә тота Ильяс — кичке уеннар кабатлана тора, икенче юлы башка чибәрләр дә туры килә. Уйный торгач исемнәр ишәя — Зәһрия, Маһруй, Шәмсенур, Фәрхенур... Барысы да әйбәт, барысы да чибәр, ләкин барысы да кыяфәтләре белән бер төсле. Һәммәсенә соклана Ильяс атлы егет, ләкин берсен генә аерып: «Менә бу — минем тиңем!» дип әйтә алмый. Кызлар өчен мөгаен Ильяс үзе дә күпләрнең берседер, ул да бүтәннәрдән аерылып тормый, аерылса, шул — атна саен яңа чабата киеп чыгуы белән аерыла торгандыр. Чабата ясарга үзе өйрәнде бит.

Әмма ныклабрак карасагыз үзгәлек бөтенләй үк юк түгелдер. Кыяфәт белән димәсәк, гадәт-сәләтләр мәсьәләсендә. Үзгәлек уен таралды дигәндә башланыр. Бу мәлдә Ильяс читкәрәк китәр дә ялгыз каен тирәсендә әйләнә-әйләнә, башкалар өчен ятрак булган такмакларын тезеп китәр:

Язлар, язлар килсәләр,
Яр буйларын ишәләр.
Бер елмайсаң сөя диләр,
Сөйсәң нәрсә эшләрләр.

Бая гына үзләре уйнаган-җырлаган кешеләр тиз арада тамашачыга әйләнәләр. Ильяска шул гына кирәк, такмаклары беткеле түгел, үзенең дә, түгәрәкнең дә күңеле булганчы тезә бирсен әле:

Барып кердем бер йортка,
Утыра анда бер корткa.
Үзе бәрәңге ашый,
Үзе корсагын кашый.

Дистәләрчә такмактан соң бер урында халык төркеме бер юлы хахылдый да кинәт кузгалган Ильяс артыннан ияреп, кайтыр якка атлап, таралыша башлый. Әмма кайтышлый да такмаклар бетеп туктамый, уен-көлке дәвам итә.

Шул чаклардан башлап, Ильяска «артист» кушаматы ябышып калды. Һәм дөресен әйтик, бу кушаматка ул үзе дә һич каршылык күрсәтмәде. Киресенчә, моны ишеткәндә, авызы ерыла гына торган иде. Шулай, дөресе шул. Шаян җыр, такмак аның шатлыгы, бер як канаты иде. Ә икенче канаты — аты... Әле күптән түгел генә сабан туенда беренче булып килгән иде.

Бәләкәйдән үк әтисе янына утырып кунакка барырга, базарга йөрергә ярата иде. Ат эчерергә дигән булып, бер сәбәпсез ат атланып, сәгатьләр буе кыр юллары буйлап чабарга җай таба. Печән төялгән арба-чанага чумып, чалкан ятып, күккә карап барган чакта, күңеле юлның чиксез булуын теләп кайта. Үзенә аталган тайны ияләштерергә тырышып, аны печән белән сыйлый, чишмәгә килгәч, иң әүвәл суны аңа эчертә. Озакламый шул яшь атка атланып йөрер көннәрне сагынып көтә...

Әмма тормыш син дигәнчә генә барса икән лә. Юк шул, алай була алмады. Көннәрдән беркөнне Ильяс белән һич киңәшеп тормастан, тайны суеп, итен базарга илтеп саттылар. Ильяс өйдәгеләр белән атна буе сөйләшә алмыйча башын иеп, кайгырып йөрде. Җитмәсә, аның шулай хәсрәткә калуыннан кызык табып, олы була белмәгән кайберәүләр елмаерга, кайгы уртаклашкан булып мыскыл

итәргә маташтылар. Болар бөтенесе бергә, үсмер күңелендәге җәрәхәтне тирәнәйтте. Рәнҗеде Ильяс. Җанында нинди тойгылар алмашынды, нинди хисләр яңармас өчен үлде...

Ләкин соңыннан билгеле булганча, бу хәл, башкалары белән чагыштырганда кысыр кайгы, алдагы бәлаләрнең башы гына булган икән әле.

Авылның иң мәгънәле, иң күңелле, җырлы-моңлы матурлыгы мәңге дәвам иткәндәй тоелса да, Ильяс өчен (бәлки аның өчен генә дә түгелдер) бер заман кояшның яктылыгы бермә-бер кимеде, әйтергә кирәк ки, яртылашка калды. Һич арттыру түгел, шул чакта Ильясның бер канаты инде чынлап каерылды, сынды. Көннәрдән бер көнне, әтисе белән бергәләп, исән калган ике атның икесен дә тезгеннәреннән тотып, авылның уртак утарына үз кулы белән илтеп тапшырды ул...

Ярты гасырдан соң менә замана тагын алмашынды — теләгең булса сатып ал да асра. Яшьрәк булгач, Фәтхелислам алды. Игелеген күрсен. Мәгәр ул авылда бердәнбер атлы кеше булып калыр. Бүтән беркемгә, шул җөмләдән Ильяс картка хәзер чуртымамы ат? Атны бушка биреп тә шатландыра алмыйсың син аны хәзер. Ә теге чакта!

Ул чакта малай кара кайгыга чумган иде. Атасы белән урамнан атсыз атлаганда, һичнәрсә күрмәс булды. Авыл уртасына җиткәч кенә күзләре ачылып киткәндәй тоелды. Ходайның хикмәте, әтисе кулында — йөгән! Әтисе, буш йөгәнне нишләтергә белмәгәндәй, әле кулбашына сала, әле балтырларына бәргәләп, йөгәндәге ак тәңкәләрне чылтырата. Соңгы куанычлар! Шулай да әтисе һич югы шул кысыр куанычны саклап калырга тырышкан бит. Ильясның исә зиһене аңа да җитмәгән, сөекле җирән кашкасын йөгәне-ние белән калдырган иде...

Тәңкәле каеш йөгәнне, әйтерсең, кирәге кабат чыгар әле дип, әти кеше чоланның кул җитмәсрәк бер почмагына элеп куйды. Ләкин малай кулы җитмәс урын буламы. Малай йөгәнне көн саен диярлек бер тотып карый торды, йөгәннең хәтта кирәк чагы да булгалый иде. Җирән кашка, мескенкәй, эшкә җигелмәгән көннәрендә үзе дә сагынып кайта иде. Ильяс иртән торып чыгуга, ихатада бахбай чемченеп йөри! Менә сиңа бәйрәм! Ильяс чоланнан тәңкәле йөгәнне чылтырдатып алып чыгар да, кашканы чишмә буена алып китәр. Ялындырыбрак булса да, ат Ильяс чиләгеннән салкын су чөмерер. Бераздан, ихлас чабып, тагын ихатага кайтып керерләр.

Ат кайта алмаган чакларда, дөресрәге, уртак утардан ирекkә чыга алмаган көннәрдә Ильяс аның янына үзе барыр. Кашка, җиңелчә генә кешнәп, баш кагар. Ильяс куш куллап печән сузгач, улактан аерылып, шул печәнне кабар.

Көзгә хәтле матур гына дәвам итте шулай. Әмма бер көнне Ильяс утарга кереп аты янына килсә, кашка, әйтерсең ки, аны, иң ихлас дустын, танымады. Кешнәп кую түгел, борылып та карамады. Утарда бернигә һәм беркемгә илтифат итмәстән, киртә буенда басып тик тора бахыр. Муеннарыннан сыйпагач та исе китмәде.

Ильясның сөмсере коелды. Өйгә кайтып хәлне әтисенә сөйләгәч кенә, атка рәнҗүенең урынсызлыгы ачыкланды. Сәбәп канлы җәрәхәткә бәйле — җирән кашканы печкәннәр икән...

Җәяүлегә калгач бер коелып төшкән булса, дәртле, житез айгырдан күндәм алашага әйләнгән атның нәкъ үзе шикелле үк, Ильяс та боекты.

Ләкин һич тә гаҗәпләнәсе түгел: арба ватылса утын, үгез үлсә ит, дигәндәй, бригадир дип атала башлаган күрше абзый иртән, я кичтән тәрәзә кагып нинди эшкә барырга кушса, шунда йөрү егет кешегә җитә торган нәрсәме? Дөресен әйтик, җитмәде Ильяска — үзенә

аталып туган таен, сабан туенда беренчелекне алган җирән кашкасын — балалык, яшьлек дустын сагына бирде. Нәкъ менә шуңа күрә дә, аты белән бергә булу җае чыккач, җитәкче иптәшләр колхоз сыерларын көткән кешегә яздан көзгә хәтле ат бирәбез, дигәч, бигрәк тә үз атын бирергә ризалашкач, Ильяс, ике көтүченең берсе сыйфатында, шул авыр эшне һич җиксенмичә үз өстенә алды. Көннәр буе кырда, урман-болында сөекле аты белән бергә булгач, сүнгән теләкләре яңаргандай тоела иде.

Тора-бара эшнең дә кызыгы сизелә башлады. Күзәтсәң, маллларның һәркайсының үз гадәтләрен, үз холыкларын күреп була икән. Берсе көтүче игътибар итмәгәнне сизсә, качарга гына тора. Икенчесе көтүчедән, үзенең сакчысы, яклаучысыннан ерак китмәскә тырыша. Еш кына аңа таба муенын сузып мөгри. Төшкелектә елга буена, туплавыкка килгәч, кайберләре тиз арада суга керергә ашыкса, икенчеләре комда кызынырга ярата. Нәкъ менә кешеләр кебек, хуҗалары шикелле. Чынлап та мал хуҗасына охшый икән. Охшамаганы хәрәм малдыр.

Сыерлар кырдан кайтып фермага якынлашканда, малайлар Ильяс абзыйлары янына йөгерешеп киләләр. Алар беләләр: Ильяс абзыйларының капчыгы яки кесәләре буш булмас. Бигрәк тә июль, август айларында. Әмма бүләк бушка бирелми. Аны аласың килсә, нинди дә булса һөнәр күрсәтергә тиешсең.

— Ягез әле, әнә теге кәкре каен янына барып, миңа таба йөгерешегез. Беренче килгәнгә — куш уч чикләвек.

Ильяс атын тышаулап, кыңгырау тагып, иркенгә җибәргән арада малайлар җан-фәрманга чабышалар. Һәм килеп җитәләр. Беренче килгән малайга ике уч, икенче килгәненә бер, өченчесенә — ярты уч чикләвек эләгә. Кемнәрдер өлешсез кала. Мәгәр, гадәттә, кесә моның белән генә такыраймый. Ярышның башка төрләренә күчәләр.

— Әллә көрәшеп тә күрсәтәсезме?— ди ул яндарак торганнарны кочаклап ук.— Ә?

Җиңүчеләргә баягы кебек үк бүләк мул тия. Табышлы көннәрдә барлык ярышлардан соң чират җырга да җиткәли. Монысына йөрәге җиткән малайлар юк диярлек. Шулай да бик кечкенә сабый бер көнне һич тартынусыз:

— Җырга чикләвек буламы?— дип тешсез авызын ерып хихылдыйсы итте.

— Булмыйча инде, иң күп чикләвек — җырчыга. Әллә җырлап җибәрәсеңме?

Кайда ялындыру, малай җырның иң шәбен үзе генә белгән бер көйгә яңгыратып та җибәрде:

> Барып кердем бер йортка,
> Утыра анда бер кортка.
> Үзе бәрәңге ашый,
> Үзе корсагын кашый.

Көләргә дә, еларга белмәссең дигәндәй, малай таныш репертуарны тәгәлли язганда гына Ильяс кычкырып көлеп җибәрде:

— Һәйт, менә ичмасам җырчы! Менә рәхмәт. Миннән дә уздырдың, егет икәнсең!

Малайның аркасыннан каккалагач, кесәсендәге барлык чикләвекне аның итәгенә селкеп түкте.

Җәй шундый бәйрәмнәр белән бизәлеп узды китте.

Көтү яланнан кергәч, көзге һәм кышкы салкыннарда (элекке мәчет клубка әйләнгәч) шаукымга ияреп кенә түгел, ә чын ихласлык һәм, әйтергә кирәк, кайнар дәрт белән һәвәскәр драма түгәрәгенә йөрде яшь Ильяс.

Клубта атна саен төрле уен һәм бию, җыр кичәләре гөрләп тора.

Җәйге уеннар кыш көне шунда күчте. Дөресен әйткәндә, болары җәйгеләре белән чагыштырганда да күңеллерәк, даимирәк оештырыла икән. Махсус оештыручылар ике яшь кенә кыз — башкалардан киемнәре, кыяфәтләре белән үк аерылып тора. Яңа җыр, яңача бию, яңа уеннар өйрәтүче кызларның һәр икесе заман шатлыклары һәм өметләренең тәгаен рәвеше икәнлеге күктәге ай һәм кояш шикелле ап-ачык булып күренә икән. Син аларның кара ничек киенүләрен! Каян тапканнар диген: икесендә дә чем кара гармун итәк, дингезчеләрнеке сыман канатлы-яллы блузаларының күкрәкчәләренә көмештәй ялтырап, елкылдап торган төрле калай бизәкләр беркетелгән. Башларында — ул чакта ис̄ме дә билгеле булмаган «беретка» дип аталган күзерексез кипке... Күзерексез шул кипке астыннан җилкә турысынача киселгән, кечке болытлардай кабарган чәчләр... Шул кием һәм кыяфәтләргә өстәлгән чаялык, дәрт, янып торган яшь, матур сихерле, тылсымлы күзләр... Авылдагы озын күлмәк, алъяпкычлы, озын толымлы кызлар арасында алар айдан төшкән Зөһрә, йолдызлардан иңгән фәрештә сыман тоелалар икән. Беренчесе бөтенләй чит кыз, икенчесе әллә таныш инде? Кара, карачы, таныш кына ди сиңа! Күпме бергә йөреп, сөйләшеп, мыскыллашып, биешеп-җырлашып үскән гап-гади авыл кызы лабаса! Нинди төскә кергән әнә — танырлык түгел, танысаң ышанмалы түгел. Күнегелгән исеме белән дә атыйсы килми. Иллә исемсез кеше булмый, эндәшергә, исемен әйтергә туры килә. Кешенең исеме үзе белән туа һәм азаккача аннан аерылмый. Бу кызның да исеме юк түгел, әйе, бар. Кыен булса да әйтергә туры килә, бу кызның исеме... әйе, аның исеме — Бәһрәмия! Клубта уен оештырып йөрүчеләрнең икенчесе дигәнебез менә кем икән ул!

Әйтерсең ки, шушы Череккүлдә бәрәңге ашап, чабата киеп үскән Бәһрәмия түгел, ә бөтенләй ят кыз — сүз кушарга курыкмалы, сусаң кул җиткесез югары, изге зат! Тагын шунысы гаҗәп: айдан төшкән, йолдыздан иңгән булуларына карамастан, үзләре шундый ягымлы! Тәкәбберлек, һавалану дигәнне бөтенләй белмиләрдер, белсәләр дә ишетеп кенә беләләрдер кебек. Авылның сабан сөреп, җир тырмалап үскән егетләрен, урак урып, чүп утап буй беккән кызларын иш күреп, җитәкләшеп бәйрәм иткән көннәре. Клуб киңлеген тар итеп, бик тә сирәк очрый торган зәңгәрле-каралы күбәләктәй парә-парә җилпенә-җилпенә очкан көннәре. Тартыныбрак, читтәрәк торучылар янына үзләре килеп, матур сүзләр әйтә-әйтә уенга катнаштыралар. Җырны, уенны үзләре башлыйлар. Яңаларын өйрәтәләр.

Ильяс урман-кырда йөргән арада нихәтле үзгәреш!

Беренче көннәрдә, алар килә башлагач, Ильяс еракка тайпыла, хәтта чыгып ук китә торганга күрә, шулай да җаен китереп, кайчандыр үзе ялчан булган Бәһрәмия инде килеп Ильясны кыюлыкка чакырмас диген син. Бер көнне ул егетнең горурлыгына кагыласы итте:

— Әй, Ильяс абый, шул хәтле мыкый булмасагыз, ялчы хатыннар сыман,— дип, аны кызгануын бөтен клубка игълан итте, хәерсез.

Кызның сүз кушуына күңеле булып елмаерга тырышкан иде, елмая алмады, үпкәләргә тырышса, үпкәли, рәнҗи алмады Ильяс. Агач бүкән шикелле тәз катып авыз ачып торды да тиз арада өенә тырақлады. Кыз хаклы иде. Авылның моңарчы иң кыюсыз, хәтта томана исәпләнгән егетләре дә хәзер әнә килешсез-килбәтсез гәүдәләрен селкетә-селкетә биеп, җырлап йөриләр. Шулай кылана торгач, өс башлары үзгәрә, карарлыкка әйләнә, үзләре ыспайлана, шөкәтлерәк була бара, хәрәкәтләре, сүзләре шомара. Ә Ильяс соң нишли? Әле күптән түгел генә майданның үзәге булган Ильяс нишләп көн үзәгеннән читләшә?

Уйлый төшкәч төшенде егет: җәй буе сыерлар белән телсез аңлашып, аның теле ялкауланган икән, һәм бәлки әле зиһене дә. Монысы — бер. Икенчедән, кием ягы хөрт икән: таушалып беткән күк

чалбарын оекбаш балакларына тыгып, чабата кигән. Колакчын иске бүрек, якасыз бишмәтне телгә аласы түгел — ташка улчим. Менә кайда икән хикмәт. Иртәгедән моның кәсебенә керешү фарыз. Адәм актыгы сыйфатында яшәү — егет эше түгел. Егет икәнсең, егет бул. Һәм Ильяс үзенең егетлеген исбат итәчәк, менә күрерсез. «Исемем Ильяс булмасын, әгәренки заманның шул иң атчаянный ике кызын бөкләп ике кесәмә салмасам!» — дигән шактый ук тыйнак карарга килде егет. Килде дә көтү кө тел алган өч капчык арышны чираттагы базарга алып та китте. Сатты. Акчалы булды. Иллә кием базарда да юк дәрәҗәсендә иде. Булганы исә ошап бетми. Аның күзе төшкән, кулга эләктереп булмасмы диебрәк йөргән бер костюм бар иде барын. Елга аръягының Әшмән дигән авылында җәй саен каникулга кайта торган Исәнбәк исемле студентның шәһәрчә киенә белүенә эчтән генә сокланып йөри иде. Ничектер бер аларга кергәч, игътибар иткән иде Ильяс: түр як бүлмәдә шул костюм эленеп тора. Ул киемнәрне егет нишләп калдырып китте икән дип кызыксынгач, студентның апасы: «Модасы бетте дип калдырды» — дип, бик тә сәер сүз әйткән иде. Моны аңлап җиткермәде Ильяс. Ләкин онытмады. Хәзер менә шуны сатып алмакчы булды ул. Елга инде туңган. Көзгедәй шома боз аркылы чыгып, туп-туры максатына таба атлады. Сукмак дигән нәрсәләрне дә эзләп тормастан. Кар әле җир агартырлык кына яткан иде. Һәм шул рәвешле туп-туры таныш өйгә килеп тә керде.

— Мулла җиңгәчәй, киеп карап булмас микән шул чалбар белән зимнәчтүркене, ә?— дип, оялып кына сорый алды.

Апа кешенең:

— Ние бар аның, ки, алай бик киясең килгәч,— дип, искитмичә әйткән сүзе егетне хәтта гаҗәпсендерде.

Туйдырып бетергән иске киемнәрен салып идәнгә ыргыткач, сак кына тотып, яшел чалбарны, аннары гимнастерканы алып киде.

Исәнбәк гимнастеркалы биленә сары каеш буа, балакларын резинкалы тасмалар белән каптырып, сары сандали кия иде. Үзе сәер, үзе җыйнак. Ильяс та аңа охшарга тырыша. Ак пима белән бу яшел чалбар бигрәк тә килешле күренә ләбаса. Билгә чалбар каешын алып бугач, башы күккә тия язды Ильяснең. Күңелендәге соравын кычкырып әйтергә дә куркып, ул студентның апасына текәлеп калды. Түти елмаеп үзе сүз кушмаса, ай-һай, Ильяс костюмны салып, чыгып китүдән башка чара таба алыр иде микән. Ә болай җап-җайлы килеп чыкты. Түти кеше:

— Кала кешесе булдың да куйдың— дигәч, Ильяс үзе дә сизмәстән кычкырып көлеп җибәрде.

— Мулла җиңгәчәй... сорамакчы ием. Әйе. Бу... бу кәчтүм ничә тәңкә тора икән?

— Менә инде, бер дә белмим шул.

— Студент энең күпмегә алганые икән?

— Кышлый бер сарык сатып акчасын җибәргәнием, шуңа алдым дигәние.

— Алайса, безнең бер сарык синеке булсын, ә? Мулла җиңгәчәй, ә?

— Бер дә белмим шул, үзе сатарсың да димәгәние.

— Азсынсаң, бер-ике пот ашлык өстәрмен.

— Нишләп азсыныйм инде. Бәясен белмәгәнемне генә әйтүем.

— Мулла җиңгәчәй, ә?

— Соң... алай ук кирәк булгач, алырсың инде, алай булгач.

— Рәхмәт, мулла җиңгәчәй, гомер онытмам яхшылыгыңны. Кәчтүм минеке, бер сарык белән ике пот ашлык — синеке. Булсынмы шулай?

— Булсын, булсын, алай бик тә кирәк булгач.

Иске чалбар-күлмәген култыкка кыстырып, иске бишмәт астына ямь-яшел гимнастерка һәм чалбар киеп, түти кире уйламасын өчен

ашыга-ашыга, үз авылына элдерде Ильяс. Ә икенче атна базарыннан шундый ук уңыш белән — кара тышлы, өр-яңа тун киеп кайтты. «Менә хәзер айдан һәм йолдыздан иңгән пар кызның икешәр пар күзе шар кебек түгәрәкләнсен әле!» — дип уйлады һәм шул уй белән рәхәтләнеп бер елмайды.

Яңа киемнәрдә күргәч, кемдер гаҗәпләнеп, кемдер сокланып, ә кемдер исә көнләшеп караганга күрә, иляләшә төшсеннәр өчен ул бер-ике атна клубка бармыйча, читтәнрәк урап йөрде. Көндез эш юктан эш тапкан булып, кыяфәтен бөтен авылга күрсәтеп чыкты. «Ну шәп булган, шәп тә килешә икән, пулный студен булгансың»,— дип тел шартлаткан авылдашлар бер-ике атнадан чынлап та тынычландылар һәм бөтен нәрсә үзенең гадәти җыпкысына кайтты дияргә мөмкин. Ә бер көнне урам уртасында Бәһрәмия:

— И-и-и, Ильяс иптәш, исәнмесез! Нишләп югалдыгыз алай? Клубка күз дә ташламыйсыз. Килегез инде, мәҗбүри килегез,— дип, өс-башка илтифат итмичә генә аны кичәгә чакырды.

Болай кемне генә махсуслап чакыралар дисең? Ильясны чакыралар менә. Димәк, ул анда кирәкле кеше. Әйе. Шул көннән соң клубтагы һәр кичә яңадан Ильясныкы булып китте. Җыр-биюне, уеннарны әйткән кая, анысы, кем, кечкенә әйбер. Ильяс абзагыз спектакль дигән нәрсәне кешеләрнең исләренә төшерде ләбаса. Менә монысы инде ул телләгәнчә, аның холкы кушканча иде. Әйе. Бөтен авыл халкын дигәндәй җыеп, кыш белән яз очрашкан ак һәм җылы көннәрнең берсендә, ниһаять, Зөһрә белән Бәһрәмия җитәкчелегендә илгә атаклы «Галиябану» пьесасын шаулаттылар.

Галиябануны Зөһрә, ә Хәлилне кем уйнады дисез? Дөресе шул — Ильяс энегез башкарып чыкты. Бөтен авыл рәхәтләнеп кул чапты. Спектакльдән соң бөтен авыл Галиябану көен җырлап кайтты. Бөтен авылны гармунлы җыр әйләнде. Ильяс энегезне айдан төшкән Зөһрә белән йолдыздан иңгән Бәһрәмия үзләре култыклап кайтты, мин сиңа әйтим. Шулай култыклашкан хәлдә, бераздан алар җырлы-гармун төркемнән арткарак калып, юк сүзне бар итеп, тыныч кына гәпләшеп атладылар. Зөһрәләр турына җиткәч, аны капкасына хәтле озата килделәр. Зөһрә кичке бозлы карны шыгырдата-шыгырдата ихатасына кереп киткәч, һәм шуннан соң икәүдән икәү генә калгач, нишләптер, телләре әйләнмәс булды. Баягы уен-көлке, шаян сүзләр кинәт җилгә очкандай югалдылар. Урам буена диярлек, бер-берсенә кәррә сүз куша алмыйча интектеләр. Кай арада кая китте бөтен авыл яшьләрен үзенә җәлеп иткән, оештырган, дәртләндергән Бәһрәмия! Кая киткән мәзәкче дигән даны таралган Ильясның җорлыгы? Кая?

Гармун чыңнары, урам көйләре дә тынган инде. Урамда хәзер бер генә тавыш — бозлы кар шыгырдавы.

— Шыгырт-шыгырт, шыгырт...

Ике пар аяк көйле генә атлый, әлбәттә. Шулай булгач әле күрсенергә дә кирәк түгелдер. Аңларга кирәктер ки, мөгаен бу мәлдә ике йөрәк тә бәлки бертигез көй белән, гадәттәгедән көчлерәк һәм ешрак типкәндер. Шулай да... ике чая беръюлы кинәт кенә оялчанга әйләнер дип бая гына аларның кайсы уйлый алган булыр иде икән!

— Шыгырт-шыгырт, шыгырт-шыгырт...

Ильяслар өе артта калды. Арка урамга, тыкрыкка борылдылар. Тар сукмактан аллы-артлы барганда, кар да шыгырдамый башлады шикелле. Чөнки Бәһрәмия әүвәл әкренәеп, соңыннан тукталып ук калды. Өйләренә килеп җитәрәк, үзе телгә килде.

— Син шушында кал инде, йә әткәйләр күрер,— дип көлгәнгә тартым ымлык чыгарды. Һәм аннары оялган булып, башын иде.

Хикмәттер, шул сүзләрдән һәм ымлыктан соң Ильяска да җан кергәндәй тоелып, ул да:

— Күрсәләр дә курыкмаска була,— дип, батырая алды.

— Зөһрә күрсә...

Менә сиңа, ишетмәсәң ишет. Мондый сүз ишетермен дип башына китерә алмаган егет кызга текәлеп карады. Ай яктысында кызның күзләрендә шаян очкыннар ялтырап куйды. Кыз сирпегән очкыннар чәчелми-түгелмичә Ильяс йөрәгенә күчтеләр. «Менә ничек! Шаяртыпмы, чынлапмы, көнләшкән була чибәр. Шунысы хак, сөйләшергә җай тудыруы көн кебек ачык».

Җиңел сулап куюың, егет, бик тә урынлы. Инде, шул рәвешле, кызга якын ук килергә, иңенә кул куярга димәстән, кочаклагандай ишарә ясарга җай туды. Форсатны ычкындырма. Менә шулай.

— Нәрсә, Зөһрә куркыныч кешемени?

— Көнләшсә... — Бәһрәмия көлүен тыярга тырышты, ахрысы.

— Көнләшсә, көнләштерергә дә була.

— Кара, нинди батыр егет.

— Син кушсаң, батыраерга да була. Минем кебек ярата белсәң.

— Белмәсәм, өйрәтеп кара.

— Их, Бәһрәмия, Бәһрәмия! Шаяртма, уйнама ут белән, янгын чыгаруың бар.

— Ә мин уйнамыйм.

— Чынлапмы, Бәһрәмия?!

— Кычкырма шул чаклы. Әткәйләр ишетсә...

— Ишетсен әткәңнәр. Бөтен урам ишетсен, бөтен авыл.

— Нәрсәне ишетсеннәр?

— Мин сине яратам. Менә шул сүзне ишетсеннәр. Әйе, Бәһрәмия, яратам, исемеңне дә, үзеңне дә — туганнан бирле!

Соңгы сүз харап итте — кычкырып көлде Бәһрәмия, кәмитче артистның мәхәббәт игълан итүе дә көлкеле килеп чыкты.

— Ясалмарак уйныйсың, артист!

Ильяс мескен кызның шулай ук көлеп әйткән бу сүзләрен үчекләү диебрәк аңлады да сөмсере коелды. Күпмедер торгач уфтанып:

— Ә мин анын белән чынлап сөйләшкән булам тагы, — дип, китәргә җыенды.

— Ильяс!

Ильяс тукталды, кире борылды. Менә шунда Бәһрәмия егетнең иңенә үзе сарылып, аның колагына пышылдап кына диярлек иң еракка яшерелгән серен ачты:

— Мин дә яратам — күптәннән бирле, теге чактагы кичке уеннардан башлап, — диде. — Үзең мине әле генә күргәч тә...

Бәһрәмия пышылдап кына әйткән сүзләр, нинди телефон чыбыклары аша таралгандыр, монысын әйтү кыен, әлбәттә. Шунысы хак, Ильяс белән Бәһрәмия мәхәббәте хакында икенче көнне үк бөтен авыл белә иде инде. Яшьләр ул хәбәрләрне кире кагып азапланмыйча һәм авылны бик көттермичә, зарыктырмыйча гына, кызыл туй ясадылар. Ягъни дисәк, аракысыз һәм артык шауламыйча, бәйрәм уздыралар. Шуннан соң клубка йөрүләр, язгы һәм җәйге көннәрдә йорт-курада эш күбәю аркасында, сирәгәйде. Бәлки башка сәбәп тә булгандыр. Анысы хакында тарих кычкырып сөйләми. Мәгәр моңа карап кына Ильяс артык ук җитдиләнеп китмәде, билгеле, сәеррәк гадәтләреннән, ә Бәһрәмиячә әйтсәк, балалыктан ычкына алмады. Бичәсен ярату, ир булу фактысы аның үзен яшь җилкенчәк сыманрак тотуына комачау итмәде. Утардан сыерларны чыгарганда гадәттәгечә бик кычкырмыйча, илла савымчы кызлар ишетерлек тавыш белән аларга төртмәле җыр калдырып китүен ташламады.

Безне сөйгән кыз юлына
Гөлләр сибә күр, алла.
Безне сөймәгән кызларга
Теш сызлавы бир, алла.

Тегеме, бумы сәбәп белән Ильяс абыйлары шаяртмый гына китеп барасы итсә, кайчак кызлар үзләре: «Безне матур тавышыңнан мәхрүм итмә инде, бер генә булса да җырлап кит», — дип ялынудан да тартынмыйлар. Ялындыра торган кеше Ильясмы инде?

— Менә сезгә җырның иң шәбе! — дип, чыбыркысын җилкәсенә сала да башын кыегайта:

Агыйделнең аръягында
Бер энәгә бер сыер.
Йә бәхетсез, йә гомерсез
Булмасам ярарые.

Өченче, дүртенче... һәм башка көннәрдә дә бетми байлык, һәм бетәсе дә түгел. Шундый чибәр тыңлаучылар булганда, җыр бетә димени. Әнә бит:

— Бигрәк моңлы, бигрәк ямансу да инде җырларың! — дип мактап туймыйлар кызлар Ильяс абыйларын.

Дөрес мактыйлар, Ильяс абзыйлары үзе дә шулайрак фараз кыла. Мәгәр җыр белән генә чикләнсә, Ильяс Ильяс булмас иде. Аның бит башка һөнәрләре дә юк түгел...

Сыерлар утары белән янәшә авылның янгынчылар алачыгы урнашкан. Бер ат, мичкәле агач арба еллар буе шунда әзер тора. Алла сакласын, янгынчы Мәхмүткә эш кенә чыга күрмәсен. Әлегечә, гомер буе эшсез интексен. Бер мичкә су алып кайтсын да, икенче көнне түгеп, яңадан алып кайтсын, тагын түксен. Мәхмүт еллар буе шул шөгыль һәм уй белән яшәсә дә, көннәрдән бер көнне Ильяс энесе аңа шулай да башка шөгыль табасы итте. Иртәнге кояш белән бергә уянып, сыерларны чыгарыр алдыннан алачык янындагы арбага утырды да тәмәке төрергә кереште. Янгынчы арба шыгырдап куйганнан гына уянмагач, каты итеп бернечә кабат тамак кырды. Шунда гына алачыкның капкасы ачылды һәм күзләрен уа-уа Мәхмүт чыкты.

Кара син аның атлавын — аягына гер асканнармыни. Кыяфәтен, ничек селкенүен кара — аягүрә йоклаган көне. Күзенә Ильяс түгел, дөньяның үзе үк күренми аның. Ә дөньяда нинди матурлык! Кояшның җиргә яп-якты мәхәббәт чәчеп, чын гашыйкларча караган мәле. Барча табигатьнең — агач һәм үләннәрнең, кош-кортларның кояшка рәхмәт әйтә-әйтә елмайган, көлгән һәм иҗтиһат иткән чагы. Шундый ямьнәрне күрмичә, уйлап та бирмичә, үзенең иң шәп көннәрен йоклап үткәрсен, имеш, җир бәндәсе. Бигрәк тә бүтәннәрне гамьсезлеккә бирелмәскә, мәгънәсез йокламаска өндәргә тиешле кеше — янгынчы, иминлек сакчысы йоклап ятсын, имеш. Әнә бит Ильясны күргәч тә бик гаҗәпләнмичә генә, рәхәтләнеп киерелде. Ильяс каты гына итеп тагын бер-ике тапкыр тамак кыргач кына бармак юанлыгы итеп төрелгән тәмәкегә күзе төште. Һәм шунда гына ул җәйге челләдә, йоклаганда да башыннан купмый торган, һичбер төсе булмаган киез эшләпәсен батырыбрак киеп, көтүченең каршысына килеп басты.

— Син нәрсә, иптәш көтүче, пажаркыны яндырмакчы буласың мәллә?

Көтүче иптәш исә ике күзен берьюлы чет-чет йомгалап, башын бер иеп, бер күтәреп, бик тә кайгылы кыяфәт белән уфтанды:

— Пажаркы гына дисәң икән. Их, шулай гына булсачы!

Янгынчы сыңар бармагы белән эшләпәсен күтәреп куйды.

— Кайда, нәмә яна? — дигән сорау белән кулына чаң суга торган тимерен — арба кендеген эләктерде.

— Иплэп, бик каушама, янгынчы иптәш, башта тыңлап бетер.

— Мыгырдамый гына әйт, ни бар?

— Бар шул. Әйтәм бит, яман хәбәр. Герман ягыннан.

Мәхмүт абзыйның колаклары тагын шөмрәйде: беренче бөтендөнья сугышын кичергән кеше германның нәрсә икәнен белә бит

инде — эшләпәсен бу юлы кире батырып куйды.

— Йә, йә, шуннан ни?

— Шул, Мәхмүт абзый. Герман патшасы ультимат җибәргән икән: һәр авылның һәр өеннән сигезәр пот төтен җыеп җибәрегез, дигән. Әгәренки өй борынына сигезәр пот төтен җыеп җибәрмәсәгез, сугыш башлыйм дип әйткән ди герман.

— Ә-ә-ә, алай. Һе. — Кинәт кенә уй төшкән башын янгынчы эшләпәсен салып ук кашыйсы итте. — Бик тә гаярь патша ул герман. Булыр аңардан, булыр. Бик җайсыз бит әле — үзең беләсең, җәй көне мичкә сирәк ягыла. Җыялырлар микән шул хәтле төтенне. Сигезәр пот бит, ә? Кышка хәтле көтмәс микән, германны әйтәм. Иптәш көтүче, ә?

— Анысын миннән сорама инде син, германның үзеннән сора.

— Һе, ансат сиңа — сора.

— Мин нишли алам? Шундый хәл, абзый, мин үзем дә шуңа күрә аптыраште калдым да. Күрше Әшмән авылында әнә яртысын җыеп та бетергәннәр ди.

— Бәләкәй авылда җыелыр ул.

— Соң... ярый, син үзең уйла инде, ничек тә җыеп җибәрү ягын карыйк, тизрәк. Күрәләтә сугыш башлатсак, асубы яман булыр.

Ильяс шул сүз белән төргән тәмәкесен таптап, үз юлына китте. Мәгәр ике-өч минут уздымы, юкмы, кинәт яңгыраган чаң тавышыннан сискәнеп, шып тукталды.

Авылда бер дә юкка чаң какмыйлар. Чаң кагуның сәбәбе һәрвакыт бик җитди була — кайчак җыелышка чакыра чаң, кайчак бөтен авыл өчен пешерелә торган аш өлгергәнне белгертә, ә кайчак... алла сакласын, ходай күрсәтмәсен, янгын сүндерергә чакыра.

Ник чыңлый бүгенге чаң?

Кояш әле көянтә хәтле генә күтәрелеп килгәндә, күктә, офыкта болытлар кызыллыгы сүнеп тә җитмәгәндә, җыелыш җыярга беркемнең башына килмәс. Бу араларда тегенди-мондый өмә, уртак аш та була алмый. Димәк, бердәнбер сәбәп кала...

Ильяс бик тә ушлы, алай гына түгел, башлы бәндә булса да, андый кеше авылда ул үзе генә дигән сүз түгел. Башкалар да тиз чамалап алды бит әнә: кем чиләк чылтырата, кем бәгүргә сузыла, кем балта, көрәк тота кулына. Һәм чиләк, һәм бәгүр, һәм балта, көрәк, лом тоткан авылдашлар күзләрен ышкый-ышкый, ахылдый-ухылдый, янгын алачыгына таба чаба. Алар артыннан:

— Ут бар, янгын, пажар! — дия-дия малайлар, кызлар йөгерешә.

«Уф, бар икән күрәселәр!» — дигән уй һәм хис белән алар артыннан Ильяс иярә.

Алачык тирәсендә инде шау, гөр: ни бар, кайда ут? Кайда? Ник ашыкмыйсыз, янып бетә бит, бетә авыл! Коп-коры чиллә! Тиз, тизрәк! Әй, Мәхмүт, ни карап торасың авыз ачып? Карга сымак? Авызыңа су каптың мәллә?

Колхоз рәисе булган Миңлебикмөхәммәтҗанов янгын сүндерүченең якасына ук ябышкач, тегесе дә — гомер буе баш иеп, алай гынамы, дөресен әйткәндә, юхайланырга күнеккән янгынчы Мәхмүт тә корыч бармаклардан котылыр өчен селтәнеп алырга мәҗбүр:

— Артыңа ут капкан әнә үзеңнекенә! — дип җикерә хәтта. — Сабыр итегез, җыелып бетегез, аннан кире әйтермен.

Ильяс белән берлектә соңга калганнар да килеп җиткәч, чынлап та теле ачылды Мәхмүтнең. Тәүлегенә бер генә мәртәбә дә салынмый торган эшләпәсен салып, шуны сүзләре белән бергә йомарларга-әвәләргә кереште:

— Эш харап, иптәш авылдашлар. — Һәм шул җөмләсе белән тагын гауга кузгатты.

— Ни бар, әйт, тиз! Тиз диләр сиңа!

— Тиз әйтәм, авылдаш иптәшләр. Сүзем шул. Хәбәр килде. Герман дигән безнең дошманыбыз... — Авыл шым булды. — Әйе, шул герман безгә яу белән килмәкче ди...

Авыл авыр сулыш алып куя. Авылның эче жу итә. Өнсез кала авыл, сынына ката. Чөнки германның нәрсә икәнен белә ул. Һәм барча башлар түбән иелә. Бераздан рәис булган Миңлебикмөхәммәтҗанов кына телгә килә ала:

— Кем, Герман килмәкчеме, килә диденме? Ачыграк әйт әле.

— Ачыгы шул аның, иптәш авылдашлар, килмәкче ди, яный ди. Әгәр дә мәгәр авылыгыздагы һәр өй башына сигезәр пот төтен җыеп җибәрмәсәгез, сугыш башлыйм дип әйтеп әйтә ди.

Авыл тагын шаккката, бермәлгә телен йотып җибәрә. Тораташтар итеп сихерләнгәнмени — селкенә дә алмый, каткан хәлдә тора. Бары тик шактый вакыттан соң гына адәмнәргә зиһен кайтып, тел яңарып, аптырау авазларга әйләнә башлый:

— Төтен!? Ә-ә-ә, төтен диген, ә? Сигез пот! Каян җыеп бетерербез соң аны?

— Югыйсә сугыш белән киләм дип әйтә ди герман.

— Ай-һай, аны нәрсәгә җыярбыз соң, капчыкта торамы соң ул?

— Югыйсә, герман... шундый явыз ул дошман, сугыш ачам дип әйтә ди бит. Нибуч, җыярга кирәк.

Рәис булган Миңлебикмөхәммәтҗанов Мәхмүтнең әле алдына ук килеп, аның күзләренә текәлеп карый, әле артына чыга. Нәрсәдер аңларга азаплана бичара. Ниһаять, бер заман төпле фикергә килә:

— Син, абзый, әллә йокыдан саташып уяндыңмы?

— Йокыдан? Нинди йокы ди ул? Әллә мине йокы чүлмәге дип белдегезме? Минме әллә йоклый белә торган кеше, уттай чиллә вакытында? Әллә мине йоклап кына эпи черетеп ята дисезме? Ә?

— Алайса нишләп тозсыз хәбәр сөйлисең?

— Нинди тоз? Кайчан мин сезгә тоз дидем? Мин бит сезгә татарча, төтен, дип тугылыйм лабаса! Шуны аңламагач, персидәтел башың белән. Һы. Тозсыз, имеш, германның кем икәнен белмәсәгез, җыймагыз төтен. Азабын үзегез күрерсез. Миннән калмады, хәбәрен җиткердем.

Шулай дип ул кай арададыр җигеп өлгергән атын тугарырга керешә. Күләргә дә, еларга да белмәгән кешеләргә карап, шулай да:

— Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга. Ныклап тотынсак, җыеп булыр. Каян килеп кая китмәгән сигез пот төтен, җыярга кирәк. Төтен ул уттан хәерлерәк. Сугыш ул өй яну гына түгел, ил яну дигән сүз. Әшмәндә әнә җыеп бетерә язганнар ди. Без дә калышмыйк, социалистик ярышка чыгыйк. Бүгеннән җыя башлагыз төтенне, актык сүзем шул.

Янгынчының еларга җитешеп кычкыруына каршы, ни хикмәт диген, бөтен авыл бөтен якын-тирәне селкетеп, калтыратып, шаркылдап җибәрде. Йокысы ачылды кешеләрнең. Һәрхәлдә, күзләре ачылды. Егыла-егыла, җиргә утыра-утыра, ауный-ауный рәхәтләнеп көлеште авыл халкы. Әмма Мәхмүткә тел тидерергә ашыкмадылар. Рәис Миңлебикмөхәммәтҗанов кына, кыскартып әйткәндә, Бикмәт кенә Мәхмүт абзыйның җилкәсенә кул куеп, иплəп, бәлки әле иркәләп үк, тыныч сорау бирде:

— Каян ишеттең син бу хәбәрне? Кем авызыннан?

— Кем дип... сүз иясе белән йөримени?

— Шулай да? Мин бит яхшымы-яманмы рәис кеше, үзегез сайлап куйган. Миннән андый гына серне яшерергә ярамый бит. Йә, кем китерде хәбәрне?

— Кем дип... шул инде, бар бит безнең авылның әртисе.

— Ильясмыни? Шулайдыр дигән идем аны, рәтле кеше сөйләмәс мондыйны дигән идем. Нәкъ үзе, билләһи!

Рәис шунда янә кабынып, йодрыкларын төйнәп, Ильясны эзләргә кереште:

— Жанын алам суырып, ысвулычның. Телен йолкыйм артис актыгының, бүтәнчә булдыралмыйм. Кайда ул бытбылдык, кайда? Күрсәтегез!

Рәис артыннан, нәкъ аныңча кабарынып, тагын да дөресрәге, сугышырга җыенган әтәчтәй кәдрәеп, Ильясны эзли башладылар — агач араларыннан, келәт артларыннан, утар капкасы ышыгыннан эзләделәр, бөтен якын-тирәне тентеп чыктылар. Бу чакта Ильястан җилләр искән иде. Вакытын бик белеп кенә шылган иде ул. Башына бик вакытлы килгән чираттагы даһи уе аның мөгаен шул булгандыр: «Яшәп ятабыз бит әле матур гына итеп. Иртәгесе көн бүгенгедән гүзәлрәк. Иртәгә тагы ни бирмәс ходай?»

Ул көнне колхоз көтүе соңгарак калып чыкты.

## Дүртенче бүлек

Шуннан соң ферма кызлары атна буе диярлек Ильястан җыр сорап аптыратмадылар, ялынмадылар. Искә төшереп чыркылдашырга әлеге бер үк җай җитә иде. Ул көннәрдә Ильяс,чыбыркы урынына каеш камчы тотып, көтүне алып чыкканда ук ат менә торган булды. Янәсе, әгәр дә мәгәр һөҗүм итүче табылса, камчы әзер, камчы куәте җитмәсә, атның аяклары җитез — яхшымы-яманмы сабан туе чапкагы — куып карагыз.

Чынлыкта исә, камчыга да, ат җитезлегенә дә эш чыкмады, әлбәттә. Беренчедән, колхоз көтүен көтү теләсә кем кулыннан килә торган эш булмаганлыктан, аны эшеннән аерырга ашыкмасалар, икенчедән, ачу дигәннәре көнендә үк көлү белән алмашынган иде бит, үзегез күрдегез. Әйе. Җайсыз хәлдә калган бердәнбер кеше ул янгынчы Мәхмүт булгандыр. Чөнки узганы берсе аны күрүгә:

— Төтен җыям әле, дүрт капчык булды инде — үлчәп алырсың, — дигәндәйрәк сүзләр белән үртәү ягын карады.

Мәхмүтнең бәхәсләшер чамасы юк — коерыгын аяк араларына кыса да алачыгына кереп шыла. Шул ук вакытта кешеләрнең чырае Ильяс өчен дә тиз генә яктырмады. Яшьләр аны күрүгә авыз күтәреп шаркылдашса да, олыраклар, германның нәрсә икәнен белгәннәре сүз белән булмаса, күз белән шелтәлиләр иде. Карашларның мәгънәсен Ильяс шәп күрә: «Дөньяда шаярмый торган әйберләр була. Ут белән сәхнәдә генә уйнарга ярый, анда да бик саклык белән. Ә тормышта бу — җинаять. Бигрәк тә сугыш дигән җинаять куркыныч, бигрәк тә — илгә, дөньяга капкан ут».

Әйтелмәгән шелтәләрне дөрес аңлаган Ильяс үзен зур тырышлык белән тыйнак тотты — артистлыгын гүяки онытты. Билгеле бер мөддәткә чаклы, дип өстик. Шулай эшләсәк, тагын да хаклырак булырбыз.

Никме?

Ник дигәндә, беренчедән, күңеленә шул вакыйгадан соң үкенүгә тартым бер хис йогып калса, аннары исә, иш янына куш дигәндәй, Бәһрәмиягә бәйле икенче бер хәл аны пошаманга салды.

Избач мөдире булган культурник Бәһрәмия чатнама суык, кышкы бер көнне гайре дә табигый хәбәр алып кайтмас диген син. Уку йортында җыйналган китапларның байтак өлешен яндырырга район үзәгеннән исемлек килгән, имеш. Шул күрсәтмәне вакытында үтәмәгән өчен алласызлар оешмасы һәм партячейка башлыгы Фәрхиев дигән адәм Бәһрәмиягә: «Әгәр дә мәгәр тиз арада ул китапларны юк итмәсәң, үзеңнең юкка чыгуың ихтимал», — дип, имән бармагын селки-селки янаган икән. Төнне рәтләп йокламыйча, малайны мәктәпкә озатмыйча, мыштым гына чыгып шылмасынмы бичә. Аның

хаерсез йомыш белән китүен сулышыннан ук сизгән Ильяс, шулай ук озак юанмыйча, мал-туарга аз-маз печән-салам салгач һәм малайны уятып мәктәпкә җибәргәч, үзе дә югары очка менеп китте. Шикләнүе рас килде — учакның нәкъ кызган чагы иде.

Ирләр акылы катнашканлыгы әллә каян күренеп тора — хуҗасы үлемгә озатылган ихатадагы җимерек келәттән алагаем бүрәнә ташып өйгәннәр дә, гөрләтеп ут якканнар. Кояш белән ярышкандай, учакның чатыр-чотыр күккә үрләгән көне. Убыр ут теләсә нинди әйберне йотып кына җибәрә. Азык исә мулдан. Бәһрәмиягә чират җитми дә диярлек, мәктәпкә барышлый балалар тукталган да чыр-чу килә — сикерә, йөгерешәләр, янган әйберләрне таяк белән актара-актара утка көч бирәләр. Авыз ачып карап тора-торалар да өйгә кереп китәләр. Йөгерә-чаба йорттан китап ташыйлар. Үрсәләнә-үрсәләнә яна китаплар. Менә кызык, менә ичмасам тантана!

Шул манзарадан Ильяс беравык һушсыз калгандай торды. Ышанырлык күренеш түгел иде бу. Ләкин әкертен-әкертен аның исәнкерәгән миенә аз-маз фикер үтеп керә башлады. Әнә бит яна ут! Күпме кешеләрнең һәм дәверләрнең акыл хезмәте, тәҗрибәсе, киңәшләре, хисләре яна. Үз эчләренә еллар һәм гасырларны җыйган, халык һәм ил тормышын сыйдырган тарих яна. Кешеләрнең киләчәктә алачак белемнәре, өметләре, әдәпләре, хыяллары, язмышлары яна. Авылның Фәрхиев дигән алласызы биргән боерык аркасында күпме байлык күккә оча!

Ильяс чамалаганча, сәбәп — бик гади. Сәбәп, икенче төрле әйткәндә, кара көнләшү дип атала. Хикмәтнең төбе шунда дип исәпли Ильяс.

Избач моннан бернечә ел элек Закир исемле мулла йортына өйдәш кергән иде. Гыйлем нияләшкән йорт бит, кешеләрнең монда килеп гәзит-журнал укулары, култыкларына китап кыстырып чыгулары табигый хәл иде. Мулла абзый гавамны, шул исәптән Бәһрәмиянең үзен якты чырай белән каршы ала, аңнарына ак нур җыярга теләгән өчен мактый һәм үсендерә. Белемле кеше, янәсе, тәүфыйклы, инсафлы була. Кыргыйлыкка изгелек-игелекне каршы куя белә, тормышта гаделлеккә хезмәт итә. Ләкин ул бик каты ялгышкан икән. Күпмедер вакыттан соң китаплар ярдәме белән, Бәһрәмия катнашы һәм мулла абзый фатихасы белән рухланган хакимият вәкилләре билләренә наган аскан хәлдә килеп керделәр дә мулла абзыйга тиз арада киенергә боерык бирделәр. Бәһрәмия китаплар тулы күрше бүлмәгә кереп шылса һәм, халык үзе әйткәнчә, арты белән генә тын алып утырса, остабикә исә хәлне аңламыйча, өйгә басып керүчеләрне алладан куркырга, тамуг кисәүләренә әверелмәскә үгетләп ялварды, бичара. Мулла абзый актан-карадан сүз әйтми чыгып киткәч, ботак-чатаклы җикерүләр, тупас аяк тавышлары тынгач исә, өй эче, аның барлык почмаклары тыярга тырышып та тыела алмаган үксү, сулкылдау авазлары белән тулды.

Мулла абзыйны урам буйлата алып барганны күргәч, халык аякка басты. Авыл советы тирәсендә зур төркем җыйналды. Тавыш, гауга. Барча тавышлар мәгънәсе йодрыкларга төйнәлгән: «Мулла абзыйны авылдан йолкып алырга хакыгыз юк. Авылга белем, тәрбия бирә килгән изге затны без сезгә болай җиңел генә биреп җибәрмибез. Кешеләр җанына шәфкать нуры сипкән бердәнбер яктылык чыганагын сүндерергә ирек куймаячакбыз!»

Гепучыларның акыру-җикеренүеннән дә файда юк, киресенчә, халыкны үчектерделәр генә. Тамаклар тәмам карлыккач, бермәлне уртага авылның алласызлар башлыгы, партячейка секретаре Фәрхиев кереп басты да ким дигәндә ун-унбиш минутлык нотык сөйләп алды. Мәгънәсе шул: «Дин — ул халык миен агулый торган әфьюн. Бөек Маркс шулай дип әйткән. Без, ягъни аның бөек тәгълиматын

тормышка ашыручылар, ленинчылар, сезнең шул әфьюннан исергән башларыгызны дәваларга алындык. Без якты, хөр тормыш төзибез, яңа кеше, һәр төрле исереклектән азат кеше тәрбиялибез. Вәгъдә итәбез ки, ант итәбез ки, без сезне мулла коткысыннан коткарачакбыз. Күзләрегез ачылып, акылларыгыз яктыргач, безгә әле рәхмәт әйтерсез. Без — ул сезнең муллагызга алмашка килүчеләр! Без — ленинчылар, искелеккә бомбалар!»

Теләсәң ышан, теләмәсәң ышанма. Авылның иң мескене, ямаулы ыштан, тишек чабата киеп йөргән малай, авызын ачса үпкәсе күренә торган егет, бүген килеп әнә нинди яңгыравыклы сүзләр сөйли. Ай-һай да тиз үзгәрә бәндә — районга ике-өч мәртәбә киңәшмәләргә барып кайткач та ялкынлы комиссарга әйләнде. Егерме биш ел укыган мулланы алыштырмакчы! Адәм баласын тугач та кулына алган, исем кушкан, гамәл дәфтәренә теркәгән, аннары күңелләргә иман, шәфкать күндерә килгән остазны болай кычкырып кына алмаштырып булырмы икән? Иң зур өстенлеге ярлылык һәм наданлык булган бәндәгә кешеләр киңәш һәм фатиха сорап килерләрме?

Ай-һай, авылдашлар әнә бик тиз тугарылып төшмәде ич әле. Сәер сүзләр яңгырашыннан колаклары катыбрак торса да, бераз суына төшеп, бәхәсне дәвам итте, тарткалаша бирделәр һәм, ниһаять, наганлы кешеләрне йомшарга мәҗбүр иттеләр. Уртак фикер һәм гамәл шундый булды: мулла абзыйны мунча кертеп, сыйлап, арбага күчтәнәчләр төяп, басу капкасын чыкканчы озата бардылар.

Мулла абзыйны кая җибәрүләрен ул чакта белмәсәләр дә, шомланулары хаклы булып чыкты. Күпмедер вакыттан соң коточкыч хәбәр: безнең авылныкын гына түгел, башка муллаларны да җыеп, Себер кышына озатканнар икән. Халыкны дин әфьюныннан, авылны мулладан шул рәвешле азат иттеләр.

Әмма алласызлар оешмасы башлыгы булып авылны шаулаткан Фәрхиев алмаштыра алдымы соң Закир мулланы? Юк, киресенчә, аннан курыкса курыктылар, ялагайланса ялагайландылар, әмма балаларга исем кушарга аны чакырмадылар, дөнья белән хушлашканда, Фәрхиев кешеләр янында була алмады, дога укымады. Туфрагы җиңел булсын, фин сугышына барып кайткач, каядыр китте дә, эзсез-хәбәрсез югалды Фәрхиев. Кая ул басу капкасынача озатулар!

Китаплар яндырганда, ул иде иң нык шатланып тантана иткән кеше. Халык миен чистартуның янә бер чарасы буларак, еласаң ела шунда дип, остабикәне өеннән мал йортына куып чыгаручыларның да берсе ул иде.

Әйе, ул кабызган учак шәп дөрләде.

Учак яктысы күзләренә төшеп кузгаткандыр, мөгаен — остабикә җимерек куышыннан чыккан да тыныч кына басып тора шунда. Саргаеп сулган чыраенда ялкын төсләре уйный. Өстендә — иске-москы, кылкалы бишмәт, төссез шәл. Калтыранган иреннәре кемнәрнедер каргыймы, дога укыймы?

Ильяс төшенгәнчә, догасына ул гомер юлдашының исемен куша иде:

— Инсаннарга сабырлык бир, алла, инсафлык индер. Закирҗан хәзрәткә ныклык бир, исәнлек бир.

Остабикә сөекле иренең бу вакытта кайда, нинди хәлдә икәнлеген белә идемени? Юктыр, әмма сизгәндер — изге күңелләр, сагынган җаннар бер-берсен ерак аралардан да тоялар ди бит.

Янәсәй дигән зур дәрьяны боз һәм кар каплаган. Карлы һәм бозлы яр буена китереп, мең ярым мулланы анадан-тума чишендереп, әсир гаскәрләр сыйфатында сафларга тезгәннәр. Остабикә шул хәлне күз алдына китерә алдымы икән? Юктыр, әмма күңеле ерак мәхшәрдән авазсыз килгән хәбәрне тоеп шомлангандыр.

Яр буе, елга өсте. Олы-олы бәкеләр тишелгән. Ялангач кешеләр-

не шул бәкеләргә төшерә торалар. Батмаска һәм агымга бирелмәскә тырышканнарның башларына күсәкләр белән сугып, колгалар белән төртеп, этеп, боз астына озаталар. Чиратлап шулай — мең ярым мулла, мең ярым гомер, мең ярым зиһен, мең ярым якташ, милләттәш, мең ярым иман...

— Инсаннарыңа шәфкать бир, мәрхәмәтле кыл, тәүфыйктан аерма, ходаем, бер аллам! Аһ!

Остабикә җан ачысы белән кычкырган бу мизгел Закир мулланың башына күсәк белән сугылган чак түгел иде дип кем әйтә ала?

Нәкъ шушы мәлдә остабикәнең үзенә дә икенче бер катылык өстәлде:

— А-ай!

Гарәп хәрефләре белән язылган башка китаплар артыннан утка Коръән һәм Мөхәммәдия китабы очып төшкәч, остабикә күзләрен йомды. Егыла язар хәлдә чайкалып куйгач, сукыр кешедәй кармаланакармалана, үзенең җимерек куышына таба атлап китте. Бу вакытта аның сөекле ирен Янәсәй дулкыннары үз иркенә алган иде.

Әйтерсең ки, остабикә дә шул ук дулкыннар белән агып китте, күздән югалды. Ильястан башка аны күрүче дә булмады шикелле.

Остабикә күздән югалгач, Ильяс избач күтәрмәсенә борылып карaса, ни күрә! Баскычтан бер кочак китап тоткан Бәһрәмия төшеп килә. Аңа хәтта ярдәм итмәкче булып кузгалды шәфкатьле ир. Ләкин тукталды. Тәне эсселе-суыклы булып, чымырдап куйды. Йа хода, болары — өр-яңа китаплар лабаса! Дин сөременнән чистартабыз дип акланырга да җай юк. Дингә бәйләнеше бөтенләй булмаган, әле күптән түгел генә кайткан китаплар. Аларның ни гаебе? Китап та җинаятьче була ала микәнни?

Җуылдап торган китап тәмугына бер кочак яңа китап ыргыткач, гөнаһлы тузаннардан чистару өчен Бәһрәмия түшләрен, итәкләрен какты, кулларын сыпырып куйды. Китапларның ничек януын күзәтү өчен, ахрысы, бераз тукталып торды. Йа хода! Чырае иң бәхетле кешеләрнеке төсле алланган. Ялкын шәүләләре аның йөзендә бии, күзләрендәге яшел төсләрне балкытып уйный. Иренең үзенә карап торганын сизгәч кенә, җәһәт кузгалып, яңадан өйгә кереп китте ул. Малайлар тагын аның артыннан иярделәр. Димәк, януга хөкем ителгән китаплар бетмәгән булып чыга...

Китапларның нинди икәнлекләрен карыйм дип, учак янына килсә, аларның берсе Ильяска бик тә таныш тоелды. Кызыл тышлы калын китап — пьесалар җыентыгы. Ильяс аны ничәмә тапкыр өенә алып кайткан һәм, бүтән яшьләр белән бергә, кумәк уку вакытында тыңлап утырган, сәхнәдә уйнаган. Ут эчендә — шул китап. Убыр уты аны кимереп, чәйнәп ята инде. Берничә минуттан авызын ялмап куячак. Әгәр ирек куйсаң. Юк, Ильяс түзә алмады. Йөрәк ачыргалануына чыдамыйча утка ташланды. Ут телләре аның бияләен көйдереп, беләзек турын ялап әчеттергәнгә, кинәт читкә тайпылып таяк-фәлән юкмы дип эзләнде. Тапты. Таякны әйбәтрәк тоту өчен бияләйләрен салып кесәсенә тыкты. Аннары җай белән учактан китапны этә-төртә читкә чыгарды. Кар өстендә чыжлаган китапны элэктергән иде, әллә кул пешкәнгә, әллә артык ашыкканга һәм каушаганга, китап, тере сыман, ычкынып, төшеп интектерде. Карга батырып аунаткач кына, ниһаять, тынычланды. Тәтенме, пармы чыгып торган гаепсез корбанны, әйтерсең, кадерле җан иясен, кочаклагандай, Ильяс урамга атлыкты. Үзенә кемнәрнеңдер игътибар иткәнен сизеп борылган иде, шуны күрде: аңа чәнечкеле күзләр белән алласызлар башлыгы Фәрхиев текәлгән иде.

Тагын шуны күреп алды Ильяс — избачтан чыккан малайлар кулында ике-өч кенә китап, Бәһрәмия кочагы буш. Янарга хөкем ителгән китаплар беткән булып чыга. Шул зәгыйфь юаныч белән ка-

нәгатьләнгән Ильяс, күңеле күтәреләя язып, үз кулына эләккән китапны куенына ук тыкты да, эшне уенга бору өчен, янәсе, малайларның нәкъ үзләренчә, чатыр-чотыр чабып китте...

Бәһрәмиянең өйгә кайткач беренче әйткәне шул булды:

— Кая куйдың?

— Нәмәне?

— Атаң башын.

— Ә-ә, атаң башын! Бәкегә илтеп ыргыттым. Мин аны бит кызык өчен генә алганыем.

— Көлделәрме соң?

— Малайлар көлде бит. Җитмәгәнме шул?

Хатын «ыһым» дигән ымлык белән мәсхәрәләп куйгач, ир аңа сынагандай текәлеп карады. Бичәнең чыраенда иртәнге матур алсулык сүнгән, күзләрендәге яшел яктылык уңган, яшел һәм ал төсләрне кара-кучкыллык алмаштырган иде. Сөремме, әллә корыммы йогып калган? Әллә яктыртмый торган кара ут шәүләсе төшкән идеме?

Атна буе куркыныч сораулар белән иза чикте хатын. Өйгә тентү кертәсең, үзеңне дә алып китәрләр, имеш. Язмаганны сөйләргә аңа куш. Әмма да ходай сакланганны саклый бит. Шулай дөрес булыр: Ильяс китапны ят куллар җитмәс урынга яшереп куйды.

Бәһрәмия сиздеме, сизмәгәнгә сабыштымы — янаулары төкәнде. Мәгәр шикләнебрәк карый торган булып калды. Чыраенда, хәрәкәтләрендә салкынлык һәм читләшү галәмәтләре пәйда булды. Сагаю элеккеге якынлыкны юкка чыгарды димәсәң дә, шунысы хактыр — күпмедер дәрәҗәдә барыбер сүрелде хисләр. Шул көннәрдән соң Бәһрәмия, кинәт үзгәреп, чәнечкеле, тупас сүзлегә әйләнде: ир белән хатын арасында чәчәткеч төтенле учак пыскып булса да яна бирде. Аралар ерагайды.

Мәгәр тормыш тукталмый бит, җан биргәнгә юнь бирә, кояш чыга, ай калка. Ильяс исә дөньяны ярата, тормышның ямен, мәгънәсен таба һәм күрә белә генә түгел, башкаларга да күрсәтә ала торган адәм ләбаса. Әйе, хәерлегә каршы, алама хәлләрне онытырга ярдәм иткән яңалыклар булмады түгел. Була торды. Хәтта — бәйрәмнәр.

Ильяс өчен бәйрәмнең иң олысы шул иде: көннәрдән бер көнне авылга театр килеп төште — артистлар, чып-чын артистлар!

Ике-өч урынга — клуб диварын телгә дә алмастан, янгын алачыгына, каравыл өенә һәм кибеткә, арттыра төшсәк, ашъяулык кадәр игъланнар ябышты. Игъланнарның һәркайсының тап уртасында аяк чаклы таяк төсле хәрефләр белән «Туй» дип язылган иде. Ваграк хәрефләргә күз салсаң, нәфис сүз, интермедия, җыр, бию, дигән сүзләрне уку мөмкин иде. Укый белгәннәр әлбәттә, ярты хәрефне дә төшереп калдырмыйча кабат-кабат укыдылар. Олырак яшьтәгеләр, латин хәрефен танымаган наданнар — тыңлап рәхәтләнде.

Театр килү хәбәрен көндезге савымга килгән кызлар китерде. Көтүне бераз иртәрәк алып кайтуны инәлеп-инәлеп сорадылар. Үзенең тычкан коерыгы чаклы гына йомшак һәм яшь мыегын бөтерә куйгач, һәм аннан соң да үз дәрәҗәсен саклап кына ризалашты өлкән көтүче (аның яшь ярдәмчесе дә бар бит әле). Әйе. Саклык белән генә, анда да, янәсе, чигенү өчен җай калдырып кына, вәгъдә бирде:

— Сезнең хакка... чибәрлегегез хакына ничек булса да иртәрәк кузгалырга тырышырбыз, — диде. Һәм мыегын янә бер мәртәбә сыпыргач, — әгәренки Миңлебикмөхәммәтҗанов иптәш эшне бозарга азапланмаса, — дип өстәде.

...Бәйрәмгә кызлар сораганнан да иртәрәк кайтты көтү. Шул сәбәптәндер, Ильясны бу көнне өч кенә малай каршылады. Ильяс капчык төбендәге бар булган карагатны ярышлар оештырмыйча гына,

учлап-учлап өләште дә, атын тышауламыйча җибәргәч, буш капчыгын җилтерәтеп өенә ашыкты.

Бакча коймасына кадакланган комганны чылтырдата-чылтырдата, пошкыра-пошкыра рәхәтләнгәч, күтәрмәдән аякларын салындырып, аларны кул комганы белән сабынлап юды. Бәһрәмиянең бирнәгә алып килгән иң матур сөлгесе белән сөртенде. Бәһрәмия гәрәбә төсенә кертеп юган идәнгә шап-шоп басып, ак өйгә узды. Иң түр почмактагы чөйдә аның саклап, кадерләп, рәешкә генә кия торган сөекле костюмы көтә. Зәңгәр сызык төшкән ак күлмәген кигәч, гүяки бәхетнең үзенә, ә чынында чалбарга чумды, гимнастерка кигәч, биленә сары каеш буды. Студент егеттән һич калышасы килмәгәнгә, сары сандали алган иде, шуны киеп, сары базар оекбашын резинкалы каптырма белән каптырды. Сары аяк, кара чәч һәм яшел гәүдәле Ильяс урамга чыккач, бәлки аны Бәһрәмия аркасында гына таный алганнардыр. Авылдашларның күзләре түгәрәкләнеп, аннары ныклабрак карагач кына: «Алай икән, син икән әле бу», дигән мәгънә белән елмаялар иде. Авылдашларын шулай гаҗәпләндерә-гаҗәпләндерә клубка узды. Клубның беренче рәтенә — иптәш рәис утыра торган иң дәрәҗәле рәтне сайлап утырды. Исәбе акланды, әлбәттә. Иптәш рәис белән терсәккә терсәк терәп утыру дәрәҗәсенә иреште ул. Башта болай булды. Рәис иптәш бичәсе белән кереп утырган мәлдә Ильяска күзе төшеп, аны көчкә таныганнан соң гына:

—Ә-ә, мин әле сине райком вәкиле дип торам, баерсың әле, танымадым үзеңне, — дип хихылдагач, Ильяс:

— Хәерле кич, иптәш рәис, — дип, шактый зыялы кеше сыман, җитди рәвештә баш какты.

Спектакль башланыр вакыт җитте. Тиздән сәхнә алдына чаршауны аралап тел бистәсе чыгачак та, барча артистлардан чук-чук сәламнәр күндерәчәк. Рольләрне кемнәр башкарганын хәтергә төшерәчәк һәм чаршауны ачачак. Таш сындай катып, сулыш алмыйча ук, мөгаен, Ильяс шул мизгелне көтте. Бичәсе аның хәлен аңлый, билгеле, тиле-миле сораулар белән диңкетми, уң ягындагылар белән генә сүз алмашкалый. Клуб эче гөжелдәвен белә. Спектакльне башларга вакыт икәнен аңлатып, гөрләп кул чаба. Мәгәр нишләптер, тел бистәсенең йодрыктай борыны чаршауны аралап чыгарга ашыкмый. Шуңа күрә, эшнең нәрсәдә икәнен белер өчен рәис сәхнәгә менеп төшәргә булды. Һәм күп тә үтмәстән, төште дә якындагыларга, шул исәптән Ильяска карап:

— Анда декорация ватылган. Төзәтә алмыйча интегәләр әле, — дигән хәбәр җиткерде. — Бераз гына сабыр итик инде.

Ильяска шул сүз җитә калды. Үзе дә сизмәстән:

— Аларга ярдәм итәргә ярамыймы соң? — дип сорады.

— Нишләп ярамасын икән?

Сорауны ниятен хуплау дип кабул иткән Ильяс рәиснең үзеннән һич ким булмаганча җитди кыяфәт белән сәхнәгә менеп тә китте. Арадан бер артист:

— Сезгә кем кирәк, иптәш? — дип сорагач кына, каушый төшеп:

— Декорациягезне төзәтмәкчеием дә...— дип, малайларча борынын тартып куйды.

Ильяс чүкеч һәм кул пычкысы сорап алды. Аннары алны-артны карамыйча кисте, юнды, кадаклады. Күп дигәндә, ун-унбиш минуттан соң эшен бетереп баш калкытканда артистларның өлкәнрәге бүлмә тактасын селкетеп:

— Булган бу, — дигәч, Ильяс үз эшен ихлас мактап:

— Җир селкенсә дә кузгалмаячак, — диде.

Мактануны кешеләр ничек кабул итте икән диебрәк, тирә-якка караса, ни күрә: аның эшләгәнен барча артистлар тамаша кылган икән. Төрлесе төрле тарафтан:

— Рәхмәт, рәхмәт, — диештеләр.

Арадан берсе, япь-яшь кыз бала аеруча сөенгән иде шикелле. Өлкән артистның:

— Кулың алтын икән, энекәш, безгә син генә җитмисең икән, — дип, кулбаштан каккалавын шул кыз елмаеп, җөпләп торганда Ильясның күңеле күккә күтәрелгән иде.

Ильяс сәхнәдән мактаулар бәхетенә коена-коена, түргә эленгән җидегән лампадан да шәбрәк балкып төште.

Һич көтмәгәндә бәйрәм шатлыгының тагын да зуррагы һәм илаһирагы көткәннән дә гүзәлрәк, сихерлерәк тавыш һәм сын булып алга чыгып басты. Моңарчы ишетелмәгән әллә нинди сәер тавыш иде бу. Күңел төпкелендәге иң тыныч тойгыларны кузгаткан, җанның моңарчы һич яктылык күрмәгән тирәнлегенә төшкән моңнар, су өстендә җем-җем уйнаган иртәнге нурлар шикелле, сибелә, ява, уйный, бии башлады. Сандугач сайравыннан да аһәңлерәк тавышлар, бии-бии бер-берсенә ияреп, моңарчы төштә дә ишетелмәгән рәхәтлек белән йөрәкне кысты. Күзләрне татлы наз әчеттерде. Иртәнге чык өстендә ялтырап балкыган якты нур җепселләренә алгасынып, моңарчы яктылык төшмәгән тирәнлекләр дулкынланып китә, кубарыла, чайкала һәм тыелгысызга әйләнә. Тыелгысыз дулкыннар шавы белән салават күперенең, кичке һәм таңгы шәфәкъгнең, җәйге кыр, болын, урман гөлләренең барча төсләрен җыйнаган нәзек көйләр кушылып, тормышның барышын, гомернең агышын мәгънәле итә. Әллә хыял, әллә истәлекләр күз алдында терелә, яши башлый.

Их, дөнья, матур дөнья, сагышлы, фаҗигале дөнья! Үзебезнең тормыш, үзебезнең яшәеш шушы лабаса! Дөнья куа-куа без аның күп төсләрен күрми калабыз икән. Ә менә бүген үз тормышыбызга үзебез читтән карап торабыз. Ул исә нинди дә моңлы икән, бәхетләребез нинди дә матур, гүзәл була ала икән. Моңнарыбыз, бәхетләребез барысы бергә тупланып, тавышка гына түгел, сурәткә дә әйләнә белә икән. Әнә бит, күр, ул сын сәхнә уртасында — япь-яшь кыз кыяфәтендә. Карашларны алгысытып, аккош йөзгән шикелле тигез атлауларын кара син аның. Бу кыз бала — язның беренче чәчәгедер. Шундый нәзберек, сулышың катырак тисә дә коелып төшәр кебек. Димәк, аны якларга, афәтләрдән, бозлы яңгырлардан сакларга кирәк...

Кыз янына иптәшләре чыкты — бергәләп җырлады, биеделәр. Кызлар янына егетләр килде, сәгатьләр түгел, әйтерсең көннәр, айлар, еллар буе җырлый-җырлый, бии-бии сөйләште, бәхәсләште, тиргәште, киңәштеләр. Сөйләшеп, бәхәсләшеп, тиргәшеп, киңәшеп, елашып, көлешеп, ниһаять, аңлаштылар... Аннары туй ясадылар.

Туй — күпләр өчен бәйрәм, шул исәптән Ильяс өчен дә. Илла да кайбер дәрәҗәдә күңелне кырган сәбәп тә булмады түгел. Шатлыклы көйләр, бию көйләре — ләкин соңыннан, иң соңыннан аларда да ниндидер сагыш ишетелә башлады. Ник? Ни сәбәп? Монысы да тиз арада аңлашылды — сәхнәгә иң беренче чыккан кыз баланың кемгәдер кияүгә чыгуы кагылды бугай күңелгә. Ни сәбәптәндер, күңел аны үзенеке итеп тоярга тырыша икән! И, бәндә! Нәрсәләргә генә өметләнми бит нәфес дигәнең!

Ильяс моның өметсез эш икәнен бик каты аңлый, әлбәттә. Кешегә сөйләсәң, акылдан шашкансың диячәкләр. Һәм хаклы булачаклар. Менә дигән хатының бар, сиңа тагын ни кирәк, диячәкләр. Тагын хаклы булачаклар. Ләкин бит Ильяс бөтенләй икенче нәрсә хакында уйлый. Сәхнәгә беренче булып чыккан кызга ул һич тә сез уйлаганча түгел, күктәге йолдызга караган кебегрәк карый. Уйлап бак, әйтсеннәр ди сиңа, күктәге иң якты йолдыз кияүгә чыккан дисеннәр. Дөньяның яме кимерме шуннан соң, юкмы? Билгеле инде, кими дә кими. Сәхнәгә беренче булып чыккан кызга да шул күзләр белән карады Ильяс.

Икенче җәһәттән, нәкъ менә шуңа күрә, чак кына рәнҗегән кебек тоелганга күрә дә бугай, Ильяснын шушы кыз белән кызыксынуы тиз генә уза алмады. Бәһрәмиясен өйгә хәтле озатты да, бераз һавада йөрим әле, дигән булып (көтүче саф һавага сусаган, имеш!), яңадан клубка таба менеп китте.

Анда яшьләр тегене-моны сөйләшеп, тәмәке тарткан булып төн кыскарталар иде. Аларга кушылмыйча, бераз вакыт читтәрәк торды Ильяс. Дөрес чамалаган — артистлар китеп өлгермәгән әле. Сәхнә ягы ишегеннән берәм-берәм коела башладылар. Ник икәнен бәлки үзе дә төшенеп җитмәстән, Ильяс шул табарак атлады. Көтте.

Урынны да дөрес сайлаган иде. Артистларның һәркайсы аның янынннан уза торды. Менә сандык хәтле гармунын күтәргән Фәрит дигән Солтанов, өлкән артист Манчаровский, һәм... аның белән бергә — иң якты йолдыз калыкты... Йолдыз, чын йолдыз! Ап-ак җәйге плащ кигән. Куерып бетмәгән йолдызлы караңгылыкта шулай тоелды гынамы, әллә чынлап та шулаймы, кыз Ильяска игътибар итеп, аны танырга тырышкандай карады кебек. Бәлки спектакль буе үзенә сихерләнгәндәй текәлеп калган кешене ул үзе дә исендә калдыра язгандыр. Йөзләрчә күздән бәлки Ильяс күзләренә игътибар итмичә кала алмагандыр. Алай түгелдер дә бәлки, ләкин ник, ник шулай булуына күңелнең ышанасы килә соң?

Их, бәндә, бәндәләр!

Ильяснын өметсез уфтануларын авылга фаш итәргә теләгәндәй, Солтанов сандык хәтле гармунын тартып җибәрде һәм урамга баягыдан һич ким булмаган матур тавышлар сибелде. Югары очка таба атлап барышлый, башка артистлар ул уйнаган көйләргә иярделәр. Авыл егетләре белән бергә Ильяс та алар артыннан атлады. Сандык хәтле гармунның баян дип аталуын, ә сәхнәгә беренче булып чыккан кызның Рәгыйдә исемле икәнен шул чакта күңеленә сеңдерде Ильяс.

Баян тавышы яңа һәм ят булган кебек, спектакльдә, концерт вакытында яңгыраган җырлар шикелле үк, урамда ишетелгәннәре дә бөтенләй диярлек икенче төрле иде — үзе якын, таныш, матур, әмма авылдагыча түгел. Бүген Ильяс бөтенләй яңа авазлар белән, яңа көйләр, яңа кешеләр белән очрашты. Болар бәрәңге һәм умач ашап яшп торганнардан түгелдер — әүлияләрдер. Югыйсә, безнең сыман җир кешесе шушындый матур сөйләшә, җырлый ала димени. Әнә бит сүзләре дә күкнеке:

Зәңгәр һава, зәңгәр болыт
Зәңгәрләтә диңгезне.
Зәңгәр һаваларда йөзгән
Айлардан эзлим сезне.

Көен әйткән дә юк, анысы яңа да яңа инде. Шул ук вакытта гадәттәгечә гади — хәтергә уелып керә дә куя.

Артистлар күмәк җырлый, әмма Рәгыйдә исемле кыз бала җырлаганда кушылмаска, кушылганда да аның тавышына комачау итмәскә, аңа ярдәм итәргә тырышалар. Менә кызның үзе яңа, үзе таныш җырларыннан берсе — тыңла да отып кал:

Син дә җырла, матур егет, Син дә җырла, матур кыз.
Матур булсын, матур булсын, Матур булсын бу тормыш.

Бу матур тавыштан, матур җырдан соң матурланмыйча карасын бу тормыш! Барып чыкмаячак! Ильяснын бөтен гомеренә җитәчәк бу матурлыклар. Менә шулай, кадерле иптәшләр.

Инде бер генә мәсьәләне чишәсе калды. Рәгыйдә чынлап чыктымы кияүгә, әллә сәхнәдә генә, шаярып, кеше көлдерер өчен генәме? Шуны ачыклыйсы иде. Башка егетләр ничектер, ә Ильяс шул ният белән азакка хәтле иярә барды. Һәм максатына иреште дә. Иң өлкән артист булган Илһам Манчаровский (әнә бит, аларның фамилияләре

дә адәмнекечә түгел!), әйе, иң өлкән артист белән култыклашып атлавыннан ук эчкә җылы иңә. Күпмедер атлаганнан соң исә өмет бөтен килеш акланды, мин сиңа әйтим. Ак киемле чибәр бала, бер мәлне тукталды да Манчаровскийдан аерылгач, урам читенәрәк тайпылып, бармакларын гына селкетеп, янәсе, кул болгады:

— Тыныч йокы, иптәшләр!

Манчаровскийның:

— Тыныч йокы, Рәгыйдә, матур төшләр күр, — диюенә, шулай ук үзенә хас булганча, тапкыр җавап кайтара белде:

— Начальство кушкач, күрәбез инде аны, иң матурларын! — дип, капкага таба атлап китте.

Башкалары: «Молодец, әйбәт әйтте», — дип рәхәтләнеп көлеште һәм сөйләшә-сөйләшә ары атладылар. Рәгыйдәнең сәхнәдә кияүгә чыккан егете — шулай ук гади генә түгел, әүлия булырга тиешле чибәр, ыспай егет — Марат Юлдыбаев дигәннәре бераз баргач ук шаян дулкынга күчәсе итте:

Зәкәрия, кеммая,
Кызыл ыштаныңны киеп,
кая бардың син бая.

Әүлия дә шушы рәвешле шаяра белә икән. Башкаларның җиңелчә генә көлеп куюын да, җырның һәм җырчының үзен дә гаепкә бөкмәде Ильяс, киресенчә, Рәгыйдәгә ихтирамнары зурлыкка, хәерле галәмәткә юрады. Шулай булмыйча соң, ничек булсын ди! Бая бит гел тәүфыйклы, гүзәл җырлар гына җырладылар. Һәм тыйнак сөйләштеләр. Әйе, аңлашылды.

Инде, ниһаять, рәтләр сирәгәйгәч, баянчы да үзе урнашкан өйгә кереп киткәч, җыр һәм гәп тынып, кызыклар беткәч, Ильяс тукталды. Аннары Рәгыйдә кереп киткән өйгә яңадан кайтып, урам уртасыннан, еракта куыклы лампа балкыткан тәрәзәгә, өй эченә озак кына карап торды. Ачык күренмәсә дә, барыбер таныды Ильяс. Рәгыйдә ак киемен салган, алсу-кызыл кофтадан калган — ут ялкыны кебек, бүлмәне балкытып, нәрсәдер эшләп йөри — җилпенгән саен Ильясның йөрәк бәгырен көйдерә, ялмап уза. Ә үзе исә, әлбәттә, әлбәттә, шуны белми ул — башына да китерми. Шул уй белән Ильяс бер кабат: «Аһ!» — дип куйды да, каты-каты адымнар белән өенә кайтып китте.

Төн буе рәтләп йоклый алмыйча, кандалалы өйдәге сымак борсаланып ятты. Көтүне яланга вакытыннан иртәрәк алып чыкты.

Көндезге сәгать уннарда исә (артистларның йокысы кайчан туйганны чамалап) ярдәмчесенә көтүне урманга алып кермәскә кушты да авылга юл тотты. Билгеле инде, туп-туры клубка.

Дөрес чамалаган иде. Клуб ачылганны хәтта әле бераз көтәргә дә туры килде. Көтеп морадына ирешкәч, беркемнән рөхсәт сорамыйча, сәхнәгә менеп, кичәге чүкеч һәм балтаны үзе куйган җирдән алды да, декорацияләрне сүтәргә кереште. Сәхнә түрендәге сурәтле чаршауны (озакламый моның задник дип аталуын беләчәк) алышырга клуб мөдирен чакырды. Анысын палас төргән кебек төреп, аннары ах-ух килеп, тышкы күтәрмәгә чыгарып куйдылар. Әкренләп, күтәрмәдә һәм шундагы чирәм өстендә сурәтле чүпрәк-чапраклар һәм такта өемнәре барлыкка килде.

Эш моның белән генә бетмәгән иде әле. Артистларны күрше авылга илтәсе атлы ике арба килеп туктагач та, кучер малайлар ярдәме белән, Ильяс ул әйберләрне арбаларның берсенә рәтләп төяп тә өлгерде. Артистлар берәм-берәм килә-килешли: «Нинди рәхмәт төшкере бәндә эшләп куйды боларны?» — дип, тел шартлата тордылар һәм, кем эше икәне беленгәч, Ильясны мактап туя алмадылар. Манчаровский иптәш кичәге сүзләрен кабатлады:

— Безнең театрга син генә җитмисең икән, Ильяс дус, — дип аның аркасыннан каккалады. Алай гынамы әле. — Син гади Ильяс кына түгелсең. Хозыр Ильяс булмагаең, — дип, баш селкеде.

Рәгыйдә исә, мең мәгънәле күзләре белән, мөгаен, Манчаровский абыйсы әйткәнне җөпләп, читтәнрәк елмаеп торды. Әгәр кыюлыгы җитсә, мин сиңа әйтим, Ильяс дус кызны, үзе хәтле чемоданы белән бергә күтәреп, арбага ук утыртыр иде. Мәгәр моңа ук житәрлек түгел иде кыюлык. Ильяс үтәмәгән эшне Марат атлы Юлдыбаев башкарды — хәерсез, арбага тәки китереп салды чемоданны. Әллә гарьлек, әллә үкенеч авырлыгыннан Ильяснын башы иелде, гаебе фаш ителгән адәм сыман, кызарып куйды. Бит кызулыгын сизүдән икенче оялып, читкәрәк тайпылды. Олаулар кузгалганчы, шул төштән кыймшанмады. Клуб мөдире белән кул кысышкач, Ильяс янына килеп Манчаровский куш куллап саубуллашты һәм аңа яңадан җан өрде. Кучер малайлар гадәти жорлык белән дилбегәләрне тартып атларны кузгаткач, бүтән артистлар да кул болгап саубуллаша белделәр. Артистларга иярә төшеп, ул үзе дә елмаеп кул изәде. Иң куанычлысы шул — барча әүлиялардан аермалы рәвештә, Рәгыйдә сөйкемле, таң шикелле серле күзләре белән томыраеп, Ильяс белән хушлашты. Күздән югалганчы йөзендәге серле яктылык сүнмәде һәм Ильясның күңеленә күчеп, мөгаен, гомер буе балкыр өчен калды...

Шул рәвешле киттеләр. Янында һичкем булмаса да:

— Хәерле сәфәрләр сезгә! — дип, ул чак кына элегрәк әйтелергә тиешле сүзен үз алдына әйтеп куйды.

• • •

Дөресен әйтик, шул көннән соң Ильясның шуклыгы, жорлыгы бермә-бер кимеде. Ник алай дип сорасаң, һич икеләнмичә әйтергә мөмкиндер: ул моңа җавап бирә алмас иде.

Көннәр буе, айлар һәм еллар буе Рәгыйдәне сагынып яшәячәген сизенсә дә, ник алай икәнен, юк, аңлый һәм аңлата алмаячак ул.

Гашыйк булдымы әллә күктәге йолдызга?

«Әйе», дип тә, «юк» дип тә әйтә алмый Ильяс. Интегеп бүтән сүз эзли — таба алмый. Таба алмаячак.

Алма кебек бичәсе бар Ильясның, матур гына дөнья көтәләр. Җитмәсә, гаиләгә озакламый янә бер җан иясе өстәләчәк. Бәс шулай булгач, тагын бер бичә кирәкмени аңа? Юк, кирәк түгел. Алайса, Рәгыйдә нишләп ымсындырды, ник айкап китте җанны?

Уфф!

Савымчы кызлар, юкка ялынасыз, Ильяс абзагыз сезгә тиз генә шаян җырларын җырлый алмаячак. Шаян җырлар капчыгы тишек булып чыкты. Коелдылар — җырлар гына түгел, мәзәкләр, хикмәтле сүзләр. Капчыкны ямыйсы булыр. Әйтегезче, кайсыгыз кем ямашыр аны?

Кызганыч, моңа язмышның насыйбы булмады. Артистлар нишләптер, авылга тиз генә сугылмады һәм аларның юлын кисеп, илгә афәт килде... Сугыш!..

Бу юлы Мәхмүт картка хәбәрне Ильяс китермәде, — хәлләр шаярырлык түгел иде. Шул хәерсез көннәрнең берсендә очрашкач, Мәхмүт карт үзе дә «сигез пот тотенне» телгә алырлык кәеф тапмыйча, сүзләрен рәнҗүле карашы белән генә аңлатырга тырышты. Тырышмаса да, барыбер Ильяс аның әйтелмәгән шелтәсен сизде: «Менә хәзер шаяр инде, юньсез нәмәрсә», — диясе килгәндер картның. — Үз кияңне үзең дә күр менә — юраганың юш килде, төтен түгел, ут җыярга туры килмәгәе...»

Бу сүзләрне Ильяс сугышның үзенә барып җиткәч, ут эченә ке-

рер алдыннан да кабат-кабат төшерде хәтеренә.

Өйдән чыгып китешли, чолан кәрнизенә үрмәләп, дәвер хәтереннән куырылган кызыл тышлы китабын алып юл капчыгына салган иде. Ничәмә мең чакрымлы юлларда капчык һич буш калмыйча, аның төбендә һәрвакыт күңелне ут сыман ялап, әрнетеп торган шул тере хатирә булды. Бүтән байлык өстәлмәде, диярга кирәк. Капчыкка салу җайсыз булган ачы нәмәрсәләр аның җанына мул җыелды — шартлаулы ут күңелгә чәчәткеч төтеннәре белән бергә тулды...

Сугыштан ул кәкерәеп каткан терсәк, бөгелми торган беләзек белән кайтты. Инде туры мәгънәсендә уң кулсыз, уң канатсыз калды. Икенче сынык канаты — аты шулай ук сугышка киткән иде. Табигыйдер ки, яраткан аты һич югы яралы хәлдә булса да кайта алмады.

Бу рәвештә ничек яшәргә, ничек гаилә карарга, дөнья күтәргә? Ә яшәргә кирәк иде.

## Бишенче бүлек

Бәһрәмия ул кайтуга йорт-кураны исән-аман диярлек саклаган — көтүдән ашыгып кызыл сыер һәм өч-дүрт сарык кайтып керә. Абзарлар элеккечә үк булмаса да, авып төшмәгән, эчке яктан карасаң, төнлә йолдызлар күренсә дә, бераз кул тидерсәң, рәткә керәчәк. Салам белән ябып, яңгыр һәм кар-бураннан ышыкларга мөмкин. Иң җайсызы — малларга кышлык азык әзерләү. Бөгелми торган терсәк-беләзек белән печән чабып булырмы?

Олы малайга ун яшь, ике кыз балага — сигез һәм алты. Алар әлегә бер генә эш башкара: өстәлгә куелган ризыкны үз куллары белән тотып ашый беләләр.

Чүкечне кулга бәйләп, җан ачысы түгеп, чалгыны чүки алды. Озаграк интексә дә, сул кулы белән кайрады. Һәм икенче көнне малаен ияртеп, урманга китте. Чалгы сабына кулны баягыча чүпрәк белән бәйләп куйды. Һәм... ходай үзең ярдәм ит...

Бер селтәнде, ике, өч... Бөтен җан әчесен эшкә кушып селтәнсә дә, юк, ярдәм итәргә ашыкмады ходай. Ул теләгәнчә кыланмый чалгы, иярәсе килми зәгыйфь кул артыннан, көчле кулларны гына ихтирам итеп күнеккән ул.

Ярый, шулай да булсын. Әмма Ильяс белән дә шаярырга ярамый. Ул синең җаеңны барыбер табачак. Кул алга чыгарга, сул якка талпынырга теләмәсә, Ильяс үзе икеләтә ныграк борылачак. Менә шушылай. Бер, ике, өч мәртәбә. Шактый күп мәртәбә. Чалгы бер аяк ягыннан икенчесе ягына күчә башлады лабаса. Әйе, үлән ава, покос гадәти булмаганча тар килеп чыга чыгуын да... анысына түзәргә кирәк. Вакыт җитәрлек әле, әзләп-әзләп барыбер җыелачак печән. Покос тарлыгыннан печәннең дәрәҗәсе төшмәс бит. Шулай менә. Ары киттек, чаж-чож, чаж-чож...

Барасы эш — бара. Тәртипме — тәртип. Ә шулай да читтәрәк торган малай ник шаркылдый соң әле анда?

— Әй, син, ник көләсең? Аю биетәләр мәллә?

— Синнән көләм, әти, кыяфәтең... биегән төсле, акробатик номер күрсәткән төсле...

— Һы, тапкан кызык. Биеп тә, акробат дигәнеңчә кыланып та көн күрә кайбер адәмнәр.

— Ачуланма, әти, мин болай гына, кызыктан.

— Менә үзең чаба башларсың, шунда көләрсең, яме.

Чалгы, малай кулына күчкәч тә, әллә ни кыра алмый, билгеле.

— Катырак селтә, катырак. Чалгың чабылган җиргә хәтле үләнне аударып бетерсен. Таррак алдыр, колачың җиткәнчәрәк. Менә шулай, ват, бара бит! Ә син әйтәсең.

Эти кеше бая чама белән ярты сәгать, ә хәзер малае ун-унбиш минут азапланып чапкан печәнгә күз ташлаган иде, ни күрсен — бөтенесен нибары бишәр метр озынлыктагы ун покос печән чабылган. Күп дигәндә, өч күбә печәндер. Нишләргә? Өмет өзеп өйгә тыракларгамы, әллә әлегәчә интегүне дәвам итәргәме?

Дәвам итәргә. Булган кешенең көрәге утын кисә дигәндәй, дәвам итәргә. Учлап, бөртекләп булса да җыярга печәнне, бүтән юл юк.

Чаж-чож, чаж-чож...

Уфф!

Шулай ярты көн узды. Чиратлашып чапкан булдылар.

Күп дигәндә, биш-алты күбә җыйдылар. Бер чүмәлә печәнгә бер атна вакыт китәчәк. Димәк, хатын белән киңәшләшергә туры килә. Дәвам итәргәме, әллә бүтән җай бармы?

Бәһрәмиянең иркенләп сөйләшергә дә вакыты җитми — ул колхоз печәнен җыярга йөри, төшкелеккә кайткач, гаиләгә аш-су әзерләсе бар, кичкелектә сыер савасы, сепаратка барасы... Болардан тыш, кер юу, өйне адәмчә тоту кебек эшләр, кем әйткәндәй, мәшәкатьләрне тавык чүпләсә дә бетерәсе түгел.

Бүген дә шулай — кырдан кайтып керү белән казанга су салып учак тергезде дә бакчага чыгып, чөгендер яфраклары өзде, берничә бөртек яшь бәрәңге табып, юып, турап, казанга салды. Аклы-каралы он кебек нәрсәдән умач уды. Озакламый, өйгә аш исенә тартым ис таралды. Ире белән малае да кайтып кергәч, өйгә ямь, гаилә күңеленә җылылык керде. Кәеф бераз рәтләнүдән файдаланып, түгәрәк өстәл янында Ильяс, хатынын мактагандай итеп, сүз башлады:

— Без юкта хатыннар печән чабарга өйрәнгән икән.

— Сыер дуласа аттан уздыра. Остарып беттек инде.

Ильяс сүзен ялгый алмыйчарак торды, «остарып беттек» дигәне фикерне бүтән яккарак авыштыра иде. Бәһрәмиянең җырлы, биюле уеннар оештырып йөргән чагы, башына күзерексез кипке, өстенә аллы-яллы һәм канатлы блуза, гармун итәк кигән рәвеше, шул кыяфә тә зал буйлата канатлы коштай бөтерелеп, очынып йөргән чагы хәтергә килде:

Биючenең итәге
Бии-бии кыскара.
Биючегә сүз әйтмәгез,
Бии-бии остара.

Җилпенә-җилпенә Бәһрәмия хәзер шулай җырлар дип ничек күз алдына китерергә мөмкин?

Хәзер каршыда бөтенләй бүтән кеше утыра. Чиртсәң кан чыгарга торган алсу бит кояш көйдергән, чор җиле куырган кытыршы, кучкыл чырай белән алмашынган. Беретканы гади чүпрәк яулык алыштырган. Чәчләр дә элекке түгел — шәпле атныкы сыман җилкәгә төшкән кабарынкы ял юкка чыккан, аның урынында нечкә генә бер толым барлыкка килгән. Әйтерсең, эшен генә түгел, кешенең үзен үк алмаштырып куйганнар. Чынлаптыр шулай. Заман безнең яшь гомерне көлгә әйләндерде дә көлен җилләр очырды...

Табын янында бүгенге көн турында, кыенлыкларны ничек җиңәләйтү хакында киңәшмәкче иде, барып чыкмас, ахрысы. Аның уйларын сизгәндәй, Бәһрәмия дә балаларга гына вак-төяк сүз катып, тынып калды. Ул да үз нәүбәтендә, мөгаен, иренең шәп чагын күңеленә китергәндер. Кем белсен.

Тәлинкәләр бушагач, аягүрә баскач кына Ильяс әйтәсе сүзен әйтмичә булдыра алмады:

— Малай белән печән чабып караган идек тә... әллә ни кыйратып булмый әле. Синең урынга печән җыярга... ы-ы... мин чыксам ничек булыр икән? Син монда үз көеңә чаба торсаң.

Бичә көлеп кенә куйды:

— И-и, исең киткән икән. Ние бар аның — миннән башка кем бар. Сыер булып савылабыз, ат булып җигеләбез... — Ярый әле, балалар алдында әйтемнең азагын төшереп калдырды. — Чабарбыз, чабарбыз. Чалгы көйләүче булганда.

— Алайса, печән җыярга хәзер мин китәм. Анда бераз гәүдә ял иткәч, рольләрне тагын алмашырбыз.

«Роль» дигәнгә бераз гына гаҗәпсенеп куйса да, хатын ул чаклы нык игътибар итмәде, чыраена чыгармады.

— Бар, хатыннар ир төсе күрсен. Эшләгән булып йөр шунда.

Сул кул белән печән җыю да җиңел түгел икән. Әмма, хатыннар аннан артыгын көтмәделәр дә шикелле. Икенче көнне исә кибән куярга вакыт җиткәч, исән калган карт алаша белән чүмәлә тарттыра башлагач, Ильяс инде бернинди ташламасыз да ирлегенә хилафлык китермәслек дәрәҗәдә хокуклы кешегә әверелде. Шулай атна-ун көн үтте. Бәһрәмия печәнне йорт өчен әзерли торды. Кайбер көннәрдә, бик үк юксынмасыннар, телгә кертмәсеннәр өчен, колхоз печәнен җыярга үзе барды, ир, хәл кадәренчә, малай белән бергәләп, чалгы селтәвен дәвам итте. Кипкән печәнне бергәләп бәләкәй арбада ташый тордылар. Абзар артында ярыйсы гына кибән калыккач, әчкә җылы керде. Сыерның җанын саклап була, болай булгач. Сыерлы кеше ачтан үлми ул. Сыерлы кеше — сыйлы кеше. Әйе. Инде көз елавы, кыш улавы да куркытмас. Әмма тулы тынычлык көтү тилелек билгесе булып чыкты. Кышның корсагы уйлаганнан да зуррак икән. Ә алда — кара яз. Һәркем белә моны. Яз көне басуга, чабылмый калган иген кырына чыгып, халык башак җыячак. Кар астында кышлаган ашлыкның афәтен белгән килеш, бәлки әле зыяны тимәс, дигән әлҗеле-мөлҗеле өмет белән (яки, бүген үлүгә карaганда иртәгә үлү хәерлерәк дигән уй белән) чиләк-чиләк бодай җыеп кайтачаклар...

Әмма Ильяс башкалардан чак кына аермалы бит. Ильяс авылдагы калдык-постык яшьләрне, дөресрәге, үсмерләрне җыеп, башта сәер еллар учагыннан өтәләнеп чыккан һәм аннан соң сугыш уты-ялкыннары аша узган кызыл тышлы китабындагы пьесаларның берсен сайлап, спектакль әзерләде. Баш рольне башкаручы — Ильяс, режиссер, игъланнар язып таратучы, администратор — Ильяс, тегеннән-моннан табып, үзенә күрә декорация әтмәлләүче сәхнә эшчесе — Ильяс. Бу эшләрне аңа беркем йөкләмәгән, беркем хак түләми, ашатмый-эчертми. Ачның күзе икмәктә була дисәк тә, дөрес үк түгел бугай. Сугыштан кайтканнан бирле күргәне юк икмәкне. Ә менә хикмәтсез яши алмый ул. Ачның күзе хикмәттә дә була ала икән.

Якын-тирә авылларны йөреп чыккач, бер әсәрне күрсәтү мөмкинлеге беткәннән соң яңа әсәр әзерләп интеккән арада, уйламаган-көтмәгәндә, хәл кинәт үзгәрмәс, авылга чын артистлар килмәс диген син. Ләкин килде. Элеккечә матур, ашъяулык чаклы кәгазьгә булмаса да, гәзит битенә генә булса да язып, игълан элгәннәр иде. Ильяс үз күзләренә ышанмый торды. Ышангач исә, кичне җиткерә алмыйча газапланды.

— Бичәкәй, бүген клубта — спектакль. Җыена башла.

— Клубка? Котып суыгынамы, катып үләргә?

— Тамаша карарга, кызык күрергә.

— Минем өемдә — үз әртисем, бушлай күрсәтә кәмитне.

— Әллә бармаска итә инде?

— Эш калдырып... Бар, син баргач та җиткән.

Аптырабрак калды Ильяс. Бәһрәмия соңгы елларда нык үзгәргән иде үзгәрүен. Әмма болай ук дип уйламаган иде Ильяс. Бичәсен ул юри шаярта, үчекләргә тырыша дип кенә чамалады. Кайчандыр кешеләрне клубка үзе чакыра, уеннарны үзе оештыра торган, бөтен

клубны очып-бөтерелеп әйләнә торган чая кыз... Хәзер килеп шундый сүз сөйләр дип кем башына килсен? Аны шайтан алмаштырганлыкка ничек ышанмассың хәзер?

Шулай уйлап, Ильяс бик җитди һәм шаярмаска киңәш иткән тавыш белән:

— Ярар, җитте сиңа, җыен, — дип куйды.

Ләкин хатыны:

— Үзеңә җитте! — дип җикергәч, сискәнә куйды.

Үгетне туктатты. Һәм алга куелган каты-котыны капкалагач, сүзсез генә чыгып китте.

Клуб янындагы төркемгә кушылып, юк-бар сөйләшкән арада... чапрыш урамнан таныш гәүдә күренде. Ничәмә ел узуга карамастан, таныды Ильяс. Менә ичмасам кеше! Күпме гомер кичкән, күпме кайгы-җафа чиккән, әмма үзгәрмәгән!

Килеп җитәсен белгән килеш, Ильяс аның каршысына ашыкты.

— Иптәш Манчаровский! Исәнгенәмесез, саумысыз!

Күзләрендәге гаҗәпсенүгә караганда, өлкән артист үз гомерендә бер генә кабат күргән кешене танымады, әлбәттә. Ләкин артык дулкынлану аркасында, Ильяс мондый ваклыкка игътибар итүдән ерак иде.

— Мин — Ильяс. Хәтерлисезме? Ильяс мин. Бер вакыт сәхнәгезне төзәтеп корган идем, — дип, бүреген өскәрәк калкытты.

— Таныйм, нишләп танымаска. Ильяс. Хозыр Ильяс. Әйе шул, сәхнәне бик шәп итеп корган идең.

Ялгышмаган Ильяс — хәтерли бит әнә, онытмаган тәки!

— Рөхсәт итсәгез, бүген дә эшләргә була.

— Шулаймы? — дип, ихлас сөенде карт артист. — Әйдә, дус кеше. Бик зур игелек күрсәткәнең булыр. Миңа димәсәң, сәнгатькә.

— Рәхмәт, иптәш Манчаровский.

— Менә бит нинди кешеләребез бар безнең! — дип, Манчаровский Ильясның иңеннән кочаклап клубка алып керде.

Театрда сәхнә эшчесе юк икән, штатта каралмаган. Шунлыктан бу эшне артистлар үзләре башкара. Манчаровский шул хакта бераз зарланып алды.

— Син бик тә кулай кеше дә бит. Нишлисең.

— Алсагыз, мин ике куллап риза булыр идем. Язга чаклы.

— Әйтәм бит, эш хакы түләп булмый.

— Булмаса соң.

Карт артист колагым ялгыш ишетә диебрәк торганда, сәхнәгә дөбердәп башка артистлар менә башлаганлыктан, сүз өзелеп калды. Һәм Ильяска чүкеч-келәшчә барлап, эшкә керешергә туры килде. Такталар шакылдаткан арада күтәрелеп, ул Рәгыйдәне эзли иде.

Ул түгелме дип, яшьрәк бер-ике кызга бик текәлмичә генә, ләкин тикшеребрәк караудан файда чыкмады. Берсе буй-сыны белән Рәгыйдәгә тартым тоелса да, хәрәкәтләре ят, йөз-чырае белән аннан нык кайтыш иде. Рәгыйдә булса, сәхнәгә әллә кайчан инде җан бөркеп, бөтерелеп йөрер, Ильяска да сүз кушар, көлә-көлә сөйләшер иде. Аннан кире, Рәгыйдәнең йөзе болай авыруга охшашлы ямансу түгел иде. Әллә инде ул юкмы, каядыр киткәнме?

Шунысы хак, килеп җитмәсме дип күпме көтсә дә, кыз берничек тә күзгә чалынмады. Теге чакта баш рольне уйнаган әүлия егетне таный язса да, Ильяс үзе аңа әллә ни игътибар итә алмады. Ильясның бая гына шатлыктан канатланган җаны җилпенмәс булды. Кырылды кәефе. Кәефе кырылу сәбәпле, соңгы кадакларга ул катырак, хәтта ачу беләнрәк сукты. Эш беткәч исә, рәхмәт ишетергә дә теләмәстән, чүкеч-келәшчәне ян тәрәзә төбенә куеп, сүзсез генә сәхнәдән төште.

Клуб яртылаш тулган иде. Колхоз рәисе сәхнәгә менгәч, ким дигәндә ярты сәгатьлек нотык тыңлап утырырга туры килде. Ул сүзен очлар очламас бер мәлдә таныш тавыш — ниһаять, баян тавышы яңгырады. Шул кадәр матур, шул кадәр якын, нәкъ менә Рәгыйдә хатирәсе шикелле назлы, үзәк өзгеч сагышлы тавыш иде ул. Күңелләрне күтәрер өчен махсус уйналган дәртле көйләрдә дә сагыш төсмәрләре ишетелә, тамакка төен булып төйнәлә. Йотып та булмый, күз яшьләре белән юып төшерү дә мөмкин түгел. Елыйсы килә, елап булмый — әллә күздә яшь юк, әллә кешеләрдән оят. Тойгыларның болай төйнәлүе заманның үз галәмәтеме, әллә Рәгыйдә белән күрешү өметенең алдануыннанмы? Әллә бу елларда ифрат та сирәк ишетелгән баян тавышы тетрәттеме җанны? Барысы, барысы бергәдер, бергәдер...

Баян тавышы тынып, бер-ике минут үткәч, пәрдә алдына Манчаровский чыкты. Иң әүвәл Ильясны шаккатырганы шул булды: «Ак калфак» исемле әсәр күрсәтелә икән. Игъланны ничәмә кабат укып, пьеса исеменә күз төшмәгән. Ник диген? Ильяс анда бары тик бер генә сүз — Рәгыйдә исемен генә эзләгән иде. Исемнәр язылмаган иде. Ачуың килмәгәе, ат боты хәтле хәрефләрдән мәгънәле бер сүз җыя алмаган Ильяс. Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе — ботак тишеге. Дөресе шул.

Һәм менә — чираттагы могҗиза — баш рольне... Хәмдияне... кем?.. Ильяс, ышанма, ялгыш әйткәндер Манчаровский. Элекке, күнегелгән гадәт буенча гына, ялгышып кына әйткәндер. Ләкин ничек булса да әйтте бит һәм йөрәк әйтерсең бәхеттән шартлады. Йөрәк тә, зиһен дә юкка чыкты. Шулай да ишетте колаклар. Бөтен халыкка ишетелерлек итеп, игълан итте Манчаровский: — Хәмдия — яшь һәм талантлы артисткабыз Рәгыйдә Нәзифуллина!

Һәм шул җитте. Башка исемнәрне ишетүнең кирәге калмады. Дөресрәге, аларны ишетүдән Ильясның зиһене баш тартты. Спектакль, әйтерсең, бер кешедән гыйбарәт. Манчаровскийның барлык рольләрне һәм башкаручыларны атап, сәхнә артына китүен дә, пәрдә ачылуын да Ильяс сизми калды. Һәм күрде, сәхнәдә — Хәмдия! Һәм шул ук вакытта Рәгыйдә үзе! Базы үзәнендә үскән кызыл тал төсле зифа буйлы, сурәтләрдә генә күрергә мөмкин һәм буяуга бөтенләй мохтаҗ булмаган матур йөз! Әле күкрәгенә, әле җилкәсенә төшеп торган калын толымнар. Аккошныкы сыманрак озынча муен! Үзенең матурлыгын, камиллеген тоюдан килгән ышанычлы, ныклы һәм шул ук вакытта кечке һәм таңгы чишмә чылтыравыннан күчкән яңгыравыклы тавыш! Шундый, шундый якын һәм таныш, гүяки тумыштан таныш! Рәгыйдә, Рәгыйдә үзе! Ә нишләп бая күренмәде икән? Ә юк, бая да күренгән, тик Ильяс аны танымаган гына. Бая сәхнә артында боегып утырган кыз бала Рәгыйдәнең үзе булган лабаса. Ә хәзер ул үз кыяфәтенә кайткан. Баягы Рәгыйдә моннан берничә ел элек очраган Рәгыйдә түгел, хәзерге, менә шушы минуттагы Рәгыйдә дә түгел иде. Хәзер менә чын Рәгыйдә кайтты. Еллар буе Ильяс хыялында яшәгән илаһи зат яңадан каршына чыгып басты һәм үзенең чын барлыгында яши башлады. Дөньяда Рәгыйдә бар, ул сөйләшә, җырлый, көлә, үртәшә, шаяра. Көтүче егетне — әллә Ильяснымы? — сәнгатькә, матурлыкка, биеклеккә, бөеклеккә чакыра, рухландыра, шаштыра. Һәм күңелдә моң, көй, җыр ярала, җыр туа, Рәгыйдәнең үзе кебек үк үлемсез матурлык барлыкка килә.

Көтүче егет юкка гына Бакый исемле түгелдер. Мөгаен, бу исем — үлемсез гашыйк, үлемсез мәхәббәт дигәнне аңлатадыр. Ильяс йөрәгендә тумыштан яшәгән мәхәббәт — матурлыкка соклану шулай аталадыр. Ә матурлыкка гашыйк кеше Марат Юлдыбаев кына түгелдер, һич тә түгелдер, ә бәлки бүтән исем белән йөртелергә тиештер. Бәлки әле Ильяс дип? Ә шулай булса ни гаҗәп?

Ильяс атлы егет көтү көттеме? Көтте. Рәгыйдәне еллар буе күңелен дә йөрттеме? Йөртте. Шулай булгач, тагы ни кирәк? Әһә, җыр чыгара алу кирәкме? Менә монда уйланырлык нәрсә бар бугай.

Мәгәр көй бар бит инде, икенчесе кирәк тә түгел ләбаса. Әнә бит, яңгырый көй:

Хәмдиягә сүз әйтмәгез,
Зиһене таралган чагы...

Көйне Бакый дигән егет чыгарган, Ильястан алдарак өлгергән һәм күпләр өчен, шул исәптән Ильяс өчен дә иҗат иткән, аның уй-хисләрен дә моң рәвешенә керткән. Моң уртак булгач, аны Ильясныкы дип тә әйтеп була түгелме соң? Әйе, һич тә байлык бүлешәсе юк — күпме кеше күпме генә җырласа, кабатласа да бетәрлек түгел моң. Мәхәббәт тә шулай. Җыр ул мәхәббәтнең яңгырашка ирешкән икенче төрле рәвеше. Ул — үлемсез һәм чиксез.

Дөрес, явыз көчләр Бакыйга табигать бүләк иткән хокуктан файдаланырга — яратырга, яшәргә ирек бирмәделәр. Бакый һәлак булды. Ләкин аның кебек меңнәр исән калгандыр... Шул җөмләдән Ильяс... Рәгыйдә калды. Димәк, җыр, мәхәббәт дәвам итә.

Спектакльнең башыннан азагына чаклы Ильяс шушындый өметле газап кичереп утырды. Дөрес, ул үзе бу кичерешләрне сүз белән әйтеп бирә алмас иде. Әмма тойгылары сүзләрдән кайнаррак, тирәнрәк иде. Монысы шулай ук бәхәссездер.

Концерт вакытында газаплар юкка чыгып, әйтергә мөмкиндер, сөенечле хисләр биләп алды күңелне. Баянчыдан башлап, Манчаровскийның үзенә кадәр гел уйнады, шаярды, көлделәр, көлдерделәр. Җанга ял бирмәгән бер генә номер да чыкмады сәхнәгә. Ә иң көчлесе һәм үзәкне өзәрлек нәфисе Рәгыйдә Нәзифуллинаның атаклы тавышы булды. Бер чыгуында җырлады, икенчесендә шигырь укыды кыз. Җитмәсә, күрше авыл малае, теге чакта Ильяс костюм сатып алган студентның үзе кебек үк укуга әвәс энесе язган шигырьне укыды. Шигырь күптән түгел район газетасында басылган иде.

Үлчәнмәгән ераклыклар алда,
Дөнья — диңгез, ә син — корабль.
Шул диңгездә батып калмас өчен
Үзеңә тиң иптәш таба бел.

Клубка килгәндә башлары җиргә иелгән кешеләрнең күзләрендә очкыннар кабынды. Гөрләтеп кул чабулары аларның үз хисләрен тану, күрү һәм бәя бирү билгесе түгелмени?

Хушлашырга чыккан артистларны аягүрә басып алкышлаучыларның алгы рәтендә Ильяс тантана итте. Рәгыйдәдән күзләрен алмады. Манчаровскийга, баянчы Солтановка, үзе әүлия дип атаган Юлдыбаевка кул изәде. Ә рәхмәтләрнең иң зурысы Рәгыйдәгә багышланды.

— Булдырдыгыз, рәхмәт! Матур яшәгез, бәхетле булыгыз!

Рәгыйдә белән күзләр берничә кабат очрашты. Рәгыйдә шулай ук аңа үзенең иң якты мәгънәле елмаюларын бүләк итте. Мизгел мәңге онытылмаслык, вакытның узмавын теләрлек иде. Әмма да һәр нәрсәнең азагы була шул.

Концерт тәмам.

Пәрдә ябык.

Ильяс дус! Ябык пәрдә аша күпме карасаң да, баягы тамашаны инде күрә алмассың. Хәер, тамаша инде үзе юк, анда хәзер чын тормыш башланды, ят тормыш... Анысын сиңа күрсәтергә тырышмаслар, бәлки әле яшерергә тырышырлар. Икенче тормыш, Рәгый-

дәнең чын тормышы — пәрдә артында... Пәрдә ябык.

Шулай да күрергә тырышу, иң азактан чыгуның файдасы тиде. Ишек төбенә җитәрәк сәхнә баскычыннан кемдер аның исеме белән дәште. Борылып караса, канатлы әүлия — Марат Юлдыбаев. Ишек төбенә йөгерә-атлый килде дә кул биреп исәнләште:

— Сезгә үтенеч бар иде, Ильяс дус.

Ильясның сөенечтән күзләре очкынланып куйды.

— Сез дигәндә, аяк идәндә.

— Әйбәт сүзеңә рәхмәт, Ильяс дус. Мине Манчаровский җибәрде.

— Әйттем бит, кулдан килә торган эш булса...

— Килмәгән кая. Шул. Иртәгә декорацияләрне сүтеп төяшергә булышмассызмы дигән идек.

— Әһе. Бүген ярамыймы?

Аптырабрак куйган әүлиягә сүз әйтер җай калдырмастан, Ильяс туп-туры сәхнәгә ашыкты. Күп дигәндә унбиш-егерме минут узгандыр, әйберләр, рәте рәткә яткырылып, өеп тә куелган иде. Бер мәлне күтәрелеп караса, Манчаровский, канатлы әүлия, һәм... Рәгыйдә басып тора. Ильясның эше беткәнне махсус көткәннәр, бугай. Ильяс чүкечен куеп өлгергәнче үк Манчаровский аңа баш какты:

— Киттекме, дус кеше?

— Киттек, иптәш Манчаровский.

Шулай дип, Ильяс алар янына килгәч тә өлкән артистның чемоданына үрелгән иде, тегесе:

— Әнә, кызларныкын тот, — дип, Рәгыйдә чемоданына ымлады.

Бу сүздән канатлы әүлия шактый мәгънәле хихылдап куйса, Рәгыйдә, янәсе, ишетмәде, чемоданны үзе алды. Аның кулындагы чемоданга үрелергә Ильяс кыючылык итмәгәнне күргән өлкән артист ярдәмгә килде:

— Ал, ал, кызлар «мә» дигәнне көтмә.

Рәгыйдә исә шулай ук елмаеп, ялындырмыйча, чемоданны үзе сузды. Шуннан канатлы әүлия шаяртырга җай табып, бер дә юктан:

— Үземнең чемодан, кемгә хочу, шуңа дам, — дип көләсе итте.

Әллә бик үк әүлия түгел инде?

Урамга чыктылар. Моннан берничә ел элек очрашкандагы кебек үк авылның төп урамы буйлап атладылар. Әмма быелгы адымнар теге чактагы белән чагыштырганда җир белән күк шикелле. Бернинди җыр, шау-гөр килү юк. Фәрит дигән Солтанов баянын сандыгына ук салып, аркасына аскан. Канатлы әүлия белән Манчаровский гына юк-бар сөйләшкән булалар. Рәгыйдә исә, тагын сүрелде. Сәхнәдәге терелеге, ихтыяры җил белән очты диярсең. Эндәшсәң, кыска гына җавап бирә, эндәшмәсәң — ләм-мим, атлавын белә. Гаҗәп. Ләкин аңлау кыен түгел. Илдәге җил-яңгыр аны гына читләтеп узмагандыр.

Болай үзе нәкъ теге чактагы тәртип кабатланды. Башта Солтанов тыныч йокы теләп кереп калса, аннары — Рәгыйдә. Ләкин... Ләкин бу юлы үзе генә түгел, канатлы әүлия дә тукталды. Һәм Ильястан чемоданны алып, рәхмәт әйтте. Йөрәге жу итте Ильясның. Рәхмәткә җавап та бирә алмыйча, аптырап калды. «Рәгыйдә? Рәгыйдә белән канатлы әүлия? Тәки кушылганнармыни?»

Тавышсыз калган Ильяс әүлия кул сузгач кына һушына килгәндәй булды. Ләкин баскан җиреннән барыбер тиз генә атлап китә алмады. Рәгыйдә үзе дә тыныч йокы теләп капкадан кереп киткәч, Манчаровский тагын нәрсәләрдер әйткәч тә, каккан багана хәлендә тагын күпмедер вакыт торганнан соң гына башына азмы-күпме уй килә башлады.

Йә инде, шуны да чамалый алма инде. Сәхнәдә еллар буе егет бе-

лән кыз булып уйна да, уеннан уймак чыкмасын. Ничек итеп шул аһ-лар, уфлар эзсез узсын, аерылышып, кавышып, сөенешкән һәм газапланган яшьләр бер-берсенә ничек итеп чынлап тартылмасын. Бик тә гади нәрсә ләбаса, уен гадәткә әйләнә.

Нәтиҗә катгый һәм дөрес иде. Шунысын гына төшенәсе калды: рас шулай икән, ике артистның кушылуы бик тә табигый икән, нишләп соң әле Ильясның кәефе кырылды? Нинди нигездә? Ни хакың бар синең моны һуш җуярлык дәрәҗәдә авыр кабул итәргә? Интегергә, авыр суларга — аһылдарга? Дивана! Бүтән сүз юк. Бары тик исәрлек аркасында гына. Бетте китте. Бөтен сәбәп шул гына. Әйе.

Катгый нәтиҗәгә нокта рәвешендә, үз уйларына ул «Тфу!» дип төкерде дә, каты-каты басып, өенә юнәлде. Кар белән аяклар сатулашуы гына бөтен авылга ишетелгәндер. Шул кадәр нык шыгырдады кар, әйтерсең ки, Ильясның беркатлы җүләр булуыннан кычкырып-кычкырып көлә һәм такърарлый:

— Шыгырт, шыгырт, шыр чыккан, шыр чыккан җүләр.

Бу җүләрлегеңне Бәһрамиягә кайтып сөйләсәң, ул ни дияр иде икән?

Берни әйтмәс, уклау гына күтәрер иде.

Шул фикерне җөпләгәндәй таныш шигырь хәтергә килде:

> Син минем миләүшәм идең,
> Яме идең болынның.
> Яшь төшкәч, башкаема
> Уклау белән тондырдың.

Уклау тәмен чынлап татыганга исәпләп, күңеле бераз тынычлана төшкәч кенә, Ильяс ишек какты. Йокылы-уяулы «Кем бар?» — дигән сорауга гадәттән тыш җылы итеп:

— Мин бу, әнисе, ач! — диде. — Йокыңны бүлдем, ачуланма инде.

Болынга ямь биргән миләүшә чакларың бар иде лә ул синең дә, дип өстәмәкче иде, тиешле урында тыйлыга белде. Йә, шуннан соң аны кем дивана дия алсын?

Булдырдың, Ильяс, яшә.

* * *

Кыш көне авыл кешесенең мәшәкате әллә ни күп түгел. Мал-туар кычкыра, каз-тавык күтәрмә төбенә килеп шыгырдый башлагач, аларга җим саласың, хатынга утын кертеп бирәсең, ихата көрисең. Бик уңган булсаң, сыер абзарындагы тиресне көннекен көнгә чыгарып, аяк астына яңа салам саласың. Тагын нинди эш? Бетә дә яза бугай. Дөресен әйтсәк, гадәттә бу эшләр дә Ильяска калмый — аларны Бәһрамия һич авырсынмыйча үзе башкара. Ильяс, теләсә, кояш чыккач та кайгы-хәсрәтсез, рәхәтләнеп йокы симертә ала. Бүген дә шулай кузгалмаска иде исәбе. Ишек шыгырдата-шыгырдата урык-сурык йөргән Бәһрамия адымнарын йокы аралаш тыңлап, төшкә хәтле аунамакчы иде. Әгәр дә мәгәр кузгатырлык сәбәп чыкмаса. Әмма сәбәп чыкты, хәерсез. Сәбәп йокының бик үк тирән булмавына бәйле булды. Тәгаен әйтсәк, болайрак. Малай мәктәптән бик тә иртә кайткан икән. Көн артык салкын булганга, дәресләрне үткәрмәскә боерык килгән, имеш. Сабак алмыйча, теләсә кая сугылып кайтышлый, малай клуб тирәсендә йөренгән артистлар янында туктап торган. Аптырашка калганнар артистлар. Күрше авылга илтеп куярга тиешле ат чирләгән. Нишләргә белми аһ оралар ди.

Шушы хәбәрне ишетүгә, мин сиңа әйтим, Ильяснын йокысы качты куйды. Сикереп торды да, ашыгыч юынып, аннан-моннан капкалап, клуб ягына теркелдәде. Хәбәр хак икән. Артистлар — пошаманда. Ильяс Манчаровский белән идарәгә үзе кереп чыкты. Ат юк. Исән калган ике-өч ат болынга печәнгә киткән. Сөмсере коелган рәис күзләрен яшереп кенә:

— Үгез бар-барын,— дигәч, Манчаровский мәзәксенеп бер Ильяска, икенчеләй рәискә караганлыктан, рәис үз гаебен йомшартырга чамалады, күрәсең.— Болай җиккәләдек инде без аны,— дип, күзләрен тагын өстәлгә текәде.

Манчаровскийның чырае чирле кешенекедәй чытык иде. Шуны күргән Ильяснын йөрәге сулкылдап куйды. Ихлас кызганды. Рәгыйдәне күз алдына китерде. Ул да хәзер, мөгаен, кара кайгыга чумгандыр. Аны җәлләп йөрәгенең соңгы тамчы мае сызылып тамгандай булды. Шундый ярдәмсез, җайсыз хәлдә калган кешеләрне ничек авыр хәлдән коткарырга тырышмыйсың ди. Әйе, ничек тә ярдәм итү ягын карарга кирәк.

Шул ният белән ул рәис сүзләрен җөпләргә тиеш тапты.

— Үгез дигәч тә... аны да бит ходай бар иткән. Үгез дә мал. Нәкъ үзе. Көйләп-чөйләп йөртсәң, тарта ул йөкне.

Азрак тын торганнан соң рәис күзләрен яшермичә генә:

— Әллә тапшырабызмы ходайга?— дип, Манчаровскийга уйларга мөмкинлек бирде.

Манчаровский шулай ук ашыкмыйча гына әйтте:

— Бүтән һич чара юк икән, нишлисең. Ни әйтсәң дә, юл кешесенең юлда булганы хәерле. Тапшырыйк.

Олаучы табу шулай ук җиңел түгеллеген белгән Ильяс монысын шундук үз өстенә алды. Үгезле чана белән килергә вәгъдә биреп, җәһәт кенә чыгып китте. Җигү әйберләрен, бигрәк тә камытны көчхәл белән табу һәм әмәлләүне, тагын бүтән мәшәкатьләрне тәфсилләп сөйләүнең кирәге юктыр. Үгезне көйләп-чөйләп кенә, җитәкләп кенә клуб янына тәки китереп җиткерде. Үрәчәле зур чанага азрак печән белән мул гына салам салган иде. Декорация такталары кырылмасынга һәм үгез ачыга калса аңа ныклык бирер өчен шулай тиеш иде. Сәхнә әйберләрен Юлдыбай әүлия һәм баянчы Солтанов төяштеләр. Аннары һәркем чемоданын йөк өстенә куйды. Манчаровский белән Рәгыйдә утырып барырга, калганнар җәяү тәпиләргә килештеләр. Хәерле юл теләп рәис үзе озатып калды. Ләкин аның теләге үгез нияте белән туры килдеме соң? Хикмәт әнә шул сорауга бәйле иде.

Юл кешесенең юлда булганы хәерле, дидек. Дөрес. Мәгәр юлга чыгу үзе үк гүр газабына тиң дигәнгә ышаныргамы, юкмы? Ышанырга туры килә. Чөнки дип әйтик, үгез каядыр барырга, җылы, сөекле, туган абзарыннан аерылырга ашкынып торамы? Күр әнә, баскан җиреннән кыймшанырга да чамаламый. Ачуың бик килсә, рәхәтләнеп арттыр — Ильяс абзагыз аны кузгату өчен үзенең еллар буе туплаган һәм физик, һәм әхлакый запасларының, ким дигәндә, яртысын исраф иткәндер. Дучар булгандыр дисәк, тагын да хаклырак булырбыз. Шулай. Дилбегәне бер тартты Ильяс, үгез койрыгын гына селкеткәләде. Җитәкләп кузгатмакчы иде, моның белән дә ризалашмады үгез. Бу мизгелдә чак кына селкенгәндәй тоелса да, барыбер күзгә күренерлек хәрәкәт ясарга теләге сизелмәде.

Йөк өстенә менеп кунаклаган Манчаровский белән Рәгыйдә, мескенкәйләр, түземлекләре төкәнгәч, чанадан төшәсе иттеләр. Шул чакта Рәгыйдә:

— Берәр телем эпи сузсаң, бәлки иярер иде,— дип куйгач, башкалар аңа ньк кына сәер караш ташладылар. Акылына зәгыйфьлек килмәгәнме, янәсе.

Мәгәр фикер бик дөрес иде. Моны шәп белгән Ильяс үзенең бөтен кыюлыгын җигеп, чанадан бераз печән йолыкты да аны Рәгыйдәгә сузды:

— Шушыны биреп карагыз әле. Ашаса, алгарак атларсыз,— дигән киңәшне бирә алды.

Йа алла диген, үгез кабул итте сыйны. Чәйнәде, йотты. Ильясның ымын тыңлап алгарак киткән Рәгыйдә артыннан... ышанасызмы, юкмы? Әйе, Рәгыйдә артыннан иярә китте хөрмәтле вә гыйззәтле үгезебез. Менә шулай. Авыл башына чыкканчы шул ысул үзен тулысынчааклады. Авылны чыккач, хәтта печәнсез дә Рәгыйдәдән калышмаска тырышып атлады. Һәм — никадәр куаныч!— тигез юлга чыккач, Рәгыйдә йөгереп күрсәткәч, аңа ияреп, хәтта юыртып китте. Рәгыйдә арый язып Манчаровский янына, йөк өстенә сикергәч тә байтак ара матур гына атлый белде.

Чакрым чамасы үрле җир узганнан соң, яңадан өч-дүрт чакрым — сөзәк юл. Тәвәккәлләп Ильяс үгезне ашыктыра төшкән иде, үгез юыртып та китте. Монысына ук өметләнмәгән иделәр. Ләкин дөреслеккә кем каршы килсен. Нәкъ шулай булды. Мәгәр бит халык борын-борыннан: сыер дуласа аттан уздыра, дия килгән. Үзегез беләсездер, үгез ир затыннан булса да: барыбер сыер нәселеннән. Шуны истә тотыйк, чөнки хәзер үз күзебез белән күреп халыкның хак әйткәненә ышанырга туры киләчәк. Әйе, бәхәсләшмәскә сүз куешыйк. Хикмәт менә нәрсәдә. Үгезебез бик матур гына юыртып киткәч, пассажирларның кәефе бермә-бер күтәрелде.

— И-их, үгез дус, килде-китте аттан шәбрәк икәнсең ласа!— дип Манчаровский үгезне тагын да үсендерә төште.

Рәгыйдә рәхәтләнеп, кычкырып көлү өстенә күңелендәге иң назлы тойгыларын чәчеп очындыра иде.

— На, на, малкай! Чибәркәй, җитезкәй! На-а!

Үгез әллә чынлап та үсенеп-очынып, кылтаеп китте, әллә аягы чана башындагы аскы аратага бәрелеп үртәлде. Ни булса шул — юырту белән генә канәгатьләнмичә, арт санын чөя-чөя, чабарга тотынды. Алданрак җәяүли киткән Юлдыбаев белән Солтанов һәм тагын өч-дүрт артистны куып җиткәч, алар да утырырга теләгән иде, өлгерә алмау сәбәпле, йөгереп карасалар да, утыра алмадылар. Ильяс дилбегәне никадәр нык тартып карамасын, матур-матур сүзләр әйтмәсен, үгез ул сүзләрне колакка да элмичә, чабуын белде. Тагын ярты чакрымлап чаптымы, кимрәкме, бермәлне чабуы дулау дигән тизлеккә күчте. Чын мәгънәсендә дулап чабарга кереште үгез. Әйе, чапсын иде әле, түзәр идең анысына. Тизрәк барасы төшкә җитүдән һич зыян күрмәс идең. Мәгәр юл, бигрәк тә кышкы юл тигез генә буламыни. Сикәлтәле җирдә чана гопылдап чокырга төшкән чакта эчеңне тот та кычкыр, бүтән чараң юк. Сикәлтәләрдән, эч айкалулардан да яманрагы юкмы тагы? Бар. Сабыр итегез.

Әйе, кем. Сикәлтәләр өстенә, икеме, өчме метрга җитмәле шомарган, салулы урыннар азмы әллә. Бар алар, күп. Байтагын исән генә узарга да мөмкин булды. Ләкин бит гел син дигәнчә генә булмый. Менә мин сиңа әйтим, шундый бер шомарып беткән, салулы җирдә чана, каткан бозгамы, бүтән нәрсәгә бәрелдеме, авып та китте, пассажирлар мәтәлеп, кар өстенә очты. Ни булганны аңлар дәрәҗәгә килгәндә, манзара менә нинди иде: Манчаровский биш-ун адым артта чалкан ята, ә Рәгыйдә белән Ильяс... бер-берсенә чат ябышкан, мөгаен артык та нык курыкканнан, бер-берсен мөмкин кадәр нык һәм кайнар рәвештә кысышып кочаклашканнар һәм шул хәлдә карга күмелеп диярлек яталар иде. Әйтерсең ки, рәхәткә чумганнар. Яшерүнең файдасы тимәс, дөресен әйтик, Ильяс салкын кар чиметүен тойган хәлдә Рәгыйдәнең аңны томалар дәрәҗәдәге кайнар сулышын, аннары... аннары иреннәр, әйе, шундый саф һәм кайнар

иреннәр татлылыгын сизә. Изге якынлыкны Ильясның бите, муены, колак яфрагы тоя. Чынлап. Рәгыйдә чынлап та аның колак яфрагын сабый тешләгәндәй, ярәшү билгесе сыман итеп, кабат-кабат, шаяра-кәлә тешләп кар эчендә ауный. Өнме, төшме, шунысы гына бик үк ачык билгеле түгел кебек. Мәгәр аңлашылмас нәрсә булмас. Аңлашылды. Әйе. Боларның ким дигәндә, ике-өч минут шул чәнечкеле салкын һәм әйтеп бетергесез назлы рәхәтлектән аерыласы килми ята икән. Манчаровский шуны үз күзе белән күреп һәм аңлап, сәхнәдәгечә ачы көлүе белән көлгәч кенә, айнырга дучар ителделәр. Ниһаять, салкын кар эченнән, дөресрәге, бер-берсенең рәхәт кочагыннан чыгып, торып басарга мәҗбүр булдылар.

Торып баскач та, Ильяс тиз үк Рәгыйдә өстендәге карны кагарга керешә. Тегесе исә, елмаюдан, көлүдән көчкә тыелып Ильяска чын якынлык хисләре сирпеп, һич тайпылмыйча, тыныч кына басып торды. Ильяс шикелле үк, мөгаен ул да язмышка, очраклы маҗарага, бигрәк тә хөрмәтле вә гыйззәтле үгезгә ихлас күңелдән рәхмәтләр әйткәндер. Тойгылар сүзгә әйләнә алмаса да, законлы төскә кермәсә, дә, моңа карап кына кичерешнең мәгънәсе һич үзгәрмәгән, кимемәгәндер. Бәлки әле арта гына төшкәндер. Рәгыйдә өчен әйтә алмаса да, Ильяс үзе шуны яхшы төшенде: ходай үзе насыйп иткән бу вакыйгага, ничәмә генә кабат юынса да, Рәгыйдә иреннәренең биттә, муенда, колак яфрагында калган эзләре җуелмаячак, сүрелмәячәк. Бу кайнарлык, бу рәхәтлек, бу бәхет бөтен гомергә җитәчәк. Һәм иң мөһиме, бу хис ир белән хатын-кызга хас талпыну гына түгел. Бу бөтенләй икенче төрле якынлык, изге һәм саф, һичнинди түбәнлеккә чакырмый торган илаһи якынлык...

Бу хиснең исемен хәзергә Ильяс атап әйтә алмый әле. Мөгаен, ул тора-бара гына ачыкланыр. Ләкин моңа карап, хис тирәнлеге һич кимемәс.

Шул уй белән Рәгыйдә өстендәге карны кагып бетергәч, Ильяс үз өстендәге карны каккаларга керешә. Йа хода! Бәхет һәм рәхәтлек кар эчендә бергә яту белән генә, Рәгыйдә өстен кагу белән генә бетмәгән икән әле! Дәвам итә икән! Инде килеп, Рәгыйдә Ильяс өстендәге карны да кагыша! Монысын ук өмет итә ала идеме әллә Ильяс! Ильяс! Нинди бәхетле йолдыз яралганда тудың икән син? Бу көннән, шушы мизгелләрдән башлап, инде дөньядан китсәң дә һич үкенечле булмас иде. Йа хода! Бар икән шушындый бәхет тә. Әгәр үгез дуламаса, әгәр чана салуламаса, әгәр йөк аумаса, әгәр мәтәлеп кар куенына чуммасалар, ниһаять, әгәр дә мәгәр Ильяс өеннән чыгарга куркып, боегып ятса, шушындый могҗиза барын белер идемени?! Белми яшәр һәм белмәгән килеш дөньядан китеп барыр иде. Рәхмәт ходайга (бар бит ул ходай!), рәхмәт язмышка, рәхмәт Рәгыйдәгә. Рәхмәтнең дә иң зурысы — хөрмәтле үгез дуска! Яшә үгез дус, мең яшә!

Җитмәсә, аттан хәтәррәк дулап күрсәткән үгез үзенең тәүфыйклы була алуын күргәзеп тора икән әле. Йөк аугач та шып тукталган, малкай. Кыймшанмый да басып торган көне. Рәхмәт! Инде моннан ары ярты адым атламасаң да хәтер калмас. Чананы Ильяс үзе тартып булса да калган ярты чакрымны узачак һәм йөкне тиешле урынга илтеп җиткерәчәк.

Манчаровскийның, трагик буларак, бөтен кырны, ак чиксезлекне калтыратып көлүеннән, Рәгыйдәнең февраль кояшы сипкән аллы-зәңгәрле нурларга өстәлгән ягымлы, якты карашыннан һәм гөнаһсыз сүзләреннән соң, Ильяс чананы берүзе күтәреп турылады. Үгезне аркасыннан, муеныннан сөеп иркәләде. Рәгыйдәгә булган хисләр ихласлыгы белән сөйде. Мөгаен, яхшылыкка яхшылык белән җавап бирәсе килгәндер, ни булса шул, үгез матур гына кузгалып, күңелле генә барып җитте күрше авылга. Чын дусларча саубуллашканнан

соң, Ильяс үз авылына, Черекк үлгә таба юл тотты. Үгез исә, һич көйсезләнмичә, тыныч кына атлап, хәтта кай урыннарда юыртып, Ильясны интектермичә генә алып кайтып җиткерде. Инде Ильяс та үзен ниндидер максатка ирешкән кеше сыман тоеп, күңелендә илаһи бер тынычлык хис итә иде.

Ләкин тынычлык озакка бармады.

Бер-ике көннән соң ук әлеге сәер мизгелне сагыну хисе барлыкка килеп, төннәрне йокысызга диярлек әйләндерде. Мәгънәсе аңлашылмаган яңа хис аны түзә алмаслык дәрәҗәдә ашкындыра, каядыр чакыра, һәм, әйтерсең, Рәгыйдә тавышы белән эндәшә иде.

## Алтынчы бүлек

Зур рәхәтлекләр күрермен дип чыкмаса да (бу заманда рәхәткә исәп тотмаслык кына зиһен бар лабаса), юл Ильяс уйлаганнан да хәерсезрәк булып чыкты. Билгеле инде, хәерчегә — җил каршы. Әче февраль җиле белән көрәшеп кара син. Муеныңа, битеңә, үзле карын сылап, күз ачырмас. Күз ачкысыз буран каршылар дип башына китергән идеме ул? Койрыгыңны кысып, җылы өеңдә ятмасаң, шул кирәк сиңа. Мондый көндә рәтле эт тә оясыннан чыкмаска тырыша, әгәр котырмаган булса. Котырса, бүтән чут. Гадәттә, эт буранда котыра. Ильясның хәле шундыйрактыр, күрәсең. Югыйсә, нинди иркен кола-яланда, чиксез бушлыкта аннан башка берәр җан иясе күренер иде лә!

Күзләрен һәм муенын әле бер кулы, әле икенчесе белән, алай да түзмәслек булса, ике куллап бураннан ышыклый-ышыклый, күпме барылды икән? Сыланган карны сөртә-сөртә, күз кабаклары ачыта башлады. Аннан бигрәк — муен. Каһәр суккан җил бүрек белән яка арасында киндер җеп юанлыгы чаклы гына калган ачык җирдән өрепме өрә. Өрә генәме, кисә, пәкесез телә. Пәкесез телгәләгән төшне чәнечкеле кар белән ышкый — тоздан зәһәррәк әрнетә. Түземең төкәнсә, күз-битеңне, муен-җилкәңне ышкый-ышкый сикергәләргә, бөтерелергә кереш. Җилгә Ильяс аркасы белән борылып атлый, хәле бетсә, тукталып тора. Әз генә хәл кергән төсле тоелгач, тагын атлый, тагын борыла һәм күз-битен куш куллары белән каплап үрсәләнә. Үрсәләнә-үрсәләнә, тагын атлый... Әйтерсең, мәҗбүри рәвештә барып җитәргә тиешле ниндидер катгый боерык алган ул. Әйтерсең аны боерыклардан да өстенрәк, барып җитмәсәң гомерең белән хушлашасың дигәндәй янау мәҗбүр итә. Бик тә интеккәч, бик тә үрсәләнгәч, бик тә әрнегәч, һич югы кире борыл да җил аркан кайт та кит азмы-күпме җылы сакланган өеңә. Ләкин юк, анысын Ильяс дивана башына да китерә алмый, атлавын белә.

Ярый әле солдат итекләре исән иде. Куныч ларына кар тулып лычма су булса да, катылыгын җуймый, таралып төшми. Юл катысын сиздерерлек дәрәҗәдә кала. Ә юлны юл дип атау анысы бәхәсле нәрсә. Кичәге юл ярты аршынлы кар астында калган. Ярты аршынлы карга бата-бата атлаганда, әгәр аякта чабата булса, мамыкка баскан кебек кенә тоелыр иде. Юлмы, юлсыз кырмы, белә алмас идең. Шулай да кирза итекләр юл катысыннан аерылмаска ярдәм итә. Каядыр барып борыныҥ белән карга капланганчы атла.

Атлавын белә анысы Ильяс, белми дисәң, гөнаһлы буласың. Ләкин шушы рәвешле көч исраф иткәннән соң күпме генә ара үтелде икән?

Базы елгасы аша турыдан олы юлга чыгып, сигез чакрым дип исәпләнгән Ишкар авылына җитте. Ишкарны узгач, җил юнәлеше чак кына үзгәреп, чапрышка әйләнде. Ляшты дигән авылга җител-

де. Ниһаять, Әсәнгә җитәрәк, аяклары җирне тоймый башлагач, эченә шом керде. Ял итмичә атлый бирсә, бу авылдан ерак китә алмаячак. Аяк кына түгел, бөтен гәүдә сөм тоймаска әйләнсә, үзе дә шундый хәлгә керәчәк. Әле кайбер нәрсәләрне аек чамаларлык чакта, азрак ял итү хәерле булмагае.

Шундый уй белән Ильяс Күәш елгасының калтырап торган күперенә менмичә, боз сукмагыннан узды да, авыл башындагы иң беренче өйгә керергә булды.

Капкага таба яңа гына салынган бернечә эз күзгә чалынды. Димәк, хуҗалары исән.

Исән кешеләр калдырган эзләргә басып, ачык капка янына килде. Өйдән хәлле генә тавышлар ишетелә. Исән генә түгел, яхшы ук көр күңеллеләр икән әле, дип уйлады Ильяс һәм, җылынып, кибенеп чыгарга гына рөхсәт итәрләр, дигән өмет белән кутәрмә тирәсенә килде. Өскәрәк менеп, өсләрен каккалады. Аннары биштәрен салып кутәрмәгә куйды. Утырып, итекләрен салып какты. Ким дигәндә яртышар кило бозлы кар коелгандыр. Бүреген, шинелен салып селкеде.

Шушы эшләрне башкарганда, өйдән кем дә булса чыгып сүз кушар да өйгә чакырыр бәлки ди өметләнгән иде. Ләкин өмет акланмады. Өмет акланмау кәефкә җайсызрак тәэсир иткәч, Ильяс берара хәрәкәтсез торды. Өйдәге тавышларга игътибар беләнрәк колак салса, ул тавышлар бик ук гадәти түгел икән. Тавышлар артыграк кискен һәм төрлесе төрле югарылыкта. Асылда хатын-кыз тавышлары өстенлек итә: яный, куркыта, ялына. Сирәк ишетелгән ирләр авазы исә тынычландырырга, акыл бирергә тырыша. Яшь тавыш — малайлар тавышы — кемнәрнедер өйдән куа. Әйе, ныклап тыңлагач, сүзләрен ишетеп тә була икән. Кычкырыпмы кычкыра малай:

— Чыгып китегез, кемгә әйтәләр, берегез дә калмагыз, эзегез булмасын!

Менә нинди эзләргә басып кергән икән Ильяс. Дөньяда калмаска тиешле эзләргә. Ниндидер җитди сәбәбе бардыр инде — бер дә юкка яшь җан шушы хәтле ачыргаланмас.

Капчыгын бавыннан тоткан хәлдә, өйалды ишеген каккан булды Ильяс. Ишетмәделәр. Өйалдына рөхсәтсез узды. Өй ишеген каккач, өйдәгеләр беразга сүзсез калсалар да, ишек артында кем барлыгына игътибар сизелмәде. Өйгә дә рөхсәтсез керергә туры килде.

Утыр диюче дә, ни йомыш дип сорарга теләк сиздерүче дә юк иде. Һәр кеше үз эчендәге утны иреннәре белән кысып, күзләр белән генә чәчкәләп, берара тын торды.

Алъяпкычлы, кайчандыр зәңгәрсу төстә булган, хәзер исә шактый таушалган күлмәктән һәм, яулыгын күкрәгенә кыскан апа, Ильяс керүгә «Аһ!» дип, чак кына аңа таба омтылып куйды да артка чигенде. Мич алдына килеп, ызбутка таянды. Икенче якта, тәрәзә янындагы эскәмиядә яшь кенә хатын-кыз тезләренә портфель куйган, алдындагы кәгазьләрне һәм көрән төсле карандашын селкеткәләп утыра иде. Икенчесе, аның яныннан торып, ишек төбенә барып басты. Ир кеше исә түрдәге сәкедә утыра бирде. Ә малай? Малай әнисе артына ышыклангандай, казан янында ук тора икән.

Ишектән чак кына сулгарак, почмаккарак тайпылган Ильяска сәке уртасында берүзе утырган ир кеше сүз кушты:

— Сезне кем дип белик?— Ильяс аптырабрак калганны сизгәч, өстәмә сорау белән ярдәмгә киләсе итте.— Сугыштан кайтып килешме?

— Юк, яңадан китеп барыш,— дип, нишләптер үчеклисе килебрәк, үзе дә уйламастан ялган сүз ычкындырды Ильяс.

Бер секундтан соң ук үкенсә дә, сүз ычкынган иде инде.

Шул сүз белән ул үзе кергәнче башланган тарткалашуларга яңа

көч өстәгән булып чыкты. Ишек төбендәге хатын-кыз шул сүзне эләктереп алды да аның мәгънәсен меңгә төрләндерергә, үстерергә, баетырга кереште.

— Әнә, күрәсезме, кызылармеецны? Кулын карагыз, төзәлеп тә бетмәгән, ә яңадан китеп бара — сугышка! Сезне яклап! Сез исән булсын дип! Коллыкка эләкмәсен дип. Ә сез нишлисез? Ничек ярдәм итәсез фронтка? Ярдәм! Анысын уйлау кая! Үз бурычыгызны түләмисез, изге бурычтан баш тартасыз.

Яшь хатын-кыз шулкадәр рухланып әйтте, Ильяс хәтта кабат сугышка китеп баруына үзе үк ышана язды. Шул хакта кайнарланып белдерү ясарга авыз да ачкан иде. Мәгәр шау-шуның мәгънәсен төшенеп җитмәгәнлектән, хатын-кызның илһамлы телмәрен тагын тыңларга тиеш булды.

— Йә, квитанция яза башлыйбызмы, түлисезме?— дип, хатын каршысындагы портфельле кызга ым какты.— Язсынмы? Тулысынча булмаса, яртысын. Былтыргы недоимканың яртысын. Йә?

Хуҗабикә кулын ызбуттан алып селкеде:

— Их, кызым, кызыкаем. Шуны да аңламагач соң. Каян алыйм ди мин ул акчаны? Кем биргән аны миңа? Кем безгә нәрсә бирә? Кайда ул керем дигәнегез? Гел чыгым гына лабаса! Инде урлашырга кушасызмы? Урларга да юк бит ул акча. Кемнән урлыйм? Әйтегез, чыгам да урлыйм.

— Остарып беткәнсез бурлыкка. Менә ничек? Кеше таламакчы.

— Үзегез котыртмакчы бит. Котыручы гына юк.

— Ә сез котырмагыз, башыгызны эшләтеп карагыз, уйлап карагыз. Сезгә бөтен кешеләр белән беррәттән, ихтирам итеп, кешегә санап, бөтен ил күләмендә салына торган изге налогны салганнар. Бүтәннәр түләгән, ә сез...

— Ярты авыл түләмәгән, каян алсын...

— Ярты авыл өчен җавап биреп маташмагыз, үзегез өчен җавап бирә алмаган көе. Әйтегез, күпмегә языйк квитанцияне?

Хуҗабикә ык-мык итте, ачуын, үртәлүен тыя алмыйча аһылдап куйды да, амин тоткандай битен сыпырып, өнсез калды.

Усал хатын шуннан соң күпме генә илһамланып нотыклар сөйләсә дә, апаның инде телен яздыра алмады. Ахырда исә, өметен тәмам җуйгач һәм талчыккач, түрдә утыручы иргә карады:

— Булмады. Яхшылыкны аңлый торган хатын түгел икән. Инде яманлашырга туры килә. Чутлый башлыйбыз. Шулай бит, иптәш председатель?

— Нишлисең, карагыз.

— Бергәләп карыйбыз, иптәш председатель. Мин налог инспекторы гына, авыл Советы власте — сез. Сезнең җитәкчелектә менә бу апалар илне дошман кулына тапшырмакчы булалар.

Инспектор, әлбәттә, ялгышты. Соңгы сүзләре әнисе артындарак торган малайны алга чыгарга мәҗбүр итте. Малай җилпенеп инспекторның алдына ук килеп басты:

— Син, син үзең дошман! Халык кыраннатып йөрисең. Кулыма корал эләккәч тә мин сине атарга кайтам!

Инспектор мондый кыюлыкны көтмәгәнлектән, баскан җиреннән, егылып китәрдәй булып, чайкалып куйды. Егылмавына ышангач, чак кына көлемсерәгәндәй итте. Тиз арада үзен кулга алып, бөтен булган зәһәрен җыеп, оча-куна таларга кереште:

— Шулаймыни әле? Совет властен ныгытырга тырышкан, фронтка ярдәм итәргә тырышкан кешеләр сезнең дошманмыни? Алайса, син кем булырга җыенасың соң? Солдат булыргамы, бандит булыргамы? Ә? Кем булып чыгасың син? Ә?

— Мин призывник, кулымда менә повестка. Ә син — дошман! Халык дошманы!

— Әйтәм бит, иртәгә сугышка китәргә тора балакаем. Аны юлга әзерлисе бар. Ә сез... сез...— Сүзләренең азагына чыга алмаган апа яулыгы белән авыз-борынын каплап, елап җибәрде.— Солдаткаларга аз-маз ылгут бар ичмасам. Аларга упыска кермиләр. Минем нинди гаебем бар ирем сугышка киткәнче чирләп үлгән өчен? Аның урынына малаем китә. Шулай булгач, солдаткадан кай төшем ким минем?

— Малаең киткәнче салынган налог. Китсен, справка җибәрсен, аннан сезгә дә булыр льгота. Ә искеләрен барыбер түләргә туры киләчәк. Аларыннан котылу юк. Анысы әҗәл белән бер. Белеп тор шуны, чүпрәк баш.

Әнисен хурлау малайны тагын ярсыта төште:

— Син ул чүпрәк баш. Кансыз! Сугыштан исән кайтсаммы! Исән генә кайтыйм, җаныгызны суырам. Беренче булып сине юк итәм, халык дошманын. Сине!

— Куркытма, энем, сугыштан кайткач та син син булып калырсың, без без булып калырбыз. Йә, апа, соңгы кабат сорыйм: язабызмы квитанция?

Апа, әлбәттә, сүз әйтә алмады. Аннан акча өмет иткән беркатлы инспектор уйланыбрак торды-торды да, янә председательгә эндәште:

— Булмады. Башладык.— Шуннан соң зәһәр чәчкән күзләре белән өйнең дүрт стенасын капшап узды.— Бу самовар күпме тора?— Җавап бирүче юк.— Йөз тәңкәдән ким түгел, яз, җәлләмә. Шулай, йөз тәңкә.— Чөйдә эленеп торган тунны алып селкеде.— Менә дигән тун, рәхәтләнеп киярлек.

— Улымныкы. Нәрсә киеп китәр аны талап чыксагыз?

— Анысы безнең кайгы түгел. Күпмедән язабыз.

Председатель йөзен җыерып читкә борылды. Ильяска шул гына җитмәгән диярсең. Ул үзенә чират җиткәнен, ниһаять, аңлады. Әгәр өйдәгеләрне яклап тавыш куптарсаң, власть вәкиле ничек карар, дип, нишләргә белмичә кыҗрап кына утырган Ильяс, ниһаять, сикереп торды. Иң башта портфельле кыз каршына килеп басты:

— Кәгазьләреңне җыеп сумкаңа сал.— Кыз уңга карады, сулга бакты. Инспектордан ярдәм көтте. Ләкин инспектордан алдарак боерыкны, онытыла язган солдатлыгын яңартып, чираттагы рольләренең берсенә кереп өлгергән Ильяс бирде.— А ну, приказываю, кәгазьләрне — сумкага!

Ходайның хикмәте, приказ тәки приказ булып чыкты, лабаса. Кыз бу юлы беркемнән киңәш көтмәстән, кәгазьләрен җыеп, сумкасына салды да чыкылдатып бикләп тә куйды. Ильяс каршында үрә катты. Ильясның ачуы кимеп, кызга матуррак сүз табарга тиеш булды.

— Әйбәт, шәп. Сиңа хәзер китеп торсаң да була.— Шуннан соң егет янына килеп, аның повесткасын укып карады.— Дөрес, чын. Ә сез, иптәш председатель, данлы Кызыл Армиягә батыр егетләрне шушылай озатасызмыни? Иптәш Сталин сезгә шулай куштымы?

Провокациянең монысы да үз бурычын арттырып үтәде. Инде өйнең иң түрендә җәелеп утырган председатель кинәт сикереп торды. Үрә катмаса да, сабагын укымый килгән баладай, баскан җирендә боргаланырга керешге.

— Иптәш Сталин дип... Шулай куштымы дип... Иптәш Сталин недоимканы түләмәскә закон чыгармаган бит. Нишләтик соң— Райфо требует, болар шул закон нигезендә таләп итә.

— Таләп итми сезнең бу кызларыгыз, талый.

Мич яны ышыгыннан апа да чыгып канат җилпергә җөрьәт итте:

— Көпә-көндез талыйлар, алладан да, Сталиннан да курык-

майлар, чисти имансызлар. Упыска кергәннәр. Малайны армиягә озатышасы урында.

— Дөрес апа, каты тор. Ә син, иптәш председатель, колхоз председателенә аңлат — бу егеткә юллык азык әзерләтсен. Уфага хәтле җитәрлек булсын. Булдымы?

— Соң... әйтербез, әйтербез.

— Ә нинди олау белән озатасыз? Кыңгыраулы олаулар бармы? Безне теге мәлдә шулай озатканнар иде, беренче китүдә.

— Соң... Үзең беләсең ләса. Кыңгырау чыңлата торган заманмы? Аннан...

— Нәрсә аннан?

— Бу егет... авылдан бер үзе генә.

— Алайса ярар, кыңгыраусыз түзәрбез. Ишетсен колагыгыз — исән атларның иң хәллесен җиксеннәр. Алдый алмассыз, иртәгә хәтле үзем көтәм ничек озатуыгызны карарга. Миңа барыбер военкоматка. Бергә барырбыз. Сораулар юкмы?

— Юкмы дип... сорау дип... Бар инде ул сорау. Сез кем буласыз соң?

— Менә мин иртәгә баргач военкомга кереп мондагы хәлләрне сөйләп бирермен. Булачак солдатны, булачак солдат анасын ничек җәберләвегезне төшендергән чакта, ул минем кем икәнне яшермичә сезгә дә әйтеп бирер. Ә хәзер — егетне озату хәстәрен күрегез. Сезгә китәргә мөмкин, иптәш председатель.

Бу вакытта баягы зәһәренең әсәре дә калмаган, сарык бәрәненең дә эле сөзәргә өйрәнмәгәне кебек юашланган райфо инспекторы, үзен елмаерга мәҗбүр итте:

— Ә безгә? Китәргә мөмкинме безгә?

— Сезгәме? Сезгә! Әйе, сезгә монда килмәскә мөмкин булган. Борынгы заманда недоимщикларның өennән соңгы әйберләрне талап чыгуларын дәреслекләрдән укый идегез бит? Талаучыларга нәфрәт белән тула иде йөрәкләрегез. Ә үзегез? Патша ялчыларыннан кай төшегез ким? Кай төшегез ким?

— Соң инде... без закон нигезендә... без чыгарган налог мәллә?

— Сез егетнең армиягә китәсен белдегез бит?

— Каян белик без аны?

— Нишләп белмичә йөрисез?

— Соң инде...

— Бер дә соң түгел. Әйе, яхшы чакта сыпырыгыз моннан.

— Безгә ни, иң җиңеле шул. Җавабын үзегез бирерсез.

Инспектор кызның тагын шулай тырнакларын күрсәтеп куюы армиягә китәсе малайга тагын ошап җитмәде булса кирәк, ул баягыча кайнарлык белән бармак селкеп, инспекторга янарга керешге:

— Минме, сезнеме! Армиядән исән кайтсам, җаныгызны суырам! Кеше талау түгел, сүз әйтәлмәслек итәм. Авызыгызны... авызыгызны с... ссу капкан сыман ача да алмассыз.

Инспектор үзе дә, тагын да катырак сүз ишетүдән шүрләп бугай, налог агентына ым какты, тиз генә шылу ягын карады. Председатель алар артыннан иярде.

Ильяс тәкъдиме белән хуҗа апа авыл советына хәзер үк барырга тиеш булды — председательне куып җиткү нияте белән ашыгыч киенеп, сәдәпләрен каптыра-каптыра алар артыннан китте. Шәл ядлыгын урам уртасына җиткәч кенә башына уралы.

Һич киметми һәм арттырмый әйтәбез ки, шуннан соң бу өйдә төп хуҗа булып Ильяс үзе калды. Егет белән юк-бар сөйләшәсөйләшә утын әзерләп мичкә яктылар. Мич алдына утырып, өшенгән тәннәрен җылыттылар. Шул арада күзгә күренерлек төенчек белән апа кайтып керде.

— Әй, рәхмәт төшкерләре, мичкә ягып та җибәргәнсез икән

Балама күмәч пешерергә үзем дә ягармын дигәнием. Бирделәр менә, амбарга барып алдым. Син булмасаң, сорарга да баш җитмәгән булырые. Аллага шөкер, тамак туйдырып китәрлек тә, юлда ашарлык та булды. Бирделәр тәки. Булгач ни бирәләр инде ул. Бер генә кешелек таптылар. Бөтен авылга каян җиткерсеннәр. Юк бит, юкны бирәлмәйләр инде ул. Рәхмәт инде сиңа, исемең ничек әле?

— Анысы пүчтәк, апа.

— Кем булсаң да рәхмәтле, игелекле бәндә икәнсең. Урының оҗмахта булыр, алла бирса. Юл кешесе, арыгансыңдыр, берсәк сөяләп тор.

Түргә, бүрәнә буена иске тун җәйгәч, мендәр салып килде апа:

— Бар, ял итеп ал. Черем итсәң дә була. Чәйгә уятырбыз.

Ильяс оекларын салгач, апа аларны җәһәт кенә мич өстендәге киштәгә элде:

— Үзең торуга коп-коры булыр, алла бирса. Ят.

Ильяска нәрсә: «Бар бит дөньяда инсафлы, тәрбияле кешеләр,— дип, сәкегә үрмәләргә генә калды.— Кайбер адәмнәр кадерле кунакка да болай ук хөрмәт күрсәтмәсләр иде».— Шундыйрак уйлар уйлап, йоклап та китте. Йокы аралаш малай белән ананың тыныч гәпләшүе, мәктәптән кайткан кыз балаларның ихлас чыркылдашуы, әниләренең исә: «Абый йоклый, шауламагыз»,— дип тыя торуын ишетеп яту үзе бер рәхәт һәм татлы иде.

Шундый әйбәт кәеф белән чәй эчтеләр. Төнлә дә йокысыз интегүче булмады шикелле. Әни кеше генә йокладымы, юкмы — монысы гына ачык сизелерлек булмады. Кышкы кояш чыгып көянтә биеклеге күтәрелгәч, капка төбенә атлы чана да килеп җитте.

Малаен озата чыкканда, аналарга хас булганча, балавыз сыгу, улының юатырга тырышуы — бөтенесе табигый иде. Егет чанага утыргач кына, Ильяс рәхмәтләр әйтеп саубуллашканда, апа, яшьле күзләрен сөртә-сөртә булса да, сәфәрчегә дә игътибар итәргә көч тапты:

— Үзеңә рәхмәт, игелекле бәндә,— диде. Һәм кичәге соравын кабатлады.— Сине кем дип белик соң? Сорасалар кем дип әйтик?

Ильяс дөньяда бер генә кеше булып яшәмәвен, сәхнәдә булмаса да, тормышта барыбер күп рольләр башкарып яшәвен белә, әлбәттә. Бу юлы нинди роль башкарды соң әле ул? Озак уйламастан, үзлегеннән диярлек җавап табылды тагы:

— Мин Хозыр Ильяс булам, апа,— дип, рәхәтләнеп бер көлде дә, чанага менеп, егет белән янәшә, артка карап утырды.

Икесен дә, сугышка китүчеләр сыйфатында, күрше-тирә җыйнаулашып, күзләр сөрткәләп, кул болгап калдылар.

* * *

Егеткә киңәшләрне юмарт биреп, куш куллап хушлашкач та, Ильяс, ашыгыч эше бар кеше сыман, театр бинасын эзли китте. Андый бина юк икән. Театрның район культура йортында урнашканлыгын әйттеләр. Ильяска барыбер иде — театр гына булсын, артистлар исән булсын. Барысын да сәламәт хәлдә күрергә ниятләнгән Ильяс культура йортын тиз тапты. Ләкин моңа карап аның күңеле күтәрелде дияргә ашыкмыйк. Киресенчә, әллә ничек, шом туды аның күңелендә. Тәбәнәк кенә, озын гына агач йорт. Биек койма аркасында ул үз дәрәҗәсеннән дә тәбәнәгрәк тесле күренә икән. Күпмедер ел ачып каралмаган агач капкалар. Койма ни дә, капка ни — бөтен буйга кар күмгән. Көрт ярып узган ике-өч эз булмаса, ташландык йорт дияр идең. Яшәп тә ята икән культура! Ана-

ларын сатмалы адәмнәр, эчләрендә җаннары бар микән?

Кәефе кырыла язган, ике-өч минут арасында килгәненә үкенә башлаган килеш, шулай да кемдер калдырган эзләргә басып, Ильяс аяклары да капкага таба атладылар. Ян капкадан узды. Җан иясе барлыгы сизелмәде.

Ихата зур гына икән. Койма буйларында озын-озын бүрәнә өемнәре калкып тора. Клубны... әйе, хәтере калмасын, культура йортын сипләп салырга уйлаганнардыр инде. Бүрәнәләр чери төшкәч, бәлки сала да башларлар.

Ихата яклап, тәбәнәк кенә күтәрмә, ишек. «Авыл клубында да ишек икәү була, сәхнә ягы ишеге аерым була. Боларның шунлык та рәтләре юк икән, юньсезләрнең».

Ильяска бер ишек житә житүен. Шуннан керә ул. Һәм керде дә. Сул якта касса авызы. Янында ишек. Тавыш ишетелгәнлектән, шул ишекне какты. Касса бүлмәсендә җыештыручы хатын балалары белән ашап ята икән. Әлеге дә баягы, сәкегә тезелешеп утырганнар. Авыл өйләрендәгедән аерма шул гына, бүлмәсенә бәрабәр — бәләкәй сәке. Хәл-әхвәл белешкәч тә, клуб директорының кайдалыгын сорады. Кергән чакта уң якта ишек күргән иде бит — шунда икән директор бүлмәсе. Бая чамалый алмаганына гаҗәпләнеп, ашыга төшеп, Ильяс шунда китте.

Бүлмәдә бер кыз чут төймәләрен шакылдатып утыра. Хисапчыдыр. Ильясны күргәч тә шакылдатуын озак дәвам итмәкче, имеш. Ильясның кемлеген белми шул әле. Зыян юк, белдерербез.

— Кызым, миңа директорның үзе кирәк иде.

— Директор теге якта.— Кызның башы сәхнә ишегенә ымлады.

— Анда узарга ярыймы соң?

— Белмим шул.

Бу әле рөхсәт билгесе түгел иде. Әмма дә ялындыра торган заманмыни. Сәхнәгә илткән күтәрмәгә менеп, ишекне кыю гына ачты да эчкә чумды. Караңгы. Пәрдә төшкән. Арткы чаршау янында тәрәзә яктылыгы сизелгәнгә күрә, шунда узган иде, бер-ике урындыктан башка нәрсә күзгә чалынмады. Сәхнәгә чыгып, анда бераз ял итеп торды һәм менә шушында чак кына эченә җан кергәндәй булды аның. Җылылык хәтта аркасы буйлап узды. Әйе, сәхнә ләбаса бу, чын сәхнә! Чынның да нindие әле — Рәгыйдә йолдызы калыккан сәхнә! Аның тавышлары шушында яңгыраган. Теләсәң әле дә ишетергә мөмкиндер...

— Әй, кем бар анда?

Менә сиңа — көт назлы, нәфис тавыш. Нindидер тупас, кара аваз. Ләкин чакырылмаган кунак бүтәнгә лаеклы микән? Ильяска бүгенгесе көндә шунысы да ярап торадыр. Һәм ул тавыш килгән якка, залга төшеп китте. Анда идәнгә зур гына чүпрәк җәелгән. Шуңа сурәт төшереп ята икән тупас тавыш иясе.

— Иптәш директор сез буласызмы?

— Мин. Ә сез кем?

Ильяс үзенең исемен белмәгәндәй, тагын икеләнеп калды.

— Мин ни... шул инде, үзең күреп торасың бит — яралы солдат.

— Бик тә кызганыч, яралы солдатлар сез генә түгел.

— Шулай шул. Авыр хәл. Иллә яшәргә кирәк.

— Акыллы сүз.

Әңгәмәнең чамалы икәнен сизенгән директор, пумаласын буяуга манып, киндергә тагын нindидер сызыклар диикме, төшерә башлады. Ике-өч минут Ильяс ул ясаган сурәтне һәм рәссамның үзен күзәтеп тыныч кына басып торды. Рәссам да аны күпсенмичә, барын-югын сизмичә шөгылен дәвам итте. Шактый вакыттан соң ул, стена буендагы урындыкларның берсенә утырып, сурәтенә карап тын калды. Ильяс ике-өч урындык ара калдырып утырды. Рәссам-

ның сөйләнергә артык ашыкмавы аркасында, сүзне үзе башларга тиеш булды.

— Әле керешли карап аптырадым. Капка төпләрегезне, ишек алларыгызны көрт баскан. Көрәүче юк икән.

— Аның өчен бездә штат каралмаган.

— Аның өчен ник кирәк штат. Көрәк кирәк аңа. Көрәк табып бир син.

Директор Ильяска беренче тапкыр игътибар белән карады:

— Көрәр идеңме?

— Нишләп көрәмәскә?

— Акча каралмаган.

— Һаман акча сезгә... Ә миңа рәхмәт җитә.

— Кызык адәм, ахрысы, син. Чынлап сөйләшә беләсеңме?

— Менә инде, минем формага кара, шинельгә.

— Ә-ә, солдат. Солдат алдаша белми... Әйдә соң, күрсәт сыйфатыңны. Көрәкне табабыз аны.

Шулай дип, директор, Ильясны чакырмый-нитми, ишеккә таба атлады. Шулай. Тышкы якка чыктылар. Директор, булдыра алганча тиз атлап, бәдрәф янындагы такта сарайга керде дә тимер көрәк алып чыкты. Килеп җиткәнен көтмичә, Ильяс аны туктатырга мәҗбүр:

— Агач көрәк юкмыни?

— Әй, агач көрәк!! Баш диген. Хәзер карыйм.

Икенче күренүендә кулында агач көрәк иде, анысын Ильяс рәхмәт әйтеп алды. Аны аңлап җиткермәгән егет, ни дияргә белмичә, баскан төшеннән кузгала алмыйча карап калса, солдат исә җан-фәрманга эшкә дә кереште.

Урамның тапталган җиреннән башлап, капка киңлеген алып көрәде. Карның өске өлеше йомшак булса да, аскы өлеше шатырдап тора иде. Кыш башыннан көрәк тимәгән. Мәгънәсезләр! Нинди җан белән түзәләр диген. Директорны әйт, сурәт ясап арган чагында чыгып кулына көрәк алса, иҗаты хутлырак китәр иде ләбаса! Интеллигент, янәсе. Дәрәҗә төшә. Адәм баласы әллә нишли, бозыла. Сугышка чаклы киресенчә, теләсә нинди эш мактаулы иде.

Тимер көрәкнең дә кирәге чыкты. Шакылдата-шакылдата боз ватты. Күтәрмә боздан арынгач һәм көрәкләрне үз урынына илткәч, хуҗалар ишетмәсме дип, биегән сыман сикергәләп, күтәрмә тактасын шакылдатып караса да, тиешле бәндәләр койрыкларын да селкетмәделәр. Ильяс шуннан соң залга керергә мәҗбүр булды. Әйтер хәле юк, бу юлы аны күрүгә пумаласын тиз ташлады да директор, аңа таба үзе килде.

— Йә, ничек?

— Чыгып карыйк. Әйдәгез.

«Карыйк» дигәне үз эшенә сокланасы килү хисе белән бәйләнгән иде. Картинасын ясап бетергәч, директор да үз эшенә кабат-кабат карап торадыр әле. Үзенә күрә һәр эш сурәт бит. Урамда, ихатада әле берничә сәгать элек кенә бөтенләй икенче төрле күренеш иде. Рәссам моны аңлардыр. Әйе, аңлады — рәхмәт. Үзе дә әйтә белде рәхмәтне.

— Шә-ә-әп! Кара, нинди уңган кеше икәнсең. Менә безгә синең кебек кеше шәп булыр иде. Каравылчыбыз ялкау — төнне йоклап үткәрә дә, яктыргач та өенә чаба. Шушыңа тәки җитми кулы.

«Үзегез эшләсәгез дә хәрәм булмас иде»,— дигән уен солдат тыярга тиеш тапты. Турыдан-туры үз йомышына күчте.

— Мин сәхнә эшчесе сыманрак шөгыль табылмасмы дип килгән идем дә... театрга. Алар мине белә.

— Шулаймыни? Син әллә... кем... кем диделәр әле? Әйе, син әллә теге Хозыр Ильясмы?

— Шулайдыр, иптәш Манчаровский кушаматыдыр.

— Хәзер аңлашылды. Кем икән бу сәер адәм дип баш вата идем әле. Аңладым, Хозыр абый, рәхмәт, ихлас күңелдән.

— Мин театрны эзләп килгән идем.

— Алар авылда бит.

— Мин... кайтабыз дип сөйләгәннәрие дә.

— Кайтырлар, озак тормаслар анысы. Ну бит, анда да штат юк, зарплатасыз ничек эшлисез?

— Соң... безгә ни колхозда да түләмәйләр. Ичмасам, яраткан эшеңне эшләү — үзе бәхет.

—Тагы бер кат төшендердең, абый. Шәп. Мин дә изгелеккә яхшылык белән җавап кайтарыйм. Квартир табып бирәм. Алар кайтканны шунда көтәрсең.

Ильяс бүреген рәтләбрәк киде дә, шинель төймәләрен каптыра башлады. Аннары юл капчыгының залда калганы искә төшеп, аны барып алды. Капчык буш диярлек инде. Бичәсе ике-өч көнлек дигән ризык биш-алты бөртек бәрәңге һәм ярты кыерчык алабутамы, нәрсәме икәнен белеп булмый торган ипи кыерчыгыннан гыйбарәт иде. Күңел ныклыгы өчен шул җитә. Ильяс капчыкны бавыннан эләктереп күтәргәч тә, директордан театрның тәгаен кайсы авылда икәнлеген сорады. Моннан унбиш чакрымлы Коралачык дигән авылда икән.

— Караңгы төшкәнче барып җитәргә кирәк. Мин чаптым алайса. Исән булып тор әле, энекәш.

* * *

Коралачыкка ул караңгы төшкәч кенә барып җитте. Юл капчыгы асып, клубка солдат шинеленнән килеп кергән кешегә бөтен зал борылып карады, ягъни үз авылларыныкы түгелме, янәсе. Аларны ымсындырмас өчен Ильяс, үзенә игътибар юнәлгәнне сизгәч, кире мәгънә белән баш чайкады һәм кул белән ишарәләп алгач, як-якка үрелгәләп, буш урын эзләде. Капчыгын һәм юеш бүреген шинель итәгенә — тезенә куйгач та сәхнәгә текәлде. Күңеле тынычланды. Әйтерсең, дөньяның барлык мәшәкатьләреннән, шушы фәкыйрь, кешелекне кимсеткеч тормыштан сәхнәгә карап котылырга, матуррак вакыйгаларга кушылырга мөмкин. Җитмәсә, әнә Бакый, тере әүлия, Ильясны күреп тә алды. Ильяс шул сөенечтән кул болгагач, тегесе яшертен генә елмаеп куйды. Бөтенесе рәтле булыр, алла бирса. Бүген әйбәт була алмады, иртәгә, әлбәттә, хәлләр яхшырачак. Шулай бит?

Спектакль беткәч, концерт башланыр алдыннан Ильяс сәхнәгә менде. Юлдыбай әүлия белән, Манчаровский һәм, билгеле инде, Рәгыйдә белән кул кысышканнан соң өлкән артист каршысына яңадан, гаепле кеше сыман, баш иеп килде.

— Менә минем килүемие, сәхнә эшчесе булып. Алырсыз микән?

Манчаровский битендәге буяуларны сөртә-сөртә җитди генә үзенең таныш дәлилләрен хәтергә төшерде — әлеге дә баягы акча мәсьәләсен. Ильяс моны мең ишеткән һәм мең тапкыр кабатлаган лабаса инде:

— Сездән миңа бер тиен дә кирәкми, тик миңа маэмай кебек сезнең артыгыздан ияреп йөрергә генә рөхсәт итегез. Ә сәхнәне мин карармын, нәкъ сез теләгәнчә булыр.

— Соң инде, Ильяс дус, без сезгә ике куллап риза,— дип, кунакны әүлия иптәш якларга тырышты.

Рәгыйдә шулай ук: «Әһе!»,— дип баш какты лабаса. Тагы ни кирәк?

Кирәкми. Мәсьәлә хәл ителде. Шул көннән соң Ильяс үзен чын театр кешесе дип хис итте. Дөньядан аңа бүтән нәрсә хаҗәт түгел — бүгеннән башлап, аның күңеле бәхетнең иң югары гөмбәзенә менеп кунаклады.

Гадәти эш башланды — сәхнәне корасың, сүтәсең, чанага төйисең, бушатасың, ташыйсың, тагын корасың, тагын сүтәсең, тагын, тагын... Һәм ары табан яши китәсең. Ә иң рәхәте, иң татлысы шул — сәхнә кырыендагы тәрәзә төбендә, яки шундагы буш урындыкка утырасың да, көннәр, атналар буе спектакль карап, рәтләрәк тормыш белән яши бирәсең. Аннан да мәгънәлерәге — һәр сүзе, хәрәкәте, күз керфекләренең һәр тибрәнеше, күзләренең һәр ачылып йомылганы, елмаюы, көлүе, җырлавы, моңаюы белән — Рәгыйдә үзе. Гомергә, мәңгегә шушы хәл дәвам итсә, гомергә, мәңгегә Ильястан да бәхетлерәк кеше булмаячак. Менә ул буран һәм көртләр аралап еллар буе, озын гомере буе шушы ләззәтле сәгатьләргә омтылып килде бит. Килде һәм иреште максатына. Тырышкан табар, ташка кадак кагар. Нәкъ үзе, билләһи!

Әмма мәңгелек бәхет буламыни? Дөресен әйтик, аның күңел кошы ашкынулы хисләр белән атна буе күкнең иң биек ноктасында кагынудан башлап, әкертен-әкертен түбәнәя, түбәнәя, түбәнәя торды. Иң әүвәл әүлия дигән Юлдыбаевның бик үк әүлия түгеллеге ачыла барып, күңелгә шом сала башлады.

Кайсы авылда иде әле? Түбән Манчарда булса кирәк. Юлдыбаев спектакльгә соңга калып килде. Манчаровский белән Рәгыйдә, сәхнә белән арткы бүлмә ягына, бүлмәнең бер почмагыннан икенче почмагына таба атлый-йөренә арыгач, өстәлгә аяк салындырып, аяк селкетеп утырудан да туйганнар иде инде. Юлдыбай нәрсәдер оныткан, имеш, шуны алырга дип, яңадан фатирына киткән иде. Ильяс ул-бу килеп чыкмадымы дип, эзли барса, Юлдыбайның өйдә эзе дә юк. Каядыр бүтән якка киткән, димәк. Өй борынча эзләргәмени аны шушы зур авылда? Эзләр идең, табар идең дә бәлки... Инде таң әтәче кычкырыр чак җитәр. Бер генә юл — югалган мал үзе кайтып керсә генә.

Ильяс килүгә язган мал чынлап та кайтып кергән һәм киенеп, бизәнеп утыра иде.

Ильяс хәвефле уйлар белән Рәгыйдәнең үртәлеп интегүен күрмәс өчен, үз урынына, сәхнә кырыена чыгып утырды. Көтте. Халык түземлеген җуеп берничә кабат инде кул чапкан иде. Аяклар белән дөберди башлагач, чыкмыйлармы дип, Ильяс сәхнә як ишектән күзләрен алмас булды. Тагын, тагын зарыгып көтте. Рәгыйдәдән бәлки һич тә ким интекмәгәндер, артыграк булмаса. Ниһаять! Күренде Манчаровский. Яшьләрчә җитезлек белән чаршау алдына чыкты. Һәр сүзе саен диярлек кул чабалар. Барлык артистлар исеменнән сәлам тапшыргач, һәр исемне атаганнан соң алкышлар ява торды. Бу борчулы кич шулай да үзенең икенче төрле мисалы белән, сүрелә язган күңелне шактый биеккә күтәрүе белән барыбер матур булып истә калды. Менә хәзер дә бүгенгедәй хәтердә. Ни дисезме? Манчаровскийда хикмәт. Менә ул әсәрдә хәрәкәт итүче каһарманнар белән бергә, башкаручыларны да атап чыккач... Йа хода, үз колакларына үзе ышана алмады Ильяс. Ләкин ышанасы килә һәм бик теләп ышанды да. Чөнки, ни дисәң дә, төш күрү түгел, өннең үзе лабаса! Әйе, барлык исемнәрне атап чыкканнан соң, башкалардан һич аермыйча, Манчаровский гаять матур яңгырашлы, куәтле тавышы белән, үзенең гаять мәгънәле һәм илаһи авызын тутырып:

— Сәхнә эшчесе — фронттан яраланып кайткан батыр сугышчы Ильяс Баһадиров! — дип, тантаналы рәвештә бөтен залга игълан итте.

Гадәттәгедән һич ким булмаганча шаулап-гөрләп кул чапты халык. Ильястан хәзер дә: «Үз гомереңдә иң бәхетле көнең кайсы көн?» — дип сорасалар, менә шушы көнне, театрның законлы бер әһеле икәнен тою һәм шул тойгыны яклап тамашачыларның кул чабып раслаган көнен атар иде.

Икенче бер күңелле нәрсә — Ильясның баягы борчылуларының да кысыр булып чыгуы. Сәхнәгә аяк басу белән Манчаровский да, Рәгыйдә дә кинәт үзгәрделәр дә куйдылар, гүяки аларны кинәт кенә пәри алмаштырды. Кая ул баягы үртәлү, көю, өзгәләнү. Манчаровский юк, бары тик куәтле мирза гына бар. Рәгыйдә югалды да, аның урынына тәкәббер һәм чибәр Хәмдия пәйда булды. Сәхнәдә бөтенләй башка кешеләр, башка тормыш. Ильяс анда булган һәр хәрәкәт, һәр сүз, һәр ымны күзәтә, күңеленә сеңдерә, йота бара.

Атналар, айлар буе диик. Чөнки Дүртөйлегә кайткач та яңа спектакль әзерләмичә, шушы ук әсәр белән Борай, Яңавыл, һәм Бөре районнарына чыгып китәргә карар иттеләр. Агыйделнең аргы ягына... Ят авылларның һәркайсын хәзер үз рәвешләрендә искә төшереп булмый инде. Барып чыкса да танымас иде. Ә менә аларда булган хәлләр гомернең соңгы мизгелләренәчә нәкъ булган көенчә, бер генә шәрехка да кимемичә күңелдә яши дә яши бирә. Онытылмый торган һәм онытылмаячак иң назлы авазларның берсе Манчаровскийның куәтле тавышы:

— Сәхнә эшчесе — Ильяс Баһадиров!

Авыл саен, һәр кич саен.

Ильяс үзе дә бурычлы булып калмаска тырышты, билгеле. Бер көнне ул Манчаровскийга күрше Әшмән авылыннан Әнис дигән малайның район газетасында басылган бер шигырен биргән иде. Кичәнең концерт өлешендә өлкән артист моңарчы кеше колагы ишетмәгән шул өр яңа шигырьне укып уңыш казанды.

Әнә Манчаровский сәхнәгә чыкты да, алдагы номерны игълан итәр алдыннан төрле хәрәкәтләр ясап, укырга кереште. Юк, икән әле, башта залдагы кешеләргә мөрәҗәгать иткән икән:

— Сезнең авылда Сания исемле, апамы, кызмы бардыр инде?

— Бар, бар,— диештеләр,— бөтенесе ике данә!

— Менә бу шигырь аларга махсус атап язылган. «Сания апа» дип атала. Тыңлыйбызмы?

— Тыңлыйбыз, тыңлыйбыз!

Көянтә-чиләк аскан апа кыяфәтен алып укый башлый артист:

Сания апа суга бара, Көянтәсе бизәкле.
Егетләргә күз дә салмый, Шунсы өзә үзәкне.

Берәүләр үз эргәсендәге Санияга төртеп тә өлгерә:

— Сине кайчан карап торган диген!— янәсе.

Шигырь дәвам итә:

Сания апа суга бара, Көянтәсе яшелле.
Егетләрне күрмәс өчен күзен аска яшерде.
Сания апа суга бара, Көянтәсе зәңгәрле.
Каян килгән тәкәбберлек Аңа шушы кадәрле.
Сания апа суга бара, Көянтәсе кәкере.
Егетләргә карый-карый... Узып китте бәкене!

Халык рәхәтләнеп көлде. Манчаровский алкышларга баш ияия киләсе номерны игълан итте. Бик тә көйле барды концерт — бер атна, ике, өч атна...

Юк, өченче атнада көйле үк була алмады. Бер көнне әүлия дигән Марат Юлдыбаев тагын сынатты.

Манчаровскийның сәхнә арты бүлмәсендә һәм сәхнәдә арлы-бирле йөренүе, Рәгыйдәнең өстәлгә утырып аяк селкетүе, бер төшеп, тагын менеп үрсәләнүе, Ильясның Маратны авыл бетереп эзләве һәм таба алмавы, тагын аптырашка калып аһ орулар... Беренче очракта Ильяс кайтып кергәндә Юлдыбай грим салып утырган булса, бу юлы соңга калып та күренә алмады. Югалды Юлдыбай. Ильяс ишектән керүгә аның янына җыелган булдылар.

— Ничек, киләме?— янәсе.— Таптыңмы?

— Эт белән генә эзлисе калды. Юк.

Сәер ухылдап, Манчаровский артка чигенде.' Тагын йөренеп алды да яңадан Рәгыйдә каршына килеп басты.

— Спектакльне отменять итәбез инде. Хәзер чыгам да әйтәм.

— Коточкыч!

— Рәгыйдәнең — бу вакытта инде Хәмдиянең — чыраенда әйтеп бетергесез әрнү, моң бар иде. Шулкадәр кызганды Ильяс Рәгыйдәне, мөмкин булса, баскан төшендә кинәт Юлдыбайга әверелер иде. Ничек? Ничек Юлдыбаевка әверелергә? Тукта әле, ни өчен Юлдыбаевка әверелүнең кирәге бар? Әгәр дә мәгәр Бакыйга дисәң әле...

— Иптәш Манчаровский, әгәр... әгәр мин әйтәм...

Манчаровский саламга чат ябышкан батып баручы адәм хисе белән Ильяска иелде:

— Йә, йә!

— Мин әйтәм, әллә үзем чыгып карыйммы... сәхнәгә диюем.

Манчаровский аңлый алмыйча интекте, колагына ышана алмыйча газапланды, ык итте, мык итте! Һәм шулай ук-мыктан ары уза алмыйча, тагын йөренеп килде. Рәгыйдә каршына барып, аннан киңәш көтте. Шулкадәр ярдәмгә мохтаҗ иде Манчаровский бу мизгелдә, аның өчен Ильяс җанын бирергә әзер иде. Һәм өлкән артист саламга ябышмыйча булдыра алмады:

— Ничек диден әле син? Кабатла әле.

— Мин ул рольнең бөтен сүзләрен беләм.

— Их, сүздә генә булса хикмәт!

— Сүз дип... уйнаганым да бар. Күпме инде сезне карап тордым.

Сәхнәне һәм сәхнә артын янә берничә мәртәбә әйләнгәч, Рәгыйдәдән тагын киңәш көтеп, тагын ишетмәгәч, башка артистлар да хәрәкәтсез катып калгач, Манчаровский түзмәде, үзалдына сөйләнгәндәй әйтте:

— Ул бит... ишетмисезмени, Бакыйны мин уйнап карыйм ди, спектакльне өзмик ди. Ишетмисезмени, ә? Колакларыгыз тонганмы? Уйнаганым бар ди, ләбаса, нишләп колак салмыйсыз?

Чигәләрен ышкыды, уйланды, уфтанды, хәл итте — башын югары чөеп, тантаналы рәвештә белдерү ясады:

— Спектакльне өзәргә хакыбыз юк. Игълан итәм,— диде дә, Ильясны җитәкләп, өстәл янына китереп чишендерә дә башлады.— Бар, Рәгыйдә, тамашачыны тынычландыра башла. Чыгып нәрсә дә булса сөйлә, бие, укы, җырла. Бездән сигнал булгач, катнашучыларны, башкаручыларны игълан итәрсең...

Рәгыйдә өстәленнән сикереп тә төште, шундый ук тизлек белән сәхнә ягына чыгып та сызды. Читлеккә эләккән песнәк пырылдап очтымыни.

Ни булганын абайлаганчы, Ильяс үзе, Манчаровский тырнакларына эләккән куян мисалында, ни кушса шуны үтәвен белде. Чалбар, күлмәк, түбәтәй киде, билен буды. Ләкин битен буярга керешкәннәр иде, тагын бер коточкыч бәла килеп чыкты. Эш менә нәрсәдә, Ильяска театрны эзли килгәндә, юлда салкын тиеп, уң як битендә бармак башы хәтле шеш чыккан иде. Атна чамасы интеккәннән соң кире Дүртөйләгә кайтып шуны кистергән

һәм врач шеш эченә марля тыгып калдырган иде. Имеш, шул калган үлекне үзенә җыя да икенче операция вакытында марляны алганда, чистарып кала. Больницага кабат барганчы, менә нинди мәҗбүрият килеп туды бит әле. Марляның очы биттә күренеп, тырпаеп тора. Мондый йөз белән җитди лирика берләшә алмый — геройлык күренеше, нәфислек тойгысы җилгә оча диган сүз. Ильяс йолкып карады шул тычкан койрыгы сыман тырпайган марля очын. Күзләреннән ут чәчрәде. Кычкырып җибәрә язды. Кычкырса: «Менә сиңа батыр солдат!» — дип мыскыллап көләчәкләр иде. Ләкин барыбер ниндидер чара күрергә кирәк. Нишләргә? Манчаровскийның зиһене үз урынына кайтты.

— Кайчы да юк ичмасам, — дип, шырпы кабызды. — Хәзер беразга түз.

Тычкан койрыгын ник тартасы иткәндер, тагын сикерә куйды Ильяс. Шушыннан соң бөтен түземлеген җыяр өчен гәүдәсен таштай катырып күзләрен йомды. Манчаровский янып торган шырпыны биткә терәп үк диярлек, марляны яндырырга кереште. Ильяс тешләрен кысты. Тартылуданмы, пешүдәнме — әйтеп аңлата алмаслык авырту яндырып үтте. Ләкин алда — роль, көтүче егеткә әйләнәсе!.. Хыялда яши үк башлаган шул шәүләне ычкындырмас өчен, ул җәзага түзәргә тиеш. Сәнгать җиңел бирелми, корбан сорый. Һәм ул түзде. Бугазга ук тыгылган ыңгырашу авазын кулы белән буып «Эмм!» — дигән ымлыктан башка тавышны чыгармауга иреште. Һәм менә бер вакыт койрык өзелеп чыкты. Әйе, чыгуын чыкты да, авырту да туктала язды. Ләкин көзгегә караган иде, кәефе тагын җимерелде. Марляның төбе калган. Анысын инде яндырып бетермәле түгел. Әлеге дә баягы, Манчаровский бәладән коткарды:

— Зыян юк, кайгырма. Без аны хәзер бик матур миңгә әйләндерәбез. Борын белән күз зуррак булса, отышлырак булыр иде дә... Бигрәк тә — герой өчен. Ну, ярый, болай да әйбәт.

Сөйләнә-сөйләнә ул, ниндидер буяулар алып, битне матурларга, бизәргә кереште. Алар шушы эш белән шөгыльләнгәндә, сәхнә ягыннан Рәгыйдә тавышын ишетерлек хәлгә килгәннәр иде инде. Ул инде җырга ук күчкән. Спектакльдән башланасы кичә концерттан башланды, ягъни. Үзе бер кызык, үзе бер яңалык! Тиздән сәхнәгә чыгарга тиешле ясалма артистның күңелен күтәрер өчен булса кирәк:

— Син сәхнә кешесе булырга тиеш булгансың, конешно, — дип мактап куйды Манчаровский.

Ә Рәгыйдә җырлый:

Алма сатучылар килгән,
Үлчәүләре бар микән?
Әҗәлгә дару бар диләр,
Мәхәббәткә бар микән.
    Ай, һилләү, һилләү, һилләү,
    Ай, һилләү, һилләй-ләү.

Дөрес, һилләүләрнең иң кирәк чагы. Җыры да, җырчысы да күптән күренмәгән тансык ризык төсле матур һәм татлы. Буш вакытны тутыру гына түгел, үзенең хаклы урынында яңгырый ул. Рәгыйдә моны аңлый, әлбәттә, һәм һич аптыраусыз халыкның күңелен иркәли:

Алма бөрле, алма бөрле,
Алма чәчәге төрле.
Башкаларга күз дә салмыйм,
Сине күргәннән бирле.
    Ай, һилләү, һилләү, һилләү,
    Ай, һилләү, һилләй-ләү.

Яшә, Рәгыйдә! Инде максатыңа ирештең, ягъни, коллектив кушкан бурычны шәп үтәдең. Җырны тәгәлләмичә тукталсаң да сүз әйтмәсләр хәзер. Инде чын артист сыйфатында профессиональ сәхнәгә беренче мәртәбә чыгасы бәндә үз миссиясен үти башларга әзер. Ул инде сәхнә артында басып тора. Нидер укына. Әлбәттә, әлбәттә, күңелендә еллар буе йөргән, хәзер берничә минуттан ук сүзгә һәм хәрәкәткә әйләнәсе йөрәк кичерешләрен кабатлый ул. Ә син, чибәр, бик теләгәч алай, тәгәллә җырны:

Алма турыйм, алма турыйм,
Алманың түгәрәген.
Хәзер ниләр уйлый икән
Мәхәббәт күбәләгем.
Ай, һилләү, һилләү, һилләү,
Ай, һилләү, һилләй-ләү.

Җыр тәгәлләнүгә Манчаровский сәхнәгә яшьләрчә атылып чыкты да кулын читтәнрәк Рәгыйдәгә таба сузып, залга аны тәкъдим итте:

— Рәгыйдә Нәзифуллина!

Рәгыйдә Нәзифуллина, кабат-кабат баш игәннән соң, сәхнә артына очты. Ләкин яңадан чыгып, халыкка күренергә тиеш булды, алкышлар тынмыйча аптыратты. Тагын берничә тапкыр күренгәннән соң гына арткы бүлмәгә узарга мөмкинлек туды. Аңа бераз ял итәргә, сулышын тигезләргә кирәк иде. Әйе, хәзер нишләсә дә ярый аңа. Җан тыныч хәзер — Манчаровский бик тә теләсә, кич буе сүзе бетмәячәк һәм тамашачыны ялкытмаячак. Игълан ителгән спектакльне өзү болай үзе матур күренеш булмаганга күрә генә борчылды бит ул бая. Хәзер исә, рәхәтләнеп йөзә әнә үз стихиясендә. Үзенең кем икәнлегеннән башлап, Дүртөйле колхоз-совхоз театрының биографиясе белән таныштырганнан соң, туп-туры «Ак калфак»ка күчте әнә. Ләкин... Ләкин дип әйтик, артык та нык гадәтләнгәнгә күрәдер, артык илһамланудандыр, бер кечкенә детальне бутабрак җибәрде шул:

— Бакый — театрыбызның талантлы артисты — Марат Юлдыбаев!— дип кычкырды.

Аңа җавап — көчле кул чабулар!

Шуннан соңгы алкышлар — башка артистлар хөрмәтенә яңгырады. Шулай булды. Бүтәнчә, күрәсең, була да алмагандыр. Әнә бит сәхнә эшчесенең дә фамилиясе ишетелми калмады:

—...— Ильяс Баһадиров!

Көчлеме, түгелме, аны да алкышладылар. Тагын ни кирәк сиңа? Артыгракны өмет итәргә базсаң, эш күрсәт. Менә сиңа ходаең бирде бит форсат? Бирде. Беренче юлга ярый — Марат Юлдыбаев булып чык сәхнәгә. Ояты аңа булыр. Юлдыбай бүгенгесе көндә ул оятка лаек. Уйлап карасаң, фамилия буталу файдагадыр әле. Ходай бар бит ул! Һәм... башланды!

Рәгыйдә Хәмдиягә, ә Ильяс... Ильяс? Әйдә, әҗәт рәвешендә булса да кыюрак булыйк, Ильяс Бакыйга әйләнде диик. Тыңлагыз әнә, карагыз, кай җире белән артист түгел? Мирза егетләре алдында баш бөгәргә туры килгәне өчен үзенә дә, ул егетләргә дә тышка бөтен көченә чыга алмаган нәфрәт белән, бары тик Рәгыйдә... юк ла, Хәмдия хакына гына түзеп, алар белән сөйләшә алган хәлдә, Марат Юлдыбаевтан отып алган хәрәкәтләрне, ым вә аһларны ихлас кабатлап, ул хәтта Хәмдияне нык кына гаҗәпләндерде дә бит әле. Рәгыйдә беренче мәлдә нишләптер саграк, гадәттәгедән тыйнаграк уйнаса, соңга таба Юлдыбайны да, сәхнә эшчесе булган Ильяс абыйсын да онытып, бары тик Бакый белән генә сөйләшә һәм аны кимсетә, һәм бераз гына

ярата башлады. Соңыннан исә, бөтенләй, бөтенләй бөек хискә бирелеп аның янына ихлас күңел белән килеп йөрәген ачты. Әмма соң иде инде. Бу вакытта Бакый юк, ул инде бу каһәрләнгән тормыштан, үзенә тиң булмаган яр сөю әчесеннән азат иде. Хәмдиянең дә күзләре тормышны беренче кабат үз төсләрендә күреп, кинәт үзгәрде — аның да яшәргә сәләте калмады — үзе баш тарткан мәхәббәте янына килеп, аның өчен җанын бирде.

Кешеләр кичәнең башланган өлешендәгедән дә көчлерәк итеп кул чаптылар. Сәхнә ябылгач, алкышлар тагын да катырак яңгырады. Пәрдәне кабат-кабат ачып ябарга туры килде.

Шунда гына Ильяс үзенең Марат Юлдыбаев дәрәҗәсенә зыян китермәгәнлеген абайлады. «Миңа артык дәгъва белдерә алмый, болай булгач»,— дип күңелен тынычландырырга тырышты. Ә Манчаровскийны күрсәң! Ул нинди дә булса сүз әйтүдән узган иде. Шатлыктан яшьләнгән күзләрен яшермичә туп-туры Ильяс янына килде дә, аны каты итеп кочаклады:

— Рәхмәт, коткардың! Тәки коткардың! Яшә!

Артыгракка өметләнгән Ильяс, Рәгыйдә дә килеп кочаклар, диебрәк көткән иде дә, алай ук булып чыкмады. Матур гына елмайган килеш, үз өстәле яныннан, ерактан гына ул:

— Котлыйм сезне, талантлы дебютант!— дип, аннары, ни өчендер читкә борылып, кием алмаштырырга кереште.

Сәхнәдә нинди сүзне ничек әйткәнен, кайчан кая таба атлаганын, сәхнәгә кайчан кереп кайчан чыкканын Ильяс аң белән түгел, нindидер инстинкт кебегрәк тойгы белән генә башкаруын шул минутларда гына аңлады, үз хәле аның башына шунда гына тәгаен төсендә килеп җитте. Анысын да озак уйларга туры килмәде. Сәхнә киемнәрен салып, үзенекеләрен кигәч тә аңа Манчаровский икенче почмактан бик ягымлы, үз иткән тавыш белән:

— Сәхнәне бүген сүтеп тормассың, иртәгә өлгерербез,— дип, үзенең яңа артистының иҗади эшен кабул иткәнлеген янә сиздерде.

Монысының да әһәмияте бар иде. Бүген артистлар алдында, бигрәк тә Рәгыйдә янында әйтелде бит бу бик тә матур сүзләр.

— Рәхмәт, иптәш Манчаровский, сезгә рәхмәт.

Көндәлек киемнәр киелеп, чемоданнар ябылгач, артык гәпләшмичә генә һәм урамда да җырлашмыйча, көз көне ерак илләргә китеп барган кошлар кебек тавышсыз-тынсыз гына тезелеп уздылар. Фатирларга гадәттәгедән сүренкерәк теләкләр белән саубуллашып таралыштылар.

Уңышка ирешкән бәхетле дебютант кына ул төннең күп дигәндә чиреген йоклый алгандыр. Калган өлешендә ул күптән түгел генә аңсыз диярлек уйнаган ролен зиһене аша үткәреп, акыл белән баетып, өр-яңадан башкарыпятты.

Ә иртәгәсен? Иртәгәсенниләр? Алары тагын гомер азагынача онытылмас өчен бөтен ваклыклары һәм нечкәлекләре белән истә калдылар.

Гадәттәге үз эшләрен эшләп, әйберләрне олауга төягәч, Ильяс дөньяга күтәрелеп караса, саубуллашырга колхоз рәисе килгән икән. Артистлар составы тулысы белән аның тирәсендә. Манчаровский белән озак кына сугыш һәм көнкүреш хәлләре хакында гәпләшкәннән соң, ямчы малай үз урынына менеп кунаклагач, беренче булып шул ике җитәкче кул кысышты. Аннары рәис кеше Рәгыйдәгә борылып, күңелендә булган иң матур тойгыларын аңа багышлады. Кулларын кабат-кабат сөйде, чәбәкләде. Шуннан соң күзләре белән эзләнеп сорады:

— Кайда соң әле безнең кәтүчебез?— Башкалар эндәшми-

чәрәк торганга күрә, ачыклыйсы итте.— Иптәш Юлдыбаевны әйтәм. Кайда әле ул?

Аракы парыннан арынып җитмәгән Юлдыбай, уянып киткәндәй булып, гадәттәгедән кыюсызрак аваз бирде:

— Мин монда, иптәш председатель. Рәхмәт сезгә.

— Юк, сезне әйтмим, Юлдыбаевның үзен әйтәм мин.

— Ну, мин бит инде Юлдыбаев.

— Яле, шаяртма иртә таңнан. Кызыксыз шаяртканны яратмыйм мин. Кайда соң әле Бакый, көтүчене әйтәм?

Аңлашылды хикмәт. Рәисебез Ильясны эзли икән. Башкалар, кинәт исләренә төшереп, читтә тыйнак кына басып торган сәхнә эшчесенә текәлделәр:

— Сиңа әйтә иптәш председатель.

Ильяс шуңа ышангач, ялындырмыйча рәис каршына килеп басты:

— Әллә әйтер сүзегез бармы, иптәш рәис?

— Нишләп әле гаепле кеше сымак читтә торасыз? Сезгә мәҗлеснең уртасына менеп утырсагыз да килешә. Рәхмәт, иптәш Юлдыбаев. Шул кадәр килештереп уйнадыгыз. Хәмдия белән икәүләп. Бөтен халыкның күзе сездә булды. Шул хәтле чын, табигый. Сүзләрегез, тавышларыгыз, сәхнәдә атлап йөрүләрегезгә хәтле матур. Бөтен халык сокланды. Үзәкләрне өздегез. Сезгә исәнлек бирсен. Исемегез дә матур, Марат, фамилиягез дә сирәк очрый торган — Юлдыбаев. Гел сәхнә өчен тугансыз икән. Юлларыгыз имин булсын, бәхеткә, уңышларга бай булсын, иптәш Юлдыбаев. Тагын бер кабат рәхмәт сезгә. Исән булыгыз.

Шул сүзләр белән рәис, ике куллап Ильясның кулын кысып, каты-каты итеп селкеде. Аннары сиздерер-сиздермәс кенә көлешеп, авызларын тиз генә яңадан йомган башка артистларга карады:

— Барыгызга да ихлас күңелдән рәхмәт. Корычтай сәламәтлек телибез сезгә. Тагын килегез.

Рәис ике кулын күтәргәч, артистлар чаналарга үрмәләде. Һәркайсының йөзендә тел белән әйтелмәгән шуклык билгеләре чагыла иде. Рәиснең яшертен ымлыкларга бик исе китмәде шикелле. Артист халкы шулай мәзәкчән инде ул дип уйлагандыр.

Киттеләр. Һәм рәис ишетмәслек ара узганнан соң! Менә башланды шау-гөр — шаярту, үртәшү, мыскыллау!

— Әй, Марат!

— Кем тия?

— Мин сиңа әйтмим, чын Маратка әйтәм, Юлдыбаевка.

— Чүрәкәй үрдәк? Тапкан такылдар кызык,— дип зәһәрләнде Марат Юлдыбаев.

— Бүген Бакыйны кайсы Юлдыбаев уйнар икән? Кечәге Юлдыбаймы, өченче көнгесеме?

— Өченче көнге Юлдыбай бетте, кичәгесе генә калды,— дип сүзгә кушылды икенчесе.

Бу сүзләр Ильясның йөрәгенә сары май булып ягылалар иде. Мәгәр шаярту озаккарак киткәч, ул Рәгыйдәгә игътибар итте. Аңа ничегрәк тәэсир итә икән бу хикмәт? Авылдан чыкканнан бирле ләм-мим сүз әйтмәвенә караганда, ошамый аңа мондый әвәрә. Һәм шуны шәйләгән Ильясның үз күңеленә дә бераз салкын йөгерде.

Ничә көн узгандыр, бер көнне кич, сәхнә арты бүлмәсендә җыйналгач, һәм спектакль башланырга берничә генә минут вакыт калгач, кичә башланыр алдыннан халыкның түземлеген ныгыту өчен сәхнә артыннан берничә көй уйнарга дип чыгышлый, Солтанов бер анекдот сөйләп ташларга җөрьәт итте.

—Җәмәгать!— дип башлады ул сүзен.— Сез беләсезме, ишеттегез микән. Мин ике Юлдыбаевның бәхәсләшүенә тап булдым бит әле.— Артистлар, шул исәптән Ильяс белән Марат үзләре дә колакларын шөмрәйткәч, дәвам итте.— Беренче Марат икенче Маратка зарлана: «Безнең тамашачы халкы бигрәк надан инде, профессионал артистны һәвәскәр артисттан аера алмый. Син профессионал артист түгелдер, һәвәскәр артисттыр дип, шыр чыккан наданлыгын күрсәтеп тора!»— дип үртәлә. Ә икенче Марат аңа җавабында болай ди: «Бер дә исең китмәсен аның өчен, халык уйлап тормый ул. Миңа да шулайрак: син һәвәскәр артист түгелдер, профессионал артисттыр, дип бәйләнәләр».— дип дустын тынычландыра.

Артистлар үзләре дә тамаша карарга бик ярата. Фәрит Солтановның мәзәге исә шундый игътибар казанды ки, бөтенесе бер тавыштан кычкырып көлеп җибәрделәр. Әүлиялыктан шактый ераклашып өлгергән Марат Юлдыбаевның хәтере калыр дип уйлап кына баксыннар икән лә. Бер карасаң, мәрхәмәтсез бит артист халкы. Әмма икенчеләй, тәртипсезлеккә бирелә торган хак җәза да шул иде бугай. Әнә бит файдасы да юк димәслек. Әйтелмәгәнгә исәпләнсен, Маратның соңгы көннәрдә авызына бер грамм көмешкә капканы юк. Шул нигездә, үзендә Фәритнең якасыннан эләктерергә дә хаклымын дип уйлаган, күрәсең. Урыныннан сикереп тә торды, Фәритнең якасыннан тотып җилтерәткәч, аның колак төбенә берне җопып та куйды.

— Анаңны сатыйм, уйлабрак сөйләрсең моннан ары. Башың эшли башлар... сволочь!

Сәхнәгә, изге сәхнәгә чыгар алдыннан шушындый да оятсыз сүгенү ишетермен дип, кем уйласын!

Бүлмә шым булды. Халык күңелен күрә торырга чыгасы Фәрит, кире чигенеп, баянны өстәлгә куйды һәм Юлдыбайга укталса да, яңадан нидер уйлап, нәрсә эшләргә, ни әйтергә белмичә, өстәлгә сөялде. Шундый ук хәрәкәтне Рәгыйдә, Ильяс, хәтта Манчаровский үзе ясап алды. Фәрит тукталгач, алар да тындылар. Ярый әле гауга димәстән, хәтта бәхәс тә купмады. Спектакль башланырга минутлар гына калган. Шул сәбәп кешеләрне, шул исәптән Фәритнең үзен дә акыллырак булырга мәҗбүр итте. Һәм биш-алты минуттан, авызга су кабып, һәркем үз эше белән шөгыльләнә башлады.

* * *

Билгеле ки, Ильясның Бакыйга һәм Рәгыйдә Хәмдиясенә мәхәббәте бермә-бер генә түгел, инде икеләтә, өчләтә арткан иде. Гомумән, бу мәхәббәт дөньядагы һичнинди үлчәүләргә сыймый торгандыр. Бакыйдан һәм Рәгыйдә Хәмдиясеннән аерылмас өчен ул теләсә нинди авыр җәзаларга түзәргә әзер иде. Әмма, син дигәнчә генә барса икән лә. Артык күп уйналган спектакльне алмаштырырга кирәклеге, «Ак калфак» урынына бүтән кием кияргә вакыт җиткәнлеге телгә кереп кабатлана торганлыктан, Ильясның кәефе кырыла, йөрәге сулкылдап куя. Мәҗбүри җайсызлыктан котылу мөмкин булмаганга күрә, ул бер көнне үзе өчен кадерле ядькарьгә әйләнгән кызыл тышлы көек китабын капчыктан чыгарырга тиеш булды. Китапны сыйпый-сыйпый гына Манчаровскийга сузды:

— Менә, ифрат шәп пьесалар, теләсә кайсын бүген үк тот та куй.

Манчаровский китапның кыяфәтенә бер гаҗәпләнсә, аны ак-

тарып карагач, телсез үк калды. Әле уңай яктан, әле кире яктан битләрен санагандай итте. Утлы кисәү тоткандай, кулыннан кулына күчереп торды. Шул рәвешле, шактый интеккәч кенә, кире Ильясның үзенә бирде.

Аннан соң, шулай ук сүзсез генә килеп, китапны Фәрит Солтанов капшап карады. Аннан соң — башкалар. Китап кире Ильясның үзенә кайткач кына бер кыю сүз әйтерлек кеше табылды,— Марат Юлдыбаев.

— Менә нәрсә, иптәш Баһадиров, бу китапны син тиз арада юк ит. Син аны безгә күрсәтмәдең, без күрмәдек. Мин, намуслы кеше буларак, шуны әйттем. Бетте сүзем.

Ильяс берәм-берәм барлык артистларны күздән кичерде. Һәркемнең чырае — көл төсле, күзләр кырыс, иреннәр телне ирекқә чыгармаслык дәрәҗәдә кысылган иде. Шул хәлне күргән Ильяс китапны артка яшергәндәй итте дә, Рәгыйдәгә текәлде. Рәгыйдә, шулай ук аптырап, томраеп карады. Димәк, бер генә чара калган: китапны яңадан — капчык төбенә. Тагын берничә елга.

Читкәрәк китеп почмакта яткан капчыгын күтәргән иде, Рәгыйдәнең кискен тавышын ишетте:

— Ильяс абый!

— Ә?

— Миңа бүләк ит син аны. Истәлеккә. Мин сакламын. Беркемгә күрсәтмәм. Синдә калса, йә чагарлар.

— Сине... чакмасларммы?

— Барыбер, миңа бир аны, Ильяс абый.

Ильяс мондый куркыныч ядкарьне Рәгыйдәгә бирә аламы инде? Юк, мең мәртәбә юк.

— Хәзергә үземдә калсын, Рәгыйдә. Соңыннан карарбыз.

— Әлсә, тотып карарга рөхсәт ит.— Шулай дип, Ильяс кулыннан китапны алды да, йөгереп тә китте.— Китап — минеке, Ильяс абыйга биреп кенә торган идем.

Хода бәндәсе, нишли бит — китапны кочаклаган да вальс көйли-көйли әйләнә. Башкалар аптырабрак торган арада Марат, сугышырга җыенгандай җилтерәп барды һәм, күз иярмәс тизлек белән эләктереп, җилкәсенә үк күтәрде дә, бар тавышка чарылдавына илтифат итмәстән, хатынын арткы бүлмәгә алып чыгып китте. Көчле куллардан ычкына алмаган Рәгыйдәнең һавада буталган аяклары гына күренеп калды.

Бераздан идәннәрне сыгылдыра-сыгылдыра атлап чыкты Юлдыбаев. Чыкты да китапны Ильяс битенә тондырды:

— Үзең сакла кисәвеңне. Зәхмәтеңне тиле хатынга йоктырма, амавыз.— Шул сүздән соң янә сәхнә артына борылып, йодрыгын уйната бирде.— Чүпрәк баш, кибәк баш! Ни көтәсең аннан, дивана тек дивана!— Тагын хатыны ягына чыгып китте.

Киңәшмә башлана алмыйча шулай тәгәлләнде, репертуар мәсьәләсе ачык килеш калды. Ләкин ул онытылырлык әйбер түгел иде. Чираттагы авыл клубы янында артистлар чаналардан төшүгә, Манчаровскийның ике олау да ишетелерлек арага басып үзенә дикъкать соравы, шул мәсьәләгә бәйле иде.

— Бер генә минутка, иптәшләр.— Һәм чана тирәсендәгеләр тукталып калганны күргәч, белдерүне әйтеп бетерде.— Бүген көндезге сәгать өчкә клубка җыелыйк әле.

Гадәттә, көннең ул вакытында репетицияләр үткәрелә. Әмма, спектакль күптәннән күрсәтелә килгәнлектән һәм шомарган булганлыктан, репетицияләр бу арада онытыла язган иде. Ник чакыра дип фаразлаулар, шикләнүләр булмасын өчен, ахрысы, Манчаровский сүзнең ни хакында барачагын тәгаен әйтергә тиеш тапты:

— Яңа әсәр укыйбыз. «Котырган эт» дигән пьеса.

— Ә котырган эт кайсыбыз?

— Фәрит, син, шаярмыйча түзәлмисең, ә?

— Беләсе килү гаепмени, Илһам абый?

— Гаеп түгел. Шуңа күрә дә әйтеп торам лабаса. «Котырган эт»— мин язган пьеса. Балаларны тәҗрибә хайваны итеп файдаланган фашист врачы турында. Бүгенге көндә актуаль тема. Сезнең белән әсәр хакында киңәшергә кирәк бит. Гаҗәпме шушы?

— Түгел, түгел.

— Җыелабыз?

— Җыелабыз.

Һәм җыелдылар.

Тынлык. Җитәкче сүз башларга тиеш. Ләкин ашыгырга нияте сизелми әле. Кулындагы дәфтәрне алмыйча, аны җилпәзә кебегрәк уйнатып торуына дикъкать итсәң, ниндидер четерекле нәрсә барлыгын чамаларга мөмкин иде. Дөресрәге, бу хәрәкәт һәм хәрәкәтсезлек кешеләрне борчулырак дулкынга әзерләү ысулы иде шикелле. Чынлап та, артистлар хәвефлерәк хәбәр көтеп, сагаеп калдылар. Тагын тынлык. Әмма монысы давыл алдыннан була торган тынлыкка тартым иде.

Дәфтәр якындагы урындыкка куелды. Фаразлар, димәк, аклана — сүз пьесага кагылмаячак.

— Әсәрне укыр алдыннан бер мәсьәләне хәл итеп алыйк әле, иптәшләр.

Урындыкларның, күчә төшеп, дөбердәп алуы — тәкъдимнең дәвамын көтү билгеседер. Мизгелне дөрес бәяләгән җитәкче сорауны турыдан-туры куярга мөмкин дип санады:

— Без үзебезнең коллективта тәртип бик тә шәп дип, бөтен нәрсә ал да гөл дип әйтәләбезме?

Башлар иелә, күзләр яшерелә. Гаеплерәк кешеләр чак кына кызара да инде. Дөрес сүзгә җавап юк.

— Бер артистның йодрыгы икенче артистка һич тартынусыз күтәрелә икән, бик тә югары культура галәмәтеме икән бу? Партия һәм хөкүмәтебезнең нинди авыр шартларда да безнең театрга эшләү мөмкинлеге, яшәү мөмкинлеге тудыруына лаеклы җавапны без шулай бирәбезме? Үзебезнең яшәвебезне шулай аклыйбызмы? Үзебез әдәпсез килеш, халыкта әдәп тәрбияләргә җыенабызмы? Үзебез кара булган хәлдә, аны агартырга азапланабызмы? Нинди нәтиҗәләргә, нинди уңышларга исәп тотабыз? Минем шуны беләсем килә. Киләчәктә нишләргә? Кай таба барабыз? Барабызмы, әллә тәгәрибезме? Я? Нишләп эндәшмисез? Мин сездән җавап көтәм, иптәшләр.

Кешеләр, өстәл тирәсеннән читкәрәк утырдылар. Өстәлнең бер ягында Рәгыйдә, икенчесендә Марат Юлдыбаев кына калды. Бу күренешкә караганда, җавапны шушы гаиләә бирергә тиеш буладыр кебек. Мәгәр Рәгыйдәнең ни гаебе бар монда?

Шуны белер өчен диярсең, Ильяс залга төшеп, Манчаровскийдан ике-өч урындык кырыйгарак утырды да, шуннан сәхнәдәгеләрне күзәтергә кереште. Җыелышны сәхнәдә үткәрәләр иде.

Рәгыйдә үз гәүдәсеннән үзе оялгандай, ике як битен учлап өстәлгә йомылган. Юлдыбаев баш күтәреп Манчаровскийга эндәште:

— Нәрсә, Илһам абый, сезнең комедиягезнең башымыни бу?

— Комедияме, фаҗигамы — ачыклыйк.— Юлдыбаев сүз әйтмәгәч, тагын сорарга туры килде Манчаровскийга.

Солтанов моның белән риза түгел:

—Бергәләп дип, Илһам абый. Бер пычрак сыер өчен бөтен көтүне гаеплиләр димени?

— Кем пычрак, синме?— Юлдыбаевның күзләреннән кара очкыннар чәчелде.— Ипләбрәк сөйләмәсәң...

— Күрдегезме? Менә шушы инде безнең Юлдыбаев. Беләсезме, ул кайчаннан башлап котырды?

Юлдыбаев йодрыгы сугылганнан өстәл ким дигәндә ике-өч сантиметр сикереп куйгандыр:

— Кем котырган? Синме?

Рәгыйдә, өстәл белән бергә күтәрелеп, аннары җәһәт кенә кызлар артына барып ышыкланасы иткән иде, урындык булмаганлыктан, Фәрит аңа үз урынын калдырды һәм Юлдыбайның нәкъ каршысына килеп утырды. Тырышыбрак үрелсәләр, куллары өстәл аркылы бер-берсенә җитәрлек иде. Шуны күреп, ахрысы, Манчаровский Фәритне дә тәртипкә өндәргә мәҗбүр булды:

— Иптәш Солтанов, үзең дә сүзне үлчәбрәк сөйлә.

— Соң... Дөресен әйтергә ярамаса, бетте. Су каптым.

— Дөресен син әйт, тик адәмчә, тыныч кына. Тыңлыйбыз, Солтанов. Әйдә. Йә...

Солтанов үзен тыныч тотарга тырышып чәчләрен, җилкәләрен сыпырып куйды. Һәм чынлап та, көйле генә сөйләргә керешге. Аны бүлдермәскә кушып, Манчаровский сәхнәнең ике ягындагы ике рәткә куллары белән ишарә ясады:

— Сабыр гына тыңлыйбыз. Булды. Әйдә, Солтанов.

— Солтанов дип... Мин генә түгел, бөтенебез белә бит. Нишләптер куркалар гына, әйтмиләр.

— Әйдә, син башла, тыңлыйбыз.

— Башла дип... Мин Маратны күптәннән беләм. Ходай аны холыксыз итеп яратса да, элегрәк ул мондый ук түгел иде. Кеше белән сөйләшерлек кенә рәте бар иде. Моңарчы без аның белән хәтта дуслар идек. Беренче көннәреннән үк хәтерлим. Училище бетереп килгәч тә, сез аңа беренче рольне, герой егет ролен бирдегез. Кыяфәте әйбәт, яшьлеге бар, үзегез әйткәндәй. Шулай бит? Тагын ни кирәк? Рәгыйдә белән уйный торгач, үзен нәкъ аның кебек талантлы дип исәпли башлады. Тамашачы мәхәббәтен Рәгыйдә белән тигез бүлеште. Шулай үзенең театрда беренче артист булуына ышанды. Үз көченә ышануның артык зыяны юктыр. Хәтерлисездер, без Уфага отчет белән баргач, бөтен спектакльләрне күрсәткәч, кала кешеләре Маратны иң талантлы артистлар рәтенә, сезнең белән, Рәгыйдә белән янәшә куеп мактадылар. Исегездәдер. Газеталарда да шулай язылды. Шул көннәрдә Юлдыбаев үзенең киләчәктә тагын да зуррак дәрәҗәгә ирешергә тиешлеген чамалап, культура-агарту идарәсе кешеләре белән якынлашып, хәмер ярдәме белән ярап, Уфага күчү турысында сүз куештылар. Начальникның: «Нәзифуллина белән син киткәч театрыгыз таралмасмы соң?»— дип соравына Юлдыбай, беләсезме, ничек җавап бирде?» Ул театр барыбер таркалачак, анда бит профессионал режиссер юк»,— дип, Илһам абыйны юкка чыгарды. Менә шуннан кайткач масайды Юлдыбай. Үзен монда башкала гастролеры дип хис итә. Аның урыны — өстә, биектә! Күреп торасыз, әле дә шул югарылыкта.

Солтанов өстәл янындагы урындыгы белән уң кырыйдагы рәткә күчте. Тагын тынлык, җайсыз тынлык.

Ильяс, сәхнә биеклегенә карап, Фәрит сүзләрен үз зәвыгы белән чагыштырып, Маратның бөтен килеш-килбәтен күздән кичерде. Кыяфәте, нишләптер, Ильяска ул хәтле шәп тоелмый икән Маратның. Гадәттәгечә әйткәндә, эре торыклы чырай — озынча бит, ярыйсы ук калын иреннәр, шул ук вакытта, зур ук булмаган күзләр. Ямьсез түгел, күпләргә ошый торган, ирләрчә дип исәпләнгән кыяфәт. Буй ягы да уртачадан гына калкурак. Менә шуны —

башкалардан бер башка озын булуын ул сәләт ягыннан да өстенлек билгесе дип уйлаган, күрәсең...

Тынычлык урнашудан файдаланып, Манчаровский тагын бер яңалык хәбәр итте:

— Сезгә мәгълүм булмаган кадәресе дә бар, иптәшләр. Идарә адресына, безнең театрны бетерүне сорап, рәсми гариза кергән. Аның авторы кем диярсез?

— Улмы әллә?— дип, сәхнәнең ике ягындагы ике рәт берьюлы өнгә килде.— Шул кадәр дә оятсыз булып чыгамыни?

— Бәяләрне соңрак бирербез. Бәлки бик мөһим дәлилләре бардыр. Иптәш Юлдыбаевның үзен тыңлап карыйк, минемчә.— Кешеләр дөрес дип җөпләгәч, Манчаровский Маратка борылды.— Әйдә, иптәш Юлдыбаев, сиңа чират җитте. Аңлат безгә. Нәрсәсе белән безнең театрның булуы сиңа комачау итә. Ни өчен аны тарату фарыз — республикадагы бердәнбер татар театрын? Миллион ярым халыкның шуңа нишләп юк хокукы? Партия һәм хөкүмәт авыр сугыш шартларында да халыкны тәрбияләүдә кирәкле эш башкара дип исәпләгән театрның? Ә? Бары тик шушы кирәклек аркасында гына югарыда безнең театрны бетермәү дөрес дип табылды. Бары тик шуның аркасында, Юлдыбаев тәкъдименә хут бирелмәде. Моннан ай чамасы элек кенә булган идем шәһәрдә, хәтерлисездер. Безнең язмышны кыл өстенә куйган кеше менә ул — сезнең каршыгызда.— Ике яктагы ике рәтнең нәфрәтле ымлыкларыннан соң, Манчаровский сүзен төгәлләде.— Аңлат, Юлдыбаев, безнең беләсебез килә.

Чигенер урыны беткән, инде почмакка кысрыкланган җәнлек сыман, Юлдыбаев, көтелмәгән сикерешкә әзерләнеп, бөрешә төште. Ике рәткә җәһәт күз йөгертеп алгач, торып басты да, башта акрынрак, соңыннан кыза барып, менә нинди монолог сөйләп ташлады ул. Аны тын да алмый тыңладылар.

— Үзем өчен генә түгел, сезнең өчен дә тырышам лабаса. Әйе. Мин, намуслы кеше буларак, шуны әйтергә тиешмен. Менә сез терелә́й тотып ашарга җыенган кеше, сезнең мәнфәгатьне кайгыртa, башыгыз җитсә. Гаҗәп, конешно, ләкин Солтанов дөрес сөйли. Безнең театрның профессиональ дәрәҗәсе һәвәскәрлек кимәленә төшеп җитте, дияргә була.— Юлдыбай сәхнәнең иң алдына — авансценага чыгып, гүяки халыкка мөрәҗәгать итте.— Дөрес түгелме әллә, сез бит, Илһам абый, артист кына, режиссерлык белемегез юк. Үзегез артист, үзегез директор, үзегез конферансье. Кыскартып әйткәндә, йорт казы — очасыз да, тәпиләп тә йөрисез. Әмма ләкин ерак көньякка, ерак максатка барып җитәрлек түгел бит. Миннән башка кеше моны сезгә әйтә алмас, эчтән генә уйлап йөрер.— Ике рәткә ике мәртәбә якын килеп, тагын уртага чыкты да күтәренке тавыш белән дәвам итте.— Мин, намуслы кеше буларак, шуны әйтергә тиешмен. Без халыкка чын сәнгатьчә әйтелгән фикерләр җиткерергә тиешбез. Без түбәнгә түгел, югарыга карап эш итәргә, Станиславский югарылыгына, Шекспир биеклегенә карап яшәргә, һич югы тырышырга, уйларга бурычлыбыз. Кара авылны дөнья яктылыгына чакырырга тиешбез. Үзебезнең мич арты кысанлыгыннан чыгарга, кәбәркә психологиясеннән котылырга тырышырга бурычлыбыз. Менә нинди ниятләр, менә нинди хыяллар белән яши бит сез хәзер үк терелә́й тотып ашарга җыенган коллегагыз.— Юлдыбай өстәл артындагы урындыкны алгы якка чыгарып, шунда утырды.— Ә чынлыкта нишлибез? Кабатларга мәҗбүрмен, без һәвәскәрлекнең дә түбән һәм зәвыксыз дәрәҗәсенә тәгәри барабыз. Мисаллар кирәк диярсез. Пожалуйста. Театр белеме димәстән, гади грамотасы да җиде класстан артмаган колхозчы, га-

ди бер көтүче безнең сәхнәдә төп рольне башкара ала.— Юлдыбай торып ике кулын күккә сузды.— Бу ни дигән сүз, кадерле иптәшләр? Бу марксизм классикларына каршы килү дигән сүз. Халыкны сәнгать биеклегенә күтәрергә тырышу урынына, аның үз кимәленә төшү дигән сүз. Гафу итегез, без моның белән ризалаша алмыйбыз, безнең чын сәнгать югарылыгына омтыласыбыз килә. Минем генә түгел, сезнең дә. Кем отылачак — әгәр дә сезнең барыгыз да академия театрына күчеп, анда яңа иҗади мөмкинлекләр ачылса? Ә?— Тагын рәтләргә мөрәҗәгать.— Беләм, сез патриотлар. Сезгә театрны яшәтергә кирәк. Гафу итегез, чын театр хәзер үк юк инде. Юкны саклый алмаячаксыз. Үзегез хәл итегез. Игътибар белән тыңлаган өчен рәхмәт.

Юлдыбаев сөйләп бетерүгә, Ильяс башта кайнарланып кул чапса, шундый ук дәрт белән идән дөбердәтте. Билгеле инде, бөтен кеше аңа сәерсенеп карап куйды. Шул исәптән — Манчаровский.

— Кул чабуның мәгънәсе дә бармы, Ильяс дус?

— Һы, нишләп булмасын, бар. Юлдыбай, ихлас уйнаса, чын артист та була ала икән. Үзегез күрдегез бит. Болай да шәп уйнаганы югые моңарчы.

— Кызык. Алайса, аяк дөбердәтү... анысы нигә?

— Ә-ә! Анысы сүзләренең мәгънәсенә. Ул, япа-ялгыз агач, бер үзе урман булмакчы. Халыктан качып, пәйгамбәр булмакчы.

— Шактый кызык кеше син, Ильяс дус. Юлдыбаев, ишеттеңме? Сиңа аннан күп нәрсәгә өйрәнергә кирәк әле.— Марат мыскыллы елмайды гына.— Гафу ит, Юлдыбай, син театрны бетерү урынына, әйе... атап әйтик, яңа режиссер табып, яңа көчләр белән ныгытырга тырышу юлын сайламадың. Бетерү җайлырак булганга күрәме?

— Яңа көчләр табу минем вазифага керми, шуның өчен анысын сезгә калдырам. Карагыз.

— Ансат, бик тә ансат. Йә, иптәшләр, нинди фикергә киләбез?

— Проблеманы хәл иттек — пәрдә төште, театр таралды. Хушыгыз!— Шул сүз белән Фәрит, урындыгыннан кубып, залга сикерде. Һәм Ильяс янына килеп утырды.

Аның үз янына килүеннән файдаланган Ильяс баягы фикерен тәгәлләргә җөрьәт итте:

— Мин Юлдыбайның бәхетсезлеге нәрсәдә икәнне төшендем. Бүтәннәргә ишетелмәслек әйттем дип уйласа да, аны ишеттеләр. Һәм гаҗәпләнүләрен яшермичә, карашларын аңа текәделәр.

— Соң? Ни өчен?

— Ул гади кешеләрне мыскыл итә. Үзен алардан өстен дип белә. Үз героена ниччасный көтүче дип карагач, уены ялган булып чыга. Ә менә бу юлы монологы шул кадәр чын булып ишетелде, ник дигәндә, ихлас сөйләде.

— Аңладыкмы, иптәшләр?— Манчаровскийның чырае көтмәгәндә яктырып китте.— Менә шулай ул, җәмәгать. Көтүче сүзләре!.. Ә? Уйлый төшик ләкин. Нинди нәтиҗәгә килербез, вакыт күрсәтер. Ә хәзер ял итегез. Рәхмәт сезгә. Кичкә хәтле исән булыгыз. «Котырган эт»не иртәгә укырбыз.

Пәрдә төште...

## Җиденче бүлек

Шул көннән соң «ике Юлдыбайның» берсе дә беркем теленә кереп карамады. Бу хакта шаяру һәм шаярту онытылды шикелле. Хәтердә шулай калган. Ильясның хәтере алдауны белми ул. Мәгәр

бу әле, каршылыкның бетүе түгел, бары тик эчкә яшеренүе генә иде. Чөнки ул көннәрдә артист Марат Юлдыбаев белән сәхнә эшчесе Ильяс Баһадиров арасыннан иләмсез олы кара мәче узды.

Әллә Ильяс уйнап күрсәткән Бакыйны иң чын, иң дөрес Бакыйга исәпләп, әллә тәртибе аркасында, иптәшләр арасында Юлдыбаевның абруе бермә-бер кимеде, төште, дисәк тә хаталанмыйбыздыр. Шуны Юлдыбай үзе дә сизеп бугай, кәефе һич күтәрелми, гел чырай сытып йөри башлады. Чырай сытылган саен, кәефе төшкән саен уены начарая, уены начарланган саен кәефе ныграк кырыла. Ике чик бергә тоташканлыктан, Марат, кыршау эчендә чабып каядыр барып җитәргә чамалаган, барып җитмәгәнен сизгән саен чабуын тизләткән һәм, җан-фәрманга чаба торгач, тәмам хәлдән тайган тиен кебек, бер көнне шулай ук чыгырыннан чыкмыйча булдыра алмады.

Чираттагы авылларның берсендә Ильяс, көндез клубта сәхнә корганнан соң квартирына кайтып бара иде, урамның нәкъ уртасыннан, дөресрәге, урамның бер ягыннан икенче ягына таба чайкала-чайкала, күзгә күренмәгән спираль сызыклар сыза-сыза, бу килә — Марат Юлдыбай!

Аек чагында да бәйләнергә җай эзләгән кеше, хәзер сәрхүш чагында җәнҗал чыгармас дип ничек ышанасың. Очраштыңмы, беттең инде. Якаңнан эләктерәчәк. Бер көнне бит аек хәлендә дә Фәриткә ничек ташланган иде. Урам тар димәсәң дә, кеше күренмәслек киң түгел. Кышкы урам бигрәк тә тар бит инде, ә тагын да бигрәк — кәҗә тәкәләре өчен. Бу исә нәкъ шундый очрак. Кәҗә тәкәсе ролендә калмыйм дисәң, кире борыл да чап. Монысы — куркаклык сыман. Ә курыкмасаң? Бөтен авылга дан китәчәк. Аннан соң күрен син Манчаровский күзенә, Рәгыйдәне әйтеп тә тормастан. Нишләмәк кирәк соң?

Бердәнбер җай шул — Ильяс капыл гына читкә каерылды да урамның иң читенә чыгып, бот төбенә чаклы, мин сиңа әйтим, үз теләге белән көрткә кереп батты. Шунда да әле атлаган була мескен. Тизлеге харап — ун адымга ким дигәндә ун минут узгандыр, чак кына ялганлый төшсәң. Бормалы-бормалы спираль ясап атлаган Марат тизлеге дә шул чамадан артмагандыр, әлбәттә. Җиргә текәлгән килеш, атлавын белә. Әйтерсең ки, Ильясны бөтенләй күрми ул. Гүяки, үз кайгысы үзенә бик җиткән. Иллә мәгәр ара якынаеп, икесе бер турыга җиткәч, нык кына чайкалып, арты белән ава яза-яза, юлның икенче читенә хәтле чигенде дә, мин сиңа әйтим, сөзешер өчен чигенгән тәкәдәй, мөгезләр бәрелешер алдыннан кисәтүен белдерергә тиеш тапты:

— Мин, намуслы кеше буларак, шуны әйтергә тиешмен. Алдан ук кисәтеп куям, мин сине сәхнәгә аяк бастырмыйм, эзең булмасын. Себер китәсең килмәсә, сыпырт үзеңнең сыер-сарыкларың янына. Өметләнмә, барыбер син түгел, мин калачакмын сәхнәдә. Бүген дә чыраеңны күрәсе булмыйм. Белеп тор, бүген дә, иртәгә дә син уйнамаячаксың, мин уйнаячакмын. Мин Бакый, ә син — колхозник несчастный. Мин Марат Юлдыбаев, син түгел, мин! Маташма минем фамилияне урларга. Белеп тор Юлдыбаевның кем икәнен, мин, мин, мин Юлдыбаев!

Артка әлегедән чак кына ныграк чайкалса, карга чумасы иде дә, ходай коткарды — тигезләгеч көч-хәл белән саклап кала алды мескен. Ике кулын йодрыкка төйнәгән хәлдә, җиргә бөтен нәфрәт катылыгы белән баса-баса, ары атлап китте. Узып китте, китте, ниһаять. Ильяс тиз генә такыр җиргә чыгып, нәрсә уйларга белмичә, фатирына таба атлады.

Гаҗәп, исерек кешегә карагач, кинәт күз аллары караңгыланып киткәндәй тоелды. Моңарчы, әйтерсең, Марат түгел, кире-

сенчә, Ильяс исерек булган. Нәкъ үзе, билләһи. Анда-монда сугылып-буталып йөргән. Аңгы-миңге шулай йөргән чакта, менә хәзер кинәт кенә, өстенә бозлы су коелгандай, айныды куйды бичара. Исерек кешенең сүзләре аның өчен шул өскә коелган бозлы су булды. Исерек, ләкин ходайның үзеннән иңгән хак сүзләр! Эчкән кеше — сабый. Сабый теле белән сөйли хакыйкать. Менә шул, Ильяс дус!

Сыерларың, сарыкларың янына сыпыр дидеме? Анысы да гаҗәп түгел. Абзары-курасы, ихатасы, авылы, үз гаиләсе, ниһаять, хәләл бичәсе, малае, чәчкәдәй ике кызы... Ниһаять, үз дөньясы! Барысы, барысы анда бит. Ходай яшәргә кушкан тормышы шунда. Ә монда нәрсә?

Дөрес әйтә Юлдыбай, монда ул — арбаның бишенче тәгәрмәче. Ильяснең монда кирәге — тишекле бер тиен. Монда аны кызганып, үксез баланы рәнҗетмәс өчен, ярдәм итәр өчен, шәфкать йөзеннән, ходай каршында савап өчен генә сыендырдылар. Менә ничек икән! Шуны, бик тә, бик тә гади мәсьәләне башы әйләндереп чыгара алмаган, хәл итә, чишә белмәгән. Менә ул нинди миңгерәү! Булдыксыз! Үз кешелеген үзе кимсетеп йөргән мәхлук. Менә кем ул Ильяс! Менә кем булган исерек. Һәм менә ул инде айныды. Аны, эчми исергән дивананы эчеп исергән дивана айнытты. Ак тәүбә, кара тәүбә — Ильяс дустың синең киңәшеңне тотар! Менә шул.

Кеше белән җан-фәрманга усаллашып кычкырышкан сыман калтыранып, кызарып, шундый карарга килде Ильяс. Аны гаиләсе көтә. Аның ходай биргән урыны шунда.

Иртәгә, иртәгә булмаса — берсекөнгә!

Кешеләргә күренмәс өчен урманга таба илткән тыкрык буйлап китте. Өйләрне узып бераз гына баргач, туктады, алда — зыярат. Тәне эсселе-суыклы булып китте. Фикер булып укмашмаган тойгысы шундыйрак иде: аңа беркая да юл юк, кая гына атласа да, юлы менә шушында китерәчәк — зыяратка.

Югары максатларга юл бикле, кире кит, монда сукыр тыкырык...

Бөтен гәүдәсе калтырап куйды Ильяснең. Зыяратка аркасы белән борылып, гәүдәсен турайтты, күзләрен, битләрен сыйпады. Аннары, кайтыр якка күпмедер атлагач, күңелендә җыелган яман ачылыкны беркемгә дә юнәлтмичә түкерде дә түбән якка төшеп китте.

Фатирга урнашкач, ул, әйберләрен калдырып, хуҗабикә белән ике-өч кенә сүз алмашып чыгып киткән иде. Хәзер өйдәгеләр төшке ашка, өстәл янына җыелышкан икән. Капкадан узгач тәрәзә аша шуны шәйләде Ильяс. Үзен тыныч халәткә көйләп ишекне ачты. Ачты да, ни булганын тагы абайламыйча, аңышмыйча, ишек төбендә катып калды. Ник?

Ник икәнлеген соңрак төшенде.

Әйе, ишекне ачып керде ул. Исәнләште. Һәм шул арада өстәлнең бирге ягындагы ике кызның берсе — кечерәге аңа шаккатып карап торганны күреп, үзе дә әллә ничек каушап калды.

— Исәнме, кызым!— дип, балага, үз кызын күз алдына китереп, күңелендәге бөтен җылылыкны туплап эндәшкән иде, мондый ук җылы мөнәсәбәт күргәне булмагандырмы, әллә чынлап та үз әтисен сагынганга күрәме, кыз аңа авызларын мелт-мелт итеп бераз карап торды да, кычкырып елап җибәрде. Ильяс исә кинәт ташланып, күтәреп алды кызны, каты-каты кочып, иркәләргә керешге.

— Менә бит ул минем кызым, ничек үскән бит ул!

Бала ничек тиз елап җибәргән булса, шундый ук тиз арада чырык-чырык көләргә дә керешге. Шул кадәр ихлас көләргә бары тик сабый гына сәләтледер, сагынган әтисе кочагына алып сөйгәндә

генә мөмкин булган чын сөенү белән сөенә беләдер.

— Эти! Эти!— дип, Ильясның җилкәсеннән кочаклап алды бала, аның битләренә үз битен куеп иркәләнде.— Эти кайтты, эти кайтты! Эти!

Өйдәгеләр Ильясның үзеннән һич тә ким аптырамаган, каушамагандыр. Алар да ни әйтергә белмичә, кузгала алмыйча утыра бирделәр.

Ильяс үзе дә баягы ярсуларыннанмы, әлеге котелмәгән хәлдән, яңа бер җилкенү беләнме, баланы ихлас коча-коча, үбә-үбә, кат-кат иркәләгәннән соң, инде һәр нәрсәнең чиге-чамасы булганны хәтеренә китергәч кенә, кызны әнисенә бирәсе итте. Әнисе кул сузган иде, кыз тагын Ильясның җилкәсеннән кочаклады. Шулай шактый азапланганнан соң гына әни кешенең:

— Булды, кызым, абыйның юынасы бар, йә, җитеп торыр, ул китми әле,— дигәч кенә тынычлана язды.

— Абый түгел, эти!— әнисе тагын телсез калгач, үзе сорау бирде.— Ул китмиме?

— Китмим, китмим. Юынып кына алыйм да... Бергәләп чәй эчәрбез. Булдымы? Менә шулай. Акыллы кыз бит син, үскән кыз.

Кыз, ниһаять, әнисе кулына күчкәч, Ильяска карап шундый матур елмайды, нәкъ менә Ильясның үз кызлары шикелле инде. Кызлары искә төшеп, йөрәге тагын җилкенеп, чәнчеп куйды. «Ә син йөрисең монда хуҗасыз эт сымак!»— дип, эченнән үз-үзен әрләргә тиеш тапты.

Кич, билгеле инде, Ильяс клубка юнәлде. Балаларның әнисе килмәдеме дип күзәткән иде дә, күренмәде. Балалары, бигрәк тә: «Эти кайтты!»— дип сөенгән кызчыгы яныннан китәсе килмәгәндер инде.

Төнлә кайткач, тавышсыз-тынсыз гына ятты һәм иртүк торып бераз капкалагач, баланы уятып бер сөясе килсә дә, кичәге кебек өзгәләнмәсен дип, күз белән генә хушлашуны мәслихәт тапты. Хуҗабикәгә рәхмәт әйтеп, исәнлек-саулык теләп, тиз генә чыгып китү ягын карады.

Алда — тагын юллар. Ләкин юлларның нык кыскарганлыгы ачыкланды. Шуны бүтәннәргә ничегрәк, җайлырак итеп аңлату чарасын эзләп, берничә көн уйланып йөрде ул.

Бер авылга килгәндә, юлның юешлеген, юл катысының баткакка әйләнә башлаганын күргәч, күңелендә гүяки яңа сөенеч ялтырап китте. Сәбәп бар икән, уйлыйсы да булмаган. Сәбәп — яз. Иң кызыгы — моны кешеләргә аңлатып интегәсе юк. Арбаның бишенче тәгәрмәченнән аерыласы килмичә кем газаплансын! Төште калды ул — беркем сизмәде.

Ильяс шулай гына булыр дип фаразласа да, чынында икенче төслерәк икән. Авылга җитеп, квартираларга таралырга торганда, Манчаровскийны туктатты:

— Яз җитте бит, иптәш Манчаровский, ә?

— Бик әйбәт, хәерле белән килсен.

— Авылның үз мәшәкатьләре... Мин китәрмен инде,— дигәч, Манчаровский актан-карадан сүз дәшмәс булды.

«Нәкъ шул — бишенче тәгәрмәч! Даһи фикернең кирәгеннән тиз расланыуы гына бу!»— дип уйлап өлгерде Ильяс.

Хәер, монысы аның чираттагы ялгышы иде. Спектакльдән кайтканда башкалардан бераз арткарак калгач, үзенең уйланып йөргәнен җиткерде Манчаровский:

— Шулай инде, Ильяс дус, сәбәбең — тормыш таләбе. Гаиләң кайгырып көтә торгандыр. Дөресен әйткәндә, сине гел бушка эшләтү үзе бер оят. Тамак ялына...

— Әйттем бит, авылда анысы да юк дип.

— Анысы башка эш. Без бит үзенә күрә акча алган булабыз. Фактически әйтсәк, без дә шул тамак ялына йөрибез инде. Бары тик һәвәслек аркасында. Сине, ярый, хуҗалыгың көтә. Безнең ул да юк. Китәсең икән, без каршы түгел. Тик бер уй бар иде.

— Анысы ни?

— Ни дип... Сине озату кичәсе үткәрикме әллә дигән идек. Әгәр син каршы килмәсәң.

— Каршы дип... яхшылыкка каршы киләләр димени.

— Әйбәтрәк бер авылда. Яме?

— Йә соң. Мәшәкатьләнмәсәгез дә ярарые.

— Синең хакка бернинди мәшәкатьтән дә курыкмыйбыз.

* *
*

Аралары чолан белән аерылган ике өйле йортның берсендә оешты мәҗлес. Өстәлдәге иң хөрмәтле сый — пар бөркелеп торган эре бәрәңге һәм Бөре заводыннан килгән көмешкә. Беренче апрельгә багышланган кечкенә шаяру: тәүге тостка бирелгән эчемлекнең көмешкә икәнен акыллы кешеләр генә сизәчәк, ә бүтәннәргә ул су булып тоелачак, янәсе.

— Яшәсен беренче апрель! Чөмердек!

Кемдер каш җыера, кемдер тыныч, кемдер пырхылдап стаканны шапылдатып өстәлгә куя. Шуларның берсе — Рәгыйдә.

— Нишләп, градусы җитмәдеме, әллә?— дигән була Илһам абыйлары.

— Сизелмәгән кая, Илһам абый. Шундый куәтле, эчеп тә булмый.

— Ә сиңа, Ильяс дус, ничек, шәпме көмешкә?

— Мондый да шәп көмешкәнең бер җирдә, беркайчан булганы юк, хәзер дә юк, булачагы да юк һәм...

— Һәм, һәм...

— Һәм булмасын, кирәге дә юк.

Мәҗлес халкы азмы-күпме көләргә азапланган арада Юлдыбаевның:

— Тапкан шаярыр нәрсә, карт дурак!— дигәне ишетелгәч, аңа борылып карадылар.

Нәтиҗә әзер:

— Сиздегезме, кемнең кем икәне ачыкланды. Инде килеп, акыллы затларга — көмешкә тәмен сизгәннәргә яңа тост тәкъдим итәбез.

Ләкин өстәлдә буш шешәләр генә утырып калган иде. «Бүтән юкмыни?» дип кызыксынды халык.

— Бар, бар, акыллылар өчен табабыз. Бар әле, Сәрия сеңелкәш, теге өйдән алып чык әле.— Кыз кузгалган арада елмайган була үзе.— Әйе. Җәл түгел. Анда өч бидрә тулы. Җитмәсә, кое ерак түгел.

Тагын ризасызлык белдергән ымлык. Сәбәбе дә бар — кәефсез чагы Юлдыбаевның — икенче атна инде Рәгыйдә белән квартирга аерым керәләр. Мондый чакта шаяру кыендыр. Гаепкә алмыйк. Бәйрәм дәвам итә бит әле. Әнә, ике шешәне тукмак шикелле тотып, өченчесен күкрәгенә кысып, ишектән Сәрия керде.

— Әйдә, Сәрия. Булды, коя башлагыз.

Вак-төяк сүзләр, шаяртулар. Шулай берничә тост күтәргәннән соң, ниһаять, Манчаровский Ильяска карап елмайды:

— Инде килеп, синең үзеңнең әйтер сүзең юкмы, Ильяс дус?

— Сүз акча түгел, бездә дә булгалый.

Торып басты Ильяс. Чак кына уйланып торгач, сүз чынлап та табылды.

— Әйтәсе килгәнем шул гына, иптәш артистлар. Заман авыр, сезнең эшегез авыр. Иллә сез барыбер бәхетле, озын гомерле. Чөнки дип әйткәндә, үзегез бер генә кеше булып тусагыз да, күп-күп кеше булып яшисез. Берничә гомер кичерәсез дигәнем. Шулай яшәй бирегез. Исән-сау булыгыз. Калганы булыр. Рәхмәт сезгә.

Шулай дип ярты стаканны каплагач, башкалар да аннан калышмады. Мәгәр бөтенесе шома гына тәгәлләнергә язмаган икән. Стаканның эченә үк керергә тырышкандай текәлгән Юлдыбаевның:

— Алланың кашка тәкәсе хөрмәтенә эчәргә була,— дигәненә каршы Фәрит:

— Аңларга да була, үзеңнән талантлырак кешеләрдән шулай көнләшәсең инде аны,— дигән иде, тегесе дөбердәп торып басты.

Кыяфәтендә һичнинди яхшылык галәмәте сизелми, корбанына ташланырга җыенган кара кош шикелле канатлары җәелгән иде. Бер, ике секунд... Ул Фәриткә ташланачак...

Шуны сизеп, башкалар да сикереп торды. Күзе булган кешегә: әгәр дә Фәриткә кул күтәрәсе булсаң, безнең белән эш итәчәксең, дигән кисәтүне күрмәслек түгел иде. Берничә минут шулай сүзсез күренеш хасил итеп тора-торгач, ниһаять, Маратның кабарган канат-каурыйлары шиңеп гадәти хәленә кайткач, бөтенесе бергә, дәррәү утырдылар.

Манчаровский гына, үзенең ихтыярын кырыс карашы белән мәҗлес халкына җиткерергә тырышкандай, кузгалмыйча утыра бирде. Башкалар утыргач та, һичбер каушау галәмәте сиздермичә, әйтерсең, баягы телсез, хәрәкәтсез бәрелешне юкка чыгарды, танымады. Хәтта елмая алды Илһам абыйлары.

— Дөрес булды, соңгы тостны, хушлашу тостын шулай аягүрә басып күтәрү югары әдәп билгесе булды.— Һәм шул урында сәхнәдәге кебегрәк итеп көлде.— Рәхмәт, җәмәгать. Инде теләгәнчә бәйрәм итегез — җырлагыз, биегез.

Шулай дип ул урындыгыннан купты һәм Ильяс янына килде:

— Иртәгә тагы безне күрмичә китмәссең бит әле?

— Сезне тагын бер күрмәйчә китү юк. Рәхмәт.

— Шәп. Алайса, иртәгә чаклы.— Аннары борылып башкаларга кул изәде.— Иртәгә чаклы.

Рәгыйдә, бер сүзгә дә катнашмыйча, күрше бүлмәгә кереп китте. Яңадан чыкмасмы, саубуллашырга мөмкин булмасмы дип Ильяс озак кына көтсә дә, чыкмады. Инде бәлки йокыга да талгандыр.

Ильяс бернинди ниятсез ихатага чыкты. Баян тавышын һәм соңгы мәртәбә яңгыраган җырларны тыңлый-тыңлый, бер тирәдә хискә талыбрак йөренә торды. Мәҗлес бозыла язу аркасында җырның, музыканың тиешле югарылыкка күтәрелеп җитмәвенә карамастан, төн барыбер күңел кузгатырлык матур иде. Тик шунысы җитешсез — Рәгыйдә тавышы ишетелми. Өстәвенә, җыр көйләре тукталгач, бию көйләре тыңларга җыенган Ильясның бу өмете дә акланмады. Баян тавышы тынды. Озакламый баянлы әрҗәне аркасына аскан Фәрит Солтанов үзе күренде. Чыккач та Ильяс янына килде.

— Ә-ә, син мондамыни әле? Кайтабызмы соң?

— Рәгыйдә белән саубуллашып булмады. Нишләргә белмәйрәк торуым.

— Теге калай әтәч китсен инде.

— Китә белер микән?

Фәрит җавап кайтарырга өлгергәнче, кызларның Маратны култыклап һәм әйдәләп чыгуын күргәч, икесенең дә эчләренә җылы керде. Бигрәк тә Ильяс, өстеннән тау төшкәндәй, җиңел сулап куйды.

Кызлар Ильясны үзләре кочаклап, өстәл янында әйтелгәннәрне кабатлый төшкәч, киткән чакта кул болгадылар. Шактый исереп өлгергән Маратны яңадан култыклап, капкадан чыгып киттеләр. Ильясның исән һәм гарип кулын берьюлы кыскач, Фәрит нык адымнар белән боз бөртекләрен шатырдатып, китеп барды.

Аллага шөкер, шул рәвешле, Рәгыйдә белән хушлашырга туптулы мөмкинлек туды. Һәм Ильяс яңадан өйгә кереп китте.

Эчкә узды. Рәгыйдә яткан бүлмә ишеге төбенә килеп, нинди дә булса аваз ишетелмәсме дип көтте. Бернинди тавыш әсәре сизелмәде. Гүяки, бүлмәдә беркем юк иде. Ул-бу була күрмәсен тагы.

Күңеленә курку иңгән Ильяс ишек шакыды. Менә шунда куркып кычкырды Рәгыйдә:

— Кем бар анда?— Тавышы еламсыр иде.

— Рәгыйдә, минием бу, Ильяс. Хушлашмакчыием дә...

— Ильяс абый?

Ильяс ишекне ачты:

— Ярaймы соң керергә? Әллә үзең чыгасыңмы?

— Кер, кер, Ильяс абый. Мин синнән курыкмыйм.

— Ярай әлсә,— дип Ильяс эчкә узды һәм ишекне сак кына япты.

Бүлмә караңгы булганлыктан, башта Рәгыйдә күзгә күренмичә, аның караватта ятып торганын чамаларга гына мөмкин иде. Шулай да бераздан бүлмә ярыклары аша төшкән зәгыйфь яктылык күзгә чалына башлап, аннары шәүлә рәвешле генә гәүдә барлыкка килде. Юрганын кочаклап, бер карасаң, нәрсә эшләргә белмәгәндәй, икенче карасаң, ым белән үзенә чакыргандай, талпынып куйгандай тоела иде. Ильяс моны үзенчә юрады — баягы күңелсез хәлдән соң тынычланып бетә алмаган.

Берсүзсез күпме торырга мөмкин — телгә килде Ильяс:

— Я, Рәгыйдә, исән бул инде.

— Ничек? Китәсеңмени?— Әйтерсең, беренче кабат ишетә.

— Китәм инде, Рәгыйдә.

— Ашыкма, сабыр ит. Хәзер, мин торыйм әле.

Эчке киемнән генә икәнлеге күренеп, һич югы шәйләнеп тора, тышкы күлмәген кияргә ашыкмый да кебек. Бер кулы белән караваt башына тотынган, икенчесе белән чәчләрен учлаган хәлдә нәрсәнедер хәтеренә төшерергә тырышкандай башын ия төшеп тора бирде. Күпмедер вакыттан соң теләгән фикерен исенә төшерде бугай. Әллә нәрсәнедер хәл иттеме? Ихтимал, шунысы дөресрәктер. Менә ул янындагы урындык башыннан күлмәген алып, Ильяска чыгып торырга кушмыйча гына, киде. Аякларына оекбаш һәм шундагы чөйдән алып, өстенә пальто элде дә бер үк гаилә кешесе сыман, бик табигый рәвештә:

— Мин дә һавага чыгып, сулыш алыйм инде,— диде.— Син капка янында мине саклап тор. Теге явыз кеpә күрмәсен. Бар.

Мондый ышанычны ничек акламыйсың. Чыккач та Ильяс урам якка узды. Күктән төшкән фәрештә үзе дә аннан калышмады — Ильяс капканы ачканда, ул инде баскычтан төшеп килә иде. Кулында комган да бар иде шикелле. Күктән төшкән фәрештә өчен монысы гаять тә мәзәк тоелганга, Ильяс ул кадәресен күрмәскә тиеш тапты.

Урамда җан әсәре сизелми. Дөнья тын. Шундый тын. Шау-шу сөя торган кеше булмасаң да, мондый тынлык сине тормыштан бөтенләй аергандай, бөтен галәмдә япа-ялгыз икәнлегеңне тояргa мәҗбүр итә дә, йөрәгең, бөтен күкрәгең әллә ничек җилкенә башлый һәм шул чакта кинәт: «Аһ!»— дип кычкырып җибәрәсең килә. Урамдагы кара-кучкыл бушлыкка карагач, күкрәк уртасында тагын шул сагыш кузгалып өлгерде инде. Мәгәр Рәгыйдә коткарды — аның күтәрмәгә баскан аяк тавышы шыгырдап куйгач, Ильяс үзенең әле бөтенләй үк ялгыз түгеллеген исенә төшерде.

Аяк тавышы тынды. Рәгыйдә Ильясны көтә бугай. Ильяс бәләкәй капканы ачып караса, нәкъ шулай — күтәрмә уртасында басып тора Рәгыйдә. Ильяс аның янына ашыкты һәм алар караңгы өйалдында бергә кармалана-кармалана, бер-берсенә «ялгыш» елыша-елыша, өй ишегенә таба атладылар. Караңгылык Рәгыйдәнең кулына ни тотканын күрмәскә тагын ярдәм итте. Шулай кыштыр-кыштыр эчке ишеккә җиткәч, Ильяс Рәгыйдәгә ялгыш ныграк бәрелеп, аны кочаклабрак куярга мәҗбүр булды да, шуның өчен гафу үтенде. Рәгыйдә исә, ваклыкларга игътибар итмичә, һичбер ымсыз-нисез ишекне ачты.

Ильяс аның өстеннән пальтосын алып, шинеле белән бер чөйгә элде. Аннары бая кешеләргә биер өчен бушаткан иркен урында йөренеп торды. Рәгыйдәнең су шапырдатуын күңелне иркәләгән рәхәтлек белән тыңлап, аның сөртенүен шундый ук җылы хис белән күзәтте. Бу минутларда күзгә бер нәрсә ачык күренмәгән, яшәү үзе үк тукталган сыман тоелган караңгы дөньяда назлы, нәзберек һәм ялгыш кагылсаң коелып төшәргә торган чәчәк тажы кебек бер җан иясенең, җанлы чәчәк, төнге күбәләкнең хатын-кыз шәүләсе рәвешендә генә булса да янда йөрүе, хәрәкәтләнүе хәзер аны күзәткән икенче затның сугыштан исән кайтуын аклый торган, кешелекне рәнҗеткеч фәкыйрьлектә гомердән баш тартмаска мәҗбүр итә торган бердәнбер сәбәпнең булуы әйтеп аңлата алмаслык ләззәт китерә, күңел тынычлыгы бирә иде. Шушы матурлык, шушы изге җан иясе булганда, кеше дөньядан бизмәс, дөньяда кеше заты исән булыр. Шул исәптән — Ильяс.

Хушисле салкынлык бөркеп, Рәгыйдә аңа кагылып диярлек бая үзе яткан бүлмәгә узды. Ильяс берничә минут тагын аның тын бүлмәдән ишетелгән кыштырдавын рәхәтләнеп тыңлады. Аның нишләргә белмичә торуын сизгән әүлия эчке яктан:

— Нишләп кермисең, Ильяс абый?— дип, йә алла, Ильясны үз янына чакырды түгелме соң?

Колакларына ышанмаган Ильяс ишеккә кагылырга җөрьәт итмәгәнлектән, Рәгыйдә үзенең чынлап дәшүен кабат расларга мәҗбүр:

— Әйдә инде, Ильяс абый, нишләп торасың бер ялгызың?

Кыяр-кыймас кына ишек ачып керүенә, каршында — әүлия! Чып-чын фәрештә! Әйе, әйе, һич тә кеше заты түгел, шәүлә генә! Ике кулы белән чәчләрен күтәргән, башынияр-имәс тора басып! Зифа талның нәкъ үзе. Талның ябалдашы — кабарып, тузгып, күкрәкләргә төшкән чәчләрдер. Юк, алай гына түгел, чәчләр — кабарып бүлмәне каплаган томандыр. Ильяс әнә шул томан эченә кереп, күз күремен һәм аңын ук җуйды бугай. Кергәч тә, адашудан курыккан юлчы сыйфатында тыйлыгып калды. Нәрсәнедер ачыкларга, аңларга тырышуы иде бугай. Ул шулай һуш җуеп торган мизгелдә Рәгыйдә — төп-төз, тәнсез шәүлә — гүяки җилдән чайкалып, тирбәлеп куйды. Аннан соң әкрен генә шуышкан шикелле, җилдә очкан төсле генә Ильяска таба якынлашты. Якынлашты, килеп җитте... Килеп җитте дә... Йә хода! Ничек ышанасың ди мондый хәлгә?! Ничек моны өндәге хәл дип исәплисең? Әйе, төштә, бары тик төштә, яки хыялда гына була алганча — нәкъ шулай. Әйе, килеп җитте дә Рәгыйдә әтисе кочагына ташланган сабый шикелле, Ильясның җилкәсеннән кочаклап, асылынып калды. Ә Ильяс? Шатлыгы ташудан ихтыяр җуйган Ильяс аңсыз рәвештә сабыйны күтәргән төсле итеп, аны кулына алды. Алды да мөмкин булганча биегрәк күтәреп, селкетеп, тирбәтеп торды. Аннары күкрәгенә кысты.

Шулай күтәргән килеш, атлар-атламас әйләнгәләп иркәләгәч, караватка китереп утыртты. Үзе аның каршысына чүгәләде. Рәгыйдәнең әле дә тәнсез диярлек йомшак бармаклары ихтыярына буй-

сынып, башын аның тезләренә куйды. Тәнсез диярлек бармаклар аның чәчләрен тарадылар. Бу рәвеш, бу фигыльләр күпмегә сузылгандыр — дөрес, бәхетлеләр өчен вакыт көчен җуя — сорасаң бәлки икесенең берсе дә әйтә алмас иде. Әмма мәңгелек берни юк. Рәгыйдә кузгалып куйгач, Ильяс аягүрә басты. Ләкин Рәгыйдәдән күз алмады — аның һәр хәрәкәтен, хәрәкәткә ошаган һәр селкенүен күреп, яратып торды. Әйе, менә Рәгыйдә юрганын, ястыктан кайтышрак зурлыктагы мендәрен каккалап, кабартып салды. Аннары, мөгаен елмаеп, һәрхәлдә ишетеләр-ишетелмәс көлеп, йомшак урын-җиргә чумды.

Ильяс түр тәрәзә әргәсендәге почмактагы урындыкка утырып, бераз ял итмәкче иде. Рәгыйдә юрганын күтәрә төште.

— Нишләп анда... тагын бер ялгызың?— дип, тагын өзелеп чыгарлык нәзек тавышы белән көлеп куйды.— Моңаерга вакыт күп булыр әле.

Шул чаклы дөрес сүзләргә ничек җавап бирәсең. Бөтенесе алда бит әле, алда...

Соңыннан артык ук үкенмәс өчен, Ильяс ни булса шул, дип, тагын Рәгыйдә каршына, караватк янына килеп басты.

— Утыр.

— Урын-җиргәме?

— Булса соң...

Утырды Ильяс — рөхсәт белән булгач, гаеп эшмени. Һәм ул бераздан Рәгыйдәнең чәчләрен сыйпарга кереште. Тегесе исә, аның кулларын үзе тотып, үзенең битләрен сыйпаттырды. Гаҗәпме? Гаҗәпнең аръягында! Исең китмәле һәм акылга сыйгысыз.

Шуның белән чикләнсә икән әле. Юк. Рәгыйдә Ильясның ике кулыннан тартып аны иелергә мәҗбүр итте. Үзенең эссе сулышы белән калган азмы-күпме зиһенне өреп таратты, юкка чыгарды. Рәхәтлек ташкынына бирелеп, талган билен турайтыр өчен генә кузгалган иде, шул арада үзе дә сизмәстән, караватка чынлыкта ул инде яткан ук булып чыкты. Ярый әле, артык оялырлык түгел, ни дисәң дә бит әле ул тышкы киемнән — гимнастеркадан һәм чалбардан. Итекләрен генә кай арада салып ыргыткандыр. Яшерен-батырын түгел, шундый хәл иде менә: Рәгыйдә — аның куенында! Актыккы якынлыктан бары тик юрган һәм кием калынлыгы оялчанлык кына аерып тора. Ә тагын да ныклабрак уйласаң, бәлки әле аермый да торгандыр. Әнә бит арада бернинди чик калмады, инде соңгы чикләр җимерелде дияргә мөмкин. Әнә бит бер-берсенә тартылган ике зат чынлыкта инде кушылды, кавыштылар — иреннәр бер-берсен эзләп тапты. Ләкин... Ләкин җимерелде дисәң дә, нәзберек бер хис, сизем рәвешендә, ниндидер бер киртә барыбер калган икән. Бу хис, мөгаен, оялудан көчлерәк. Рәгыйдә хакында әйтә алмаса да, Ильяс моны белә: иреннәр тиешле чиктә шулай ук туктала. Иреннәр бер-берсенә кагылган, иркәләгән, әйе, анысын да әйтик, бер-берсен үз эченә алып, кысып-кысып ләззәт ала да... сүз белән әйтеп булмаслык бер чиктә туктала белә. Шуннан арысы — гөнаһ буладыр... Анысына Ильяс исәп тотмый, андый нәрсә хыялында да юк аның. Ә Рәгыйдәнең? Анысын Ильяс белми, сизми, бәлки сизенгәнен үзенә дә сиздерми, хәлнең алай була алуына ышана алмый. Ышанса да кабул итә алмас иде...

Якынлык ләззәтеннән һәм йокыга оеудан дип фаразлый Ильяс, Рәгыйдә әнә ышанмаслык сүзләр тәкърарлый. Аңлата, соңгы чикне узарга рөхсәт икәнен аерым-ачык белдереп пышылдый:

— Мин Марат белән бүтән беркайчан да бергә булмыйм инде,— ди.— Син дә аны бар дип исәпләмә. Аңладыңмы?

— Аңладым,— дигән була Ильяс, ишеткән сүзләренә һаман ышанмаган килеш.

Тагын сүзсез хисләр һәм уртаклашмаган уйлар. Рәгыйдәнең ишаләр белән аңлаткан тирән мәгънәләре. Әлбәттә, Ильяс кебек кыюсыз кешегә ул мәгънәләрне сүз белән әйтмичә булмый торгандыр. Һәм Рәгыйдә, гүяки йокы аралаш, ераккарак чакыра:

— Сине хәзер бер нәрсә дә чикләми. Вөҗданың тыныч булсын, барысына хакың бар. Син... Син... Әллә син мине яратмыйсыңмы?

— Син ни сөйләйсең, Рәгыйдә?! Синнән дә яраткан кешем юк. Син — минем иң зур хыялым. Яшәвемнең мәгънәсе син. Син булмасаң яшәү үзе кирәк түгел.

— Мин дә шулай, нәкъ синеңчә... Бәхетем, бәхетсезлегем син!

— Син минем кочагымда түгел, җанымда. Сулышыңны сизеп, тәнеңне тоеп, сүзләреңне ишетеп торсам да, чын барлыгың еракта, бик тә еракта. Күктәме син, җирдәме, әйтә дә алмыйм. Сине бөтен итеп, чын итеп, мин сәхнәдә генә күрәм. Синең сәхнәдәге чагыңа гына ныклап ышанам. Син минем өчен бер генә исемле түгел. Син минем өчен Рәгыйдә, син — Хәмдия, син — Асылъяр! Менә кем син! Кулга тия торган түгел — акылда, хыялда гына яши торган бөек зат!

— Мин — хатын-кыз, шунысын да онытма.

Иреннәр кайнарлыгы белән расланган ихлас тойгылар, аңлашу, яратышулар күпме дәвам иткәндер, анысын кем белсен. Шундый билгесезлеккә чумып, рәхәтлеккә талып ятканда күпме вакыт узды икән? Бер-берсен икесе ике төрле яраткан бәхетле җаннар бәхеттән арып йокыга талгач, тагын күпме бергә булганнардыр, анысын шулай ук уйларлык дәрәҗәдә булмаганнардыр. Вакытның чикле икәнлеген кояш чыгып аңлатмаса, инде ни дияр идең?!

Ләкин чик бар, кояш бар.

Ильяс күзләрен ачып караса, дөнья инде яп-якты.

Яктылыктан оялганга күрә, сикереп торды да аягына итекләрен элде. Биленә каешын буды. Шуннан соң Рәгыйдәнең уяу килешме, йокы аралашмы елмайган иреннәрен, битен, чәчләрен сыйпады да, бүлмәнең икенче ягына чыгып, китәсе килмичә, тукталып калды. Китсә, бу бит инде бөтенләйгә, мәңгелеккә китү, теге дөньягача очрашмас өчен хушлашу лабаса!

Йөрәк чәнчүенә түзә алмыйча, Ильяс якындагы бер урындыкка чүкте. Һәм... Ах, гөнаһ шомлыгы! Сизмичә калган булып чыкты ла. Ике кешегә бер баш җитмәгән! Хәерсез, кичтән ишекне бикләми яткан булганнар. Дөбердәп килде керде теге явыз... Юлдыбаев!..

— Ә-ә! Шулайдыр дигәнием лә аны. Сизенгәнием. Йокы дөрес бүленгән икән. Саклыйбызмы? Минем байлыкны яман күзләрдән эт булып саклыйбызмы?

Шулай дип бүлмәгә узмакчы иде, Ильяс аның каршысына килеп басты:

— Саклаем, бигрәк тә — синнән. Чәнти бармак белән дә кагыласы булма.

Маратның чыраеннан, әйтерсең, усаллыкны чүпрәк сыман итеп сыдырып төшерделәр. Гаҗәпләнүдән ул хәтта елмаеп, юашлана куйды:

— Кара син моны, кара! Шул кадәр бирелгәнлек! Эт тә хуҗасына шушы хәтле тугры була алмыйдыр. Рәхмәт, дус кеше. Бетте, ачуланма. Мин аңа кагылмыйм, тырнагым белән дә чиртмәм, курыкма. Йә җибәр.

— Саклап торам, тавыш чыгарасы булсаң...

— Әйтәм бит, сүзем генә бар, бер генә сүз.

Ильяс читкәрәк тайпылгач, әкрен генә, сак кына ишек ачып Юлдыбай тәки хатыны янына керүгә иреште. Тавыш чыкмасына ышанып җитмәгәнлектән, Ильяс ишек яныннан ерак китми торды. Теләсәң-теләмәсәң, ниндидер кыштырдаган тавышлар ишетелеп куя иде.

Ә бер мәлне... нәрсә, ничек?.. Караватт, карават шыгырдавы. Рәгыйдә уянып, сикереп тордымы әллә? Шулай бугай. Әнә ул:

— Аһ!— дип ыңгырашып куйды.

Маратның «Тшш!» дигән ымлыгыннан соң, гүяки тынычланды.

Тик... бераздан...

Бераздан коточкыч хәл — оятыннан егыл да үл!

Әйе, әйе, караватның кабахәт шыгырдавын теләсәң-теләмәсәң дә ишет. Җитмәсә әле, Ильяс исеме телгә алына. Юлдыбай, әлбәттә, аның хакында:

— Ул китте, китте, курыкма!— дип хатынын алдый.

Тегесе әллә чынлап ышана, әллә бүтән сәбәп белән — тавыш чыгармый, тынычлана, тына. Шуннан файдаланган ир җәнлек үз шөгыленең бөтен кайнарлыгын шыгырдык оятсызлыкка әйләндереп, гамәлен азагына җиткерә, шыңшый, улый, һәм, ниһаять тына.

Ә Ильяс? Ул нишләргә тиеш иде? Нишләде? Ник хатының белән ямьсез йоклыйсың дип, тавыш кубарырга тиеш идеме ул? Ах, шайтан орган, Марат үзе бәйләнергә, Ильясның үзен оялтырга тиеш лабаса! Ник кешенең хатыны белән ятканын тыңлап торасың дип бәйләнергә хаклы ул. Шуннан? Ильясныңмы хакы юк? Үзе кагылырга курыккан изге затны, әүлиягә тиң Рәгыйдәне, җыр тудыруга сәбәпче була алган Хәмдияне, Асылъярны... тагын, тагын күпме каһарман кызларның барысын берьюлы мәсхәрә итү — Ильясның ишек төбендә калганын белгән килеш, юри, үч итеп эшләнгән гамәл кабахәтлек түгелмени? Әхлакка хыянәт түгелме?

Җинаять! Кешелек затына хыянәт!

Моның өчен җәза тиеш. Ләкин нинди җәза?

Нинди җәза бирә ала Ильяс? Нәрсә генә кулыннан килә аның?

Бер генә эш килә аның кулыннан. Хәзер, берничә минуттан чыгачак Юлдыбай. Чыккач та, бер сүз әйтмичә генә, үзенең бөгелми торган кулы белән, ярыйсы ук каты йомарлана торган йодрыгы белән әшәке җанның колак төбенә тондырачак. Карар әзер. Әзер карар белән каты-каты басып йөренгән Ильяс, шул рәвешле, Марат белән араны өзәчәк.

Шулай. Чыкты Марат. Чыраенда ачу галәмәте калмаган. Елмая хәтта. Тугарылды калды Ильяс шул кадәр шат йөзгә карап. Йодрык булып төйнәлергә тиешлеген кул бөтенләй онытты. Ләкин якты чырай алдакчы иде. Марат кояштай елмайган килеш:

— Әх, син! Изге җан!— дип, әйтерсең, мәсхәрә итте.

Әйтерсең, нәрсәдер белә. Янәсе, Ильяс булдыра алмаганны адәм төсле бәндәләр әнә ничек җиңел башкаралар!

Баш бетте — хыялдан, изгелектән, матурлыктан берничә генә минут эчендә бер нәрсә дә калмады. Хыялны, изгелекне, матурлыкны берничә минут эчендә изде дә чыкты Юлдыбаев! Һәм шулай ук Ильясның кешелеген, ирлеген, намусын таптап, җимереп, кырып, юкка чыгарып китте. Кай арада!

Шуннан соң Рәгыйдә кем булып кала инде?

Ильяс үзе кем?

Бетте, уйларга җай бетте. Уйласаң, харап башың!

Исән чакта юлыңда бул. Болай да артык соңга калдың.

Саубуллаша, имеш. Саубуллаштың менә. Дөньяга күренергә оят.

Кичтән ул Манчаровский белән әле тагын бер кат күрешергә, артистлар төялеп киткәндә озата калырга вәгъдә биргән иде. Вәгъдәдә торыр рәт калмады. Фатирына барып, биштәрле капчыгын асты да, сугыштан кайткандагы кебек, ләкин җиңеп түгел, җиңелеп, бәлки йортсыз-җирсез сукбай мисалында, тагын юлга чыгып китте. Инде ничәнче кабат! Ник тынычлана алмый, догасыз әрвах сыман кубарылып йөри ул? Ник бер җирдә туктала алмый? Өендә, гаиләсендә?

Инде житкәндер. Ак тәүбә, кара тәүбә. Череккүленнән — туган, үскән, инде менә ил агасы булырга тиешле яшькә житкән урыннан көннәренең иң соңгысынача купмаячак, кузгалмаячак.

* * *

Дөресен әйтик, авыл Ильяс юклыктан артык зарыкмаган иде. Әллә нинди үзгәрешләр булгандыр дип кайтса, һич сизелерлек түгел — ул киткәндә ничек, кайтканында шулай. Авыл тормышы табигатьнең үзе кебек — әйтерсең, мәңгелек торгынлык. Дөньяның күзгә күренә торган үзгәреше — ел фасылларыдыр. Аерма шул яклап кына күзгә чалынды — киткәндә Ильясны ап-ак кыш озатса, хәзер ямаулы яз каршылады. Күрше-тирәдә дә әллә ни яңалык күзгә ташланмый — үлем-житем булмаган, аллага шөкер. Хатын, балалар, мал-туар шулай ук исән. Ягъни дип сөземтә чыгарсак, шул, китеп тордымы Ильяс авылдан, юкмы — авыл өчен барыбер иде. Беркемгә файдасы тимәсә дә, зыяны да тимәгән. Шулай да бер бәләкәй генә аерма бар икән, балалар сагынган иде.

Гадәттә балаларны махсус рәвештә сөюне ясалмалык дип исәпләсә дә, бу юлы исә үзенә охшамаганча эшләде — кулдан төшкәннәренә инде өч-дүрт ел булса да, кыз балаларын кулына аңлы рәвештә алып, гаделлек өчен чиратлап, махсус рәвештә сөйде. Ә малай инде зур. Әтисе кайтып кергәч тә китап-дәфтәрләрен алып ишек төбенә килде дә, бераз вакыт әтисен биленнән кочаклап торгач, мәктәбенә китеп барды.

Ә бичә? Бәһрәмия?

— Ә-ә, язган мал, кайткан икән әле,— дип, якты ук диярлек караш ташлады да үз эшләрен дәвам итте.

Билгеле инде, әгәр теләгең булса, өйдә ир-атка да шөгыль табарга була. Димәк ки, тагын китте яшәү арбасы тәгәрәп, гомер-бакый тәгәрәгәнчә.

Өйдәге вак-төяк шөгыльдән тыш, колхоз идарәсе яңа вазифа йөкләде. Фермада җайсызрак икән хәлләр — сыерлар күтәрәмгә кала бара. Ящур дигән үләт кыра малларны. Ачлыгын әйткән дә юк. Әзрәк тәртипкә китерә алмассыңмы, ни дисәң дә хатын-кыздан куәтлерәксең бит әле, эшләп кара, дигәч, күнде Ильяс. Аның өчен бу һич тә ят гамәл түгел, теге елларда көтүче булып мал холкы шактый өйрәнелгән бит. Көтүчелектән мөдирлеккә үрли икән, бик хуп, кеше үсә дигән сүз!

Ләкин аны беркайчан да көтүче дип, хәзер исә «завферма» дип атарга җыенмадылар. Кушаматы һаман искечә кала бирде — «Артист». Элек шаянлыгы, шуклыгы өчен шулай атасалар, хәзер исә чын артистлар белән театр уйнап йөргәне өстәлде.

Тормыш арбасы дидекме? Әйе, тәгәри бирде. Күзгә күренгән үзгәреш — ямаулы яз яшел язга юл биреп, гөрләвекләр шавы яфраклар шыбырдавы белән алмашынды. Җир яшәргәч, болынга төс кергәч, азрак рәтләнмәсләрме дип, Ильяс сыерларны җәйләүгә чыгару мәшәкатен үз өстенә алды.

Шул көннәрдә Дүртөйле колхоз-совхоз театры безнең районга килгән икән, дигән хәбәрләр йөрде. Йөрәге сагыштан ярсып, берничә кабат тагын дөпелдәп куйса да, елның әлеге фасылында малларның каны мәхәббәткә тарткан шикелле, тыелгысыз теләге туса да, үзен тыя белде, теләген йөгәнли алды Ильяс. Башын иеп телен тешләп йөрсә йөрде, мәгәр театр спектакльләр күрсәткән авыллар ягына борылып карамады. Артистлар хәтта ки Череккүлнең үзенә килеп чыккач та мыегын да селкетмәде. Ире нинди бәндәләр белән йөргәнне белер өчен барган Бәһрәмия болай ошатып кайткан уеннарын. Мәгәр бөтен хәбәре

— Хәйран килештерәләр,— дигәннән ары узмады.

Ильяс исә: «Бик шәп, афәтле болыт читләтеп узды»,— дип, яңадан тыныч күңел белән үз эшләрен дәвам итте.

Елга буенда көннәр буе чемченеп йөргән малларны саздан да яман баткак ферма утарында яткырып йончытмас өчен, төнгелектә дә болында калдыру мәслихәт күрелде. Колхоз идарәсе ярдәме белән шунда утар сымаграк нәмәрсә әтмәлләделәр. Моның өчен елга буендагы чаукалыкта казыклык-киртәлек агач кистеләр. Ферманың бердәнбер аты белән шул агачларны алырга килгән иде Ильяс. Үлән чемченә торсын дип, атның тезгенен бушайтып, аркалыгын төшергәч, яшь имәннәрне ташый һәм арбага китереп сала башлады. Җилкәсендә күтәреп бер китерде, ике китерде, ә өченче килүендә, Базы ягыннан әллә нинди матур, таныш тавыш колакка чалынгандай тоелып, тынып калды. Тыңлап торды. Әмма атның үлән кетердәтүеннән башка, алгарак кузгалганда арба шыгырдавыннан башка, бүтән ым-шым ишетелмәде. «Артык сагынам, ахрысы, шуңа күрә, колак юкны ишетергә тырыша»,— дигән нәтиҗә ясап, яңадан агачлыкка кереп китмәкче иде... тагын! Тагын матур һәм үзәк өзгеч таныш тавыш!

Инде шик юк, колак иҗаты, җан алдануы гына түгел, чын тавыш иде. Шуңа ышанган Ильяс ашыгыч эш төшкәндәй Базы ярына таба йөгерә-атлый төшеп китте. Җитте яр буена. Караса, теге якта... Йә алла, теге якта, йөз, йөз илле метрлы гына арада! Кемнәр диген! Ул — Рәгыйдә! Аның янында — Сәрия. Сәриядән арттарак — Юлдыбай бугай. Аргы ярдагы карт өянке төбенә килгәннәр дә шуның күләгәсендә ял итәләр. Ни хакындадыр сөйләшкән, бәхәсләшкән булалар.

Ильяс бирге ярның актык чигенәчә килде дә, шунда, үзе кагарга җыенган казыкларның берсе сыйфатында, катты да калды. Әйе, каккан казык сыман, сихерләнгән сыман, селкенергә дә куркып торды. Аргы ярдан күзләрен аера алмыйча торды. Яшьләнгән күзләрен сөртмәгәнгә күрә, аргы яр гадәттәгедән дә матуррак, яктырак булып, ямь-яшел дулкыннар уйнаган төсле ялтырый, балкый иде. Бу кадәр дә яшь һәм яшел төсләрне, тере дулкыннар уйнавын, җилнең күзгә күренеп дулкынлануын Ильясның үз гомерендә беренче мәртәбә күрүе иде. Шул хәтле тиз үзгәрсә дә үзгәрә икән табигать! Аргы якка карамаганга биш былтыр. Нинди гүзәллектән үзен мәхрүм итеп яшәгән икән Ильяс!

Әйе, аръяк искиткеч ямьле, гүзәл, сихерле — оҗмахның нәкъ үзе. Ә андагы кызлар хур кызларыдыр.

Шулай әсәрләнеп күпме торгандыр, бермәлне аргы ярдагы чырчу тынып, Рәгыйдә дә ярга басып, мөгаен, ул да үз күзләренә ышанмыйча һәм күргәнен саташуга юрап, басып торгандыр. Әйе, ул Рәгыйдә! Бүтән кем булсын? Бүтән кем шулай бөтен барлыгы белән, ихлас омтылу белән яши, тоя, кичерә алсын! Ул! Рәгыйдә!

— Рәгыйдә! Рә-гый-дә-ә!

Бер ярдан икенче ярга әнә нинди матур исем яңгырап чыкты бит. Һәм икенче яр да җавапсыз калмады:

— Ильяс абый! Илья-а-ас!

Һәм куллар, куш куллар болгап чакыру тиз арада бәйләнешле сүзләргә әйләнде:

— Бу якка, бу якка чык, Ильяс абый!

Мөмкин түгел дигәнне аңлатып Ильяс мескен җилкәләрен җыерган була, ике кулын очмас канатлар итеп җәя — бернишләп булмый, янәсе, су суык, тирән.

— Сикер, Ильяс абый, чык! Көтәм, Ильяс! Бүген китәбез, актык көн! Күрәсең килми әллә? Ильяс!

Мондый чакыруга эчендә җаны булган теләсә нинди туң бән-

дәнең дә йөрәге эрер иде дә, шушы язгы суга кушылып агар иде. Ә йөрәге бозмы Ильясның? Ташмы? Юк, боз түгел, таш түгел, юк, аның йөрәге — балавыз, эреде, акты. Бетте Ильясның йөрәге, юкка чыкты.

Йөрәкне юкка чыгарган иң сур сәбәп — теге якта суга төшмәкче булып, Сәрия кулыннан ычкына алмый Рәгыйдәнең үрсәләнүе.

— Минем әйтәсе сүзем бар!— Сәриягә борылып, аңа ялвара.— Җибәр, Сәрия, җаным! Сәрия!

Бу сүзләрне ишетсә дә аңламаган Ильяс барыбер баскан урынында калырлык түгел иде инде. Аягындагы кирза итекләрне салып атты да сикерде! Алкып аккан, әле җылынып өлгермәгән салкын суга ташланды. Лашпор-лошпыр йөзәргә тотынды. Ә Рәгыйдә? Ул! Ул! Ул да кергән инде. Ул да бу якка таба килә! Йөзми әле, ул якта бит яр сөзәк, су сай. Атлап килә Рәгыйдә. Әмма тынычланып бетмәгән, ярсуы кимеп өлгермәгән язгы су аны кирәкмәгән якка, аска таба өстери. Ильяс исә дулкын Рәгыйдәне агыза күрмәсен дип, аның саен ашыга. Ашыгудан һәм су салкынлыгыннан тыны куырыла, йөрәге кысыла. Шуның белән бергә йөрәкне сагыну, күрергә ашкыну телгәли, туктатырга чамалый. Әмма иң авыры инде артта — яр буендагы чоңгыл инде узылган. Уртада су күкрәк турысыннан гына, ә теге табарак хәтта билдән генә. Һәм менә максат якында гына, бәхеткә кул сузасы гына калды. Кул сузасы да кочып аласы!

Кулларын сузды Ильяс һәм кочаклап алды бәхетен! Йөрәгенең нәкъ түренә сеңдергәнче кысты Рәгыйдәнең салкыннан калтырап торган изге гәүдәсен. Калтырый-калтырый Рәгыйдә үзе дә Ильясның җилкәләреннән, аркаларыннан кочты, башын сыйпады, битләрен, иреннәрен сөйде. Ильяс нишләсә, шуны кабатлады. Читтә, яр буенда кешеләр бармы-юкмы, исләренә кертерлек, аңларлык хәлдә түгел иде алар. Читтән караганда нинди тиле, акылга сыймаслык манзара — ике кеше, ир кеше белән хатын-кыз елганың, ташуы тынып та өлгермәгән елганың нәкъ уртасында, яшел киңлекнең, илнең нәкъ уртасында беркемне күрмичә, һичкемнән тартынмыйча, яшел киңлектән, илдән, халыктан, ниһаять, кояштан оялмыйча, бер-берсенә чатырдап ябышкан хәлдә басып торалар!

Икесе дә чын дерелдәү белән дерелди, тешләре тешкә тими — сүз әйтер хәлләре калмаган инде. Шул килеш нидер әйтмәкче, нәрсәнедер аңлатмакчы Рәгыйдә.

— Син... син... ул... ул... аңламый калдым... мин гаепле, гаепле түгел, түгел... син... ул...

Ярый әле башка чак кына зиһен очкыны ялтырап керә язды, исенә төште Ильясның — ярга, ярга чыгарга кирәк бит!

Рәгыйдәнең нәрсәдер лебердәвенә колак салмастан, ул аны аръякка, өянке ягына таба җитәкли китте. Күзгә бернәрсә күренми — ак-кара юк, бары тик өянке генә бар — бердәнбер маяк. Бары тик шул маякны гына шәйләгән Ильяс һаман калтырый, шыңшый һәм теле ачылып кына килгән сабый мисалында леберди биргән Рәгыйдәсен су читенә, ниһаять, китереп җиткерде. Шулай ук җитәкләгән хәлдә өянке төбенә китереп утыртты.

Шул чакта гына ул үзләре янында Сәрия белән Юлдыбаевның шулай ук нишләргә белмичә ахыруларын, аптырауларын, йөдәгән булуларын абайлады.

Җитмәсә, Рәгыйдә яңадан торып басты да бер үк вакытта көләргә һәм еларга кереште. Ильяс аны тагын кочаклап юатырга азапланды — күзләрен, битләрен сөртте. Юлдыбай исә ниндидер катыкаты сүзләр әйтә-әйтә кычкыра, кизәнә, яный. Ләкин кем генә ул сүзләрне ишетер, аңлар дәрәҗәдә булды икән? Ихтимал, Сәриядер. Ул бер заман чарылдап җибәргәч, ике ирнең икесе берьюлы чайкалып, артка чигенеп куйды.

— Туңдырып үтерәсез бит! Икегез дә күздән югалыгыз! Хәзер аның киемнәрен алыштырырга кирәк. Җылытырга. Югалыгыз! Үзем, үзем карыйм Рәгыйдәне, китегез!

Бая гына (бая? Бәлки танышканнан бирледер?) бер-берсен сүзсез һәм сүзләрнең иң ачылары белән каһәрләгән ике ир, кинәт айныгандай шым калгач, Сәрия адәмчәрәк итеп өстәде:

— Барыгыз, өегезгә кайтыгыз. Син дә, Марат.

Марат янавын дәвам итте:

— Китәм бит, чынлап китәм.

— Чынлап кит.

Шул сүздән соң, үпкәләгән төсле капыл борылып, Юлдыбай биек ярга илткән үзән сукмагыннан китеп тә барды. Ильяс, суга кереп, яңадан шапыр-шопыр атларга, аннары йөзәргә кереште. Үзен белештермичә, ярга чыгып капланды. Сулуы капкан иде. Чак кына җан әсәре кергәч, күтәрелеп, яр өстенә үрмәләде. Менде ярга. Ярга менеп утыргач караса, аргы якта әле Сәрия белән Рәгыйдә һаман нәрсә хакындадыр сатулаша, бәхәсләшә иде. Сәрия — әни, Рәгыйдә сабый роләндә. Әйтерсең — сәхнәдә! Әллә сәхнә белән чын тормышның аермасы шул хәтле генәме?

Сәрия Рәгыйдәгә үз киемнәрен кидергән. Үзе эчке күлмәк өстенә плащ кимәкче иде, нидер исенә төшеп, тукталды һәм плащны да Рәгыйдәгә көчләп кидерергә тиеш тапты. Рәгыйдәнеке булырга тиешле кыска куртканы үзе киде. Тез башына җитеп бетмәгән курткадан кызның шәрә ботлары күренгәч, Рәгыйдәнең иң эчтән дә коры киемнәр кигәнен чамаларга мөмкин иде. Ялангач тәнгәчә чишенеп киенгән кызлар, ниһаять, китешли Ильяс торган якка борылып карарлык көч таптылар. Хәтта Сәрия кул болгады. Рәгыйдә еламсырап кычкырды гына:

— Хуш, Ильяс абый! Ачуланма! Ильяс! Хуш!

— Исән бул, Рәгыйдә! Мин сине онытмам! Онытмам!

Бу исә чынлап та хушлашу, гомерлеккә хушлашу иде.

Рәгыйдәнең суга сикерергә мәҗбүр итәрлек дәрәҗәдә әйтәсе килгән сүзе нинди булды икән? «Теге чакта, бик мөмкин вакытта, син бүре була алмадың, шуңа күрә мин шакал ризыгы булдым»,— диясе килдеме икән? Ләкин ул аны әйтә алмый китте. Ә Ильяс аңлады.

Бөтен булганы менә шул. Ильясның театр белән бәйләнеше, «артистлыгы» бары тик шушылардан гыйбарәт.

Җәй үтте. Ул җәйдән соң икенче язда сугыш бетеп дөнья тынычлана язгач, һәм тагын бер кыш узгач, Дүртөйле театрын таратканнар, дигән хәбәр килде. Бу халык кайгысы иде, халык телен, аның мәдәниятен кысрыклау галәмәтләренең бер мисалы иде. Әмма, Ильяс күзәтүенчә, халык үзе кайгыру түгел, бу хакта уйлап та бирмәде, хисенә түгел, исенә дә кертмәде.

«Гаделсезлеккә юл куелмасын!»— дигән баш белән хат язып, авылдагы барлык өйләргә кереп, Ильяс шуңа кул куюларын сорап йөрсә дә, кул куючы табылмады. Кем аңламыйча, кем, элеге дә баягы, моны Ильясның чираттагы шаяруына юрап, кул гына селтәделәр. Үз имзасы белән генә Уфага җибәргән хатына җавап та килмәде. Гаҗәпме? Гаҗәпме? Уйлый төшсәң, һич тә гаҗәп түгел...

Ильяс өчен, билгеле инде, тагын бер шәхси фаҗига иде бу. Театрны югалту Рәгыйдәне югалту белән бер булды.

Авыл өйләренең берсенә дә телефон куелмаган. Әмма тәкый гаҗәп, гыйбрәтле хәбәрләр, һич арттыру түгел, шәһәрдәгедән тизрәк һәм ераграк тарала анда. Ипидер шулай. Кем тарата, ничек тарата? Халык үзе монысын «чыбыксыз телефон» дип исәпли. Һич ватылмый, бозылмый торган шундый телефон бар авылда.

Шактый соңгарып булса да берсеннән-берсе үкенечле, аяныч

хәбәрләр Ильяска да килеп ирешә тордылар.

Дүртөйле театры таралгач, Манчаровский белән Рәгыйдәне Уфа театрына чакырганнар. Манчаровский киткән, ә Рәгыйдәне Юлдыбаев җибәрмәгән. Рәгыйдә театрсыз яши аламы инде? Сәхнәне ул читлектәге кош мисалында сагынгандыр, бичара. Талпынып-талпынып та оча алмагач, канатлары салынгандыр.

Язгы ташкын тынып та бетмәгән елга суына киемле килеш сикергәнче үк, шашкан дигән хәбәр йөргән иде бит. Акылдан язу белән язмауның аермасы әлләни түгел икән. Үзенә ишеттермәсәләр дә, ул вакыйгадан соң Ильясны да «Ычкынганрак ул»— дип, шактый озак чәйнәделәр. Ә Рәгыйдә хакындагы гайбәт тагын да ямьсезрәк, аяусызрак иде. Нәкъ менә шулардан соң Бәһрәмияне шайтан икенче кабат алмаштырды да инде. Җанына усаллык, шәфкатьсезлек, миһырбансызлык тулып, үзенекен дә, Ильясның да җанын агулау кәсебенә кереште.

Юлдыбаев үзенең туган авылына клуб мөдире итеп җибәрелгәч, шул авыл китапханәсендә эшли башлаган Рәгыйдә бик каты чирләп киткән икән. Хәбәрләр аны һич кызганмый — диваналык чире, диләр, хыялыйга әйләнгән, имеш. Монысы — Бәһрәмия туглый торган пүчтәк хәбәр, яла. Икенче төрле әйткәндә, Ильяс Рәгыйдәне бөтен кешегә караганда ныграк белә. Театрсыз яши алмаганга боегудан башланган өметсезлек чире — иң төп сәбәп. Бүтәне — үпкәгә салкын тидерү дигәне, барыбер шуңа бәйле — яшәргә теләк беткәннән.

Шулай бик каты чирләгәч, Марат Юлдыбаев аны район больницасына алып киткән. Ильяс монысын да күз алдына җиңел китерә ала. Ашыгудан түгел (Марат кеше кызгана белми ул), бары тик усаллыктан, кайбер тойгылары һәм гамәлләре өчен Рәгыйдәне гафу итеп бетерә алмаганлыктан аның усаллыгы шулай ук чиргә, явызлыкка әйләнгән. Явызлык күп очракта кешенең үз башына була. Юлдыбай очрагы нәкъ шуның мисалы.

Ачуын һәм ярсуын басарга тырышып, куа ул атны. Кычкыра, дилбегәне атның авызы ертылганчы тарткалый. Дилбегә тарткалап кына җан ачысы басылмаганлыктан, чыбык белән, таяк белән кыйный.

Юлда Рәгыйдә аның хәерсез хәрәкәтләрен күрсә, сизсә дә, ирен акылга өндәрлек хәлдә түгел бит. «Нишлисең, ник шул хәтле ашкынасың?»— дигәнне ыңгырашу аркылы гына аңлатырга азаплана. Юлдыбаймы инде ымга игътибар итәр кеше. Аңа төшендерер өчен маңгаена сугып әйтү генә таман. Колагына да элми ул Рәгыйдәнең ризасызлыгын. Ашыктыра, куа бирә атны.

Шулай чаба торгач, таулы урынга җителә. Хәтерли Ильяс ул төшне, ким дигәндә бер чакрым җир — таулы юл. Таулы юлдан төшеп күпергә җиттем дигәндә генә каршыга автомобиль килеп чыга. Күпер төбе бит инде — ике якта биек юлдан читкә авып, арба-чанамы, машинамы аска тәгәрәмәсен өчен, кырык-илле метр арага ике яклап баганалар тезелгән. Менә нинди җирдә каршына килә машина. Машинадан өреккән ат кинәт бөтен көченә чаба башлый — ыргый, сикерә. Ат чаба, аңа каршы машина чаба. Машина гүелдәп узса да, ат тынычлана алмыйча, дулавын белә. Бер мәлне баганага килеп бәрелә дә, чана авып та төшә. Рәгыйдә җиргә егылып та кала. Юлдыбайның эш тагын да хәтәррәк — дилбегәгә эләккән ул. Муенынnанмы, ничектер, бүтән җиреннәнме. Шунысы хак, ычкынмый дилбегә. Ат чаба, ә дилбегәдән ычкына алмаган Марат өстерәлепме өстерәлә. Өстерәлә бирешли, юл читендәге баганаларга бәрелә. Ат авылга чабып кергән һәм хәле бетеп тукталган бер төштә карасалар, бәргәләнеп, суелып, канга батып беткән Юлдыбаевның инде җан әсәре калмаган...

Рәгыйдәне коткарганнар, больницага салганнар. Әмма ул инде терелерлек булмыйча, күпмедер вакыттан соң дөньядан барыбер киткән...

Күпмедер генә ай узгач, Манчаровский да алар артыннан ияргән, дигән хәбәр ишетелде.

Бу кешеләрне югалткач, Ильяс үзен алардан калышмагандай хис итте. Дөрес, болай ул исән сымак йөри. Әмма чынлыкта, ныклап тикшерә калсаң, исәнме икән? Әллә шулай тоела гынамы? Әллә ул да вафатмы күптән?

Һәрхәлдә, театр таралганчы яшәгән Ильяс инде юк, анысы кайдадыр еракта калды. Хәзер яшәп ятканы бүтән Ильястыр ул...

Бу хәлләр булып узганнан соң инде кырык җәй килеп, кырык кыш үтсә дә, алар — нәкъ кичәге шикелле — бөтен ваклыклары һәм нечкәлекләре белән хәтердә сакла624налар.

Менә шул иде бөтен тормыш.

Ә калганын яшәүгә исәпләп була микән?

* * *

Ул чактагы күңел ярсулары ярларына кире кайтты, әлбәттә. Ләкин моның белән генә чикләнә алмады шул. Күңел Базы елгасының үзе белән бергә коргаксыды, бергә кипте дисәң, дөресрәк булмагае.

Берничә елдан соң йөрәге, ни хикмәттер, авыл тынлыгында да тынычлык эзли, ялгызлыкка омтыла башлады. Ялгызлык үзе җан газабы. Бер карасаң, ялгызлык сагышы, кара сагыш, муенга чорналып, канның соңгы шатлыкларын агулый. Төннәрендә боздай салкынлыгы белән бергә куенга кереп ята. Бер генә көнгә, бер генә сәгатькә аерылып торса, аерым йокласа икән лә. Аны ничек ташлап калдырырга, ничек котылырга?

Икенчеләй, авылдашлар карашы җанны тырный: «Беләбез, беләбез, таныш җыр:

Сикереп суларга төшәрсең,
Янса яшь йөрәккәең».

Ә син яшь үк булмасаң да мәхәббәтең артыннан биек ярдан чынлап сикердең бит. Үзеңнең бик үк тулы түгеллегең исбат ителсә, фаш ителсә, Рәгыйдәң хыялыйлыгы бар тирә-юньгә тамаша кылынды.

Әйтерсең ки, бөтен дөнья карап, күреп торган! Менә нинди, менә ниләр эшли ул чыбыксыз телефон!

Бәһәрмиянең беренче өянәкләре шунда башланды. Өянәкләрнең башлангыч чорындагы кычкырыш-талашларны искә аласы килми. Булды инде, булды. Ходай ярлыкасын.

Тулаем алганда, күрәләтә мәсхәрәләү, мыскыллау кими төшсә дә, авылдашлар барыбер елмаебрак карый, ә Бәһрәмия, киресенчә, айга бер генә елмая. Шулай узды берничә чәнечкеле-тигәнәкле ел. Берничә елдан олы малай Зәкәрия армиядән йөреп кайткач һәм өйләнгәч, суга сикереп төшкән ярлардан бераз булса да ераклаша төшү өчен, телсез шелтәләрдән, мыскыллы карашлардан котылу өчен, яңа җирдә яңачарак яшәп, Бәһрәмиянең алама гадәтләрен онытттыру нияте белән, ярыйсы ук мәшәкатьле чара уйлап тапты Ильяс.

Базының аръягында, өч чакрым чамасы түбәндәрәк Әшмән авылында Зөлхәбирә җиңгәчәйнең күршесендә генә сугышка хәтле үк хуҗасыз калган бер кечкенә өй Ильясның үзе кебек үк моңаеп, ялгыз гомер сөрә иде. Ильяс шунда күчеп китәргә карар кылды. Бәһрәмияне күндерү тырышлык таләп итмәде. Чөнки өйләнгәч үк

яңа өй салып иза чиккәнче, яшьләр иске өйдә үзләре генә яши бирсеннәр. Яңа йортны ашыкмыйча, интекмичә генә салсыннар. Ә карт белән корткага исә картлыкны урман арасында адаштыру җае чыкмасмы.

Шул ниятләр белән күчтеләр.

Чынлап та монда тыныч иде — күренсә, елына бер генә тапкыр күренә автомобиль. Анда да Зөлхәбирә җиңгәчәйнең малайлары кунакка кайткан чакларда гына. Ягъни, һавадан хушбуй исләре генә аңкып тора.

Бәһрәмия, хәерсез, ул һаваны берничә ел гына бозмыйча яши алды. Ашыкмыйча — бәрәңге утыртып, кәҗә-сарык, каз-тавык үрчетеп — көйле генә гомер сөрделәр. Әмма тагын берничә елдан көтелмәгән үзгәреш тәки килеп чыкты бит.

Малай өй салырга әзерләнгән иде. Бүрәнәләрен, җиткелекле итеп, Череккүл урамына буратып та куйган иде. Ләкин башына икенче исәп төшеп, көннәрдән бер көнне ничәмә автомашина һәм трактор белән дөбер-шатыр барча шул бүрәнә-такталарны эти-әнисе янына китереп ташламасынмы. Алты почмаклы, клуб чаклы зур йорт салды Зәкәрия. Карт белән корткага да, үзләренә дә урын җитәрлек.

— Файдасызга гомер әрәм итмәгез әле, балаларга күз-колак булып яшәгез,— дип, эш беткәч, бер рәхәтләнеп көлде олы малай.

Кызлар бу вакытта кайсы кай якка таралышкан иде инде. Атап әйткәндә, калага тайган иделәр.

Шулай итеп, яңа урында да матур гына яшәп киттеләр. Зәкәрия монда да җир җимертеп эшли. Аллага шөкер, тракторчы бит ул. Тимер тәмен белгән кешенең дәрәҗәсе авылда зур. Бәхетле нигез булсын. Әйе. Ә шуннан соң?

Шуннан йорт җиһазлары арта барды. Ә бер мәлне түргә, иң дәрәҗәле урынга шкаф чаклы әрҗә — телевизор дигән әкәмәт менеп кунаклады, мин сиңа әйтим.

Әйткәнгә исәпләнмәсен, тапшыруларның төрлесен карадылар. Олысы, кечесе. Бигрәк тә — кечеләр. Алты яшь кенә тулган иянсәр (ягъни баланың кызы, урысча оныкчка диләрме?) Рәмзия иляләште — көн-төн дигәндәй, шунда утырыпмы утыра.

— Нәрсә карыйсың?— дигәч:

— Це кепеәсәс,— дип җавап бирә.

Икенче вакыт:

— Бер дә кызык әйбер түгел ләса, сүндереп тораек,— дигәнгә каршы:

— Барыбер карыйм, миңа димәгәе, хет Хрущев сөйләсен,— дип кырт кисте.

Шуннан соң өйдәгеләр эч пошканнан гына телевизор карасалар, үзләре дә: «Барыбер карыйбыз, кирәгем исә, хет гел Хрущев сөйләсен»,— дип көлә торган булдылар.

Кызыксыз тапшыруларның зыяны тимәде лә ул. Әйбәтләре харап итте.

Көлкеле спектакльләр караганда, Бәһрәмия:

— Кара син, ифрат килештереп уйнайлар,— дип сокланса да, бер көнне бөтенләй икенче төрле сукаларга керешге, мәгънәсез.

Көтелмәгән хәл: Казаннан «Ак калфак»ны күрсәтәләр. Беренчедән, Ильяс бабагызның башында исән калган егерме-утыз бөртек чәче үрә басса, шул хәлен сиздермәскә тырышып шыпырт кына карап утырса, ниндидер шом тойгандырмы, кара яктан аяк очларына гына басып, Бәһрәмиянең килеп кергән көне. Хәмдия белән Ильясның... Тфу, Хәмдия белән Бакыйның җыр турындагы сөйләшүләренә җиткәч кенә, шашкандай, бу кортка кинәт чәрелдәп кычкырып җибәрмәсенме!

— Ә-ә, сөяркәсен карап утыра икән әле! Ә-ә! Диванаң терелгәнмени? Менә ни өчен шымытырланып утыра икән. Миннән качып! Хыялый чибәре үлмәгән икән. Син мине юри алдаган булгансың. Җир бит, егылып үлгере, алдакчы, хәсис, башың беткере!

Шул сүзләр белән шалт иттереп, телевизорны ычкындырды да дөп-дөп атлап чыгып та китте. Күренгән саен, мин сиңа әйтим, янауларын, рәнҗүләрен туктатып кына да торасы итмәде. Кимерепме кимерде, ашапмы ашады Ильясның колак итен.

Уфф! Бар икән күрәселәр! Булмаган икән — Бәһрәмиянең явызлык чиреннән тәки качып кына котылып булмаган! Бетте баш, гүпчим начар эшләр. Болай булгач, гомерлеккә китте афәт!

Шуннан соң Ильяс хәтта телевизор да карамас булды. Дөньяның барлык яхшылыкларыннан баш тартты.

Өйдән котылып тору нияте белән Базы буендагы пионерлар җәйләвенә каравылчы булып керде. Кич китте, иртән кайтты.

Тагын бер шөгыле бар икән әле бабагызның — ике-өч сарыгы аркасында, җәенә ике-өч мәртәбә авыл көтүен көтәргә туры килә. Мал аз калгач, бу елларда көтүче яллаудан мәгънә юк.

Башка көннәрдә һаман бер төрле: ел фасылларына карап, бакча, ындыр мәшәкатьләре. Абзар-кура, киртә-койма ныгыта тору. Такта-токтаны Зәкәрия, аллага шөкер, таба! Һич булмаса, бүрәнәдән тактаны үзе яра. Әтисенә иң яраткан шөгыль тәэмин ителә — бигрәк тә койма кою, әрҗәдер-мазардыр ясау килешә аңа. Кул кәкрелеген онытып, көннәр буе шакылдатыр тактаны. Мондый чакта карт үзен яшь кеше сыман итеп, сәхнә коргандагы кебек итеп тоя. Кайдандыр, кайсы почмактандыр, сиздермичә генә, Манчаровский, Рәгыйдә карап тора...

Монысы — җан яшәеше, көл арасындагы соңгы кузларның сизелер-сизелмәс җылылыгы. Яктылыгы түгелдер, куз инде күмергә әйләнгәндер, кара төскә кереп бетә язгандыр. Кабатлап әйткәндә, монысы да күңелдә калганы гына бит.

Ә тышкы якта — икенче күренеш. Өйдәгеләр, авылдагылар, хәтта авылга кунакка кайтып китүчеләр дә Ильяс бабалары хакында сүз чыкканда, еш кына сәеррәк бәя бирәләр: «Яшәп ята инде, бернинди моңсыз, гамьсез,— янәсе.— Алай яшәп йөзгә җитүдән дә кызык юктыр», имеш.

Әлеге дә баягы, чыбыксыз телефон аша бу сүзләр картның үзенә дә ишетелгәли. Рәнҗеми карт: «Дөрес сүзгә җавап юк».

Җитмәсә, шул дөреслеккә Бәһрәмия:

— Чирләгән чакта чәй генә дә ясап эчерми,— дип, бәхәскә һич урын калдырмыйча, мөһер чәпәп куя.

Менә сиңа үзгәреш, һәм менә сиңа Хозыр Ильяс! Аның үзен дә шайтан алмаштырмаган дип хәзергесе вакытта кем әйтә алыр? Ильясы бар да, Хозыры кайда?

Мәгәр без онытып бетермик, шулай да Ильясның кайбер элекке гадәтләре сирәк-мирәк булса да, әле дә ялтырап-ялтырап куйгалый бит.

Бер елны Зөлхәбирә җиңгәчәйнең студент малае Әнис өйләнеп кайткан иде. Яшьләр үзләренең алма-шомырт бакчасындагы эскәмиядәме, караваттамы утыралар икән. Ильясларның чоланы ягыннан кемнеңдер гырлый-гырлый йоклаганы ишетелә. Шундый да тәмле һәм озак итеп көпә-көндез дә йоклап була икән, дип, шарык-шорык көлешә студент кавеме. Берничә сәгатьтән болар янына Ильяс абзыйлары кергәч тә көлүләрен дәвам итәләр:

— Әй, Ильяс абый, йокының кирәген бирдегез, симерттегез йокыны, ә?— диләр.— Гырлавыгыз шундый нәфис.

— Арттырмыйсызмы, балалар?

— Ким дигәндә, ике сәгать, чоландамы, өйалдындамы. Ну шәп тә гырладыгыз.

— Юк, чоланда түгел, өйалдында да түгел. Өй артындагы чирәмдә.

— Өй артында... җирдә йокладыгызмыни?

— Йокладыгызмы дип ни. Ул мин түгел бит. Зәкариянең карт дуңгызы бит ул.

Яшьләргә бу — менә дигән мәзәк. Рәхәтләнеп көлделәр. Ильяс үзе чәнти бармак зурлыгы мыегы астыннан көлемсерәп кенә куйды. Аны-моны сөйләшкән арада тузганакка күзе төшеп, карт шуңа игътибар юнәлтте:

— Күр син боларны — җәйге эсседә дә папахаларын салмыйча утыралар.

Моны ишеткәч, студент егет:

— Кара-кара, Ильяс абый, син сәнгать кешесе икән ләбаса!— дигән бәя бирде.

Хәерлегә каршы, дип уйлый Ильяс. Бәһрәмия дә, авылның башка кешеләре дә Ильяс сүзләреннән мондый нәтиҗә чыгара белмиләр. Белсәләр, тагын бер кушаматмы тагарлар, гайбәтме таратырлар иде.

Студентлар белән сөйләшү җиңел икән. Тиз аңладылар. Аңлашкач, карт үзенең хәтта иң яраткан, иң кадерле ядкареннән — кызыл тышлы китабыннан аерылырга ризалашты. Күпмедер елдан соң Казаннан: «Китабыгызны Татарстан Дәүләт музеена тапшырдык. Сугышта яраланган җәрәхәтле китаплар күргәзмәсенә куйдылар»,— дигән хәбәр киләчәк.

Менә шушындый вак-төяк кызыклар һәм кызыксыз уйлар белән уза көннәр, айлар һәм еллар. Инде гомер узды дисәң дә үпкәли алмассың.

Дөнья экәм-төкәм тизлеге белән булса да алга бара бугай, һәрхәлдә, үзгәрә тора. Көчле-куәтле кешегә тормышны яңадан көйгә китерергә, канат җилпеп карарга мөмкин, ахрысы,— ат сатып алырга, ат рәхәте күрергә рөхсәт бар. Ләкин инде хәзер кая барасың? Кая китә алсын йорт казы! Күзгә кергәч, канатланган була ул, кыр казлары артыннан китә күрмәсеннәр тагы, дип, курка язган чаклар да була хәтта. Әмма да ләкин кысыр хәсрәт тиз юкка чыга. Яңадан тап-тар ихатага тәпи-тәпи, тәпи-тәпи, сөенә-сөенә кайтып керерләр дә, гүзәл томшыкларын шакылдата-шакылдата, ялгаш суын эчкән булырлар.

Әйтерсең ки, бөтен ләззәтләре шул.

## Сигезенче бүлек

(СОҢГЫ ҖӘЙ)

Ерак нәсел-ыру яшәгән чишмәле ярларга һәм аннан ары елганың Рәгыйдә белән мәңгелеккә аерылышкан урынына күзләре яшьләнгәнче карап, Рәгыйдә хатирәсен саклаган карт өянке жуылдаганны күңеле тулганчы тыңлап, озак, озак басып һәм утырып торды Ильяс. Узган гомернең аккан су икәнен инде ничәнче кабаттыр, үз күзләре белән күреп ышанырга мәҗбүр ул. Әле кайчан гына Базы нинди киң иде дә, хәзер исә, аягыңны салып балакларыңны сызган да, чык та кит аргы ярга. Шулай, аякларны салыр идең, балакларны сызганыр идең дә, шапыр-шопыр чыгып китәр идең. Әмма чыгып ни бар хәзер? Анда сине кем көтә? Үз ярына Рәгыйдә чакырган чактан, яшь-яшь җәйдән соң әлеге карт җәйгә килеп җиткәнче кырык ел гомер узган. Яр белән яр, җәй белән җәй арасында кырык ел су аккан. Кырык ел!

Шуннан соң Ильяс карт менә инде кырык беренчегә таба елганың кайчандыр су алкынган коры үзәне буйлап атларга мәҗбүр.

Ач тамагың, тыныч колагың. Карт, төшкелеккә өйгә кайтмыйча, пионерлар җәйләвендә генә тәгам алырга тиеш тапты. Дөресен әйткәндә, тамактан ризык үтә торган көн түгел бит.

Җүләр куалаган Бәһрәмия кырык ел элек кысканга быел кычкырып, үзен дә, картын да адәм мәсхәрәсенә калдырды. Дивана сөяркә, имеш. Күрсәттең инде менә кемнең җүләр икәнлеген, бөтен авылга фаш иттең. Авызыңны шайтан ялаган нәрсә.

Көнләшә, имеш, берәүләр. Яман да кайнар итеп ярата диярсең. Чөрләгән карт тавык! Түш кайнарлыгына түзә алмый. Суынырсың да бер вакыт, һушыңа килгәч, үзеңә үзең хәйран калырсың. Инде суына ук башламадыңмы икән? Картың өйдә юкта чак кына булса да уйлана төшмәдеңме? Ә Ильяска юаныр әйберләр монда, җәйләүдә, табыла торыр. Менә шулай.

Балаларның чыр-чулап төрле уеннар уйнавын, йөгерешүен, сикерешүен, җырлавын, биюен һәм дә башка һөнәрләрен карагач, фикерләр чынлап та үзгәрә төшеп, тәнгә чак кына җан керде шикелле. Ул хәтта янә үзенең ерак яшьлеген күз алдына китереп куйды. Ләкин Ильяс сагынган балалар бу түгел шул. Болар, Ильяс бабаларыннан отып: «Барып кердем бер йортка, утыра анда бер кортка»,— дип җырламаслар. Болар әнә бөтенләй икенче төрле җыр җырлыйлар. Хәтта әтиләре-әниләре теле белән түгел, урысча. Болар нинди адәмнәр булып чыгар икән? Кешеме, иттән ясалган машинамы? Башка китерерлек түгел. Шулай уйлап, баш чайкый бабалары.

Бабалары алар белән бәйләнешкә кереп карамады түгел. Беренче елларда аралашырга хәтта бик тырышты. Әле узган җәйдә генә, иске гадәт буенча, бер литрлы банканы чүмәкәй тутырып җиләк җыйды да бертөркем балалар янына килде:

— Ягез әле,— дигән булды яшь чагындагыча ук, имеш, шаян кыяфәт белән.— Ягез әле, мальчиклар, йөгерешеп карагыз әле. Алдан килгәнегезгә ике уч тутырып җиләк бирәм.

Малайлар исә аптырап калдылар. Бик нык гаҗәпләнеп:

— Чауа, чауа,— диештеләр.

Арадан берсе картның теләген тәрҗемәләп аңлаткач та исләре китмәде:

— Шту за глупыс, шту за глупыс,— диешә-диешә, үзләренең тупларын куа-куа ары китеп бардылар.

Авылның үзендә исә йөгерешерлек малайлар гомумән юк. Пенсионерлар авылында сабыйлар тавышы ишетсәң, белеп тор — кемнеңдер улы яки ияннәреме кунакка кайткан дигән сүз.

Бүләк кабул итәрлек балалар аның үз өендә генә инде — әлеге дә баягы иянnәре һәм Бәһрәмия әбиләре. Алар рәхмәт әйтә-әйтә җиләкле чәй эчтеләр.

Бу юлы да Ильяс карт җәйләүнең төп йортына (матур кирпеч йорт — ашханәләре, кунак бүлмәләре, мунчалары — бөтенесе бер түбә астында), әйе, җәйләүнең төп йортына килешли, шундый ук сәер күренешкә тап булды.

Өйдән ерак түгел, ком җәеп ясалган киң сукмак аркылы, ашыкмый-нитми генә, йоннары майланган күндәй елкылдап торган бер тычкан узып бара. Ике-өч метр гына ераклыкта шул тычканны күзәтеп, мәһабәт гәүдәле мәче утыра. Ильясны күргәч, мәче, тәпиләре-тырнаклары белән тычканны эләктергән ишарә ясап, кабат-кабат мыяулап куйды. Шул кадәр ямансу тавыш белән мыяулады, хәтта аңа карау кызганыч иде.

— Мыяу, тотып бир тычканны, тотып бир, мыяу!— Янәсе...

Тиешле кешеләр гафу итсеннәр, иллә мәгәр Ильяс бу җәйләүдәге балаларның күбесен әнә шул тук мәче рәвешле итеп күрә. Бу ба-

лалар Дүртөйле театрын ник яптыгыз, дип, моны фаҗига дип кабул итмәячәкләр. Колакларны иркәләп быргы тавышы яңгырыймы? Яңгырый. Ашханәдә ризык туярлыкмы? Туярлык. Эстафета дигән йомышсыз йөгерешләре, әллә нинди эшләр башкарган кебек рапорт бирүләре, туп артыннан акыра-акыра чабулары күңелләрен күтәрәме? Күтәрә. Шулай булгач, сиңа тагын атаң башы кирәкмени? Кирәкми. Шулай дәвам итегез. Эшләнмәгән эшләр өчен зурайгач та рапорт бирә килсеннәр. Иген һәм терлек үстермичә генә, калҗаның иң майлысын эләктерергә өйрәнсеннәр. Өйрәнми калучылар булса, оста итеп урларга, таларга керешсеннәр. Менә шулай.

«Бер әйттем, биш кайттым. Тәүбә, тәүбә. Кая барып чыгарбыз, ходай белсен».

Димәк, өйгә кайтмыйча тагын булмый.

Бәһрәмия бәлки тынычлангандыр инде. Әйдә, ул да адәм баласы бит — карт ник югалды дип, нишләп кайтмый дип борчылмасын, кайгырмасын.

Бәһрәмия игътибар итсен өчен, махсус рәвештә тамак кыра-кыра кайтып кергән булды. Шулай да өйгә үк узарга кыючылык итә алмады.

Кортка үз гаебен йомшартыр өчен берни булмагандай елмаеп чыгар да чәйгә чакырыр әле дигән өмет белән Ильяс абзар-кура тирәсендә әйләнгәләде. Мәгәр өмете акланмагач, рәнҗүдән һәм Рәгыйдәне моңарчы булмаганча җилкенеп сагынудан туган яңа бер теләк белән югары очка менеп китте.

Фәтхелислам урам як утыргычта авыз киереп иснәп утыра иде. Ильяс күренгәч, йокысы ачылды. Карчык-корчык сыер савып, чәй әзерләп өйгә дәшкәнче, акыл иясе белән тел үткерли торырга исәпләп өлгерде бугай. Иртән күрешкән булуларына карамастан, торып, куш куллап исәнләште. Мәгәр икәүләп яңадан утыргач, гәп хәләхвәл сорашудан уза алмыйча интектерде.

Кәмитче даны йөрткән кешенең ык-мык утыруыннан сәерсенгән Фәтхелислам сорауны турыдан тотарга мәҗбүр:

— Кәефең юк димме, Ильяс агай?

— Кәеф табылырые ла ул.

— Ә ни табылмас?

— Ат.

— Ат?— Көтелмәгән сүздән отыры гаҗәпләнгән Фәтхелислам читкәрәк тайпылып куйды.— Әллә синең дә ат алыргамы исәп?

— Исәбе булырые, вакыты бетте, Фәтхелислам.

— Бетте дип, әкәмәт. Атна-ун көн җиткән аңа. Бөтенесе йөз таңкә кирәк.

— Минем атна көтәргә дә вакыт бетте бит, Фәтхелислам.

— Яле, Ильяс агай, бармакка чабата кайтарып утырма.

— Миңа ат бүген кирәгие шул, Фәтхелислам. Бүген димәсәң, иртәгә.

— Ә-ә, шулай дигән аны, атыңны биреп тор әле диген. Нишләмәк буласың ат белән?

Ильяс сер иде шул дип караса да, Фәтхелисламның кызыксынуын туктата алмады. Дөресен әйтергә туры килде. Фәтхелислам егет кеше, рәхәтләнеп риза булды. Ильяс әллә шул сөенечтән, әллә һаман хатынга рәнҗеше сүрелмәгәнлектән, үз өен узып, туп-туры пионерлар җәйләвенә юнәлде. Төнлә җәйләүне кабат-кабат урап, шулай ук җидегән йолдыз да җиде әйләнеп күк түбәсенә күтәрелгәч, йокыга ятты. Һәм, әйтергә кирәк, сандугачның беренче тавыш калтыратулары белән уянып, уңга-сулга тайпылмыйча, югары очка ашыкты.

Фәтхелислам, рәхмәт төшкере, атны үзе җигеп, печән салып, басу капкасыннан чыгарып ук җибәрде.

— Атны бик йончытмаска кара, Ильяс агай.
— Үз көебезчә булыр, Фәтхелислам. Йә, булды, мең яшә.
— Үзең исән йөр, Ильяс агай, хәерле сәфәр.
Әмма турысын әйтик, сәфәрне хәерле булды дисәк, дөрес үк була алмас иде. Очы-кырые күренмәстәй тоелган, утыз чакрымлы, өч сәгатьлек юл бер мәртәбә: «Аh!» — дип кычкыруга сыйды. Чиксез дигән уйларын җыйсаң, чәнти бармакка чорнарлык фикер чыкмагандыр. Базы буеннан Яубазы дигән кечкенә елгага җиткәч кенә бәләкәч бер мәгънә укмаша язды шикелле. Базы ягында туган кешенең Яубазыга таба ашкынуында ходайның үз әмере сизелә иде кебек...

Арбадан Ильяс шундый фикер белән төште.
Базы, Яубазы... Бер-берсенең барлыгын белеп аккан ике елга Агыйделдә очрашкач, бер-берсен таныйлар микән?— дип уйлады ул.
Рәгыйдә Ильясның нинди хисләр белән яшәвен белми китте. Ильяс Рәгыйдәнең илаһи зат икәнлеген белеп яшәде. Мәгәр мондый белемнән ни файда? Рәгыйдә уй белән генә барып җитү мөмкин булган ерак фикер иде һәм шулай булып калды бит. Хәзер инде исемнәр генә якынайта: Базы, Яубазы...
Кайдадыр тагы Талбазы бар бугай. Исеме бар, елгасы юк...
Мәгәр өч матур исем бер дә юкка очрашмагандыр, алар бер тамырдан яралган кардәшләрдер. Ерак заманнарда тәкъдир кушуы аркасында гына аерылышканнардыр. Сагынышып яшәгәннәрдер. Алар сагышы Ильяс белән Рәгыйдәгә мирас сыйфатында күчкәндер. Димәк, адәм хисләре — табигатьнең үзеннән.
Барып җитә алмаслык тоелса да, менә җителде бит әле. Рәгыйдә шушында ул, Яубазыдан ерак түгел тын зыяратта. Зыярат эчендәге агачлар шавын, тормыш сулышын ишетеп, тыңлап ятадыр.
Зыяратка йөз метр чамасы җирдә Ильяс атын тугарып арбага бәйләде. Аллага шөкер, печән мул, ашыкмый гына яшел тәмне рәхәтләнеп кетердәтсен Фәтхелисламның сөекле аты. Ильяс бабагыз Рәгыйдә исемле гүзәл кыз каберен табып, йөрәк сүзләрен әйтсен, туйганчы фикер, хис алмашсын.
Шундый ният белән зыярат эченә керде карт. Кабер саен туктальп, кирәк исемне танырга тырышты. Эзләде, озак эзләде. Бер сәгать, ике сәгать эзләде. Таба алмады. Кабер ташларындагы узган гасыр исемнәрен укый алса да, хәзерге заманныкыларын тану кыен иде. Бигрәк тә — яңаракларын. Күбесенең өстендә агач, казыклар гына басып тора. Аларга исемнәр язылган булгандыр, ләкин хәзер эзләр дә калмаган инде.
Иске һәм яңа каберләрне күпме генә төпченеп күздән кичермәсен, якын исемгә тап була алмады. Аптырагач, Юлдыбаев Марат исеме юкмы дип йөренде. Андый юанычны да артык күргән икән ходай. Әйләнгәләп йөри торгач, картның үз башы әйләнә башлады. Барча уй-хисләрне ачы сөрем күмде. Хәлдән тәмам тайган карт зиһенендә уй түгел, бер генә сүз калды: «Рәгыйдә, аваз бир,— кайда син, Рәгыйдә, Рәгыйдә!»
Бердәнбер сүзне уйда кабатлап, зыярат читенәрәк чыкты. Бу төштә койма бөтенләй җимерелеп юкка чыккан икән. Каберләр вак-вак түмгәкләргә әверелгәннәр. Маллар йөри, димәк. Ә Рәгыйдә? Рәгыйдә дә шулай тапталган булса?
— Рәгыйдә, Рәгыйдә, Рәгыйдә!
Исемне эчтән генә әйткәндәй тоелса да, чынлыкта ул кычкырып уйлаган икән.
— Аһ-ай, әллә шашкан инде ходa бәндәсе?
Барча үкенечләрне мәсхәрәләгәндәй, гыжылдавык тавыш ишетелде. Аның иясе — таяк таянган ак бабай.

— Кемне эзлисең, алла бәндәсе? Акылыңа зәгыйфьлек килдеме әллә? Нинди Рәгыйдәгә кычкырасың?
— Нинди дип, шуны да белмәскә. Рәгыйдә, атаклы артистка. Шуны эзләвем. Каберен дијуем.
— Әртиске дисеңме? Анысы кем соң тагы?
— Соң инде, авылларда театр куеп йөри торган изге җан. Шуны да хәтерләмәскә теге.
— Һеһ, хәтер инде ул — төпсез иләк. Сиксәннән ашкан адәмнән әллә ни көтмә. Үзем дә кортканы көчкә-көчкә табам.
— Соң инде, иманлы халык зыяратны шушы хәлдә тотамы?
— Тота. Элекке түгел бит халык — үңгәрде. Кыямәтне онытты, бер нәстәдә гаме юк, ашарга булсын, эчәргә. Дөнья үзе нык үңгәрде.
Нишлисең бит, шул рәвешле, очы-кырые күренмәстәй тоелган утыз чакрымлык юл бер сәер сүз белән очланды: «Үңгәрде, халык үзе үңгәрде...»

• • •

Юллар очлангач, Ильяска кырлы-урманлы сукмаклар калды. Базы буена илтә торган тын сукмаклар.
Эх, дөнья, дөньялар!..
Узды гомер, узды китте буш арбадай шалтырдап.
Моның өчен кемне гаепләргә?
Үзенме? Бары тик үзен генәме?
Алай дисәң, авылның барча кешеләрен кара — иң шәп яшәде дигән Фәтхелисламны. Нәрсә күрде алар үз гомерләрендә? Үз гомерләрендә Рәгыйдәләре булу мөмкинлеген башларына китерә алмауларын әйтәсе дә юк. Хәтта менә шушы пионерлар җәйләвен каравыллау да теләсә кемгә тия торган бәхет түгел ләбаса! Барысы да — Ильяс та, Фәтхелислам да, бүтәннәр дә заман ни кушса, шуны үтәделәр. Чәчтеләр, урдылар, сугыштылар, үлделәр, ачлыктан җәфаландылар. Шулай булгач, кемне гаепләргә?
Заман, заман гаепле, дип уйлый Ильяс. Безнең гасыр... Егерменче диләрме әле? Әйе, егерменче гасыр алдакчы булып чыкты. Егерменче гасыр безне алдады. Ходай кушып, сезнеке, егерме беренчесе шәп булсын, алдамасын. Ильяс бабагыздан сезгә фатиха менә шул.
Сабый чакта һәм аннан соң нәрсәгәдер омтыла адәм баласы — мәгънәгә, максатка, идеал дигәннәренә. Ильяс та шулайрак яши башлаган иде. Яшьләй үк аны алга чакырды ат, аннары мәхәббәт, гаилә... Аннан? Аннан соң мәхәббәттән көчлерәк тойгы барлыкка килде — Рәгыйдә, Хәмдия, Галиябану... Гомерлек хыял! Дөньяда аны иң авыр чакларда да шул тойгы исән саклады.
Кешеләр аны аңламадылар. Ильяс тел белән әйтеп бирә алмаган изге хисне гади көнкүреш мәхәббәте белән бутадылар. Хакыйкать башкача, бик тә башкача иде бит. Эх, дөнья, әх син, гөнаһлы дөнья! Нишләп син болай Ильяс өчен ят булып чыктың соң әле?
Үзең шундый чиксез киң, бай, матур. Ә кеп-кечкенә адәм баласына үзе теләгәннең чиреген дә бирә алмыйсың...
Әнә бит, нинди күңелле, рәхәт, назлы яфрак шыбырдавына шыксыз, шөкәтсез, мәгънәсез авазлар кушылып колакны рәнҗетә:
— Карга алып киткән аксак чебеш өчен шул чаклы гауга куптаралар димени? Ай-һай да саранлык була икән шул чаклы.
— Эш саранлыкта гына булса икән,— дип, хәтердәге авазга үз тавышы белән җавап бирә Ильяс карт.— Хикмәт һич тә саранлыкта гына түгел, ә саңгыраулыкта, сукырлыкта, җансызлыкта. Җанлы, аңлы кешегә үзе бер кызык лабаса. Карга, карчыга, тилгән чебеш

типми торамы? Бу бит тормыш үзе шулай корылганлыкны күрсәтә торган мисал лабаса.

Шулай дип уйлый Ильяс. Уйлыймы? Әллә төш күрәме? Икесе бергә — уй төшкә тоташа. Күктә ала карга пәйда була. Ямаулы карга. Аңа да җир йөзендә бик үк фарт килмәгән. Ходай карганы башка матур бизәкле кошлардан, хәтта кара каргалардан һәм чәүкәләрдән дә соңрак ятратканга күрә, кара төс җитми калган аңа. Буявы җитмәгәч, ходай төрле төсләр — нигездә кара һәм күк төсләрне берберсенә өстәп буяган. Шулай барлыкка килгән ала карга, ямаулы карга...

— Каррр, карр, каррр!

Бик тә якыннан ишетелә матур яңгыравыклы аваз. Кыр буендагы иң биек каен башына кунган да, бөтен киңлекне карашына сыйдырган хәлдә, ерак-еракларга ишетелерлек итеп, җаннарга яшәү дәрте өстәп кычкыра ямаулы карга:

— Карр, карр, алда бәхет бар, барр, барр! Карр!

Ләкин ул хәйләкәр. Кай арада үз биеклеген, кыр киңлеген калдырып, авылга килгән дә Ильяс картның күз уңында гына торган чебешен эләктереп тә киткән. Әнә ул инде югарыда. Чебеш аның тырнакларында тиберчинә. Ә чебеш дигәне... Чебеш дигәне икенче караганда бөтенләй чебеш тә түгел икән. Чебеш дигәнең кеше икән — чибәр, гүзәл хатын-кыз! Кара, ныклабрак кара, күз әчетә дип торма — кара һәм таны! Һәм карый Ильяс, карый, күрә, таный. Аждаһа чаклы ямаулы карга тырнакларында аның иң матур хыялы, гомер максаты, яшәү мәгънәсе тиберчинә лабаса! Ямаулы карга шуны, шуны — Рәгыйдәне, әйе, әйе, Рәгыйдәне күтәреп киткән лабаса!

Карт бастырылып — арган, талчыккан хәлдә уянып китсә, күзгә инде кояш яктысы төшкән икән. Хәтта җылысы да шактый сизелерлек. Күз алдында — яп-якты дөнья. Шулай да күңелдә — югалту, курку хисе. Югалту авырлыгы уянгач та бик озак басылмый торды.

— Уфф! — дип, күзләрен сыйпады Ильяс карт.

Ул да түгел, якында гына быргы тавышы яңгырады. Шау-шулы, чыр-чулы тормыш дәвам итә дигән сүз.

Җәйләү тирәсен әйләнеп чыккач, елан таулары дип йөртелгән яшел тау һәм саз сукмаклары аша авылга таба атлап китте.

Җир өстендә япь-яшь җәй тантана итә иде.

*1989—1990*

# Рөстәм Сүлти

## Җырым минем

Җырым минем,
кылларында —
Итил шавы,
Чулман шавы,
Болгарымның гөлләр чагы,
Казанымның гөрләр чагы...

Чулпы чыңы.
Чулпы чыңы...
Чулпы чыңы —
Сокландырган юлаучыны.

Сөембикә сулкылдавы,
Туп-туп тояк тупырдавы,
Манаралар аһылдавы...

Богау чыңы.
Богау чыңы...
Богау чыңы —
Сискәндергән юлаучыны.

## Чик кирәк

*Союздаш республика статусы алу өчен чит илләр белән чиктәш булу кирәк. Шул исәптән Татарстанга да...*

Мәскәү хәбәрләреннән.

Чик кирәк шул, әйе,
Чик кирәк.
Бу кадәр җәбер-золымга
Чик кирәк шул, чик —
Бик кирәк.

Чик кирәкме? Искә төшсен
Болгар-йортым чикләре,
Алтын Урдам чикләре,
Казан-илем чикләре...

Тирбәлүдән мәхрүм бүген
Татарның бишекләре.
Кысан, тынчу зинданымның
Ачыгыз ишекләрен,
Ачыгыз ишекләрен!

---

**Рөстәм СҮЛТИ** *(1969)— яшь шагыйрь, шигырьләре көндәлек матбугатта күренә килде, журналыбызда беренче мәртәбә басыла. Казанда яши.*

## Сукырлык

Дөнья тулы сукыр, җиһан тулы сукыр,
Кем соң Хакыйкатьнең әлифбасын укыр?!—

Хәрефләрен күккә сыза гарьчел яшен,
Күтәрелеп өскә кара әле, Кешем!

Шәкертләре сукыр — телсез мөдәрриснең,
Җәзалары каты, һай, күпме дәреснең...

Кемнең күңел күзе, кемнең маңгай күзе,—
Югала ник җирдә адәмнәрнең эзе?

Карга күзен карга чукымаган чакта
Бәндә күзен бәндә чукып сукырайта.

Дөнья тулы сукыр, җиһан тулы сукыр,
Кем соң Хакыйкатьнең әлифбасын укыр?!.

## Шагыйрь гомере

Язылды
акбур белән
Түбә башларына —
үзе язды...

Язды
нурлар белән
Йөзек кашларына —
яры язды...

Язылды
алтын белән
Кабер ташларына —
Оста язды...

Язылды
җырлар белән
Халкы йөрәгенә —
Үзе язды.

Язылды
гомере буе
Югалтмыйча төсен —
Бер үк исем!

## Дуэль

Пычак белән арттан кадыйсың шул,
Байтак җаннар сиңа бит баш ия...
Мин дуэльгә дәшәм сине бүген,
Мин перчатка ташлыйм, әй, Мафия!

Тик бергә-бер, көчләр тигез булсын,
Күзләремә кара тик туп-туры.
Дуэльләрдә көрәш гадел була,
Дуэльләрдә көрәш изге, тугры!

Багармын да кара йөрәгеңә
Пистолетның кара мушкасыннан...
Син атарсың мине... Дымык җиргә
Авармын мин япь-яшь Пушкин сыман.

Тик, Мафия, рәнҗеп үләрмен мин,
Мәкер-хәйләләрең аңлый-аңлый.
Секундантны сатып алырыңны
Белә алганмыни соң мин-сабый!..

А, юк инде! Көрәш гадел булсын,
Тапталмасын Намус, Әхлак йөзе.
Мин дуэльгә дәшәм бүген сине,
Секунданты булсын Хаклык үзе!

## Соңгы очрашу

Күзләреңдә ай шәүләсе яна,
Мөлдер-мөлдер тама аннан җиргә.
Аңлыйм, әйе... Соңгы күрешү бу,
Без соңгы кат икәү бүген бергә.

Китәсең дә мени, Сарбай, бәгърем,
Җиттемени гомрең соңгы чиккә?!
Эт халкының гадәт-йоласымы —
Үлер өчен йорттан китә читкә.

Әйтә гүя: «Чылбыр-бәем чыңын
Отып алган һава... Кыен монда».
Хөр үлемне өстен күрсәң дә бит,
Канлы каеш эзе муеныңда.

Адәм дә бит сезнең кебек, дустым,
Йөрәктә тик... каеш эзе генә.
Чит җир эте булып гомер сөргәч,
Сагыш җиле үтә үзәгенә —
Кайтып үлә туган эргәсенә.
Нигез ташы — иң-иң йомшак мендәр.
Сезнең халык китә...
Ә кешеләр
Кайтып үлә дистә, йөзләр, меңнәр...

Башка чакта хет төн ката булсын,
Тансык иде сиңа минем сүзләр...
Китәсез дә мени бөтенләйгә,
«Бәхил бул» дип мөлдерәшкән күзләр?!

## Кыйтга

Ут үрелеп алгач йолдыздан
шәмемә,
Төнге күбәләк тә чумды үз
гаменә.
Зыр-зыр килеп шәм очында
бөтерелде —
Йолдызның бер мәгъшугы
янып үлде.

## Гөл гомере

Кеше туса да — гөл, кеше үлсә дә — гөл,
Гөлләрнең дә бит, гомере ике түгел.

Гамьсез дә соң дөнья... Үзем гамьле юләр,
Гөл каберенә салам кочак-кочак гөлләр...

## Гөнаһлы алиһә

Барсың, берсең, бердәнберсең...
Алиһәм!
Сине бар иткән аллама рәхмәт,
Сине бар иткән аллам кичерсен.
Тәһлилемне[1] яулап алдың ул алламнан —
Барсың, берсең, бердәнберсең.

Юк, кичермәс алла! Һәм сине дә...
Тәмуг безгә!
                    Булмагае, дисең?!
И, гөнаһлы алиһәм син минем,
Бар син, бер син, бердәнбер син!

## Әлфирак

Барасы юл, һай, ерак,
Сүнсә кулда шәм-чырак,
Ясиның чык, ай-урак,
Җан — югары, тән — түбән,
Әлфирак[2] аһ, әлфирак!

Җан — югары, тән — түбән,
Мин — йолдыз, болыт, үлән...
Сүнеп, корып югалсам —
Ясиның чык, ай-урак,
Әлфирак, аһ, әлфирак!

---

[1] Тәһлил —«бер алладан башка алла юк» дигән гыйбарәне кабатлау.

[2] Әлфирак — аерылу.

# **Фәрит Яхин**

⁂

Тормыш, тормыш...
Тыныч агыш белән
Диңгезгәме, кая агасың?
Хәтта мескеннәрдән син, көн килеп,
Ир ясыйсың, йә ил агасы...

Без — кешеләр, яшәү өчен килеп,
Көенеп йә көлеп, бу җирдә
Сукалыйбыз тормыш буразнасын,
Авыр йөкне йөртеп һәр индә.
Арада бар ул да — хәйлә белән
Җиңеллектә көнен күрүче,
Җае килсә, оят диеп тормый,
Синең иңгә килеп менүче.
Ирләр булыйк, баскан һәрбер җирдә
Балкып калсын безнең эзебез,
Без — бәхетле! диеп әйткән чакта,
Калтырамас булсын сүзебез.
Ваклыклардан мең кат биек торыйк,—
Йолдыз иркендә, без югыйсә!
Тормыш, тормыш... Бала йонын өтеп,
Әкрен генә суык җил исә!

⁂

*Тотмый» безнең базар*
*Сатылмаган товар...*

Ал! дип килгәнегез юк,
Бир! дип киләсез һаман.
Монсы булмаса, тегесе
Сезнең йөзгә бик таман
Икәнен дә мин беләм.
Безнең диварлар ялангач,
Ә сезнеке — чат келәм...
Бир! дип киләсез һаман.

## Үсеш

Җир баласы тау идем,
Дәрья суыдай идем,
Җилләр чыгып, күпереп,
Бар дөньяны тутырып
Кайнар һәм шашар идем,
Дулкыным каплар идем.

---

Фәрит ЯХИН — *галим, филология фәннәре кандидаты, шигырьләре «Идел» журналында, «Яңа аваз» газетасында дөнья күрде. Казанда яши.*

Жир-Анама тисәләр,
Тәнем белән калтырап,
Чайкалып китәр идем,
Ташларым сибәр идем...
Татар булып яшәдем,
Татар булып торамын,
Тотар кулым киселгәч,
Әйтер телем өзелгәч,
Диңгезем башкаланды:
Тынды, тәмам сай калды,
Тау-ташларым күмелде,
Очкын күзем сүрелде...
Сөяк бирсәң — кимерәм,
Калҗа бирсәң — симерәм,
Дошманыңа мин өрәм,—
Эт хезмәтендә торам!

❀

Заман сыкрап кына алга күчте,
Иске җирдә калды хәрәбә;
Элладаның кара кашларына
Гашыйк булу тойгың — әрәмгә...
Барсын кичте: мең ел эчендә бит
Мең төрлене күрде замана.
Бөтерелде кырлар буйлап җилләр,
Үкси-үкси көннәр яңара...
Элладаның кара кашлары да
Төрки кочакларда эреде,
Табып була микән бу дөньяда
Саф көенчә калган ыруны?!
Зур шәһәрләр тетрәп торыр иде,
Дала аты кешнәп куйганда,
Диңгезләргә түгелеп төште еллар,
Дан артыннан ирләр куганда.
Гасырларны гасыр алмаштырды,
Озын чорлар кыска тоелды...
«Вәхши» Дала «бөек» Европаның
Итәгенә килеп егылды.

## Күңел ачкычы йөртүчеләргә

Саз чалып, дуслар алдында
Җырладым, тыңладылар,
Күзләреннән яшь агызып,
Моң белән аһ ордылар.
Диделәр:— Нигә моңарчы
Син бездән ерак йөрдең?
Наз-сагыш ямен, өләшеп,
Ник хәзер генә бирдең?
Һәм әйттем гафу сорап мин:
— Үзегез башкача бит!
Моңлының күңел ишеген
Изге теләк ача бит!
Сез бүген — башкача бит...

# Фердинант Шәехов

*Фердинант Галиәскәр улы Шәехов 1937 елда Татарстанның Әгерҗе районы Кызыл Яр авылында туган. Иж-Бубый мәктәбендә урта белем алган, Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган. Аннан соң төрле урыннарда җаваплы эшләр башкарган. 1967 елда авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы буенча Әгерҗе район авыл хуҗалыгы идарәсенә баш инженер итеп күчерелгән. Ләкин анда озак эшләргә язмый, бәхетсезлеккә очрап, 1968 елда ул сукыр кала.*

*Хәзерге вакытта ул Алабуга шәһәрендә яши һәм эшли.*

*Аның шигырьләре 1990 елның сентябрь аенда Язучылар берлеге каршындагы әдәби консультация бүлегенә керде.*

*Бүлеккә кулъязмалар еш килә, күпчелек очракта аларны укып кәеф кырыла. Кулъязмаларда әдәбиятка артык җиңел карау, каләмдәшләрең белән санлашмау — аларны кабатлау күп була, татар әдәбиятына яңалык бирергә омтылу тоелмый.*

*Фердинант Шәехов шигырьләре укучы күңелен җәлеп итә алыр дигән уем бар. Ул тормышны үзенчә аңларга, үзенчәлекле тавыш белән тасвирларга тырыша. Кулъязмасында шигырьдән-шигырьгә осталыгы камилләшә. Әлегә каләм төртер урыннары булса да, фикерләвендә авторның үз дөньясы, шуңа күрә бу шигырьләрнең үз күзе бар, диясем килә.*

Рөстәм МИНГАЛИМ

## Йолдыз булып...

Якты язда кушылып-шаулап акты
ташкыннары безнең хисләрнең.
Янып торды, безгә бәхет юллап,
йолдызлары айлы кичләрнең.

Ник соң сүрелеп калды ярсу җилдә
мәхәббәтнең тәүге балкышы?
Нинди таулар кичеп кавышырга
куша икән безгә таң кошы?

Көн дә сине сагынып юксынудан
күңелем канатларын моң баса.
...Йолдыз булып очам күкләреңә,
сөю утың минсез янмаса!

## Әтәчләргә мәдхия

Яшәү дәртенә хушланып,
сизә күңелем кыллары:
авылларда сузып-сузып
әтәчләр кычкырганын.
Кушыла шул гап-гади моң
шатлыкка, сагышларга...
Бала йоклаган тынлыкка,
җил искән тавышларга.
Дәртле аваз үтә иңләп
шау иген басуларын:
кузгатып безнең күңелдә
дәртле хис ташулары...
Әрәмәләр, кырлар аша
төннәрен, көндезен дә
эндәшә авыл авылга —
әтәчләре телендә...
Адашсам да ялгыз калып
кышкы карлы төннәрдә,
чакырып алды әтәчләр
җылы, якты өйләргә.

Мәңге тугры таң сакчысы
кояшны каршы алып,
ялгады көннәрне чорга
кычкырып, канат кагып.
Якты күңелләр күгендә
күңелле моң тирбәлә.

Уянсын, әйдә, шул моңга
Җил шары һәр иртәдә.
Әтәчләрсез ил юк Җирдә:
байрак төсле кәпәчләр;
чакырсыннар,
озатсыннар,
яшәсеннәр әтәчләр!

## Мәдинә күле

Мәдинә күле камышлы,
камышлы күл сагышлы.
Камышларның сагышында
ерак еллар тавышы:
«Әйдә, дуслар, барыйк әле
Мәдинә күлләренә.
Мәңге онытылмаслык булып,
кердең күңелләремә!»
Сугыш елларыннан бирле
күл йөртә бу исемне.
Мәдинә исемен күлгә
кемнәр куйган дисеңме?
Сабый идем мин ул чорда,
шуңа белмим әллә ни.
Бу турыда миңа соңрак
сөйләгән иде әни.
...Печән өстендә киттеләр
ирләр илне сакларга.
Калды бар эш үсмерләргә,
хатыннарга, картларга.
Картлар әзер чүкергә дә,
янарга да, чарларга...
Хатын-кызлар йөгерешә
таңнан печән чабарга.

Без бакалы күл ягында
тирләп, янып эшлибез.
Кипсә дә тамакларыбыз,
бакалы су эчмибез.
Мәдинәнең чалгысын гел
тешсез Гыйльметдин яный.
Ни өчендер Мәдинәгә
бакалы су да ярый:
ни өчендер сагышлы җан
тыя алмый ярсуын;
рәхәтләнеп шуңа эчә
без эчмәгән күл суын.
...Мәдинә күле камышлы,
камышлы да сагышлы:
Мәдинә үзе дә күптән —
ерак еллар тавышы...
Моңнарын ерак елларның
искә алып — тавышын,—
ни өчендер, әкерен генә,
җырлый карт авылдашым:
«Әйдә, дуслар, барыйк әле
Мәдинә күлләренә.
Мәңге онытылмаслык булып,
кердең күңелләремә!»

# Нәҗибә Сафина

## Егет җыры

Әллә каян килеп кердең
Кояшлы балачакка.
Җитен толымнарын сибеп,
Йөгердең кайсы якка?

Әйләнеп карамадың,
Әйләнеп карамадың.
Йомшак җитен чәчләреңне
Күрдем җил тараганын.

Толымнарың белән җанга
Юллар салгансың икән.
Шул юллардан яшьлегемә
Кереп калгансың икән.

Әйләнеп кара әле.
Әйләнеп кара әле:
Мәхәббәтем шул юл буйлап
Һаман да бара әле.

Толымнарың инде хәзер
Җитен түгел, кар икән.
Тагын очрашты карашлар —
Чын мәхәббәт бар икән.

Әйләнеп кара әле.
Әйләнеп кара әле:
Күңелемдә һаман да син,
Син салган яра әле.

## Яшенле мәхәббәт

1.

Сукыр кура, кем дә булмас...
Кердем ташландык йортка.
Ялт итте яшен яктысы.
Аһ, өметләрем — юкка...

Синең йөзгә, күзләреңә
Мин карап тордым шашып.
«Юлаучы йә угрымы ул
Кергән яшеннән качып?»

Килә-китә яуды яңгыр.
Сукыр йортта сукыр төн...
Күпме еллар төн яшәгән
Йортка шәм кабыздың син.

Шәм янына икебез дә
Килдек без якынрак.
Шатлыгыннан елый-елый
Янды шәм балкыбрак...

2.

Шәм яктысы. Син дә миңа
Карап тордың уйчан гына.
Таң алдыннан кочагыңнан
Чыгып киттем — кыз чагымнан.

Чалт аяз көн. Елый-елый
Сүнеп барган шәмнән түгел,
Без кояштан, көннән качтык...
Сукыр йортның күзен ачтык.

---

Нәҗибә САФИНА — *яшь шагыйрә, шигырьләре көндәлек матбугатта басыла килде. Казанда яши.*

## Шул чагында, бәлки...

Аклыкларга аклык өстәп кенә
Коелалар карлар.
Күңелемдә эремичә калган
Ак кар таулары бар.

Салкын саклап йөрмәскә диеп,
Килешмәскә, бәлки?
Кар өстенә карлар явып тора,
Бирешмәскә, бәлки?

Чигәләргә кунган кар бәсләрен
Тарап төшерегез!
Йөрәккәем һаман саклап йөрткән
Хисне кичерегез?

Җылы эзләп төшә карлар җиргә
Эри — язлар белән.
Җир шарының мәңге туңлыгына
Кайчан язлар килә?

Күңелемдә поляр төннәр туа,
Туа поляр көннәр.
Күңелем буйлап йөри изге, явыз...
Тагы әллә кемнәр...

Булдырмаска иде күңелләрдә
Эремәслек ташлар:
Шул чагында, бәлки, мәңгелек туң
Җирдә эри башлар...

## Үзем... бары тик үзем...

Югалтып карыйсым килде:
Син китмәдең янымнан.
Юатып карыйсым килде:
Еламадың — ялынмам.

Үзем киттем сине ташлап...
Үзем көттем сине башлап.

*

Мин дәшмәдем.
Әнә еллар шаһит.
Әйтер сүзләр катты таш булып.
Еламадым — түгелер яшьләремнән
Тау-тау үсеп чыкты ак болыт.

Көлмәдем дә.
Әнә кояш шаһит.
Шатлыкларым сары кояшта.
Кырык яшьтә сабый бала кебек
Буыламын бүген күз яшькә.

Ак болыттан бүген яшьләр түгел,
Таш-таш сүзләр җиргә коела.

Шашып көләм, гүя сары кояш
Минем өчен сыман тоела.

Тау-тау ташлар — алар минем
хисләр!
Тетрәүләрне кая куясың?
Киләчәккә җавап бирер өчен
Ташларга да сүзләр уясың.

Ах, бу таулар — шагыйрь
хисләреннән
Янып каткан ачы җаннардыр:
Бәлки, шуңа шагыйрьләрнең
җанын
Хәтта таш та аңлый аладыр?!

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Рашат Низамиев**

# КАР КЕШЕ

ПОВЕСТЬ



Нәрсә буласын әле бирәү дә белми иде...

Бу минутларда аның йөрәге: «Китәргә, хәзер үк китәргә!» — дигән кайнар талпыныш белән типте. Кая китәргә, ни өчен китәргә — сүз әнә шул хакта барачак та инде.

Балачакның яшел сукмаклары башланып кына килгәндә шундый кискен адым ясау өчен нинди көч кирәк булгандыр — моны бирәү дә ансат кына әйтеп бирә алмас, мөгаен. Малайга тугыз яшь тулып килә иде. Менә шушы кыска гына ара эчендә ул әллә ничаклы хисләр кичерде, дөньяның байтак төсләре белән танышып өлгерде. Ләкин бу халәте бик тә тынгысыз иде: көн арты көн узган саен төсләр буталды, тузгыды, хисләрнең үзара бәхәсләшүеннән буталчыклык галәмәте көчәя генә барды.

Бүген исә яшерен бер хыял, читлегеннән котылып чыккан кош сыман гайрәтле талпынды да, малайны ерак сәфәргә чакырды! Нәкъ шул минуттан дөнья урталайга — ак һәм карага бүленде. Дөньяны бер сызык, фәкать бер сызык кыл урталай аерып тора. Ул сызык малай басып торган төштән уза. Сызыкның теге ягына борылып карыйсы килми иде, чөнки анда соры, караңгы төсләр. Хәзер иң яхшысы — алга таба кузгалу, ак дөнья белән очрашу һәм үзең дә шуңарга тизрәк кушылып китү...

Әйе, ул бүген бөтенләйгә китәргә булды. Кая таба, ничек барачак — монысын әйбәтләп уйлады, бар хыялын эшкә җигеп, җентекләп әзерләнде. Уен эшмени: ни әйтсәң дә, карлы-бозлы чакрымнарны, күз күрмәгән киңлекләрне ера-ера әллә ничаклы араны узасы бар аның.

Уңайлы форсат үзеннән-үзе килеп чыкты. Мәктәптә укулар, шаушу тукталган чак — каникул вакыты. Димәк, каядыр китеп барганын белми дә калачаклар. Әнисен кичә ашыгыч рәвештә больницага алып киттеләр. Олыларның сүзенә ышансаң, ул менә-менә бала табарга тиеш икән. Узган ел инде бер тапкыр бәби алып кайтырга дип барып та буш кул белән әйләнеп кайткан иде. Гаеп кемдә булган-

---

Рашат НИЗАМИЕВ (1950) — *шагыйрь һәм прозаик. «Кызыл җәй», «Бөек сер» дигән китаплар һәм «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән композитор Фәрит Яруллин турындагы роман-хроника авторы. Казанда яши.*

дыр — анысы малай өчен караңгы, — әмма әти белән әнисе бу хакта еш кына сүзгә килеп, баштарак хәйран ямьсезләнеп йөрделәр. Ямьсезләнергә сәбәп бар иде шул: әтисе эчеп-исереп йөргәндә өй һәм абзар-каралты тирәсендәге барлык авыр эш әни кеше җилкәсенә төште... Инде бу юлы больницадан бала белән кайта күрсен, бәлки икесенең дә дөньяга карата мәрхәмәте артыр? Хәер, бу чакта инде малай еракта, бик еракта булыр. Әнә бит, сәфәргә җыенган чагы, алда аны кул тимәгән икенче бер дөнья көтеп тора...

Мәктәпкә йөри торган каптырмалы күн сумкасын үзе белән аласы итте. Чөнки ул, ике каешлы булганлыктан, җилкәгә бик тә ипле менеп утыра. Ике кулың буш икән, чаңгы таякларын кирәгенчә рәхәтләнеп селти аласың дигән сүз. Озынча тастымалга ярты ипи һәм кичтән пешерелгән берничә калҗа ит төреп салды. Бер шешә чәйне, түгелеп китмәсен дип, сумка почмагына җайлабрак урнаштырды. Икенче бүлемтектәге чиста дәфтәр һәм каләм янына «Туган тел» китабын куярга да онытмады. Хәзерге заманда белемсез калу ярыймы соң: әгәр анда — ул барасы урында мәктәп юк икән, үзлегеннән укый-яза торыр.

Әтисе фермага төшеп киткән. Иртән аның чәй эчеп, ашык-пошык киенеп чыгып киткәнен йокы аралаш бераз хәтерли ул. Терлекчеләр йортында ферма мөдире өчен дигән аерым бүлмәсе бар аның. Әти кеше шунда көнозын диярлек исәп-хисап эшләре, төрле саннар белән мәш килә, өстәл тулы кәгазьләрен әле бер якка, әле икенче якка шудырып йөртә. Сыерлар күпме ризык ашаган, күпме сөт биргән — әтисе боларны кәгазьдә генә түгел, гамәлдә дә үз кулында тота иде булса кирәк. Колхоз фуражын сатып эчкәне өчен бер тапкыр каты шелтә бирделәр инде аңа бирүен...

«Их, әти, әти, минем китеп баруыма син дә сәбәпче ич...»

Малай бу сүзләрне кычкырып әйтмәде әйтүен, ләкин үзе күңел төпкеленнән күтәрелгән әлеге әчке авазны аермачык ишетте. Соңгы вакытларда ул үз-үзе белән сөйләшергә күнегеп китте шул.

Өй эчендә сәер тынлык иде. Тәрәзә пәрдәләре, аңардан да бигрәк кар көртедәй сураеп торган акшарлы мич нигәдер моңсуланганнар шикелле. Аерылышу минуты җиткәнен алар да сизә микәнни? Аннары малайның күзе, ирексездән, сул як стенадагы рәсемгә төште. Рәсем, биш-алты кнопка ярдәмендә, расписание кәгазе янына беркетелгән. Кайсыдыр журналдан кисеп алынган бу сурәт сине «ә» дигәнче табигатьнең кул җитмәстәй ерак бер почмагына илтеп куя. Ап-ак киңлек! Кар һәм боз патшалыгы. Бер читтәрәк котып станциясе, андагы йортлар һәм радиоантенна баганалары төсмерләнә. Әнә, зур, мәһабәт гәүдәле ак аю сәяхәткә чыккан. Котып йортларын урап-урап, бөҗра-бөҗра эзләр калдырып, бәлки сунарга барышыдыр аның...

Малай әлеге рәсем белән төшендә дә, өнендә дә хәйран саташып өлгергән иде. Бу юлы күңеленнән генә болай саубуллашты: «Ә син моңайма, ак аю, без синең белән Арктикада очрашырбыз әле».

Чыгып китәм дигәндә генә, үз-үзен читтән күреп калырга теләгәндәй, көзге каршына килеп басты. Күпне күргән агач рамлы, бер почмагы чатнаган көзгедән аңа нәкъ үзе төсле бер малай карап тора иде. Нәкъ шундый колакчын бүректән, кышкы пәлтәдән, аякларында тезгә җиткән киез итек. Пәлтә якасы өстеннән яшел шарф бугаң. Ике як җилкәсендә сумка каешлары.

— Син чынлап та китәсеңме? — дип сорады көзгедәге сурәт.

— Әйе, чынлап китәм, менә хәзер үк, — диде малай.

— Юлың озын, туңмассыңмы соң?..

— Юк, мин җылы киендем...

— Син ничек сереңне моңарчы берәүгә дә әйтмәдең? — дип төпченде көзгедәге сурәт.

— Кемгәдер чишсәң, сер булудан туктый ич ул, — диде малай һәм көзгедәге чагылышына үз итеп кенә күз кысты.

Стенадагы сәгать, шаңгырдатып берне сукты да унынчы яртыны җиткәнлеген искәртте. Вакыт, китәргә вакыт!.. Кар өстеннән батмый бара торган чаңгылары аңа тугры юлдаш булыр. Таяклар да сынатмас, һәрчак ярдәмгә килер.

Ул, һәр адымын истә калдырырга тырышкандай, ашыкмый гына атлап ишегалдына чыкты. Авылда карак-фәләннең булганы юк, ишеккә йозак салып тормаса да ярар. Чаңгылар, тимер таяклары-ние белән бергә, утын әрдәнәсенә сөяп куелган иде. Шәм кебек төз ике таякның икесен ике якка батырып куйды да, иелә төшеп, киез итекләрен чаңгы каешына тыкты. Бу эшен тәгәлләгәннән соң таякларны кабат кулына алды, култасмаларына таянып, аларның ныклыгын тикшергәндәй итте.

Тукта, нәрсәдер онытыла түгелме? Менә шушы уй тукталып калырга, тирә-ягына күз салырга мәҗбүр итте. Әйе, ишегалды бакчасындагы миләш белән саубуллашасы бар ич әле аның! Үзенең яраткан сердәше белән...

Әнә ул билдән кар эченә чумган. Шәрә ябалдашларын күккә сузган да, болытларга үзе генә белгән телдә нидер ялвара кебек. Бәлки салкын, күңелсездер аңа? Кешеләр, җылы итеп киенә дә, суыктан тамчы да курыкмыйча рәхәтләнеп йөри бирә, кирәксә өенә кайтып сыена. Агачларның исә ни җылыныр киеме, ни ышыкланыр почмагы юк. Шуңа күрә дә алар, көннәр җылынгач, ашкынып яфрак яра башлый. Мөгаен, миләш агачы да түземсезләнеп кояшны һәм язны көтә торгандыр.

Бакча уртасындагы келәт тә яртылаш кар эчендә күмелеп утыра. Ул кышкы йокыда, хәзергә аңа кереп-чыгып йөрүче юк. Түбәсен чүмәлә кадәрле кар баскан. Җәйләрен малай түбәгә бик еш үрмәләп менә, дөньяны шушы биеклектән күзәтергә ярата иде. Аның әле анда үзе генә яхшы белгән тылсымлы куышы да бар. Куыш түбәсенә дә бүрек-бүрек кар яткан...

Кояшлы, эссе көннәрдә миләшнең куе ябалдашлары келәт түбәсен күләгәләп тора. Монда җиләс, монда рәхәт... Яфрак арасында кайчак кояш нурлары көмеш энәдәй чагылып-чагылып китә. Могҗиза түгел диген син моны: бармак башы тикле бөреләрдән җәй саен ничаклы җилпәзә ачыла, ничаклы тәлгәшләр барлыкка килә! Малайның моны әллә ничә тапкыр сокланып күзәткәне бар. Баштарак бөреләр бүртә, «черт» итеп кабыгын сала. Аннары сабый бала йодрыгыдый йомарланып килгән нәни яфраклар берәм-берәм бармакларын ача башлый. Хәзергә алар әрем төсендәрәк. Карыйсың, берничә көннән ботак саен җилпәзә-яфраклар пәйда була. Алар көн арты көн һаман яшелләнә, ныгый, зурая баралар. Нечкә саплы чемкәләрдә исә тары бөртеге хәтле генә миләшләр күренә. Менә шулар тыгызлангач, борчак кадәрле булып өлгергәч, түзмисең, авыз итеп карыйсың... У-ух, миләш ачысы телне һәм аңкауны көйдереп кенә ала! Сабыр итәргә, тәмам кызарып-пешеп җиткәнен көтәргә кирәк шул аларның.

Ямь-яшел, ачы миләш ничек, ни рәвешле алсуланып пешә — хәзергә монысы табышмак. Тормыш үзе, гомумән, малай өчен зур бер табышмак иде. Аның берәүгә дә зыян-зарар эшләгәне юк. Ә ни өчен аны рәнҗетәләр? Нигә берәү дә аңламый малайны? Ни өчен әләкче исемен күтәрүгә караганда кимсетүләрне йоту җиңелрәк икән? Нигә ул үзенең язмышы, үткәне турында берни дә белми?

Сораулар күп, ә җавап юк...

Шулвакыт, малайның уйларын бүлдереп, миләш агачына ике кызылтүш килеп кунды. Сирәк-мирәк булса да, бирегә килеп чыккалый иде алар. Тагын сыйланырга килгәннәр, күрәсең. Миләшнең иң очтагы ботакларына берәүнең дә кулы җитәрлек түгел. Көзен әни-

се, бер кәрҗин миләшне җыя да, кышка саклар өчен чоландагы зур кадакка элеп куя. Ис тигәндә һәм баш авыртканда шифасы бар икән аның. Уңышның күп өлеше, өзелмичә, агачында килеш кала. Малай бу хәлгә куана гына. Уттай янып торган тәлгәш-тәлгәш миләшләр бакчага, ишегалдына, келәт һәм койма буйларына әнә ничек ямь биреп тора! Кара көзләрдә дә, якты кышларда да гел шулай.

Малайның хәтереннән бер вакыйга йөгереп узды...

Кара көз иде, яңгыр тоташлай яуды-яуды да авылны һәм аның йорт-кураларын энәсеннән җебенә кадәр чылатып ташлады. Малай кичтән йокларга яткач та тәрәзә артында әле һаман яңгыр пышылдый иде. Иртән табигатьне икенче ягы белән алмаштырып куйганнар диярсең: яңгыр туктаган, күк йөзе шома-зәңгәр булып ачылган, аяк асларын туңдырган. Кичәге күлләвек урыннарны көзгедәй боз каплаган. Бер төн эчендә шундый кискен үзгәреш булса да булыр икән! Әнә, кемдер хәтта түбә кыекларына санау таякчыгы хәтле генә ялтыр бозлар элеп чыккан. Малай бу тамашага сокланып, гаҗәпләнеп калды. Ләкин бу минутта аны иң нык сокландырганы миләш агачы иде. Ул ничектер биегәеп, ачылып, мәһабәтләнеп киткән. Утлы күмердәй төртке-төртке миләшләре дә күз явыңны алырдай булып ялтырый. Көннәрнең болытлы һәм яңгырлы торуы элегрәк бу матурлыкны кеше күзеннән читкәрәк яшергән, күрәсең.

Келәт почмагына сөялеп әлеге күренешне тамаша кылганда, ботакларның берсенә песнәк килеп кунды. Малай, суларга да куркып, келәт стенасына тагын да ныграк сеңде. Кыймылдамаска тырышты. Песнәк кебек тиктормас кошны якыннан күрәсе килә иде аның. Сары түшле, карасу-яшел канатлы кошчык бер урында озак тормады, тимерчыбыктай нечкә аяклары белән этенеп, ботактан-ботакка сикерде. Аннары, үрелә төшеп, нәни томшыгы белән кызыл миләшләрне чукырга кереште. Ни гаҗәптер, томшыгына табигать сые эләкми иде. Миләшләр бер-беренә җиңелчә бәрелеп, бары «зең-зиң» дигән нечкә аваз чыгардылар. Әйтерсең, күзгә күренмәс нәни кыңгыраулар зеңләште. Бүрек колакчынын төшергән булса, мондый «музыка»ны бөтенләй ишетми дә каласы икән... Ул арада, чит кеше барлыгын сизенепме, песнәк уктай атылып очып та китте.

Зеңләү авазының серен белергә теләгәндәй, малай миләшкә якынрак килде: хикмәт менә нәрсәдә икән! Яңгыр тамчылары төнлә, кибәргә өлгермәгәнлектән, юка боз катламы булып миләшләрне төреп алган лабаса! Бер-беренә бәрелеп, шулар үзара зеңләшкән икән. Бозлы миләшләр... Алар матур, алар кызыктыра. Ләкин мондый каты, авыр, кызыктыргыч хәзинәгә песнәкнең көче җитәме соң — гәүдәсе дә, томшыгы да бәләкәй, таяныр тәпиләре дә нечкәрәк шул аның.

Кызылтүшләрне күр әнә: агачтан миләшне турыга баскан килеш кенә чүплиләр. Томшык, тәпиләре генә түгел, аларның койрыгына тикле гайрәтле!

Кыш уртасы булганлыктан, миләш агачының иң очында диярлек соңгы тәлгәшләр генә эленеп калган иде. Куркытучы-мазар күренмәсә дә, ашык-пошык сыйланганнан соң, ике кызылтүш ничек кинәт килеп чыксалар, шулай кинәт кенә китеп тә бардылар. Һавада беразга канат эзләре генә уелып калды кебек. Ишегалды еш кәрәлгәнгә күрә, бакча рәшәткәләре кар астында калган диярлек. Малай рәшәткә башларына бәрелмәскә тырышып кына бакча эченә узды, миләш каршына тукталды. Кызылтүшләрнең ашык-пошык сыйлануы эзсез узмаган: агач төбендәге кар өстенә, эре-эре кызыл йолдыз булып, соңгы миләшләр коелган иде.

Түбә башына гына түгел, җәйләрен миләш очына да еш үрмәли иде малай. Андый чакта уч төбе һәм бармаклары кызарып чыга, карала торган иде. Әнә шунда да ул хәзер, көрәнсу кәүсәдә һәм ботак-

ларда үзенең бармак эзләрен күрергә теләгәндәй, миләшкә тагын бер кат озаклап текәлеп карады...

— Хуш, миләш! Мин китәм инде... — дип пышылдады ул. Һәм капыл гына китте. Шушы минуттан башлап кыр ягына, тау ягына барасы иде аңа. Өйләренең авыл читендә, ялгыз утрау сыман аерым бер калкулыкта булуы малай файдасына иде. Чөнки кая таба киткәнен авыл кешеләреннән берәү дә күрми калачак. Каршы очрамаулары, төпченмәүләре хәерле — юкса алдашсаң яхшы түгел, ә дөресен әйтергә ярамый. Ә инде өйләре авылдан шулай читтәрәк бүленеп калган икән, моның үзенә күрә сәбәбе бар. Әтисенең сүзләренә караганда, йорт тирәсендә кайчандыр тагын дүрт-биш хуҗалык торган, яшәгән, бәрәңге үстергән, мал-туар асраган. Заманнар үтү белән күршеләр, йорт-җирен сатып, читкә киткәннәр. Әрем, кычыткан баскан нигез урыннарына карап кайчандыр анда чынлап та йорт булганлыгын әле дә чамаларга мөмкин. Кечкенә авыл бетәргә тиеш, диләр иде бит элек. Кечкенә булса да, чит-читеннән тарала башласа да, кайсыдыр акыллысының киңәше белән авыл үзәге барыбер сакланып калган. Менә шундыйрак тарихлы авыл бу.

Әтисе, күршеләренә ияреп, нигә ул чакта шәһәр яисә утар үзәгенә күченеп китмәгән — малай моның сәбәпләрен белми иде.

Күпме ераклашканын чамаларга теләп, ул артка — авыл ягына борылып карады һәм, әлбәттә, иң элек үзләренең өен күрде. Өй түбәсен кар каплаган, ул бераз корымланган; урта бер җирдән күтәрелгән калай торба бу күренешне күпмедер бозып тора икән. Ни генә булмасын, бакчаны, келәтне, келәт буенда үсеп утырган миләшне, әле тагын абзар-кура рәтен үзе тирәсенә җыеп китергән бу йорт аның өчен кадерле дә, кызганыч та иде. Әнә шул хисләре тәэсирендә күңеленнән генә: «Хуш, туган йорт!» — димәкче иде дә ничектер тыелып калды. Туган йорты шушымы соң аның? Кайда туган, ничек дөньяга килгән — моны бит берәү дә белми. Кемнән сорыйсың ди аны. Әтиәнисеннән сорау, гомумән, оятлы һәм гаеп эш булыр иде. Малайларга тел чишеп кара, шундук бармак төртә-төртә көләчәкләр генә.

*Малай үзенең чын әтисен һәм әнисен белми иде — фаҗигонең башы менә нәрсәдә. Малайны хәтерсезлектә гаепләп булмый; чөнки сабыйлар — ничек туганын, өлкәннәр үзенең ничек үлгәнен беркайчан да белә алмыйлар...*

Әле дөньяда тагын мәктәп дигән нәрсә бар иде. Шәм шикелле тигез бүрәнәләрдән салынган, класс саен кара тактасы, өстәл һәм парталары булган, тәнәфесләрдә гөрләп торган гап-гади башлангыч мәктәп. Өй түбәләре бар да кар белән капланганлыктан, хәзер кырдан аны төп-төгәл чамалавы читен. Ләкин мәктәп малай өчен барыннан да бигрәк укытучысы белән кадерле, якын иде. Кара чәчле, ачык йөзле, йомшак тавышлы япь-яшь Чулпан апа аны хәреф танырга, укырга-язарга, үсемлекләрне һәм җан ияләрен рәнҗетмәскә өйрәтте. Менә шуларны белмәсә, Чулпан апасының кырыс та, ягымлы да карый торган күзләрен күрмәсә, малай никадәр хәзинәдән, дөньяны таный башлауның беренче шатлыкларыннан мәхрүм каласы икән! Укытучысын ул беренче күрүдә үк яратты, аңа тартылды, аның кебек булырга омтылды.

«Әйбәт малай күренәсең», — диде укытучы беренче тапкыр күрешкәндә үк. Менә шуннан соң начар булып кара син! Мактау сүзләреннән малай бер башка үсеп киткәндәй булды ул чакта. Үзенә карата мондый сүзләрне беренче тапкыр ишетүе иде аның. Бүтәннәр дә әйтсен иде бу сүзне, әтисе яки әнисе... Юк шул, алар мактауга саран, бик тә саран.

Кинәт Чулпан апасын мәктәптә итеп күз алдына китерде ул.

Класста дәфтәрләр тикшереп утырган чагы икән аның. Класс тәрәзәсеннән малайның китеп барганын күреп алган да, иң өстенә пәлтәсен салырга да онытып, ап-ак күлмәктән килеш мәктәп болдырына чыгып баскан. Үзе кулын болгый, үзе борчылып әйтә кебек:

— Хәтәр юлга кузгалгансың, энем... Борыл, ишетәсеңме?!

Малай икеләнеп калды, тик бу озакка түгел иде. Аны бит алда беркем дә белмәгән хыялы, әле берәү дә сизмәгән зур сере көтеп тора. Шушы тыелгысыз көч аны алга әйдәкли ашыктыра, офыклар артындагы ак дөньяга чакыра.

— Гафу итегез, Чулпан апа, миңа ничек тә китәргә кирәк...

Яраткан укытучысы белән саубуллашуы шушы иде. Яшь, ап-ак сынлы укытучы сурәте, хыял җимеше буларак, мәңгелеккә мәктәп болдырында басып калды. Аннары сиздерми-нитми генә укучысының күңеленә күчте.

Малай, ике терсәге белән сумкасын өскәрәк этәргәндәй итте дә, алга омтылды. Күңеленә иң якын нәрсәләр белән саубуллашкач, аңа ничектер җиңел булып китте. Чаңгы табаннары астында кар шыгырдый, таякларны алга таба күчергән саен пластмасс бөгәлҗәләр арасыннан кар кисәкләре очып чыга. Үзе теләгән, көтеп алган сәфәре бу аның, кыенлыклар очрый калса, түзәр, ничек тә түзәр. Иң мөһиме — сәфәр ахырына кадәр чаңгыларны ничек тә таза, бөтен килеш сакларга кирәк.

Тау дигәне авылдан бер-ике чакрым читтә иде. Тау итәгенә аяк басканчы әле иң элек кечерәк кенә елга аша чыгасы бар. Елга инде әллә кайчан туңган, су һәм бозлары белән калын кар астында күмелеп калган. Каралып күренгән яр читләрен исәпләмәгәндә, хәзер аны танырлык та түгел. Сөзәк һәм тигезрәк урынны сайлап, малай елга уртасына шуып төште. Чокыр-чакыр җирләрне әйләнеп узганнан соң саклык белән генә ярның икенче ягына күтәрелде. Әнә тау якында — кул сузымы җирдә генә! Ләкин тау үз итәгендә басып торган малайны бөтенләй искәрмәде шикелле. Ничек оеп утырган булса, шул хәлендә өнсез генә йокымсырый бирде. Аның каравы тау итәге, башланмаган дәфтәр битедәй, искиткеч матур, чиста, шома иде. Малай түзмәде, таякларының берсен карандаш итеп, кырпак кар өстенә ашыкмый гына бер-бер артлы җиде хәреф төшерде. Бу хәрефләрдән «АРКТИКА» дигән тылсымлы сүз барлыкка килгән иде.

Тауның күзе, колаклары, озынча гәүдәсе генә түгел, хәтере дә кар астында күмелеп калган, күрәсең. Юкса, җәйге көн булса, малайны танымый калмас иде. Җәйге эссе көннәрдә су коенырга килгәч, алар тау өстенә менмичә калмыйлар иде. Таш, ком, кыска үлән киртләчләренә ялантәпи баса-баса өскә күтәреләсең. Тезне кочаклап тау башында утыру — үзе бер шатлык! Авыл ягына бармак белән төртә-төртә: «Әнә безнең өй!» — дип бәхәсләшү, әүмәкләшеп көрәшү дисеңме — берсе дә калмый.

Ни гаҗәптер, тау өстендәге басуда елның-елында күкрәп арыш үсә иде. Кемнәр, кайчан чәчә аны — малайлар арасыннан моны берәүнең дә күргәне юк. Ат дугасы күмелерлек арыш, дулкын-дулкын булып тирбәлә дә, офыклар артына китеп, җай гына югала. Күпме текәлеп карасаң да, арыш кыры белән офык кушылган сызыкны күрә алмыйсың. Тау башындагы кырның иге дә, чиге дә юктыр, ахры.

Хәзер әнә тау кышкы йокыга талган. Ул өнсез, битараф. Күпме теләсәң дә, аны уята алмыйсың. Тау битендә тамырланып яшәүче кәрлә чикләвек куаклары да кар әсирлегендә. Әнә кайсының очлары, кайсының ябалдашлары бихисап антеннадай өскә сузылган. Малай инде тырыша-тырмаша тауның уртасына җитеп килә иде. Баштарак ул, сөзәк урында, «Беларусь» тәгәрмәчедәй эзләр

калдыра-калдыра менде. Тора-бара алай мену кыенлашты, чөнки артка мәтәлеп киту куркынычы бар иде. Мәтәлдеңме — якаңа, итәкҗиңнәреңә, итек куныычларыңа кар кереп тулачак. Ансат котылырмын димә: андый чакта кар киемгә һәм тәнгә тигәнәктән дә болайрак сырыша!

Таунын урта бер җирендә ул, кырык биш градус борылыш ясап, чаңгыларын янәшә бастырган иде. Чикләвек куаклары тирәсенә җиткәч, болай бару күпмедер җиңеләя төште: мондагы кар тотрыклы, калынрак икән. Өскә таба кыйгачлабрак та күтәрелергә мөмкин. Ләкин бу юаныч озакка бармады. Үч иткән шикелле, чикләвек ботаклары әле таяктан каптыра, әле чалбарын яисә пәлтә итәген йолыккалый. Берсендә, егылып китәм дигәндә генә, көч-хәл белән каршындагы ботакка тотынып өлгерде. Шәрә ботакларын суза-суза, былтыр җыйган чикләвекне соравымы әллә куакларның? Җыйды — анысы хак. Тик үзенә булдымы соң бөртекләп өзгән элеге чикләвекләре?

Бу күңелсез вакыйга әле дә хәтерендә...

Август ахырлары иде. Ике классташы — Сипкел Хәмит һәм Саескан Сәмит белән малай бергә чикләвеккә килде. Тау битенә күтәрелделәр дә кечерәк бер әрәмәдәй үсеп утырган куаклар арасына өчесе тиң кереп югалдылар. Һәркемнең күбрәк җыясы килә иде, билгеле. Әмма чикләвек аз күренә, чөнки биредәге кәҗә сукмакларын өлкәннәр дә, бала-чага да берничә кат таптарга өлгергән иде. Малай тиз төшенде: өскә карап күзләреңне талдырасы юк, чикләвекнең күбесе дәшми-тынмый гына аскы ботакларда посып ята икән! Яфракларны аралый-аралый эзлисең, уенчыктай тирбәлгәнен күрәсең — менә шуннан соң гына алар учыңа төшеп кунаклый. Кишәнкәсеннән салдырсаң, балавыздай саргылт чикләвекләр тагын да матурланып китә. Бер-берсен тапканга сөенүдәнме, күңелле генә шылтырашып та куялар. Бер сәгать чамасы узды микән, куактанкуакка күчә торгач, малайның кепкасы таза-йомры чикләвекләр белән тулды. Якында гына иптәшләренең көлешкәне, үзләре янына чакырганы ишетелде.

Хәмит белән Сәмит, чыннан да, аны көтеп торалар иде.

— Ә-ә, син хәйран җыйгансың! — дип каршылады аны Хәмит, гаҗәпләнүен яшермичә.

— Без җыеп азапланмадык, менә монда гына тутырдык, — дип шаркылдады Сәмит һәм кыска бармаклары белән корсагына сугып алды.

— Җеннәрең булышкан сиңа!.. — Сипкелнең теленә генә түгел, җәлпәк йөзенә дә үчекләшү төсмерләре ташып чыккан иде.

Боларның астыртын нияте барлыгын сизенеп, малай ни дип җавап бирергә белмәде ул чакта. Мондый кыл нмышлары беренче тапкыр гына түгел инде: йөриләр-йөриләр дә азакта сиңа карата берәр этлек эшләп куялар. Алар икәү, син берүзең. Мондый чакта малай өчен шактый кыен хәл туа.

Бер көчек өргәндә аңа икенчесе кушылып киткәндәй, Хәмитнең сүзләрен Саескан бик тиз эләктереп алды:

— Әйе, сиңа җеннәрең булышкан! Юкса кай арада кепка тутырыр идең? Безгә бит әнә юньләп тәтемәде дә чикләвек...

— Соң сез бит... ашап бардык, дисез.

Малайның бу сүзләре тегеләрне, киресенчә, кыздырып кына җибәрде:

— Ашаса, әллә синекен ашаганмы!

— Әйе, үзебезнекен ашадык.

— Иртәтеп килгәнебез өчен рәхмәт әйт.

— Әйт, рәхмәт әйт. Без булмасак, безнең авыл булмаса, син бу чикләвекләреңне төшеңдә дә күрмәс идең.

Хәмит тагын ниләрдер әйтте, «әйе»ләрен кушып, Сәмит тагын ниләрдер кабатлады — малай боларны ишетми иде инде. Ярты сүздән аңлашылды ич: кепкадагы чикләвеккә күзе кызган боларның. Нишләргә? Ул бит әти-әнисен чикләвек белән сыйларга, аларны шатландырырга уйлаган иде. Юньләп сорасалар, өлеш чыгармас идемени? Ә болай масаеп, рәнҗетеп, гаделсез төстә җаныңда тукыналар икән, киресенчә, үҗәтлек күрсәтәсе килә. Бирешмәскә кирәк, юкса җиңелү ачысы йөзеңә корымдай ягылып калачак.

«Саескан» дип белеп әйткәннәр, Сәмит һаман такылдый икән әле:

— Кеше өлешенә кул сузасың. Син бит безнең авылныкы түгел!

Соңгы сүзләр мал йның иң авырткан җиренә сукты. Башы әйләнеп китте, аяк астындагы җир чайкалып куйды сыман. Әллә түгелмәсен дип, әллә тотынып әйбер эзләүдәнме — кепкасын ике кулы белән ныграк кысып тотты. Үзенең рәнҗүен дә, әйтерсең лә, кулларында әнә шулай кысып тора иде ул. Бу минутта кайдан тәвәккәллек килгәндер аңа, артка каерыла төшеп:

— Мәгез алайса! — диде дә кепкасындагы чикләвекләрне нәфрәт белән тегеләрнең күкрәгенә сипте. Бу аның иң дәрес җавабы иде. Кәҗә сукмагына һәм куак төпләренә шыбырдашып эре чикләвекләр коелды. Аларның кайберләре, бу хурлыкны күтәрә алмыйча, тау астына ук тәгәрәде.

Сипкел белән Саескан шуны гына көткәннәр диярсең: комсызланып, терсәкләре белән берсен-берсе этә-этә җирдәге чикләвек өстенә ташландылар, һәркайсы күбрәкне эләктерергә тырышты. Әле генә бер сүздә булган ике дусның тузан туздырып, пар әтәчтәй тарткалашуы читтән караганда кызык та, кызганыч та иде. Ә малай алардан өстен калуын күңеленең кай төше беләндер тойды, үзен җиңүче итеп хис итте.

Ике дус аны тау астында куып җитте. Шундый да канәгать, тыныч һәм гамьсез атлыйлар ки, гүя, әлерәк кенә арада бернинди низаг та, мал бүлешү дә булмаган! Гүя, алар берәүне дә рәнҗетмәгән... Әле җитмәсә чикләвек тәкъдим иткән булып маташалар: янәсе әнә ничек юмарт һәм кешелекле алар. Юк инде, юхаланмагыз, ул чикләвекләр утлы күмер булып болай да малайның тамак төбендә утыра.

Авылга кайтып җитәрәк Сипкел шулай да кисәтәсе итте:

— Кара аны, әтиеңә әләклисе булма, юкса...

— Әйе, әләклисе булма, — дип, Саескан аңа кушылды. — Юкса телеңне ничек тешләтергә белербез.

Бу кисәтүгә исе китмичә генә, малай өйләренә борылды. Таудагы хәлләр турында әти-әнисенә ул болай да бер сүз әйтмәячәк иде аңысы. Түзмәс, елап җибәрер, мин бу авылныкы түгелмени, алайса мине кайдан алдыгыз, дип ычкындырып ташласа, үзе өчен бер дә яхшы булмас. Тегеләр исә «әләкче» дип мәктәпкә сасытырлар. Андый исемне күтәрәсе килми иде аның.

...Малайның әлеге хәлләрне хәтерләве шушы урында өзелде. Кыйгачлап күтәрелә торгач, тауның буеннан буена аска таба сузылган ермак читенә килеп чыккан иде ул. Аста — упкын рәвешендәге бушлык, тирәнлек, ермакның чит-читләрендә исә юка көртләрнең каен тузыдай бөгәрләнеп төшкән канатлары күзгә ташлана. Чаңгы таягы белән сак кына чукып, шундый кантарларның берсен китеп төшерде ул. Кар кисәгенә ияреп, баягы уй-хатирәләре дә аска тәгәрәде шикелле... Кире чигенде дә, инде икенче якка кыйгачлап, өскә күтәрелүен дәвам итте.

*Балачакта кечерәк түмгәк тә зур тау булып күренә, диләр. Малайның чаңгыда адымлап-адымлап күтәрелгән тавы табигать корып куйган уртача тауларның берсе иде, әлбәттә. Ул географик кар-*

*таларга да төшерелмәгән. Авылда аның биеклегеннән берәүнең дә үлчәп караганы юк. Гомер-гомергә бу тауның зурлыгын өлкәннәр дә, балалар да үз каланчасы биеклегеннән чыгып бәяләгәндер. Тау менү ләззәтен аңа күтәрелеп караганнар гына белә. Малайның кыш кочагында йокымсырап утырган, билгесезлек белән өретелгән тауга беренче тапкыр күтәрелүе. Үткәненнән һәм рәнҗүләрдән ераклаша барып, ялгызлыкка һәм азатлыкка сусаган күңелнең биеккәрәк ашкынуы бу. Ул бүген хыялына һәм йолдызларга якыная төште шикелле...*

Тау сыртына күтәрелеп, тигез урында таякларына таянгач кына ул еш-еш сулыш алуын аермачык тойды. Әллә шатлыктан, әллә беләкләренә көч килүдән инде, йөрәге дә шушы дулкында «деп-деп» тибә иде. Юк, ул тамчы да арымады, киресенчә, бөтен гәүдәсендә яңа бер көч уянган һәм шул көч, бөтен тәне аша узып, күзгә күренмичә генә салмак әйләнеш ясый. Шулай да маңгай бераз тирләп чыккан. Бүреген күтәрә төшеп, бияләен салмыйча гына кул аркасы белән маңгаен сөртеп алды. Рәхәт, күңелле иде бу минутта, әйтерсең, ул дөньяның иң биек ноктасында берүзе басып тора.

Әйе, хәзергә — берүзе, ялгызы. Ләкин ул Арктикага барып җитәргә, эзләгән кешесен табарга һәм шуның белән ялгызлыкка да, язмышындагы табышмакка да чик куярга тиеш. Шулай булмаганда бу сәфәрнең нигә кирәге бар?

Хәл җыеп, тынычланып күпмедер басып торганнан соң чаңгыларын тагын хәрәкәткә китерде. Әле кайчан гына арыш тирбәлгән, хәзер исә тоташ кар астында калган кырга ничек аяк басканын сизмәде дә кебек. Алда аны кул тимәгән ап-ак дөнья, күз күрмәгән ап-ак киңлек көтеп тора иде. Текәлебрәк карасаң, басу киңлекләре белән офыкның кушылып киткән җирен бераз шәйләргә мөмкин. Көн матур, күкләр аяз. Кояш үз итеп, ниндидер ягымлылык белән карый, нурлары белән ашыкмый гына җирне иркәли... Очкындай ялтырап, бихисап кар бөртекләре күзне чагылдыра. Җемелдәп артка күчүләре кая, анда инде бер кочак булып яңалары кабынып өлгергән! Аяк астында әнә шундый йолдызлы, якты юл җәйрәп ята. Артта, ике тасма булып, чаңгы эзләре сүтелә.

Тирә-юньдә аклык, аклык... Кышның шушы матурлыкларын бераз күзәтеп барганнан соң ул яңадан уйга чумды. Тырышып-тырышып атлаган саен аның уй-хыялларына да җегәрлек, җитезлек иңә иде кебек. Әнә, сул якта, ниһаять, кибән тезелмнәре һәм телеграм баганалары күзгә чалынды. Юк, малайның хыялы аларны бүтәнчәрәк рәвештә күрде, бүтәнчәрәк кабул итте: тегеләре — котып йортлары, болары — радиоантенна мачталары...

Малайның күзаллавы, хыялдан тизрәк чынбарлык ясарга омтылышы шушы дулкынга тәмам көйләнеп җиткән иде. Менә ул курку белмәс котыпчылар яши торган станциягә якынаеп килә! Шундагы иң биек йортларның берсенә, дөресрәге, антенна очына булса кирәк, урак-чүкечле кызыл байрак беркетелгән. Малайны кызыл йолдызлы вертолеттан әллә кайчан күреп алганнар инде. Әнә зур чанага әллә ничәшәр эт җигеп, кар туздырып җилдерә-җилдерә, аны алмага чыкканнар! Алар һәммәсе дә бер төслерәк киенгән: өсләрендә җылы тун, бүрек, ак халат. Берсенең кулында хәтта мылтык та бар. Дилбегәгә җигелгән этләр, килеп җитү белән, уйнарга иптәш табылды дип, шатлыктан өреп куяр, әлбәттә. Халатлы кешеләр исә малайны шундук урап алыр.

— Исәнмесез! Мин сезнең янга килдем, — дияр малай, күшеккән кулларын угалап.

— Син ничек безне таптың? — дип таң калыр котыпчы абыйлар.

Менә шунда ул үзенең эзләгән кешесен күреп алыр! Кар кеше

килеп кочаклаганда ничек тә елап җибәрмәскә кирәк. Юкса, чын сәбәбен белмичә, җебегән, диярләр. Тик менә Кар кеше аны дөрес аңлармы, шундый исем белән дәшкәнгә үпкәләмәсме? Ә нигә үпкәләсен икән, малай хәзергә аның чын исемен белми ич...

«Аның чын исеме ничек икән соң?»

Күпме генә уйлап караса да, малай бу соравына җавап таба алмады.

Әйе, малайның зурдан кубып, ак өметләр белән Арктикага чыгып китүенә, чыннан да, Кар кеше сәбәпче иде. Вакыйга исә болайрак булды.

Көннәрнең берендә, дәресләрен әзерләгәннән соң, өйләрендәге телевизорны кабызып җибәрде ул. Анда беренче сурәтләреннән үк игътибарыңны үзенә җәлеп итәрдәй кызыклы тапшыру бара иде. Тау чаклы боз кантарлары... Бу галәмәт тамаша кочагында бер генә җан иясе дә күренми... Юк, бар икән! Әнә, буйдан-буйга чатнап ярылган бозлы тирән суда ак аю су коена. Каерылып төпкә чуму белән, су аның артыннан күбекләнеп, зур казандагы шикелле кайнап-кайнап кала. Кире чыкканда исә шундый да киң ярыктагы сулар, бозлы ярларына сыешмыйча, өскә үк атылып менә. Ак аюның бер-бер тәпие генә дә киез итек кунычы кадәрле бар икән ләбаса!.. Бу күренештән әсәрләнеп, малай экранга тагын да ныграк беректе.

Аннары әлеге күренешне башкалары алыштырды. Котып станциясе, палаткалар, радиоантенна очындагы әләм, җигүле этләр, ак халатлы абыйлар... Хәтта канатлары белән күкне яра-яра очкан вертолетны да күрсәтеп алдылар. Аннары экранда сакаллы бер абый пәйда булды. Өстендә ак халат, бүреге дә ак башлык белән каплаулы. Анда, боз һәм карлар илендә, бик тә салкын, ахры — бу абыйның сакал-мыекларын, бүрек колакчыннарын ап-ак бәс каплаган. Кыскасы, бөтен җире ап-ак! Ул үзләренең эше турында сөйләгәндер, әлбәттә, малай аларның күбесен аңламады, аңларга тырышмады да. Бу кеше аны үзенең матурлыгы, нинди суыктан да курыкмавы, ап-ак тешләрен күрсәтеп елмаюы белән әсир иткән иде. Ул аны шул минуттан ук яратты, озаграк сөйләвен теләде. Бөтен җире ап-ак булганы өчен, мавыгып китеп, күңеленнән генә аңа «Кар к ше» дигән исем кушып та өлгерде.

Кар кеше тагын күпме сөйләгәндер, малай аның:

— Минем икенче класста укучы бер улым бар, мин аны бик сагынам,— дигән соңгы сүзләрен генә хәтерләп калды. Бу сүзләр аңа тылсымлы тәэсир итте, иләс-миләс хыялын әллә нинди яңа төсмерләргә манчыды. Шушы көнне малай күңелендә, йомылган чәчкә бөреседәй, үзе генә белгән яшерен сер барлыкка килде. Чәчкә ачылса, нинди төстә булачак — монысын ул белми иде әле.

Кичен әти-әнисе эштән кайттылар.

— Мин Кар кешене күрдем! — дип, малай сөенче алырга ашыкты.

— Саташтыңмы әллә? — диде әтисе кырыс кына.

— Хыялый, юк белән баш катырма! — дип, әнисе почмак якка кереп китте.

Малай ялгышканын аңлады. Әгәр серен менә хәзер ахыргача чишеп бетергән булса, аның бит тиргәлүдән башы чыкмас иде. Сер төпкәрәк, тирәнгәрәк төшеп ятты. Әнә шул сер, көннәрнең берендә канат ярып чыгар өчен, көч җыя, беренче мөмкинлек тууын көтә иде.

Ул көн килде. Малайның зурдан кубып, ак өметләр белән Арктикага чыгып китүенә, чыннан да, Кар кеше сәбәпче иде. Ул гына иде микән соң?

Бу сорауга җавап бирү өчен без Госман атлы малайның моңа кадәрге тормышына да күз салырга тиеш булабыз.

* * *

Балачакка купме кояшлы көннәр, су коенулар, кештердәтеп яшел кыяр ашау ләззәтләре бүләк иткән җәй узып та бара. Җәйнең яшел канатына берән-сәрән булса да кызгылт-сары төсләр кунаклый башлады. Йомгактай йомры каз бәпкәләре, тәмам үсеп, инде әнкәләре янына янәшә бастылар. Өлкәннәр көнозын басу-кырдан кайтып керми диярлек — бар булган ашлыкны урып, суктырып, амбарга ташыйлар. Авылга август айларында гына була торган җитдилек, моңсулык иңә.

Госманның беренче класска барыр чагы җитеп килә иде. Ул аны шатланып көтә, әле кайчан гына кырыеннан карап уза торган мәктәпкә инде үзенең дә аяк басасын уйлап, күңелендә рәхәтлек тоя. Әнисе сатып алган өр-яңа күлмәк һәм мәктәп формасын көн дә бер тапкыр тоткалап, сыйпап-сыйпап карый. Кичә әтисе район үзәгеннән кайтты, кулында — Госманга дигән тимер каптырмалы сумка. Аның эченнән дәфтәр, каләм һәм төсле карандашлар килеп чыкты. Аларны күргәч, җиде төстәге карандашка тиң булып, малайның күңелендә аллы-гөлле салават күпере кабынды!

Тагын да күңеллесе алда булган икән әле. Авылга читтән яңа укытучы килгән, диделәр. Өй борынча кереп чыгачак, мәктәпкә йөрисе балаларның әзерлеге белән танышачак икән, дип тә сөйләделәр. Көннәрнең берендә, чыннан да, Госманнар өенә килеп керде ул. Бусагадан узды, исәнләште.

— Исәнмесез! Мин Чулпан булам. Улыгызны беренче класста укытачакмын, — диде ул гаҗәеп ягымлы, табигый тавыш белән.

Малайның колак төбендә аның шушы ягымлы тавышы гына утырып калды. Укытучы апаның яшь, чибәр, ак күлмәктән булуы малайның аңына томанлырак барып җитте. Боларны ул алга таба, мәктәпкә йөри башлагач кына якыннанрак күрәчәк һәм әчке соклану кичерәчәк иде.

Әти-әнисе кунакчыллык күрсәтеп:

— Бик әйбәт, — диделәр икесе беравыздан.

— Мактап йөрисең икән, кызым. Самавырым өлгерергә тора,— дип әнисе чәйгә үк кыстарга тотынды.

— Бер дә борчылмагыз. Чәйләп торырга вакытым юк. Мин бары танышырга, улыгызның мәктәпкә әзерлеге хакында кызыксынып килдем. — Аннары малайга борылып: — Исемең ничек әле, үскәнем? — диде.

— Госман.

— Менә таныштык та. Минем дәфтәргә дә шулай дип язылган. Күз тимәсен, әйбәт малай күренәсең.

Госман, колакларына хәтле кызарып, дулкынланудан кулларын кая куярга белмичәрәк басып торды.

— Китап-дәфтәрләрең әзерме? — дип, укытучы сорашуын дәвам итте.

— Әзер, әзер, — дип күтәреп алды әнисе һәм шкафны ачып малайның күлмәк-костюмнарына хәтле күрсәтте.

— Алайса бик әйбәт,— диде Чулпан апасы шатланып. Әти-әнисенең эшләре турында да бераз сорашкач, саубуллашып чыгып китте.

— Мәктәптә күрешербез, — дип елмайды ул киткәндә.

Укытучы әнә нинди ягымлы, көләч, тәмле телле була икән! Малайның күңел дөньясына яңа бер нур, кешеләр арасында гына була торган яктылык күпере сузылды бу көнне.

Кичен исә, малай йокларга яткач, ир белән хатын арасында мондыйрак сөйләшү булды.

— Алып кайтканда бер яшь идеме әле үзенә? — диде ир, нәрсәнедер хәтерләргә тырышып.

— Әйе,— диде хатын теләр-теләмәс кенә.

— Кара син, алты ел узып та киткән...

— Әйбәт укый күрсен инде.

— Укыр, анысы өчен борчылма, акыл тәпәне буш түгел аның. Син менә мин әйткәннәргә борчылсаң иде, хатын.

— Тагын таларга керештеңме?

— Чәбәләнмә, әйтәм генә ич. Үз балабыз булып, әлеге костюм һәм сумкаларны аңа тоттырсак, бөтенләй бүтән булыр иде дим...

— Госманны да үзебез үстерәбез, барыбер түгелмени?

— Барыбер булса, дуга белән печән чабарлар иде аны. Үсә төшкәч, барыбер дөресен беләчәк. Син аны тәрбиялә, эшкә өйрәт, ә ул, үсеп җиткәч кенә, көннәрнең берендә, безне ташлап, бөтенләйгә китеп барса?

— Алай куркырлык булгач, баштарак ни уйладың соң?

— Беләсең ич, балагыз булмас, диделәр. Ә миңа малай, аңлыйсыңмы, малай кирәк иде! Госманны үстерербез анысы, шикләнмә. Тик миңа үзебезнеке, үз каным, үз дәвамым кирәк...

— Нишлим соң, ходай мәхрүм иткәч...

— Ул чаклардан соң ун ел узды инде. Ә син врачларга яңадан бар. Врачның берсе тегеләй, берсе болай сөйли аның. Кайсы хаклы икәнен дә белмәссең.

Ир белән хатын, икесе берьюлы уфтанып,сүзне шушында туктаттылар. Малай тирән йокыда ид . Ярый әле ул аларның сөйләшкән сүзләрен ишетми калды.

Көннәрдән бер көнне ишетер, бергә уйнап йөргән иптәшләреннән ишетер ул бу хәбәрне...

Көннәр, атналар, айлар сизелми генә уза торды.

Беренче класста укый торган малайлар ягымлы, тәмле телле Чулпан апаларының кирәк чакта кырыслык та күрсәтә алуын беләләр. Бернинди гаебе һәм катнашы булмаса да, бу эшнең бер очы Госманга да барып тоташа иде. Нинди бәйрәмдер, малай анысын яхшылап белми, беркөнне әнисе иртүк торып гает коймагы пешерде. Госман шуларның икесен чиста кәгазьгә төреп салды да сумкасына тыкты. Класска керү белән, китап-дәфтәрләрне буямасын дип, аларны парта капкачы астына яшерде. Исәбе — озын тәнәфестә тамак ялгау иде.

Тәнәфес булгач та ул иң элек тышка чыгып йөгерде. Әйләнеп керсә, Чулпан апа Сәмит белән Хәмитне өстәл янына кара-каршы бастырган да, аларны нык кына орыша иде:

— Ризыкны рәнҗеткән өчен беләсезме, иң зур җәза тиешле сезгә... Бөртеген дә калдырмыйча хәзер үк ашап бетерәсе булыгыз!

Хәмит белән Сәмит тәнәфестә коймак атышып уйнаганар икән. Укытучы апа күреп алган да, сабак булсын дип, тузанлы коймакларны көчли-көчли ашатып бетергән үзләренә.

— Госман, гафу ит, — диде Чулпан апа, коймакларның кемнеке икәнен белгәч.

— Ә мин алар атышып уйнаган коймакны барыбер ашамас идем, — дип җавап бирде малай.

* * *

Фермада эшләгәнгә күрә, әтисе күбрәк шунда кайнаша. Әнисен авылда «кибетче Са мә» дип йөртәләр, ул да көнозын диярлек кибет эшләре белән мәшгуль. Шуңа күрә, билгеле инде, ишегалдын себерү, казларны алып кайту, бакчадагы түтәлләргә су сибү кебек җиңелрәк эшләр Госман җилкәсенә төшә иде. Ул аларны, әлбәттә, теләп-яратып башкара, үзенең кирәклеген тоюдан зур үсеп киткәндәй була.

Кул астына кера торсын диптер инде, беркөнне этисе утын ярган җирдән малайны үз янына чакырып алды.

— Кил әле, кулың эшкә өйрәнә торсын. Балта тотып торсаң да файда,— дип, түмәр өемнәренә ишарәләде.— Күрәсеңме боларны? Һәркайсына ачкыч таба белсәң генә шартлап ярыла алар.

Госман инде беренче классны тәмамлаган, балта тотарлык кына куәт бар иде аның беләкләрендә.

— Аякларыңны аерып бас!

— Балта йөзен агачка туры куй.

— Сапның очыннанрак тот... Менә шулай! — дия-дия, әтисе киңәш арты киңәшен яудырып кына тора. Аның кулына эләккәч, зур башлы агач тукмак уенчыктай очып кына йөри. Балта түтәсенә сугар алдыннан, үз-үзенә көч бирер өчен, «һоп!» дип кычкырырга да онытмый әтисе. Самавыр чаклы дәү түмәр чырт-чырт ачыла да тукмак басымына түзә алмыйча бер заман кап урталай ярылып китә.

Аннары әлеге яркаларны, берәр пүлән зурлыгында калдырып, як-яктан турап чыгалар. Агач түмәрнең төрлесе бар, бигрәк тә ботаклысы тиз генә бирешергә теләми. Әтисе, акыл биргән кебек итеп, инде ботаклы агачны ничек ярырга кирәклеген өйрәтә башлый:

— Балтаны ботакка беркайчан аркылы чапмыйлар. Юкса, кереп каба да, кәҗә маеңны чыгара ул. Балта йөзен агачның үзәгенә туры китергәндә генә ботакны җиңеп була... Әһә, һаман бирешмиме? Ул чагында аны чөй белән куркытабыз!

Боларны әтисе әнә шулай сөйли-сөйли, күрсәтә-күрсәтә эшли.

Шулай тырыша торгач, байтак утынны турап ташладылар. Ял итәргә генә утырганнар иде, капка ишеге ачылып китте. Түбән очның Этәч Закиры икән... Бернинди этәчлеге юк, бу кушаматы аңа этисеннән күчеп калган. Имеш, сугыштан соң этисе базарга этәч сатарга киткән моның. Базарга тикле урман аша узасы бар икән әле. Менә шунда этәче тота да урманга кереп кача тегенең. Артыннан куып та карый, тик теге хәерсез нәрсә суга чумгандай юкка чыга. Буш кул белән кайтса кайта, ләкин кушаматлы була этисе...

Эре-эре атлап килгән уңайга Этәч Закиры сәлам бирде, утын өемнәрен күргәч:

— Эшләрегез каты икән, — диде.

— Тырышкан булабыз,— дип, әтисе бер сәбәпсез көлеп җибәрде. Кордашының килеп керүенә шат күренә иде ул.

— Сөйләшкәнчә, кордаш...— Этәч Закирының нинди дә булса йомышы бар иде булса кирәк, куен кесәсенә ишарәләде.— Алып та килдем мин аны.

Яннарында Госман булгангамы, бүтәнчә сүз куертмадылар. Әтисе ым кагу белән, лапаска кереп киттеләр. Малай бүрәнә өстендә утырып калды. Олылар эшенә тыкшынуны яратмый иде ул. Үзләре ярган утын агачыннан каен тузы кубарып алды. Кәгазь юкалыгы шушы нәрсә, ике ирен арасына куеп өрсәң, йомрандай әче итеп сызгыра башлый. Мавыгып китеп, этәч килгәнен күрми дә тора икән. Кызыл кикрик, башын бер якка кыйгайткан да, ят тавышны сәерсенеп тыңлый. Малай, бу шөгылен ташлап, үзе этәчне күзәтергә кереште. Тавыклар патшасы җирдә яткан кайры черекләре арасыннан тырышып-тырышып корт эзли иде.

Этиләренең мыдыр-мыдыр сөйләшкәне ишетелде. Лапастан чыгып та киләләр икән. Йорт хуҗасы җилкәсендәге капчыкны дөпелдәтеп җиргә төшерде. Малай, «дөп» иткән тавыштан, капчык эчендә буш бидон ятканлыгын аңлады. Ферма бидоннарын әтисе нигә шулай уңга-сулга тарата икән? Нигә икәнлеге аңлашыла: әнә ничек «кәефләнеп» чыккан ич ала ...

— Капчыгын кайтарырсың. Мин фермага киттем.

— Әлбәттә, — диде Этәч Закиры һәм капчыклы йөкне җилкәсенә

атландырып чыгып та китте. Госман ирексездән төлке белән әтәч турындагы мультфильмны исенә тшере: әнә төлке кетәклеккә кергән... әнә капчыгындагы әтәчне әләктереп качып бара. Әнә аны куа чыктылар...

Кушаматы «әтәч» булса да, Закир абый әкияттәге төлкегә бик тә охшаш иде бу минутта. Тик аны куа чыгучы гына күренми. Тормыш белән әкият арасында зур аерма бар, күрәсең.

Әтәч Закиры, гомумән, куен кесәсен буш йөртми иде булса кирәк. Аннары ул моны Госманның әнисеннән һәрвакыт яшереп эшләргә тырыша. Бозау сую тарихында да нәкъ шундый хәл килеп чыкты ич.

...Нәрсә булгандыр бичаракайга — күзгә генә карап торган җан иясе язга кергәндәрәк тәмам тамактан язды, ябыкты. Мөлдерәп карап торулары кызганыч үзенең. Мантымый башлагач, аны суярга булдылар. Чакырыптырмы, әллә борыны сизепме, әтисенә ярдәмгә Әтәч Закиры да килеп җиткән. Госман киенеп тышка чыкканда алар инде бозауның яртылаш туналган гәүдәсен, аягыннан тияккә әләктереп, юан аркан белән сугым киртәсенә асып та куйганнар иде.

— Кешедән усал нәрсә юк дөньяда, энем. Күрәсеңме, әле генә аякта йөргән җан иясен «ә» дигәнче нишләтеп ташладык, — диде Әтәч Закиры, малайның гаҗәпләнеп карап торуын күргәч.— Син бу тирәдән китеп торсаң да ярар...

Әтисе аның бу сүзләренә кулын гына селтәде:

— Ир бала ирләр эшен күреп үсәргә тиеш ул.

Әтәч Закирының тел төбендә бүтәнчәрәк нәрсә яткан икән.

— Бисмилла әйтеп чалдык. Инде... нитеп алсак та ярыйдыр, кордаш, — дип, як-ягына каранып алды ул һәм куенына үрелде. Әтисе, аның сүзләрен хуплап, баш какты. Госман үзенең китеп торырга тиешлеген аңлады. Баскыч төбендә аңа кулына чиләк-чүмеч һәм тастымал тоткан әнисе каршы очрады. Чиләктә — кул юарга дигән кайнар су иде.

— Әйдә, улым, әтиләрең кулына суны син салып торырсың, булмаса.

Госман әнисенә иярде. Алар килгәнне күреп, ирләр ашык-пошык рәвештә бозау түшкәсенә иелделәр. Бигрәк тә Әтәч Закирының хәрәкәтләрендә кабалану сизелә иде. Әнисе авыз ачып сүз әйтергә дә өлгермәде, ул борчулы һәм куштан тавыш белән:

— Менә, Саимә, бозавыгыз нәрсә йоткан булган, бичаракай,— дип, гөнаһсыз малның бугазыннан буш «чикүшкә» шешәсе тартып чыгарды.

Канлы шешәне күреп, әнисе гаҗәпләнде, аптырап калды, билгеле.

— Әй аллам, бозау аяк астындагы теләсә нәрсәне чәйни, йота, диләр шул аны. Әнисеннән аергач, шешә белән сөт эчергәли идем, әллә шул гадәтен куды микән?

— Менә монысын хак әйтәсең, хатын,— диде әтисе сүзгә кушылып.

— Ә син дәшми калыр идең ичмасам! Сатып алган чирең үзеңә генә түгел, бозау язмышына да төшкән әнә, — дип, әнисе аны җиңелчә битәрләп алды.

Бәрәңге тукмагы хәтле генә чикүшкәнең бозау тамагына сыюы әллә ни гаҗәп түгел. Тик менә кай арада бушаган, кай арада анда күчеп өлгергән ул? Юкса аның баярак кына Әтәч Закиры куенында ялтыраганын Госман үз күзләре белән күреп калды ич... Әйе, Закир абый хәйлә корды, алдашты, тик менә әтисе нигә аңа кушылды, үзенең дәшми калуы белән алдашуга юл куйды икән? Малай бу сорауга җавапны төсмерли, ләкин әтисе белән әнисен ачуланыштырасы килми иде аның.

Әнисе өйгә кереп киткәч, ирләр икесе тиң мыек астыннан мәгънә-

ле генә елмаеп куйдылар. Әтәч Закирының теле чишелеп үк китте:

— Беләсеңме, кордаш, — дип сүз башлады ул, туныйсы тиренең сырт өлешен баш бармагы белән каезлап.— Буш шешәләр белән тәҗрибәнең төрлесен ясап караган бар минем. Майбәдәр карчык беркөнне морҗасын төзәтеп бирүемне үтенде. «Тиешле акчасыннан тормам, энем, рәтләп кенә бирче шуны»,— ди бу гозерләнеп. Миңа нәрсә, ике кулга бер эш дигәндәй, килеп тә җиттем. Морҗасының төтен юллыгы җимерелгән икән. Тыштагы берничә кирпечне кубарып, эшкә дә керештем. Күрәм: өстәлгә шешәле нәрсә чыгарырга уенда да юк моның. Төбендә генә калган нәрсәкәйне куенга кыстыра килгән идем. Карчык ишегалдына чыккан арада тиз генә шуның белән тамак чылаттым.

— Шуннан, шуннан? — диде әтисе аны куәтләп.

— Шуннан әлеге буш шешәнең төбен китеп төшердем дә, якъяктан кирпеч белән камап, төтен юллыгына тыгып калдырдым. Икенче көнне иртүк килеп җиткән Майбәдәр карчык. «Закирҗан энем, морҗабыз үкерә, зинһар, тагын бер карап кына алчы шуны», — дип ялвара бу. Яңадан бардым, караштырган булам. Мичкә ныграк яксаң, һава өскә суырылганда шешә авызының ничек үкергәнен белеп торам үзе. «Маһибәдәр җиңги, бер яртысыз да рәтләп булмас моны»,— дигәч, карчыгың чыгарып куйды бит яшергән запасын. Шуннан соң гөлләр иттем морҗаны, әле дә рәхмәт укып туймый!

Закир абый сөйләп бетергәч тә әтисе иң әлек кычкырып көлде, аннары кинәт җитдиләнеп:

— Безгә төрттереп куюың түгелдер ич бу? Курыкма, мондый мәшәкать уңаеннан Саимә сыйламый калмас үзебезне,— диде.

Әтәч Закиры аны тынычландырырга ашыкты:

— Юк ла инде, булмаганны! Чикүшкәне мин, эш башына күчтәнәч булсын, дип, кенә алып килдем. Син бит моны яхшы беләсең.

Үзе тыңлады Госман, һаман бер нәрсә турында сөйләшәләр, дип, аларны сабыйлыгы белән җәлләп тә куйды.

Менә нәрсә газаплаган икән аны: эчәгеләрен эшкәрткән чакта бозауның ашказаныннан чабата хәтле бияләй килеп чыкты! Йон бияләй диярлеге дә калмаган тегенең, тапталып, яшелләнеп беткән, мунчалага охшаш иде ул. Мескен бозау табакларга турап салганнан соң да кызганыч иде әле.

Ирләрнең ни өчен шундый тәмсез исле сыеклыкны эчкәнен, аңардан ни юаныч тапканын малай берничек тә аңлый алмады. Әтисенең исерек, бигрәк тә чайкала-чайкала кайтып кергән чагын күрсә, ул аны кызгана, аңардан ераклаша иде. Ничек кыюлыгы җиткәндер: бервакыт шулай да, үзен җиңеп, сәрхүшләнеп кайткан әтисенең янына ук килеп утырды ул. Әтисе, сизмәмешкә салышкандай, баштарак оеп, тын гына утырды. Түзмәде, зиһене ачылып китеп, кытыршы куллары белән Госманның чәченнән сыйпады. Менә шушы хәрәкәт инде болай да нәүмиз малайның күңелен нечкәртеп җибәрде.

— Әти, әти, бүтән эчмә! — диде ул йорт башының тәмәке исе сеңгән киемнәренә капланып. Аннары, калкына төшеп, ике йодрыгы белән күз яшьләрен сөртте.

Әтисе аны әллә чынлап, әллә юатып:

— Ярар, улым, соңгы тапкыр бу... Бүтән эчмәм,— диде. — Ә хәзер миңа йокларга кирәк...

Мондый көннәрдә әнисе борчулы йөри, юньләп сөйләшми. Сөйләшсә дә, иренә ачулы сүзләр белән җавап кайтара. Ярый да шундый чакта әтисе дәшми калса...

Икенче көнне инде әтисе, гаепле кешедәй, сөйләшми йөри, чүмечләп салкын су гына эчә. Госманга әйткән сүзендә тора ул, кичен аек килеш кайта. Гаиләдәге кичәге борчулар каядыр артка чигенә, өйдә

тынлык, үзара аңлашу урнаша. Тик озакка түгел, берничә көннән тагын шул ук хәлләр кабатлана. Аннары этисе, ишегалдында туктальш ясап, капка баганасы белән «сер»ен уртаклаша:

Калхуз — диңгез, без — парахут,
Уртасыннан йөзәбез...

Бу — аның үтә «кәефле» чакларда гына җырлана торган җыры.

Берсендә, кыш көне, этисе бөтенләй кайтмыйча калды. Ферма өендә куна калган, дип уйладылар. Ә ул, кайтып җитә алмыйча, юлда кар өстенә ятып йоклаган икән. Чәче һәм бишмәтенең бер җиңе кар өстенә ябышып каткан. Кичен клубтан кайтучы яшьләр күреп алмаса, үзе тиз генә уяныр иде микән ул? Ябышып каткан чәчен, җебетеп азапланмыйча, кайчы белән генә кисеп алганнар. Гәүдәсен кубарганда бишмәтенең җиңе умырылып калган, билгеле...

Госман бу хәлләрне икенче көнне генә ишетеп белде. Аңа этисе өчен оят, хурлык иде. Качып кына елаган чакта үзенең көчсезлеген, бәләкәйлеген тойды. Бөтен күңелсезлекләргә аракы гаепле иде шикелле. Дөньяны ничек итеп яхшыга таба үзгәртәсен белми иде әле ул. Күңеленең кай төшендәдер нәфрәт яралгысы барлыкка килде, үзенә чыгар сукмак эзләде.

Форсат көтмәгән-уйламаган җирдән калкып чыкты. Ишегалдына май ае кергән, койма буендагы чирәмнәрне кояш иркәләгән чак иде. Госман, юк эшен бар итеп, лапастагы әрдәнәлеккә керде. Эреле-ваклы утыннар арасыннан юка каен тузы кубарып алырга да, шуны сызгыртып карарга иде исәбе. Актарына торгач, бөтенләй уйламаган нәрсәгә тап булды ул: ике утын арасындагы бушлыкта башланмаган шешә посып утыра иде!.. Бу хәерсез табыштан Госманның баштарак күз аллары караңгыланып китте. Кем булсын, этисе яшергән, әлбәттә, шулай качып эчә торган гадәте бар ич аның.

Нишләргә? Күрмәмешкә салышып китеп барыргамы? Әллә... Госман табылдык нәрсәне курка-курка гына кулларына алды. Шешә саллы, авыр күренә иде, кузгаткан чакта эчендәге сыеклык сәер генә чупылдап алды. Малай нәни кулларында агу тотып тора — этисенең бөтен яхшылыгын, кешелеген юкка чыгара, өйдә еш кына гауга тудыра торган әшәке агу. Малайның нәфрәте учына, бармак очларына ургылып төште. Хәзер инде, тәвәккәлләп, соңгы хәрәкәтне ясыйсы гына калган иде... Хәйран көч белән ыргыткан шешә әрдәнә почмагына килеп бәрелде. Госман аның «доңк» итеп бәрелүен, чатнап пыяла ватылганын ишетте. Эчендәге байлыкның «ә» дигәнче шыбырдап акканы, утын башларының чылануы исә кыска төш шикеллерәк хәтерендә калды. Әллә дөрес эшләде, әллә юк — шушы ике хис буталчыклыгын җиңеп, бу тирәдән тизрәк качу хәерле иде.

Аяклары үзеннән-үзе инеш буена алып китте. Госман, игътибарын читкә юнәлтү өчен, су өстендә йөзеп йөргән каз бәпкәләрен санарга кереште. Буталды, яңадан башлады. Каз бәпкәләренең тамчы да батмыйча шулай табигый йөзеп йөрүләре гаҗәеп иде. Госман әнә, суга кердеме, аяк-кулларын туктаусыз хәрәкәтләндереп торырга тиеш. Юкса бөтен гәүдәң аска китә башлый, авыз-борынга су тула.

Биредә инеш буе аулак иде. Буа — авылның түбән очында, малайлар күбрәк шунда кайнашучан. Госман анда барасы итмәде, бүген аңа ялгызы да бик тыныч, рәхәт иде. Чирәмгә ятып, үлән арасыннан аваз бирүче дәртле чикерткәләрне күзәтте. Алар, кемдер чиртеп җибәргәндәй атылып, бер үләннән икенчесенә күченәләр. Әнә, әле бөреләнеп кенә килгән шайтан таягы чәчәгенә энә карагы килеп кунды. Төрле төстә ялтыраган үтә күренмәле канатлары нәфис, соклангыч иде бу затның. Ни өчен энә карагы дигәннәр аңа — белмәссең.

Төш җиткәндәрәк Госман өйләренә кайтты. Кайтып керер алдыннан гына күңеленә шик, курку үрмәләде аның. Лапас вакыйгасы

суынмыйча, кайнар килеш көтеп торадыр шикелле. Күңеле дөрес сизенгән икән, шулай булып чыкты да: лапас эчендә, чыннан да, ыгы-зыгы купкан чак иде! Әти-әнисенең ни өчен кычкырышканын аңлар өчен ул лапас почмагына елышты. Сагаеп кына эчтәге тавышларга колак салды.

— Кысыр башың белән талашып торганчы, лутчы әнә бала табу турында уйлар идең,— дип җикеренә икән әтисе.

— Тагын шулай мыскыллыйсы булсаң...— дип, әнисе нидер әйтергә теләгән иде, ирнең ачулы тавышы аны бик тиз бүлдерде:

— Кара, янап маташа тагын! Синнән курка торган бүрегем әллә кайчан тузган инде минем.

— Юньлегә түгел синең бу кылануларың.

— Ә синеке юньлегәме? Кая куйдың, нигә ваттың минем запасны?

— Валлаһи дип әйтәм, күргәнем дә юк андый нәрсәне! Ватылган икән, бик әйбәт, эчми торырсың әнә.

Госманның эче «жу» итеп китте. Яхшы нияттән эшләгән эше начарлыкка булды микәнни? Ул бит әтисенә дә, әнисенә дә бернинди начарлык теләмәгән иде. Никадәр генә кыен булмасын, хәзер ул чын дөресен әйтеп бирергә, әти белән әнисе арасындагы гауганы туктатырга тиеш.

Тик ничек әйтергә моны, аякларын җирдән аерып, лапас ишегенә кадәр ничек барып җитәргә? Иң авыр адымнар иде бу. Үзен җиңәҗиңә, Госман шушы араны үтте, уңайсызланып зурлар каршына килеп басты. Малайның нидер әйтәсен сизеп тегеләр тынып калды.

— Әти, шешәне мин ваттым, түлке әнине орышма...— дип әйткәндә аның күзләреннән терекөмештәй ике яшь тамчысы төште.

Әтисенең бөтен ачуы шундук малайга күчте.

— Шулаймы? Әле син, борын астың кипмәс боры, атаң тапкан мал белән шаярасыңмы? — диде дә кисәктән генә Госманның яңагына сугып җибәрде.

— Нишләвең бу? Баланы харап итәсең ич!

Госман, үзе дә сизмәстән, чайкалып киткән уңайга болай да әнисе куенына барып кергән иде. Шунда үкенечле бер хис белән беренче тапкыр диярлек ана кочагының кирәклеген аңлады ул. Яңагы авырткан өстенә, авыз эчендә җылы һәм тозлы ят тәм барлыгын да тойды...

Чәйнекне ваткан өчен әнисе бервакыт аны шулай ук кыйнарга җыенган иде. Ул чакта, баланың ни гаебе бар дип, җәзадан әтисе аралап калган иде аны. Бүген әнә киресенчә килеп чыкты. Аңламассың бу өлкәннәрне...

* * *

Буа тыкрыгы — малайларның иң яраткан урыны. Кояшта кызыну һәм су коену өчен шуңардан да кулай җир юк авылда. Чирәмдә ятасың-ятасың да, аннары «чулт!» итеп берәм-берәм инешкә чумасың. Еракка чумуда ярышасың. Андый чакта иң яхшысы — елга төбенә кадәр чумылып төшәргә дә, аяк бармакларын ләмле балчыкка тери-тери әйбәтләп этенергә кирәк, юкса коры кул белән су ишеп кенә әллә ни ерак китә алмыйсың. Бу хәйләне Госман уйлап тапты, тел яшереп тормыйча иптәшләренә дә сөйләп бирде.

Узган ел җәй җылы һәм яңгырлы килгән иде. Шуның хикмәтедерме, тыкрык буендагы кычытканнар котырып үсте. Алар — усал, чага-нитә калса, яман ачыттыра. Сипкел белән Саесканның тәле кебегрәк! Беркөн Госман таякка агач «ат»ка атланып килде. Тыкрык-

та әлеге берәү дә күренми иде. Менә шунда үзе өчен бик кызыклы уен уйлап тапты ул. Сул кулы белән «агач ат»ын иярләде, «кылыч» итеп уң кулына тагын бер таяк тотты. Әнә шул рәвешле «дошман» өстенә ташланды. Әй тураклый, чаж да чож кырып кына сала кычытканнар гаскәрен! Бөтен тыкрык кычыткан исе белән тулды.

Үзләре белән берничә малай ияртеп, бераздан Хәмит белән Сәмит тә килеп җиттеләр. Кычытканнар онытылды. Күлмәк-чалбарларын тыкрыкта калдырып, тизрәк инеш буена йөгерделәр.

— Әйдәгез, ярышабыз! Су астында кем озаграк торыр икән? — дип, Хәмит яңа уен тәкъдим итте.

— Әйе, кем озаграк торыр икән? — диде Сәмит аңа куштанланып.

Беренче малай суга чуму белән санарга керештеләр:

— Бер, ике, өч, дүрт, биш...

Кырыкка тикле түзде бу, шуннан соң пошкыра-пошкыра су эченнән атылып чыкты. Сәмит — кырык бишне, Госман кырык тугызны җыйды. Чират Хәмиткә җитте.

— Сәмит санасын минем күпмегә түзгәнне, — диде ул.

— Әйе, үзем саныйм,— диде тегесе белдекле кыяфәттә һәм, Сипкел суга ташлану белән, тырыша-тырыша, бармакларын бөгә-бөгә аның су астында күпме торганын исәпләргә кереште. Саескан димә син аны: акрын гына саный башлаган җиреннән берзаманны шундый кызу такылдарга тотынды бу, шулай итә-итә Хәмитнең күрсәткечен «алтмыш ике»гә җиткерде.

— Су астында иң озак торучыга дан! — дип, Хәмитнең әле су тамчылары да кибәргә өлгермәгән беләген өскә күтәрде.

Малайлар, Сипкел белән әләгешәсе килмичә, бу рекордны теләр-теләмәс кенә таныдылар, билгеле.

Кояшта бераз кипшенеп алгач, Сипкел урынынннан сикереп торды:

— Әйдәгез, хәзер йөгереш үткәрәбез. Куш өянкене күрәсезме, барыбыз да шунда киттек. Ә син, Сәмит, монда кал. Менә таяк, майкаңны бәйлә дә, шуны селтәп безгә сигнал бирерсең.

Сөйләшә-сөйләшә куш өянке янына киттеләр. Чирәмнән ялантәпи бару искиткеч рәхәт, ярыш дәрте үзенә бер тынгысызлык белән күңелләрен кытыклап тора иде. Өянке карт инде, аның кытыршы һәм яргаланып беткән кәүсәсендә әллә ничаклы истәлекләр посып ятадыр сыман. Шуның күләгәсенә тезелеп бастылар. Менә Сәмитнең майкасы, кузгалырга диган мәгънәне белдереп, кинәт кенә аска кадалып төште. Шул сигнал, әйтерсең, малайларны баскан урыннарыннан кубарып алды! Ялангач беләкләр, һаваны ишә-ишә, аяклардан да ныграк хәрәкәтләнә. Җир, күк, болытлар — болар һәммәсе дә сиңа кушылып йөгерә, кушылып әйләнә, артыңнан чаба шикелле.

Берзаман Госман, җан көче белән ыргылды да, алга бәреп чыкты. Аның үкчәсенә бастырып диярлек Сипкел килә... Тыннары бетеп, сулышлары кабып, тыкрык чирәменә капландылар. Госман беренче килгән иде.

Сипкел каршында уңайсызланыпмы, Сәмит йөзен-кашын җыерды. Ләкин бурычын ахырга кадәр үтәргә кирәк иде аңа. Бу юлы ул бик сыек кына итеп:

— Беренче килүчегә... дан, — диде һәм Госманның уң беләген өскә күтәрде.

Малайлар берәм-берәм таралып беттеләр. Госман йөгерештә беренче булып килүеннән канәгать иде, ул да авыл читендә ялгызы гына моңаеп утырган өйләренә кайтып китте. Кайтып җитәрәк кесәсенә кулын тыккан иде, корт чаккандай кире тартып алды. Кулын нәрсә соң шулай көйдереп алды аның? Сак кына актара торгач күрде: чалбар кесәсенә кемдер кычыткан яфрагы салган лабаса! Сәмит эше

микәнни? Сигнал бирергә дигән булып, тыкрык буенда ул калды ич...

Кул аркасы һәм бармак аралары үтереп сызлый да башлады. Анда тимгел-тимгел кызыл таплар бәреп чыккан иде, шулар кычыта, ачыттыра. Башта сыйпап, аннары кашып карады, сызлану исә көчәйде генә. Малайның рәнҗү һәм гарьләнүе төер булып тамагына утырды...

Икенче көнне рәнҗүнең тагын да зуррагы көтеп торган икән аны.

Тыкрык башына гына кергән иде, Госманны Хәмит белән Сәмит куып җитте.

— Кичә кычыткан тәмле булдымы? — диде Сипкел.

— Әйе, тәмле булдымы? — дип куштанланды Саескан.

Госман аптырап калды, тегеләр үзләренең гаебен шулай тиз генә әйтеп салырлар, дип бөтенләй уйламаган иде ул. Сипкел сүзен дәвам итте:

— Хәтерлисеңме, теге чакта арифметикадан күчерергә бирмәгән идең. Синең аркада без «ике»ле алдык ул көнне. Кичә шуның өчен бүләк алдың син!

Саескан исә, «әйе»сен әйтергә дә онытып, туп-туры һөҗүмгә күчте:

— Кичә йөгерештә дә бик масаеп киттең. Бездән узып йөрердәй булсаң, тиз туктатырбыз үзеңне! Син бит безнең авылныкы түгел, бары асрамага алган малай...

Бу сүзләр кычытканнан да, этисенең теге чактагы сукканыннан да болайрак итеп Госманның йөзен, алай гына түгел, бөтен тәнен, җанын өтеп алды. Әйтерсең, күк ишелеп төште дә аларның өчесен бер чатыр астына ябып куйды. Монда тар, кысан, һава җитми иде! Монда ул алар белән бергә калырга тиеш түгел — шушы чатырны ертып, тизрәк икенче дөньяга чыгарга кирәк. Ә гарьлекне нишләтергә? Госман үзе өчен кулларыннан да ышанычлырак ярдәмче күрмәде бу минутта. Бар ачуын йодрыгына йомарлап, «Саескан тәре!» — дия-дия, Сәмиткә ташланды.

Ике малай, яшь этәчләрдәй оча-кунып, чирәм өстендә әүмәкләшә дә башлады. Әле берсе, әле икенчесе өскә чыга. Госман өскә чыккан саен Сипкел аны аска әйләндереп төшерә... Әнә шундый тигезсез көрәш булса да, кабыргасы авыртса да, Госман үкенү хисләре кичермәде. Саесканга тамчы да бирешмәде ич ул. Сипкелнең ярдәме генә хурлыклы җиңелүдән коткарып калды аны. Икенче юлы авызын үлчәбрәк ачар...

Әмма тиз генә күрешер микән соң алар? Моннан ары Госман алар белән уйнамаячак. Сәмитнең оятсыз чыраена ныграк кундырасы булган да бит, Хәмит комачаулады... Юк, юллары аерылды, арада упкын барлыкка килде. Тегеләр кайдадыр еракта, елганың аргы ягында басып торалар. Алар үзләре дә бу упкыннан куркалар, юл табалмаслар шикелле.

Хәмит белән Сәмит ноктадай кечерәеп, алар урынын дөньяга булган үпкә, рәнҗү, аңлашылып та бетми торган тагын әллә нинди хисләр биләп алды. Баярак ишеткән сүзләре, күпме куып караса да, колак төбеннән китми иде: «Асрамага алган малай...» Дөресме бу? Дөрес икән, үз этисе һәм әнисе кемнәр, кайда алар? Нишләп моңарчы бер дә эзләп килмәгәннәр соң? Боларга җавап юк иде. Аңлады: боларны ул берәүдән дә сорый алмаячак; үзеңә тигән бәхетсезлек турында нигә әле төпченергә — башкалар белгән саен ул зурая, тармаклана гына барачак ич. Кемнән, ничек итеп сорыйсың ди: тирә-якта бары бушлык, томан, билгесезлек иде...

*Малайга бәйсез рәвештә дөнья һаман үз кучәре тирәсендә әйләнә: кояшның иң биек ноктасына якынлашып килгән, аяк астындагы чикерткәләрнең атылышып уйнаган, эсселектән сусап-әлсерәп утыр-*

*ган агачларның туфрактагы ерак дымны сөзеп-сөзеп кенә яфрак биеклегенә кадәр күтәргән чагы иде. Үзенең борчу һәм сораулары чолганышында калган Госман бу хәрәкәтләрдән әллә читкә атлап чыкты, әллә, киресенчә, дөньяның талгын әйләнешенә яңа бер дулкын булып кушылды — моны тәгаен генә әйтү кыен иде бу минутта...*

Өйләренә ничек кайтып җиткәнен юньләп хәтерләмәде ул. Бакчада, миләш агачы каршында басып торуы гына аңына барып җитте. Малайны ниндидер хәвеф туктаусыз эзәрлекли, артыннан куып килә иде шикелле. Менә шунда ирексездән «Гөлчәчәк» әкиятендәге кызны, кыен чакта аның алмагачка ялварып әйткән сүзләрен исенә төшерде:

> Әйләнмәле алмагач,
> Бәйләнмәле алмагач.
> Соры бүре куып җитте,
> Яшерсәнә, алмагач,
> Яшерсәнә, алмагач!

Нәкъ шушы сүзләрне кабатлый-кабатлый миләшкә эндәшәсе, бушанасы килде аның. Миләш кенә аны аңлар, үзенә сыендырыр, яшел куллары белән иркәләп өскә — кешеләрдән, рәнҗүләрдән азат булган икенче бер дөньяга күтәрер иде шикелле. Менә шул чакта, капыл гына аҗаган яктырып киткәндәй, малайның зиһенендә илаһи бер фикер ялтырады. Йолдызларга кадәр үк барып җитмәсә дә, ул бер баскыч биеклегендә күккә күтәреләчәк, бүгеннән алып шунда яши башлаячак!

Малайның гайре табигый хыялы, никадәр генә сәер тоелмасын, аның нык ышануынча, чынбарлыкка якын, бик тә якын иде. Ул, вакытның бер минутын да әрәм итмичә, шундук эшкә кереште. Лапас һәм койма буеннан эреле-ваклы такталар ташыды, янәшәдәге келәттән пычкы, чүкеч һәм кадаклар алып чыкты. Аннары, элекке чакларыннан да остарак итеп, келәт түбәсенә үрмәләде. Иң озын ике тактаны алдан ук әзерләп куйган иде, шуларны миләш ботагы белән келәт түбәсе арасына сузып салды. Басма әзер һәм ул нык, ышанычлы күренә иде.

Инде хәзер булачак «өй»нең идәнен һәм түбәсен корырга кирәк. Он иләгәндәге кебек итеп, миләш төбендәге эрекмәннәр өстенә пычкы чүбе коела. Тукран тавышына охшап, бакчага чүкеч авазы чәчрәп очты. Эш кораллары, малайның ниятен аңлагандай, бәләкәй оста кулында шактый терчә, өметле хәрәкәт итте. Госман ялгышрак селтәнеп, чүкеч белән бер-ике тапкыр бармагына да сугып алды, әмма үҗәтләнеп түзде, еламаска тырышты, аның өчен корылманың тизрәк оешуы кыйммәт иде.

Тактага такта ялгана, малайның уйлары уйга ялгана...

Авылда моңа кадәр агач башларына сыерчык оялары гына хуҗа иде. Шуларга иш булып, әмма алардан зурлыгы белән нык аерылып торган өр-яңа куыш барлыкка килде. Аның басмасы келәт түбәсенә тоташкан. Шунда бөтен гәүдәң белән сузылып ятарга да мөмкин: гәүдәң — эчтә, аякларың тышта калачак. Тик менә ялангач идән, бераз ятып тору белән, кабыргаларыңның кайдалыгын бик тиз искә төшерә иде! Госман моның да әмәлен тапты — келәт почмагында эленеп торган иске бишмәтне менгереп җәйде.

Малай менә шулай күктә яши башлады.

Биредә аңа беркем комачау итми иде. Дәүләт «чик»ләрен бозып керүче дә күренмәде. Ул шушында китап укый, кыяр белән ипи ашый, хыял дәрьясында йөзә, хәтта кайчакларны йоклап та ала иде. Эти белән әнисе, үз мәшәкатьләре муеннан булганга күрә, малайдагы үзгәрешне әллә ни сизмәделәр. Аның иске такталардан куыш корып, көнозын диярлек шунда кайнашуына уен дип карадылар.

— Кара аны, егылып төшә күрмә! — дип кисәтү ясады беркөн әтисе астан.

— Хыялый икәнсең, агач башыннан төшкәнең юк, — диде әнисе аның бу сәерлегенә гаҗәпләнеп.

Малайның тирә-юнь белән элемтәсе өзелмәгән иде. Күзләре күргән, колаклары ишеткән чакта мондый мөмкинлектән качарга җыенмый да ул. Әнә кайдадыр трактор тырылдаганы колакка чалына. Биредән авыл йортлары, аларны да узып өскә үрләгән тупыллар рәсемдәге шикелле кечерәеп күренә. Аста, кул сузымы җирдә генә, ишегалды күзгә ташлана. «Кыр-кыр» килеп, анда ике тавык нәрсәдер бүлешә. Шифер түбәле агач йорт... Госман шунда үскән. Аны тәрбияләп үстергән ике кеше: ир белән хатын әнә шунда яшиләр, дөнья куалар.

Уйлап карасаң, аларның кайгысы Госманныкыннан зурырактыр да әле. Аларга бит бала кирәк. Кычкырыша башласалар, сүзләре һаман шуңа килеп төртелә. Шушы арада әнисе тагын врачларга барып кайтты. Госман да үзенең берәр энекәше яки сеңелкәше булуын тели, бик тели. Бәлки, шуннан соң әтисе эчүен ташлар. Бәлки, алар тату, күңелле генә яшәп китәрләр. Бала арбасын Госман үзе рәхәтләнеп тартып йөрер, елый башласа, бәбигә имезлек каптырыр иде... Агач башында, үзенең куышында яткан чакта, ул күп вакыт әнә шуларны уйлый, яшерен генә теләк тели иде.

Кайчакларны Госман җиргә «кунакка» төшә.

Төшми хәле юк, чөнки ишегалдын себерәсе, түтәлләргә су сибәсе, кичен казлар алып кайтасы бар аның. Һаман-һаман кыяр белән корсак тутырып булмый, ашарга да төшә, сөйләшми-нитми генә тәлинкәдәге ашны сыпыртып куя. Кайда куну дигән нәрсә генә четерекле булып чыкты. Төнгә агач башында калыр идең, әти-әнисе орышачак, барыбер җиргә чакырып төшерәчәк. Җәйгә кергәч, быел чоландагы агач караватта йоклый башлаган иде ул. Вакытның йокыга дигән өлешен хәзер дә шунда үткәрәсе итте. Юрганга төренеп, май кебек эреп йоклыйсың — нәрсәсе начар моның?

Үзенең уенча, Госман җәй буе әнә шулай күктә яшәде, җиргә кунакка гына төшкәләде.

Ләкин агач башындагы тормышына ияләнеп җитте дигәндә генә яраткан куышын ташларга туры килде аңа. Авыл күзгә керде, табигать кышка әзерләнә башлады. Бөтен агачлар шәрәләнеп, моңсуланып калганда бакчадагы миләш, киресенчә, матурланды, тәлгәштәлгәш утлар кабызып, тирә-юньне бизәргә ашыкты. Аңардан, нәни парашют сыман бөтерелеп, җиргә яфрак арты яфрак коелды. Җил ерак офык артларыннан салкын болытларны куып китерде, яңгырлар ешайды. Пыскаклап яуган яңгыр Госманның иске такталардан ясалган куышын да баштанаяк чылатып, каралтып ташлады.

Госман тагын җирдә яши башлады: мәктәпкә йөрде, бозда шуды, беренче кар төшкәнне көтә-көтә чаңгыларын хәстәрләде.

Экранда Кар кешене күрергә, аннары Арктиканы, ак кыйтганы эзләп сәфәр чыгарга берничә ай калган иде.

* * *

...Эңгер-меңгер әле куерып кына килгән чакта малай еракта ялгыз эскерт күреп алган иде. Турылап шунда китте. Ничә чакрым җир узгандыр, аяк-куллары, гәүдәсе арыган иде инде аның. Чаңгы таяклары да гер асып куйгандай авырайды. Малайның ашыйсы да килә иде. Эскерт бик вакытлы очрады аңа — ял итәр, җылыныр, тамак ялгап алыр. Өмете алдамады: япан кыр уртасындагы эскертнең бер ягын калын кар капласа, икенче ягында саламнары күренеп торган, куышка охшашлы ышык урын бар иде.

Чаңгысын салып, таяклары белән бергә эскерткә сөяп куйды.

Сумкасындагы шешәле чәйне, җылына торсын дип, куенына тыкты. Малай шушында төн кунарга кирәклеген аңлап алды. Моның өчен, саламны йолкып, куыш авызын тирәнәйтергә кирәк иде. Бу эшкә тотынганчы иң элек ашап алырга булды.

Саламга аркасы белән терәлеп утырды да, сумкасыннан чыгарып, тастымалдагы ризыкларын алдына җәеп салды. Ит кисәге салкын иде, кабу белән тешләрне камаштырды. Ипи белән бергә чәйни торгач кына җылынды, авыздан сулар китерде. Карыны ачкангамы, ризык бик тәмле иде. Шуңа күрә анысын ваклап-ваклап капты, йотып җибәргәнче авыз эчендә йөртеп, җылытырга тырышты.

Салкын ризык тәнгә әллә ни җылы китерми икән, киресенчә, бияләен салган арада бармаклары туңып өлгергән. Ризыкларны җыештырганнан соң малай куыш авызын тирәнәйтергә тотынды: эше дә барыр, бармаклары да җылынып китәр. Саламның исә бирешергә исәбе юк иде — ул тәмам тыгызланып, катлы-катлы булып яткан. Шулай да учка керә, йолкыган саен кисәге-кисәге белән сүтелеп чыга. Малайның туңган бармаклары, чыннан да, бик тиз җылынып китте, аркасына кайнар елдырым йөгерде.

Энә белән кое казыган шикелле, байтак тырышты ул. Бияләйләрен салып, хәтта яланкул йолкый башлады. Болай эшләгәндә салам тагын әйбәтрәк савылып чыга икән. Тик менә салам очлары бармакны чәнчә, пәлтә җиңе аша үтеп, беләккә кадала... Кинәт куллары бушлыкка кереп китте аның! Шикләнеп кенә тагын бияләен киде, бушлыкны капшап карады. Төргәк-төргәк бөгәрләнеп яткан ике салам арасы икән бу. Көчәнеп-көчәнеп йолыкканнан соң гына ике кочак салам, бер-бер артлы кубып, аяк астына тәгәрәде. Шунда гына малай җиңел сулыш алды — төн кунарга урын бар дигән сүз.

Кышкы көн кыска булганлыктан, бик тиз караңгы төште. Күктә, бозлы миләшләрне хәтерләтеп, тәлгәш-тәлгәш йолдызлар кабынды. Кинәт малайның үрелеп аларны тотып карыйсы килде. Ләкин йолдызлар аның өчен кул җитмәслек биеклектә иде. Менә шунда тагын бозлы миләшләргә үрелгән песнәкне хәтеренә төшерде ул. Эскерт һәм йолдызлар каршында япа-ялгыз калган малай үзен әнә шул песнәк хәлендәрәк тойды. Никадәр гаделсезлек: үзе теләгән бик күп нәрсәләргә көче җитми аның...

Үзеннән-үзе яктырып ай калыкты. Аның нурлары, үтә күренмәле юка пәрдә булып, кыр өстенә төшеп капланды. Караңгылык, чигенә-чигенә, ай хакимиятенә юл бирде. Кырда «шылт» иткән аваз да юк. Баягы саламнар кыштырдавы колак төбендә эленеп тора иде, тынлык анысын да кысрыклап чыгарды. Чү! Җир белән күк арасында ниндидер аңлашу бара, шуның авазы кар өстендә сизелер-сизелмәс кенә тирбәлә кебек. Шул тылсымлы авазларны тотарга, кайдалыгын чамаларга тырышып, баскан урынында катып калды малай, күңе е шом басты. Йөрәге типкән тавыш икән ләбаса бу! Тынычланып, ай яктысында коенучы эскерт тирәсен күздән кичерде.

Ниндидер сихри көч белән ай туктаусыз үзенә тарта, күтәрелеп карарга мәҗбүр итә иде. Нәрсәләр бар икән бу билгесез, галәм куенында көмеш табактай ялтыраган җисем кочагында? Малайның уйлары ай турында ишеткән әкияткә барып ялганды. Тынсыз, өнсез карап торган айның уртасында иңнәренә чиләк-көянтә аскан Зөһрә кыз шәйләнә иде. Малай, үз хәлен зе белмичә, әкияттәге ятимә кызны кызганып куйды. Җем-җем килгән хыялый сурәт малай өчен бик тә вакытлы иптәш, юаныч иде. Зөһрә кыз әнә биектә, малай исә эскерт кочагында төн үткәрер... Бәлки әле Зөһрә кыз да Җирдәге малайны күреп торадыр...

Йолкынган салам юрган булып хезмәт итәч иде. Сумкасын эчкәре урнаштыргач, малай үзе дә куышка кереп ятты, гәүдәсен тырышып-тырышып баштанаяк салам белән каплады. Суык кай арада тә-

ненә кереп өлгергән — баштарак туңдырып, калтыратып җибәрде. Аяк-кулларын гәүдәсенә тагын да якынрак елыштырды. Нык кына арыганга күрә, үз сулышы белән үзе җылынып, тиздән йокыга да китте.

Төшендә ул Арктиканы күрде, Кар кеше белән саташып чыкты. Чирләп киткәнен, температурасы күтәрелгәнен малай белми иде.

...Нәкъ шул сәгатьләрдә малай йоклап яткан эскерткә аклы-каралы бер эт якынлашты. Ай әле һаман да салкын нурлары белән япан кырны, эскертне һәм аңа сөяп куелган таяк-чаңгыларны коендыра иде. Этнең сизгер борыны якында гына кеше исе барлыгын сизде. Яңа актарылган салам тирәсендә арлы-бирле ташланып, ул шундук өрергә, хуҗасына хәбәр бирергә ашыкты. Хуҗасы килеп җиткәч, шыңшуга күчеп, аның аяк астында бөтерелергә кереште.

Төнге сунарчы, этнең сәерлеген һәм эскерт буендагы кечкенә чаңгыларны күреп, нидер барлыгын бик тиз аңлап алды. Мылтыгын җилкәсенә ташлап кулларын бушатты да көпшәк саламны аралый башлады.

...Туңудан чирләп, саташып киткән малай күзләрен ачкан бер мәлдә каршысында Кар кешене күрде. Әйе, чынлап та Кар кеше иде бу! Әле генә төшендә күргәнчә: ак халаттан, ак башлыктан, сакалмыекларын бәс каплаган, хәтта аркасында мылтыгы да бар. Ул нигәдер бик җитди, борчулы күренә, нидер сорашмакчы була, ләкин малайның җавап бирерлек тә хәле юк. Шуңа да карамастан, ул барыбер сөйләшкәндәй итеп иреннәрен кыймылдата, өзек-төтек авазлар чыгара, кайчаннан бирле зарыгып көткән очрашуны югалтасы килмичә, әле генә төшендә күргәннәрен саташа-саташа өр-яңадан аңында терелтә иде...

— Исәнме, Кар кеше? Мин синең янга килдем.

— Син ничек эзләп таптың мине?

— Бик озак килдем, ничә көн узганын хәтерләмим дә.

— Юлда курыкмадыңмы соң?

— Курыктым, ләкин кире кайту оят иде. Төнлә кибәндә кундым мин...

— Туңгансындыр ич, ничек аяк-кулларыңны өшетмәгәнсең әле.

— Мин җылы киендем.

— Юк, син туңгансың. Сиңа җылы ыр а кирәк. Әйдәле, палаткага керик.

— Кар кеше, мин әти-әниләрне ташлап киттем...

— Шулай ярыймы соң инде! Моннан ары алай эшлисе булма.

— Мин Арктикада, сезнең янда калам. Рөхсәт итәсеңме, Кар кеше?

— Рөхсәт итәрмен. Ләкин барыбер Зур Җиргә кайтарырбыз сине. Шушы көннәрдә самолет киләчәк...

— Кирәкми, Кар кеше! Мин бит кайтып китәр өчен килмәдем. Миңа шушында калу кирәк!

— Уйлашырбыз. Бу нәрсә миннән генә тормаячак.

— Кар кеше, шундый исем белән дәшкәнгә үпкәләмисеңме син?

— Нигә үпкәләргә, мин бит чынлап та Кар кешегә охшаган.

Малай Кар кешегә исәктән генә «этием» дип әйтергә батырчылык итмәгән иде. «Инде хәзер әйтсәң дә ярыйдыр»,— дип уйлады.

— Кар кеше, мин сиңа «эти» дип эндәшсәм, ачуланмыйсыңмы?

— Юк, әлбәттә. Минем бит нәкъ синең кебек улым бар, Госман исемле.

— Менә, мин булам ич инде ул! — дип шатланды малай ак халатлы «этисе»нең куенына ташланып.

— Шулаймыни? — дип гаҗәпләнде Кар кеше һәм малайны җиңел генә күтәреп алды да кочагына кысты.

— Эти, эти, без бергәләп әнине дә эзләп табарбыз, шулай бит? Кар кеше, ризалык белдереп, уйчан кыяфәттә баш какты.

...Малай аңында төш, хыял, чынбарлык өчесе бергә эн шулай килеп кушылды. Ул Арктикага барып җитүенә һәм Кар кешене эзләп табуына ш лкадәр нык ышанган иде ки, сунарчы кочагында аңа җиңел булып китте. Хәтта елмаерг азапланды.

Кар кешенең аучы икәнен белмәве белән беразга булса да бәхетле иде ул.

Сунарчы боларның берсеннән дә хәбәрдар түгел иде, малайның саташып әйткән сүзләреннән ачык кына мәгънә тапмады. Менә ул малайны кочагыннан төшерде һәм, ауга чыкканда гына кия торган ак халатын салып, аны баштанаяк шуңарга төрде «Туган тел» китабы һәм ризыклар салынган сумканы, анданиләр барын карап та тормыйча, тиз генә аркасына, дөресрәге мылтык көпшәсенә элде. Бераздан, малайны күкрәгенә кысып кочаклаган хәлендә, эскерт яныннан кузгалып китте. Һәрвакыт алдан барырга өйрәнгән эт, сунарның өзелгәнен аңлап, күндәм бер кыяфәттә хуҗасы артыннан иярде.

*Бозлы миләшләр сыман чекрәеп, күктә әле һаман төнге йолдызлар яна иде.*

* * *

Ишетәсеңме, малай, мин сиңа гомер уртасыннан эндәшәм! Тормыш сине, кып-кызыл миләшләр кебек, матурлыгы белән кызыктырды. Ләкин синең язмышка миләшнең ачысы, бозлысы эләкте. Никадәр сәер тоелмасын, бозлары эреп төшкәннән соң андый миләш тәмле була. Миләштәге бозларны эретү өчен сиңа вакыт һәм тормыш-яшәеш тәҗрибәсе кирәк иде.

Мин синең исән калуыңны һәм көннәрнең берендә үз акылың белән шушы хакыйкатькә ирешүеңне телим.

Беләсең микән, синең барлык кичерешләрең, яндырып-яндырып, минем йөрәк аша да узды. Синең белән бергә кайгырдым, шатландым, әллә ничә кат туңдым һәм җылындым мин. Эскерттәге салам сабаклары минем дә кулны һәм беләгемне тырнап узды. Арктикага кыйтгага барып җитәсемә мин дә шикләнмәдем. Синең пакь, керсез йөрәгең күтәрелгән биеклеккә асылда мин дә күтәрелдем. Синең фаҗигаң — минем дә фаҗигам иде. Ә фаҗига кешеләрне актан караны аерырга, уйлый белергә һәм сафлыкка өйрәтә.

Син эти-әниеңә начарлык теләмәдең. Хәмит белән Сәмиттән үч алырга җыенмадың. Чөнки табигать сине дөньяга гадел, намуслы, киң күңелле, әчкерсез итеп яраткан иде. Син бары дөреслек артыннан киттең, сорауларыңа җавап эзләдең. Бары шул.

Ишетәсеңме, мин синең исән калуыңны телим. Хакыйкать эзләү көрәшендә син әле намусыңны күп тапкырлар яманлыкка каршы калкан итеп куячаксың. Мин моңа ышанам.

*Февраль, 1990 ел.*

# Хәбир Ибраһим

## Стефани

Ара ерак. Еллар узган.
Һәр мәхәббәт сүнә, фани...
Дистәләгән еллар аша
Дәшәм сиңа, Стефани!

Күз алдымда — ачык йөзең,
Урман алды, Юзя[1] яны...

Син ничектер, ә мин шул ук:
Үзгәрәлмыйм, Стефани.

Үпкәләүле күз карашың
Һаман истә, гүя «яный»...
Дистәләгән еллар аша
Дәшәм сиңа, Стефани!

*

Соңгы сүзең һаман борчый мине,
Борчый мине һаман язмышың...
Нигә шулай җанга якын икән
Еракларга китеп барышың!?

*

Мин чакырам сине.
                    Ә син юк!
Әйтерсең лә мин — Сак,
                    Ә син — Сок.
Әйтерсең лә төнге урманда
Ике сагыш йөри,
                    ике ут...

*

Куып җиталмәдем сине мин:
Син — бер бала, син гел йөгердең,
Син кырларга
          кереп
               күмелдең...
Ә ник миндә калды күңелең?

[1] Юзя — Трускавец курортындагы изге чыгыш-чишмә.

*Хәбир ИБРАҺИМ — яшь шагыйрь, драматург, шигырьләре «Идел» журналында басылды, пьесасы «Адым» театрында куелды. Казанда яши.*

# Мирһади Разов

❁

Бөре кебек шартлап ярылмакчы —
Кайнар хисләрдән тула
Йә эверелеп гөрләвеккә, җаным
Агып китмәкче була.

Газапланам. Әмма рәхәт газап —
Елыйм да, аннан көләм,
Йөрәгемне тере кисәкләргә —
Шигырьләр итеп бүләм...

❁

Чыклы таңда печән чаба егет,
Уйнап тора көчле беләкләре.
Бер кыз күзли аны тирәлектән,
Коя-коя җыйган җиләкләрен.

Омтыла ул егет тарафына,
Күзләреннән ташый сөю хисе,
Сихерләгән дәртле чалгы җыры
Һәм исерткән кызны чәчәк исе.

Шул халәттә сылу — ул егетнең
Кочагына очып керер иде,
Җиләк кебек, кайнар сулышыннан
Рәхәтләнеп изрәр, эрер иде.

Егет исә чаба каерылып,
Шатлык ташый аның күкрәгеннән...
Ә офыкта кояш күтәрелә —
Чыгып кызның утлы йөрәгеннән.

❁

Йоклый малай камыл арасында...
Яшь башаклар капшый Җир күкрәген.
Тып-тын. Җилләр поскан күләгәгә,
Тыңлый дөнья нәни ир йөрәген.

Бу башаклар сөттән тулыр әле,
Дәрт уятып исәр төн җилләре.
Малай үсәр — кызлар серен белер,
Ымсындырыр аны кыз билләре.

Гашыйк булып бирәр гүзәл гөлгә
Үзенеке итәр шул чагында.
...Күктә кызлар тәне кебек болыт
Агып бара кемнең кочагына?

Их, гөнаһсыз чаклар! Вакыт үтәр,
Буразнага язлар орлык салыр.
Кыз куены учак булып яныр,
Бөртек — шытып, нәсел — җәер тамыр.

---

Мирһади РАЗОВ — *1960 елда туган. Шигырьләре «Беренче карлыгачлар» җыентыгында басылды. Чаллыда яши.*

Шәмдәлемдә ялкын калтырана:
Сүндем дигәч, кабат кабына.
Керфекләрне татлы йокы баса.
Һаман яңа сүзләр табыла.

Күп калмады инде яктырырга,
Тәрәзәмә кага таң җиле.
Офыкларның алсу елмаюын
Көтә инде минем җан — тиле!

Шушы мәлнең моңсу рәхәтлеге!
Салкынлыгы көзге таңнарның!
Елашуы тәрәз артымдагы,
Сандугачсыз калган талларның...

## Рәмис Аймәт

### «Сукыр тәкә»

Ефәк шәлең — чуклы сихер:
Күзләремнән урадың да,
Күлмәк җиңемнән тарткалап,
Үчекләдең Өн тавында...

Сез качтыгыз — бөтерелеп,
Җиде чатка, «хур кызлары».
Көлештегез, ә мин, юләр,
Эчтән генә сызып яндым...

Сезне эзлим кочак җәеп,
Кочагыма кем соң керер?
Абынамын... карашларың,
Бәлки — сиңа барыр күпер?!

«Тукта, егет, хәрәмләмә»—
Сискәндерде синең тавыш.
Тавышыңны яшен өзде,
Давыл купты... әллә каргыш?!

Ә бит — таптым, кочагыма
Килеп кердең үзең, көлдең...
Тик җанымны, көнләшепме,
Төне буе яшен телде.

Шатлыгымны җил тузгытты,
Йөрәгемдә шул ук ярам.
Ә син һаман кочагымда
Шашынасың: «Хәрам, хәрам».

Айлы кичтә сине эзләп
Таңнарыма сукмак салдым...
Шәлең чишеп эзләсәм дә,
Табылмадың, табалмадым.

...Чыны бармы бу уенның?—
«Шәлне чишсәң, хәрам, хәрам...»
Һаман дөнья буйлап, сине —
Күзем бәйле,— эзләп барам.

### Сөргеннән — җыр...

*Исә җилләр...*
Х. ТУФАН

Кыйбла яктан җилләр исә —
Бары салкын җилләр генә.
Барыр җир тапмыйча гүя
Оялыйлар йөрәгемә.

И җилләрем!
Керегез, кер,
Урыным җитә сезгә генә...
Ә мин барыплар кагылыйм
Кемнәрнең соң йөрәгенә?

---

Рәмис АЙМӘТ — *Казан дәүләт университетының татар филологиясе факультетында укый. Шигырьләре көндәлек матбугатта күренә килә.*

## Гарәфи Хәсәнов

# ШӘФӘКЪ ЧЫПЧЫГЫ

ПАРЧА



Кешенең асылын сүзе түгел, кылган гамәле ача. Чыннан да, берәү үзе турында шундый итеп тел тегермәне тарта, дус-дошман арасында шундый кече күңелле итеп күрсәтә, чын әүлия дип уйлыйсың. Ә икенче берәү алай җәелеп тә китми. Әйтерсең, сүзне сатып ала инде! Аның шулай аз сүзле булуын, аның шушы төксе кыяфәтен күреп, бу кешегә кайчан да булса, берүк, эшең төшә күрмәсен, дип әйтерсең. Ләкин чынлыкта — теге буш куык түгел, ә бәлки шушы аз сүзле кеше авыр минутларда җылы сүз дә таба, ярдәм кулы да суза.

Әйе, кемнең кем булуын кылган гамәле күрсәтә, дип бик дөрес әйткәннәр! Бу картлар сүзе, әлбәттә, безгә — кешеләргә карата әйтелгән. Ләкин ул, бер үк дәрәҗәдә, безнең кече туганнарыбызга да туры килә! Чыннан да, мохитыбыздагы һәрбер җан иясе дә үз-үзен яман йә яхшы ягы белән күрсәтә бит. Һәм без, шуңа карап, һәрбер тереклек иясенә «яман» йә «яхшы» дип мөһер дә сугып куйганбыз. Моның нәкъ шулай икәнлеген быел миңа бер бәләкәй генә кошчык, бер таныш шәфәкъ чыпчыгы бик ачык күрсәтте. Гүя ул үзе: «Мин бит сез уйлаганча бер яклы гына түгел, мин бит җанлы, мин бит киң колачлы», — дип әйтте.

Мәгълүм ки, шәфәкъ чыпчыгы туган якларына март ахырында ук кайта.

Димәк ки, туган як, туган урын күчмә кошларга да кадерле! Шушы сагыну хисе аларны озын сәфәргә кузгата, шушы сагыну хисе, адаштырмый-нитми, туган җирләренә җиткерә.

Безнең борынгы бабаларыбыз исемнең җисеменә туры килүен хуп күргән. Алар шәфәкъ чыпчыгының да кулай атын безгә мирас итеп калдырган. Урыслар да, нәни кошның шәфәкъ вакытында ничек сайравын искә алып, «зарянка» дип әйткәннәр.

Ләкин борынгы урыс агайлар әлеге кулай исемне генә азсынган күрәсең: «малиновка» дип тә атаган. Чөнки, кайчандыр, яңгырап чыккан бәллүр тавыш урысча «малиновый» дип тә аталган.

Бездә дә бу кошчык үзгә исемен алган. Чөнки ул кура җиләклеген дә хуп күрә. Хуп күрә, торыр урыны ук иттерә. Ул бит яз саен шунда кайта, шунда урнаша. Саф су бар, зирек агачы да бар, зирек бар җирдә — кура җиләклек тә бар. Безнең борынгы бабалар шәфәкъ чыпчыгының кайда яшәвен күргәннәр һәм, әнә шуннан чыгып, атның үзгәсен дә биргәннәр: кура җиләге чыпчыгы...

---

Гарәфи ХӘСӘНОВ (1921) — *«Җирем-суым», «Кошларым-дусларым», «Җир ул уртак йортыбыз» һәм башка китаплар авторы. Казанда яши.*

Бездә әле бу кошчыкның тагын бер исеме бар: каратүш. Анысының сәбәбен хәзер үк әйтмим әле, хикәяләү дәверендә ачылыр...

Бүген мин көткән кошчыгымны беренче тапкыр бик якыннан күрдем! Үзен күрдем дә, тын да алмыйча, аның көмеш челтәрәвен тыңладым. Сакаллы сабый ич мин: елмаеп куйдым. Елым уңышлы башланды, дип сөендем, шулай дәвам итәчәгенә өмет багладым. Инде катага «ут та капты» — аяк чыланды, инде кайчаннан бирле эчтә «этләр өрүен» дә сиздем. Өем дә әнә генә, кереп, тамак ялгарга да була, югыйсә. Ә үзем... Үзем һаман да, күзле бөкән булып, баскан урынымнан купмадым.

Якты таң-иртә... Тын һәм тантаналы вакыт. Менә саба җиле исеп куйды; һәм, нәкъ шуны көткәндәй, алсу күк гөмбәзенә алтын солы бөртекләре сибелде.

Күңелем тулы шатлык-куаныч! Бүген иң әүвәл шәфәкъ чыпчыгының көмеш тавышын тыңладым, аннары кояшны каршыладым, сызылып таң атканга — яңа көн туганга шаһит булдым.

Инде аяк та туңды, инде эчтә дә «ачлык корты» чынлап уянды. Хәзер бер минут тормый өйгә керәм, дидем, инде китәргә дә җыендым. Китәр алдыннан фәкать биек чыршыдагы таныш шәфәкъ чыпчыгына күз салдым. Ә ул, туңдым дип, ачыктым дип тормый, көмеш челтәрәвен өзми! Әлеге хәлне күреп, мин дә түзәргә ниятләдем. Имеш, шушы нәп-нәни кошчык сайрый бирсен, ә син, оялмыйча, өйгә кереп кит тә, өйдә утыр!

Ул арада кояш тәмам көләчкә әйләнде, инде күзне чагылдырды, җылы нурларын иңдерде. Ә теге кошчык дәртле сайравыннан туймады. Мин, бер исәр адәм, һаман тыңлый бирдем, күпме тыңласам да туймадым...

Төш җиткәч кенә, сайрар кошым аңга килде, биек чыршысыннан читкә таба очты. Мөгаен, бераз әл-хәл алыйм, дип тә әйткәндер.

Зәңгәр шәфәкъ иңгәчтен, кызыклы бер хәл шәйләдем. Бу нәфис кошчыкны мин тагын бер кат «каратүш» дип атадым. Чөнки аның алсу түше кичке эңгердә гүя үз төсен җуйды, карасуга әйләнде. Озакламый кошчык кичке караңгылыкта йотылды, ләкин шунда да көмеш тавышы тынып-тукталып калмады. Фәкать кара төн кергәч кенә, биек чыршысыннан аска таба чумды, чыршылар арасында юк булды, сайраудан тынды.

Вак кошлар арасында матур тавыш белән сайрау да көрәш коралы санала. Сугышны сайрау алыштыра, бары тик кан коймау гына кошлар арасында һәр төрнең сакланып калуын тәэмин итә.

Көннәрдән бер көнне шәфәкъ чыпчыгы, әдәпсезлек күрсәтеп, минем биткә кызыллык китерде. Болай булды бу хәл.

Менә ул, һич көтмәгәндә, көмеш өнен өзде, биек чыршысыннан түбәнгә томырылды, төшә-күтәрелә ачык урманга таба җилпенде. Менә кардәш, икенче бер нәни кошчык оя корган шомырт янына очып барды, шомырт агачының урта бер ботагына утырды. Әйе, бүтән бер урынга түгел, нәкъ менә оя янына урнашып, хуҗа сыман кукраеп килеп утырды ул. Әле, җитмәсә, оялуны да белми, бу бит чит биләмәнең үзәге дип әйтми, рәхәтләнеп сайрый да сайрый. Гүя, кояшлы ачык бу җирне үзенең шәхси биләмәсе итмәкче. Гүя, шул хакта әйтеп, әйләнә-тирәгә белдерә. Әллә соң ул күршесенең матур сайравыннан көнләшеп куйганмы? Әллә, янында сайрап, ярыш ачып, аны читкә кумакчы буламы? «Синең шәхси биләмәңдә сайрыйм, әйдә, кулыңнан килсә, түшеңне киер, әйдә куып җибәр», — ди әйтә кебек ул үз кыяфәте белән. Нишлисең бит, шәфәкъ чыпчыгының шундый гадәте дә булгач. Ниһаять, күңеле булып, шомырт ботагыннан купты ул. Купты да, очып та китте, үзенең биек чыршысына таба талпынды. Анда ул янә үзенең көмеш челтерәвен башлады. Ай-һай, аңардан мондый вакчыллыкны һич көтмәгән идем. Шул тикле матур сайрый торган кош начар күңелле, хосетле булыр дип уйламаган идем.

Ул арада кар качкан калку урыннарда яшел үләннәр дә баш төртте. Тау бите саен тыйнак умырзаялар балкыды. Алар — кар чәчәкләре — рәвешләре белән җирдәге йолдызлар кебек иде.

Инде яз яшел үләннәрен, нәфис чәчкәләрен күрсәтте. Нәкъ шуны гына көтеп торгандай, шәфәкъ чыпчыгы оя корып җибәргән зирек тирәсендә әнкә дускае да күренде! Димәк, әнкә кошчык моның сайравын да, торган урынын да яратты. Хәер, башта ул, очып-тикшеренеп, урман эчендәрәк тулганды. Ул әле, җимле урынмы, дип, җирдә — түбәндә дә мәш килде. Минем бит бала туйдырасым булыр, күрим-тикшерим, дип әйтте кебек ул.

Шул рәвешле иске танышым ялгыз яшәүдән туктады. Ул инде буйдак түгеллеген бөтен әйләнә-тирәгә җиткерде. Көмеш челтерәү тавышына үзгә аһәңнәр дә өстәлде: тыңлап туймаслык иттерде.

Су язы эшне бик тиз тотты, күчмә кошларны дәшеп кайтарды. Инде кайтканы бере туган урынын тапты, матур сайравын башлады. Һәм мин, колакка сагайгандай, шәфәкъ чыпчыгының көмеш өнен бик үк ишетә алмадым. Аны һәрьяклап килгән кошлар өне — сайрау авазлары каплады. Алар һәммәсе берьюлы урман яңгыратты, алар кояшлы ачык урыннарда да томшык йомуны белмәде. Башлап, бу күрше кошчыккайның көмеш челтерәвен сайрар баркылдык[1] моңнары күмеп китте. Ул иртәнге шәфәкътән үк чәйгә дәште, кичке шәфәкъта дә тынмады. Ул хәтта кояш баткач та дәшү-үгетләвен куймады: «Чәй эч, чәй эч, чәй чы-гыш-лы», — дип, әйткән өстенә әйтте. Әле, шуңарга өстәп: «Соңла-ма!» — дип, дәшә-сызгыра да торды ул.

Ниһаять, су язы үтте-китте, якты истәлекләр калдырды. Елның иң күркәм чагы — яшел май да керде, күздән шатлык яшьләре тамызды. Минем картлыкны оныттырган, көткән вакытым да шул инде! Әлеге чәчәкләр язы җылы яклардан мәшһүр кошкайны — сандугачны-былбылны — дөньяга бер сайрау остасын кайтарды. Инде сандугач сайравын ишеткәч, күздән йокы качты. Көндез дә, иртә-кич тә мәшһүр былбыл сайравыннан туймады. Аның өздереп сайравы баркылдыкны чәйгә дәшүдән туктатты, ничәмә-ничә төрле сайрар кошкайларны томшык йомдырды. Гүя, алар һәммәсе дә: без күмәкләшеп җырладык, хор башлап җибәрде, инде бераз тыйнаграк булыйк, сандугачның тавышы моңлырак, инде аны тыңлап карыйк, диде. Сайрау остасы кыстатып тормады, моңлы көйләрен сузып җибәрде.

Ә берзаман шундый вакыт килде — сандугач сайравына ап-ак шомырт болыты өстәлде. Инде хуш исле шомырт болыты өйгә юлны бүлде, күздән йокыны качырды.

Әйе, чәчәкләр язы килде, аның белән эшчән бал кортларына да, минем үземә дә көн килде. Инде картлыкны оныттырган эш һәм мәшәкать башланды. Мин тыңлап иялангән шәфәкъ чыпчыгы да көмеш чылтыравын киметте. Димәк, бу күркәм чаклар аның өчен дә тыгыз вакытка әйләнде. Үзе ул әткә кошчык, үзе көнозын оя типте, җылы күкәйләр өстендә утырды. Аны тик кичке шәфәкъ кына җылы оядан кубарды. Кубарды, көмеш челтерәвен башлатты. Шунда гына ул җылы күкәйләрне әнкә дускаена тапшырды. Үзе көмеш челтерәвен шундый тантаналы башкарды ки, көмеш өнен әнкә дускаена багышлады. Анда аңа төнозын оя тибәсе, дип, үзен ул ялгыз сизмәсен, дип тырышты ул. Үзе төнозын тышта калды, үзенең дускаен һәм оясын саклады.

Менә, ниһаять, кошчыкларның йөрәк парәләре кысан күкәйләреннән киң иркен дөньяга чыкты. Алар, борынлау белән, азык сорап, әткә-әнкәләрен утлы табага бастырды. Зурлар, үзләре ашамыйча, чират белән, җимне бирәр кошчыкка каптырды. Һәр бала кошчык: «Миңа бир!» — дип, сары томшыгын киң ачты, төпсез бугазын күрсәтте. Зурлар, ут капкан кебек, тагын очты, тагын әзләнде. Әткә кошчык, әнә шулай, көне буе азык ташыды, үзе төннәрен тышта гел йокысыз үткәрде: керфек тә какмыйча, оя эчендәге балаларын саклады. Ун көн эчендә нәни кошчыклар ныгып-зураеп та куйдылар: канатлы да, йонлы-каурыйлы да булдылар. Шунда инде боларның оялары кысанланды — һәркайсы ирек даулый башлады: аягүрә калкынырга тырышты, канатын җилпеде. Хәзер стена буйлап оя авызына менәм, аннан җиргә сикерәм, дип итенде. Чөнки шул кыска гына арада әлеге бала кошчыклар үсмер пырхылдыкка әйләнде. Алар, әлеге үсмер пырхылдыклар, тиздән оя ташларлар, җиргә сикерерләр, үлән арасында йөрерләр. Ләкин...

Гадәттә, шәфәкъ чыпчыклары кысан ояларында нәкъ унике көн яшиләр. Ә менә бу нәниләр, ун көн яшәгәннән соң, янә дә ике көннән канат җилпибез инде, дип кенә хыялланып торганда... ятим пырхылдыклар булып, ярым караучысыз калдылар. Әткә кош — тугрылыклы дустын, ә үсмер пырхылдыклар — газиз әнкәләрен җуйдылар.

Ә бит һәлакәт килер көнне кичке шәфәкъ шундый тантаналы балкыган иде! Ул шундый алсу булды, алтын нурларга бай булды. Һәм әткә кошкай да шундый дәртле итеп, шундый онытылып сайрады.

---

1. Дрозд (русча).

Менә таң атты. Иртән мин, әнкә кошны күпме эзләсәм дә, тапмадым. Аны ай күрде, кояш алды... Әйе, иртән мин, эшне бүлеп, шомырт янында да таптандым, ләкин аның җим эзләп җирдә йөрүен дә, өстә канат җилпүен дә күрмәдем. «Төнен, мөгаен, җиргә егылгандыр, шунда юкка чыккандыр,— дип әйттем мин.— Аны ерткыч кош, яки ерткыч җәнлек үткер тырнагына алгандыр». Тамакка каты төер тыгылды, аны күз яше белән тышка чыгарды, йотып җибәрә алмадым.

Әле бит, бәла ялгыз йөрми, яңа бәла ияртә, дип әйткәннәр. Картлар сүзе күңелемә кинәт курку салды. Инде берәр үсмер пырхылдыкның җиргә төшүеннән, шунда һәлак булуыннан курыктым. «Менә күр дә тор, — дидем, — яшьләр арасында берәр кыбырсыгы табылыр! Башта ул, оя авызына килеп, иркен дөньяга күз салыр, аннары канат пырхылдатыр — кысан оясын ук калдырыр!» Ә бит әнкә-әткә кошлар, гадәттә, оядан егылган кошчыкны юкка чыкканга саныйлар, һич югы оя тирәсеннән эзләп-нитеп тә тормыйлар.

Хәер, егылган кошчык поскан урынында дәшми-кыймылдамыйча утыра. Мөгаен, усал ерткыч сизәр, шундук һәлак итәр, дип куркуыннандыр инде. Һәм ул, иртәме-соңмы, яки ачтан үлә, яки, сакланса-сакланмаса да, берәр ерткыч тырнагына эләгә. Зурлар, шул хәлне белеп, оя ташлаучыга канаткулларын ук селтиләр. Ул бит барыбер һәлак булачак, дип, табып-туйдырып та маташмыйлар...

Күңел, чыннан да, дөрес сизгән... иртән бер үсмер кыбырсыгы кысан оясыннан иркен дөньяга күз салды! Башта ул оя тишегендә күзен тасырайтып утырды: аннары, канат пырхылдатып, таш күк түбәнгә атылды. Атылып та төште һәм, җиргә сеңгән кебек, яшел үләндә юк та булды. Әмма, аның посар урынын төшкән чагында ук шәйләдем дә сузмый-нитми шунда таба атладым. Янына килдем, өркетмичә генә, өстенә йомшак кәләпүшемне капладым. Аның йөрәге чыгардай булып типте. Кәләпүш аркылы үсмер пырхылдыкның назлы җылысын тойдым, ул ничектер якын булып китте. Шуннан инде, харап булмасын, дип, өйгә алып кайттым. Өйдә аксак һәм оча алмый торган гарип кошкайлар аңарчы да бар иде, бу үсмер пырхылдыкны шулар арасына агач читлеккә җибәрдем. Җирдән җим табып, кулдан азык алуын теләдем. Ә ул, әйтерсең, тәкәллефле кунак, йомшак азыктан баш тартты! Җимнән йөз чөерде, көчләп биргәч кенә ашады. Ә мин, барыбер, һаман таба тордым, һаман ирексезләп сыйладым. Мин бу сабыйның ачтан үлмәвен дә, миңа ияләнүен дә теләдем. Болай ул үзе, тора-бара, кулдан җим дә алды, аны күз ачып йомганчы ук һаман йота да бирде, алай ачыгып та куймады... Ләкин, ач булмаса да, сайрау тавышы чыгармады, тып-тын гына черкелди дә торды ул. Чынлыкта сабый исән калган әткә шәфәкъ чыпчыгын да юксынды, аны көтте. Ник соң ул очып килми, ник соң җим китерми? Җимне син түгел, әти бирсен, мине онытмасын, дип тә әйтте кебек ул миңа. Нишлисең, ябык форточканы шундук төбенәчә ачтым. Әткә кош ачык форточкадан зәгыйфь черкелдәүне ишетсен, очып керсен, үсмер пырхылдыкны сыйласын, дип озак көттем, ике күземне дүрт иттем. Аның очып керәсенә чын күңелемнән ышандым. Ятим ятимнең хәлен аңлар, аны ташламас, дип уйладым. Ә бит, чыннан да, нәкъ шулай килеп чыга: бер заман әткә кошчык җирдән күтәрелде, ачык форточкадан өйгә очып керде, агач читлеккә ябышты. Сабыена ул җим дә бирде, аның тәмләп йотуын да күзәтте. Өстәвенә әле, «черек-черек» дип, иркә сүзләрен дә яудырды. Үсмер кошчык шуннан соң тынычланып куйды. Инде күз йомып, бүтән борчылмаячагын күрсәтте. Ә ялгыз әткә кошчык... Җимне ул куыш оядагы үсмер пырхылдыкларга да ташыды, агач читлектәге ялгыз кошчыкны да сыйлады. Әле, үз тамагыннан өзеп, агач читлектәге гарип кошларны да туйдырды. Шуңа иртәнге, хәтта кичке шәфәкъта дә сайрап-челтерәп куймады. Ә инде ике көннән... Әйе, нәкъ ике көннән куыш-оя үсмер кошчыклардан арынды. Шушы биш-алты бөртек үсмер пырхылдыклар ярым егылышып төштеләр. Инде төшкәне бере, гүя, җиргә сеңде, поскан урыныннан купмады. Димәк, төшкәне бере яңа шартларда шүрләп калды. Әткә кошчык... Сабыйларны кучкә җыюны да, сыйлау-тынычландыруны да онытты, үзен күрсәткәндәй, очып-күтәрелеп мәш килде. Аннан соң гына азык эзләп очты, менә азык китердем, дип, үсмер пырхылдыкларына хәбәр бирде. Чак ишеттереп, бары сулыш алган кебек иттереп әйтсә дә, һәр үсмер кошчык поскан урынында шушы ишетелмәсне дә ишетте. Ишетте, тып-тын черкелдәү авазы чыгарды. Җимне миңа бир, поскан урыныма китер, диде. Һәм әткә

кошчык, инде килгән саен, берәр пырхылдыкны сыйлады. Оядан төшкән кошчыкларның исән-имин канат җилпенүен күреп шатландым мин. Тик шунысы кызганыч: өйдәге нәни кошчык үз туганнарын күрми, ничек яшәргә кирәклеген дә өйрәнми! Һәм мин түзмәдем, читлекне ачып, тоткынны ирекка җибәрдем. Аны әткә кош ябылуда күрде, ирекка чыгаргач та, читкә какмас, таныр, туйдырыр, дип өметләндем.

Шулай итеп, биш бөртек үсмер кошчык янына алтынчысы өстәлде. Аны алар үлән арасында, поскан җирләрендә күрерләр. Күрерләр, башта, ул соң каян килгән, нишләп монда йөри, дип тә әйтерләр, тора-бара үзләренең төркемнәренә алырлар. Әгәр берәр ялгыз кошчык читтә калса, озаклап читлектә дә утырса... ул бит ирекка җибәргәч тә читтә яшәвеннән, ялгыз яшәвеннән туктамый, килмешәк була, туган тиешлеләреннән ят була. Һәм аны, елап сораса да, уртак төркемгә алмыйлар. Аны очраткан бере һаман читкә кага, чөнки ул, гел читтә яшәгәнгә, төркем эчендәге уртак кагыйдәләрне белми һәм, шул сәбәпле, теләсә-теләмәсә дә, бәла генә китерә. Әйтик, әткә кош азык алып килә, ә ул «Җимне миңа бир!» — дип, поскан урыныннан кычкыра, баш суза, дуска-дошманга күренә. Шуңа, иртәме-соңмы, үзе дә һәлак була, үз тирәсендәгеләрне дә һәлакәткә дучар итә. Менә шул хәлне алдан белеп, читкә кагалар да инде аны кошчыклар.

Ярый әле, бер оя үсмер пырхылдыклар сак һәм тыңлаучан булдылар. Ялгыз әткә кошчык бик ук борчылып тормады, җим эзләп шактый читкә очты, тыныч күңел белән йөрде. Үсмер пырхылдыклар кыска гына арада зураешып куйдылар, бөтенләй танымаслык булдылар. Болай тимгелле киемнәре элеккечә калды калуын, тик һәркайсы ялгыз кошчыкка ук әйләнде. Инде — син күр дә мин күр — үлән арасында оча-җилпенә дә башладылар. Оча башлауга, алар ботакларга кундылар, бөтен әйләнә-тирәне күрделәр. Хәтта әле аучы этен дә яшеренми-нитми күзәттеләр. Бу хәлне күреп, әткә кошчык тәмам тынычлыгын югалтты: үзем юкта берүк харап булмагайлары, дип ут йотты. Шуңа күрә җимне дә якын тирәләрдән генә, кабаланып кына эзләде. Үзе җим эзләп җирдә йөрде, үзе, еш кына әшен бүлеп, аскы ботакка да күз салды. Берәр ерткычны күрде исә, тиз-тиз килеп, «тсс!» дип кисәтү ясады. Балалары, моның сүзен тыңлап, дәррәү чүгешеп куйдылар, шундук күренмәслек булдылар. Шулай итеп, әткә кош җим дә тапты, әлеге ялгыз баш хәлдә дә очар кошчыкларын төрле хәтәрдән дә саклады.

Ләкин бер көнне оча башлаучылар каушап-югалып калдылар. Бер мәшһүр әләкче көтмәгәндә урман яңгыратып кычкырды. Әйе, имән каргасы үзе күргән бер нәрсәне бөтен урманга җиткерә, шуның белән төрле хәтәрдән коткара. Менә хәзер дә «каррә!» сүзен урман яңгыратып әйтте ул. Аны бар урман халкы «Хәтәр бар!» дип, дөрес мәгънәдә аңлады.

Шунда каршыда, урман кырыенда, урман корткычы да күренде. Бер кыргый мәче күзен тасырайтып килеп чыкты. Аскы ботакта чүкми утырган биш-алты бөртек очар кошчыкны күзәтте, күзгә күренмичә якыная башлады. Ул кинәт посып куйды, җайлы җирдә кыска сикереш тә ясады.

Ләкин «хәтәр бар!» дигән хәбәрне ялгыз кошкай — әткә шәфәкъ чыпчыгы да ишетте. Ишетте дә сагаеп куйды, мәчене күрде дә оча-йөгерә, балалары янына ашыкты. Анда ул «тсс!» дип куйды, шуның белән очар кошчыкларын кисәтте. Сез, берүк, утырыгыз, сеңеп куегыз, тыныгызны да чыгармагыз, дип әйтте. Шуннан соң әткә кошчык... Әйе, ул инде, оча-сикерenә, очар кошчыкларын калдырды. Ул инде якынлашып килгән кансыз дошманына таба атылды, аның башы тирәсендә мәш килде. Гуя, ул мәченең авызына керде, аның бар игътибарын очар кошчыклардан читкә тартты. Менә шуннан соң... Әйе, тиз-тиз һәм тигез атлап «тычкан йөрешен» башлады. Моны борынгы бабаларыбыз ук, таң калып, «тычкан йөреше» дип атаган. Башта бу кошчык урман корткычын алдау-ияртү ягын карады, әле бер мизгелгә ул, «әйдә тот!» дип, аның алдында ук тукталды... Һәм аның артыннан ук кыргый урман мәчесе дә юк булды, гүя һәр икесен урман йотты.

Ә теге оча башлаучылар... Алар, әйтерсең, ялгызбаш әткәләренең күздән югалуын гына көттеләр. Алар, җил сыпырып алган кебек, җиргә җилпенделәр.

Шулай май узды, ә мин майның ничек узганын сизмәдем дә: кошчыкларны күзәттем, бал кортларының «безз-безз» килеп табыш китерүләрен күзәттем. Чәчәкләр язы әнә шулар белән матур истәлекләрен калдырды. Инде җәй ае — июнь керде, инде сизелми генә ул да үтеп, эссе июльне җиткердем. Шунда тагын бер тапкыр иске танышның көмеш өненә сокландым. Аны, бе-

ренче ишеткәндәй, таң калып, онытылып тыңладым.

Бу чакны сайрар кошлар дәшмәс-күренмәс үк булган иде инде. Алар, сайрауны онытып, бала кошчыкларын, газиз нәниләрен бактылар. Җим эзләделәр, нәниләргә күз-колак булып, карый-өйрәтә тордылар. Инде ялгыз кош — кәккүк булып кәккүк моңлы кычкырудан туктады. Башта сакауланып куйды, тора-бара томшык йомды, гүя, кәккүк: «Мин бит болай да, сайрый башлап, бик тиз туктауны белмәдем. Мин бит кешеләргә шуның белән озын гомер теләдем», — диде. Кәккүк гүя шулай диде, моңлы кычкырудан туктады. Инде сандугач булып мәшһүр сандугач та «телсез былбыл» дип әйттерде. Ә менә шул чакта минем иске танышым...

Әйе, яңа яз килгән кебек, ул үзенең биек чыршысында дәртләнеп сайрады! Үзе, күптәнге гадәтенчә, иртән сайрады да, бары кичен генә сайрады; үзе, эссе җәй дип тормады, яздагыча дәртләнеп тә сайрады. Ул бит көмеш өнен тагын бер кат әнкә дускаена багышлады. Чөнки шул әнкә дускае бит янә дә күкәй салу ягын карады.

Көннәрдән бер көнне... Язын беренче булып оя ташлаган кошчык-кыбырсыкны күрдем мин! Димәк, бу таныш кошчык мине онытмаган, мине яратуын саклаган. Менә ни өчен минем янга ишек төбенә үк килгән ул! Әйдә, бабайның хәлен белим, әйдә күреп китим, дигән ул. Мине күрү шатлыгыннан ниләр кыланырга белмәде: як-якка канатларын сузды, җилпәвеч итеп, җыеп-таратып та маташтыː әле, сиртмәле итеп, нәни койрыгын куя-күтәрә торды; үзе шул рәвешле кылана бирде, үзе бер генә мизгелгә дә кара күзкәйләрен миннән алмады. Шулай, әйтерсең, кырын карамауны, кумавымны сорады. Кая ул кырын карау?! Аның истә тотуына, мине онытмавына шат булдым. Башым күккә тиеп, авыз ерылды. «Ярый, син булдың. Син бит кыбырсык вакытымда җирдән таптың, мине коткардың», — дип әйтте күк ул миңа.

... Салкын көз һаман түргә узды: һәм, шул хәлне күреп, зур-зур кошлар ишле көтүләргә берләште, бергә очу, күчү күнегүләрен ясый башлады. Алар, төркемләп-төркемләп, туган җирләрен калдырды.

Ә теге сайрар нәни кошкайлар... Алар хәзерге торган җирләреннән, җимсез җирләреннән кисәк кенә юк булды.

Кеше бит ул гомер буена рухланып-дәртләнеп, зур өметләр белән яши. Мин дә өметләнгән идем... Ичмаса, кулга ияләшкән әлеге дә баягы кыбырсык шәфәкъ чыпчыгы кышка беркая да китмәс, минем янда торып калыр, дип өметләнгән идем. Әйе, мин ул сабыйны кышын-кыш буе карап-тәрбияләп, ул яраткан сыйлар белән туйдырып-тукландырып торырмын, дип өметләнгән идем...

Ләкин алай килеп чыкмады. Бәләкәй кыбырсык, үзенең туганнары җыйган көтүгә кушылып, мине бөтенләй исеннән үк чыгарып, китеп барды... Хәер, бөтенләй онытып бетермәве дә бик ихтимал. Аның табигать кануннарына — чакыру авазына буйсынып китеп баруы, бәлки әле, яз җиткәч тә, үзенең туган җирен сагынып кайту өчен дә кирәктер.

Димәк, яңадан яз җитәр, җылы якларга очкан кошлар яңадан безнең якларга кайтырлар. Яз гына җитсен.

Мин түземсезләнеп язны көтәм...

## Марат Әмирханов

# САБА ҖИЛЕ

ХИКӘЯ



Шап итеп, бәләкәй капка ачылды. Байназар, бур кешедәй тәшвишләнеп, тәрәзәгә күз салды, җәһәт кенә барып телевизорны сүндерде. Экран, болыт эченә кергән кояш кебек, бераз тоныкланып торды, аннан соң бар яктысын бер ноктага җыеп, кайнар һәм караңгы кочагына яшерде.

Байназар — телевизорга мөкиббән киткән бер бәндә,— буш вакыты чыктымы, шул әрҗәгә каплана. Гайбәтеннән генә шикләнә, шуңа күрә капкасына да олы сиртмә куйдырды, кыңгырау кебек, кеше кергәнне хәзер хәбәр итә. Ә кеше күп килә, танышы да, таныш түгеле дә. Әлеге җирән чәчле егетне дә танымый торды.

— Түрдән уз, улым, дога кылып алыйк, соң сөаленне ирештерерсең, китап кабалануны хуп күрми.

— Алай озаклап торырга вакытым таррак шул, бүген төнлә әткәй вафат булды бит әле...

Йомышчының тавышы утка тигән балавыз шикелле йомшап китте. Байназар да, авыз эченнән нидер укып, учлары белән битен сыйпап куйды. Егетнең миһербанлыгы, кече күңеллелеге ошый иде аңа. Хәзерге яшьләрнең бәгъзеләре ата-аналарын хөрмәтләү түгел, җирләргә дә кайтмыйлар.

— Иншалла, улым, әткәң картның урыны оҗмахта булыр, мондый итагатьле бала тәрбияләгән ата дөньялыкта кешеләргә рәнҗү салмагандыр, шәт.

— Әткәебез бик гадел кеше иде...

— Бик шулайдыр, балам, бик ышанам, кем атлы иде соң әткәң, кайсы авылныкы?

— Үзебезнең авылныкы инде, Аюбашныкы. Кәбир Зиннәтуллин.

— Кем-кем?

— Кәбир Зиннәтуллин, элекке мәктәп директоры.

Байназарның йөзенә сары төс йөгерде. Үзе нидер әйтергә тели, ләкин калтыранган иреннәре арасыннан пыш-пыш итеп һава гына чыга иде. Ниһаять, иреннәре дерелдәүдән туктады:

— Каргыш шулай ул, искәрмәстән суга,— дип, ниндидер үзенекенә охшамаган тавыш белән кеткелдәп көлде ул.— Инде мин кирәк булдым мени?

Байназар кан тамырлары бүртеп торган какча йодрыгын егетнең борын төбенә китереп терәде.

— Соңгы юлга озатканда кешеләр бәхилләшә түгелме, Байназар абзый,— дип, егет тыныч кына аның йодрыгын читкә этәрде,— ялгышмасам, дин үзе дә шуңа өнди.

— Дин, дин,— дип мыгырданды Байназар.— Мин аны бәхилли алмыйм, аңлыйсыңмы, бәхилли алмыйм!

Кәбирнең улы чыгып киткәч тә ул әле гәүдәсен туп шикелле ишеклетүрле очыртып йөртте, тик барыбер тынычлана алмады; ахырда, телевизорын тоташтырып, экранга бик озак текәлеп утырды. Ләкин телевизорда барган хәлләр бу минутта аның өчен ачыган аш кебек кенә иде.

---

Марат ӘМИРХАНОВ *(1933)— «Таш һәйкәл», «Чулманның ак йолдызы» һәм башка китаплар авторы, ТССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Казанда яши.*

* * *

...Байназарны, Минзәлә педучилищесын тәмамлагач, Аюбаш мәктәбенә укытучы итеп билгеләделәр. Ул вакытта югары мәгълүматлы укытучылар җитешми иде. Ихтимал, Алабуга укытучылар институтының табигать фәннәре факультетына читтән торып укырга керүен дә исәпкә алганнардыр. Теләүчеләрне чыгарылыш имтиханнары билгеләре буенча институтка теркәү гадәте бар иде.

Кәбир мәктәптә икенче елын эшли иде инде. Шуңа күрәме, яшь укытучы алдында үзен бик һавалы тотты. Танышуга ук, нигәдер, Байназарны бәдрәфкә алып керде дә колагына кайнар тынын өрде:

— Син кем төркеменә керәсең, директорныкынамы, завучныкынамы?— диде.

Байназар аптыравыннан җилкәләрен сикертте: ул монда эшләргә килде, төркемнәргә бүленеп ызгышырга түгел.

— Их, син пешмәгән бәрәңге,— дип мыскыллап көлде Кәбир.

— Син үзең кем яклы соң?

— Башың яшь, энекәш,— диде Кәбир, серен ачмады. Ләкин сүзе бетмәгән икән әле, күзләренең аклары белән Байназарга бер карап алды да теш арасыннан төтен чыгаргандай битараф кыяфәт белән кисәтте:

— Монда Зөбәрҗәт исемле бер туташ бар, череп таркалган мещанка, алай-болай тырнагына эләгә күрмә. Вообще, борыныңны сузма, мин бойкот игълан иттем аңа.

Шушы бер-ике минут эчендә Байназар мәктәп, авыл турында шактый күп белешмә алды. Хак идеме алар, юкмы,— монысын киләчәк күрсәтер. Тик шунысы ачык: аның әле кызлар артыннан йөрергә дә, коллективның ызгыш-талашында катнашырга да исәбе юк. Әйбәт кенә эшләп өс-башын юнәтү, әнисен сыерлы итү, институтны бетерү — бу инде күптән билгеләнгән максат иде.

Зөбәрҗәтнең үзен күргәч, бу уйлары тагын да ныгый төште. Ник дисәң, мондый чибәр, мондый кәттә кызны карату бу хәлендә, бик нык теләгән очракта да, кулыннан килә торган эш булмас иде. Һәм ул шуны да аңлады: байкотны, Кәбирдән битәр, кыз игълан иткәнгә охшый. Чөнки, үзен эрегә санап йөрсә дә, Кәбирнең килеш-килбәте мактанырлык түгел иде, тәбәнәк гәүдәле егетләрне кызлар өнәп бетерми бит ул.

Байназар баштанаяк эшкә чумды. Яшь кеше, ир кеше, дип, аңа мәктәп яңы бакчасын да сылап куйдылар. Карышмады, азмы-күпме акчасы да киләчәк бит әле аның. Кәбир, педсоветтан соң, мыскыллап, аның кулын кысты: әйттем бит, башыңа менеп атланачаклар, дип; күрерсең, монысы — баласы гына...

— Кемдер эшләргә тиештер ич инде анда.

— И-и мескен! Ат, әнә, гомере буена эшли, рәхәтен генә күрми.

Чыннан да, бакча бик мәшәкатьле булып чыкты, дәрес бирүгә караганда күпкә авыр иде анда эш оештыруы. Балалар бил бөгәргә әллә ни ашкынып тормыйлар, класс җитәкчеләре ярдәм итми. Еллар буена бакчада берниндн тәҗрибә эшләре үткәрелмәгән, укытучылар җиләк-җимешен үзләренә җыеп алганнар да, шуның белән шул. Байназар бу гадәткә чик куярга теләгән иде дә, каршы төштеләр, бигрәк тә директор хатыны чыгырыннан чыкты. Директор үзе дә:

— Хәмидә апаңның ачуын чыгарма, андый чакларда бик яман ул,— дип кисәтте. Ләкин аның үзен, киңәшмә саен, бакча өчен тәнкыйтьлиләр иде. Шуңа күрә яшь укытучыга ярдәм итәргә кирәк тапты. Ә Байназарда үҗәтлек җитәрлек иде, бакчада эш тәки акрынлап җайга салына башлады.

Бер уңайга китсә, китә бит ул. Һич көтмәгәндә Зөбәрҗәт белән аралары ялганып куймасынмы! Дөрес, чибәр кызлар белән бәйләнешкә керүнең куркыныч икәнен белә иде ул. Дусты Исламны, әнә, берсе коры күмергә калдырып яндырды да, бер түрә малаена иярең, Казанга элдертте. Байназар дустын суга ташланганда чак тотып калды. Тик йөрәк үзенекен итә, каһәр, җигелмәгән тай кебек бит ул, тыймалы гына түгел.

Зөбәрҗәткә игътибар итмәскә тырышты Байназар, вәгъдәсендә торыр өчен бөтен көчен куеп карады. Ләкин сылу кызлар өчен нәкъ менә битарафлыкның иң зур җәза икәнлеген белми иде әле ул.

Көннәрдән беркөнне кичкырын Зөбәрҗәт үзе биология бүлмәсенең ишеген ачып керде. Байназар күп вакытын шунда уздыра, дәресләренә

дә кабинетта әзерләнә, фатирына йокларга гына кайта. Арыган арада мандолинасын кулына алып күңелен юата. Кыз кергәндә дә, мандолинага кушылып, яраткан җырын көйли иде:

Исле гөл исле була,
Яран гөл төсле була,
Сагынганда айга карыйм,
Гел синең төсле була...

Зөбәрҗәт кулларын чәбәкләде:

— Менә нинди талант яшеренеп ята икән безнең биология кабинетында!— диде ул, тигез ак тешләрен күрсәтеп.— Тавышыгыз шундый йомшак, моңлы...

Байназар, гаепле кеше кебек, кызарып чыкты, ни әйтергә белми аптырап торды. Тавышы бик көчле булмаса да, килешле иде, моны ул үзе дә белә, мандолинаны да шактый оста чиертә. Ләкин җырны да, уенны да ялгызы калгач кына, үзе өчен генә башкара.

— Гафу итегез, мин сезне күрмәдем,— диде ул, аклангандай. Әйтерсең лә, ниндидер ярамас эш кылган иде.

— Сез үзегез кичерегез, зинһар, ишек яныннан тыныч кына үтеп китә алмадым. Тагын җырлагыз, ә?!

Зөбәрҗәт, күзләрен сабый бала кебек мөлдерәтеп, егеткә карады. Байназар бу караштан эреде дә төште, күңеленә беркетеп куйган эшләре дә, күз уңында, уенда торган максат-планнары да җил очырткан төтен кебек «ә» дигәнче юкка чыкты.

Әйе, Зөбәрҗәт аны ихтыярсыз бер затка әйләндерде дә куйды. Әнисенә сыер алып бирү дә чынга ашмас, ерак бер хыял гына булып калды. Киресенчә, туй мәшәкатьләренә дип, әни-сеңелләре үзләре болай да юка янчыкларын чишәргә мәҗбүр булдылар.

Кәбир дә өйләнде. Үзе кебек үк түгәрәк йөзле фельдшер кызны эләктереп алды. Барышып-килешеп яшәделәр, бүлешәсе нәрсә калмаган иде инде. Һәркайсы, үзенә тигән хак өлешеннән риза-бәхил булып, тормыш сукмагына аяк басты. Һәрхәлдә, Байназар шундый фикердә иде.

* * *

Бервакыт Байназарны райкомга чакыртып алдылар. Калын иренле, сирәк тешле секретарь аның белән бик дустанә сөйләште.

— Мәктәптә хәлләрегез ничек дип сораштырып башыңны катырып тормыйм, туганкай,— диде ул.— Безгә хәл күптәннән ачык. Әлегә җүнле кешесе генә чыкмый торды. Икеләнеп-микеләнеп торма, ал кулыңа дилбегәне.

Байназар маңгаен учы белән сыпыргалап алды. Мондый тәкъдимне көтмәгән иде ул.

— Җә, туганкай, ничек?

— Ни әйтергә дә белмим бит әле, иптәш Хөснуллин.

— Курыкма, барыбыз да шулай башладык, минем үземне менә егерме яшемдә директор итеп куйдылар. Иң мөһиме — катгый тәртип, «директор» дигән сүздән бөтенесенең коты алынып торсын.

Секретарь, майланмаган арба кебек шыгыр-шыгыр килеп торган форточканы ябып, элмәккә каптырып куйды да урынына утырды:

— Онытып та җибәргәнмен, кандидатлык стажың ничек бара, бетәме әле?— дип сорады.

— Җыелыш булды инде, кабул иттеләр, райком бюросы нинди фикергә килер бит...

— Анысына борчылма, үзеңне партия члены итеп саный аласың.

Бу көнне кичен кечкенә мәҗлес сыманрак нәрсә җыеп алдылар. Уллары Булатка бер яшь тулган көн иде. Байназар районнан кайтканда, мәсьәлә тәмам хәл ителми торып, әлеге тәкъдим турында беркемгә дә әйтмим дип үз-үзенә сүз куйса да, бераз төшереп алгач, капчыгын төбеннән үк селекте дә ташлады. Ләкин Кәбир бу хәбәрне бик тыныч кабул итте, күптән кирәк иде, дип кенә куйды. Байназар исә сүзен һаман шул якка каера, мактанасы, үзен күрсәтәсе килә. Шулай булмыйча, мәктәп ди-

ректоры булу уен эш түгел, бик зур дәрәҗә, бик зур ышаныч бит. Дусты шуны да аңларга теләми, Булат булса, шул җиткән аңа: шаярышырга тотындыларммы, бер-берсеннән аерырмын димә. Әле ат, әле фил, әле паровоз булып кыланды Кәбир бу кичтә.

— Безнең әтиебезнең улы белән болай уйнашырга вакыты юк, бакчасыннан аерыла алмый,— дип, иренә төрттереп алды Зөбәрҗәт.

— Моннан соң гүпчем дә өйгә кайтып кермәс әле,— дип көлде Кәбир.

Шушы көннән башлап Байназар хыял дәрьясында йөзде. Көне көн, төне төн түгел, гел шул хакта уйлана. Нинди генә планнар кормады ул, алар тормышка ашса, мәктәп республикада беренче урынга чыгарга тиеш иде. Ләкин атна-ун көннән бу күтәренке халәт күңел төшенкелеге белән алышынды. Чөнки районнан бер хәбәр дә юк иде. Әллә кире чигенделәр инде, дип борчылды Байназар. Алайса, ымсындырмаска иде. Ихтимал, чыннан да, бу вазифага лаек түгелдер ул. «Ай-һай нәфесең,— дип үз-үзеннән көлде Байназар,— беткән иде ди синең ишеләр!» Кәбиргә ни әйтергә менә, портфельсез министр, дип ирештерер инде. Их, бу телне, кирәкмәгән чакта чишелеп, ярага тоз салды бит, каһәр!

Дөрес, мәктәптә политик мәгариф кабинеты мөдире булып китте. Тик ул үз вазифасына караган эшләр белән генә шөгыльләнде, укытучыларның сәяси белемнәрен күтәрү, укучыларга коммунистик тәрбия бирү мәсьәләләре белән генә кызыксынды. Байназар белән дә очрашты. Озак кына сөйләшеп утырдылар. Әңгәмә тәгалләнгәч, сәгатенә карап, уены-чыны белән әйтеп куйды вәкил:

— Өйлә вакыты үтеп киткән, ә авызга бер кабым ризык кергәне юк, язвәләрең азар монда.

— Әйдәгез соң, безгә кайтыйк,— дип урыныннан торды Байназар.

— Зур комачау ясамаммы, иптәшегез ачуланмасмы соң?

— Юкны сөйләмәгез, зинһар, үзегез генә гаеп итмәгез.

Райком вәкиле җиңел аралашучан ханым иде, Зөбәрҗәт белән дә бик тиз уртак тел тапты. Булат чат ябышты үзенә, тәмам дуслаштылар.

Шуннан соң озак та үтми райком бюросына дәштеләр. Беренче секретарь аңа алтын кысалы күзлеге аша бик озак сынап карап торды. Байназарның тез аслары калтырап китте, әйтерсең лә зур җинаять кылган да суд алдында хөкем карарын көтеп тора.

— Сәфәров, сез нинди җәмәгать эше алып барасыз?— Тәүге сорау шушы иде. Аны прокурор бирде.

Байназарның авыз эче кипте, телен әйләндереп ник бер сүз әйтә алсын. Ул, ниндидер яклау өмет итеп, идеология секретарена күз төшерде. Ләкин тегесе аның карашын кабул итмәде, башын иеп, алдындагы кәгазьгә нидер язып куйды. «Бюро шулай шомлы үтә, ахры»,— дип уйлады Байназар.

— Сорау аңлашыламы?— дип сорады Беренче.— Сузмагыз, безнең эш болай да муеннан.

— «Белем» җәмгыятен җитәклим...

— Үзегез нинди тематика алып барасыз?

—Атеистик темага, йолалар һәм традицияләр турында лекцияләр укыйм.

Беренченең йөзе буйлап ниндидер сызыклар йөгерешеп узды, ләкин елмаямы, ризасызлыгын күрсәтәме — тәгаен гына аңларлык түгел иде.

— Партиядә икейөзле кешеләр тора аламы, ничек уйлыйсыз, Сәфәров?

— Бу мөмкин түгел!

— Без дә шундый фикердә.

Секретарь мәктәпкә килеп киткән вәкил ханымга ым какты.

— Улларын сөннәткә утырткаңнар, Мәгъсүм Шакирович,— диде тегесе.— Үзем күреп кайттым.

— Шушымы сезнең материалистик караш?— дип тавышын күтәрде Беренче.

— Һәр халыкның үзенә генә хас гореф-гадәтләре була,— дип аңлатырга тотынды Байназар, ул үзен дөрестәге кебек иркен хис итә иде инде.— Әйтик, исем кушу, нәүрүз бәйрәмнәре... Сөннәткә утыртуны да шуларның берсе, дип саныйм. Боларның дингә дә, материализмга да катнашы юк.

— Комган, кәләпүш белән кешелекнең якты киләчәге — коммунизмга бармакчы инде, алайса?— Беренче үзенең белдеклелеген бюро әгъзаларына да юллый иде.— Коммунистик җәмгыять төзү процессында,— дип дәвам

итте ул.— Милләтләр дә, телләр дә берләшәчәк, гадел җәмгыятьтә чуарлык булмаска тиеш, без искелек калдыкларыннан тулысынча азат булган яңа кеше тәрбияләргә бурычлы. Ә сез, иптәш Сәфәров, татарның иске реакцион гадәтләрен, ярым-йорты телен коммунизмга сөйрәп алып кермәкче буласыз. Халык үзе дә болардан ваз кичә ләбаса. Татар теленең Минзәлә күперен узгач кирәге калмый, дип сөйлиләр районда, шуны да ишеткәнегез юкмыни соң сезнең?

Секретарь, нотыгын тәгәлләгәч, ертылган чүпрәк кебек һыйшайган йөзен идеология секретаре ягына борды:

— Каян табасыз шундый надан укытучыларны, һич аңламыйм.

— Мәгъсүм Шакирович,— диде тегесе ниндидер ялагай кыяфәт белән,— замечаниегез бик дөрес, гаебебез зур, әмма аны төзәтергә көч тә, тырышлык та җитәрлек бездә. Сәфәровка килгәндә исә, мин бюро членнарын аның эше кеше белән бөек Ленин партиясен пычратмаска өндәр идем. Иң куркынычы, Мәгъсүм Шакирович, шунда, бу адәм чын-чынлап мәктәп директоры постын яулый башлады. Партияне ул үзенең шәхси карьерасы өчен файдаланмакчы иде. Юк, бу барып чыкмас!..

* * *

Байназарның тормыш арбасы зур тизлек белән түбәнгә таба тәгәри башлады. Ул үзендә бу һәлакәтне туктатырлык көч таба алмады. Директор итеп Кәбирне куйдылар. Дәрәҗәгә ирешүгә, дусты аралашудан туктады, хәер, партиядән читкә тибелгән, политик яктан тотнаксыз дип табылган кеше белән якын элемтәдә тору директорга гына түгел, гади укытучыларга да куркыныч булып яный иде. Шуңа күрә барысы да аннан читләште. Ә киләсе уку елыннан яңа биолог чакырдылар, Байназарга мәктәп яны участогы мөдире вазифасы белән генә канәгатьләнергә туры килде. Дөрес, ничәдер сәгать җыр, рәсем дәресләре дә укытып карады. Ләкин рухы сынган иде инде. Үзе дә сизмәстән, шешә белән дуслашты Байназар. Иртәнге якта хатынының аякларын үбеп гафу үтенә, ә кичен ләх булып исереп кайта иде. Мондый мөгамәләгә күнекмәгән иркә кыз Зөбәрҗәт бу хәлне үзенчә кичерде, ахыргы чиктә араны өзәргә, дигән карарга килде; чибәрлегем бар, үземә тиң кеше табылыр әле, дип уйлады. Ниятен озын-озакка сузмады, көннәрдән бер көнне Байназарны салкын шыксыз өй каршы алды, өстәлдә ике генә җөмләлек язу калган иде: «Син мине алдадың, ышанычымны акламадың, хәлеңнән килмәгәч, йөзем җимешенә үрелмәскә иде. Безне эзләп тә, эзәрлекләп тә йөрмә, файдасы тимәячәк. Зөбәрҗәт».

Байназар, хатынының Түбән Камадагы апасы янына күчеп киткәнен белсә дә, аны бүтән бимазаларга батырчылык итмәде. Колхозның алма бакчасында каравылчы булып берәр ел чамасы эшләгәннән соң, Төмән якларына чыгып китте. Иөрмәгән җире, шөгыльләнмәгән һөнәре калмады. Уч тутырып акча алган чаклары да булмады түгел, булды, хәтта өйләнеп тә карады. Ләкин җан тотрыклыгы килмәде. Чакырсалар — килә, кусалар — китә, нигә дөньясының асты-өскә килми шунда, аңа барыбер иде. Шулай төрмәгә дә барып эләкте. Анда кануннар катгый иде. Көч хөкем сөрә төрмәдә, кансызлык хөкем итә, яшеңне дә, мөмкинлегеңне дә сорап тормыйлар; буйсынмыйсың икән, юлдан алып кына ташлыйлар, кеше гомере чебен җанына да тормый. Сакчылар да, төрмә хуҗалары да белә моны, ләкин һичнинди йогынты ясый алмыйлар, ихтимал, теләмиләрдер дә.

Байназар утырган төрмә-колониядә «Зевс» кушаматлы бер бәндә патшалык итә иде. Дуамаллыгы белән дан тота иде ул. Мин-минлеге аеручә ярсыган чакларында хәтта чын патшалар да җәяү генә йөри торган урынга кадәр күтәреп алып чыгалар иде үзен. Посылка, бүләкләр дә иң элек аның кулына керә, күп вакыт хуҗасына өлеш тә тими кала. «Җарияләр»гә, гомумән, кытлык юк, колониягә эләккән яшь-җилкенчәкне беренче булып шулай ук «Зевс» татый.

Байназарга бу куркыныч янамый, чөнки яше дә, тышкы кыяфәте дә кызыксыну уятырлык түгел. Ул — кара йомышчы, аны патша катына якын да җибәрмиләр. Шулай да бер мәртәбә «Зевс»ның каршысына басарга туры килде аңа.

Утыз яшьләрдәге егет иде ул. Ат теледәй зур җәлпәк борынлы, шундый ук итләч йөзле, күзләре кысык, тегәрҗеп калынлыгында гына. Ә менә чәче чем кара, аз гына алга төртелебрәк торган шома иягенең нәкъ уртасында мәхәббәт уемы да бар...

«Нинди бик таныш йөз соң әле бу, кайда күрдем мин аны?» — дип уйлаган иде Байназар аның турында. Әмма аңа хәтер капчыгында казынырга ирек бирмәделәр.

— Бугор алдында торасың, тезлән, обрезок,— дип, тез астына китереп типтеләр.

«Зевс» үзе Байназарга күзен дә сирпемәде: фәкать, чәйнәвеннән туктап, янындагы берәүгә мөрәҗәгать итте:

— Әйт, иртәгә өч «курчак» әзерләсен.

Байназар, боларны ишетеп торса да, ярдәмче аңа түкми-чәчми башлыкның сүзләрен җиткерде, үзеннән дә өстәде: вакытында китермәсәң, яулык бәйләтербез, обрезок, бавырыңны суырып чыгарырлар анда, ха-ха-ха!

Хикмәт шунда, өлкәнрәк яшьтәге токтыннар, бигрәк тә мөселман халкы, юкны бар итеп булса да, мая туплаучан. Байназарның исә кесәсе такыр иде. Чөнки моңарчы киләчәк турында баш ватып азапланмады. Ашаталар-эчертәләр, җан саклау өчен шул җитмәгәнмени, дип уйлады.

Ул тагын бер мәртәбә «Зевс»ка күтәрелеп карады. Бер генә мизгелгә күзләре очрашты. Яшен тизлегендә башына уй бәрде Байназарның: миңа охшаган лабаса бу! Яшь чагында килеш-килбәте, буй-сыны нәкъ шушы егетнеке кебек иде!

Уйлары ярты юлда өзелде Байназарның, чыбыркы белән сыдырып алгандай, күңеленә кайнар бер ук кереп кадалды. Иа, аллам, юк, бу мөмкин түгел, юк, юк! Ул, үзен-үзе белешмәстән, изүен аерып ташлады, тик җиңеллек килмәде.

— Булат... улым...— дип ыңгырашты ул һәм, киселеп ташланган агач кебек, йөзтүбән ауды.

* * *

Байназарны төрмә шифаханәсенә салдылар. Атна-ун көнен бик авыр ятты. Шулай да тырышты-тырмашты, тернәкләнде тәки. «Зевс»ның улы Булат түгеллеген дә ачыкладылар. Охшашлык кына булган икән. Сәламәтләнүенә, дарулардан битәр, шушы хәбәр күбрәк ярдәм иткәндер, мөгаен. Акыллы да, гадел дә, тәртипле дә аның Булаты! Улы белән әлемтә тотмаса да, Байназарның нигәдер иманы камил иде моңа.

Тетрәнү чир-хаста гына түгел, ниндидер сафлану, хушлану да алып килде Байназарга. Ул үзе өчен һәр көнне ниндидер яңалык ача иде. Күптән, бик күптән көннең шушындый илаһи яктылыгын, кояш нурларының ана кулыдай йомшак-мәрхәмәтлелеген җаны, тәне белән тойганы юк иде. Күр, дөнья нинди ямьле икән, гүзәл икән! Ә ул аны ничәмә-ничә еллар сасы аракы сөременә, төрмә пычрагына буташтырып, танымаслык хәлгә китергән...

Кайчандыр үз дөньясы да бөтен иде ич, абруе бар иде, хөрмәт итәләр иде. Ни өчен шулай килеп чыкты әле бу, нигә соң ул ерып чыга алмастай саздыкка тәгәрәде, нинди каһәр суккан кара мәче аның юлын кисте?

Уйлана-уйлана башы тубал була иде Байназарның. Ул инде тәүге көннәрендәге кебек ачыш-табышларына да куанмый башлады, кешеләрдән читләште, йомылды.

— Картлач, шөрепләрең бушап бара түгелме синең?— дип, бармагын чигә тирәсендә әйләндерде берсе ашханәдә.

Байназар аңа күтәрелеп карамады, ашавын дәвам иттерде.

— Әй, син...

— Юк нәрсәгә нервыңны бозма,— дип бүлдерде күршесен икенче токтын,— беләсең килсә, «Зевс» колак пәрдәсен тишкән аның, ха-ха-ха...

Бот чабып көлештеләр. Һәм шушы көннән башлап токтыннар аны үз исәпләреннән төшереп калдырдылар, башка бимазалаучы булмады.

Байназар үзен тынычлыкта калдыруларына шатланды гына. Бәхетенә, савыккач, шифаханәдә йомышчы итеп калдырдылар үзен. Элекке кебек йөзләгән кеше белән сафка тезелешеп эшкә йөрисе юк, көнозын диярлек

берүзе. Хәер, берүзе дип тә әйтеп булмый, һаман уйлары, хыяллары белән. Үз фаҗигасенең асылына төшенү теләге әнә шулай аңа һич кенә дә тынгы бирми иде.

Беркөнне шифаханә башлыгы Байназарга аш пешерү бүлмәсен тәртипкә китерергә боерык бирде. Еллар буе тупланган вак-төяк чүп-чар, череп, кыйшаеп беткән киштә-миштәләр күп иде анда. Болары аның үзләре аварга тора. Ә менә бармак калынлыгы юан тимердән эшләнгән зур су бакын икенче ярустан төшерү өчен шактый баш ватарга туры килде Байназарга. Ахыры барыбер әмәлен тапты. Иң элек ике сүс арканны корыч боҗра ярдәмендә матчага беркетте, аннан соң бакның кырындагы уемнарына кертеп, арканнарны түшәмдәге тимер әрәтә (төрмә бинасында тимер буа буарлык!) аша үткәрде, очларын ныклап тәрәзә янындагы баганага бәйләп куйды. Җайланма әзер!

Арканнарны иплән кенә бушата-бушата Байназар бакны идәнгә төшерде.

Аның ничек эшләвен башлык та күзәтеп торган икән.

— Вәйт, хитрый татарин,— дип көлде ул,— Архимедтан ким җирең юк, ә беләсеңме ул нәрсә дигән? Нәрсә дигән әле, миңа таяну ноктасы гына бирегез, җир шарының астын өскә әйләндерә алам, дигәнме?

Бәндәгә дә шундый ук таяну ноктасы, терәк зарур икән ләбаса! Терәге нык, үз таяну ноктасын тапкан кеше тормыштагы зил-зиләләргә бирешми, аларны үткәреп җибәрә белә. Бар идеме соң Байназарның андый терәге?

Әлбәттә. Институтта укыды, белгечлек алды, мәктәптә эшли башлады. Болар терәк түгелмени? Терәк. Аннан китереп, гаилә! Нинди чибәр кәләш сайлаган иде бит ул. Улы! Кыйбласы исә, иң ышанычлы таяну ноктасы, бәхәссез, коммунистик аң иде. Бу аң кешене һәрвакыт хак юлдан гына йөртә, тайпылу-боргалануларга ирек куймый. Чөнки аннан да гадел, аннан да халыкчан аң башка юк! Байназарның канына ул шулай сеңгән иде. Партиягә дә гаризасын чын күңеленнән, әлеге аңга икеләнүсез инанган кеше буларак язган иде...

Нигә соң бу терәкләрнең нигезе черек булып чыкты, нигә алар аны тотып кала алмадылар? Терәкләр түгел, ихтимал, ул үзе черектер? Бәгъзе адәмнәр моннан да авыррак сынауларны җиңеп чыгалар ич. Димәк ки, язмыш! Ә язмыштан узмыш юк, диләр. Хикмәт, күрәсең, шунда. Алайса, язмыш дип, һәр нәрсәгә разый-бәхил булып, кул кушырып утырыргамы?

Байназар бу сорауларның очына чыга алмый азаплана. Берара ул, беткән баш беткән, үткәнне барыбер кире кайтарып булмый, дип кулларын да селтәп карый. Тик күңел түренә кереп оялаган ниндидер корт инде аңа тынычланырга ирек бирми. Ул искечә яши алмый иде инде. Шуның белән бергә, ничек итеп яңача яшәү рәвешен дә күз алдына китерми.

Байназар үзеннән-үзе уй-фикерләрен, төрмә китапханәсендә укыганнарын кәгазьгә төшерергә күнегеп китте, моның өчен яшел тышлы дәфтәр дә ачып җибәрде. Әлеге фәлсәфи дәфтәр тора-бара якын киңәшчесенә әверелде Байназарның. Иң кӧтелмәгәне шул иде: аның уй-фикерләре ни сәбәпледер дини тәгълимат тирәсендәрәк чуала икән ич! Әллә соң ышанычы шул якка авышамы, чын терәге шундамы?

«Ышануның, табынуның илаһи көче — өметтәдер,— дип башлана күңел дәфтәрендәге беренче язма.— Өмет бу тарафта фәлсәфи агымны тасвирлый, үсеш, хәрәкәт мәгънәсенә ия. Хак, материалистлар да хәрәкәтне үсешнең төп алшарты итеп карыйлар. Ләкин яшәеш тәкъбирендә бу хәрәкәтне аерым буын белән чиклиләр. Бер җан туа, икенчесе мәңгелеккә эзсез югала. Әгәр шулай була калса, бу бик зур гаделсезлеккә китерер иде, өметсезлеккә, битарафлыкка юл ачар иде. Чынлыкта кеше бер дөньядан икенчесенә генә күчә, тән-гәүдәсе кала, җаны галәм киңлекләренә оча. Өметтән дә олырак көч юктыр».

Ә менә монысы — язмыш турында. Аның эзләнүләре язмыш «тозагы»ннан башланды да бит инде, гыйлемсезлек чын мәгънәсендә караңгы төн шул, язмыш җәһәтендә дингә күпме нахак бәла ягалар, саный китсәң чутына чыгарлык түгел. Ә Коръәндә нәрсә диелгән? Анда әйтелгән: «Аллаһы тәгалә бер адәмнең дә хәлен үзгәртми, әгәр ул үзе моңа җиң сызганып тотынмаса». Димәк ки, язмышка салынып һични кылмый утыру үзе үк зур кимчелек.

Шәхсән үзенә кагылган җөмләләрнең астына сызып ук куйган Байназар. Шуларның берсе: «Җәмгыять тә, партия дә кешене иләктән или. Бәндә абындымы, хәзер читкә тибәләр, ярдәмгә, шәфкатькә мохтаҗ вакытта тибәләр. Дин исә адәмне аермый. Ул аны ничек бар, шулай кабул итә...»

Байназар, менә шулай, әкренләп, күккә, бердәнбер ышаныч булырлык изге затка, үзе генә күзаллаган газиз рухка табына башлады. Төрмәдән котылгач та, туры Бохарага юл тотты, анда «Мир-Араб» мәдрәсәсендә каравылчы булып ялланды. Буш вакытларында сабакка йөрде, үзлегеннән өйрәнде. Быел менә үзе кайчандыр укытучы булып эшләгән Аюбаш авылына кайтты.



Кәбир белән алар һич көтмәгәндә очраштылар. Улы Булат Түбән Камадан бүләк итеп төсле телевизор китергән иде. Аны озатканда күзгә-күз бәрелештеләр. Булат утырачак автобустан нәкъ Байназарның каршысына чыгып басты Кәбир. Тазарган. Аркылысы-буе бер, муены җилкәсе белән тоташкан, итләч йөзендә соргылт күзләре генә сирпелеп тора.

— Исән-имин генә яшисеңме, Кәбирҗан, аллаһы тәгаләнең кодрәте киң, гаиләңә тынычлык, үзеңә тән тазалыгы бирсен,— дип, иске дустына сәлам бирде Байназар. Ләкин тегесе кул сузмады, гадәтенчә, сөзеп кенә бер карап алды да ярып салды:

— Теге вакытта чын йөзеңне ачып бик дөрес эшләгәнмен, күптән әйтергә җай эзләп йөри идем, очраттым менә, әйбәт булды.

Байназар, башына күсәк белән тондыргандай, өнсез калды. Ул, җүләр, күпме гомер теге ханымга — политмәгариф бүлеге мөдиренә үпкәләп йөрде. Әле аны да очраклы хәл дип санады, янәсе, чәй эчәргә кергәч, көтмәгәндә тап булган. Тугры коммунист, райком хезмәткәре бу хәлне, әлбәттә, тиешле кешеләренә җиткерергә тиеш иде. Баксаң, ул бер кашыктан ашап йөргән якын дустының шикаяте буенча махсус килгән икән, укытучылар белән әңгәмә, чәй — болар барысы да театр уйнау гына булган икән.

И, Кәбирҗан, Кәбирҗан... Куеныңда кара елан йөрткәнсең бит! Хуш, миңа ачуың да булсын ди, тик нигә дип шушы кара эшкә башкаларны кушарга кирәк иде, үч алуның башка юллары да күп ич.

Байназар, Кәбир белән очрашканнан соң, атна буена үз-үзенә урын таба алмый йөрде. Якын кешеңнең хыянәтен белү, һай, авыр икән?! Хәтта Кәбирнең үлем хәбәрен ишетү дә аны бу авыр халәттән суырып ала алмады, рәнҗүе кара болыт шикелле баш очында тик асылынып тора.

Якын иде, бик якын иде бит Кәбир. Дөрес, баштарак үзен эре тоткан булды. Тик, Байназарлар өйләнешкәннән соң, үз язмышы белән килешкән, тынычланган иде.

Кинәт нидер чайкалып китте, морҗа зурайткыч пыяла аша караган шикелле озын баганадай сузылды-сузылды да, урталай бүленде, өй эче акшарланган морҗа кебек ап-ак балкыш белән тулды. Шул ук мизгелдә Байназарның колак төбендә вәгазь-нәсихәт яңгырады: үзеңнең дә сыналыр сәгатең сукты, и адәм баласы! Иң якын затыма иң авыр имтиханымны җибәрермен, дигән ходай тәгалә, Коръән-кәримнән син моны үзең укыдың. Ә бүген кан кардәшеңнең җеназасына барудан баш тарттың, фани дөньяның минутлык вәсвәсәсенә бирелеп, үз шәхесеңне, үз мәнфәгатьләреңне барысыннан да өстен куйдың. Кардәшеңнең гөнаһысын ярлыкау — таңребездән килгән бөек вазифа. Сиңа әлеге хакыйкатьне мәрхүмнең улы да җиткерергә тырышып карады, ләкин дә син аны кабул итмәдең. Акылыңа кил, үзеңнең үткән тормышыңны хәтереңә төшер...

Булдымы әлеге хәл, юкмы,— ихтимал, ул Байназарга шулай тоелгандыр гына. Әмма очкындай чәчрәгән бу кайнар дулкын, очлы без шикелле, йөрәгенә кадалып торган үпкә-каргышларын үзе белән юып алып китте. Җиңеләеп калды Байназар, гүя, битеннән йомшак саба җиле сыйпап үтте. «Әлхәмдү иллаһи, күңелемә аң, тәнемә сихәт өрдең, и илаһым, моннан ары да рәхмәтеңнән ташлама»,— дип пышылдады аның иреннәре.

...Кәбирне җирләп кайтканда да телевизоры эшләп тора иде әле.

## ПУБЛИЦИСТИКА

# СУЛАР ҺАВАҢ БАРМЫ?..

*Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь Гәрәй Рәхимнең Идел-Кама тыюлыгы директоры, биология фәннәре кандидаты Булат Хәсәншин белән әңгәмәсе.*

Гәрәй Рәхим: Экология... Тирә-як мохитның, бигрәк тә меңәр, миллионышар кеше бергә җыелып яши торган тирәлекнең һавасы, суы, җире агулы газлар, химикатлар, ясалма кушылмалар белән пычранып бетте. Шуңа күрә экология турында сүз барганда, безнең «пычрану» сүзе урынына «агулану» дигән сүзне куллана башлавыбыз да бик ихтимал... Атом электр станцияләренең атом бомбасына караганда да куркынычрак була баруы (бу куркынычның ике сәбәбе бар: беренчедән, атом бомбасы хәрби продукция буларак гаять югары сыйфатлы итеп эшләнә, шуңа күрә аның шартлау куркынычы аз, ә АЭСлар, гадәти төзелеш шикелле, түбән сыйфатлы итеп төзелә, икенчедән, атом бомбасын халыкара килешүләр белән тыеп була, АЭСларны исә һичничек тыеп булмый)... Өстәвенә, табигатьнең, тирә-як мохитның чисталыгын саклау мәсьәләсендә кешеләр бер-берсенә капма-каршы булган ике лагерьга аерыла: промышленниклар, проектантлар, төзүчеләр, дәүләтнең күп акчаларын түгеп, грандиоз төзелешләр майтаруга омтыла, фидакарь зыялыларыбыз исә әлеге эшем кешеләренең зарарлы адымнарына каршы протест белдерә, күп меңле митинглар, демонстрацияләр оештыра, матбугатта чыга...

Бүгенге көндә җәмгыятебездә килеп туган экологик хәлне һәм аның тирәсендәге социаль мөнәсәбәтләрне кыскача әнә шулай билгеләп булыр иде.

Сүз дә юк, күңелгә шактый шом сала торган, әмма фактлар белән кире кагуы бик тә читен булган реаль күренеш бу. Мондый ситуация безнең иксез-чиксез илебезнең байтак төбәкләренә хас, ә инде Татарстанга килсәк, ул экологик яктан илебезнең иң киеренке хәлдәге төбәкләре арасында тора булыр. Җирле советлар һәм җәмәгать оешмалары «Татнефть», «Оргсинтез», Түбән Кама, Алабуга, Чаллы һәм Менделеевскидагы гигантлар каршында бөтенләй чарасыз калалар.

Шулай да, Булат Дәүлиевич, безнең бүген кулга каләм алуыбызның төп максаты республикабыз халкын инде болай да куркытып бетергән экологик «өрәк»ләрне барлап чыгып, укучыларны тагын да ныграк хәвефка салу түгел. Һич юк. Киресенчә, бу хәлдән чыгу юлларын эзләргә иде! Мәгълүм ки, республикада табигатьне, тирә-як мохитның сафлыгын саклаучы кешеләр, иҗтимагый хәрәкәтләр, хәтта рәсми оешмалар да бар. Татарстанда тирә-як мохитны саклау буенча махсус комитет та булдырылды. Университет галимнәре һәм студентлары бу өлкәдә туктаусыз эзләнүләр һәм көрәш алып баралар. Соңгы елларда республикабыздагы матбугат органнары да экология проблемаларына йөз белән борылды. Бездә үзенең статусы белән үк табигатькә иң миһербанлы мөнәсәбәттә булган оешма да бар — ул сез җитәкли торган Идел-Кама тыюлыгы. Ләкин, кызганычка каршы, җәмәгатьчелек аның күпкырлы эшчәнлеге турында хәбәрдар түгел. Бүгенге шартларда исә кешенең табигатькә мөнәсәбәтенең иң югары өлгесе булган тыюлык эшчәнлеге халыкка ныклап аңлатылырга тиеш иде. Татарстан экологиясе, аның тарихы, бүгенге тормышы һәм киләчәге, тыюлыкның бу өлкәдәге урыны, экологик һәм җәмәгатьчелек, экология һәм экономиканы кулларында тоткан җитәкче оешмалар, ниһаять, экология һәм әхлак, экология һәм патриотизм кебек мәсьәләләр мине генә түгел, республикабызның күпләгән гражданнарын борчый.

Шуңа күрә, Булат Дәүлиевич, мин сүзне «экология» дигән төшенчәдән үк башлап китүегезне телим. Хәтерегездәдер, СССР халык депутатларының беренче съездында «Нәрсә ул экология?» — дигән сорау бирделәр. Председательлеккә кандидат бу сорауга җавап тапмады. Сез моны ничегрәк аңлатыр идегез?

Булат Хәсәншин: Кайберәүләр, бу эпизодка карап, экология мәсьәләләре белән шөгыльләнергә тиешле комиссиянең булачак рәисе экологиянең нәрсә икәнен белми дигән ашыгыч нәтиҗә чыгардылар. Минемчә, бу мәсьәләне аңламаудан гына килә. Рәис, әлбәттә, барын да белә. Минем фикеремчә, аның сорауга җавап бирмәвенә ике сәбәп бар: беренчедән, сорау ирония белән куелды һәм аңа җавап биреп

тору үзеңне мәктәп баласы итеп тою белән бер булыр иде. Икенчедән, кыска вакыт эчендә генә экологиянең бөтен тулылыгын эченә алган җавап биреп өлгерергә мөмкин дә түгел. «Экология» төшенчәсе соңгы вакытта шул кадәр киңәйде ки, аның мәгънәсе фән, техника, промышленность үскән саен тирәнәя, байый, зурая бара. Әйтик, Мәскәүнең «Фән» нәшрияты 1932 елда бастырып чыгарган сүзлек бу төшенчәгә 22 төрле аңлатма бирә. Миңа калса, сүзлектәге «Гомуми экология» дигән баш астындагы аңлатма бүгенге таләпләргә азмы-күпме җавап кебек. Анда экология түбәндәгечә аңлатыла: «Фәннең үсемлекләргә һәм җан ияләренә хас булган (кешене дә кертеп) организмнар һәм мохитларның үзара мөнәсәбәтләренә бәйләнешле гомуми закончалыклары турындагы бер тармагы». Теоретик яктан, бу бүлгеләмә байтак мәсьәләне колачлый, шулай да, практик яктан, ул безнең тарафтан тудырылган мәсьәләләрне читтә калдыра. Бер мәсьәлә ачык: табигатьнең сафлыгын саклап, кеше үз-үзен дә саклый. Күбәләккә очар һәм яшәр өчен уңай шартларны саклап калу (игътибар итегез: уңай шарт тудыру түгел, чөнки кеше беркайчан да табигатькә уңай шартлар тудыра алмый, аны табигать үзе булдырган инде — кеше табигатьтәге уңай шартларны бары тик саклый яки бетерә генә ала!) ахыр килеп, кешенең үзе яшәр өчен уңай шартны саклау белән бер, чөнки агулы-газлы һавада күбәләк оча алмаган шикелле, анда кеше дә яши алмый.

Г. Р.: Димәк, «экология» төшенчәсе иҗтимагый, сәяси һәм әхлакый мәгънәгә ия. Миңа калса, хәзерге заманда, экологиягә мөнәсәбәтенә карап, кешенең әхлагын, аның ни дәрәҗәдә намуслылыгын, җәмгыять алдындагы җаваплылыгын, культура дәрәҗәсен билгеләп була.

Б. Х.: Мин сезнең белән тулысынча килешәм. Һәм бу урында журналистларыбызның, язучыларыбызның экологиядәге әхлаклылык турында бик аз сөйләүләре турында әйтми китә алмыйм. Безнең бүгенге экологик халәтебез шуны таләп итә: табигатьне санламаучы һәр кешенең исем-фамилиясен әйтеп, аларны халык алдында рисвай кылырга, закон тәртибендә җавапка тартырга кирәк. Һәр журналист, язучы кечкенә генә бер инешнең пычрануы яки агулануы турында, бу җинаятьне эшләүченең исем-фамилиясен әйтеп, зыянның күләмен төгәл күрсәтеп һәм аны түләтү чараларын төгәл әйтеп сөйләшергә тиеш.

Г. Р.: Мин моңа язучыларыбыз алдындагы бурыч итеп карыйм. Шулай да, Булат Дәүлиевич, ачыклап үтик әле! Табигый яшәү шартлары ягыннан караганда, Татарстан нинди урын тота?

Б. Х.: Горурланып әйтергә мөмкин, Татарстаныбыз гаять отышлы урынга туры килгән. Адәм баласына яшәү өчен күп тә кирәкми кебек: һава, җир, су һәм җылылык. Татарстанның һавасында кислород һәм башка кушылмаларның микъдары нәкъ тереклек ияләре һәм үсемлекләргә кирәкле күләмдә (бу урында «иде» дип әйтсәк килә, чөнки Татарстан һавасы хәзер бик нык пычранды); бездәге урманнар, Идел, Кама, Вятка, башка вак елгалар һәм күлләр (безнең республикада эрелеваклы 3000 елга һәм 1500 күл бар!) балык үрчетү һәм тоту, җир-су җәнлекләре, киекләр яшәү өчен бик тә уңайлы; кырларыбыз гаять уңдырышлы, терлекчелек һәм яшелчәчелекнең күп төрләре белән шөгыльләнергә мөмкин. Татарстанда җир асты байлыкларының да байтак төрләре бар, нефть чыгарып кына да безнең республика дөньядагы иң бай ил була алыр иде! Урманнарыбыздагы агачлар, дару үләннәре, алардагы киекләрне рациональ файдаланырга, умартачылыкны нык үстерергә һәм, ниһаять, яшәү шартларын бездәге язгы, җәйге, көзге җылылыкка яраштырып алып барырга зур мөмкинлекләр бар. Гомумән, Татарстан — җир шарының уникаль урыннарының берсе. Ул урман һәм дала зоналары кушылган җирдә, аның да әле Идел, Кама кебек бөек елгалары төбәгендә. Шушы уникаль географик урын безгә бөек Урманның, бөек Даланың гаҗәеп кызыклы синтезы булган Урман-Дала зонасының бөтен җайлылыкларын файдаланырга мөмкинлек бирә.

Г. Р.: Әмма географик урыныбызның мондый бай һәм җайлы булуы халыкка зыян да салган. Баштан ук шуны әйтергә кирәк, татар халкының алдынгы фикерле галимнәре, философлары, шагыйрьләре борынгы заманнарда ук табигатьне танып-белү мәсьәләсендә тирән уйланганнар. Без бит экология фәненә бары тик табигатьне танып-белү аша гына килә алабыз. Әйтик, бөтен дөнья җәмәгатьчелеге Җир шарының галәм үзәге булмавын, киресенчә, аның Кояш тирәсендә әйләнеп йөрүче күпләгән җисемнәрнең берсе генә булуын беренче кат раслаучыларны Николай Коперник (1473-1543) һәм Джордано Бруно (1543-1600) дип белә. Әмма татарның урта гасыр шагыйре Сәйф Сараи 1394 елда үзенең «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәрендә Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүе турында яза:

*Сөһәйлне курер-йу әйләнде пәр дик*
*Кояш гирдендә йөргән мисле Җир тик.*

Ягъни, Гөлдерсен, Сөһәйлне күрүгә, Җир Кояш тузанында йөргән кебек, җиңел каурыйдай әйләнде. Сәйф Сараиның бу шигыре гаять зур фәнни ачышны

раслау да! Коперниктан — 150, Джордано Брунодан 200 ел алданрак язып калдырылган ачыш! Шушы фикерне әйткән өчен, дини кануннарга тәмам инанган кешеләр Коперникны «еретик» дип, тереләй утта яндыралар, ә Джордано Бруноны, төрле җәзалар белән янап, үзенең фәнни фикереннән ваз кичәргә мәҗбүр итәләр. Гаҗәп, шушы «еретик» фикерне 1394 елда ук әйткән Сәйф Сараига берни булмый. Димәк, мөселман дөньясы, католик дөньясына караганда, фәнне хуплабрак каршы алган. Әмма, шул ук вакытта, Сәйф Сараиның исеме дөнья җәмәгатьчелеге тәлендә яңгырамый. Бу өлкәдә дөнья җәмәгатьчелеге бөек дан таҗын Коперник белән Бруногa кидерде. Ник болай? Моңа ике сәбәп бар дип уйлыйм мин. Беренчедән, тәкәббер Көнбатышның, югары фәнни һәм мәдәни культурага ия булган Көнчыгышны танырга теләмичә, аны өйрәнмәве һәм белмәве; икенчедән, «еретик» фикер әйткән өчен Коперник белән Брунoның фаҗигасе. Көнчыгыш үзе исә фәнни фикер әйтүче Сәйф Сараига шагыйрь итеп кенә карый, ул моның өчен фаҗига да кичерми, кызганычка каршы, фәнни яктан танылмый да кала.

Ары китик! Идел-Кама буйларында Бөек Болгар дәүләте яшәп яткан чакларда безнең төбәкләргә монгол басып алучылары нәфесен суза башлый. Болгар дәүләте бик күп каршылык күрсәтүләрдән соң 1236 елда Алтын Урда составына кертелә. Бу сугышның төп максаты басып алынган җирләрдә җитештерелгән байлыкларны талап алып китү була. Табигатьне һәм тирә-як мохитны яшәү өчен яраксыз хәлгә китерү монголларның максатында булмаган. Әмма, һичшиксез, шушы уңдырышлы җирләрдә үскән игенне, Идел һәм Кама буе далаларында, болыннарында үскән үләнне ашап үрчегән мал-туарны талап китү дә табигатькә зыян салмый калмаган, ә инде җәмгыятькә килгән зыянның зурлыгын әйтеп торасы да юк — гасырлар буе Идел-Кама буйларында мул тормышта яшәп яткан халык монгол баскакларыннан җәфа чигә, тәмам бөлгенлеккә төшә һәм күпләр үз туган җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр була.

Соңрак, Казан ханлыгы чорларында, Идел һәм Кама елгалары тагын да байтак илләрнең күзен кыздыра башлый. Бигрәк тә рус патшалыгы бу байлыкка кызыга. Ниһаять, 1552 елда Иван Грозный рус патшаларының әллә ничә гасырлык хыялын тормышка ашыра — ул Казан ханлыгын басып ала һәм шуның белән Идел-Кама су юлын гына түгел, ә бу бөек елгаларның ике як ярларындагы иң уңдырышлы, иң җайлы һәм иң күркәм табигый байлыкларны үз кулына төшерә. Йөзәрләгән, меңәрләгән еллар буе Идел-Кама ярлары буенда яшәгән җирле халык, аларның авыллары елга ярларыннан читкә куыла, патша хөкүмәте иң уңдырышлы җирләрне үз кешеләренә бүлеп бирә.

Тарих шаһит, бу көрәштә гадел сугыш алып барган җирле халык җиңелә һәм экологик мохитны колонизатор идарәсенә тапшырырга мәҗбүр була. Инде шушы фикеребезне раслау өчен патша хөкүмәтенең бу байлыкларны җирле халыктан ничегрәк һәм күпмерәк талаганлыгын да карап үтик. Атаклы тарихчы галим М. Худяков. Россиядә XVI-XVII гасырларда иҗтимагый-экономик тормышны чагылдыра торган язмаларның Казан өязенә багышланганнарында бирелгән мәгълүматларга таянып, шундый хисаплаулар ясый. Казан ханлыгын басып алганнан соң патша хөкүмәте гомер-гомергә тау һәм кыр ягы татарларныкы булган түбәндәге табигый байлыкларны рус служилыйларына бирә: тау ягында — 17769 чирек (бүгенгечә 89 кв. км. чамасы) чәчү җире, 575 дисәтинә (6 кв. км. чамасы) бер ел чәчеп, аннан соң берничә ел үткәч кенә, чәчелә торган җир, 260000 кибән печән чабып алырга мөмкин булган болын, 1809 дисәтинә (18 кв. км. чамасы) урман; кыр ягында 39785 чирек (199 кв. км. чамасы) чәчү җире, 45710 кибән печән чыгарлык болын, 12773 дисәтинә (128 кв. км. чамасы) урман. Бу җирләрнең җәмгысын санап карасаң, 442 кв. км. чәчү җире һәм урман килеп чыга.

Хисаплаулар күрсәткәнчә, XVI-XVII гасырларда Казан өлкәсенең тау һәм кыр ягында 6556 кв. км. мәйданы талап алынган. Бу — бүгенге Зеленодольск, Югары Ослан, Лаеш һәм Биектау районнары урнашкан территориягә тәңгәл килә.

Россиянең иң эре алпавытларыннан берсе булган Нарышкинга гына да Идел буеның хәзерге Тәмте янындагы 27384 дисәтинә иң уңдырышлы сөрү җирләре алып бирелә. Казан һәм аның тирәсендәге җирләрнең халыктан талап алынуы турында Ш. Мәрҗани түбәндәге мәгълүматларны китерә: «Казанның тирә-юнендә, ачык урыннарда мөселманнарның бихисап авыллары һәм җәйләүләре бар иде. Кешеләр барысын да ташлап, башка урыннарга күчтеләр. Шул уңайдан Бишбалта, Әхмәд, Карабай, Кадыш, Ике вәкаләтле, Тугаш, Балавыз, Киндерле, Бөреле, Аяз иле, Сыңгыр, Биектау, Чыпчык, Пимар авыллары татар хөкүмәте заманында бөтенләй мөселманнар урыны булып, соңыннан урыслар урыны булды... Казан мөселманнары шәһәрдән чыгарылып, аларга Түбән комлыкта урнашырга әмер ителде... Шул җирләрдәге татар крестьяны яңа хуҗаларга буйсынып калды».

Казан алынып, 4-5 дистә ел үтүгә, элекке ханлыкның яшәү шартлары өчен иң уңайлы булган табигать киңлекләрендә 15 монастырь барлыкка килә. 1755 елда Казанда епархия төзелгәч, Иван Грозный анда архиепископ итеп үзенең шәхси танышы, татар халкының рухи һәм дини хисләрен мыскыл итүчеләрнең берсе булган Гурийны җибәрә. Гурийга ханлык башкаласының һәм бу тирә табигатенең иң гүзәл җәүһәрләре булган Кабан күлләренең өчесе дә һәм Иделнең сул ягындагы егерме-утыз чакрымлык иң бай, иң матур болыннары бүләк ителә.

Б. Х.: Безнең Идел-Кама тыюлыгының Раифа бүлегендә хәзергечә сакланып калган монастырь тарихы да нәкъ әнә шул чордагы тарихи вакыйгаларга карый. Хәтерегездәдер: татар халык җырларының берсендә шундый сүзләр бар:

*Урман эчләрендә урман —*
*Керсәм чыгалмам инде...*

Бу сүзләр безнең борынгы бабаларыбыз яшәгән Идел-Кама буйларында нинди зур, киң, калын урманнар булуы турында сөйли. Безнең Идел-Кама тыюлыгының Раифа бүлегендә әнә шундый кереп-чыккысыз кара урманнар булган. Бу урманнар бик чиста, саф, кеше кулы кагылмаган табигый хәлдә сакланган...

Казан ханлыгы басып алынуга, Мәскәү кешеләре Идел буйларына ябырыла. Атаклы тюрколог Е. Малов әйтүенә караганда, Филарет исеме алган бер монах 1613 елда Раифа күле ярына килеп җитә. Кеше аягы басмаган бу тыныч җирләр дәрвишнең күңеленә хуш килә, ул үзенең гомерен шунда үткәрергә карар кыла, кечкенә генә бер алачык корып яши башлый.

Озакламый Филарет эзләп тапкан урынга аның дуслары да килгәли. Дәрвишлеккә аеруча бирелгән кайбер диндарлар бөтенләйгә монда калу нияте белән Филарет янәшәсендә торак әмәлли. Шулай итеп, күл ярында кечкенә генә дини җәмгыять оеша. Вакытлар үтә торгач, җәмгыять зурая, аларга гыйбадәт кылу өчен зуррак урын кирәк була башлый һәм Филарет тәкъдиме белән кашанә төзелә.

1689 елда, инде җәмгыять членнары тарафыннан шактый зур һәм әйбәт итеп төзелгән бу торакта янгын чыгып, бөтен биналарны һәм көнкүреш кирәк-яракларын юк итә. Янгыннан соң монастырь тагын да зуррак һәм ныграк итеп салына. Монастырьның гыйбадәтханәләр һәм тораклар урнашкан үзәге кремль диварларын хәтерләткән калын кирпеч стена белән уратып алына.

Раифа тирәсендәге калын, бай урманнар монастырь милке итеп беркетелә һәм алар бик нык саклана. Бу урманнарның Совет власте елларында табигый хәлендә калуы анда Казан фән үзәкләренә фәнни эзләнүләр алып барырга һәм, ниһаять, 1960 елда Идел-Кама тыюлыгы ачарга мөмкинлек бирде.

Г. Р.: Булат Дәүлиевич, бу урында күңелгә бер сорау килә: бәлки патша администрациясе, архирей, митрополит һәм монастырьлар бу җирләрдән гади татар кешесе мәнфәгатьләрендә файдаланганнардыр?..

Мисал өчен патша администрациясенең татар җирендәге урманнарны ничек файдаланганлыкларын гына карап китик. Татарстан урманнарына, гомумән, тынгылык булмаган бит. Кайбер галимнәрнең исәпләүләренә караганда, Совет власте елларында гына да Татарстан урманнарының 60 проценты кисеп юк ителгән.

Рус тарихына бөек реформатор, иң прогрессив патшаларның берсе буларак кереп калган Петр I дә — безнең җиргә бик зур зыян китергән колонизатор. Бу патша 1718 елдагы указы белән сугыш көймәләре әзерләү, алар өчен агач кисү һәм ташу эшләрен элек Петергофны төзегән татар, чирмеш, мукшы, чувашларны, хак түләмичә, файдаланырга указ чыгара. Шушы указ нигезендә безнең мәйданда иң шәп имән урманнары вәхшиләрчә кырыла, татар халкы тарихының иң кара сәхифәләрен язган лашманчылык коллыгы башлана. Татар крестьяннары көчләп лашманчылыкка тартыла.

Бу очракта, безне экологик объект буларак, урманнарның ни дәрәҗәдә юкка чыгарылуы кызыксындыра. Петр патша, Казанда адмиралтейство төзетеп, җирле халыкның үзеннән үк аның милли байлыгы булган урманнарны кырдыра. Бу хәл 100 елдан артык дәвам итә. Хәзерге Татарстан һәм аңа күрше өлкәләрдә эшкә яраклы урманнар юк ителеп беткәч кенә, 1827 елда адмиралтейство Казаннан Әстерханга күчерелә.

Әмма вәхшиләрчә урман кисү чорында да җирле халыкка имән агачы алу кискен рәвештә тыела. Әгәр берәүнең имән кискәнлеге исбатланса, аңа үлем куркынычы яный.

Ул чактагы экологик әхлак кагыйдәләре әнә шундый булган.

Кызганычка каршы, табигый байлыкларны файдалану ягыннан экологик әхлак бүгенге көндә дә әллә ни югарылыкларга ирешкән дип булмый. Мисал өчен Татарстанның төп казылма байлыгы нефтьне генә алыйк. Безнең республика әле кайчан гына нефть чыгару буенча Советлар Союзында һәм дөньяда беренче урынны алып торды. Шул ук вакытта без ул чакта, Татарстан нефте дәүләт өчен иң арзанлы ягулык — аның бер тоннасын чыгару нибары бер стакан газлы су бәясенә төшә, дип мактана идек. Бу «бер стакан су» Татарстанның көнчыгыш районнарындагы кыр-болыннарга, чишмә-инешләргә, урман-әрәмәләргә нинди бәһагә төшкәнен без әле хәзер генә чамалый башладык. Баулы, Азнакай, Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Түбән Кама шәһәрләре һәм эшчеләр поселокларына барып, андагы һаваны сулап, суларыннан авыз итеп карагыз...

Әле дә хәтеремдә: Татарстан нефте башланып киткән атаклы Шөгер скважинасыннан нибары 20 чакрым ераклыктагы туган авылым Федотовка кырларында агып яткан Аланлык һәм Корманлы исемле ике нәни инешләрдән без сугыштан соңгы елларда гына да әле күпме балык тота идек. Ул чакта, аның форель икәнен дә белмичә, керкә дип кенә йөри идек. Соңыннан, укып белгәч, шаккаттым, без көн саен,

ыштан балагы белән тотып, кыздырып ашый торган бу балыкның даны дөньяга «король балыгы» дип таралган икән: «Форель!» Бу — корольләр ашындагы иң затлы ризык икән! Форельнең тагын бер хикмәте шунда: аның белән суның сафлыгын тикшереп карыйлар. Суның аш-су өчен яраклымы-юкмы икәнен белү өчен аңа форель җибәрәләр: ул яши алса, бу иң саф су була. Форель пычрак суда яши алмый. Чыннан да, бер ярыннан икенче ярына сикереп-атлап чыгарлык Аланлык белән Корманлы инешләрендә керкәләр инде яши алмый башладылар.

Бу инешләрдән тулып-тулып күпме нефть акты?! Әле моннан берничә ел элек кенә безнең авылдагы (һәм нефть районнарындагы һәр авылда да шулай булгандыр дип уйлыйм) ап-ак каз-үрдәкләр нефть аккан елгада коенып кап-кара төскә керәләр, берничә атнадан инде аларның йоннары коелып бетә иде. Авыл тирәсендәге болыннарда кара күзгә кадәр шәп-шәрә калган, кап-кара төстәге каз һәм үрдәк төркемнәре йөри. Авыл кешеләре аларны, фаҗига катыш шаярып, «нефтяниклар» дип атый. Хуҗалары бу каз һәм үрдәк ояларын өйләренә дә кертмиләр, чалмыйлар да, чөнки инде аларның итләре ашарга яраксыз.

Республика нефть промышленностендагы җавапсызлык, саксызлык, бу төбәкләрдәге тормышның хәвефле яклары үзен бик ачык күрсәтә башлады. Татарстан нефте үзен илленче елларда ук бик яман яктан күрсәтә башлаган иде, тик ул чакта моңа игътибар итүче генә булмады. Илленче еллар башында бездән 25-30 чакрымдагы Кәләй авылының бер тракторчысын, кырда җир сөреп йөргәндә тракторы-ние белән җир уба. Мондый җир иңүләр, мондый фаҗигалар башка урыннарда да була, ләкин аларның бик күбесе җәмәгатьчелектән яшерелеп калдырыла. Бүгенге көндә, Татарстан нефтен җир астына тозлы су кудыртып ала башлагач, күп газаплар кичергән бу төбәкләргә яңа афәтләр яный. Беренчедән, җир гаять нык суландырыла. Әйтик, минем туган авылымда базлар мөлдерәмә су белән тула, аларда күпме азык-төлек харап була. Икенчедән, уйсу җирләрдәге иң уңдырышлы басулар тозлы сазламыкларга әверелә — мондый мохитта бер җан иясе дә яши алмый. Өченчедән, һәм монысы иң зурысы булса кирәк, бу як авылларның йөзләгән чишмәләренә агулы су килә. Шуның нәтиҗәсендә, безнең якның гомер бакый саф сулы салкын чишмәләре белән дан тоткан авыллары суны цистерналар белән ташып эчәргә мәҗбүрләр.

Б. Х.: Нефть чыгаручыларның мондый «хәйләкәр» һәм, сез әйткәнчә, гарип эшчәнлеге турында республикабыз матбугатында да хәбәрләр күренгәләде. Бу — һичшиксез, түзеп тора алмаслык, кичекмәстән төзәтелергә тиешле хәл. Экология мәсьәләләрендә намуссыз, йә булмаса экономика, финанс ягыннан көчсез булган оешмалар, шул исәптән санэпидстанцияләргә дә җәмгыять, бер яктан экономика һәм финанс ярдәме күрсәтергә тиеш булса, икенче яктан, аларны юридик яктан бик нык җаваплылыкка тотарга тиеш. Әйтик, СССР Югары Советының экология мәсьәләләре белән шөгыльләнүче комиссиясе, илдә экологик прокуратура челтәре булдырырга кирәк, диган тәкъдим белән чыкты. Мондый прокуратура, һичшиксез, урыннардагы экологик халәтне контрольгә алыр иде. Әмма миндә шик тә туа — ярый, республикабызның нефть районында экологик прокуратура төзедек ди. Ул прокуратура нәкъ әнә шул санэпидстанцияләр кебек үк җирле бюрократик администрация табасында бии башламас дип кем гарантия бирә?

Шулай да без алдагы сүз сөрешебездән бераз гына читкәрәк киттек бугай. Мин Идел һәм Кама елгаларының бүгенге көндәге пычрану дәрәҗәсен, һәм, Иделдәге — Куйбышев, Камадагы Түбән Кама ГЭСлары төзелү аркасында, бу ике бөек елга сулары республиканың никадәр җирләрен үз колачына алуын һәм ярларында борын-борыннан төпләнеп яшәгән җирле халыкның көнкүреш рәвешенә тәэсир итүен күз алдында тотам. Бу мәсьәләне мин бик җитди мәсьәлә дип карыйм. Уен эш түгел бит, Куйбышев сусаклагычының яртысына якыны Татарстан мәйданына керә. Шуңа Түбән Кама сусаклагычы астында калган җирләребезне дә кушсак, Идел һәм Камадагы бу ике ГЭС кына да якынча Казан ханлыгы җиңелгәннән соң талап алынган җирләр кадәр болын, кыр, урманнарны «басып» алган булып чыга. Әмма колонизатор басып алган җирләр көнкүрештә файдаланылган — басуларга икмәк чәчелгән, болыннарда печән чабылган, хәрби һәм хуҗалык зарурияттына урманнар киселгән. Ә соңгы елларда безнең су астында калган иң уңдырышлы сөрү җирләребез, печәнгә иң бай тугай-болыннарыбыз, урманнарыбыз, туп-туры мәгънәсендә, «суга төшкән балта кебек» хуҗалык әйләнешеннән төшеп калган. Гомумән әйткәндә, инде экология, табигатьне, тирә-як мохитны саклау турында иң югары урыннарда сүз барса да, күп кенә законнар кабул ителсә дә, газета-журналлар чаң сугып торса да, кызганычка каршы, безнең җәмгыять табигатьне кыруын аңа зыян салуын дәвам итә. Без һәр кешедә табигатькә саклык хисе уятмасак, һәлакәткә баруны туктата алмаячакбыз.

Г. Р.: Димәк, һәр кеше үзен табигатьнең һәр яфрагы, һәр җан иясе белән тыгыз хокуклы итеп санарга тиеш. Алардан өстен түгел, ә тигез хокуклы. Шул чакта гына без үзебез йөргән сукмакта, үзебез яшәгән бакчада, үзебез күреп белгән урман, кыр, болын, елга, күл, диңгез, океан, материкта, ахыр килеп, Җир дигән планетабызда табигый сафлык, тәртип, яшәү рәвешен саклап кала алачакбыз.

**Яхья Абдуллин**

# ЧИШЕЛМӘГӘН ТӨЕННӘР

Татар һәм башкорт якынлыгының, мәдәнияттә үзара йогынтысының ерак тарихтан килүче тамырлары бар. Бу тугандаш ике төрки халык күптәннән янәшә мәдәни-рухи кыйммәт-әр алмашып яши. Шуның нәтиҗәсендә, әхлакый күзаллау, дөньяны танып белү, һәм тойгыларны белдерү кебек рухи өлкәдә уртак сыйфатлар шактый. Шул ук вакытта бу халыкларның һәрберсенең үз үткәне, үсешенең үз тарихи юлы бар. Хәзерге татарларның ата-бабалары болгарлар утрак тормышка бик иртә аяк басалар, әле X гасырда ук үз дәүләтләрен төзиләр, эре шәһәр үзәкләренә нигез салалар, игенчелек, һөнәрчелек һәм сәүдә үсешен тәэмин итәләр. Бу инде утрак халыкка хас язма культураның аларда иртә барлыкка килүенә йогынты ясамый калмый. Башкортлар исә XIX гасырга кадәр күчмә тормыш белән яши һәм бу хәл котылгысыз рәвештә аларның мәдәниятендә, халык авыз иҗатында, язма мәдәният туууда һәм үсешендә үзенчәлекле чагылыш таба.

50—60 нчы елларга кадәр фәндә башкорт әдәбиятының яшь булуын, күптән түгел генә барлыкка килүен белдергән караш яшәп килде. Мәсәлән «Әдәби энциклопедия»нең (М., 1929) 1 томында башкорт әдәбияты «фәкать Октябрь революциясе нәтиҗәсендә барлыкка килгән яшь революцион әдәбиятларның берсе» (373 б.), ә «башкорт язучылары үзләре саф башкорт телендә язуны «Башкортстан» газетасы чыга башлау белән бәйләп, башкорт әдәбиятының һәм башкорт әдәби теленең туган елы итеп 1924 елны саныйлар» (375 б.), дип әйтелә. Башкорт әдәбиятының яшь һәм яшь язма телле булуы «Зур совет энциклопедиясенең» (М., 1950) 2 басмасындагы 4 томында да чагылыш тапкан. «Октябрь революциясенә кадәр,— дип яза анда СССР фәннәр академиясенең хәбәрче әгъзасы М. К. Дмитриев,— башкортларның үз язулары, әдәби телләре һәм әдәбиятлары булмый».

«Башкорт совет әдәбияты тарихы»нда (БДУ нәшрияты, Уфа, 1963) «Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр башкорт әдәбияты әле мөстәкыйль милли әдәбият булып китә алмый... Фәкать Октябрьдан соң гына башкорт әдәбияты алдында мөстәкыйль рәвештә үсәр өчен киң юллар ачылды. Революциягә кадәр формалашырга өлгермәгән әдәбиятның тарихында сыйфат ягыннан өр-яңа чор башланды» (8—10 б.), дип басым ясала.

Бу тарихи объектив фактны үзенең «Башкорт тамгасы» (1967) дигән мәкаләсендә Башкортстанның халык шагыйре, Социалистик Хезмәт Герое Мостай Кәрим тирән һәм дөрес гомумиләштерде: «Дистә гасыр дәвамында башкорт ук-җәя асып ат өстендә утырды. Ләкин, мәгълүм булганча, сугышчы һөнәре яңаны иҗат итә торган һөнәр түгел. Ул фәкать хәрабәләр ясарга һәм кабер өстенә курганнар өяргә генә сәләтле. Һәм шуңа күрә, үзебезнең ирек сөючән ата-бабаларыбыз турында уйлаганда, горурлык һәм соклану миндә үкенү һәм пошыну белән бергә кушыла... Әбугалисина үзенең соклангыч фәнни ачышларын ясаганда, Низами үзенең үлемсез поэмаларын иҗат иткәндә, Рафаэль Санти үзенең шедеврларын тудырганда, Бөек Петр баткаклык урында шәһәр торгызганда, ул тыныч һәм мәһабәт кыяфәттә иярдә утырды. Дөнья өстендә Моцарт, Бетховен, Чайковскийның сихерле аһәңнәре йөзеп йөргәндә ул үзе һәм даласы өчен моңлы озын

---

*Яхья АБДУЛЛИН (1920)— галим, фәлсәфә фәннәре докторы, профессор, Татарстанның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе, дүрт гыйльми китап һәм күп кенә бүтән хезмәтлар авторы. Казанда яши.*

жырларын сузды. Иван Федоров Русьта китап бастыра башлаганнан соң да башкорт кулына үзенең туган телендә язылган китапны алу өчен 350 ел кирәк булды.

Тормышның, тулаем алганда, акмый торган суга охшавына, ә бай һәм юмарт рухлы халыкның үз сәләтләрен һәм иҗади көчләрен тәрәккыят эшенә җигә алмавына кем гаепле иде соң? Октябрьга чаклы үзенең милли дәүләтчелеген булдыруга ирешмәгән халыкның тарихи язмышы шулай булды... Дөнья цивилизациясенә без әле бик озак гомер кушылып китә алмас идек. Бу безнең гаеп түгел, ә бәлабез. Тарих шулай хөкем итте... Чынлыкта кешелек дөньясы илле гасыр дәвамында тудырган кыйммәтләрне без фәкать илле ел элек кенә аңлау бәхетенә ирештек. Болар бар да башкорт халкы Ленин партиясе кулыннан яңартылган нигездә үзенең автономияле дәүләтчелеген алгач кына мөмкин булды». (М. Кәрим. Өч туган турында хикәят. М., 1978, 272—273 б.).

«Халыкның тарихи язмышы шулай булды», дигән фикер башкорт мәдәниятенең кайбер эшлекләләренә ошамады һәм алар халыкның шул рәвешле яңаруында тарихи могҗизаны, яңа социалистик милләт барлыкка килүен тирәнрәк аңлатасы урында, үткәннең мәдәни мирасыннан үзләре өчен дә өлеш чыгарырга тырышу кебек җиңел юлга бастылар. Ә мондый өлешне алар тугандаш татар халкының бай сәнгать мирасыннан таптылар.

Күрше татар халкы исәбенә әдәби чикләрне киңәйтү һәм башкорт әдәбиятын баету гамәле әле сугыш алдыннан — кырыгынчы елларда ук башланды. Башкортстанда яшәүче татар әдәбияты классигы Мәҗит Гафурины башкорт совет шагыйренә әверелдерү бу юнәлештә ясалган беренче җитди адым булды. Революция алды елларында һәм 20—30 нчы елларда ул фәкать татар шагыйре булып кына саналды. М. Гафури үзе да шулай исәпләде. Башкорт язучысы Д. Юлтый да үзенең мәкаләләрендә М. Гафурины, С. Кудашны, Г. Гомәрне, Г. Насыйрины «үзләренең әсәрләре белән башкорт әдәбиятын үстерүгә өлеш кертүче» «Башкортстанның татар язучылары», дип саный (Д. Юлтый. Башкортстанның матур әдәбияты — 10 ел мәдәни фронтта, Уфа, 1929). Акрынлап М. Гафури башта башкорт совет әдәбиятына нигез салучыга, аннары башкорт әдәбияты классигына әверелә һәм аның иҗаты башкорт әдәбиятының совет чорындагы гына түгел, революция алды елларындагы күренеше буларак та карала башлый. Менә шулай акрынлап-акрынлап М. Гафуриның иҗаты тулаем башкорт милли әдәбияты казанышы итеп карала башлый һәм хәзер инде Башкортстанның әдәбият белгечләре «XIX гасыр ахырында мәгърифәтчелек традицияләрендә башланып киткән М. Гафури иҗаты XX гасырда башкорт әдәбиятында тәнкыйти реализмны ныгыту өчен барган көрәштә үзәк урынны ала» («Халыкка бирелгән талант». Уфа, 1982, 74 б.), дип язалар. М. Гафуриның башкорт әдәби хәрәкәтендә катнашуын беренче планга чыгарып, Башкортстанның әдәби галимнәре аның татар әдәбияты вәкиле булуы хакында бик сирәк искә алалар. Бу хәл хәтта М. Гафуриның тәрҗемә китапларына да үтеп керде. Барлык әсәрләре туган татар телендә иҗат ителсәләр дә, анда башкорт теленнән тәрҗемә диелгән.

Татар әдәбияты вәкиле М. Гафуриның тарих ихтыяры белән ике тугандаш халык — татар һәм башкорт халыкларының классигы бул·п китүе б·хәссез нәрсә. Ике яисә өч халыкның язучылары булу язмышы М. Акмулла (татар, башкорт, казакъ), Ш. Бабич (татар, башкорт) кебек әдипләр өлешенә дә чыкты. Алар бу әдәбиятлар тарихында үзләренә лаек урыннарны алдылар. Моны аңлатып була әле.

Ләкин шушы күркәм мисаллар, бигрәк тә М. Гафурины башкорт совет әдәбиятына нигез салучыга әверелдерү гамәле башкортның әдәбият галимнәренә башкорт әдәбиятын борынгылатып күрсәтү юнәлешендә яңа омтылышлар ясап карау өчен этәргеч бирде. Монысы — борчылырлык хәл.

Башкорт әдәбиятының тарихи кысаларын гасырлар катламына җәяргә омтылуның икенче чоры Ә. Харисовның «Башкорт халкының әдәби мирасы (XVIII-XIX гасырлар)» (Уфа, 1965) монографиясеннән башланып китә. Үзенең китабында Ә. Харисов Башкортстан әдәбиятының формалашуы һәм үсеше, татар һәм башкорт әдәбиятлары арасындагы үзара бәйләнешләр кебек гаять катлаулы мәсьәләләрне күтәрә. Ләкин бу тарихи-теоретик проблема бик тә субъектив аңлатыла, тарихилык һәм фәннилек принципларыннан читенеп, өстән-өстән генә хәл ителә. Башкорт галиме хәзерге Башкортстан төбәкләрендә һәм аның тирәсендәге өлкәләрдә табылган XVIII һәм XIX гасырга караган барлык тарихи язма ядкарьләрне, татарлар тарафыннан т·тар телендә язылсалар да, башкортныкылар дип белдерә. Ә. Харисов монда Башкортстанның башкортлар өчен генә түгел, ә башка халыклар, шул исәптән татарлар өчен дә икенче ватанга әверелүе хакында күзгә күренеп торган фактны күрмәмешкә салыша. Төрле тарихи сәбәпләр аркасында 6.645 мең татарның фәкать чирек өлеше генә (1.764 мең яисә 26,6 проценты) үз республикасында яши. (Моны 1989 елда уздырылган халык санын алу буенча рәсми мәгълүматлардан чыгып әйтәм). Татар халкының калган өлеше республика чикләреннән т·шка, шул исәптән Башкортстанга һәм аңа чиктәш өлкәләргә таралып утырган. Шунысын да әйтергә кирәк, ·ашкортстанда татарларның рәсми саны (1.120 мең) бер өлеше әле

һаман «башкорт» дип теркәлүгә карамастан, (Д. Сираев. Беләсезме хәлләрне.— «Шәһри Казан» газ., 26.11.1991 һ. б.) башкортлардан (863 мең) күбрәк.

Башкорт җирләрендә татар катламы борыңгыдан ук килә. Профессор Р. Г. Кузеев раслаганча, әле Казан ханлыгы басып алынганчы ук, хәзерге башкорт җирендә татарлар һәм башкортлар бергә яшәгән. XVI-XIX гасырларда Идел буйларын Россиягә кушканнан соң, татар катламы Казан, Пенза, Сембер һәм башка губерналардан күчеп килүчеләр исәбенә тагын да арта. Бу күчеп утыручылар дәүләт тарафыннан да, бигрәк тә саклану чикләре төзүгә бәйле рәвештә башкарыла, шулай ук үзләре теләп килүчеләр дә шактый күп була (татарлар өчен патша хөкүмәте урнаштырган авыр ясактан котылу омтылышы, дини һәм милли эзәрлекләүдән качу, буш җирләр эзләү һәм сәүдә эшләрен җайга салып җибәрү). Нәтиҗәдә хәзерге Башкортстан мәйданында һәм аңа чиктәш төбәкләрдә күп санлы эреле-ваклы татар авыллары һәм шәһәрләре барлыкка килә. Мәсәлән, «Башкортстан АССР. Административ-территориаль бүленеше» (Бишенче басма. Уфа, 1969. 432 б.) белешмәсе мәгълүматлары буенча, 1969 елның 1 гыйнварена Башкортстан АССРның 48 районында (53 районнан) 1000 нән артык татар авыллары санала.

Җирле халык арасында сакланып калган архив һәм тарихи материалларга һәм хәзерге Башкортстан җирләренең ничек итеп үзләштерелүе хакындагы риваятьләргә караганда, XVII-XVIII гасырларда татарлар, хәер еш кына башка милләт вәкилләре дә, зуррак күләмдә җир алып калу максаты белән, ул чакта өстен хокукларга ия булган «башкорт» сословиесенә язылганнар. Нәтиҗәдә «башкорт» этнонимы икенче мәгънәне дә ала — ул билгеле бер этносның вәкилен генә түгел, сословиене дә аңлата башлый һәм социаль атамага әйләнеп китә. Хәзерге Башкортстанда Казан татарлары һәм мишәр сөйләмнәренә ия татар телле «башкортлар»ның булуы өлешчә шуның белән дә аңлатыла. 1959 елда халык санын алу вакытын а 305348 башкортның татар телен ана телләре итеп тануын әйтү дә җитә.

Үзе өчен яңа булган бу төбәкләрдә татар халкы мәдәни традицияләрен үстерүне дәвам итә, әдәби телен саклый. «Кире кагып булмаслык тагын шушы фактны да искә алырга кирәк,— дип язды башкорт галиме Җ. Киекбаев,— башкорт җирләренә күчеп утырган татарлар мәдәни яктан үсеш дәрәҗәсе буенча бер башка югары тора иде..» («Башкорт һәм татар диалектларын өйрәнүнең кайбер мәсьәләләре». Җыентык. Казан, 1961, 370 б.). Җ. Киекбаев, А. Юлдашев һәм башка башкорт галимнәренең хезмәтләрендә күп тапкырлар басым ясап әйтеп кителгәнчә, татарлар Башкортстанга утрак тормыш рәвеше, игенчелек ысуллары һәм кораллары һәм үз язма мәдәниятләрен алып киләләр. Алар анда үзләре һәм башкорт балалары өчен мәктәпләр ачалар. Бу татар мәдәниятенең Көнчыгышка, Көньяк-Көнчыгышка һәм Төньяк-Көнчыгышка таралу чикләрен киңәйтә. Күчеп килгән татарлар яңа эстетик һәм башка рухи кыйммәтләрен тудырып, башкортлар белән кулга-кул тотынышып эшлиләр.

Шушы шартларда ике якын тугандаш халык — татарлар һәм башкортлар, үзара кушылып, бер-берсен баетып торалар. Башкортстандагы татар халкының мәдәниятенә һәм әдәбиятына башкорт мәдәниятенең тәэсирен дә инкарь итәргә ярамый. Халыкның авыз иҗаты, халык музыкасы өлкәсендә бу бигрәк тә ачык күренде. Бер ук вакытта башкорт мәдәнияте үсешенә татар мәдәнияте дә көчле йогынты ясый. Мәктәп-мәдрәсәләрдә татарлар һәм башкортлар уртак программа буенча татар телендә бергә укый башлыйлар. Татарның әдәби традицияләре, китаплары, әдәби әсәрләре акрынлап башкорт гаиләләренә дә үтеп керә.

Үзенең борыңгы традицияләренә нигезләнгән татар әдәбияты Урал тирәсендәге төбәкләрдә әнә шулай туды һәм үсте. Менә шушы әдәбиятны башкортның әдәбият белгечләре 60—70 нче елларда, теге яки бу язучының кайда яшәвенә карап «башкортныкы» дип атый башладылар.

Башкортстанда һәм аңа чиктәш өлкәләрдә башкорт галимнәре тапкан ул язма ядкарьләрнең күпчелеге татар халкы вәкилләре тарафыннан иҗат ителгән иде. Аларны авторсыз калдыру өчен, Ә. Харисов үзе үк уйлап тапкан сафсатачыл теориясенә мөрәҗәгать итте: имеш, «татарның әдәби теле фәкать XIX гасырның икенче яртысында гына кулланышка кергә» (49 б.), ә шуңарчы татар язучылары «тере сөйләм теле белән һич тә уртаклыгы булмаган «төркидән»— ясалма китап теленнән генә файдаланганнар» (50 б.). Бу рәвешле күрәләтә ялган борыңгы татар әдәбияты әсәрләрен исемсез, милләтсез итә, аларны татар халкының тарихи һәм иҗади эшчәнлеге чикләреннән чыгарып ташлый, «иясез малга» әверелдерә. Ә иясез малны кулга төшерергә кем кызыкмас? һәм Ә. Харисов Башкортстанда табылган кульязмаларны башкортныкы дип игълан итеп, XIX гасырда иҗат иткән Әбелмәних Каргалыны, һибәтулла Салиховны, Шәмсетдин Суфи-Зәкине башкорт әдипләренә әверелдерә.

Ләкин Ә. Харисов һәм башка башкорт филологларының «Урал ягы — Идел буе төркиләре»нең әдәби теле һәм шул телдә иҗат ителгән әдәбияты турында концепциясе, этник иясе күрсәтелмәгәнгә, тарихи дөреслеккә каршы килә. Ул татар әдәби телен

һәм шул телдә язылган әдәбиятны инкарь итүгә юнәлдерелгән. Ләкин тарихи гаделлек шундадыр, әле XV-XVI гасырларда ук иске үзбәк, иске азәрбайҗан, иске төрекмән телләреннән аермалы буларак, Урал-Идел буенда чын әдәби тел формалаша башлый. Рус дәүләтенә кушылгач та шушы телдә әдәби әсәрләр иҗат ителә, рәсми кәгазьләр языла. Академик В. Бартольд күрсәтүе буенча, тарихның аерым чорларында татар теле дипломатик тел буларак та кулланыла. һәм нәкъ менә шушы тел Россиянең рәсми һәм фәнни даирәләрендә татар теле дип атала. Академиклар А. Казымбәк, В. Бартольд, В. Радлов аны казан татарлары теле дип саныйлар. Күренекле шәрык белгечләреннән Петербург университеты профессоры В. Григорьев, Казан университеты профессоры Н. Катанов та шул ук фикердә торалар. Төрки халыклар арасында татар телендә әдәбият һәм дәреслекләрнең киң таралуы христиан миссионерларын да зур хафага сала. Н. Ильминский һәм А. Знаменский, мәсәлән, эшчәнлекләрендәге уңышсызлыкларны шуның белән аңлаталар. Русча-татарча сүзлек төзегән рус галимнәреннән И. Гиганов (XVIII гасыр) һәм Трояновский (XIX гасыр) татарның язма материаллары белән эш итүләренә шикләнмиләр.

Татар телен гыйльми рәвештә өйрәнүнең ике гасырдан артык тарихы бар. Бу эшне әле XVIII гасырның 70 нче елларында татарның беренче грамматикасын һәм беренче татарча-русча сүзлеген әзерләгән Казан гимназиясе укытучысы С. Хәлфин башлап җибәрә. Аны Казан университеты адъюнкты С. Хәлфинның оныгы Ибраһим Хәлфин (XIX гасыр) дәвам итә. Татар телен, әдәбиятын өйрәнүгә С. Күкләшев, А. Ваһапов, М. Иванов, Г. Махмутов һәм, ниһаять, атаклы мәгърифәтче-демократ К. Насыйри зур өлеш кертте. Бу галимнәрнең һәммәсе дә бу телне татар теле, ә шул телдә язылган әдәбиятны татар әдәбияты дип карыйлар. С. Күкләшев исә бу телдә өч стиль булуын билгеләп үтә: 1) әдәби әсәрләр языла торган югары стиль; 2) рәсми эш кәгазьләре алып барыла торган урта стиль; 3) гади сөйләм стиле.

Үзләре тарафыннан ук уйлап табылган «Урал ягы — Идел буе төркиләре» концепциясенә яраклаштырылып, боларның барысы да башкорт галимнәре тарафыннан инкарь ителә, үткәннең язма документларына мөрәҗәгать иткәндә саксызлык күрсәтелә. Бу хәл кайбер басмаларда ап-ачык күзгә бәрелеп тора. Әйтик, «Башкортстан тарихы буенча материаллар» җыентыгы томнарында (М.,— Л., 1 том, 1949; IV том, 1956; V том 1960) мисал итеп татар телендә язылган документлар китерелгән һәм документларның үзләре дә «татар язмасыннан тәрҗемәләр» дип билгеләнгән (мәсәлән, өченче томның 11, 511—513, 539—540, 544 битләрдә урнаштырылганнарында). Ләкин башкорт тарихчылары документлардагы мондый искәрмәләрне төшереп калдыралар, йә башка белән алмаштыралар, яисә үзләренчә төзәтәләр. Җыеп кына әйткәндә, киң җәмәгатьчелекне саташтыру, алдау бара.

Ә. Харисов башлап җибәргән башкорт әдәбиятын «баету», аны күп гасырлык тарихы булган әдәбиятка әверелдерү гамәле 60—70 елларда бүтән башкорт әдәбият белгечләре тарафыннан да күтәреп алынды. Бу мәсьәләдә профессор Г. Хөсәенов аеруча өлгерлек күрсәтте. Өстәвенә Ә. Харисовның «теориясе» хәзер XX гасыр башына карата ул чакта башкортның әдәби әсәрләре татар әдәби телендә язылган дигән күрсәтмә белән тулыландырыла. Бу концепция әдәбиятлардагы теләсә нинди художество-эстетик үзенчәлекләрне юк дәрәҗәсенә калдыра, Башкортстанда яисә элеккеге Уфа губернасында яшәгән һәм татар телендә язган теләсә кайсы язучы иҗатын башкорт әдәбияты җимеше итү өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр ача. Бүген ул шулай эшләнә дә: Уфа яки Оренбург губерналарында яшәгән барлык язучылар, композиторлар, музыкантлар, артистлар башкортныкы дип игълан ителә!

1979 елда биш томлык «Башкорт әдәбияты тарихы» план-проекты нәшер ителде. «Урал ягы һәм Идел буе халыклары әдәбияты тарихы мәсьәләләре» (Уфа, 1978), «Башкорт әзәбияты тарихеннән» (Уфа, 1975), «Башкортстанның язма ядкарьләре» (Уфа, 1982), «Урал-Идел буе халыкларының әдәби мирасы һәм заман» (Уфа, 1980), «Көньяк Уралның археографиясе һәм лингвистик текстологиясе» (Уфа, 1977) кебек аерым җыентыклар чыкты. Аларда башкорт әдәбиятының формалашуы һәм үсеше турында яңа концепция эшләнә һәм тәкъдим ителә. Җыентыкларның авторлары, бу концепция яңа ысуллар кулланып һәм зур тикшеренүләргә нигезләнеп эшләнде, диләр. «Башкорт әдәбияты тарихының» беренче томы (план проекты буенча) башкорт әдәбиятының борынгы һәм урта гасырлар дәверенә багышлана. Ул «борынгы Болгар нигезендә туган башкорт-татар уртак мирасы» дип карала, һәм аны «Кыйсаи-Йосыф»тан башларга тәкъдим ителә. Ә XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башындагы башкорт әдәбиятына багышланган икенче томда исә татар язучылары һәм галимнәре С. Күкләшев, М. Иванов, һ. Салихов, Ш. Зәки, Г. Чокрый, Риза Фәхретдинев, З. Һади, Ф. Туйкин иҗатлары башкорт әдәбияты мирасы итеп күрсәтелә. Башкорт милли әдәбияты кысаларын Башкортстан филологлары революциягә кадәр чыгып килгән «Карчыга» һәм «Чүкеч» дигән татар журналлары исәбенә дә киңәйтергә маташалар.

Язучының кайсы милләттән булуын ачыклау өчен аның кайда тууын дәлил итеп алу гына аз булуын исәпкә алып, башкортның әдәбият белгечләре теге яки бу язучыда башкорт каны эзли башладылар. Алар фикеренчә, бу хәл теләсә кайсы язучыны башкорт әдәбияты вәкиле итеп санарга хокук бирә. Ләкин язучының теге яки бу милли мәдәният вәкиле булуын этник чыгышына карап кына билгеләргә ярамый. Гоголь — украинлы. Аның әтисе украин телендә шигырьләр язган. Иҗатының күпчелек өлеше дә украинлылар тормышын чагылдыра. Ләкин ул чын рус язучысы. Безнең көннәрдә күп кенә татарлар башкорт, рус, үзбәк, казакъ язучылары булып китте. Башкортстанның халык шагыйре С. Кудаш хәзер башкорт язучысы санала, ә революциягә кадәр һәм егерменче елларда ул татар язучысы дип исәпләнде. А. Таһиров белән дә шул ук хәл килеп чыкты. Иҗатының эчтәлеге һәм характеры белән ул егерменче еллардагы татар язучысы булса да, утызынчы елларда башкорт прозаигы булып китте. Егерменче елларда Башкортстанның татар язучылары булып саналган Г. Гомәр, Г. Насыйри утызынчы еллардан соң башкорт язучыларына әверелде.

Соңгы елларда Г. Хөсәенев «XI-XVIII гасырларда Урал-Идел буе төбәкләре төрки телле әдәбиятларының бердәмлеге» турындагы теорияне күтәреп чыкты. Анда татар һәм башкорт әдәбиятлары «бер үк төрле үсүләре, әдәби теленең уртаклыгы, этник, географик факторларының бик якын булуы» белән характерлана («Урал ягы һәм Идел буе халыклары әдәбияты тарихы мәсьәләләре». Уфа, 1978, 3—6 битләр). Шушы концепциягә таянып, башкортның әдәбият белгечләре XIII-XVIII йөзләрдәге бөтен татар әдәбиятын башкорт һәм татар халыкларының уртак хәзинәсе итеп санарга тырыша. Татар шагыйрьләре Мәүлә Колый (XVII г.), Утыз-Имәнине (XVIII г.), Татарстанның көнчыгыш районнарында яшәүләрен истә тотып, башкорт халкы шагыйре дип белдерәләр. Халык юлбашчысы Батыршаны (XVIII г.) 1755 елгы башкорт күтәрелеше җитәкчесе итеп кенә таныталар. Мәгълүм булганча, аның иҗтимагый әдәби эшчәнлеге турыдан-туры татар җәмгыяте тормышына да бәйләнгән. Ул җитәкчелек иткән баш күтәрүдә башкорт белән бергә татарлар катнаша. Батырша (Габдулла Галиев) мишәр-татар гаиләсендә туып үсә, татар мәдрәсәсендә укый. Аның «Падишага хат» һәм «Мөрәҗәгать»ләре татар телендә язылган. Башкорт тү еллеген ул үзе әйтә. Башкортлар янына барып очрашулар уздыруын ул һәрвакыт күршеләре белән аралашу рәвешендә сурәтли.

Әгәр урта гасырлар атар әдәбиятының аерым вәкилләре «Идел-Урал төбәге төрки телле әдәбияты бердәм системасы» теориясе нигезендә башкортка әверелдерелсә, соңгырак зам н (XIX йөз-XX йөз башы) язучылары туу урыны яки паспортка теркәлү принцибы буенча үткәрелә. Мисалга, «Агизел» (1983, № 3) журналында басылган бер мәкаләдә Р. Фәхретдиневнең «башкорт» булуын раслаган яңа документлар табылды, диелә. Чынлыкта исә мәшһүр галим Татарстанның Әлмәт районы Кичүчат диган татар авылында дөньяга килгән. Заманында Р. Фәхретдиневнең үз «Асар»ында (II китап, 83 бит) басылган шәҗәрәдән мәгълүм булганча, аның бабалары Казан губернасы Зөя өязе Шырдан авылыннан, ягъни, атаклы татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри туган авылдан. Аның паспортындагы «башкорт»лыгы исә иҗтимагый эшчәнлегенә бәйләнгән социаль-сәяси исәптән булуы ихтимал. Ләкин моңа карап кына ул татар галиме һәм язучысы булудан туктамый: әсәрләрен татарча яза, татар журналы «Шура»ны редакцияли һәм, читтән тагылган «татар» этнонимын танымаса да, татар халкы исеменнән эш йөртә.

1983 елда басылып чыккан XX гасыр башы башкорт поэзиясе антологиясендә («Башкорт әдәбияте». XX йөз башы. Поэзия. Уфа, 1983) М. Гафури, С. Кудаш, Г. Ходаяров, Я. Юмаев, Ф. Туйкин, Б. Мирзанов кебек татар шагыйрьләре һәм татар мәдәнияте эшлеклеләре башкорт дип күрсәтелгән. Революциягә кадәр «Карчыга», «Чүкеч» журналларында һәм «Урал» газетасында басылып чыккан билгесез авторларның революцион рухтагы шигырьләре дә шулай ук башкорт революцион шигърияте үрнәкләре итеп тәкъдим ителә. Ф. Туйкинның биографик белешмәсендә аны беренче башкорт драматургы дип атаудан да тайчанмыйлар.

Хәтта күренекле татар драматургы Мирхәйдәр Фәйзине дә башкорт совет әдәбияты классигына әверелдерергә омтылышлар булды. Башкорт язучысы Н. Иделбай «Агизел» (1981, № 11) журналында басылган мәкаләсендә бу фаразны дәлилләү өчен үтә беркатлы фактлар китерә. Имеш, драматургның анасы Зәйнәп ханым башкорт кызы була, ул озак еллар Башкортстанда яши һәм, ниһаять, М. Фәйзи әсәрләренең теле «Урал башкортлары теленә бик якын тора». Менә шулардан чыгып М. Фәйзи татар халкының классик драматургы гына түгел, башкортныкы да булган, диган нәтиҗә ясала (123 бит).

Чынлыкта М. Фәйзи Чистай татары улы (аның агасының малае — күренекле татар композиторы Җ. Фәйзи) һәм әсәрләрен дә саф татар шигъри телендә язган. Дөрес, аның әсәрләре, бигрәк тә пьесалары Татарстанда гына түгел, Башкортстанда да киң таралды. Ләкин М. Фәйзи үзен татар язучысы дип саный (кара: Фәйзи М. Сайланма әсәрләр. Ике томда, 2 том. Казан, 1957, 442—443 битләр).

Башкортның әдәбият белгечләре татар телен Октябрьгә кадәрге башкорт әдәбиятында

гамәли тел итеп танысалар да, алар тарихилык принцибын сакламыйлар: аларны хәзерге башкорт теленә кайбер гарәп сүзләрен һәм иске стиль элементларын саклап тәрҗемә итәләр (мәсәлән, М. Акмулла шигырьләре шул рәвешле «яңартылган»), язучыларның исемнәрен башкорт әйтелешенә күчерәләр (мәсәлән, Чокрыйны — Сокрый, Ялчыголны — Ялсыгол), аларның әсәрләрен рус теленә тәрҗемә иткәндә «башкортчадан тәрҗемә» дип күрсәтәләр (мәсәлән, оригиналлары татар телендә язылган М. Акмулланы, М. Гафурины, Ш. Бабичны).

Матбугат басмаларында татар фольклоры әсәрләрен башкорт халык авыз иҗаты дип тәкъдим итү күренешләре дә очрый. Мәгълүм булганча, СССР Фәннәр академиясенең Урал бүлеге Башкортстан фәнни үзәге Тарих, тел һәм әдәбият институты Башкорт халык иҗатының күп томлы җыентыгын әзерләде һәм бастырып чыгарды. Җыентыкның томнары белән җентекләп танышкан кеше анда чыганаклар һәм гамәли материаллар белән бер яклы һәм алдан ук хәл ителгәнчә саксыз эш итүне күрми кала алмагандыр. Мәсәлән, революциягә кадәрге чыганакларга (XVIII-XIX гасырлар) мөрәҗәгать иткәндә, гәрчә алар татар телендә язылсалар да, аларга бик еш алда искә алып кителгән «төрки» тәгъбире өстәлә.

Башкортларда да, татарларда да сюжетлары һәм әйтергә теләгән фикерләре буенча авазлаш лирик әсәрләр шактый күп. Без моны ике тугандаш күрше халыкның милли-мәдәни элемтәләре нәтиҗәсе дип исәплибез. Ләкин татар фольклорчыларыннан аермалы буларак, аларның башкорт һөнәрдәшләре, гадәттә, бу турыда сөйләргә теләмиләр. Мәсәлән, башкорт фольклоры җыелмасында төрки халыкларның күбесенә, шул исәптән татарларга да мәгълүм булган тарихи һәм язма эпослар «Заятүләк һәм Сусылу» (1 китап), «Алпамша», «Кузы Күрпәч белән Баянсылу» (2 китап), «Чура батыр», «Буз егет», «Йосыф белән Зөләйха», «Таһир белән Зөһрә», «Сәйфелмөлек» (3 китап) басылып чыга. Кызганыч ки, җыелманы төзүчеләр бик сирәк очракларда гына татар фольклорында теге яки бу дастанның булуы хакында искә алалар.

Башкорт халык иҗаты җыелмасының җыр фольклоры кергән беренче китабына татарларның киң таралган «Сәгать чылбыры», «Бөдрә тал», «Дим-Дим» һәм башка шуның кебек җырлары башкорт көйләре буларак кертелгән. «Ямьле Агыйдел буйлары», «Ямьле Дим буе», «Мәдинәкәй», «Порт Артур» һәм ике халыкның да уртак мирасы булып саналган бүтән җырлар шулай ук фәкать башкорт җырлары итеп кенә тәкъдим ителә.

Башкорт фольклоры җыелмасының «Риваятьләр. Легендалар» томында (Уфа, 1980) татар халкының рухи мирасы булса да, берничә риваять башкорт халкыныкы итеп карала. Мәсәлән, томның 139 битендә «Килкабыз» риваяте басылган. Бу топонимик риваять 1974 елда Башкортстанның Бакалы районы Килкабыз дигән татар авылында язып алынган («Башкортстан АССР. Административ-территориаль бүленеше» белешмәсендә Килкабыз татар авылы буларак билгеләнгән. Бишенче басма. Уфа, 1969, 61 бит. № 86).

Мәдәни мирас мәсьәләләрен хәл итүдә үз максатларына ирешү өчен башкорт галимнәре башка төрле гамәлләрдән дә тайчанып тормыйлар. Аерым алганда, алар башкорт этносының таралу даирәсен ясалма рәвештә киңәйтергә омтылалар. Барлык тарихи-лингвистик дәрәслеккә бармак аша карап һәм гамәлдәге тел фактларын санга сукмыйча, алар «фәнни-теоретик нигез» үткәрергә омтылып, Башкортстан территориясендә һәм аңа чиктәш өлкәләрдә яшәүче татарларның сөйләмен башкорт теле системасына кушалар. Хәзерге диалектологларның, шул исәптән СССР Фәннәр академиясе Башкортстан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институтының өлкән фәнни хезмәткәре С. Миржанованың мәкаләсе моңа ачык мисал булып хезмәт итә ала. «Совет Башкортстаны» газетасында (1983 ел, 26 февраль) ул «Башкорт әзәби теле һәм төньяк-көнбатыш һөйләше» дигән язма бастырып чыгарды. Ул анда Башкортстанның көнбатыш, төньяк-көнбатыш районнарында яшәүче татарларның гына түгел, Татарстанның Актаныш, Минзәлә, Әгерҗе районнарында һәм Пермь өлкәсендә яшәүче татарларның телен дә башкорт теленең бер диалекты дип белдерә. Башкортстанның санап үтелгән районнарында башкорт әдәби телен өйрәнү һәм беренче сыйныфтан башлап мәктәпләрдә татар балаларын башкорт теленә өйрәтү автор тарафыннан хуплана һәм дөрес дип табыла.

Ә соңгы вакытларга кадәр татар телендә сөйләшүче авылларда мәктәптә татар теле укытылуы һәркемгә мәгълүм. Бу мәсьәлә (укыту теле һәм эш кәгазьләрен алып бару) 1933 елда Башкортстанның ВКП(Б) өлкә комитеты тарафыннан төзелгән махсус комиссиясенең эшчәнлеге нәтиҗәләренә нигезләнеп һәм халыкның теләген искә алып гадел хәл ителгән иде (карагыз: 1933-1935 еллардагы лингвистик экспедицияләр материаллары фонды, СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институтында саклана торган 107 нче туплама; Башкортстан Үзәк Башкарма Комитеты Президиумының 1930 елның 16 сентябрендә кабул ителгән «БАССР район башкарма комитетларында эш кәгазьләрен шушы милләт телендә алып баруны кертү турында» карары. СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институты архивы. 3 фонд, 9 нчы тасвирлама, 5 нче эш. Бу карарда татар теле мәктәпләрдә укыту һәм учреж-

дениеләрдә эш кәгазьләрен алып бару теле буларак кертелгән районнар санап кителә).

Үзләренең нигезләнмәгән дәлилләрен раслау өчен башкорт филологлары татар һәм башкорт сөйләмнәренең чикләрен ясалма рәвештә урнаштыру белән шөгыльләнәләр. Бу чынбарлыкка бөтенләй туры килми. Революциягә кадәр (А. Г. Бессонов, Н. Ф. Катанов, В. В. Котаринский, Мартемьян Иванов, В. М. Филоненко) һәм революциядән соң башкорт телен өйрәнүчеләрнең һәм кайбер башкорт тел белгечләренең Башкортстанның төньяк-көнбатышында һәм көнбатышында яшәүче халыкның сөйләмен чынлыкта бу тел системасында карамадылар, хисә аларны көчеш тибына керттеләр (мәсәлән, башкорт диалектларын өйрәнүче профессор Җ. Киекбаев). Бу мәсьәләдә башкорт диалектларын күптәннән өйрәнеп килүче филология фәннәре докторы Н. Ишбулатовның фикерләре дә чынбарлыкка туры килә. Ә башкорт теленең күренекле белгече А. Юлдашев Башкортстанның көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш районнарында татар сөйләменең урнашуы тарихи үсеш нәтиҗәсе булды дип яза. Казан ханлыгы яулап алынганнан соң Башкортстанның бу районнарына татарларның күпләп күчеп килүе нәтиҗәсендә анда татар һәм башкорт халкының нисбәте тамырыннан үзгәрде. XVIII-XIX гасырларда бу районнарга татарлар электәгечә күпләп килмәсәләр дә, татар теле даирәсенең йогынтысы көчәя барган. Монда кайбер өязләрдә, аерым алганда Бәләбәйдә һәм Бөредә (анда халыкның 60-65 проценты татарлар) татарларның сан ягыннан күбрәк булуы гына түгел, ә күчеп килгән татарларның Уфа, Бәләбәй, Бөре, Эстәрлетамак шәһәрләрендә, игенчелектә, сәүдә үзәкләрендә купчелекне тәшкил итүе, татар телендә укытыла торган мәктәпләр ачылуы, башкорт халкы арасында татар публицистикасының, матур әдәбиятының һәм әдәби татар теленең киң таралуы бик тә мөһим роль уйный. Ә башкортның язма теле тарихи үсеш дәверендә, ягъни XX йөзнең 30 нчы елларына кадәр, татар әдәби теленә таяна (Юлдашев А. А. Башкорт теленең төньяк-көнбатыш диалекты үзенең әдәби телгә мөнәсәбәтендә. Җыентык. Төрки телләрнең диалектология мәсьәләләре. Фрунзе, 1968; Башкорт милли теле формалашу проблемаларына карата. Җыентык. Башкорт филологиясе мәсьәләләре. М., 1959; Башкорт теленең бердәм формалары барлыкка килү мәсьәләләре. Җыентык. Милли телләрнең формалашуы һәм үсеше мәсьәләләре. М., 1960, 275—276 битләр; Башкорт теле. СССР Халыклары телләре, 2 том, М., 1960, 173 бит; Хәзерге башкорт теле грамматикасы. М., 1981, 13 бит).

Башкортстандагы көньяк-көнбатыш, көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш районнардагы халыкның сөйләме татарча булуы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты һәм КДУ галимнәре үткәргән диалектологик тикшеренүләр белән дә раслана. Башкортстанның төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш районнарындагы сөйләмнәрне өйрәнү максаты белән беренче экспедицияләр илленче еллар урталарында оештырылды. Тупланган материаллар Башкортстанның алда санап үтелгән районнарында гамәлдә татар сөйләмнәре булуын күрсәтте (Л. Т. Мәхмүтова. Башкортстан АССРның төньяк-көнбатыш районнарындагы татар сөйләмнәре турында. «Татар диалектологиясе буенча материаллар». 2 нче чыгарылыш, Казан, 1962, 57—85 битләр; А. Ш. Әфләтунов. БАССРның көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш өлешендәге татарларның тел үзенчәлекләре. Кандидатлык диссертациясе буенча автореферат, Казан, 1961; Х. Алмаз. Башкортстанның Дүртөйле һәм Илеш районнары татарларының сөйләшенә карата. «Татар теле һәм диалектологиясе мәсьәләләре». Казан, 1959, 145—165 битләр).

Илленче еллардагы экспедицияләр нәтиҗәләре 1968-1979 елларда уздырылган лингвистик географияне өйрәнү һәм Идел буе, Урал ягы татар халык сөйләмнәре атласы материалларында да расланды.

Күрсәтеп үтелгән шушы чор эчендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты Башкортстанның төньяк-көнбатыш, көнбатыш һәм төньяк-көнчыгыш районнарына 29 экспедиция үткәрде. Барлыгы 321 торак пункт өйрәнелде. Нәтиҗәдә аларның 254 ендә татар теленең урта диалекты сөйләмнәре, 56 сында мишәр сөйләме һәм 11 ендә Казан татарлары һәм мишәр сөйләмнәре таралуы мәгълүм булды. Бу хакта татар диалектологлары Л. Т. Мәхмүтова, Д. Б. Рамазанова, Ф. С. Баязитова, Т. Х. Хәйретдинова күп санлы хезмәтләрендә язып та чыктылар. («Татар диалектологиясе буенча материаллар», 2 нче чыгарылыш. Казан, 1962; 3 нче чыгарылыш. Казан, 1974; 4 нче чыгарылыш. Казан, 1978; «Татар теленең тарихи диалектологиясе буенча тикшеренүләр», Казан, 1979; «Татар теле белеме буенча СССРның 50 еллыгына багышланган конференция. Докладларның тезислары». Казан, 1972; «Татар теленең диалектологиясе һәм тарихы буенча тикшеренүләр». Казан, 1982 һәм башкалар).

Сан ягыннан татарлар күбрәк яшәгән төбәкләр ничек итеп Башкортстан мәйданында калды соң әле? Эш шунда ки, татарларның дәүләтчелеген тәзү катлаулы һәм кыен эш булды. Патша Россиясенең колониаль сәясәте, даими әзәрлекләүләре нәтиҗәсендә татарлар Идел буйларына һәм Урал ягындагы төрле кавемнәр яшәгән җирләргә ничек туры килсә, шулай күчеп утыралар. Бу хәл төзелә торган республиканың чикләрен билгеләүдә шактый зур кыенлыклар китереп чыгара.

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын төзү буенча гамәли чаралар 1920 елда, Идел буеннан һәм Уралдан акларны куып чыгарганнан соң күрелә башлады. Моңа кадәр исә, 1919 елның 20 мартында ук Совет хөкүмәте Совет власте ягына чыккан Башкортстан хөкүмәте белән Башкортстанны совет автономиясе итү хакында Килешү төзеде. Моның белән Кече Башкортстан чикләрендә БАССР төзүгә нигез салынды. Аңа автономияле республиканың хәзерге территориясендәге көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш районнар керде.

В. И. Ленинның күрсәтмәсе буенча, 1920 елның 4 мартында ТАССР чикләрен билгеләү белән шөгыльләнүче Хөкүмәт комиссиясе эшли башлады. Бу комиссия каравына, хәзерге мәйданнан тыш, Татарстан АССР составына шулай ук Уфа губернасының Бәләбәй һәм Бөре өязләрен дә кушу турында тәкъдим кертелде.

1920 елның 27 маенда Татарстан АССРны төзү турында РСФСР Халык Комиссарлары Совет декретына кул куелды. Анда Республиканың мәйданы да билгеләнгән иде. Ләкин Уфа губернасының Бәләбәй һәм Бөре өязләре турындагы мәсьәләне, ул төбәкләрдә татарлар күпчелек тәшкил итсә дә, бу өязләрдәге хезмәт ияләренең теләген ачыклаганчы ачык калдырырга карар ителде. Ул замандагы мәгълүматлар буенча, Бәләбәй өязендә яшәүче 671 мең кешенең 62 процентын татарлар һәм 4,5 процентын башкортлар тәшкил иткән. Ә Бөре өязендә 626 мең кешенең 65 проценты татар һәм фәкать 4,4 проценты гына башкорт була (С. Атнагулов, Башкортстан. М.-Л., 1926, 83 бит).

Ревком, соңрак ТАССР хөкүмәте, шулай ук республиканың чикләрен төгәл ачыклау буенча административ комиссия бу өязләрдә җәмәгатьчелек фикерен белү өчен омтылыш ясап карыйлар. 1921 елның 11 июлендә административ комиссиянең рәисе Әхмәтшин бу өязләрне Татреспубликага кушу хакындагы мәсьәлә буенча ТАССРның Үзәк Башкарма комитетында чыгыш ясаганда, «Бу өязләрнең җаваплы эшлекләреннән бөтен халыкның да ТАССРга керергә теләве турында күп санлы гаризалар керә, ләкин алардан күренгәнчә, бу мәсьәләне Уфа губернасы башкарма комитеты һәм башка администрация тоткарлый», дип сөйли (ТАССРның Үзәк дәүләт архивы, 128 фонд, 27 эш, 136 бит).

Бөре һәм Бәләбәй өязләрендә бернинди плебисцит уздырылмаса да, Кече Башкортстанның партия һәм совет органнары үтенече белән 1922 елның 14 июнендә БҮБКның «Автономияле Башкорт Совет Социалистик Республикасының чикләрен киңәйтү турындагы» декреты белән Уфа, Бөре, Бәләбәй өязләре Башкортстанга кушыла (Башкортстан АССРның төзелүе. Уфа, 1959, 733 бит).

Оешып килгән вакытларда Татарстан АССР белән Башкортстанның чикләрен билгеләү тарихы шундый. Бүген Башкортстандагы татарларның өчтән икесе авыл җирләрендә яши, шуның белән бергә «татар авылларының күпчелеге башлыча республиканың чуашлар, марилар, мордвалар, удмуртлар һәм башкалар яшәгән көнбатышында, көньяк-көнбатышында һәм өлешчә төньягында тупланган (Гарипов Т. М. Башкортстанда телләрнең үзара йогынтысы барышы. «Башкортстанда тел бәйләнешләре». Уфа, 1972, 26 бит). Болар нәкъ элеккеге Бәләбәй һәм Бөре өязләре мәйданы. Бу факт шулай ук башкорт галиме Р. З. Шәкүров тарафыннан да раслана. Ул: «Хәзерге Башкортстанның этник картасында... татарлар Башкортстанның көнбатышында һәм өлешчә төньяк-көнбатышында аеруча тыгыз утырганнар», дип яза (Шәкүров Р. З. Дим елгасы бассейны этнонимнары. Уфа, 1975, 183 бит). Нәкъ менә ул чактагы Бәләбәй һәм Бөре өязләрендә яши торган татар халкын бүген башкорт галимнәре башкорт, ә телләрен башкорт диалектының үзенчәлекле бер төре дип игълан итәләр.

1922 елда күпчелеген татар халкы тәшкил иткән җирләрне, анда яшәүчеләрнең теләкләрен исәпкә алмыйча, Башкортстан АССР составына кушу аркасында шундый дәгъваларга урын калдырылды. Соңыннан бу мәсьәләнең торышына Республикабызның хакимият даирәләренең Башкортстан АССРда яшәүче татарларның язмышына битарафлык күрсәтүләре дә тискәре йогынты ясады. 1921 елда ТАССРның Эчке эшләр халык комиссары Әхмәтшин Бәләбәй һәм Бөре өязләрен Татарстан республикасына кушу турында партиянең өлкә комитетына мөрәҗәгать итте. 1921 елның 21 июлендә өлкә комитеты бюросы бу тәкъдимне карый һәм искә алып үтү белән чикләнә. Мондый хәл алга таба да дәвам итә. Башкортстанда исә акрынлап-акрынлап татар халкының мәдәни мирасына кул сузу башлана һәм киң җәелә. Республиканың рәсми җитәкчеләре моңа битараф карыйлар. Татарстан галимнәре дә дәшми. Фәкать Ә. Харисовның китабы чыккач кына «Казан утлары»нда А. Фәтхинең башкорт галимнәренең «тикшеренүләренә» хак бәя биргән «Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби бәйләнешләр» (1968, № 2) дигән мәкаләсе басылды. Ләкин бу язманы республиканың рәсми органнары дошманлык белән каршы алалар, журнал редакциясенә һәм мәкалә авторына каты шелтә сүзләр әйтелә. Ә татар мәдәнияте мирасын башкортлаштыру гамәле дәвам итә.

Шушы шартларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре арасында сиксәненче елларда шушы гамәлгә каршылык күрсәтү фикере туа. Күп санлы материаллар җыела, әдәби чыганаклар һәм матбугатта чыккан рәсми доку-

ментлар берләштерелә. Шушы нигездә тиешле белешмәләр әзерләнә. Мәсьәлә Мәскәү, башкорт һәм безнең галимнәр катнашында СССР фәннәр академиясенең М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институтында тикшерелүгә куела. Бу сөйләшүгә СССР Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы Ломидзе җитәкчелек итә. Безнең яктан филология фәннәре докторы Н. Г. Юзиев, профессор М. А. Госманов, филология фәннәре докторы Гали Халит, филология фәннәре кандидаты Л. Т. Мәхмүтова, Ф. С. Фасеев һәм шушы юлларның авторы катнашты. Сөйләшү барышында без килеп туган хәлдән чыгу юлларын эзләү өчен мондый очрашуларны чиратлап Казанда һәм Уфада оештырырга тәкъдим иттек. Бер үк вакытта, менә шушы язма әзерләнде һәм ул 1983 елда КПСС өлкә комитетына тапшырылды. Ләкин аңа бәйле рәвештә бер генә эш тә эшләнмәде. Башкорт галимнәре белән дә очрашулар оештырып булмады. Ә алар исә милли мирасны үзләре теләгәнчә тарту-сузуларын дәвам иттерәләр. Күптән түгел башкорт авторлары Ә. Ишбирдин, И. Галәутдинов һәм Р. Халикованың «Башкорт әдәби теле тарихыннан очерклар» исемендә «Наука» нәшриятында чыккан китабы моңа ачык мисал булып хезмәт итә ала. Бу хезмәттә дә профессорлар Ә. Харисов һәм Г. Хөсәенов башлап җибәргән һәм үстергән тенденцияләр дәвам иттерелә.

Менә шушы хәлләрне истә тотып, без 1983 елда КПСС өлкә комитетына бирелгән бу язманы хәзер халык игътибарына тәкъдим итәргә кирәк дигән нәтиҗәгә килдек. Ник дигәндә, бүген авыз йомып дәшми калу тарихи үткәнебезгә һәм бай мәдәни мирасыбызга дөрес бәя бирүгә, рухи куәтебезне баету мәнфәгатьләрендә файдалануга зур комачаулык китереп чыгара. Ә иң куркынычы, бу гамәл татар-башкорт халыкларының гасырлардан килгән дуслыгына, ике тугандаш халыкның үзара аңлашуына һәм мәдәниятләрен баетышуына зур зыян китерә. Бу хәл шушы ике якын туган халыкның берберсенә карата дошманлык саклавы белән кызыксынган көчләр тегерменәнә су коя. Безгә, татарларга, башкорт халкының борынгы мәдәнияте якын һәм аңлашыла. Без аның бай фольклорын, бию үрнәкләрен, гамәли сәнгать нәкышьләрен, көнкүреш традицияләрен беләбез һәм хөрмәт итәбез. Татарларның һәркайсы башкорт музыкасын һәм халык көйләрен үзенекедәй яратып кабул итә. Казанга башкорт театрлары килсә, заллар шыгрым була. Татар мәдәниятенең, татар әдәби мирасының башкорт халкы өчен дә якын һәм кадерле булып әверелүенә, аның рухи тормышына тирән үтеп керүенә көенмибез, сөенәбез генә. Без фәкать мирасыбызга беркемнең дә кул салмавын, мәкерле ният белән аның күп гасырлар дәвамында халкыбыз вәкилләре тарафыннан тудырылуын шик астына куймауларын гына телибез.

Бу мәсьәләдә җәнҗал чыгару безне дә, башкорт халкын да яхшыга илтмәячәк. Шуңа күрә килеп туган хәлдән чыгу юлларын эзләргә һәм үзара аңлашуга ирешергә кирәк. Шушы күзлектән караганда, татар һәм башкорт галимнәренең, язучыларының түгәрәк өстәл янына утырып тыныч шартларда үзләрен борчыган мәсьәләләрне уртага салып сөйләшүләре ифрат файдалы булыр иде. Һәм моны кичекмәстән эшләргә кирәк. Ике бертуган халык арасында гасырлардан килгән дуслыкны саклап калу һәм ныгыту мәнфәгатьләре шуны таләп итә.

*Искәрмә: Мәкалә филология фәннәре докторлары профессор Г. Халит һәм Н. Юзиев, тарих фәннәре докторлары С. Алишев һәм З. Гыйльманов, фән кандидатлары Л. Мәхмүтова, И. Надыров һәм М. Сәйдәшева катнашында әзерләнде. Эшлекле киңәшләре һәм биргән материаллары өчен автор аларга рәхмәтен белдерә.*

# ШИГЫРЬЛӘРДӘ ЗАМАН ТӨСМЕРЕ

## ПОЭЗИЯБЕЗДӘ ЯҢА СҮЗЛӘР

Телдәге аерым сүзләрнең пассивлашуы, искерүе белән беррәттән, икенче процесс та яшәп килә: яңа сүзләр — неологизмнар барлыкка килә. Тел — катып калган күренеш түгел, ул һәрдаим үзгәрә, камилләшә, яңа сүзләргә байый бара. Һәм бу табигый да. Җәмгыять, җитештерү, фән, культура үскән саен, яңа төшенчәләр барлыкка килә һәм аларга исем бирергә кирәк була.

Фән-техника прогрессының кызу темплар белән үсүе, моңарчы билгеле булмаган нәрсәләр уйлап табылу — һәрвакыт яңалыкка, үзгәрешкә омтылучы, көннең кадагына сугып баручы шигърият дөньясына да үтеп керде, яңа сүзләрнең күпләп иҗат ителүенә ярдәм итте. Поэзиядәге бу үзгәрешләргә тәнкыйтьче Тәлгать Галиуллин да игътибар итә һәм болай ди: «Яңа проблематика традицион образлар системасын тагын да баета төште, поэзиянең фикерләү рәвешен киңәйтеп җибәрде, лексиконына яңа сүзләр өстәде».

Яңа сүзләр иҗат итү хәзер аеруча арта бара. Илебездә, гомумән, дөньяда бара торган үзгәрешләр әдәбиятта чагылыш тапмыйча кала алмый. Заман сулышын тоеп, чор, көн, ил белән бергә атларга тырышучы шагыйрьләребез, укучының шигърият белән дуслыгын тагын да арттыру, бертөслелектән качу, яңа фикер һәм төшенчәләрне атау өчен яңа сүзләргә мөрәҗәгать итә башладылар. Алар илебездә бара торган үзгәрешләргә, сәяси ыгы-зыгыларга, табигать дөньясына килгән бәла-казага битараф кала алмыйлар. Бу исә үзенчәлекле яңа сүзләр тууга, лексикабызның башка телләр хисабына түгел, үз сүзләребез исәбенә байый баруына зур этәргеч бирә.

Күренекле шагыйрь Р. Фәйзуллин Татарстанны Төтенстан дип атаган икән, моңа һич тә гаҗәпләнергә кирәк түгел. Автор, меңләгән торбаларның атмосферага газ һәм төтен чыгарып, яшәешебез өчен иң кирәкле булган һаваның пычрануын гына түгел, Казанга «шөһрәт» китергән «феномен»ны да күз алдында тота:

*Татарстан — ТӨТЕНСТАН...*
*Дәүләт тимерчелеге!*
*Казан яшьләренең даны —*
*Сугыш-тукмаулар буенча*
*Илдә «беренчелеге».*

Л. Лерон да, «Татарстан — Төтенстан» чагыштыруын эпиграф итеп алып, «Без яшибез, әйе...» шигырен иҗат итә. Ул да республикабызның хәзерге вакыттагы халәтен, аңа янаган экологик куркынычны яңа сүзләр белән укучы күңеленә ирештерүне кулай күрә:

*Татарстан — ТЕТРӘСТАН...*
*Бу да шулай, әйе;*
*Түбән Кама, Чаллы янә*
*тетрәп түбәнәйде!*
*Без яшибез, әйе...*

Яшь шагыйрь Татарстан сүзенә параллель рәвештә Төтәрстан, Татырстан, Тотарстан, Татарустан кебек үзенчәлекле, образлы чагыштыруларга корылган яңа сүзләр дә куллана.

Ирония, сатира һәм юморга корылган эпиграмма, пародияларда яңа сүзләр дә

еш күренгәли. Л. Лерон исә бу жанрда эшләүче бердәнбер диярлек шагыйрь. Г. Афзалга багышлап язылган эпиграммасында ул бюрократ, партократ сүзләре белән янәшә кулланырлык, милли, нәкъ менә «үзебезнең» түрәләрне атау өчен кулай «түрәкрат» сүзен иҗат итә.

*«Кәгазь кортларын» да тетә*
*Афзал,*
*Түрәкратларны да тетә*
*Афзал.*
*Читтә калмый хәтта куштаннар да...*
*Әллә аңа өстән кушканнармы?!*

Катлаулы, авыр елларны үз җилкәсендә татыган Нури ага Арсланов, канга сеңгән гадәт буенча, әле хәзер дә — түрәләрне тозлап-борычлап орышырга җыенмый, үзенчә, яңача, җиңел генә аңлатырга тырыша иде:

*Түрәләргә дә сүзем юк, —*
*түрәләнеп юлдан язмасалар.*

Күренекле шагыйрь, юмор-сатира остасы Г. Афзал да торгынлык елларында тамыр җәйгән эгоизм, «мин генә»лекне — «мин-минизм», — дип атаган һәм шул елларны шигырендә түбәндәгечә күрсәтергә тырышкан:

*Мин-минизм алга киткән заман,*
*Романтизм артка чиккән заман.*

Татарстанның мөстәкыйльлеген таләп иткән язмаларга матбугатта зур урын бирелде. Алар арасында шигырьләр дә күп иде. Ә. Мәхмүднең «Союздаш» исемле шигырен укыгач, безгә статусны үзгәртүне Тарих, Кояш, Җир, Дөнья үзе дә куша кебек:

*Кояшлы күк безгә юлдаш,*
*Галәмдәш без, кояшташ.*
*Хокукыбыз безнең тигез —*
*Без күптәннән союздаш.*

Үз илебез — Татар иле туып килә торган бу көннәрдә шигырьнең актуальлеге һич тә кимеми һәм андагы кояшташ, җырдаш, йолдыздаш, дөньядаш дигән яңа сүзләр дә, лексиконыбызда лаеклы урыннарын табарлар дип ышанасы килә.

Шунысы сөенечле, шагыйрьләребез үз «казаннарында» гына кайнарга теләмиләр. Алар дөнья мәйданын да күзәтәләр, гомумкешелек проблемаларына кагылышлы мәсьәләләргә дә битараф түгелләр. Р. Харис «Мин — галәм» дигән шигырендә Җир, Дөнья, Кеше язмышы белән шаяручыларга нәфрәтен белдерә һәм микро сүзен кушу юлы белән түбәндәге тәкъдимнәрне укучы хөкеменә тапшыра: микроҗир, микрокешеләр, микродөнья, микрохалыклар, микробөекбозлавыклар, микроатлантида, микропомпей.

*Һәрбер күзәнәгем — микродөнья,*
*микрокешеләр анда көн итә.*

Р. Юныс «Учтагы песнәк» поэмасында җир шарының әле бер, әле икенче ягында кабынып торган сугыш-шартлауларның арта баруына ачына һәм үз фикерен яңа сүз аша укучы күңеленә сеңдерә:

*Җаннан җанга күчә, куәт ала*
*Минисугыш, минишартлаулар.*

Сугыш уты кабызырга җыенучы «замананың неовәхшиләре»нә яшь шагыйрь Г. Моратов та үз сүзен әйтеп калырга тели:

*Замананың неовәхшиләре*
*Үрелгәндә кабат кынына*
*Ракетадай посып ята ул көн*
*Җирнең күкрәк куышлыгында.*

1988 елны Әрмәнстанда булган көчле җир тетрәү бирәүне дә битараф калдырма-

ды. Һәркем булдыра алганча, матди яктанмы, рухи яктанмы, үз өлешен кертергә тырышты. Шагыйрьләр дә әрмән халкына килгән фаҗигане үзләренеке итеп кабул иттеләр. М. Шабаев андагы кайгы-мәхшәрне, күз яшьләрен, ятимнәрне, меңләгән мәетләрне чагылдыру өчен телебездә генә булган сүзләрне җиткерә алмый, Ә р н ү с т а н, к а б е р с т а н кебек яңа сүзләр дә кулланырга мәҗбүр:

*Әрмәнстан...*
*Ә р н ү с т а н,*
*Булды тоташ к а б е р с т а н.*

Барыбыз өчен дә таныш булган һәм көн дә кулланыла торган Татарстан төшенчәсе ярдәмендә яңа сүз иҗат итү поэзия өчен хас күренеш. Һәр шагыйрьнең үз «стан»ы, үз иле бар. Алда әйтелгәннәргә тагын түбәндәгеләрне дә өстәргә була: Бәхетстан, Былбылстан, Гөлстан, Нурстан, Җирстан, Илстан, Хыялстан (Р. Гатауллин), Каенстан, Йолдызстан (Р. Әхмәтҗанов), Тукайстан, Моңстан (Зөлфәт), Мишәрстан (Ә. Рәшитов), Мәрмәрстан (Ә. Мәхмүдов), Болгарстан (Р. Миңнуллин), Биекстан (Р. Фәйзуллин), Себерстан (Л. Лерон) һ. б.

Хәзерге поэзиядә күренекле шәхесләрнең фамилияләренә төрле кушымчалар өстәү юлы белән дә яңа сүзләр барлыкка килә. Мәсәлән, Ш. Галиев — Т у к а й д а ш, Т у ф а н д а ш, И. Юзеев — Т у к а й л ы к, Х. Туфан — Т а к т а ш л ы к, Р. Гатауллин — Б а б и ч л ы к, Р. Фәйзуллин — С ә й д ә ш л е к сүзләрен иҗат итә. Әлеге шагыйрьләр бу яңа сүзләр аша шәхес иҗатының, эшенең бөеклеген киләчәк буыннарга җиткерү, күрсәтү кебек олуг вазифаны да үтиләр. Г. Тукай, Х. Туфан кебек корифейлардан үрнәк алган язучылар булганда, татар әдәбиятының барыр юлы киңәячәгенә нык ышана Ш. Галиев:

*Тугандашлар —*
*Т у к а й д а ш л а р, Т у ф а н д а ш л а р*
*Шигъри сафка тезелгәч,*
*Дуслык юлы да нык булыр,*
*Җыр юлы да өзелмәс!*

Әдәбиятның төп предметы — Кеше. Ә поэзиядә Кешене, аның хисләрен, язмышын, күңел дөньясын чагылдыру бигрәк тә мөһим. Әнә шул таләпләргә җавап итеп язылган шигырьләрдә үзенчәлекле яңа сүзләр дә еш очрый. Мәсәлән: ш а т л ы к т а ш, м о ң д а ш, к а й г ы д а ш (Х. Әюпов), х а л ә т т ә ш (Л. Зөлкарнәев), х ы я л д а ш, х и с т ә ш (Р. Гатауллин), у й д а ш (Н. Арсланов), я з м ы ш т а ш (Р. Харис), к ү ң е лд ә ш (Ш. Галиев), к е ш е д ә ш (Зөлфәт), б а в ы р д а ш (М. Хөсәен), с ә л а м д ә ш (Г. Садә) һ. б.

Милли мәсьәләләрне хәл итү — барлык халыкларның да уртак теләге, максаты. Р. Харис төрле милләт халыкларының кәрдәштәш, хезмәттәш, табындаш кына түгел, я з м ы ш т а ш булып яшәячәкләренә дә ышана:

*Сез руслардан руслар туар,*
*украиннар, белоруслар,*
*болгарлардан татар туар,*
*бер тамырдан чуваш туар —*
*кәрдәштәш тә, хезмәттәш тә,*
*табындаш та, я з м ы ш т а ш та*
*булып яшисе халыклар.*

Күзәтеп үткән яңа сүзләр — шагыйрьләрнең шәхси, индивидуаль «җимешләре». Поэзиядә алар артканнан-арта бара һәм хәзерге заманның поэтик сөйләме өчен шактый ук типик күренеш санала. Яңа сүзләрне аксакал шагыйрьләребездән алып, Р. Зәйдуллин, Г. Моратов кебек яшь шагыйрьләр дә теләп иҗат итәләр. Бу сүзләр очраклы сүз (окказионализм), ягъни автор неологизмы гына булып калырмы, әллә гомумтел күренешенә әйләнерме, анысын әйтүе кыен. Сүземне Р. Фәйзуллинның поэзиядәге неологизмнар турындагы әйткән сүзләре белән тәмамлыйсы да килә: «Кайчакта, фикерне чагылдыру өчен котелмәгән сүзләр дә кирәк. Бу — укучыда поэтик тойгы уята. Тормыш агышы да шуны таләп итә. Укучыны сискәндерү, җәлеп итүдә дә яңа сүзләрнең роле зур».

**Мансур МОРТАЗИН.**

# БЕЗГӘ НИНДИ ЖУРНАЛИСТИКА КИРӘК?

Милли тормышта үзгәртеп кору гаять зур җанлану тудырды, милли мәдәниятләрнең кузгалышын китереп чыгарды, куәтле милли хәрәкәтләрне дөньяга китерде. Һәр милләт һәм халык үзенең узгандагы тәҗрибәсен барлый, милли ихтыяҗларны һәм мәнфәгатьләрне тормышка ашыра торган нәтиҗәле чаралар эзли. Матбугат, телевидение һәм радио әнә шундый чараларның беренче сафында тора.

Әйе, журналистика төрле милли көчләрнең сәясәтен эшләүдә һәм тормышка үткәрүдә актив роль уйный. Эш тагын шунда: «Һәр халык үзенең рухын үз матбугатында чагылдыра» (К. Маркс). Милли мәдәниятне, милли телне үстерүдә дә журналистикага зур роль туры килә.

Шуңа күрә дә төрле иҗтимагый көчләр, политик партияләр, аларның лидерлары һәм идеологлары һәрвакыт милли матбугат челтәрен булдыру зарурлыгын әйтә килделәр һәм бу сүзләрне практик төстә тормышка ашыру өстендә эшләделәр.

Россиядә милли журналистика челтәрен булдыру хәрәкәте озак һәм кыеннан барды. Ул, нигездә, XVIII—XIX гасырларны һәм XX йөзнең башын колачлый. Ә татарларда исә бүген без күздә тоткан матбугат системасы XX гасыр башында бик тиз арада барлыкка килде. Моның объектив һәм субъектив сәбәпләре бар иде. Мин капиталистик иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең чагыштырмача үскәнлеген (ә матбугат, кагыйдә буларак, феодализмнан капитализмга күчкән чорда туа), сәяси һәм идеологик алшартларның җитешкәнлеген, татарның милләт буларак оешуын, милли үзаңының калыплашуын, материаль-техник базаның, әдәби алшартларның (күп жанрлы халык авыз иҗаты, күп гасырлык әдәбият, публицистика үрнәкләре, К. Насыйри календарьлары, листовка әдәбияты һ. б.) өлгерүен күздә тотам. Ләкин патша самодержавиесенең колониаль политикасы аркасында татар журналистикасының барлыкка килүе ясалма төстә тоткарланып килде. И. Запольский, М. Никольский, К. Насыйри, Г. Ильяси, Ш. Әхмәров, Һ. Максуди, И. Терегуловларның милли басмалар чыгарырга омтылып та, патша властьларының кире кагуларын искә төшерик.

1905-1907 елгы халык революциясе патша самодержавиесе корган ясалма киртәләрне алып ташлады. Объектив һәм субъектив факторларның өлгерүен, милли үзаңның нык үскән булуы татар журналистикасының бик тиз барлыкка килүенә сәбәп булды.

Г. Ибраһимов татар матбугатын төп социаль көчләргә һәм аларның партияләренә яраклы рәвештә дүрт төркемгә аерды: большевистик, реакцион клерикаль, либераль һәм эсерлар матбугаты (Ибраһимов Г. «Урал» һәм уралчылар. Казан, 1927, 11 б.). Октябрьгә кадәрге матбугатны дифференциацияләүдә Г. Ибраһимовның зирәклегенә тиешлесен биргән хәлдә, гасыр башындагы революцион-демократик журналистиканы эсерлар матбугаты кысаларына гына сыйдырып бетерүнең мөмкин түгеллеген дә искәртик. Мөгаен, шуңа күрәдер, профессор Ибраһим Нуруллин, ул чорда чыгып килгән газета-журналларның иҗтимагый-политик юнәлешен билгеләүнең кыен эш икәнен әйтеп, аларны түбәндәгечә төркемнәргә тәкъдим итә: либераль-буржуаз, вак буржуаз-демократик, пролетар-революцион, клерикаль һәм карагруһ матбугат. (Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан, 1982).

Әйтергә кирәк, бу бүленеш тә шартлы гына. Мәсәлән, еш кына клерикаль һәм буржуаз матбугат арасында аерма табу җиңел түгел. Икенче яктан, вак буржуаз-демократик басмалар арасында да җитди аермалар бар. Революциягә кадәр чыгып килгән һәр газета һәм журналны комплекслы төстә җентекләп өйрәнәсе бар һәм шуннан соң гына аның тибын ачыкларга була. Дөрес, бездә прогрессив юнәлешле газета-журналлар яхшы ук өйрәнелгән. Мин Г. Ибраһимов, И. Рәми, М. Гайнуллин, Р. Нәфыйков, Р. Әмирханов, Х. Хәсәнов, Ү. Гыймадиев һ. б. хезмәтләрен күздә тотам. Әмма бездә реакцион яки либераль буржуаз дип йөртелгән матбугат органнары («Тәрҗеман», «Казан мөхбире», «Нур», «Бәянел-хак», «Кояш», «Вакыт», «Йолдыз» һ. б.) «күтәрелмәгән чирәм» килеш диярлек ята. Хәзер аларны нык лап өйрәнү сорала.

XX гасыр башында төрле социаль төркемнәрнең мәнфәгатьләрен яклаучы һәм аларга юлланган матбугат формалашты. Сүз яшьләр һәм хатын-кызлар өчен чыгарылган газета-журналлар хакында бара («Тәрбиятель этфаль», «Әль-ислах», «Сөембикә» һ. б.).

Төрле профессиональ төркемнәрнең информациягә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерүче газета-журналлар зур төркемне тәшкил итте. Профессиональ-тармак структурасы буенча промышленник һәм сәүдәгәрләр, мәгариф хезмәткәрләре һ. б. өчен матбугат та чыгып килде.

Татар матбугатын тормышны чагылдыру ысулы буенча да төркемләргә мөмкин. Бу билге буенча сатирик басмаларның зур отрядын атарга кирәк.

Ниһаять, вакытлы матбугат органнарының шактый зур өлешен милли-территориаль матбугат төркеме берләштерә. Татарлар тупланып яшәгән төбәкләрнең күбесе: Казан, Петербург, Уфа, Оренбург, Мәскәү, Әстерхан, Самара, Сембер, Уральск һ. б. милли матбугат белән тәэмин ителгән иде. Кайбер чыккан газета-журналлар, әйтик, Казан һәм Оренбургныкылар татарлар өчен үзәк басма ролен дә үйнаган.

Шулай итеп, революциягә кадәр 58 газетаны һәм 37 журналны берләштергән татар журналистикасы системасында (Кара: Нуруллина Р. М. Газеты и журналы на татарском языке (1905 — 1985) Казань, 1989), ул чордагы төп газета-журнал типлары булган. Бу матбугатның югары дәрәҗәдә үскән булуын күрсәтә. Чөнки матбугат дифференциациясе — аның өлгергәнлеген күрсәтүче билгеләрнең берсе һәм әһәмиятлесе.

Әлбәттә, заман таләпләренә, политик көчләр нисбәтенә, материаль-техник мөмкинлекләргә ярашлы рәвештә, шулай ук патша властьларының кысуы аркасында бу система үзгәрә торган. Әйтик, 1905 — 1907 еллар тирәсендә туган татар журналистикасын оештыру моделендәге күп элементлар юкка чыккан. Әлеге система Февраль революциясеннән соң гына янә тулылана башлаган.

Октябрь революциясе милли журналистика челтәрен тамырдан үзгәрткән. Клерикаль, буржуаз, вак-буржуаз матбугат әлеге системадан төшелгән. Шул ук вакытта хезмәт халкының барлык катлауларының информацион ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлеш алынган. В. И. Ленин җитәкчелегендә матбугатның дифференциацияләнгән челтәрен булдыру җәһәтеннән киң колачлы эш җәелдерелгән. Партиянең VIII съездында В. И. Ленин, халыкны агарту юнәлешендә гигант эш җәелдереп җибәреп, тарихта беренче мәртәбә хәзерге эре капиталистик типография техникасын буржуазия өчен түгел, ә эшчеләр белән крестьяннар өчен файдаланылуын горурланып сөйләгән. «... Без бу җәһәттән чирек яки ярты гасыр эчендә бер генә социалистик партия дә эшли алмаганны эшләдек» (Ленин В. И. Әсәрләрнең тулы җыелмасы, т. 38, 150 б.). Әмма ул тулаем бу эш белән канәгать булмаган.

Партиянең XII съезды укучыларның һәр катлавына исәпләнгән матбугат типларын булдыру һәм үстерүнең зур программасын билгеләде. РКП(б)ның XIII съезды әлеге программаны аныклады, милли, яшьләр һәм профессиональ матбугат челтәрен үстерү зарурлыгын күрсәтте. Бу программаны үтәү нәтиҗәсендә, илдә милли матбугатның яңа моделе формалашты. Ул түбәндәге типларны берләштерә иде: милли-территориаль (үзәк, республика, өлкә, өяз, соңрак район-шәһәр, колхоз-совхоз басмалары), сыйнфый (эшчеләр, крестьяннар, интеллигентлар матбугаты), профессиональ-тармак (металлурглар, тире-ярычылар, химиклар һ. б. матбугаты), социаль-демографик (хатын-кызлар, яшьләр матбугаты), чынбарлыкны чагылдыру ысулы җәһәтеннән сатирик органнар.

Бу милли матбугат системасы утызынчы елларның беренче чирегенә кадәр диярлек яшәп һәм камилләшеп килде. Ләкин зур үкенечкә, Сталин культы һәм торгынлык елларында әлеге система бик зур зыян күрде. Милләтләрнең бергә кушылуы турындагы фәнгә каршы булган теория, иҗтимагый тормышның барлык өлкәләренең, шул исәптән рухи яшәешнең ялгыш аңланган һәм ясалма төстә кызулатылган интернациональләшүе, масса-күләм информация чараларына җитәкчелекнең чиктән тыш үзәкләшүе, журналистиканың оештыруның кыршауларга куып кертелүе милли матбугатны нык чикләүгә һәм аның массаларга йогынтысын киметүгә китерде. Системадан байтак элементлар алынды. Бигрәк тә милли-территориаль матбугат нык зарар күрде. Татар телендәге үзәк һәм өлкә газета-журналлары бетерелде. Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез туган телдә информация алуга булган ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмады. Матбугатның башка буыннары да хәлсезләндерелде.

Әлбәттә инде, сугыш милли матбугатка зур зыян салды. Дөрес, сугыш елларында матбугатның бер тибы — хәрби пресса үсеш алды. Мәсәлән, татар телендә 16 хәрби газета чыкты. Ләкин хәрби матбугат булдыру, беренчедән, мәҗбүри чара иде. Икенчедән, ул ни генә әйтсәң дә «экстремаль» журналистика иде. Өченчедән, хәрби матбугат тыл матбугатын кыскарту исәбенә яшәде.

Сугыштан соң татарча кайбер матбугат торгызылды, яңалары барлыкка килде: «Азат хатын», «Татарстан коммунисты», «Татарстан яшьләре». Ләкин, шул ук вакытта, милли матбугатның массаларга йогынтысы кими барды. Нинди дә булса яңа матбугат органын тергезү утә кыен эш иде. Моның өчен КПСС Үзәк Комитеты секретареннан рөхсәт алырга кирәк иде. Бу эшнең башында, билгеле булганча, озак еллар буе М. А. Суслов торды. Ул исә теория һәм идеология өлкәсендә милләтләрне кушу идеясен иң актив үткәрүче булды. «Идел» журналы өчен көрәшү тарихын гына искә төшерик. Ул үзе генә дә — бер гыйбрәтле тарих һәм сабак. Яшьләр журналын

чыгару идеясе илленче еллар ахрында без япь-яшь егет чакларда ук, җәмәгатьчелек фикере үзәгендә иде. Ә бу эшне тормышка ашырганчы инде мин картаеп бетә яздым, аны укырдай уллар гына түгел, оныклар үстерә башладым!

Үзгәртеп кору аркасында милли тормышның уянуы илдә өр-яңа ситуация тудырды. Милли журналистика, бер яктан, милли хәрәкәтнең, массаларның милли үзаңын формалаштыруның куәтле катализаторы, халыкларны политизацияләү чарасы булса, икенче яктан, бу процессларның колачын һәм өлгергәнлеген билгеләүче бер критерий да булып тора.

Хәзерге яңарыш шартларында безгә милли журналистиканы оештыруның яңа моделе кирәк һәм аны эшләгәндә 20 нче еллар тәҗрибәсен исәпкә алу, аннары аны этаплап тормышка ашыру зарур. Яңа модельне эшләгәндә төп принцип итеп: милли матбугат йогынтысы белән бөтен татар халкын колачлау алынырга тиеш. Әлеге модель шундый дифференциацияне күздә тотарга тиешле ки — ул милләттәшләребезнең күптөрле ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен формалаштыру һәм үстерүгә юнәлдерелгән булсын. Чөнки һәръяклап һәр гармонияле үскән шәхеснең асылында нәкъ менә ихтыяҗларның күптөрлелеге һәм өлгергәнлеге ята.

Милли матбугат системасының барлык элементларын шушы алшартлар җирлегендә камилләштерергә кирәк.

Беренче. Иң элек милли-территориаль вазифалы басмалар тибы үзгәрешкә мохтаҗ. Зарури булганда, СССР яки союздаш республикалар Югары Советларының Милләтләр Советы байрагы астында үзәк газета һәм журналлар чыгаруга көрәшергә вакыт. «Зарури булганда» дигән тәкъбирне кулланганда, мин теге яки бу милләтнең Союз буенча таралышын күз алдында тотам. Әйтик, украиннарны, татарларны, чувашларны, әрмәннәрне һ. б. Татарларга килгәндә исә, алар өчен СССР Югары Советының Милләтләр Советы каршында үзәк газета һәм журналлар чыгарырга кирәк. 20 нче еллардагы кебек. Дөрес, Татарстанның кайбер матбугат органнары («Социалистик Татарстан», «Сөембикә», «Казан утлары», «Чаян», «Татарстан яшьләре») үзебездә генә түгел, бүтән республика һәм өлкәләрдә дә байтак тарала. Шуны исәпкә алып булса кирәк, Татарстанның матбугат органнары үз битләрендә Союзның төрле өлкә һәм республикаларында яшәүче татарлар тормышын яктыртуга да урын бирә башладылар. «Социалистик Татарстан» газетасында «Милләттәшләребез авазы» дигән махсус сәхифә бирен барыла. Бусы — изге эш. Ләкин ул гына җитми. СССР да һәм аннан читтә яшәүче милләттәшләребезнең яшәешен даими яктыртып баручы газета-журналлар кирәк. Алар милләтебезне рухи яктан туплауга, милли үзаңны үстерүгә, информацион ихтыяҗларны канәгатьләндерүгә сизелерлек өлеш кертә алачаклар.

Икенче. Тоташ яшәүче милли төркемнәр булган төбәкләрдә республика, өлкә, шәһәр, район матбугаты системасын камилләштерү таләп ителә. Татар матбугатының бу төре, өтек килеш булса да, байтак еллар яшәп килә. Мәсәлән, Башкортстанда республика газетасы «Кызыл таң», берничә мөстәкыйль һәм русчадан тәрҗемә ителә торган район газетасы, Чувашстанда, Мари илендә, Ульяновск, Пермь өлкәләрендә берәр район газетасы чыгып килә. Ә бит 20 нче елларда бу төр матбугат органнары бихисап иде.

Үзгәртеп кору заманында татарча өлкә газеталары да терелә башлады. Ульяновскида «Өмет», Самарада «Бердәмлек» исемендә, Киров өлкәсенең Малмыж шәһәрендә, Төмән өлкәсенең Тубол шәһәрендә һ. б. төбәкләрдә татар телендә газеталар нәшер ителә. Оренбург, Свердловск, Түбән Новгород өлкәләрендә дә татар телендә өлкә газеталары чыгарыр өчен әзерлек бара. Татарлар күп яшәгән башка төбәкләрдә дә татарча газеталар оешыр әле дигән өмет яши. Һәрхәлдә бүтән өлкәләрдә татар газеталары чыга башлау — күңелле күренеш. Әлеге газеталарның байтагын караштыргалаганым бар. Аларда милли мәсьәләләргә, милли телне һәм мәдәниятне пропагандалауга зур урын бирелә. Әмма бу матбугат органнары әлегә һәр җәһәттән зур кыенлыклар кичерә. Аларга тернәкләнеп китәр өчен ярдәм кирәк. Әдипләребез тарафыннан да. Бәлки, Язучылар берлеге бу игелекле эшне оештырып җибәрүче булыр?

Өченче. Милли республикаларның үзләрендәге журналистика да камилләштерүгә мохтаҗ. Бу уңайдан милли республикалардагы күренеш бик чуар: матбугат органнары кайда аз, кайда күп. Әйтик, союздаш республикаларда туган телдә территориаль, социаль-демографик һ. б. матбугат типларының киң челтәре бар, ә элеккеге автономияләрдә бу челтәр үтә ярлы.

Дөрес, соңгы вакытта бездә алга китеш сизелә. Татарстанда яшьләр һәм балалар өчен журналлар («Идел», «Салават күпере»), берничә район һәм күптиражлы газета (Әлмәттә, Түбән Камада, Чаллыда, Зәйдә, Лениногорскида, Казан университетында), тармак газетасы («Аваз») барлыкка килде. Уйлавымча, әлеге тенденция дәвам итәчәк.

Республикаларда милли журналистиканың барлык типлары да тулыландыруга лаек. Иң элек сүз милли-территориаль тип басмалар, ягъни район һәм шәһәр газеталары турында бара. Әйе, Татарстанның һәр шәһәрендә һәм районында татар газетасы чыгып килә. Әмма ул тип газеталар арасында русчадан татарчага тәрҗемә ителә торганнары (һәм киресенчә) байтак. Андый басмалар заманы әллә кайчан узды инде. Алар аудиториянең ихтыяҗ һәм мәнфәгатьләрен канәгатьләндерә алмый. Бу газеталар баштан ук рус телендә сөйләшеп аңлашучы укучыларга юлланган. Шуңа күрә әле тәрҗемәнең түбән сыйфатлы булуын да китереп өстик. Дубляж газеталарының тиражы аз булу әнә шуннан килә. Димәк, район һәм шәһәр газеталары челтәрен камилләштерүне дубляж газеталарын мөстәкыйль басмаларга әйләндерүдән башларга кирәк.

Бездә башка тип басмалар челтәре дә тулыландыруны көтеп ята. Әйтик, КПСС илдә тоташ властьтан баш тартып, политик плюрализмга юл ачылгач, партиячелсыйныфый билге буенча дифференциацияләнгән басмалар тибы зур үзгәрешләргә дучар булырга тиеш. Хәзер бит, КПССтан тыш, башка политик партияләр дә борын төртеп килә. Алар, һичшиксез, матбугат органнарына мохтаҗ булачак, чөнки прессадан башка бернинди иҗтимагый хәрәкәт яши алмый. Халык властե органнары буларак, советларның да үз матбугаты ишәячәк дип уйларга кирәк.

Аннары килеп, бездә милли телдә мохит мәнфәгатьләрен, ягъни экономик, гыйльми, эстетик һ. б. мәнфәгатьләрне канәгатьләндерердәй газета-журналлар бик аз. Ә бит матбугат челтәре һәр ихтыяҗны һәм мәнфәгатьн канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән булырга тиеш.

Дүртенче. Республикалар, шул җөмләдән Татарстанда, башка телләрдәге матбугат челтәре дә камилләштерелергә тиеш. Мәсәлән, бездә чуваш телендә республика газетасы яшәп килә иде. Аны яптылар. Хәзер ачарга вакыттыр.

Журналистика информациясен «җитештерү» — хәзерге заман матбугат индустриясе эше. Ул, гомумән, безнең илдә, аерым алганда республикабызда, бик артта калган тармак. Ару дигәне дә — КПСС республика комитетыныкы. Теге яки бу газета-журналны ул теләсә бастыра, теләмәсә — юк. Ә бүтән социаль көчләрнең басмаларын кем чыгарырга тиеш соң?

Полиграфия промышленностен, информация туплау, эшкәртү һәм таратуга бәйле башка тармакларны яңарту проблемасы бик җитди булып алга килеп баса. Минемчә, республикада информация чараларын, шул исәптән аларның материаль-техник базасын үстерүгә юнәлдерелгән хөкүмәт программасын эшләү зарур. Бу программа район үзәкләрендә һәм шәһәрләрдә, югары уку йортларында, берләшмәләрдә, Казанда китап, матбугат, телевидение, радио, рекламаның материаль-техник базасын яңартуның күләмен һәм этапларын билгеләргә тиеш. Югыйсә безнең, «милли культураны үстерик» дип сөйләнүләребез авыз суы корыту гына булып калачак.

Әлеге программа кадрлар әзерләү проблемасын чишү чараларын да сыйдырыр иде. Милли кадрлар әзерләүдә бездә беркадәр тәҗрибә тупланды. Шул тәҗрибә җирлегендә Казан дәүләт университетында яңа уку елыннан журналистика факультеты эшли башлады. Анда татар журналистикасы кафедрасы да бар. Факультетта рус теленнән татарчага тәрҗемә итү буенча белгечлек ачылды. Кафедра студентларны укытуны, нигездә татар теленә күчерә, ана телендә дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре әзерләргә, татар журналистикасының тарихын һәм хәзерге проблемаларын өйрәнү эшен җәелдереп җибәрергә ниятләнә.

Милли кадрлар әзерләү димәктән, тагын бер проблема бар. Ул да булса — журналистика факультетына татар абитуриентларының аз килүе. Без көндезге һәм читтән торып уку бүлекләренә ел саен унар кешедән артык студент кабул иткәнебез юк. Конкурс дигәнең булмый да. Моның сәбәпләре, әлбәттә, тирәндә. Ул милли мәдәниятне кыскан сәясәт, милли мәктәпләрнең бетә язуы, туган телнең абруе төшү белән бәйле. Ләкин безгә хәзер «алма пеш — авызыма төш» дип кул кушырып утыру ярамый. Алмаш әзерләү — һәммәбезнең уртак эше. Язучылар берлеге дә ярдәм кулы суза алыр иде. Берлек яшь каләм ияләре белән шактый эш алып бара ич. Һәр районда диярлек әдәби берләшмә бар. Әдипләребез яшь талантлар белән эшләгәндә журналистикага сәләтлеләрен дә күздән ычкындырмасыннар иде диюем.

Шулай, милли журналистиканы үстерүгә кагылышлы проблемалар җитәрлек. Ә аны үстерергә кирәк. Чөнки милләтне туплау, милли үзаңны үстерү, милли мәдәниятне алга җибәрү, милли хәрәкәтләрнең активлыгын арттыру матбугаттан башка була алмый.

**Флорид ӘГЪЗАМОВ,**
Казан дәүләт университетының
журналистика факультеты деканы.

**Миркасыйм Госманов,**
тарих фәннәре докторы, профессор

# МӘҖИТ ГАФУРИ МИРАСЫННАН

Соңгы вакытларда революциягә кадәр чыккан татар журналларын караштыргалап утырган чакта шагыйребез Мәҗит Гафуриның (1880—1934) иҗат үзенчәлеген, кайбер мәсьәләләр буенча дөньяга карашын төгәлрәк чагылдыра торган яңа фактларга очрарга туры килде. Шагыйрь мирасын, аның иҗтимагый позициясен өйрәнү, тагын да ачыклый төшү өчен алар кызыклы мәгълүмат булып тора. Мәсәлән, аның милли хәрәкәткә караган кайбер фикерләрен чагылдыра торган бер мәкаләсе игътибарга лаек.

Мәкалә «Сәбәп нәрсә» дип аталып, «Сөембикә» журналының 1918 елгы беренче, төгәлрәге, аның иң соңгы санында басылган (моннан соң, мәгълүм булганча, журнал чыгудан туктый). Мәкалә ахырында күренгәнчә, ул 1917 елның 16 декабрендә язылган. Бит итәгендә публикациягә карата: «Бу мәкалә Башкорт федерациясе игълан ителеп, башкорт халкы зур вакыйга алдында тору мөнәсәбәте белән дәреҗ ителде. Идарә»,— дип искәрмә бирелә. Моннан татар журналының тугандаш халыкның азатлык өчен көрәш мәсьәләсенә карата теләктәшлек белдерүе сизелеп тора.

Мәҗит Гафури исә Урал артында киң таралган башкорт милли азатлык хәрәкәтенең — аны күзәтеп торучы буларак — табигатен аңларга, үзе аңлаганнары хакында укучыларга да төшендерергә омтыла. Аны иң гаҗәпләндергән беренче күренеш — Башкортстанда яшәүче мишәрләрнең, типтәрләрнең әлеге хәрәкәткә мөнәсәбәте була. Башкортларның соңгы вакытларда бик активлашуын, максатларына ирешер өчен үз җирләреннән башка халыкларга өлеш бирергә риза икәнлекләрен искәртеп, ул болай дәвам итә: «Мишәр вә типтәрләр исә, йә асыл федерациянең үзенә бик салкын карыйлар вә яхуд шул башкорт федерациясенең койрыгына тагылырга әзер торалар. Башкортны тәртипсезлек вә эшсезлекнең мәҗәссәм мисдакы (мәгънәви гәүдәләнеше М. Г.) итеп тоткан, башкортның бөтен нәрсәсеннән көлгән, ул халыкта гыйбрәткә вә үрнәккә тотарлык бер генә нәрсә дә тапмаган бу «горур» кавем хәзерге көндә килә дә шул башкорт хәрәкәте алдында ихтирам күрсәтә, мөселманчылык вә иманы өчен нинди фидаилекләр итәргә торган вә иткән «мөселман» бүген килә дә гомум мөселман күпчелегеннән дә аерылып, «Башкорт эсиискә»сенә тавыш бирә, мөселман күпчелеген бер дә хаксыз «буржуазия фиркасе вә кадетлар»,— дип атый!» (9 б.) Шулай итеп, М. Гафури Башкортстанда яшәүче татарларның кайберләренең, тар матди мәнфәгатьтән чыгып, әлеге хәрәкәткә карата икеле-микеле позициядә торуларын, җае килсә, иманнарыннан тиз тайпылуларын ярыйсы ук оста тотып алган икән.

Башкортларның үзләренә килсәк, М. Гафури аларның һәр адымы, һәр гамәле максатчан, алдан исәпләнгән булуын махсус билгеләп үзә, шул фикерен төрле яклап дәлилләргә омтыла. Аның фикеренчә, башкортларның садәлеге ул тышкы күренеш кенә. Кирәге чыкса, башкорт кешесе бик оста итеп мәсьәләне аңламаган үтә беркатлы адәмгә дә салыша ала. Һәрвакыт аның хуҗалык эшләре эшләнгән, ягъни печәне вакытында чабылып, балыгы кирәгенчә тотылган булыр: ауга да үз вакытында чыгып, кунагын да чакырырга, әйбәтләп сыйларга өлгерер ул. Аның ваемсызлыгы, садәлеге тышкы күренеш кенә. Мәсәлән, ди автор, белеме чамалы, зур гаиләле бер агайга башкортларның Учредительный собраниеләренә ярдәм итү, акча җыю кирәклеге хакында әйтсәң, аның бер дә исе китмәс: «Эшләрбез, ул эшләрне Алла эшләп йибәрми, йирдә бәндәләр эшли бит!» — дип кенә җавап бирер.

Шул ук вакытта башкортларга хас бу искитмәслелек сыйфаты гадәти ваемсызлык та түгел икән. Фикерен дәлилләр өчен М. Гафури башкортлар тормышыннан берничә мисал китерә. Шулардан берсе: «Бер башкорт кунаклар чакыра. Кунаклар киләсе көндә

генә 14 яшьлек бер кызы суга батып үлә. Аны бик тиз генә җыештырып куялар. Кунаклар китә, өч-дүрт көн кунак булып китәләр. Ләкин суга батып үлгән кыз вакыйгасын һич тә белмиләр. Фәкать күп вакытлар үткәч шул хәл зоһур итә» (ачыла — М. Г.).

Башкорт халкының шушындый сыйфатына игътибар иткән автор түбәндәгечә йомгак ясый: «Менә шул табигатьләргә малик (ия — М. Г.) булган мәзкүр рәвештәге башкортлар хәзер дә Зәки типтәр (Әхмәтзәки Вәлиди М. Г.) белән Манатов дигән бер «дәликалы»ның «Башкорт федерацияләренә» муафәкат (ризалык — М. Г.) итәләр. Ләкин муафәкат итеп ни эшлиләр? Җан башына утыз-кырык тиен акча җыешалар да Оренбург вә башка йирләргә кешеләр йибәрәләр вә үзләре һич нәрсә юк кебек итеп, казылык ашый вә кунакка йөрешәләр» (12 б.).

Башкортларның холкын болай бик үзенчәлекле итеп сүрәтли алган Мәҗит Гафури, тарихтан күренгәнчә, азатлык өчен барган хәрәкәтнең перспективасын тасвирлаганда шактый нык ялгышкан икән. Моның шулай икәнлеген шагыйрьнең үз язмышы да — гомеренең соңгы дәверендә «паспорт» алыштырып, титуллар үзгәртеп йөрүе дә расласа кирәк. Ихтимал, моңа Башкортстандагы мишәр-типтәрләрнең автор үзе күрсәткән гамәли омтылышлары да сәбәп булгандыр...

Шагыйрь мирасына караган икенче бер мөһим факт «Дин вә әдәп» (Әд-дин вә-л-әдәб) журналының иң беренче санында сакланып калган.

Мәгълүм булганча, бу журналны 1906-1917 елларда Казанда күренекле дин галиме, җәмәгать эшлеклесе һәм мөдәррис Галимҗан хәзрәт Баруди (1857—1921) чыгарган. Исеменнән үк күренеп торганча, ул журнал гел дини, фәлсәфи мәсьәләләрне яктыртуга багышланган. Дөрес, анда, игътибар белән укый белсәң, иҗтимагый, мәдәни тормышны чагылдырган материаллар да шактый.

Түбәндә тексты тәгәл күчерелә торган шигырьне автор әлеге журнал чыга башлау мөнәсәбәте белән махсус язган. Текст алдыннан «Мәдрәсәи Мөхәммәдия таләбәсендин (укучыларын — М. Г.) шагыйре милли Габделмәҗит әфәнде әсәре» дип күрсәтелгән. Моннан күренгәнчә, журналның беренче санын әзерләү эшенә үк М. Гафуриның җәлеп ителүе ап-ачык. Аның шәкерт килеш (26 яшьлек пишкадәм!) нашир һәм мөхәррир тарафыннан «милли шагыйрь» дип олылануы да шуны раслый.

Унөч строфадан, ягъни 52 юлдан торган әсәр шагыйрьнең җыентыкларына кермәгән. 1980—1983 елларда Казанда М. Гафуриның туган теленда чыккан иң тулы дүрттомлыкта да аңар урын бирелмәгән. Һәм бу аңлашыла. Чөнки моңарчы безнең әдәбият белемендә (дәреслекләрдән алып махсус монографияләргә кадәр) Мәҗит Гафуриның дингә мөнәсәбәте бары «Юктырсың ла, Алла» шигыре мисалында тасвирланып килде. Яңа ачылган факттан күренгәнчә, шагыйрьнең дингә, димәк, Аллага мөнәсәбәте ул кадәре үк берьяклы булмаган икән.

Дөрес, әлеге популяр шигырьне дә, игътибар белән укысаң, авторның диннән тәмам йөз чөерүен түгел, бәлки җирдә хөкем сөргән гаделсезлектән рәнҗүен күрәсең.

Түбәндә кабат басыла торган әсәрдән М. Гафуриның дингә шактый тирән мөнәсәбәттә булуы ачыла. Аныңча, кеше өчен «дин, әдәп һәм мәдәният» бертигез дәрәҗәдә кирәк һәм бергә булган хәлдә генә чын-чынлап файдалы икән. Шагыйрь инануынча бозылган әхлакны төзәтү, наданнарның, бигрәк тә рухан хаерчеләрнең белемсезлеген бетерү өчен дә диниелек зарур икән. Әлбәттә, бу мәсьәлә буенча төрле яклап фикер алышырга мөмкин. Тик шунысы хак, киләчәктә шагыйрь иҗатын яктырткан чакта, мәсьәләнең шушы ягына да тиешле дәрәҗәдә игътибар ителсә, позиция күпкә гадел һәм нәтиҗә чагыштырмача объективрак булыр иде. Ниһаять, мондый алым шагыйрь кичергән фикери эзләнү процессын да, эволюция һәм үсү үзенчәлеген дә тәгәлрәк аңларга ярдәм итәр иде.

## Әд-дин вә-л-әдәб

(1) Эчтә булган шатлыгымны кылып изһар,
Бәгъзы вакыт шигырь язу гадәтем бар;
Яхшы эшкә һәр вакытта дәрт кузгала,—
Былбыллар аваз салыр, күрсә гөлзар.

(2) Милләткә хезмәт өчен ошбу көндән,
Казанда бер журнал чыгу сәбәбендин,
Бу мөҗәллә берәм-берәм тәфсыйль итәр
Дин-исламдан, дәхи аның әдәбендән.

(3) Безләрне ошбу журнал әйләде шад,
Бу фәкыйрьнең шатлыгына кыл игътимад,

Дин вә әдәп мөҗәлләсен тәбрик идеп,
Ихтыярсыз бу шигырьне кылдым иншад.

(4) Дөнья-ахирәт сәгадәткә ирешкән зат,
Кыладыр һәрберсенә зур иҗтиһад,
Бергә булса дин, әдәп һәм мәдәният,
Шул вакытта хасил булыр асыл морад.

(5) Дин-исламның фәлсәфәсен бәян итсен,
Хәкыйкатьне һәр кешегә гәян тисен,
Хак аңлану тәрәкъкыйгә сәбәп булып,
Көннән көн милләтемез алга китсен.

(6) Дин-ислам күктә торган якты кояш,
Мәстүр түгел, хәкыйкате дөньяга фаш,
Дин-исламга зәррә кадәр зарар килмәс,
Мөганидлар һәр тарафтан атса да таш.

(7) Дин-ислам бакый булган якты бер нур,
Бу нурдан бушка калган буладыр хур,
Дин-исламның фәлсәфәсен тәфтиш итсә,
Әһле инсаф һич вакытта тапмас косур.

(8) Күп йирдә әдәп-хәя күтәрелгән,
Кирәкмәс гадаутләр әчкә кергән,
Хосусән бу заманда дөнья тулды
«Беләмез дип дәгъва кылып белеп йөргән.

(9) Саф нәрсәгә пычраклар аралашкан,
Күңелне күптән бирле кара баскан;
Мин-минлек дәгъвасендә йөргәнләрнең
Әксәре кырын юлга карап ашкан.

(10) Милләт өчен тырышудан ләззәт алып,
Дөньяңыздин динеңезне алга алып,
Һичбер кеше онытмастай эш кылдыңыз,
Артта калган мөселманга күзне салып.

(11) Дин-карендәш мөселманга кылып шәфкать
Күтәрдеңез өстеңезгә зур мәшәкъкать.
Һәп рәхәтне милләт өчен фида итеп,
Үзеңезгә рәхәтсезлек калды фәкать.

(12) Әүвәлдән Русиядә мәшһүр остад,
Дин юлында алгы сафтан кылды җиһад:
Борынгы хезмәтләрен тәкъдир итсәк,
Өмидемез дәхи арта ничә мең кат.

(13) Мотлакан заманабыз башка заман,
Сезләргә күп сөенеч, әһле Казан!
Өч гәзитә бер дә журнал чыгып тора,—
Кадрен белеп укыңыз сез инде һаман!

Бәндәләре
*Габделмәҗит ГАФУРИ*

---

СҮЗЛЕК:
Изһар кылу — белдерү, игълан итү.
Мөҗәллә — журнал.
Игътиҗмал кылу — ышану.
Иншад кылу — иншә итү, иҗат итү.
Гайан кылу — ачык итү (аңлату).
Мәстүр түгел — ябык түгел.
Косур — кимчелек, җитешсезлек.
Гадауәт — дошманлык.
Әксәре — күпчелеге
Һәп — барлык, һәммә.
Остад — остаз.
Җиһад кылу — тырышу.

# ХӘТЕР

## Ф. ВӘЛИЕВНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН



Борынгы архитектура һәм гамәли сәнгать буенча искиткеч бай гыйльми нигезгә корылган фәнни монографияләр авторы, исеме җәмәгатьчелек арасында киң таралган, халык сәнгате буенча татарлардан әлегә бердәнбер фән докторы булган, тик үзенең туган йорты Казанда һәм аның фәнни-тикшеренү институтында даими хезмәт урыны таба алмыйча, бу фани дөньяның каһәр суккан каршылыкларын җиңә алмаудан гаҗиз булып, үзенә карата көнчелектән һәм хөсетлектән тәмам туеп, тормыштан вакытсыз китеп барды Фоат Вәлиев. Фәнгә, сөйгән халкына хезмәт итүдән башканы белмәгән, киң күңелле, әмма шактый авыр холыклы, зур интеллектуаль акылга ия, ләкин күпләргә аңлашып бетмәгән үзенчәлекле шәхес иде ул. Олы талантларның күбесенә хас сыйфатлардыр инде болар...

Хатирәмне шул фидаи затның авыр язмышы өчен газаплану сүзләре белән башласам да, Фоат абый минем күңелемдә татар халкының искиткеч бай мәдәни тарихын армый-талмый тикшерүче һәм аны ялкынланып пропагандалаучы фәнни баһадир булып калачак. Үземне аның рәсми булмаган, әмма чын укучысы дип игълан итәргә дә җөрьәт кылам, моңа минем бөтен әхлакый хакым бар. Фоат Вәли турындагы хатирәләрем яңарган саен, иң әүвәл миңа моннан 30 ел элек, ягъни 1960 елда элекке Касыйм ханлыгының башкаласы Касыйм шәһәренә кылган сәяхәтебез искә төшә. Борынгы шәһәрнең татарлар яши торган өлеше, шундагы татар зираты, Хан мәчете, XV йөздән калган биек таш манара, халкыбыз тарихында кара эз калдырган Шаһгали мавзолее, аның эчендәге җисеменә бик үк туры килеп бетмәгән, зур һәм матур кабер ташлары, шунда Сөембикә каберен эзләп йөрүләребез... Фоат абыйга 39, миңа 23 яшь. Ул миңа тарих — татар тарихын сөйли, мин йотлыгып тыңлыйм. Инде бүген, үземнең дә шул тарихны ярыйсы гына белүем күзлегеннән караганда, мин Ф. Вәлиевнең шул вакыттагы фәнни эрудициясен, киң белемлеген искә төшереп хәйран калам. Бер уйласаң, махсус тарихи белеме дә юк төсле. Киевтә төзүче-инженерлар институтын тәмамлаган, аннан соң ун ел Гипротатнефть трестында архитектура-төзелеш бүлеге җитәкчесе, ике ел Казан реставрация остаханәсендә баш архитектор. Хәер, бу елларда инде ул атаклы этнограф Н. И. Воробьевның аспиранты, бер үк вакытта Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының кече гыйльми хезмәткәре. Институтта 10 ел эшләү дәверендә бу «дәрәҗәле» исем аның артыннан даими ияреп йөрде. Әйе, 50 яшен тутыручы танылган галим, «Казан татарлары орнаменты» исемле бәһа биреп бетермәслек зур монография, дистәләгән фәнни хезмәтләр авторы һәм... кече гыйльми хезмәткәр. Дөресен әйтим, Фоат абыйны бу исем кимсетте. Үзенең югарырак исемгә, «өлкән хезмәткәр» дәрәҗәсенә лаеклы булуын исләренә төшерсә дә, игътибар итмәделәр һәм ул институттан китте. Мин аны аңлыйм. Бигрәк тә соңрак, бүген дә шушы ук институтта биш-алты чиле-пешле мәкалә чыгарып, фәләнчә еллык «образованиеләрен селкетеп» йөргән кайбер өлкән гыйльми хезмәткәрләр барлыгыннан чыгып карасаң, Ф. Вәлиевнең ул чактагы принципиаль адымы гаҗәп тоелмый. Ләкин ул бөтен булган үпкәсен онытып, берничә елдан институтка кайтырга теләде, конкурста катнашты, тик гыйльми совет аны үткәрмәде. Сәнгать буенча фәнни хезмәткәр булып бер ханым

узды һәм ул шуннан берничә ел үткәч институт буенча кыскартылуга эләгеп, аннан китәргә мәҗбүр булды. Баксаң, әлеге мөхтәрәм ханымның фәндә ун елдан артык эшләү дәверендә... бер генә фәнни хезмәте дә булмаган икән. Ә конкурстан уза алмаган, ул вакытта Мари политехник институтында доцент булып эшләгән Фоат Вәлиев Йошкар-Ола шәһәрендә татар халкының сәнгать һәм архитектура тарихы буенча ике монография бастырып чыгарды, Казанга кайтып, Татарстанның халык декоратив сәнгатенә багышлап тагын бер китап чыгарды һәм докторлык диссертациясе яклады. Әйе, инде әйткәнемчә, татар сәнгатенең тарихы, ягъни матди культура белән бәйле булган бик тә мөһим өлкә буенча һәм, әлбәттә, татарлар арасында әлегә бердәнбер фәннәр докторы булды. 60 яшь тулганда күп еллык гыйльми хезмәтенең җимешен — диссертациясен СССР Художество академиясендә яклап, шуннан сабый балалар кебек шатланып кайтып, тагын үзенең туган институтына эшкә алуларын, һич югында консультант итеп билгеләүләрен сорап бара һәм тагын «отказ» ала. Бу юлы сәбәбе дә бар — пенсионер! Ә ул вакытта анда хәтта 80не тутырган кайбер тарихчылар консультант булып тора иде.

Мин бу сүзләремне әлеге институтта, ягъни үзем үк инде 28 ел өзлексез эшләүче фәнни оешмада ошатмаячакларын белеп язам. Фоат Вәлиевның татар тарихын, аның гаҗәеп бай архитектура һәм сәнгать тарихын тырышып-тырышып өйрәнүдә, шуны дөньяга чыгаруда искиткеч зур хезмәт куюын, ләкин үзе исән чакта шул зур хезмәтне, аның талантын әлеге институтта танымауларын, дөресрәге, танырга теләмәүләрен, югары класслы белгеч буларак читкә кагылуын үзе үк белә торып, күп газапланулар, артык гасабиланулар нәтиҗәсендә («быстротечный рак») вакытсыз дөньядан китеп баруы өчен йөрәгем әрнеп, җаным сыкрап язам. Бернечә монографиясенең фәнни редакторы һәм рецензенты, фикердәше һәм якын дусты буларак, аны институтка алуларын сорап ул вакыттагы институт җитәкчелегенә, СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы президиумына, КПСС өлкә комитетына бернечә тапкыр мөрәҗәгать итеп тә сүземне үткәрә алмаганлыгыма гарьләнеп язам. Кемнәр каһәрләгәннәр, кемнәр рәнҗеткәннәр, кемнәр аны читкә кагканнар — шуларның намусларында калсын.

Даһи Тукайның үлемсез сүзләре, әйтерсең, туган халкын, аның бөек матди һәм рухи дөньясын сөеп иҗат иткән, әмма һәртөрле түбәнлекләр, мыскыллаулар тоеп яшәгән Фоат Вәлигә дә багышлап язылганнар:

*Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын,*
*Без үләрбез, билгеле, тик үкенечкә калмасын.*

*Киң күңелле бул эчеңнән, мыскыл ишетсәң, «вак» диген,*
*Таптасыннар, хурласыннар, тик җаның хурланмасын.*

Әмма Фоат абыйның җаны да хурланды. Дөрес, ул көчле кеше иде, үзенең күпләрдән бер башка югары булуын сизеп яшәде, кемнәр алдындадыр баш имәде, ялагайлыкны җене сөймәде. Дөрес, хурланды, әмма сынмады, рухи гарипләнмәде.

Мин Фоат Вәлиевне идеаллаштырырга җыенмыйм. Күпләрнеке кебек, аның да җитешмәгән яклары бар иде, әйткәнемчә, холкы да бик җиңел түгел иде. Мин моны үзем дә татыштыргаладым. Сөйләшеп утыра торгач, төрле гыйльми мәсьәләләр турында бәхәсләшеп китеп, сүзгә килешә, үпкәләшеп аерылыша торган идек. Әмма аннан яшь кеше буларак, аның олы галим булуын тоеп, шуны кабул итеп, үзем башлап, Щапов урамына, аның өенә тагын барам, әнисе Нәгыймә апа (безнең әниләрнең исемнәре дә бер иде) пешергән бик тә тәмле йомшак кабартмалар ашап озаклап, сөйләшә-сөйләшә чәй эчәбез, тагын төрле фәнни мәсьәләләр турында фикерләшәбез. Әлбәттә, еш кына уртак тел табабыз. Һич кенә дә үпкә саклаучан, үч тотучан кеше түгел иде мәрхүм.

Мин Ф. Вәлиевне белгәннән бирле аның талантына, эшкә ифрат сәләтле булуына сокланып яшәдем. Киң эрудицияле тарихчы, этнограф, сәнгать белгече, архитектор һәм рәссам. Мин аның ике кулы белән дә бер үк дәрәҗәдә, бер үк тизлектә сызым сызу яки рәсем ясау сәләтенә сокланып бетә алмый идем. «Ничек алай эшли аласыз?» дигән сөалемә каршы елмаеп кына куя иде. Дөресен әйтим, аның бу табигый сәләтенә Бакый Урманче да зур бәя бирде. Без икәү Бакый ага янында булгалап, сәнгать һәм гомумән халык тарихы турында озаклап сөйләшеп утыра торган идек. Кайбер гадәтләре өчен аны җиңелчә шелтәләп, «Юк, Фоат-җан, бу юлы син хаклы түгел», дигәләсә дә, олы рәссам аны бик зур ихтирам итә, хәтта ярата иде, ә Фоат абый Урманчены гомере буе үзенең остазы итеп санады. Мин — моның шаһите.

Әлбәттә, мин аның бөтен басылган китапларына да фәнни анализ бирергә җыенмыйм, кечкенә генә язмада моны башкарып та булмый: җитмәсә, минем хатирәмнең максаты да ул түгел. Аның күпьеллык фәнни хезмәтенә бәя биреп, бернечә

сүз белән генә болай дип әйтеп булыр иде: Фоат Вәлиев милли сурәтләү өлкәсендә татар халык сәнгатен өйрәнү фәненә чын мәгънәсендә нигез салды, халкыбызның декоратив-гамәли сәнгате аның фәнни тикшеренүләрендә беренче тапкыр гыйльми-теоретик нигезгә корылды. Бу аның биш фәнни монографиясендә, Мәскәүдә басылган берничә зур коллектив хезмәттә (шулар арасында «Урта Идел һәм Урал буе татарлары» дигән һәйбәт китап, дөнья халыклары сәнгате буенча энциклопедик басма) чагылыш тапты, раслану алды, тиешле фәнни калыпка салынып бирелде.

Беркадәр баналь, кабатланган сүзләр кушып әйткәндә, Ф. Вәлиев башка бернәрсә дә язмыйча, инде телгә алынган «Татар халык орнаменты» дигән капиталь монографиясен генә иҗат иткән булса да, аның исеме татар халкының күп гасырлык сәнгать тарихын өйрәнү эшендә алтын хәрефләр белән язылып куелыр иде. Исеменә караганда, бу китап сәнгатьтәге техник алымнарның бер төренә — орнамент-бизәккә генә багышланган кебек тоелса да, монда халыкның искиткеч бай рухи дөньясының матди чагылышы булган декоратив-гамәли сәнгатькә, аның төрледән-төрле төркемнәренә, шуларны эшләү алымнарына, аларның килеп чыгышына һәм тарихи язмышына гаҗәеп төпле, нигезле, профессиональ анализ бирелгән.

Мин бу китапны кулыма алган саен — ә мин аңа бик еш мөрәҗәгать итәм — тыныч кына укый алмыйм. Никадәр зур байлык, никадәр гүзәллек вә сылулык, никадәр тирән сәнгати фәлсәфә! Әйе, бу сәнгать — чын мәгънәсендә халкыбызның бөек акылы, аның гасырлар буена тир һәм канлы яшь түгеп җыйган рухи вә матди байлыгы. Ә югалганнары, 1551-52 елларда һәм шуннан соңгы чорларда таланганнары күпме булгандыр...

Алтын-көмештән, кыйммәтле ташлардан эшләнгән атаклы ювелир, ягъни зиннәтле бизәнү әйберләре: чулпылар, хәситәләр, яка чылбырлары, беләзекләр, йөзекләр, алкалар, бөтиләр, кечкенә һәм нәфис коръән савытлары, тагын әллә ниләр, аларны бизәкләүнең бай алымнары, әйтик, кою, нәкыш, бөртекләү, каралту, кырлау, басма һәм башка югары сәнгати ысуллар — болар һәммәсе байлык, осталык вә илаһи нәфислек. Ә менә энҗе, якут, зөбәрҗәт, ахак, фирүзә кебек асылташлар куеп, яссы нәкыш, бигрәк тә төрчекле нәкыш алымы белән эшләнгән бизәнү әйберләре, Ф. Вәлиев раславынча, бары тик татарларга гына хас һәм алар дөнья зәркән сәнгатенең иң гүзәл үрнәкләреннән саналырга хаклы.

Бу әле халык сәнгатенең бер төрен генә искә алу булды. Ә һәрберебезгә балачактан бик тә таныш булган, һәр татар өен, хәтта ярлы-ябагайның да җыештырып куйган куышын үзенчә бизәп торган, әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез, абый-апаларыбыз, ниһаять, үзебез дә киеп йөргән, чигеп эшләнгән җиһаз һәм киемнәр. Кызыл башлы сөлгеләр, япмалар, келәмнәр, ашъяулыклар, башъяулыклар, түбәтәйләр, калфаклар, башмаклар, читек-кәвешләр, аларны чигүнең күп төрле алымнары, мәсәлән, элмәле чигү, тоташ чигү, каеп чигү, сәйлән чигү, чуклы чигү. Аларны бизәкләүнең бер генә төрен, чәчәк орнаментын гына ал син — мәңге яшәр табигатьтән никадәр олы байлык, гүзәллек кабул ителгән: йөзем агачы, дәлия, лалә, канәфер, кашкарый, мәк, миләүшә, гөлчәчәк, чалма чәчәк, кыңгырау чәчәк, ак чәчәк, алтын чәчәк... Сөйли-яза китсәң, туктый алмассың. Боларның һәммәсе Фоат Вәлиевның әлеге китабында, аның башка хезмәтләрендә гыйльми вә сәнгати янәрыш алып, сөйгән халкына кире кайтарылды.

Сөйгән халкы... Бу сөю берьяклы гына түгелме соң? Юк, мин һич тә бөтен халык тарафыннан сөелү турында сүз алып барырга җыенмыйм. Фән кешесе ул җырчы да, композитор да, шагыйрь дә түгел, галимнәрне, гадәттә, азрак беләләр, аларның булган популярлыгы күбрәк шул га元мә, интеллигенция арасында. Ләкин болары да бит шул ук халыкның уллары, җитмәсә, теге яки бу галимгә халык исеменнән бәя бирергә яратучы партия-совет эшлеклеләре, һәртөрле чиновниклар, функционерлар бар. Аларның «сөюе» ни дәрәҗәдә? Үзе исән чакта кагу, мыскыллау, эшенә төрлечә аяк чалу, үлгәч күкләргә чөеп мактаумы? Дәрдемәндчә әйтсәк:

*Бетеп гомерең, итеп күмгәч үзеңне,*
*Итәрләр хирзе җан*[1] *күмгән сүзеңне.*

Шул ук Фоат абыйның институтка кире кайтуына комачаулау өчен бөтен көчләрен куючыларның кайберләре бүген аның татар сәнгате тарихын өйрәнүгә керткән «зур өлеше» турында сөйлиләр, кайберләре аның 70 еллык юбилее уңае белән үткәрелгән фәнни конференциянең оештыру комитеты әгъзалары... Иа, хода, кайдан соң бу бездәге рухи гариплек, бу җаһилият? Кайдан бездәге бу кеше көенечәнә сөенеп,

[1] Хирзе җан — бөти, талисман.

кеше сөенечендә көенеп яшәүләр? Нигә татарның әле күптән түгел генә без белгән галимнәре — менә дигән тарихчы, эпиграфист, этнографлары Хәйри Гимади, Һарун Йосыпов, Әхәт Заһидуллин үз-үзләренә кул салдылар? Нигә? Кем моңа җавап бирә ала? Нигә халкыбызның гасырлардан килә торган тарихи, газиз исемен — «татар» исемен сүгеп, аны икенчегә әйләндерү максатында китаплар һәм мәкаләләр бастырып, 1552 елда Казанның «Рус дәүләтенә кушылуы прогрессив күренеш булган» дип язып, шушы институтта кадер-хөрмәт казаналар? Кайда намус, кайда пакьлек, кайда вөҗдан? Җавап таба алмагач, ирексездән тагын Тукайга мөрәҗәгать итәм:

*Керләнә өст, өстенә рух, һич хозур вөҗданга юк;*
*Ни сәбәптән җир йөзендә тәнгә — мунча, җанга — юк?!*

Әмма андый вакытта мин Фоат Вәлиев кебек фән каһарманнарының намуслы исемнәрен искә төшерәм, аларның якты хатирәсе алдында үзебнең чаларган башымны иям, киләчәккә өмет белән карыйм. Аллага шөкер, Фоат абыйның татар халык әсәрләрен җыйнау, гыйльми классификацияләү, аны бөтен итеп халыкка кире кайтару, гомумән, халкыбызның чын тарихын һәм мәдәнияте тарихын язу эше бүген ышанычлы кулларда — аның сәләтле кызы, тирән белемле сәнгатькәр Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова, Фоат абыйның фикердәшләре, якын дуслары кулында.

**Равил ФӘХРЕТДИНОВ**

---

## *Төрлесеннән*

# БОРЫНГЫ МӘХӘББӘТ БИЛГЕСЕ

Узган җәй һәвәскәр археолог Е. А. Беговатов Татарстанның Кама Тамагы районыннан бер борынгы таш орчыкбаш табып кайтты. Борынгы орчыкбашлар, шул хисаптан таштан ясалганнары да, гомумән еш табыла. Бусы шул җәһәттән үзенчәлекле: анда борынгы төрки рун хәрефләре белән аермачык итеп бер юлда *брк*, икенче юлда *ркң* хәрефләре язылган.

Татарстан җирендә руник хәрефләр белән язылган язмалар моңарчы да табылганнары бар. Күрше өлкәләрдән дә мондый табылдыклар билгеле: мәсәлән, бер язма Мари АССР җиреннән, икенчесе Куйбышев өлкәсеннән табылган. Әмма ул язмаларның берсе дә ышандырырлык итеп укылганы юк. Ә монысын бик зур ихтималлык белән *«бәрки: эркәңә»* дип укып була. Хәзерге татар фонетикасынча, *«бирге: Иркәгә»*, булып чыга, ягъни «Иркә исемле кызга бүләк» дигән сүз.

Язуны уку белән шундый сораулар килеп туа: Кем язган һәм ни өчен язган?

Руник язмачылыкның безнең якларда мөселман дине кергәнче һәм ныгыганчы, ягъни, IX-XI гасырларда кулланылганы мәгълүм.

Орчыкбашка ни өчен язмак кирәк? Әлбәттә, орчыкбаш иясенә беркетелсен, югалмасын өчен. Билгеле, бу хәл орчыкбаш кыйммәтле әйбер булганда гына муафикъ. Безнең орчыкбаш, чыннан да, читтән-еракттан китерелгән (моны аның ташы да раслап тора) һәм заманында чагыштырмача кыйбат торган. Димәк, орчыкбаш сатып алынган. Әгәр кыз үзе ясиә этисе, әнисе сатып алса, бер-ике хәреф кенә язып куяр иде (бер-ике-өч рун хәрефе язылган орчыкбашлар безнең кулыбызда берничә). Алты хәреф язып куярга кирәк тапкан кеше — бүләк бирүче генә була ала. Димәк, орчыкбаш — бүләк.

*Бәркә, бәрик, бәргү* — «бүләк» сүзе борынгы төрки язмаларда да, хәзерге төрки телләрдә дә (мәсәлән, караимча бәркә, бәрик, якутча бәрик «бүләк») еш очрый. Татар теленең көнбатыш (мишәр) диалектында бирге кызның егеткә (яки киресенчә) биргән бүләге (Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан, 1969, 86 б.). Шул фактлардан чыгып, *брк* хәрефләрен без *бәркә* (яки бәрик) дип укыдык.

*Ркң* хәрефләре нәрсә булырга мөмкин? Төп төрки телләрдә сүз башында р авазы очрамый һәм руник язуда сүз башында үзе генә килгәндә *эр* дип укылырга тиеш. Димәк безнең кулда *эркң* сүзе бар. Ул нәрсәне белдерә ала? *Эркә*ң «иркә»ме? Ләкин болай әйтү егетләр теленә хас түгел. Без *эркәңә* ягъни *иркәгә* дип укуны хуп күрдек.

Шулай итеп, безнең кулыбызда борынгы (X-XII гасырлардан калган) мәхәббәт билгесе булып чыга. Һәм Иркә дигән исем, димәк, бездә мең еллык тарихка ия!

**Рифгать ӘХМӘТҖАНОВ**

#ҺӘР ЧАГЫШТЫРУ ДА УРЫНЛЫМЫ?

Авылыбыз китапханәсеннән алып, язучы Рәфкать Кәраминең «Очар кошлар белән янәшә» дип исемләнгән трилогиясен тәшкил итүче повестьларны аерым-аерым укып чыктым.

Автордан сөенче өмет итә алам — өч китап та, укыла торгач, шактый таушалганнар.

Трилогиягә карата язучы Барлас Камалов кайбер фикерләр әйткән иде инде. Биредә, өч повесть бер китап булып басылып чыкканчы, әдәбият сөюче гади укучы буларак кына, тагын кайбер мәсьәләләргә тукталасы килә. Ниятем изге — авторга ярдәм итү.

Әсәрләрдә яшәеш чынбарлыгының тирәнрәк катламнарына яшеренгән мәгънәләрне ачыклаучы, мәхәббәт кичерешләрен, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен һәм гаилә бәйләнешләрен чагылдыручы сөземтәләр, бик матур урыннар күп. Шулар белән бергә, ахырынача уйланып җиткерелмәгән урыннарга да тап буласың. Бу бигрәк тә әдәби алым буларак кулланылып та, теге яки бу яктан үзләрен акламаучы, чынбарлыкка туры килмәүче урынсыз яки йомшак чагыштыруларга кагыла.

Язгы табигать хозурлыгының иң күркәм бизәкләреннән берсе булган тургай очышы һәм сайравы тәэсире белән шул мизгелдә кеше күңелендә туган хисләрне язучы җыйнак кына итеп тасвирлый алган: «... Кояшлы иртәгә, яз җитүенә сөенеп, өздереп сабан тургае сайрый. Бик текәлеп карасаң, аның үзен дә күреп була. Менә шактый югары күтәрелә дә, канатларын җәеп, әкрен генә аска төшә башлый, ә үзе берөзлексез сайрый да сайрый. Бераздан ул вертолет шикелле бер урында тора...» Бу сурәтләүне укыганда үзеңне, чыннан да, яңа яшәреп килүче язгы аланда тургай моңын тыңлаучы кебек хис итәсең. Ләкин шундагы «вертолет шикелле» дигән чагыштыру бал эченә тамган деготь кебегрәк килеп чыккан. Моңлы тавышлы нәфис кошчыкның канатларын җилпеп бер урында тора алуын күрсәтү өчен генә гаять зур гәүдәле, җирләрне селкетеп, миләрне диңкетеп һәм сасы газлар бөркеп гөрелдәүче вертолетны янәшә кую һичбер уңыш китерми. Беркадәр охшашлык булуга карамастан, алар икесе язучы әйтергә теләгән бер мәгънәгә сыеша алмыйлар, чөнки һавада үкереп торучы вертолет тургай моңнарыннан алган ләззәтне күңелдән тиз җуяр. Шулай итеп, бу чагыштыруда раслау урынына инкарь итү килеп чыккан. Гомумән, сабан тургаеның әле генә алынган күңел нечкәрткеч күркәм сыйфатларын нәрсә белән булса да чагыштыру кирәкме икән? Кешеләр табигатьнең ахыргача камилләшкән андый гүзәл мизгелләре белән күп мең еллар буе очрашканнар һәм хозурланганнар,— андый күренешләр күңел тарафыннан, исбат итү яки көчәйтү мохтаҗлыгыннан азат күренеш буларак, саф килеш кабул ителәләр.

Танышуны дәвам итик.

«...Әгәр шул нәрсә булса (төзелеш романтикасының тәэсир көче турында сүз бара.— Г. В.) — син чын төзүче һәм син, чәчәктән чәчәккә кунып нектар җыйган бал корты кебек, эштән эшкә күченеп йөрисе дә, ...озын берлек артыннан куасы да юк».

Әлеге чагыштыру формасы ягыннан бераз туры килгән кебек булса да, эчтәлеге ягыннан үзен бөтенләй акламый. Мәгълүм булганча, бал корты эшчәнлеген гаять катлаулы табигый инстинкт идарә итә. Ә инде җәмгыятькә юнылап хезмәт итмәүче летуннарны үлемен дә табыштан очып кайтканда таба торган югары дәрәҗәдә эшчән бу бөҗәкләр белән чагыштыру сыеша алмый. Һәркем үз эшен бал кортлары кебек тырышлык һәм төгәллек белән башкарсын иде әле!

Әсәрнең беренче кисәгендә яшь егет Гөлүс, гомерендә беренче тапкыр эчү мәҗлесендә катнашып, нык кына кызгач, космонавтлар кебек, авырлык хәлен югалткандай сизә.

Белүемчә, матур әдәбиятта чагыштыру алымы бәян ителгәнне укучы күзаллавында тагын да ачыклау һәм фикерләвендә аңлаешлырак итү өчен кулланыла. Димәк, чагыштыру өчен алынган җисем яки аерым бер халәт укучыга якын һәм таныш булырга тиеш. Әле алынган чагыштыру исә аңлашылмаучылыкны тагын да арттыра.

Автор болай яза: «Димәк, таяк ике генә башлы түгел, өч-дүрт... һәм аның берсе һәр очракта да идарә башлыгына килеп төшәчәк». «Таяк» дигән сүз үзе үк аның ике генә башлы булуын билгеләп куя һәм башкача күзалларга урын калдырмый. Уртак эш буенча җавап бирүчеләрнең күплеген күздә тотып булса кирәк, автор шундый аңлатмага бара. Шуңа да карамастан, күчермә мәгънәле «таяк»ның да (инде таяк турында сүз бара икән!) башлары икедән артмас. Идарә башлыгы шул «таяк»ның үзенә төшәчәк очын әлегә кулында нык тотып, иркле башы белән кул астындагыларны, «гөнаһларына» карап, төрлечә «кыйный» икән,— аңа карап кына таякларның башы ишәя дигән нәтиҗә ясап булмый бит.

Бик үк уңышлы булмаган тагын бер чагыштыруны китерик. «Каравай поселогы ягында этәчләр кычкыра, ерактагы мылтык авазларын хәтерләтеп, чәүкәләр тавыш биреп куя, каргалар каргылдый». Чәүкәләр чаңгылдавын мылтык авазына охшаткач, үрдәкләр бакылдавын нәрсәгә тиңләргә кала соң? Бәлки бомба шартлавынадыр!

«Ләкин комплексны сафка бастыру көннәре отыры якынлаша, кысыла бара. Гүя бу срок — тимер кыршау, һәм ул кысыла барган саен, үз эчендәге бөтен нәрсәне җитезрәк хәрәкәтләнергә мәҗбүр итә».

Һәркемгә мәгълүм, тимер кыршау берничек тә кысыла-кыскара алмый. Киресенчә, катып калган кыршау мәгънәви яктан вакыт агышын инкарь итә һәм автор, әлеге чагыштыруы белән, әйтергә теләгәненә үзе үк каршы чыга.

Ахырда, Р. Кәрамидә күп тапкырлар кабатлана торган бер күңелсез чагыштыру турында. Ул — дәү кулны көрәк белән тиңләү:

«Зиннәтнең көрәк кадәр куллары күз иярмәс тизлек белән йөри»; «... Монда партия җыелышы,— диде калын тавышлы Мәхмүтов, көрәктәй кулы белән залга ишарәләп». Ә «Сагышлы кояш» повестенда Сәлим көрәктәй учлары белән артистларны алкышлый. Гел «көрәк, көрәк һәм... көрәк» дип кабатлау укучыны туйдыра башлый. Ә бу язучының башкачарак әйтергә дә мөмкинлеге һәм җае бар бит. Мәсәлән, «Мәхмүтов... телефон трубкасын күтәрде, көчкә-көчкә номер җыйды: чөнки номер чокырына бармагы керми, дискы ычкынып китә иде». Бу сурәтләүдән соң да «көрәк»нең кирәге булырмы икән? Кеше акылының тәрәккый итүендә һәм көндәлек эшчәнлегендә төп таяныч булган иң камил һәм хәрәкәтчән әгъза — кулны, халыкчан булам дип һәм укучыга аның зурлыгын чамалату өчен генә, катып калган көрәк белән тиңләү һәм шуны җае чыккан саен тәкрарлап тору, кемгә ничектер, минемчә — әсәрне бизәми.

Сүз дә юк, трилогиядәге күпчелек чагыштырулар, охшатулар, тиңләүләр уңышлы кулланылган, персонажларның эчке кичерешләре табигать күренешләре h. б. белән аваздаш бирелгән, ә бу хәл әдәби сурәтләүнең тәэсирен тагын да көчәйтүгә китерә.

Берничә мисал.

Илфир ерактагы таныш кызы Галя турында бүлмәдәш егетләренә еш кына мактап сөйли. Көннәрнең берендә укуын тәмамлаган Галя Казанга килеп чыга, оялып кына егетләр бүлмәсенә керә. Аңа урындык тәкъдим итәләр. Әле кыз хакында җәелеп сөйләргә авторның да, озаклап күзәтергә башкаларның да вакыты юк, ә беренче тәэсирне күрсәтергә кирәк. Язучы нәкъ шушы мизгел өчен тиешле сүзләрне таба алган: «Бүлмәгә әйтерсең зур чәчәк бәйләме кертеп утырттылар. Ул бөтен дөньяны нурга чумдырды, ямьләп җибәрде». Чибәр йөзендә, сылу сынында эчке халәтенең матурлыгы, кызлык сафлыгы нур булып балкыган, килешле итеп киенгән тыйнак яшь кызга беренче күз сирпүнең уңышлы бәясе бу. Ә менә шул ук яшь парга карата икенче аңлатма алай ук уңышлы чыкмаган: «Бераздан алар шәһәр карарга дип урамга чыгып киттеләр. Чөнки аларның шатлыгы, бәхете, куанычы тулай торакның бер бүлмәсенә генә сыярлык түгел иде. Аларның сөенече шәһәр кебек зур, урам кебек киң, күңел шатлыклары Иделдәй тирән һәм тулы иде». Кешенең эчке дөньясында бара торган гаять катлаулы хис-кичерешләрнең чамасын шулай бүлмә, шәһәр, урам үлчәмнәре белән тиңләү аларга бер генә бизәк тә өстәми, киресенчә, ярлыландыруга китерә.

Бу очракта әйтәсе килгән сүз шул: кешенең тышкы дөньясына мөнәсәбәтен, карашларын күпмедер дәрәҗәдә тулы аңлата алган тел байлыгы эчке кичерешләрне ачыклау өчен шактый зәгыйфь. Инде без ниндидер сүзләр, якынча чагыштырулар кулланырга мәҗбүрбез икән — алар һәммәсе дә диярлек кешенең тышкы дөньяга бәясеннән эчке дөньясына көчләп тагылган «килмешәкләр» генә, шунлыктан, яки

алар бер нәрсә дә аңлатмыйлар, яки күрәләтә бозуга китерәләр һәм күңел акылга хәбәр итәргә теләгән мәгънәләрне, матурлыкларны биреп җиткермиләр. Җыйнап кына әйткәндә, тел хәзинәсе инде югары дәрәҗәдә бай тоелса да, кеше үзенең эчке дөньясы белән җитәрлек сөйләшә-аңлаша алмый әлегә. Китерелгән чагыштыру — шуның ачык мисалы.

Идарә башлыгының эшче егетләр белән әңгәмәсеннән кечкенә өзек: «... Әнә сора Фатыйх абыеңнан, метроны ничек төзегәннәр икән. Көрәк, кәйлә, ат... Ә ул аларны ничек сагынып, горурланып искә ала. Чөнки аның яшьлеге ул.

Мәхмүтов шулай диде дә бераз тынып калды. Аның үзенең дә яшьлеге Урал таулары буенда зур заводның мәһабәт корпуслары булып торып калды».

Бу чагыштыруларда һәр тырыш төзүченең соңыннан күңелендә урнашып кала торган мәңгелек горурлыгы, патриотик хисе көчле итеп әйтелгән. Әйе, чын төзүче үзенә дә һәм халкына да һәйкәлләр сала.

Соңгы повестьтан бер мисал.

Хикәяләүнең башында ук җан тетрәткеч фаҗигадән күңеле тирән җәрәхәтләнгән, үзен кая куярга белмәүче, төн йокылары качкан Галя белән янадан очрашабыз. Ул тышына бәреп чыккан кара кайгысыдай күлмәген киеп, авыр хәсрәтедәй кара шәльяулыгын иңбашына салып балконда басып тора һәм туып килгән көнне көтә... Үзенең хәлен урам ташында аунап ятучы, инде беркемгә дә кирәге калмаган, тыны чыгып яньчелгән резина тупка тиңли. Кайгысын уртаклашуны үтенеп, күңеленнән, тып-тын утыручы агачларга мөрәҗәгать итә... Алар да дәшмиләр. Әнә «...койрыгын сөйрәп, башын сузып, төнге биләмнән бер кара мәче кайтып килә. Галя бөтен тәне белән калтыранып куйды. Мәче еланга охшаган, ул, балконга атылып менеп, Галяны чагар төсле. Шулай итсә, барысы берьюлы онытылыр, юкка чыгар иде. Ә болай яшәү!.. Илфирсыз, берьялгызы...» Алга таба кояш чыгышындагы кабартылган мендәрдәй ак болытлар Галя күңелендәге өмет чаткылары итеп сурәтләнә.

Бөтен барлыгы белән якын күргән тормыш юлдашын шулай тиз югалткан яшь хатынның рухи һәм физик халәтен укучы күңеленә илтеп җиткерү өчен сайланган бу чагыштырулар, охшатулар бик тә урынлы. Шуларны күздән кичерү белән укучы әдип теләгән «сукмакка» баса һәм, уенда күпләгән борчулы сораулар кузгалган хәлдә, әсәр эченә кызыксынулы сәяхәт башлый.

Илебездә башланган гаять тирән мәгънәле үзгәртеп корулар халык өчен рухи байлыклар иҗат итүче осталар алдына да зур таләпләр куйды. Без, укучылар, чыгачак трилогиянең әнә шул таләпләр югарылыгында булачагына өмет баглап, әдәбиятыбызның тагын да уңышлы әсәрен кулыбызга алырбыз дип ышанып торабыз.

**Галимҗан ВӘЛИЕВ.**
Түбән Кама.

## Роза Хәлиуллинага 60 яшь



Шагыйрә Роза Заһит кызы Хәлиуллина 1931 елның 14 июнендә Татарстанның Актаныш районы Әҗәкүл авылында туган. Җиде класс белем алгач, Такталачык авылы больницасы каршында алты айлык курсларда укый һәм 1948 елга кадәр медсестра булып эшли. Аннары Казан җиңел промышленность профессиональ-техник училищесын тәмамлый, аяк киемнәре комбинатында оператор булып эшли, кичке мәктәптә, 1952—1956 елларда медицина училищесында укый. Дәвалаучы-акушер дипломы алгач, Казанның төрле медицина учреждениеләрендә һәм промышленность предприятиеләрендә эшли. 1966—1969 елларда, хезмәтеннән аерылмыйча, Казан медицина институтында укый. 1978 елдан ул — профессиональ язучы.

Шигырьләре 1960 елдан башлап республика газета-журналларында, «Беренче карлыгачлар», (1969), «Беренче адымнар» (1971), «Кызлар җыры» (1977) кебек күмәк җыентыкларда басыла. 1973 елда «Бәрләгәнгә медаль», 1977 елда «Чүкеч — нәни булышчы» исемле нәниләр өчен китаплары дөнья күрә. Җитмешенче елларда исә шагыйрәнең «Каенана» поэмасы (1977 ел, 10 сан, «Казан утлары»), «Агыйдел — аккош иле» (1980), «Идел суы илле батман» (1984) исемле лирика китаплары, «Актанышым» кебек җырлары танылу тапты. Р. Хәлиуллина — 1981 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

## Габделхәй Сабитовка 60 яшь



Габделхәй Вәли улы Сабитов 1931 елның 28 июнендә Татарстанның Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында колхозчы гаиләсендә туган.

1949 елда Күзкәй урта мәктәбен тәмамлаганнан соң укытучы булып эшли башлый. 1956 елдан журналист һөнәрен үз итә, Минзәлә районы газетасы редакциясенә эшкә алына.

1960 елда Мәскәүнең М. Горький исемендәге әдәбият институтында укып кайтканнан соң — Казан телевидение студиясендә әдәби-драматик тапшырулар буенча өлкән редактор, аннан республика балалар журналы «Ялкын» редакциясендә әдәби бүлек мөдире. 1965 елда ул «Чаян» журналы редакциясендә эшли башлый. Журналистика белән беррәттән, Г. Сабитов туктаусыз иҗат итә, хикәяләр, драма әсәрләре яза. Аның «Туган җир туфрагы», «Агач аяклы кеше», «Өч күңел», «Урман кызы», «Үлемсез Акылгали» кебек халыкчан матур тел белән, кызыклы сюжетларга корып язылган хикәяләрен, әкиятләрен укучылар яратып кабул итәләр. «Кичерелмәс гөнаһ», «Гарасат» драмалары Минзәлә дәүләт театры репертуарына кертелеп, сәхнәдә уйнала. Соңгысы СССРның 50 еллык юбилее уңае белән оештырылган конкурста (1973) бүләккә лаек була. Бер-бер артлы «Туган җир туфрагы», «Үлемсез Акылгали», «Тармаклы яшен» һ. б. китаплары басылып чыга.

Г. Сабитовның әсәрләре, бигрәк тә хикәяләре, сәнгатьчә эшләнеше һәм идея-эстетик хасиятләре җәһәтеннән югары сыйфатлы булуы белән аерылып тора. Ул әдәби тәрҗемә эше белән дә нәтиҗәле шөгыльләнә.

Татарстан Язучылар берлеге һәм «Казан утлары» журналы редакциясе коллективы юбилярларны ихлас котлыйлар һәм аларга нык сәламәтлек, озын гомер, яңа иҗат уңышлары телиләр.

# *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

## СӘЯСИ ВАКЫЙГАЛАР ХРОНИКАСЫ

25 апрельдә СССР Президентының тугыз союздаш республика белән «Илдәге хәлне җайга салу һәм кризистан чыгу буенча кичектергесез чаралар турында» уртак белдерүләре игълан ителгәннән соң Татарстанда сәяси хәл кискенләште. Республика шәһәрләрендә күпсанлы халык катнашкан митинглар ешайды.

8 майда «Татарстан Республикасының Союз килешүендә катнашуы турында» ТССР Югары Советы, Министрлар Советы, КПСС рескомы, профсоюзларның республика Советы һәм ВЛКСМ рескомының уртак белдерүе басылып чыкты.

12 майда ТССР Югары Советы үзенең IV сессиясен дәвам иттерде. Сессиядә Татарстан Конституциясенә өстәмәләр кертелде. Татарстан Президентын сайлау турында Закон кабул ителде. Шунда ук, 13 май көнне, Татарстан Президентын һәм РСФСР Президентын сайлау көне итеп 12 июнь билгеләнде. Карарның РСФСР га Президентны Татарстанда да сайлау турындагы өлеше зур ризасызлыклар тудырды, республикадагы сәяси киеренкелекне тагын да көчәйтте.

24 майда татар язучыларының ТССР Югары Советына һәм республика хезмәт ияләренә мөрәҗәгате басылып чыкты. Анда: «Татарстанда Россия Президентын сайлау — үз Декларациябездән ваз кичү дигән сүз» — кебек юллар бар. Мөрәҗәгатькә 137 язучы кул куйды.

Шундый ук мөрәҗәгать СССР Фәннәр Академиясенең Казан Фән Үзәге Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты коллективы тарафыннан да ясалды.

13 майда, ТССР Югары Советы сессиясендә РСФСР Президентын Татарстанда да сайлау турында карар кабул ителгәч, моңа кискен ризасызлык йөзеннән, республиканың халык депутаты, язучы Фәүзия Бәйрәмова сәяси ачлык игълан итте. Берничә көннән аңа шагыйрь Р. Әхмәтҗанов, «Мәрҗани җәмгыяте» рәисе, техник фәннәр докторы һәм әдәби әсәрләр авторы З. Зәйнуллин, соңра артист И. Әхмәтҗанов, тагын бераздан шагыйрь Г. Морат, язучы Ә. Мушинский, журналист З. Мәхмүди дә кушылды. Ирек мәйданында сәяси ачлык игълан итеп утыручыларның гомуми саны егермегә якынлашты. Алар арасында авыл механизаторлары агалы-энеле Зиннур һәм Рифгат Шәмсетдиновлар (Алексеевский районы), Фазыл Вәлиәхмәтов (Бөгелмә), Нәкыя Зиннурова (Алма-Ата), Абдул хәзрәт Алмаз углы (Баку), педагог-тәрбияче Әнисә Нурисламова (Чаллы) һ. б. бар иде.

Моннан тыш, сәяси ачлык белдерүчеләр янында, утырып торып, эш ташлаучылар да җыелды. Күбесе — студентлар һәм хатын-кызлар иде. Алар янына дин әһелләре күп килде, намаз укуларны шунда оештырдылар.

Фәүзия Бәйрәмова башлаган сәяси ачлык 27 майга кадәр, ягъни Югары Совет сессиясенең эше кабат башланганчыга кадәр, дәвам итте.

Бу көннәрдә Ирек мәйданында һәм республиканың күп шәһәрләрендә меңнәрчә кешеләр катнашында митинглар дәвам итеп торды.

Татарстан халык депутатларыннан 50 дән артык кеше, язучы депутатлар җитәкчелегендә, бу хәлдән чыгу өчен, ТССР Югары Советының РСФСР Президентын Татарстанда да сайлау турындагы карарын кабаттан тикшерүне сорап, республиканың Конституция күзәтчелеге комитетына сорау язды.

Комитет 18 майда, карарга төзәтүләр кертелергә тиеш, дигән нәтиҗәгә килде.

27 майда ТССР Югары Советы сессиясе, Конституция күзәтчелеге комитетының күрсәтмәсенә таянып, мәсьәләгә яңадан әйләнеп кайтты. Сессиядә бәхәсле чыгышлар башланды. Язучылардан Р. Фәйзуллин, Ф. Бәйрәмова чыгыш ясадылар, СССР халык депутаты Т. Миңнуллин һәм РСФСР халык депутаты Р. Мөхәммәдиев карарны үзгәртү белән шөгыльләнүче килешү комиссиясе эшендә катнаштылар. Ниһаять, түбәндәге карар чыгарылды:

1. ТССР, суверен дәүләт буларак, Россия Президентын сайлауда рәсми рәвештә катнашмый.
2. ТССР, кеше хокуклары принципларын алга сөреп һәм аларны хөрмәт итеп, теләге булган гражданнарга РСФСР Президентын сайлаулар көнендә хокукларын гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтә.
3. ТССР гражданнарының Татарстан территориясендә Россия Президентын сайлауларда катнашуы ТССР дәүләт суверенлыгы нигезләрен какшатмый.

12 июнь — ТССР Президентын сайлаулар көне. Бюльлетеньдә бердәнбер кандидат — ТССР Югары Советы Рәисе М. Ш. Шәймиев.

Татар халык язучысы Нәкый Исәнбәт «Шәһри Казан» газетасы аша М. Ш. Шәймиевның Татарстан Президентлыгына кан-

дитатурасын яклавын белдереп чыкты. Аның бу язма-игъланы татар халкын М. Ш. Шәймиевне Президентлыкка сайларга өндәү булып яңгырады.

## КАЗАН ТӨРКИЯДӘН КИЛГӘН КУНАКЛАРНЫ АЛКЫШЛЫЙ

30 майда Казанга йөз иллеләп төрек кунагы килеп төште. Алар арасында күпсанлы язучылар, артистлар, мәдәният һәм бизнесменнар бар иде. Кунаклар Баку аша килделәр. Беренче көнне үк алар К. Тинчурин исемендәге театрда Казан шәһәре җәмәгатьчелеге белән очраштылар 31 май көнне дусларча әңгәмә ТССР Язучылар берлегендә узды.

Очрашулар башка урыннарда да эчкерсез дуслык мөнәсәбәтләрендә үтте.

## МӘДӘНИЯТ ДӨНЬЯСЫНДА

Июнь ае башыннан Мәскәүдә, Бөтенсоюз сәнгать лотореясы залында (Урал урамы), татарның күренекле рәссамы Әхмәт Кытаевның шәхси күргәзмәсе ачылды. Бу — татар дөньясы өчен, Мәскәүдә оештырылган, бик әһәмиятле чара. Моңа, әлбәттә, рәссам эшчәнлегенең күп тармаклы һәм нәтиҗәле булуы этәргеч биргән. Ә. Кытаев әсәрләренең күчермәләре 200 000 000 нан артык дип исәпләнә.

14-16 майларда СССР Фәннәр Академиясенең Казандагы Фән Үзәгендә, күренекле галим Фоат Вәлиевнең тууына 70 ел тулу уңаеннан, татар халкының мәдәнияте, сәнгать һәм тарихы мәсьәләләренә багышланган фәнни конференция уздырылды. Аның «Алтын Урда һәм татар халкының тарихы» дигән темага «түгәрәк өстәл янында сөйләшү» өлеше 16 майда оештырылды. Конференциядә АКШ профессоры А. Франк та катнашты.

Татарстан Үзәк фәнни китапханәсе инде дүртенче ел рәттән иң күп укыла торган китапларга ярыш уздырды һәм 1989 елда чыккан китапларның 1990 ел дәвамында никадәр укылуына нәтиҗәләр ясады. 23 апрельдә җиңүче китапларның авторларына китапханәнең һәм Китап сөючеләр җәмгыятенең мактау кәгазьләре тапшырылды. Бүләкләнүчеләр арасында балалар өчен китап чыгарган язучылардан Г. Бәширов, М. Фәйзуллина, Х. Халиков, К. Тимбикова, Җ. Тәрҗеманов һ. б. бар

26 майда Казанның төрле мәйданнары гармун моңнарына күмелде. Соңгы елларда гадәткә кереп баручы «Уйнагыз, гармуннар!» бәйрәме иде бу. Тантанага республиканың һәр төбәгеннән һәм күп кенә күрше өлкәләрдән килгән һәвәскәр гармунчылар, җырчылар, биючеләр катнашты. Бәйрәм барган мәйданнарда ярминкәләр эшләде.

## «РАМАЗАН» БӘЙРӘМЕ ЕРАКЛАРГА ТАРАЛА.

Күренекле җырчыбыз Ринат Ибраһимов җитәкчелегендәге «Сәфәр» үзәге башлап җибәргән яңа бер чара — «Рамазан» бәйрәме быел тагын да киңрәк колач белән уздырылды. Аның чыгышлары Мәскәүдә башланып китте. Аннары Казан, Уфа, шәһәрләрендә дәвам итте. Урта Азия шәһәрләренә дә барып җитте. Анда чит ил артистлары да катнашты. Кичәләр махсус сценарий нигезендә, мавыктыргыч сюжет буенча төзелгән иде. Тамашаның үзәгендә Кол Гали образы гәүдәләнә. Башка чыгышлар шуңа бәйле рәвештә дәвам иттерелде.

Халык артисткасы Вафирә Гыйззәтуллина җитәкчелегендәге зур бер төркем исә «Рамазан» бәйрәмен Төмәндә уздырды. 27-28 апрельдә Төмәннең Спорт сараена бу төбәктәге татарлар агылды. Ерак арадагы татарларны, Төмән өлкәсе җитәкчелеге ярдәмендә, концертка вертолетлар белән ташып тордылар. Концерт В. Гыйззәтуллина үзе төзегән «Уяну» исемле сценарий буенча алып барылды.

## ТАРИХЫБЫЗНЫ ӨЙРӘНҮ ӨЧЕН

«Мирас» фондының Чаллыда яңа бүлеге оештырылды. Бүлекнең региональ Советы сайланды. Аңа фольклор белгече профессор Ф. Урманчиев, доцент Ә. Шәрипов, Чаллы мәчете имамы хатыйбы Идрис хәзрәт, шәһәр советы вәкиле С. Әхмәтов һ. б. керде. Советның рәисе — публицист Ф. Дунай, сәркатибе — журналист В. Гофман.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Совет әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен шагыйрь Рәшит Ханиф улы Әхмәтҗановка ТССР Югары Советы Президиумының 1991 ел, 10 апрель Указы белән, «Татарстан ССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.


* * *

1991 елның 3 апрель карары белән, 50 яшь тулу уңаеннан һәм татар совет әдәбияты өлкәсендәге уңышлары өчен шагыйрь, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рәдиф Кашфулла улы Гатауллин (Рәдиф Гаташ) ТССР Югары Советы Президиумының Мактау Грамотасы белән бүләкләнде.

# АЛТЫН ШИШӘК

Ачыш, әгәр моны шулай дип атарга яраса, кайчак бер дә уйламаган җирдә дә ясала, күрәсең. Бүлмәдә нәрсәдер язып утырганда дивардагы зур календарьга күзем төште. Анда энҗе, алмаз, асылташлар белән бизәлгән алтын шишәк (аны борынгылар ашук та дип йөрткәннәр) очындагы зәңгәр-күк фирүзә мозаиканы кайдадыр күргәнем бар шикелле тоелып китте. Мондый зәңгәркүк төс, асылда, борынгы татар истәлекләренә хас. Савыт-саба ясаганда да, сарайлар салганда да аны киң кулланганнар. Күрәсең, бабаларыбызның яраткан төсе булгандыр ул. Шундый бизәк ничек итеп урысның алтын шишәге очына эләккән соң?

Һәм кинәт... мозаика астындагы алтын нәкыш — бәдиз эченә яшерелгән гарәп хәрефләрен абайлап алдым. Гаҗәпләнүем бермә-бер артты. Бусы инде берничек тә урыс шишәге белән сыеша алмый торган нәрсә!



Календарьдагы белешмәдә шишәкнең 1621 елны патша Михаил Федоров өчен Никита Давыдов дигән оста тарафыннан эшләнүе язылган иде. Бу мәгълүмат та берничә ачыклык кертмәде. Мондый катлаулы бизәк эченә урнаштырылган гүзәл язуны аеруча талантлы нәкышчылар гына башкара алган. Эзләнә башладым. 1902 елда чыккан «Художественные сокровища России» дигән китапта әлеге шишәк турында шундый ук фикер кабатланса да, өстәп, аның Свинин, Малиновский атлы кешеләр тарафыннан өйрәнелгәнлеге, аларның бу затлы сугыш киеме Александр Невскийныкы булган дигән риваятьне искә алулары әйтелгән иде.

Бу фаразда азмы-күпме дөреслек булуы ихтимал. Чөнки А. Невский — татар патшаларының турылыклы йомышчысы (олысбашы). Шишәктәге язуның мәгънәсе дә шуны раслый кебек. Аны «... һәм туганын җиңүче» дип фараз кылырга була. Елъязмалардан күренгәнчә, А. Невский урда ханнарына каршы көчле гаскәр туплаган агасы Андрейны тар-мар итә һәм үзе бөек кенәз исемен ала.

Хәзер татар бизәге төшкән һәм гарәпчә язулы берничә шишәк билгеле. Фәндә, кызганычка каршы, мондый табышларга карата шома эшләнгән терминология кулланыла. Идел буе шәһәрләрендә эшләнеп, мәдәният югарылыгын күрсәткән бу әйберләрне исемсезләндереп, гадәттә, «Көнчыгышта эшләнгән» дип кенә карыйлар.

Югарыда тасвирланган шишәк Болгар нәкышчылары тарафыннан эшләнгән булса кирәк. Беренчедән, шундый ук шишәкнең Төньяк Кавказда, кыпчак курганнарында табылганы бар. Икенчедән, XIII йөзнең 40-50 елларында Көнчыгыш Европада монгол һөҗүмнәреннән соң тиз арада аякка бастырылган шәһәр бер генә — ул шәһри Болгар. Бары тик Болгар нәкышчылары гына хан заказын үтәп, шәхси язулы мондый нәфис шишәкне эшли алган булырга тиеш.

Никита Давыдовка килгәндә исә, шишәкне бизәүдә ул да үз өлешен керткән. Мәсәлән, борынча өстенә Архангел Михаил сурәте беркетелгән, ә татар таҗы өстенә тәре сызылган. Тик алар тупасрак. Төсе белән дә, формасы белән дә алар башка стильдә эшләнгәннәр.

**Әзһәр МӨХӘММӘДИЕВ.**

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган язучы Ләбибә Ихсанова.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотолары.

Бәясе 1 сум 50 тиен. Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРСТАНА
(на татарском языке)